ISSN 0206

# Казан утларь

2.1986



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

2

1986


## *Бу санда*


КПССның XXVII СЪЕЗДЫН КАРШЫЛАП

Ә. СӘГЫТДИНОВ. Җир баласының бәхете . . . 3

ГЕРОЙ-ШАГЫЙРЬГӘ — ЧӘЧӘКЛӘР

М. РАФИКОВ. Ике сын. *Шигырь* . . . . . . 8
Р. ЗӘЙДУЛЛИН. Җәлил кояшы. *Шигырь* . . . 8
Г. МОРАТОВ. Җәлил һәйкәле янында уйлану. *Шигырь* . . . . . . . . . . . . . . 9
Н. ШӘМСЕТДИНОВ. Тынлык — набат. *Шигырь* . 10

МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Р. МОСТАФИН. Муса Җәлил турында. . . . . 11
Ә. ЕНИКИ. Муса Җәлил хатлары. . . . . . . 19
Ш. ХАММАТОВ. Нигез ташларын салганда. . . 23
М. ХӘСӘНОВ. Идел һәм Муса. *Истәлек* . . . . 29
П. АПАКАЕВ. Лачыннар канат ныгыта . . . . 31
В. ДЕМЕНТЬЕВ. «...Җыр өйрәтте мине хөр яшәргә!» . . . . . . . . . . . . . . . 33

Ә. КАСЫЙМОВ. Җир балкышы. *Роман* . . . . 37
Р. ХАФИЗОВА. Әти кайткан көн. *Хикәя* . . . 120
С. ӘХМӘТОВ. «Май аенда»... *Фантастик хикәя* . 126

ТУКАЙНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

Өчиле. *Т. Хаҗиәхмәтов рәсеме* . . . . . . . 134
М. ӘГЪЛӘМОВ. Тукайдан хатлар. Поэма . . . 136
Р. НӘФИКОВ. Тукайның дусты, партия солдаты . 151
Ф. ӘГЪЗӘМОВ, Р. ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ. Әдипнең матбугатка карашлары . . . . . . . . . 154

ТАТАРСТАН — ТУГАН ТӨБӘГЕМ

И. Г. ЗӘЙНУЛЛИН. Буа районы . . . . . . 160

ТАРИХЫБЫЗ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

С. АЛИШЕВ. Батырша батырлыгы . . . . . 164



КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

З. МАНСУРОВ. Йөрәк бәйрәме . . . . . . . . 171

ТӘРҖЕМӘ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШӘБЕЗ

Р. САФАРОВ. Киңәшергә кирәк. . . . . . . . 181
Л. ЛЕРОНОВ. Моңны ачар ачкыч бармы? . . . 182

БИБЛИОГРАФИЯ

Ш. АБИЛОВ. Бөек шагыйрьнең үлемсез әсәре. . 185

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА

М. БОГОЛЮБОВ. Профессор Таһирҗанов . . . 189

Культура тормышы көндәлеге. . . . . . . . . 191

Тышлыктагы сурәтләр. . . . . . . . . . . . 192

*Баш редактор*
**РЕНАТ ХАРИС**

*Редколлегия*

**МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ**
**ӘХӘТ ГАФФАР**
**МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ**
**АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ**
**МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ**
**МӘДИНӘ МАЛИКОВА**
**САЛИХ МАННАПОВ**
*(җаваплы секретарь)*
**ТУФАН МИННУЛЛИН**
**ФЛҮН МУСИН**
**РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ**
*(баш редактор урынбасары)*
**РӘФЫЙК НӘФИКОВ**
**НУРИХАН ФӘТТАХ**
**СИБГАТ ХӘКИМ**
**РИЗВАН ХӘМИД**
**НИЛ ЮЗИЕВ**
**АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН**

Безнең адрес: 420066,
Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор — 53-07-60,
баш редактор урынбасары —
53-07-09,
җаваплы секретарь — 53-07-09,
*бүлекләр:*
проза, поэзия, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар — 53-07-63.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

Навстречу XXVII съезду КПСС. Очерк А. САГЫТДИНОВА о батыре хлебного фронта Раисе Хасаншине.

К 80-летию Мусы Джалиля: статьи Р. МУСТАФИНА, Ш. ХАММАТОВА, В. ДЕМЕНТЬЕВА, воспоминания А. ЕНИКИ, М. ХАСАНОВА, П. АПАКАЕВА; стихи М. РАФИКОВА, Р. ЗАЙДУЛЛИНА, Г. МУРАТОВА, Н. ШАМСЕТДИНОВА.

Окончание романа Э. КАСЫМОВА «Сияние земли»; рассказы Р. ХАФИЗОВОЙ, С. АХМАТОВА.

К 100-летию Габдуллы Тукая: рисунок Т. ХАЗИАХМЕТОВА, зарисовка «Учили», поэма М. АГЛЯМОВА; статьи Р. НАФИКОВА, Ф. АГЗАМОВА и Р. ГИЛЬМЕТДИНОВА.

В рубрике «Татарстан — родной мой край» статья первого секретаря Буинского райкома КПСС И. Г ЗАЙНУЛЛИНА.

В рубрике «Литературная критика» статья З. МАНСУРОВА. Начинается обсуждение проблем литературного перевода (письма читателей).

Рецензия Ш. АБИЛОВА на издание «Кул Али. Киссаи Юсуф».

Материалы к истории: очерк С. АЛИШЕВА «Подвиг Батырши»; статья М. БОГОЛЮБОВА «Профессор Тагирджанов».

«Трезвость — норма жизни»: рисунок С. ПРИВИНОЙ.

Новости культуры. На наших обложках — творчество художника В. Скобеева.

Техник редактор *Р. Сөләйманова.* Корректорлар *Г. Салихҗанова, А. Садыйкова.*

Производствога бирелде 9.12.1985 ел. Басарга кул куелды 11.02. 1986 ел. ПФ 05051. Офсет. ысулы белән басылд.
Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 62549. Заказ Ф-532. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе,
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1986 ел.

## Әсгат Сәгытдинов

# ҖИР БАЛАСЫНЫҢ БӘХЕТЕ

Тормышның үзәге — җәй. Көз — җимешле чак. Җир өстен алтынсу яфраклар каплаган. Һәр тараф өлмая. Кояш җирнең һәр күзәнәгенә, кышкы суыкларда сыгылып төшмәс өчен, нур иңдерә кебек. Арыш, бодай бөртекләре ничек тулышалар! Икмәк муллыгы өчен алны-ялны белми тырышучы игенчегә шуннан да зур шатлык юк. Кояш нуры белән өртелгән бөртекләргә үзенең маңгай тирен, йөрәк җылылыгын да өстәргә игенче һәрвакыт әзер. Шуңадыр, мөгаен, мин игенченең елмаюлы йөзендә бодай, арышларның төсен дә күрәм. Комбайнчы Рәис Хәсәншин йөзенә исә ул төс аеруча мул иңгән шикелле.

Беренче тапкыр без моннан биш ел элек Чәкән басуында очраштык. Ул — штурвалда, мин сораулар бирәм.

— Эшләр ничек, Рәис?

— Бик начар түгел. Арыш гектардан 25 әр центнер чыга.

Карап торуга какча гына, юка гына гәүдәле егет ул. Әмма «Колос» штурвалында баһадирдай күренә. Йөзендә елмаюы китеп тормый. Шулай да бу юлы комбайнда килеш иркенләп сөйләшә алмадык.

Бункер тулуын белдереп лампочка да күз кысты. Шуны гына көтеп торган сыман, янәшәгә «ЗИЛ» килеп тукталды. Яшь шофер Мөнирҗан Шәрифуллин:

— Әйдә, төшкелеккә киттек! — дип кычкырды.

Хәсәншинның ул турыда исендә дә юк иде. Искәрүче табылгач, кыр вагонына көйләнгән ашханәгә киттек.

— Минем шунысы уңайлы,— диде Рәис аш өстәленә утыргач, сорау бирәчәгемне сизгәндәй,— уракка төштеңме, абыйлар, энеләр ярдәмгә киләләр. Былтыр абый Себер төзелешеннән ялга кайткан җиреннән миндә ярдәмче булды. Быел Рифгать энекәш кунакка килеп, монда эләкте. Аңа техникадан башка берни кирәкми!

— Яшьләр үзләре бер участокта булгач, кыен түгелме?

— Без үзебез генәмени?! Әнә Мөгамбәр абый Шакиров. Коммунист, Алексей Маресьев кебек чын кеше дияр идем. Бер кулы юк аның. Ватан сугышыннан инвалид булып кайткан. Үзе — фронттан кайтканнан бирле комбайнчы. Аның хезмәте генә түгел, безнең кебек яшьләргә ярдәм итүе дә тәрбия чарасы булып тора. Мондый остазлар белән таулар күчерергә мөмкин!..

Икенче көнне район газетасында яңа рекорд турындагы хәбәр басылды. Хәсәншин нормадагы 260 центнер урынына бер сменага 1050 центнер ашлык суктырган. Нәкъ стахановча! Көннең икенче яртысында аны бу җиңүе белән КПСС райкомының беренче секретаре, басуга килеп, тәбрик итте. Бу елны Хәсәншинның хезмәт батырлыгы бөтен Татарстанны шаулатты: «Колос» комбайнында бер сезонда 16 600 центнер ашлык суктырды. Кайберәүләр ышанырга да белмәде — шартлы центнерлардыр, дип бәхәсле сүзләр йөрттеләр. Бу фидакарьлеге егерме биш яшьлек Рәисне республика чемпионы итте.

Шуннан соң без аңардан тагын да зуррак күрсәткечләр көтәргә хаклы идек. Ләкин беркадәр вакыт комбайнчы Хәсәншин фамилиясе телдән төшеп торды. Уңган кешегә аяк чалучысы да табылып тора бит ул. Совхоз директорының урынбасары булып алган берәү Рәискә колачлап эшләргә һич ирек бирми генә бит! 1981 ел иде ул. Үзем дә тап булдым бу күренешкә.

Хәсәншин турындагы яңа язмага материал туплап йөрим. Аның турында сөйләмәскә кушалар. Өстәвенә, сәбәбен дә әйтмиләр. Рәис янына киттем. Эш участогы бирми җәфалаганнар егетне.

Бүлекчә управляющие Григорий Митяшкин белән киңәшләштек. Ул үз сүзендә нык торды.

— Сине кыерсытмакчымы? Булыр ул мәнсездән,— диде ул.— Икмәк язмышы белән уйнарга ярамый. Әнә сиңа басу! Бөтен җаваплылыкны үз өстемә алам. Урып бетермичә чыкма, комбайныңны туктатма!

Өлкән коммунист Митяшкин үзсүзле җитәкче белән дә шулай өздереп сөйләшкән. Портфельгә генә кызыгып йөрүче урынбасар һаман комачаулап тора башлагач әйткән:

— Үзең тикшереп кара башта, эш кешесен сәбәпсезгә рәнҗетеп йөрмә! — дигән.

Әй эзләде, әй төпченде тегесе Рәиснең җитешсезлеген. Юк кына бит! Комбайнчыдан кимчелек таба алмады.

Соңыннан бу киребеткән бәндәгә калган механизаторларның да ачуы килә башлады.

— Җиттеме сиңа, юкмы? — диделәр аңа бертавыштан.— Эш кешесенең ачуын кабартудан совхозга ни файда китерәсең?

Һәм ул шул каешланган портфелен култык астына кыстырып, совхоздан китеп барырга мәҗбүр булды.

Рәис Хәсәншин исә сабыр гына эшли бирде. Сер түгел, монда аның да һәр адымын сынап тордылар. Ул үзе дә сигез-тугыз чакрымдагы Яңа Сөендек авылыннан күчеп килгән иде. Техника тартып китерде аны. Вахитов исемендәге совхозның республиканы шаулаткан чаклары иде. Совхоздагы техника паркын сокланып карап чыкты Рәис. Үзләрендә кечкенә генә бер детальне эзләп каңгырып йөргән көннәре иде. Техника прогрессы нык үскән чорда заманнан артта калып яшәргәме? Аралар да ерак түгел: бу җирләр дә Ык тугайларында, аларныкы да. Өстәвенә, яңарак кына өйләнеп җибәргән чак, хатыны Лимуза — шәфкать туташы. Авылларында аңа эш таба алмадылар. Вахитовлылар эшен дә, өен дә, өр-яңа техника да бирделәр аларга. Совхозга «Колос» комбайны кайткан иде. Рәис әле автомеханик булып кына эшләп йөри. Комбайнга бик кызыкса да, катнашым юк, дип, эндәшми торды. Совхоз комбайнчылары исә, катлаулы дип, «Колос»ка якын да килмиләр. Ниһаять, Рәис директордан рөхсәт сорады.

— Бик хуп! — диделәр аңа.— Кыю кеше икәнсең! Әйдә!

Рәис башта комбайннан файдалану кагыйдәләрен өйрәнде. Эштән бушаган араларда комбайнны җыярга тотынды. «Колос» бик тыңлаулы машина булып чыкты: Хәсәншин беренче елда ук, аның белән 14 000 центнер ашлык суктырып, район күләмендә алга чыкты. Әле Башкортстанның Шаран районына барып та булышып кайтты. Рәхмәтнең иң зурысын Мирсәяф абый Мөкъсиновка әйтте.

— Үзең әйбәт син,— диде остазы.— Синең җаныңа машина җене кагылган.

Рәис белә: аның этисе Барый ахак тимердән авылдашларына гомере буена ни генә ясамый иде?! Малай чактан шул алачыкта сандал тирәсендә уралды Рәис. Күрекне дә өрдереп торгалады. Аннары тырма тешләрен очларга ярый башлады. Җиденчене тәмамлагач, абыйсы Рафис тракторына сабанчы булып чыкты. Ун көн чамасы эшләделәрме икән — Рафис:

— Кәефем юк, район больницасына барып кайтмый ярамас,— дип, Рәискә сүз кушты.— Тракторны сиңа гына калдырсам, караңгыда шөлләмәссеңме?

Трактор кадәр трактор алып калырлык булып үсеп җит тә, «шөллә», имеш. Рәис башланган җирне сөреп бетерде, яңа участокка да юл сызды. Дөрес, анысы бераз кыеграк иде кыегын: төнлә булган эш бит. Аның каравы, өйләренә каһарман кебек кайтып керде!

Икенче елны Рәисне бик оста комбайнчы Гобәйдулла Вәлиевкә ярдәмче итеп куйдылар. Бик таләпчән иде Гобәйдулла абый, йөгертте генә егетне. Алар ул елны 5000 центнердан артык ашлык суктырдылар.

Сигезенчене мактау грамотасы белән тәмамлаганда Рәиснең максаты тәгаен расланган иде: техника хуҗасы булырга!

— Белемеңне югалтма, техникумга китәргә кирәк сиңа! — дип үгетләде аны класс җитәкчесе Фоат Кәлимуллин.

— Ялгышмадыңмы соң? — дим Рэискә.

— Ун гомер бирелсә дә, шушы юлдан барыр идем. Армиягә киткәндә мин тракторчы да, шофер да идем инде. Дизельче-механик булып хезмәт иттем.

Совет Армиясе сафларына 1973 елның көзендә комбайнда ашлык суктырган җиреннән, басудан озаталар Рәисне. Яхшы хезмәте өчен ике тапкыр ялга кайта, туган кырларны сагынуын басылдырып та китә. Армиядән соң егет һич икеләнүсез тракторга утыра. Озакламый Рәис, яңадан-яңа машиналарның серенә төшенерлек белем алу өчен,Казан авыл хуҗалыгы институтына укырга керә. Хәзер ул — институтны тәмамлау алдында.

Бөтен ил фән прогрессын күздә тотып эшләргә алынган бүгенге көннәрдә Рәис, канатланып эзләнергә — машиналарны, урындагы шартларга карап көйләү буенча яңалыкларны киңрәк кертергә, тагын да камилләштерергә тырыша.

— Төп бәла яхшы әзерлекле белгечләр җитмәүдә,— ди ул.— Бездә яңа агрегатлар файдасыз ята. Кайчак безнең эшләр өчен бөтенләй кирәксезләре дә кайтарыла. Шуңа безнең акча түләнә. Барысы да — белмәү нәтиҗәсе. Ахырда өр-яңа машина металлоломга китә. Аны бит кайдадыр көткәннәрдер, дефициттыр әле, бәлки?..

Соңгы вакытта Рәис ярты ел гараж мөдире булып торды. Шунын да ике аен комбайнда үткәрә әле ул. Аны кышкы саклаңышка урнаштыруга ук, машиналарны механик ысул белән чистарту җайланмасын, эстакада ясау мәшәкате артыннан чаба башлый. 40 машина сыешлы яңа гаражда күп уңайлыклар бар инде. Машиналарның аерым өлешләрен ремонтларлык мөмкинлекләр бар анда, җылы, иркен.

Рәис тәҗрибәле хуҗалыклардан өйрәнергә ярата. Тукай районының «Гигант» совхозында, мәсәлән, гектардан 50 шәр центнер ашлык җыялар. Монда Рәиснең бертуган абыйсы Рәсим управляющий булып эшли. Казанга имтиханнар тапшырырга барганда да, башка чакта җае чыкканда да Рәис абыйсына керә. Алар гигантлыларның тәҗрибәсен өйрәнә. Шундагы яңа алымнарны күрү Хәсәншинга диплом темасын сайлаганда да ярдәм итте. Чәчү әйләнешен фәнни нигездә, урындагы шартларга карап билгеләү, интенсив технологиягә таяну турындагы курс эшләрен бик яхшыга яклады. Диплом эше фәнни хезмәткә әверелеп бара.

Рәисләр совхозында кичекмәстән үзгәртелергә тиешле нәрсәләр шактый. Мәсәлән, Чәкән бүлекчәсендә пар җирләре 11-12 процент чамасы. Илебезнең почетлы академигы, бөек практик Т. С. Мальцев пар җирләре 20 проценттан кимрәк булса, аларны калдырмау хәерлерәк, дип дистә ел элек үк әйткән иде. Моны үтәргә кирәк! дип чыга Рәис Хәсәншин. Кара туфраклы Чәкән кырларында уңыш тотрыклы булырга тиеш! Соңгы елларда фәнгә таянып эш иткәч, 270 гектардагы арышның һәр гектарыннан —36; 245 гектардагы борчактан —25,4; 150 гектардагы солыдан —30; 1040 гектардагы бодайдан 27 шәр центнер уңыш алынды. Рәис боларның күбесен үзе җыеп суктырды.

Менә сиңа фәнни игенчелек! Әле былтыр гына махсус эзләр калдырып эшкәртелгән арыш, бодай басуларына сәерсенеп караучылар бар иде. Янәсе, күпме буш урын калдырыла. Рәис аны академия тәмамлаган агроном Камил Миңнуллин белән бергә өйрәнде. Бергә чәчтеләр. Рәис икенче язда да, тракторга утырып, бодай чәчеләсе җирне үзе әзерләде: тырмалады, культивацияләде. «Серле» эзләргә җәй буе күз салып үтә торган булды. Институт хуҗалыгында күргәннәрен дә истә тотты: анда «Беларусь» тракторы белән җәй буена кишәрлек-кишәрлек булып салынган эзләрдән узып, игеннәр тармаклана башлагач ук, төрле минераль ашламалар, препаратлар кертәләр. Күгәрек авыруларына һәм чүп үләннәргә каршы эшкәртү уздырдылар.

— Хәзер безнең совхозда интенсив технологиягә елдан-ел ныграк әһәмият бирелә,— ди совхозның баш агрономы В. Лямбин.— Уңышны күтәрүнең иң ышанычлы алымы ул. 1985 елда без 704 гектардагы бодайның гектарыннан 34,3; 360 гектардагы арыштан 35,8 әр центнер бөртек җыеп алдык. Көздән исә арышны яңа алым белән 900 гектарда чәчеп калдырдык.

— Интенсив технология шартларында,— дип өсти Рәис Хәсәншин,— табигать шартлары уңайсыз килгәндә дә гектардан кимендә 35-40 центнер уңыш алып булачак.

Яңалыкларның берсе икенчесен әйдәп китерә. Рәис хәзер — коллектив подряды звеносында. Унҗиде егеттән торучы звено узган ел 2 374 гектарда иген үстерде. Гектардан 25 әр центнер уңыш алып, совхозда беренче урынга

чыктылар. Бу рәвешле эшләгәндә егетләр техникага да, җиргә дә үз итеп, хуҗаларча карыйлар.

— Әмма әле кайчакта, механизаторлар җитмәгәндә, звено егетләрен башка эшкә күчереп торгалыйлар,— ди Рәис.— Планнар җимерелә, тәртип какшый башлый...

Рәис Хәсәншин ныклы тәртип яклы. Сүзләрнең эшлекле булуын ярата ул. «Комбайннар парады» дигән чараның да тормышчан уздырылуын тели. Югыйсә, уракка төшәргә бер-ике атна кала, агрегатларны аннан-моннан карап кына, тыштан буяп-ялтыратып чыгарып тезәләр дә — бөтенесе әзер санала. Техниканың чын-чынлап төзәтелүе игътибар белән тикшерелми. Аннары урак өстендә машиналар ватыла башлый, әллә кайларга запас частьлар эзләп чабалар. Рәис бу мәсьәләгә һәрчак бик җитди карый. Күз буяудан берәүгә дә бернинди дә файда юклыгын яхшы белә ул. «Фән-техника прогрессына таянырга кирәк чакта мондый ялгыш юлдан барырга һич ярамый»,— ди ул. Дымны саклап калу өчен, бөртекне тиешле тирәнлеккә күмдерү өчен, мәсәлән, Мәҗитов уйлап чыгарган агрегат бик уңайлы. Башкортстанда аңардан киң кулланалар. Моны Рәис тә бик хуп күрә, тик шул агрегат үзебездә һаман өйрәнелмәгән. Кирәк чакта аны таба да алмыйсың әле.

Рәис аның үрнәген Башкортстаннан өйрәнеп алып кайта, аннары үз кулы белән корып-эшләп тә күрсәтә.

Узган елгы урак өстендә мин Рәисне кабат иген җыю вакытында очраттым. Янәшәсендә беренче елын гына эшләүче Юрий Рябов комбайны урдыра иде. Иләкләренә чүп тыгылып интектерә икән. Рәис комбайнын ярдәмчесенә — бертуган абыйсының улы Илгизгә калдырды да Юрий янына ашыкты. Ул да булмый, Федор Савельев комбайнының каешы өзелгәнен әйттеләр. Комбайныннан ашлык ташучы Владимир Черновка ым какты Рәис:

— Миндә запас каеш бар, юл уңаеннан бирә кит әле!..

— «Нива» комбайны бик уңайлы! — Рәис үз техникасына гашыйк.— Йөк машинасыннан җиңел машинага күчеп утырган кебек булды.

Хәсәншин узган ел да югары күтәренкелек белән армый-талмый эшләде. Иген уңган! Көннәр әйбәт! Җай гына суктырды да суктырды. 11 августта, мәсәлән, 673 центнер суктырды. Звенодагы өлкән комбайнчы Мирсәяф Мөкъсинов, комсомолец Виктор Тимошин, Виктор Бурцев, Әнвәр Галиев тә аннан бик азга гына калыштылар. Районның хезмәт батырларына КПСС райкомының беренче секретаре О. С. Мөхетдиновның котлау телеграммасы җибәрелде. 8 сентябрь көнне совхозның бу фидакарьләре 15 300 центнер ашлык суктырып алдылар. Мондый югары җитештерүчәнлек совхозда беренче тапкыр! Дәүләткә сатылган ашлык күләме — 67 000 центнер. Вахитовлыларның мондый җиңүне күргәннәре юк иде әле.

Рәис Хәсәншинның хезмәт биографиясендә андый истәлекле сәхифәләр, саный китсәң, байтакка җыела. Ул 1979 елдан бүгенгәчә барлыгы 63 224 центнер ашлык җыеп алган. Дүрт ел рәттән район беренчелеген үз кулында тотты. Узган ел — кабат Татарстан чемпионы. Аңа ВЛКСМ Үзәк Комитетының «Алтын башак» билгесе, ВДНХның бронза медале бирелде, исеме ВЛКСМ Үзәк Комитетының елъязмасына кертелгән.

...Кышкы озын кичләрдә Вахитов исемендәге совхозның спорт залы гөрләп тора. Яшьләр Рәисне әйләндереп алган.

— Гер күтәрү ярышы кайчан?

— Иртәгә безгә волейболчылар килә!

Ярышка тирә-күршедәге Мичурин исемендәге, «Авангард», «Марс», Ленин исемендәге колхозлардан, «Урманай» совхозыннан, 89 нчы һөнәр училищесыннан спортчылар җыела. Киң күкрәкле, нык бәдәнле егетләр көч сынашып кына калмыйлар, игенчелеккә кагылышлы мәсьәләләр турында да киңәшләшәләр. Дуслашалар. Кайберләре хәтта совхозга күчеп килергә чамалыйлар.

— Яшьләрне туган җиргә беркетеп калдыруда ял вакытларын оештыру да бик мөһим,— ди Рәис.

Совхозның ВЛКСМ комитеты секретаре Рәис Хәсәншин бүлмәсендә совхоз спортчыларының уңышларын күрсәтеп торучы кубоклар, мактау грамоталары, дипломнар бар. Соңгы елларда авыл яшьләре хоккейны аеруча ярата башладылар. Хоккейчыларга уен кирәк-яраклары да булдырылган инде.

Бу яңалыклар секретарьны тагын канатландырып җибәргән. Әле кайчан гына культура йорты алдында вакытны ничек үткәрергә белмичә аптырап

йөрүче, салмыш ир-атлар урала иде. Спортны, үзешчән сәнгатьне җанландыргач, андыйлар күренмәс булды.

— Техник иҗат түгәрәкләре дә ачып җибәрергә исәп,— ди Рәис.— Бу юлда да бер урында гына таптанырга ярамас.

Яшьләрнең һөнәрләрен арттыру турында да шулай башлап йөргән ул. Совхозның үзендә 89 нчы һөнәр училищесының филиалы эшли. Шоферлар, терлекчеләр, кыскасы, теләге булган һәркем кыска гына вакыт эчендә тракторчылыкка өйрәнде. Совхозда берьюлы 30 механизатор артты. Кызу эш вакытында алар ярдәмгә дә килделәр. Эшне ике сменалы итәргә мөмкинлек туды.

Урта мәктәп укучылары да совхоздагы тормышның күркәм якларын күреп торалар. Аттестат алган яшүсмерләрне авылда калдыру җиңеләя бара. Бу өлкәдә үзе укытучы, үзе комбайнчы да булып эшләүче Фазыл Солтанов, остазлар советы председателе Мөгамбәр Шакиров, шул ук Рәис Хәсәншин нәтиҗәле эш алып баралар. Узган елгы урып-җыюда 25 агрегатта комсомоллар иде. Виктор Тимошин, Әнвәр Галиев кебек егетләр алты-җиде мең центнерлап ашлык суктырдылар. Рәис андый егетләргә зур өмет белән карый:

— Техник иҗатлары өчен мәйданны киңәйтсәң, бу яшьләр әллә нинди могҗизалар тудырачак! — ди ул.— Мин шул ук Мөгамбәр абыйны алам. Сыңар кулы белән нинди җайланмалар ясамый! Мәктәпкә шундый кешеләрне күбрәк тартырга иде. Малайлар, аларның талантына сокланып, үзләре дә канатланып китәчәк! Үзешчән сәнгать түгәрәкләре яхшы эшли, техник иҗат түгәрәкләрен дә шул дәрәҗәгә күтәрергә кирәк!

Рәис Хәсәншин уй-фикерләрен һәрчак районкүләм җыелышларда да, республика күләм киңәшмәләрдә дә әйтә килә. Аның холкы шундый: совхоз тормышына, кешеләр язмышына бәйле бер генә мәсьәләдән дә читләшми ул. Инде алына икән, һәрчак ахырынача үтәп чыга. Үзе шәфкатьле дә ул. Шунлыктан аның кылган эшләренә кешеләр рәхмәт сүзләре белән җавап кайтаралар. Рәис турында совхоз директоры Термос Рахманкулов болай ди:

— Мин аның тынгысызлыгына, булдыклылыгына карап сокланам. Яшьләребез өчен менә диган үрнәк коммунист ул.

... Җиргә бирелгән кешедән дә бәхетле җан юк, ди торган иде Рәиснең этисе. Бу сүзләрнең мәгънәләрен Рәис шактый вакыт аңламый йөрде. Игенче абыйларының җиргә куйган хезмәтен күреп, уңышка ирешү серләрен чишә-чишә Рәис этисенең бәхет турындагы фәлсәфәсенә төшенә бара. Таңны иген басуында каршылау икән ул — бәхет. Бәлки, үзең бәләкәй чакта яланаяк йөргән хәтфә болыннардан, бер ягыңа нәни улыңны алып, икенче кулың белән хатыныңны җитәкләп, янә бер мәртәбә узудадыр ул бәхет?! Алай дисәң, үзең үстергән ашлык бөртекләрен кулыңа алу бәхет түгелмени?! Шул уңыштан әниең салган беренче күмәчтән авыз итү шатлыгын нәрсә дип атарга?! Игенче өчен болар барысы да — тасвирлап бетергесез гаҗәеп вакыйгалар. Рәисне әнә шулар бәхетле итә.

**Мәҗит Рафиков**

## ИКЕ СЫН

Ач, каләмем, тылсым көчең,
Илһамга куәт бирсен.
Гаделсезлек күп тарихта,
Төзәтикче хет берсен:
Тантаналы бу мәйданда
Ник Муса ялгыз тора?
Әминәсе белән аны
Мин бүген кавыштырам...
Мусамы тормыш сөймәгән,
Гүзәллекне тоймаган?
Китәр идемени соң ул
Үзе теләп дөньядан!
Мең газаплы юллар белән
Кайтты Илгә исеме.
Ят туфракта сөякләрен
Сагыш алмый дисеңме!..
Әминә күргән көннәрнең
Агы бар, карасы бар.
Әминәнең мәхәббәтен
Дастанга саласы бар.

Исән ирләрен хур иткән
Түбән җаннар барында,
Зурла, каләм, тугрылыкны
Әминә мисалында!
Дөм-кара төн уртасында
Мең тапкыр уянган ул.
Мусаның саф намусына
Инанган, таянган ул.
«Ышан миңа!..— диеп Муса
Таш капчыкта җырлаган.
Әминә ышанычыннан
Батырлыкка көч алган.
Әминә мәңге яшәсә,
Мусага мәңге лаек.
Үлем белмәс мәхәббәттән
Үрнәк-гыйбрәтләр алыйк!

Ач, каләмем, тылсым көчең,
Ясап куйыйк ике сын:
Тантаналы бу мәйданда
Икесе бергә торсын.

**Ркаил Зәйдуллин**

## ҖӘЛИЛ КОЯШЫ

Атладылар эшафотка таба,
Бу — гомернең соңгы «әкбәре»...
Сукты сәгать. Һәммәсенең бүген
Легендага күчкән мәлләре.

Палач каршы ала...
Элеккечә
Тишек капчык кигән башына.
Юк, башкарып булмый кара эшне
Беркайчан да кояш астында —
Караңгыга, төрмә төбенәрәк
Ымлый һаман...
Көннең яктысы
Бәбәкләрен кисә. Тоткарланса
Исен җуяр, адәм актыгы.

«Кеше башы әкияттәге кебек,
Өзгән саен кабат үсә лә...»—
Фәлсәфәсе әзер, кереп түнгәч
Фәлән кадәр марка кесәгә.
Кояш кына менә ярсыта тик,
Зиндан диварына сыенып;
Балта белән өзәр иде аны...
Тик
Кояшның
юк шул муены.
Җәлил башын яшергән күк кичә,
Яшерер иде төннәр төбенә —
Хыялы буш ләкин,
Палачларның
Кулы җитми шагыйрь күгенә!

## Газинур Моратов

# ҖӘЛИЛ ҺӘЙКӘЛЕ ЯНЫНДА УЙЛАНУ

Мин — биектә:
Һәйкәл иңсәсеннән
Карап торам гүя Кешелеккә...

Бөек рәссам — Тарих иҗат иткән
Матурлыкка ниләр өстәдек?
Киләчәккә бездән калыр микән
Мона Лиза күк бер истәлек?
Чорның вәкаләтле вәкилләре
Кешедәшләрме соң барсы да?
Үз дәверен бүген кемнәр яклый
Үткән, Киләчәге каршында?..
Бүген Тукай туа алмый, диеп,
Кем шаркылдый анда, аклана?...
Халкы бәгыренә берекмәгән
Назымчыны, чорым, яклама!
Киләчәккә кемнәр барачагын
Син бүген үк тикшер, ачыкла.
...КайЧак җаһилләр дә хаким булган,
Хәким җаннар үлгән ачлыкта.
Тукай булып кемнәр яна бүген,
Җәлил булып кемнәр көрәшә?..
Мохтаҗ түгел заман — җылы урын,
Шәхси ләззәт өчен көрәшкә.

Тән асрап һәм җан асрап кына
Яшәүчеләр бу күңелемә
Ишмидантес булып кергән минем,
Ышандырма шулай түгеленә:

Мин ышанмыйм шулай түгеллеккә!
Мин — биектә.
Һәйкәл иңсәсеннән
Карап торам гүя Кешелеккә.

**Николай Шәмсетдинов,**
Төмән шагыйре.

# ТЫНЛЫК — НАБАТ

...Казан суы. Таш-бетон түшәлгән ярда
Басып торам тораташтай. Көне суык...
Язгы яңгыр, таңгы эре саф чыклардан
Бөркелә
Җәлил җылысыдай моңсулык.
А, күпме тояк таптап узган бу җирләрне,
Күпме янгын, ялмап, ялангач калдырган?!
Моабитны уилыйм.
Хыяллары меңнәрнең
Туган якларына таба очкандыр ла...
Тынлык — набат. Тынлык — өмет белән тулы.
Тынлык исәп-хисаплашыр көнгә атлый...
Тешен кыса шагыйрь,
йодрыклана җыры,—
һәм җыр сугар, бәреп ватар Моабитны!

* * *

Төрмә — ярты гектар нәфрәт, нәләт, әрну...
Акрын гына монда төсен җуя вакыт.
Кыйнау, тибү дигән сукыр коридор бу.
һәм каяндыр
кургаш якты керә — саркып.
Төрмә — тәмуг бусагасы. И, асыл ир,
Көтә сине гильотина — соңгы ятак.
Тынлык — набат.
Беркем дәшми.
Ялгыз шагыйрь
Күзәнәкләренең өнен тыңлап ята.
Ябышканнар
гранит аңкауга авазлар,
Янда гына тамчылар тама «тып» та «тып»...
Почмаккамы сыенасы — тик беразга,—
Кинәт уй-фикер агышын туктатып?!
Юк, дустыңның киң ачылган күзен күргәч,
Башны читкә бору — кабахәтлек, этлек.
Шагыйрь! Әйдә, тор һәм егылганны күтәр,
Өметеңнең бер өлешен бүләк итеп,
Уртак балта —
Үлем балтасын каршыла...
Алда — ирлек, үлемсезлек!

Русчадан **Ләбиб ЛЕРОНОВ** тәрҗемәсе.

**Рафаэль Мостафин**

# МУСА ҖӘЛИЛ ТУРЫНДА...

Муса Җәлилнең батырлыгы илгә шаулады. Бик тиз арада аның әсәрләренең күп санлы тәрҗемәләре басылды, атаклы язучыларның, галимнәрнең кызыклы фикерләре дөнья күрде, шагыйрьне якыннан белгән кешеләрнең истәлекләре булды. Шулай ук әдәби тәнкыйть һәм әдәбият белеме буенча тикшеренүләр барды, мәкаләләр, монографияләр, китаплар туды, публицистик әсәрләр язылды.

Матбугатта басылган мондый хезмәтләрнең саны айдан-айга, елдан-елга арта барды. Шагыйрьнең юбилее елларында исә алар пик дәрәҗәсенә күтәрелеп җитә. Җәлил үзе исән вакытта һәм аның егерме елга сузылган иҗат чоры дәверендә (1919—44) басылган мәкаләләр әллә ни күп түгел — берничә дистә генә. Ә менә герой-шагыйрьнең «икенче туы»ннан соңгы егерме елда, ягъни 1953—73 елларда алар бик нык арта. Муса үлгәннән соң аның турында татарча 500 дән артык, русча 550 ләп, СССР халыклары телендә 300 ләп һәм чит илләрдә берничә дистә мәкалә басылды. Ә инде 1973 елдан соң басылган әсәрләр якынча исәп буенча гына да меңгә якынлаша.

Җәлилне өйрәнү фәне бүген совет әдәбият белеменең махсус һәм зур бер тармагына әйләнде. Аның үз предметы, методикасы, тарихы һәм җитди библиографиясе бар. «Җәлилне өйрәнү» дип аталган бу тармакның зурлыгы хакында менә мондый бер мисал да бик ачык сөйли: шагыйрьгә кагылышлы хезмәт язсә әсәр язган авторларның саны бүгенге көндә 2 500 гә якынлаша.

Шагыйрьне өйрәнү ул — Муса Җәлилнең үз тормышын һәм иҗатын өйрәнү генә түгел. Бу күренешне яхшы аңлау өчен ул яшәгән чорны яхшы белергә кирәк, республикада һәм бөтен илдә барган әдәби процессны киң күзаллау сорала. Җәлил иҗатында күпмилләтле совет лирикасының мөһим закончалыклары чагылыш таба. Шуңа күрә, Муса Җәлил иҗатын киң агымнан читтә дөрес аңлап булмаган кебек, бу олы шәхеснең ролен искә алмау шулай ук гомуми картинаны да тулы яктыртмаячак. Ягъни биредә аерылгысыз бердәмлек турында сүз бара. Тикшеренүче өчен аеруча мөһим булган шарт ул.

Җәлилне өйрәнүгә зур өлеш керткән әдәбият белгечләре һәм тәнкыйтьчеләр Г. Кашшаф, Р. Бикмөхәммәтов, Н. Юзиев, З. Мәҗитов, М. Гайнуллин, И. Зәбиров, Т. Галиуллин, М. Фәйзуллина, Х. Госман, М. Маннурова, Ш. Хамматов, Х. Курбатов, Ф. Ибраһимова һ. б. лар нәкъ әнә шуны искә алып эшләделәр һәм эшлиләр.

Тагын шунысын да әйтеп үтәргә кирәк: Җәлилне өйрәнү ул — татар әдәбият белемендә генә карамый, ул хәзер бөтен совет әдәбиятының мөһим бер тармагына әверелде. Бу хакта рус язучылары һәм галимнәре В. Воздвиженский, Ю. Корольков, К. Симонов, К. Зелинский, Г. Ломидзе, В. Огнев, В. Альтов, Б. Невская, Л. Шилов һәм башкалар язуын, шулай ук илебездәге бик күп әдәбиятларда герой-шагыйрьгә багышланган әсәрләр, хезмәтләр тууын искә алсак, без әлеге хакыйкатькә тагын да ныграк ышанырбыз. Билгеләп үтү кызык булыр — Җәлил турында русча һәм башка телләрдә чыккан язмаларның саны үзебезнең телдә чыккан хезмәтләргә караганда ике мәртәбә диярлек күбрәк. Бу, билгеле, гаҗәп тә түгел. Чөнки шагыйрьнең үз китаплары да бүтән телләрдә артыграк чыга.

Тагын да әһәмиятлерәге — Муса Җәлил иҗатын өйрәнү хәзер халыкара төс ала бара. Фактларга карыйк. Татар шагыйре турында ГДР, Чехословакия, Румыния, КХДР, Болгария, Польша, Франция, ФРГ һәм тагын берничә гарәп илендә мәкаләләр басылган. Юк, биредә гадәти юбилей материаллары хакында гына сүз бармый. Мин бу очракта Җәлил иҗатын өйрәнүгә нинди дә булса яңа өлеш кертүче хезмәтләр турында сүз алып барам. Мәсәлән, «Казан утлары» журналының 1967 елгы 2 санында басылган мәкалә

сыман хезмәтләр турында. Аның авторы Ирак галиме Җәлил Камалетдин иде. Немец әдәбиятчысы Леон Небенцаль да җәлилчеләрне җәзалап үтерүгә кагылган яңа документ табып, шагыйрь биографиясенең бик мөһим фактын ачыкларга ярдәм итте. Аның 1958 елда Берлинда басылып чыккан «Икенче Бөтендөнья сугышы тарихы проблемалары» исемле китабындагы Җәлил группасы турында тикшеренүләр безгә милли легионнар хакында яңа мәгълүмат биреп кенә калмады, ә бәлки җәлилчеләр көрәшен тулы бер антифашистик фронтның өлеше итеп күзалларга булышты. Шулай ук Бельгия академиясе члены, шагыйрь Роже Бодарның Җәлил группасы турында материаллар табарга ярдәм итүе хакында да матбугатта хәбәр булды. ГДР язучылары Франц Лешнитцер һәм Эрих Мюллер да үзләрендә мәкаләләр бастырдылар.

Күнегелгән практика буенча Җәлил иҗатын тикшерү төп ике өлешкә бүлеп карала: 1919 елдан алып 1941 елга кадәрге сугышка хәтле чор һәм икенчесе Бөек Ватан сугышы чоры иҗаты, ягъни 1941—44 еллар. Дәвамлылыгы ягыннан бу ике чор тигез булмаса да, икенче чор, сугыш чоры, тикшерүчеләрнең игътибарын күбрәк тарта. Мөгаен, бередә хикмәт шундадыр — сугыш чоры иҗаты һәм аеруча Моабит шигырьләре, шагыйрь иҗатының иң югары биеклек яулаган чоры. Алай гына да түгел, бу цикл бөтен совет поэзиясе өчен иң югары үрләрдән берсе.

1976 елда Казан дәүләт университеты тарафыннан чыгарылган «Муса Җәлил» библиографик күрсәткеченнән чыгып фикер йөртсәк, барлык басылган материалларның өчтән ике өлеше шушы Моабит чорына карый. Билгеле, моның ни өчен шулай икәнен аңлаган хәлдә дә килешеп үк бетәргә ярамый. Ни өчен дигәндә, бер генә тау да, бер генә кыя да нигезсез булмый. Җәлил тормышының да баштагы чоры — әнә шундый җирлек, нигез ул. Хәзер, мәсәлән, шагыйрьнең сугышка кадәрге тормышыннан: «Муса Җәлил — тәнкыйтьче», «Муса Җәлил — балалар шагыйре», «Муса Җәлил — тәрҗемәче» һ. б. мәсьәләләр аеруча тикшерүне сорыйлар. Шулай ук татар поэзиясендә социалистик реализм методын формалаштыруда шагыйрьнең роле дә ачыклауны көтә. Аның РАПП оешмаларында эшләвен һәм вульгар социологизм авыруын җиңүдә катнашуын белү дә бик кызыклы булыр иде. Әнә шуларның барысын да тикшермичә, ачыкламый торып, шагыйрьнең үсү, чыныгу, җитлегү процессын тулы күзаллау мөмкин түгел.

Җәлил иҗатын сугыштан соң өйрәнүнең беренче елларында авторлар күбрәк Моабит шигырьләрен тикшерсәләр, хәзер исә, шагыйрьнең язганнарын киңрәк һәм тулырак итеп аңлыйсы килү теләге күп тикшеренүчеләрне беренче чор әсәрләренә дә алып килә. Мәсәлән, рус укучылары Җәлилнең зур күләмле әсәрләреннән «Хат ташучы» белән «Үткән юллар»ны бары тик соңгы елларда гына укыдылар. Мондый әсәрләрне укыганда тау түбәсе үзе генә түгел, ә аңа күтәрелү юлы да кызыклы икән, дигән уй кала.

Шагыйрь иҗатын һәм тормышын өйрәнүдә хронологик принцип белән бергә башка ысуллар да яшәп килә. Мисал өчен, Й. Исәнбәт «Җәлил һәм музыка» проблемасын өйрәнә, Р. Шаһиева «Җәлил һәм сынлы сәнгать» темасы буенча эзләнүләр алып бара, шагыйрь иҗатында халык фольклоры элементлары чагылышын И. Надиров белән Н. Юзеев яктырта, Җәлилнең педагогик карашларын Ф. Мостафин тикшерә, публицистик һәм журналистлык эшчәнлеген Ш. Хамматов яктырта, эстетик идеалын Ә. Мәхмүтов өйрәнә һ. б.

Шулай итеп Җәлилне өйрәнү фәненең предметы бик күп тармаклардан тора. Алар һәрберсе аерым-аерым өйрәнелә. Әмма бу, билгеле, гомумиләштерүче хезмәтләр кирәклеген дә кире какмый.

Ә шагыйрьне өйрәнү методикасына килгәндә, ул совет әдәбият белеме методикасыннан әллә ни аерылмый. Тик шулай да аның үзенчәлекләре юк түгел. Эш шунда: Җәлилнең соңгы чор иҗаты фашист тоткынлыгы шартларында туган һәм шуңа бәйле рәвештә күп әсәрләр конспирация таләпләренә җавап бирергә тиеш булганнар. Ягъни аларда кайбер фикерләр яисә урыны-урыны белән тулы строфалар, читләтү юлы белән әйтелә. Аннан соң фашист палачлары үз җинаятьләрен яшерү максатыннан чыгып, совет патриотлары көрәше хакындагы бөтен материалларны юк иткәннәр. Ә бу һәр документны табуны кыенлаштыра, фактны ачыклауны авырлата. Хәтта кайчак бик гади генә булган, үзеннән-үзе аңлашыла торган күренешләр дә әнә шуның аркасында табышмакка әйләнеп киткәлиләр. Бередә Җәлил исеме тирәсендә барлыкка килгән төрле имеш-мимешләрнең һәм легендаларның да күпмедер роле бар.

Шагыйрьнең күп кенә әсәрләренең югалуын, ә кайберләренең илебезгә имзасыз хәлдә кайтып җитүен искә алсак та эшнең кыенлыгы аңлашылыр. Әле ул гына да түгел. Җәлил сугышка китәр алдыннан үзе төзеп, сүзгә-сүз тәрҗемә ясап Мәскәүдәге бер нәшрияткә (Гослитиздат) тәкъдим иткән җыентыгының да әлегә кадәр табылганы юк. Мусаның фронтта язылган күп шигырьләре дә җуелган. Сугышка кадәр язылган барлык әсәрләрен дә исән дип әйтә алмыйбыз.

Укучыларның зур кызыксынуларын һаман көчлерәк тоя барган авторлар үзләренең күп кенә хезмәтләрен әдәби эзләнү жанрында яздылар. Фән белән публицистика һәм матур әдәбият арасында яткан бу алымның, әлбәттә, үз өстенлекләре бар. Андый хезмәтләр бөтен кешегә аңлашылырдай итеп, кызыклы иҗат ителәләр. Әмма фәнни яктан алып караганда, мондый хезмәтләрдәге һәрбер факт җентекләп тикшерүне, ахыргача ачыклап бетерүне сорый.

Атаклы татар шагыйренең иҗатына кагылышлы тагын бер үзенчәлек: аның шигырьләре рус һәм башка телләргә тәрҗемә ителеп үзләренә икенче яшәү алдылар, миллионнарча тираж белән дөнья күрделәр, алар мәктәпләрдә өйрәнелә, совет кешеләрен патриотик рухта тәрбияләү буенча зур эш башкара. Әнә шул тәрҗемәләр нигезендә, Муса әсәрләренең оригиналын белмәгән күп кенә авторлар (мәсәлән В. Воздвиженский, Ю. Корольков, Б. Невская, В. Альтов, К. Зелинский, Л. Шилов һ. б.) аның турында тулы бер китаплар һәм проблемалы мәкаләләр яздылар. Әлбәттә, моның ише хезмәтләрне кирәкми дип булмый, алар да үз рольләрен уйныйлар. Әмма аларга еш кына ниндидер күләмдә төзәтмә кертергә кирәк була.

Тагын шунысы да бар — Җәлил турында профессионал тәнкыйтьче, яисә галим булмаган авторлар да байтак яза. Билгеле, бусы бер дә начар түгел. Тик менә алар язганның сыйфат ягы гына күп чагында яхшыртуны тели.

Җәлилне өйрәнү фәненең тарихы да үзенчәлекле. Ул бик төгәл рәвештә өч өлешкә бүленә.

Беренче периодны Җәлил үзе исән вакытта аның турында язылган хезмәтләр тәшкил итә. Әйтеп үткәнебезчә, алар артык күп түгел. Чөнки бу чорга Муса иҗатының өчтән бер өлеше генә туры килә. Аның язылган күп лирик шигырьләре һәм поэмалары да каралама хәлендә. Җәлил исән чагында аның хакында басылган мәкаләләр безгә Мусаның әдәби процесстагы ролен белү, аңлау өчен кирәк. Әлбәттә, бирегә ул чор әдәби процессына карашларның үзгәрүе дә искә алына.

Җәлилне өйрәнүдә икенче период 1942—53 елларны эченә ала. Бу аның хәбәрсез югалуы белән «яңадан туу» арасы. Ягъни, без ул чор матбугатында Җәлил турындагы хезмәтләрне күп таба алмыйбыз. 1942 ел ахырында Татарстан китап нәшрияты Мусаның «Артиллерист анты» исемле шигырьләр җыентыгын чыгара. Китапны әдәби җәмәгатьчелек җылы каршылый. Аның турында тәнкыйтьче Хәсән Хәйри «Совет әдәбияты» журналының 1943 елгы 7 санында, журналист С. Фәйзуллин «Кызыл Татарстан» газетасының 1943 елгы 23 май санында һәм әдәбият галиме Гази Кашшаф («Һаҗәр» псевдонимы белән) «Совет әдәбияты» журналының 1943 ел 1 санында язып чыгалар. Бу авторлар бертавыштан Җәлил поэзиясенең югары патриотизмын, кайнар хисләрен, актуальлеген билгеләп үтәләр, китапка бик яхшы бәя бирәләр.

1944 елда Муса Җәлилнең «Окоптан хат» исемле китабы рус телендә дә дөнья күрә. Кереш сүзендә шагыйрь һәм тәрҗемәче Бруно Зернит болай дип яза: «Муса Җәлил исемен әйткән вакытта минем күз алдыма татар халкының уй-хисләрен иң матур чагылдыра алучы образ килеп баса. Үзенең бөтен талантын, йөрәк ялкынын ул халкына багышлады».

Игътибар итегез — автор Муса турында үткән заманда яза, ягъни ватан өчен корбан булганнарның берсе итеп. Б. Зернитның кереш сүзендә тагын мондый юллар бар: «Немец илбасарлары хыянәтчел төстә безнең җиребезне таптый башлагач, М. Җәлил, ялкынлы патриот буларак, илне саклаучылар сафына басты. Ул кулындагы коралы белән дә, иҗаты белән дә дошманга аяусыз ут яудырды».

Әмма, укучы Казанда чыккан китаптан әнә шул юлларны укыганда, Муса үзе әле исән була. Нәкъ шул көннәрдә, 1944 елның августында, ул Берлиндагы Шпандау төрмәсендә үлем җәзасы көтә. Без искә алган ике китап турында ул, билгеле, белә алмый.

1943 елның җәендә Татар опера һәм балет театры «Алтынчәч» операсын, әз бераз соңрак «Илдар»ны яңартып куя башлый. Бу уңайдан матбугатта җылы гына язылган мәкаләләр басыла. Мәсәлән, «Красная Татария»нең 1943 елгы 17 июль санында Җ. Садриҗиһанов болай дип яза: «М. Җәлил либреттосының бик тә шигъри булуы тулаем операның уңышын билгели. Әкияти сюжет поэзиясе халыкның батырлыгы һәм үлемсезлеге, патриотизмы идеясе белән бергә үрелә».

Сугыш елларында М. Җәлил исеме татар поэзиясе турындагы күп кенә мәкаләләрдә телгә алына. Ләкин 1947 елның икенче яртысыннан соң инде аның исеме очрамый. «Алтынчәч» сәхнәдә зур уңыш белән бара, җырлары да җырлана. Тик әле бу чорда шагыйрьнең исеме әйтелми.

Әмма, Җәлил язмышының котылгысыз чынлыгы булган бу чорны да, аны өйрәнүчеләр өчен әрәм үтте дип булмый. Нәкъ менә шул елларда безнең илебезгә шагыйрьнең ике Моабит дәфтәре кайтты. Җәлилчеләр группасын саткан җинаятьчегә булган суд аларның көрәшен аңларга ярдәм итте. Бу елларда Җәлил язмышын

ачыклау, тулысынча аңлау буенча эчке процесс барды, эзләнү эшләре барды. Әнә шул эзләнү эшләре инде соңрак шагыйрь исемен тулысынча акларга ныклы нигез булды.

1953 елның 25 апрель санында «Литературная газета» Муса Җәлилнең Моабит дәфтәреннән алты шигырь басып чыгарды. И. Френкель тәрҗемә иткән менә шушы алты шигырь инде Җәлилнең «яңадан туу» көне дип тарихка кереп калды. Шагыйрьне өйрәнүнең яңа, өченче этабы да шул көннән башлана.

Шигырьләр басылуның икенче көнендә ук Татарстан Язучылар союзында шагыйрь истәлегенә багышланган зур җыелыш үткәрелә. Җыелышта шагыйрьнең дуслары һәм каләмдәшләре Гази Кашшаф, Әнвәр Давыдов, Әхмәт Исхак, Риза Ишморат, Галимҗан Латыйп, Салих Баттал, Якуб Агишев чыгыш ясый. Ә 29 апрельдә «Совет Татарстаны» газетасы үзенең хәбәрчесе, язучы Фатих Хөснинең бу җыелыш хакында «Көрәшче шагыйрь кайтты» дигән язмасын урнаштыра. Республика яшьләре газетасы «Яшь сталинчы» да Әхмәт Исхакның кереш сүзе белән шул ук көнне Моабит шигырьләреннән берничәсен урнаштыра. Ә инде 30 апрельдә «Совет Татарстаны» Җәлил шигырьләренә һәм алар турындагы Гази Кашшаф мәкаләсенә тулы бер бит бирә. Бу — «Моабит дәфтәре»н анализлауга багышланган беренче мәкалә. 1953 елның шул ук 30 апрель көнендә «Советская Татария»да Муса Җәлил шигырьләрен һәм Бруно Зернитның «Ялкынлы йөрәк» дигән мәкаләсен урнаштыра.

Шулай итеп матбугатта мәкаләләр күбәя башлый. 1953 елның 6 июнендә «Правда» үзенең битендә язучы Гомәр Бәшировның «Үлемнән көчлерәк» дигән мәкаләсен бастыра.

Шул ук елда «Известия»дә Гази Кашшафның «Үлемнән көчлерәк» исемле мәкаләсе дә дөнья күрә. Гомумән, илебездә бу вакыйга турында теге яки бу рәвешле язып чыкмаган бер генә матбугат органы да калмагандыр. Шагыйрьнең «икенче туу»ына бер ел дигәндә инде аның турында йөздән артык мәртәбә язып чыктылар. Бу — сугышка кадәрге утыз елга караганда да күбрәк дигән сүз. Аларның һәммәсен дә күрсәтеп үтү мөмкин түгел, ләкин иң әһәмиятлеләренә, әлбәттә, тукталырга кирәк.

1953 елның ахырында Татарстан китап нәшрияты Гази Кашшафның кереш сүзе белән «Муса Җәлилнең соңгы шигырьләре»н басып чыгара. Менә бу беренче китап турында матбугатта бик күп мәкаләләр була. Икенче елны, 1954 тә, Мәскәүнең «Советский писатель» нәшрияты Җәлилнең Моабит шигырьләренә рус телендә дөнья күрсәтә. Ул китапка рецензия белән М. Луконин, С. Хәким, Б. Зернит, В. Огнев, С. Кривошенко, В. Любовцев, Б. Керничный, Р. Поляков, Д. Блынский, В. Азаров, М. Мөхтәсинов һ. б. лар чыгыш ясый.

1954 елның гыйнварында Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында шагыйрьнең фашист тоткынлыгында һәлак булуына ун ел тулуга багышланган зур кичә үткәрелә. Анда докладлар белән тәнкыйтьче Гази Кашшаф, язучы Юрий Корольков һәм Әзербайҗанның халык шагыйре Самед Вургун чыгыш ясый. Аларның чыгышлары Җәлилне өйрәнү фәненең яңа чорына нигез ташы булып ятты.

СССР язучыларының 1954 елның 26 декабрендә булган Икенче бөтенсоюз съезды Җәлил иҗатына югары бәя бирде. Бу хакта поэзия буенча доклад сөйләгән Алексей Сурков һәм өстәмә доклад сөйләгән Самед Вургун онытылмаслык итеп әйттеләр.

Шушы ук чорда КПССның Татарстан өлкә комитеты комиссиясе Җәлил группасының тоткынлыктагы көрәшенә караган материалларны өйрәнә һәм партия Үзәк Комитетына шагыйрьгә Советлар Союзы Герое исемен бирүне сорап мөрәҗәгать итә. Үтенечкә Өлкә комитетының беренче секретаре З. Моратов кул куя. 1955 елның декабрендә бу мәсьәлә КПСС Үзәк Комитетында карала. Ә инде 1956 елның 30 ноябре көнне КПСС Үзәк Комитеты Президиумы СССР Верховный Советы Президиумының «Татар шагыйре Җәлилов Муса Мустафовичка Советлар Союзы Герое исемен бирү (үлгәннән соң) турында»гы Указын раслый.

1956 елның 3 февралендә Казан Офицерлар йортының колонналы залында бөтен республика хезмәт ияләренең шушы вакыйгага багышланган зур митингысы үткәрелә. Ул вакыйга матбугатта да киң яктыртыла. Муса Җәлилнең тууына 50 ел тулу да нәкъ менә шушы елның февралендә республика һәм ил җәмәгатьчелеге тарафыннан зурлап билгеләп үтелә.

1957 елның 22 апрелендә Ленин премияләре буенча комитет Моабит дәфтәре шигырьләре өчен Муса Җәлилгә Ленин премиясе бирү турында карар чыгара. Шулай итеп, шагыйрьнең иҗаты да иң зур бәягә лаек була.

Мусаның язмышы ачыклангач ук аның тормышын һәм иҗатын өйрәнү берничә юнәлештә үсә башлый. Иң элек шагыйрьнең әдәби мирасын җыйнау һәм фәнни яктан эшкәртеп бастыру буенча эш кузгала. Фронтка киткәндә Җәлил үзе шигырьләрен сайлап, бер матур җыентык бастыру турында хыялланган була. Хатыны Әминәгә бу хакта әйтеп: «Ул минем соңгы җыентыгым булыр бәлки»,— дип яза Муса. Ләкин

аның моңа вакыты җитми. Икенче бер хатында шагыйрь үз әсәрләрен хронологик тәртиптә бастыру хыялын да яза. Ә инде Волхов фронтында кискен ситуация тугач, ул бу җаваплы эшне дусты Гази Кашшафка тапшыруын билгертеп яза.

Җәлилне өйрәнү фәненең атасы дип танылган Гази Кашшаф дустының бу васыятен җиренә җиткереп, үтә зур тырышлык белән үти. Ул Җәлилнең китапларда, газет-журналларда басылган барлык шигырьләрен бергә җыйный, шагыйрьнең архивыннан моңа кадәр билгеле булмаган байтак яңа әсәрләр таба һәм шулар нигезендә 1955—1956 елларда Муса Җәлил сайланма әсәрләренең беренче өч томлыгын чыгара. Бу өч томлык Җәлилне өйрәнү өчен җитди фәнни нигез булды. Аннан башка тикшеренү эшләре мөмкин түгел иде.

Җәлилнең әдәби мирасын җыйнауда аеруча күп көч куйган ике оешманы әйтми булмый. Аларның беренчесе — Татарстан Дәүләт музее. Музейның әдәби бүлеге хезмәткәрләре беренче көннәреннән үк эшкә тотыналар. Җәлилнең дуслары, каләмдәшләре, коралдашлары белән очрашулар үткәрәләр. Алар сөйләгән истәлекләрне язып баралар, яңа материаллар эзләп табалар. Гыйльми совет утырышларында шагыйрь тормышы һәм иҗаты хакында докладлар тыңланыла. Шагыйрь турында брошюралар, китаплар чыгаралар.

1955 елда Дәүләт музее Гази Кашшафның гыйльми советта сөйләгән докладын аерым брошюра итеп чыгара. Икенче елны исә шул ук оешма Нил Юзиевның «Герой-шагыйрь Муса Җәлил. Тормыш һәм иҗат юлы» дигән китабын бастыра. Болар — шагыйрь батырлыгы хакында язылган беренче китаплар иде.

1983 елда Муса Җәлилнең музей-квартирасы ачылгач, кадерле экспонатлар саны тагын да артты. Әминә ханым музейга Җәлилнең китапханәсен, шәхси әйберләрен һәм башкаларны бүләк итте. Атаклы Моабит дәфтәрләренең төп нөсхәләре шушы музей фондында саклануын әйтү генә дә ни тора бит!

Җәлилне өйрәнү эшенә илленче елларның икенче яртысында ук тотынып, хәзер инде иң зур үзәкләрнең берсенә әверелгән икенче оешма — Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты. Биредә шагыйрьнең архивы, кулъязмаларының төп нөсхәләре, караламалары һәм башка кадерле документлар тупланган. Бер генә җитди тикшеренүче дә бу фондтан файдаланмый кала алмый.

Муса Җәлилнең беренче өч томлыгы чыкканнан соң шагыйрьнең калган иҗатын барлау һәм өйрәнү эше турыдан-туры Институт җитәкчелегендә дәвам итә. Басылган әсәрләрне текстологик дөресләү, вакыйгаларны, даталарны ачыклау һ. б. зур һәм катлаулы эшләр башлана. Менә болар барысы да җитмешенче елларда М. Җәлил әсәрләренең яңа җыелмасын — дүрт томлыкны — хәзерләргә мөмкинлек бирде. Институтның әдәбият секторы бу эшкә Гази Кашшафны һәм бүтән белгечләрне дә тартты. Гази ага сәламәтлеге какшаганчы өч томны төзи һәм аңлатмалар бирә алды. Аларның корректурасын укыганда ул инде каты авырый иде. Ә дүртенче том (бирегә мәкаләләр урнаштырылган) әдәбият галиме Н. Юзиев тарафыннан төзелгән һәм аңлатылган.

Бу дүрт томлыкның дөнья күрүе Җәлилне өйрәнүдә яңа баскыч булды. Мәсәлән, 1921—23 елларда язылган яшьлек шигырьләре беренче мәртәбә шушы дүрт томлыкта басылды. Биредә шулай ук 40 яңа мәкалә дә бар. Хатларның да 43 е яңа. Ләкин эш әле монда гына да түгел. Алда чыккан өч томлыкка үткән байтак төгәлсезлекләр биредә төзәтелеп бирелә. Әнә шуңа күрә 1975—76 елларда дөнья күргән бу дүрт томлыкны без бүгенгә иң тулы һәм фәнни яктан төгәл басма дип билгелибез. Әмма, шулай булса да, Җәлилне өйрәнү әле моның белән төгәлләнгән дип һаман әйтә алмыйбыз. Фашист тоткынлыгында иҗат ителгән уннарча шигырьләр табылмаган әле. Шагыйрьнең 70 еллыгын бәйрәм иткәндә Әминә ханым Институтка Җәлил архивының тагын бер өлешен тапшырды. Анда да яңа шигырьләр бар. 1918—20 елларга гына карасалар да, ул әсәрләр шагыйрь тормышын аңлау өчен кызыклы. Шулай ук шагыйрьнеке булуы, ихтимал шигырьләрне дә җыйнау дәвам итә, көндәлек матбугатта басылган материаллар да туплана килә. Җәлилнең тууына 70 ел тулу уңаеннан үткәрелгән Бөтенсоюз конференциясендә Тел, әдәбият һәм тарих институтының әдәбият секторы мөдире, филология фәннәре докторы Нил Юзиев әйткәнчә, хәзер чынлап та, шагыйрь әсәрләренең инде сигез томнан торган тулы җыелмасын чыгару мәсьәләсен дә көн тәртибенә куярга мөмкин. Бу тәкъдим бик реаль һәм бөтен фәнни көчләрне бергә туплаганда ул чынга ашырга мөмкин. Әлбәттә, яхшы текстологик әзерлек белән.

Җәлил әсәрләрен рус һәм башка телләргә тәрҗемә итү эше дә бара. Шагыйрь исеме илебездә генә түгел, ә бөтен дөнья масштабында танылды. Андый тәрҗемәләр вакытында хаталарны төзәтә бару да зарур. 1979 елда «Советский писатель» нәшриятының Ленинград бүлеге тарафыннан төзелгән «Җәлилнең сайланма шигырьләре» басмасында байтак төгәлсезлекләрдән арынып чыгаруга ирешелде. Ул китап «Шагыйрь китапханәсе» дип аталган зур сериядә дөнья күрде.

Шагыйрьне өйрәнүнең икенче тармагы — Муса биографиясенә кагылышлы фактларны, мәгълүматларны җыйнау. Бу эшне башлаучы булып та безнең Г. Кашшаф ага танылды.

1953 елдан башлап илебез матбугатында Мусага бәйле язылган мәкалә, истәлек басылган. Аларны шагыйрьнең туганнары, дуслары, яшьтәшләре һәм көрәштәшләре яза. Ләкин аларның характеры, дөреслек дәрәҗәсе төрлечә. Кайбер хөрмәтле генә матбугат органнары да вакыт-вакыт бик үк төгәл булмаган мәгълүматлар биреп алдылар. (Алар хакында мин «Өзелгән җыр эзеннән» исемлек китабымда сүз алып барам.) Истәлекләрнең дөреслеккә туры килә торганнары нигездә 1964 елда татарча һәм 1966 елда русча Татарстан китап нәшрияты чыгарган җыентыкларга тупланган. Муса Җәлил биографиясен тулыландыруга Х. Җәлилованың 1969 елда чыккан «Абыем турында» (русча), М. Максудның 1963 елда чыккан «Кадерле минутлар» (татарча) һәм 1971 елда чыккан «Истәлекләр» китабы да зур өлеш керттеләр.

Юрий Корольковның 1959 елда Гослитиздатта басылган «Җырга әверелгән гомер» исемле документаль-публицистик китабы да бай фактик материалга нигезләнгән. Китаптагы кайбер урыннар тора-бара төзәтелүгә һәм авторның кайбер фараз кылулары бик үк расланып бетмәүгә карамастан, бу китап шагыйрьнең исемен рус укучылары арасында популярлаштыруда зур роль уйнады.

Уфада яшәүче Н. Лешкинның өлешен дә билгеләп үтәргә кирәк. Ул җәлилчеләрнең тоткынлыктагы көрәшенең күп кенә караңгы урыннарын яктырта алды. Аның журналист Ю. Карчевский белән берлектә язылган һәм Уфада 1975 елда басылып чыккан «Бит һәм маска» исемле китабы (русча) укучылар тарафыннан бик җылы каршыланды.

Шулай ук 1966 елда «Әдәби мирас»ның 78 томында басылган фактик мәгълүматлар да зур әһәмияткә ия. Анда Икенче удар армиядә Муса белән бергә көрәшкән кешеләрнең истәлекләре урын алган. «Тарихи архив» журналының 1961 елгы 25 санында да, «Архивны өйрәнү мәсьәләләре» журналының 1964 елгы 3 санында да һәм инде үзебезнең «Казан утлары»ның бик күп публикацияләрендә дә кыйммәтле мәгълүматлар бар.

М. Әминов һәм М. Миңнуллин иптәшләрнең 1969 елда «Коммунист Татарии» журналының 4 санында һәм 1969 елда «Советская Татария» газетасының 16, 18, 19 ноябрь саннарында басылган мәкаләләре дә күп яңа фактлар ачтылар. Җәлилчеләрнең көрәше партия оешмасы җитәкчелегендә барганлыгын раслаучы документлар китерелә ул мәкаләләрдә.

Әйе, шагыйрь гомеренең соңгы чорын һәм иҗатын өйрәнү өчен бик күп фактик материалны белергә, ачыкларга кирәк. Ә бу исә байтак кына кыенлыклар белән бәйләнгән. Мисал өчен, минем үземә Җәлил биографиясенең кайбер фактларын ачыклар өчен дүрт мәртәбә ГДРга, өч тапкыр Көнбатыш Берлинга барырга, ФРГда һәм Польшада булырга туры килде. Әле моның өстәвенә архивларда актарыну да, бик күп кешеләр белән хат язышу да, йөзләгән кеше белән очрашу да бар — аларына да вакыт һәм мөмкинлек табарга кирәк.

Билгеле, Муса биографиясе әле ахыргача, бөтен детальләренә кадәр ачыкланып бетмәгән. Бу юнәлештә эш дәвам итәчәк. Ләкин фактларның җыйналган кадәресе дә шагыйрьнең кабатланмас талантын һәм үлемсез батырлыгын күзаллау өчен җитә.

Ниһаять, Җәлилне өйрәнүнең өченче тармагына килеп җиттек: ул Муса әсәрләре хакында язылган әдәбият белеме хезмәтләре. Шагыйрь тормышын өйрәнү белән бергә бу юнәлештә дә эш башланды һәм биредә дә беренчелек Гази агада. Аның 1957 һәм 1961 елларда татарча һәм 1983 елда русча басылган «Муса Җәлил. Тормышы һәм иҗаты турында очерк» исемле китаплары, әлеге тармакка нигез салучы хезмәтләр дип санала. Аларның беренчесе дөнья күрүгә инде утыз елга якын гомер үтсә дә — Гази ага Кашшаф мәгълүматлары бер тикшерүче өчен дә искерми, кыйммәтен югалтмый.

Г. Кашшаф белән бер үк вакытта һәм аның җитәкчелегендә Р. Бикмөхәммәтов та эш алып бара. Бу авторның «Муса Җәлил. Тәнкыйди-биографик очерк» дигән хезмәте рус телендә 1957, 1961, 1962, 1966 елларда басылып чыкты. Галим Җәлилнең иҗат портретын яза, аның шәхесенең үсешен күзаллый, Моабит дәфтәрләренең төп үзенчәлекләрен анализлый. Фактик материал ягына килгәндә, ул нигездә Г. Кашшаф тапканнарга таяна, ләкин шагыйрьнең иҗатын аңлау буенча тагын да алгарак атлый, яңа мөһим фикерләр әйтә.

1960 елда Нил Юзиевның Җәлил поэмаларын тикшерүгә багышланган хезмәте Казан дәүләт университеты тарафыннан бастырылып чыгарылды һәм шуннан соң инде шагыйрьнең әсәрләре жанрлар буенча да өйрәнелә башлады. Аннары В. Воздвиженский һәм З. Мәҗитов китаплары дөнья күрде. Аларның һәрберсе мәгълүм фактик материалга таянып яңа гомумиләштерүләр ясый, яңа аспектка чыгып яңа нәтиҗәләргә килә.

Соңга таба Җәлил иҗатының моңарчы өйрәнелмәгән яклары да тикшеренүчеләрнең игътибарын тарта. 1977 елда Й. Исәнбәтнең «Муса Җәлил һәм татар музыкасы» дигән хезмәте русча һәм 1974 елда Ф. Мостафинның «Муса Җәлил — педагог» дигән китаплары татарча дөнья күрә. Шулай ук биредә бүтән китапларны да атап китәргә кирәк. Ә. Мәхмүтовның «Муса Җәлил иҗатында эстетик идеал» исемле китабы (Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1980), Ш. Хамматовның «Муса Җәлил — партия солдаты» дигән хезмәте (Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1982 һәм 1984 елларда), И. Зәбировның «Җәлил белән янәшә» китабы (Ташкент, «Яшь гвардия» нәшрияты һәм Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1983 ел), М. Маннурованың «Героик бердәмлек» китабы (Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1980 ел), А. Әминев һәм Х. Галиева «Муса Җәлил мәктәптә» китабы (Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1967 ел) геройшагыйрьнең иҗатын һәрьяклап өйрәнүдә билгеле бер эш башкардылар һәм аларның кыйммәте зур. Мондый хезмәтләр Мусаның тормыш һәм иҗат юлын тулы күзалларга булышалар. Тик тагын шунысы бар: соңгы елларда барысын да гомумиләштергән хезмәтләр җитенкерәмәве һаман ныграк сизелә башлады. Югарыда аталган хезмәтләрдә куелган фикерләрне җыйнаган һәм алга таба үстергән яңа китаплар кирәклеге сизелә хәзер.

Муса Җәлил турындагы библиография бик зур цифр белән билгеләнә. Мәсәлән, 1976 елгы күрсәткеч аны 2691 дип атый.

Җәлил әсәрләренең һәм Җәлил турында язылган материалларның беренче библиографик күрсәткечен 1961 елда филология фәннәре докторы Ә. Кәримуллин төзеп чыгарды. Ул 1919—1961 елларны эченә ала иде һәм, кайбер тулы булмаган урыннар калуга карамастан, зур роль уйнады.

1976 елда Казан дәүләт университетының Н. И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсе яңа библиографик күрсәткеч басып чыгарды. Ә. Г. Кәримуллин, Н. Ә. Әхмәтҗанова, Р. С. Камалова иптәшләр төзегән бу күрсәткеч 1919 дан алып 1973 елга кадәрге чорны эченә ала. Менә шушы күрсәткеч Җәлилне өйрәнүчеләр өчен бүгенге көнгә иң ышанычлы һәм тулы басма булып кала. Иң мөһим тематик бүлекләргә бүленү аның кыйммәтен тагын да арттыра.

Безнең уйлавыбызча, Җәлил турындагы материалларны хәзер түбәндәге төрләргә бүлеп карарга кирәк.

1. Шагыйрь исемен популярлаштыру характерындагы материаллар. Аларга нигездә юбилейлар уңае белән язылган публицистик мәкаләләр керә. Мондый язмаларның авторлары әллә ни яңалык ачуны максат итеп куймыйлар, алар теге яки бу республика укучыларына Җәлил хакында сөйлиләр, аның тормышы һәм иҗаты белән таныштыралар.

Ә инде юбилей уңаеннан теге яки бу күренекле әдип, яисә галим, җәмәгать эшлеклесе сүз алса — мәкалә гадәти булудан туктый, ул фәнни кыйммәт ала. Чөнки андый мәкаләләрдә еш кына очракта тирән фикерләр була. Ә алар Җәлилне өйрәнү өчен өр-яңа яссылык ачарга мөмкин. Мәсәлән, К. Симонов, Г. Бәширов, М. Кәрим, С. Вургун, А. Сурков, А. Ахматова һ. б. ларның мәкаләләре әнә шундыйлар рәтенә керә.

2. Мемуар әдәбият. Билгеле, бу төр язмалар арасында төрлесе булды. Шагыйрьне очраклы гына күрүенә таянып, үзен аның иптәше һәм көрәштәше итеп таныштырга теләүчеләр дә очраштыргалады. Кайчак тикшерелмәгән, дәлилләнмәгән нәрсәләр укучыга җиткерелде һәм буталчыклар тугалады. Алтмышынчы еллар ахырында, җитмешенче еллар башында Татарстан һәм Башкортстан чекистлары үткәргән өстәмә тикшерүләрдән соң гына кайбер мәсьәләләрдә хакыйкатьне ачыклау мөмкин булды. Әнә шуларга да карамастан, мемуар әдәбият Җәлилне өйрәнү эшенә файда итә, ул төр язмаларны укучылар да, галимнәр дә яратып укый.

3. Әдәби тәнкыйть мәкаләләре һәм әдәбият белеме хезмәтләре. Тикшерүче өчен болар иң кирәкле эшләр. 1982 елга Җәлил турында барысы утыздан артык фәнни һәм фәнни-популяр китап чыкты, тугыз диссертация якланды.

4. Шагыйрь турындагы матур әдәбият әсәрләре һәм ярым документаль әсәрләр. Муса турында язылган ике роман (Ш. Маннурның «Муса»сы һәм Г. Әпсәләмовның «Агыла болыт»ы), повестьлар (Ю. Корольков, В. Альтов, Н. Лешкин һ. б.) дистәләгән поэма (Г. Хуҗи, Д. Кугультинов, С. Хәким, И. Юзеев, Р. Харис, А. Рошка һ. б.), пьесалар (Н. Исәнбәт, Р. Ишморат, Д. Вәлиев, Т. Миңнуллин, Ә. Гаффаров һ. б.) бар. Шулай ук хикәяләр, кино һәм телесценарийлар, радиотапшырулар язылган. Шигырьләр бик күп. Гадәттә, мондый әсәрләрнең авторлары Җәлил турында җыйналган материалларга таянып эшлиләр. Еш кына очракта үзләре дә туплыйлар, яңа кешеләр белән очрашалар. Мәсәлән, минем үземә «Өзелгән җыр эзеннән» дигән китапны язганда өстәмә рәвештә тикшерү үткәрергә туры килде. Ю. Корольков та, Ш. Маннур да шулай эшләгәннәр.

РЕСПУБЛИКАН...
НАУЧНАЯ БИБЛ...

Тик шунысын истән чыгарырга ярамый: матур әдәбият әсәрләрендә автор фантазиясенә генә нигезләнгән фараз кылулар байтак була. Укучыны бу кайчак ялгыштыра да. Шуңа карамастан, матур әдәбият әсәрләре Җәлил темасына зур өлеш кертәләр.

5. Шагыйрьнең үз әсәрләре библиографиясе.

Бу өлкәдә бигрәк тә Казан библиографлары Ә. Кәримуллин, Н. Әхмәтҗанова һәм Р. Камаловаларның зур тырышлык куюларын билгеләп үтәргә кирәк. Җәлил исән чагында чыккан әсәрләр күрсәткече төзелү — алар хезмәте аркасында ирешелгән казаныш. Билгеле, ул исемлек вакытлар узган саен тулылана бара. Элек билгеле булмаган яисә псевдоним белән генә басылган яңа әсәрләр килеп чыга тора. Бөтенләй имзасыз басылганнары да очрый. Соңгы елларда басылып чыккан яңадан-яңа китаплар да әлеге исемлекне дәвам итәләр. Тәрҗемә әсәрләр күп басыла.

...1976 елның мартында Муса Җәлилнең тууына җитмеш ел тулу һәм немец телендә аның әсәрләре өченче мәртәбә басарга әзерләнү уңаеннан Берлинда булганда ГДР язучылары миннән: «Җәлил китапларының тиражы зурмы?» — дип сорадылар. Мин: «Казанда чыккан соңгы басмасының тиражы 250 мең»,— дип җавап бирдем. Язучы коллегаларым аптырашып, бер-берсенә караштылар да: «Сез 250 дип әйтергә теләдегезме?» — диделәр. Ә мин исә һаман үз сүземне куәтләдем: «Юк, алай түгел, 250 мең — ягъни чирек миллион!» Аннары, сүземне дәвам итеп, мин аларга шундый зур тираж белән чыккан китапларның да бик тиз арада таралып бетүен сөйләдем. Әңгәмәдәшләремә болар, чыннан да, бик гаҗәп тоелды.

Әйе, Муса Җәлил әсәрләре бүген халыкларны коммунистик тәрбияләүдә зур роль уйныйлар. Әнә шуңа күрә алар эстетик кыйммәткә генә түгел, ә бәлки зур иҗтимагый кыйммәткә дә ия. Ә дөресрәге, аларның менә бу сыйфатлары бер-берсеннән аерылгысыз булып бәйләнгән.

А. Тиммерманска багышланган «Бүләгем» шигырендә Җәлил:


Үзем үлсәм, исмем, җырым үлмәс,<br>
Ул яңгырар илнең кырында.<br>
Сөйләп илгә тоткын күңелләрдә<br>
Чәчәк аткан дуслык турында,—

дип язган иде.

Чыннан да, шулай — Мусаның шигырьләре бүген халык йөрәгендә, ил кырында яшиләр!

---

ӘМИРХАН ЕНИКИНЫҢ «МУСА ҖӘЛИЛ ХАТЛАРЫ» ДИГӘН МӘКАЛӘСЕНӘ



**Әмирхан Еники**

# МУСА ҖӘЛИЛ ХАТЛАРЫ

Көтелмәгән табыш җир казучылар белән иске йортны сүтүчеләргә генә очрый торгандыр дип уйлый идем — хәлбуки, менә үзем дә шулай ук һич көтелмәгән зур табышка искәрмәстән тап булдым. Әле быел гына, бер 50 ел кул тимичә яткан иске папканы актарган чакта, төрле кәгазьләр арасыннан Муса Җәлилнең дүрт хаты һәм бер запискасы килеп чыкты. (Әгәр «Соңгы китап» өчен кирәк бер кәгазьне эзләргә туры килмәсә, ул папкага һаман да кул җитмәгән булыр иде, ә бәлки әле миннән каралмыйча да торып калыр иде). Башта ышанмыйчарак тордым, аннан аптырап калдым, ә укып карагач Муса алдында беркадәр уңайсызлану да хис иттем. Аның миндә хатлары барын мин бөтенләй онытканмын лабаса!.. Ышан син коры хәтергә!.. Дөрес, ул хатларның язылуына 50 елдан артык вакыт үтеп киткән (хатлар 1932-33 елларда язылган), бу вакыт эчендә баштан ниләр генә кичмәде, онытылуы да һич гаҗәп түгел.

Шулай да мин уйланам, үзем өчен генә булса да «онытылуның» сәбәбен аңламакчы булам. Мәгълүм ки, Муса Җәлилнең даны дөньяга таралгач, яудан соң батыр күбәер дигәндәй, аны якыннан белгәннәр, дусты булганнар бик күбәеп китте. Мин дә Муса белән таныш идем, ләкин... «якын дуслар» арасына тизрәк керергә ашыкмадым... Әлбәттә, Мусаны күреп белүчеләр күп булгандыр, якын дус-ишләре дә аз булмагандыр (мәсәлән, Әхмәт Фәйзи, Гази Кашшаф кебекләр), әмма, миңа калса, дуслык — бигрәк тә чын дуслык — тирән төшенчә, ул бары тик ике яклы гына була ала, шуңа күрә бер якның гына дуслыкны дәгъва итүе җитми әле, моның өчен һәрхәлдә бик төпле дәлилләр кирәк. Ә безнең арадагы мөнәсәбәтләр нинди иде, чын дуслык дип атарлык идеме ул — бигрәк тә Мусаның даны, әйткәнемчә, бөтен дөньяга таралганнан соң?.. Минем мөмкин кадәр объектив буласым килә. Бик еракта калган елларны искә төшерәм: Муса Мәскәүдә, мин Казанда — очрашуларыбыз ул Казанга килеп киткән чакта гына була торган иде. Беренче очрашуыбыз, ялгышмасам, 1928 елның көзендә булырга тиеш. Муса Казанга килгән саен Чеңәкәйдә туктала иде, ә мин бу ялгызак шагыйрьгә еш кына барып йөри идем. Безнең очрашу да, танышу да менә шунда булды. Без башта ук бер-беребезгә ошап киттек, тиз якынайдык, арабыз һәрвакытта дусларча булды, бик теләп, иркенләп сөйләшә дә торган идек. Муса тыйнак егет иде, үзен берәүдән дә өстен куймый иде, кешегә мөнәсәбәте дә тигез-табигый иде. Һәм шушы гадилек мине аңа тарткан да булырга тиеш... Тагын хәтерлим: Мусаның Казанга бер килүендә, мин торган квартираның зур залында, хуҗалар рөхсәте белән, яшьләр кичәсе үткәрдек. Яшь әдип-шагыйрьләр, яшь артисткалар җыелган иде. Акча салышып, барынча гына чәй табыны әзерләттек, беркинди эчемлек юк (аны кирәк дип тә белмибез), аның каравы, җыр, музыка, шигырь сөйләү белән бик күңелле узган иде ул кичә! Мусаның тагын бер килүендә дүрт-биш кеше бергәләп фотога да төштек — бу фоторәсем соңыннан Муса альбомына да кертелде.

28 елдан башланган безнең бу очрашулар 1934 елга кадәр әнә шулай матур гына дәвам итеп килде. Ләкин шушы елдан соң очрашуларыбыз бетте диярлек, чөнки Муса Мәскәүдәге опера студиясенә эшкә кергәч, Казанга бик сирәк кайта башлады. Ә берике елдан минем үземә читкә (Әзербайҗанга китеп барырга туры килде. Муса 1939 елның көзендә Казанга бөтенләйгә кайткач, безнең мөнәсәбәтләр бәлки яңарып та киткән булыр иде, ләкин нәкъ шул елны мин тагын Үзбәкстанга китеп бардым... Сугыш башланган көннәрдә генә әйләнеп кайтсам да, Мусаны нишләптер бер җирдә дә очрата алмадым, күрәсең, ул инде Казаннан китеп тә өлгергән булгандыр... Ә озакламый минем үземне дә фронтка озаттылар.

Шул рәвешчә, Муса белән безнең бәйләнеш шактый гына еллар өзелеп торды. Ихтимал, шуңа күрә дә мин үземне Мусаның дусты дип санарга җөрьәт тә итмәгәнмендер. Һәм хатларның онытылып яту сәбәбен дә бәлки шуннан эзләргә кирәктер.

Әмма Муса хатларының сакланып калуына һәм 50 елдан соң булса да табылуына мин бик шатмын. Хәзер сез дә алар белән танышырсыз... Хатларга алдан ук шәрехләүләр биреп тормыйм, игътибар белән укыган кеше үзе дә күп нәрсәне аңлар, шул җөмләдән безнең арадагы дуслыкның ни дәрәҗәдә булуын да күз алдына китерер... Шулай да башта ук аңлатасы бер нәрсә бар: сез күрәсез, Муса һәр хатын «Әмир» дип башлый. Шунда ук сорау туа: ни өчен Әмир, ни өчен Әмирхан түгел?.. Хәтта шик уятуы да

мөмкин, чөнки Әмир исеме белән йөргән башка язучылар да бар бит әле... Ә хикмәт менә нәрсәдә: малай чагымнан ук мине бөтен күрше-тирә, шарикләрем һәм дусларым әнә шулай «Әмир» дип кенә атыйлар иде (тулы исемем белән атам-анам гына дәшә иде). Казанга килгәч тә якыннан аралашып йөргән дус-ишләрем миңа «Әмир» дип кенә дәшә торган булдылар. Шулар шикелле үк Муса да үз-якын итеп кыскартып кына язган. Аңлашылса кирәк.

* * *

«Әмир! Мин кайтып җиткәч тә сиңа хат язармын дип уйлаган идем. Әллә ничек, көндәлек эш арасына чумып киттем дә, хат язу шушы көнгә хәтле кичекте. Ничаво, әгәр үзең җавапны соңнатмый торган булсаң, мин һәрвакыт хат язып торырмын.

Хатта башлап сине кызыксындырган нәрсә, билгеле, язучылар тормышы булыр. Мин сиңа Мәскәү оештыру комитеты каршындагы вак милләтләр комиссиясе янында татар язучылары группасы оештырылганны әйткән идем. Ул группаның бюросына Шамил, Толымбай һәм мин сайландык. Ләкин әле бюро бер эшкә дә башлаганы юк. Мин ул Толымбай белән эшләвемә бер дә зур ышаныч белән карамыйм. Авыр булыр аның белән.

Бюро инициативасы белән түгел, «Коммунист» гәзите һәм шагыйрьләрнең үз инициативасы белән шагыйрьләрнең иҗат кичәсен гадәткә кертү башланды. Өченче көн Әхм. Фәезнең шигырьләрен уку һәм тикшерүгә багышлап бер кичә үткәрдек. Башка шагыйрьләрнең дә үткәрелер. «Интернационал»ның татарчасын язуга оештырылган конкурсның жюрисе эшләп ята. Аның бөтен эшен мин алып барам. Жюриның эше 15/I белән 1/II арасында бетәргә тиеш. Иртәгә вак милләт язучыларының киң киңәшмәсе уздырыла. Нәшриятларның докладын тыңлыйбыз. Мәскәү күләмендә бер татар әдәби кичәсе үткәрүгә әзерлек бара. Ничек булып чыгар.

Менә шулай, үзара кыймылдап ятабыз. Язучылар яза. Үзара бик дус яшибез һәм бер-беребезнекен укып, танышып торабыз.

Мин һаман «Октябрь баласы»нда. Журналның хәле тулай алганда яхшы булса да, әдәби көчләр катышмавы бик начар. Әмир! Давай яз әле бер хикәя! Моны бик җитди һәм бик ялынып әйтәм. Балалар өчен бер хикәя язып ташлачы! Бик зур хезмәт булыр ул. Бик матур итеп басарбыз. Көтеп калам.

Хат яз. Адрес (редакция). Москва, центр. Новая площадь, д 6/8. Изд-во «Молодая гвардия», ред. «Октябрь баласы» (лично).

Хуш!

Муса.

28/XI-32. Хат яз!

Ә, тукта әле, Әмир!

Мин сиңа бер йомышымны әйтергә оныткандмын икән. Миңа Ченәкәй сөйләгән иде, синең мех халкы белән бәйләнеш шәп булса кирәк. Мин бу кышны пальтосыз чыгам бит, малай! Син мине якын һәм дус күреп, бер ярдәмем тисен дип уйласаң, менә шундый эш эшли алмассыңмы? Ягъни әнә шул үзең кигән төсле бер мехтан (эче, тышы яхшы мех) кышкы кием эшләтеп алып булмасмы? Хакы 300-400 гә булсын иде дә, үзе күзгә-башка матур һәм яхшы булсын иде. Шуны эшләтеп булмасмы? Шул турыда кулыңнан килерлек булса, зинһар өчен бер конкрет ярдәм күрсәтче!

Муса.»

* * *

«Әмир!

Хатыңны алдым. Бик шатландым. Беренче бик нык шатлануым — хатыңны кулга алгач та булды. Ансы синең миңа шул хәтле тиз һәм кичектерми җавап язуың өчен иде. Икенче шатлануым — хатыңны укыгач булды. Анысы минем йомышны инде үтәп тә куюың өчен булды.

Рәхмәт, бик рәхмәт! Хат язуың өчен дә рәхмәт, йомышымны үтәвең (үтәргә сүз бирүең) өчен дә рәхмәт!..

Башлап йомыш турында:

Син әйткән проектка мин бөтен барлыгым белән риза инде. Син беләсең, минем киярге бер җүнле әйберем юк бит. Син әйткәнчә була гына күрсен берүк! Син сөйләгәнчә аның мехлары да бик матур һәм күңелле, ыспай булаçы булгач, мин шатланып риза инде. Хакына да риза. Үлчәвем —46.

Тик, зинһар, сүздә генә кала күрмәсен! Чынлап та, менә син әйткән шундый бер мехлы пальтоны бу ел ук киеп җибәрим әле. Мин гыйнвар башларында Казанга барам. Шунда без аның бөтенләй эшен бетербез. Шулай бит?!. Син аңарчы бөтен әзерлекне күреп, эшләтеп тор!.. Акча кирәк булу белән телеграм сук!.. Мин җибәрермен.

Бусы шулай булды.

Инде үзебезнең Мәскәү язучылары турында бераз информация.

Монда күптән түгел Г. Нигъмәти килде. Без бөтен Мәскәү татар язучылары җыйналып аның докладын тыңладык. Мәскәүнең бөтен телгә алырлык язучы, журналист, җәмәгатьчеләре килгән иде. Халык күп иде.

Нигъмәти «Оештыру комитетының пленумы йомгаклары һәм Татарстан совет язу-

чылары арасында эш» дигән темага сөйләде. Докладында самокритика бик аз иде. Ул күбрәк «гыйльми» мәсьәләләр тирәсендә йөрде. Оештыру комитетының кешесе булып түгел, гыйлем кешесе булып сөйләде. Доклад буенча бик күп кеше сүз алып, озын-озын сөйләделәр. Җыелыш 7-8 сәгать барды. Мин Казанда булып, хәлне күреп кайтканга бик батыр чыктым. «Казанда бер кузгалыш юк, бер яңалык юк, партия ҮК карары буенча бер дә борылыш ясалмаган, оештыру комитеты бик пассив: язучыларны оештырмый, материаль ярдәм итми» дип бик нык тәнкыйть иттем. Чөнки факт җитәрлек иде. Казан язучыларының настроениесен дә бик яхшы күреп кайткан идем. Сүзем һичбер төрле юл белән ялганга чыгарлык түгел иде.

Оештыру комитеты аерым язучыларга аерым подход ясап тарту, иҗатка якынлаштыруда, күмәккә алу юлында бер дә эшләмәвен әйттем. Бу уңай белән сине дә телгә алдым. «Талантлы яшь язучы Яникиеф, мәсәлән, нигә тартылмый?» дидем. Син генә түгел, билгеле, Туфан, Фатих Хөсни һәм башкаларның тартылмый читтә яшәүләрен искә алып үттем.

Миннән башка Толымбай да, М. Максут та оештыру комитетына нык кына бәрелделәр. Башкалар башка бик күп төрле мәсьәләләр күтәреп, шактый яңа нәрсәләр сөйләделәр. Җыелыш бик шәп булды. Нигъмәтигә дә бу зур уяулык биргән. Кайткач, ни дә булса эшләр дип уйлыйбыз. Безнең үзебезгә дә күп файда бирде. Мәскәү язучылары оешып эшләү зарядкасын алып калдык.

Резолюция язу өчен Толымбай, Шамил Госманов һәм мин сайланган 3 кешелек комиссия төзелде. «Коммунист» гәзитен карап бар, резолюциябез һәм җыелышның кыскача доклады басылып чыгар.

Инде, дускай, сиңа киңәш шул: әдәбияттан читтә йөрмә! Яз һәм бастыр! Үткәннәргә булган җәберсенүеңә чик куеп, яңа шартларга үзләш! Үткәндә ТАППның хаталары аркылы читкә этелгәнсең икән, хәзер ул үткән булып калырга тиеш. Чөнки партия шулай ди.

«Җыламаган балага имчәк бирмиләр» бит! Шулай булгач, бер дә язмый, бармый, күренмичә дә үзеңә тиешле бәһаны һәм игътибарны алып булмый. Нәкый Исәнбәт тә бөтенләй үпкәләп яшәргә уйламый. Обкомга хат яза, шигырь яза, һәм шигырен күтәреп редакциягә бара. Менә шуннан соң читләтсәләр, ул вакытта оештыру комитеты һәм редакцияләргә үпкәләргә генә түгел, протест ясарга була.

Шулай булгач син батыррак эш күр. Яз һәм дөньяга чык! Син шиксез талантлы һәм үткен язучы. Бик матур, нәфис әйберләр бирәчәксең.

Монда Татиздатның бүлеген бетереп маташалар әле. Юкса бу ел минем бер җыентык басылырга тиеш иде. Шул сәбәпле тотылып тора. Чыккач үзеңә дә берне җибәрәм дә җибәрәм инде.

Шамил Усманов, М. Максут, Яркәй, Фәез, Крымов һәм башкалар сау гына яшиләр. Хәзер үзара оешу һәм иҗат турында сөйләшү нык сизелә. Әле менә беркөн Әхмәт Фәезнең иҗатын тикшерүгә багышлап, бер иҗат кичәсе уздырдык. Бик тулы һәм күңелле узды.

Ярый, яз! Сүз бик күп булыр. Баргач бик озак утырып бер сөйләшербез әле. Үзем журналда эшлим. «Үктәбер баласы»нда. Минем журналга берәр матур гына, җыйнак кына әдәби әйбер язып ташлар идең. 33 елда гонорары бик күп булачак. Һәм журнал үзе дә бик матурлана! Ярыймы?

Шул журнал адресы белән хат яз.

Хәләл җефетеңә бик күп сәлам. Безне үткән баруда бик тәмле ашлар белән, бик бай өстәл белән, бик шәп сыйлаган иде. Һәм иптәшләрчә тулы игътибар, көләч йөз белән каршылап, күңелне шатландырган иде. Шулар өчен хәзер дә тагын бер кат, тагын бер кат рәхмәт!

Хуш.

Муса.

26/XII-32.»

* * *

«Әмир!

Мин тиз көндә Казанга барып чыгам. «Коммунист» редакциясе һәм Мәскәү татар язучылары тарафыннан Казан оештыру комитеты пленумына вәкил булып мин һәм Фәез билгеләнгән идек. Ләкин Фәез дә, мин дә бер журналда эшлибез. (1 нче гыйнвардан Әхмәт Фәез миндә секретарь булып эшли башлады). Икебезгә бергә журнал эшен калдырырга уңайсыз. Бигрәк тә мин гыйнвар номерын үзем карап чыгармыйча мөмкин түгел. Фәез әле яңа кеше бит! Журналның гыйнвар номеры декабрь 20 сеннән производствода инде. Тик художникның 10 көн авырып ятуы аркасында гына шулай кичекте. Мин ахрысы аны 10-11 ләрендә генә кул куеп, чыгарлык итеп китә алырмын. Аннан соң мин монда әле партия райкомы тарафыннан бер 15 көнгә мобилизовать ителгән идем. Шуңардан да бушыйсы бар. Шулай итеп гыйнвар 13-14 ләрендә мин Казанда булам. Казанда берничә көн булгач та, юлымны Уралга дәвам иттерәм. Ә Уралдан кайтышлый, Казанда калып, бер ай радиоцентр тирәсендә эшләмәкче булам.

Мин синең хатыңны алгач, бер җавап язып салган идем. Алдыңмы? Бу хатка инде җавап көтеп тормыйм. Чөнки үзем барам. Мәскәүдәге хәлләрне баргач озын итеп сөйләрмен. Баргач та, сине күрү һәм синдә

озак кына утырып серләшүне үземә бурыч һәм иң көтелгән тәмле минут саныйм.

Сүзнең ахырында теге йомышны да искә төшерим. Мин үзем озын юлга чыксам да, бер дә рәтле киенеп чыга алмыйм. Чөнки монда мөмкинлек юк. Булса да мин үзем шулай бик булдыксыз. Минем ул ягымны Ченәкәй дә яхшы белә. Шулай барлы-юклы кием белән генә барам. Син теге әйтелгән вәгъдәне ничек тә үтә инде. Бик ышанамын.

Мин баргач та, алып киярлек булмас микән?. Син заказ бирә торса идең. Мин акчаны әзерләп чыгам.

Ярый. Хуш.

Калганы баргач.

Иптәшеңә күп сәлам.

Муса.

7/I-33 г.»

* * *

«Әмир! Мин синең хатны алгач, телеграф белән 350 сум акча салдым. Ул акчаның ни өчен барганын үзең беләсең! Үземә һаман Казанга барырга туры килми тора әле. Моның иң зур сәбәбе шул булды: 1 нче гыйнвардан бирле безнең «Үктәбр баласы» һәм «Ударниклар» журналларының яшәү-яшәмәү мәсьәләсе каралып килде. Бу мәсьәлә безне бик кызыксындырганга, мин, ул чишелми торып, журналны ташлап китә алмадым. Икенчедән, журнал шул хәлдә торганда командировка алу мөмкин түгел иде. Хәзер ул мәсьәлә чишелде. Журналлар икесе дә туктадылар (Казандагы журналларга кушылалар). Мин үз акчама гына Казанга барып кайтырга уйлыйм. Ләкин әле монда кайда эшләү-эшләмәвемне хәл итеп китәргә кирәк. Һәрхәлдә син тунны эшләтеп куй инде. Бу ел кимәгәндә дә киләсе елга киярга ярар. Бездә кыш бик җылы, мин элекке пальто белән йөри барам[1].

Акчаны алуың турында хат яз.

Ярый, хәзергә хуш.

Сәлам белән: Муса.

16/II.»

---

[1] «Бирәм» урынына «барам» дип ялгыш язылган булса кирәк.

Искәрмә: Муса елын куймаган, ләкин открыткадагы почта штемпелендә 16.2.33. итеп күрсәтелгән. Димәк, 1933 ел.

Аңлатмалар

1. Муса Җәлил үзенең икенче хатында Нәкый Исәнбәтне телгә ала — гүя миңа аңардан үрнәк алырга куша. Моның хикмәте нәрсәдә? Нәкъ шул елларда зур шау-шу куптарган «Җидегәнчелек»тә Нәкый Исәнбәт тә гаепләнгән иде. Бу нигезсез бер уйдырма гына булуга карамастан, гаепләнгән кешеләр вакытлыча әдәбияттан аерылып торырга мәҗбүр булдылар. Шул чакта Нәкый абзый үз теләге белән укытучылык хезмәтеннән китеп, «Спартак» фабрикасына кара эшче булып барып керә. Әмма иҗади эшен һичнигә карамастан дәвам итә, нәкъ «Спартак»та эшләгән вакытында, борынгы Рим тарихыннан «Спартак» исемле трагедиясен дә яза... Хаттан күренгәнчә, Муса Исәнбәт турында яхшы хәбәрдар булган.

2. Һәр хатында диярлек Муса үзенә кышкы кием тектерү турында сүз кузгата. Чынлап та бик кытлыклы еллар иде — ул әнә Мәскәүдә дә үзенә кием таба алмаган... Мин, әлбәттә, аның үтенечен кулдан килгәнчә үтәргә тырышам. Мәгәр меховойларда тун тектереп булмаячак иде, чөнки мин эшләп киткән фабрикаларның берсендә дә мехтан кием-салым текмиләр иде. Бердәнбер чара — кулдан материал табып, берәр хосусый остадан тектереп алырга гына мөмкин иде. Кызганычка каршы, минем бу хакта Мусага язган хатларым сакланмаган, ә киемне аңа кемнән, нинди материалдан тектерүемне минә хәзер, 50 елдан соң, мин инде хәтерли алмыйм... Әминә ханымның әйтүенә караганда, 1934 елның кышында Муса өстендә каракуль якалы, кара сукнодан яңа пальто булган. Менә шул инде Казанда тектерелгән пальто булырга да тиеш.

* * *

... Күптән инде бер мәктәпкә мине беренче мәртәбә Муса турында сөйләргә чакырдылар. Бардым, белгәнемне кыскача гына сөйләдем. Соңыннан укучы балалар миңа шундый сорау бирделәр:

— Муса Җәлилнең батырлыгы нәрсәдән килә?

Мин уйга калдым. Ни диеп җавап бирергә?..

Гадәттәгечә, Ватанга бирелгәнлек, халкына тугрылыклы булып калу... дисәм, алар инде бу дәрес сүзләрне күп тапкыр ишеткән булырга тиешләр... Ничектер, Мусаның шәхси сыйфатларын истә тотып әйтәсе килгән иде. Ахырдан мин болай дидем:

— Муса бит барысыннан элек шагыйрь иде. Димәк, табигате белән ул гуманист, ягъни кешелекле, шәфкатьле, вәхшилек белән килешә алмаучы — менә аның батырлыгы да, минемчә, шуңардан килә торгандыр.

Югарыда сез укыган хатлар да минем бу фикеремне раслый булса кирәк.

**Шəмси Хамматов,**
доцент, тарих фəннəре кандидаты

# НИГЕЗ ТАШЛАРЫН САЛГАНДА

«Опера студиясе төзелгəч тə, язучылардан иң беренче кеше булып мин операга килдем. 1934 елны ук мин студиядə əдəби консультациялəр белəн ярдəм итə башладым һəм 1935 елдан штатка кереп, дүрт ел буе тоташ опера тудыру өлкəсендə көч салдым».

*Муса Җəлил.*

Без П. И. Чайковский исемендəге Мəскəү дəүлəт консерваториясе каршында оештырылган Татар дəүлəт опера студиясенең архивы белəн танышабыз. Менə студия дирекциясе тарафыннан 1935 елның 28 октябрендə чыгарылган приказ. Анда «татар студиясенə М. Җəлилов, М. Мозаффаров, М. Латыйпов, Н. Рəхмəтуллина, əдəбият укытучысы итеп М. Максудовларны... эшкə алырга»,— дип язылган. Ə 1935 елның 28 октябрендə бирелгəн таныклыкта мондый сүзлəр бар: «Җəлилов М. М. Татар опера студиясендə əдəби сотрудник булып хезмəт итə».

Мəшһүр композиторлар, музыка белгечлəре, җырчылар белəн бергə эшлəгəн М. Җəлил эзлəреннəн йөрибез, консерваториянең аудиториялəре, концерт заллары, бай китапханəсе белəн танышабыз. Татар опера студиясендə С. Сəйдəшев, Н. Җиһанов, З. Хəбибуллин, Ф. Яруллин, М. Латыйпов, Җ. Фəйзи, Л. Хəмиди, А. Измайлова, Н. Рəхмəтуллина, Г. Кайбицкая, М. Рахманкулова, Х. Зəбирова, М. Булатова, С. Айдаров, С. Садыйкова, Ф. Насретдинов, Н. Даутов һəм башка бик күп композитор һəм артистларның укуын, эшлəвен, аларның танылган рус музыка əһеллəре җитəкчелегендə үсүен, шулар арасында Муса Җəлилнең дə булуын һəм сəнгатебез үсешенə зур өлеш кертүен күңелдəн кичереп горурланабыз.

Татар студия җитəкчелеге Мəскəүдə эшлəгəн татар язучылары М. Максуд, Ə. Фəйзи, Ə. Ерикəй һəм Казаннан вакытлыча килгəн Ф. Бурнаш иптəшлəрне чакырып киңəшмə үткəрə. Киңəшмəдə катнашучылар мəскəүле əдиплəр, композиторлар белəн еш аралашкан Муса Җəлилгə студиянең əдəби җитəкчесе эшен тапшыруны беравыздан хуп күрəлəр.

Булачак татар дəүлəт опера театрын оештыру, аңа милли кадрлар əзерлəү, репертуар, либреттолар булдыру юнəлешендə Муса Җəлил актив эш башлый. «1935 елдан алып 1938 ел буе,— дип яза М. Җəлил үз биографиясендə,— Мəскəү дəүлəт консерваториясе каршындагы Татар дəүлəт опера студиясенең əдəбият бүлеге мөдире булып эшлəдем. Шуны да əйтергə кирəк, үзəк матбугат эшчесе һəм Мəскəү татар язучылары төркеме җитəкчесе буларак бу студияне оештыруда мин 1934-1935 елларда актив катнаштым».

М. Җəлилгə студиядə авыр, җаваплы һəм бик кирəкле эш — репертуар əзерлəү тапшырыла. Ул 1939 елның 22 июнендə Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе Г. Динмөхəммəтовка язган хатында (хат матбугатта басылмаган) һəм Татар опера студиясе җитəкчелегенə язган берничə рəсми отчет докладында милли опера театрының юнəлешен һəм бурычларын ачык итеп билгели. «Мин 1935 ел башында,— дип яза ул,— татар опера студиясенə эшкə кердем. Миңа əдəби эш — ягъни репертуар хəзерлəү эше йөклəтелде. Дүрт ел эшлəп, студия эшен төгəллəгəч, бу ел студия коллективы белəн бергə Казанга кайттым. Опера студиясе төзелгəч тə, язучылардан иң беренче кеше булып мин операга килдем. 1934 елны ук мин студиядə əдəби консультациялəр белəн ярдəм итə башладым һəм 1935 елдан штатка кереп, дүрт ел буе тоташ опера тудыру өлкəсендə көч салдым. Менə шунлыктан, миңа Мəскəүдəн китү зур кыенлыклар белəн бəйлəнешле булса да һəм минем өчен хезмəт итүдəн бигрəк язып яту файдалырак булса да, мин, операга нык бирелгəнлектəн, Казанга кайттым»[1].

Студиянең əдəби бүлеге эшлəре һəм бурычлары турында 1936 елның 15 августында язган күлəмле рəсми отчет докладында ул студия алдында торган кичектергесез проб-

[1] КПСС өлкə комитеты партархивы, 10 ф., 3 тасв., 16 эш, 3 б.

лемаларны күтәрә. Аның фикеренчә, иң мөһиме — татар телендә югары сыйфатлы репертуар булдыру. Шунлыктан, булачак театрга вокалистлар, режиссерлар, балетмейстерлар, композиторлар һ. б. кадрларны әзерләү белән беррәттән, опера репертуарын да тудыру бурычы тора. Аның өчен язучы-либреттистлар әзерләргә кирәк, ә алар исә үз чиратларында композиторларны әдәби текст-либреттолар белән тәэмин итәргә тиешләр. Шулай ук классик опералардан татар теленә күчерелгән текстлар да булдырырга кирәк[1].

1935 ел башында М. Җәлил инициативасы белән студиянең әдәби секторы оештырыла. Ул аның җитәкчесе булып санала. Аның белән бергә Фәтхи Бурнаш та эшли. Әдәби секторның төп бурычы студентларны уку дәреслекләре белән тәэмин итүдән, классик опера либреттоларын тәрҗемә итүне оештыру һәм оригинал текстлар яздырудан гыйбарәт була. Музыка әсәрләренең текстларын тәрҗемә итү — иң кыен эшләрнең берсе дип саный М. Җәлил. Чөнки бу эштә музыка теориясен белгән тәрҗемәче-белгечләрнең татар әдәбиятында классик опера текстларын тәрҗемә итү буенча бертөрле дә тәҗрибәсе юк иде.

Һәм, ниһаять, 1935 елның апрель аенда классик музыка текстларын татарчалаштыруда, татар әдәбияты тарихында беренче тапкыр, студия әдәби хезмәткәре М. Җәлил тарафыннан беренче тәҗрибә ясала. Бу мактаулы эшкә студия татар поэзиясенең күренекле шагыйрьләре Ә. Фәйзи, С. Баттал, Ә. Ерикәй һ. б. ларны җәлеп итә. Алар өчен студия әдәби хезмәткәре М. Җәлил музыка консультацияләре оештыра. Җырчылар беркетелә. Нәтиҗәдә 1935 елның 15 апреленнән 16 июненә кадәр 34 ария һәм романс тәрҗемә ителә. Шуларның унтугызын М. Җәлил, тугызын Ә. Ерикәй, ә С. Баттал, Ә. Фәйзи һәм музыкант Ә. Кайбицкий икешәрен татарчалаштыра.[2] 1937 елның 1 сентябрендә ясаган отчет докладында М. Җәлил 70 җыр һәм романсның тәрҗемә ителүен күрсәтеп уза.

А. С. Пушкинның 100 еллык юбилее көннәрендә, әдәби бүлек инициативасы белән, шагыйрьләр классик композиторлар тарафыннан музыкага салынган текстларны татарчалаштыралар. «Алар арасыннан егермесе бөек рус шагыйре А. С. Пушкин сүзләренә язылган. Боларның барысы да җыр-музыка репертуарына кыйммәтле хәзинә булды»[3],— дип яза М. Җәлил. Әсәрләрнең унысын М. Җәлил, дүртәрен Ә. Ерикәй, Ә. Фәйзи, ә икесен башка шагыйрьләр тәрҗемә итәләр.

Шулай ук отчетта әдәби сектор ярдәмендә үнлаган совет шагыйренең шигырьләренә җыр һәм романслар язылуы билгеләп үтелә. Аларны иҗат итүдә М. Мозаффаров, С. Сәйдәшев, Н. Җиһанов, З. Хәбибуллин, Л. Хәмиди, Җ. Фәйзи, Ф. Яруллин, М. Латыйпов һ. б. катнашты, дип яза М. Җәлил.

1935 елның җәендә Татарстан АССР Халык мәгарифе комиссариаты янында опера репертуары советы төзелә. Ул булачак опера театрының репертуарын, оригинал либреттоларын карый, тәрҗемәгә опера әсәрләрен сайлап ала. Ә Мәскәүдә репертуар советының М. Җәлил катнашындагы редакциясе һәм сайлап алу, тикшерү комиссияләре эшли.

Студиянең эшчәнлеген партиянең Татарстан өлкә комитеты игътибар үзәгендә тота. М. Җәлилнең рәсми докладында күрсәтелгәнчә, 1937 елның апрель аенда студия эше өлкә комитеты киңәшмәсендә карала һәм җитди кимчелекләр күрсәтелә, эшкә юнәлеш бирелә. Анда татарча оригинал либреттолар язу иң мөһим мәсьәлә дип куела.

Репертуар мәсьәләсендә М. Җәлил, студия җитәкчеләренең берсе буларак, дөрес һәм принципиаль линия үткәрә. Художество ягыннан сай либреттоларны кире кага.

Һәр либретто әсәренә М. Җәлил рецензияләр яза. «Һәр әсәрнең,— ди ул,— нигезен актарып, бөтен яктан җентекләп, гыйльми бер тикшерену үткәрәм. Чөнки мин авторга культура бирергә тиеш. Мин бик каты, таләпчән. Шуңар күрә мине кайбер авторлар яратмый. Ләкин яхшы сыйфат өчен шул кирәк»[4]. Әдипнең шушы юнәлештәге нәтиҗәле эшчәнлеген күрсәтә торган бер генә сан китерик: М. Җәлил 1935-1941 елларда төрле авторлар тарафыннан язылган либреттоларга 40 тан артык рецензия язган. Аның әле укучыларга билгеле булмаган тәнкыйть мәкаләләре, күзәтүләре архивларда саклана. Бу факт әдипнең тәнкыйтьче буларак нәтиҗәле эшләвен исбатлый.

Үзенең опера студиясендәге эшенә М. Җәлил объектив бәя бирә. «Мин 1934 елда,— дип яза ул бер хатында,— опера сүзе чыгу белән, студия төзелү белән бик нык кызыксынып, студиягә килдем. 1934 елның «Коммунист» газетасын гына карагыз. Опера һәм студия турында никадәр мәкалә, киңәш, сүз, әйбер язылган. Алар бар да минеке. Мин студиянең беренче көненнән үк аның кадрлары белән танышып, һәркайсына якын кон-

---

[1] Тел, әдәбият һәм тарих институты фәнни архивы, 10 ф., 2 тасв., 17 эш, 1 б. Төп нөсхә.
[2] Тел, әдәбият һәм тарих институты фәнни архивы, 10 ф., 2 тасв., 17 эш, 1—3 б. Төп нөсхә.
[3] Тел, әдәбият һәм тарих институты фәнни архивы, 10 ф., 2 тасв., 20 эш, 8 б.
[4] КПСС өлкә комитеты партархивы, 10 ф., 3 тасв., 162 эш, 12 б.

сультант булдым. Студиянең уку чорында һәр җырчыга кирәк булган опера репертуарын мин хәзерләдем. Классик опералардан ария, сценаларны татарчалаштыруның беренче тәҗрибәләрен мин ясадым. Педагоглар киңәше белән, җырчылар соравы белән аларга уку тәртибендә эшләнгән әйберләр (опера өзекләре һәм арияләрнең тәрҗемәләре) миндә 50 дән артык. Студия укучылары 4 ел буена менә шул репертуар белән культураларын үстерделәр.

Минем студиядәге эшем авторларны оештыру, аларга консультация бирү, аларның әсәрләрен редакцияләү иде... Авторлар бар да тәҗрибәсез иде. Мисал өчен алыйм: «Качкын» 10 мәртәбә тикшерелеп, кире кайтарылып төзәтелде. Аны ике ел буе төзәтергә, яңадан эшләтергә туры килде. «Галиябану»ны мин 4 мәртәбә озын-озын рецензия-консультация белән кире кайтардым. «Евгений Онегин», «Фауст» тәрҗемәләренә мин авторлардан 2-3 өлеш артыграк көч куйдым. Бөтен либреттолар менә шулай. Редактор-консультант ул автордан күбрәк белергә, күбрәк уйларга мәҗбүр. һәр авторга минем дөнья хәтле көчем кергән. Боларны раслый торган документлар (консультация хатлары, рецензияләр, либреттоларның дүртәр-бишәр вариантлары) моңа шаһит...»[1].

Опера студиясендә эшләгән елларда М. Җәлил булачак татар опера театры өчен коллектив тупларга бөтен көчен бирә. Опера студиясендә укыган җырчы, Татарстанның атказанган артисткасы Хәлидә Зәбирова истәлекләрендә болай дип яза: «Ул тулысынча үзен сәнгатькә багышлады. Муса безнең кеше иде! Ул татар опера театрына нигез салучыларның берсе...»[2]

Татар милли музыкаль культурасын күтәрүгә ярдәм итү өчен М. Җәлил үзлегеннән тырышып укый, консерваториядә профессорларның лекцияләрен тыңлый, практик занятиеләргә йөри, имтиханнарда, репетицияләрдә, академик концертларда катнаша. Социалистик Хезмәт Герое, Мәскәү дәүләт консерватория ректоры профессор А. В. Свешников горурлык белән бик урынлы рәвештә болай дип яза: «Безнең консерваториядә Советлар Союзы Герое Муса Җәлил дә музыкаль белем алды»[3].

М. Җәлилгә иҗатташ дуслары — композиторлар, артистлар, җырчылар, шагыйрьлибреттистлар аның үз квартирасына — Мәскәүнең Столешников тыкрыгына (11 нче йорт) килә торган булганнар, анда культура мәсьәләләрен уртага салып сөйләшкәннәр. Шунысы кызыклы: бу квартирада шахмат турнирлары да үткән. 1938 елның 1 маенда рус телендә чыгарылган «Шахмат бюллетене»нең өченче саны сакланган. Аның редакторы, нашире һәм художнигы Муса Җәлил булган. «Бюллетень»нең бу санында Татар опера студиясе эшендә катнашучы шагыйрьләр һәм композиторларга дусларча шаржлар бирелгән. Шахмат уеннарында Әхмәт Ерикәй, Әхмәт Фәйзи, Латыйф Хәмиди, Нәҗип Җиһанов һ. б. лар катнашканнар[4].

Архивта М. Җәлилнең «Татар опера студиясе артистлары эшчеләр арасында» исемле 1936 елда язган мәкаләсе саклана. «Мәскәүдә төрле предприятие һәм төзелешләрдә меңнәрчә татар эшчеләре эшлиләр,— дип яза ул.— Мәскәүнең үзендә татар театры булмау аларның сәхнә сәнгатенә булган сорауларын канәгатьләндерүгә шактый нык уңайсызлый. Лакин Мәскәүдә драма театры булмаса да, татар җыр-музыка сәнгатенең иң билгеле көчләрен үзенә җыйган татар опера студиясе бар. Менә шул студиягә еш кына татар эшчеләре күп булган төрле предприятие, төзелеш һәм оешмалардан үзләре өчен концерт оештыруны сорап тәкъдимнәр килеп тора». Бу — татар опера студиясенең ике ел эчендә Мәскәүдәге татар эшчеләре арасында нинди мәхәббәт казанганын күрсәтә.

Студия укучылары эшче оешмаларының чакыруы буенча төрле клубларда еш кына концертлар биргәннәр. Шундый чыгышларның берсе Мәскәү сәнгать осталары клубында уза. Бу концерт Мәскәүдәге метрополитен төзелешенең икенче чираты эшчеләре өчен оештырылган. Концертта Татар опера студиясенең җырчылары Наилә Рәхмәтуллина, Асия Измайлова, Ситдыйк Айдаров, Сара Садыйкова, Фәхри Насретдинов, Нияз Даутов, биючеләрдән Б. Әхтәмов, скрипкачы-композитор Заһит Хәбибуллин һ. б. лар катнаша. «Бу концерт,— дип яза М. Җәлил,— татар опера студиясе җырчыларының җыр техникасын үзләштерүдә, тавышны чарлауда һәм үтәү культурасына ия булуда һаман үсә барганлыкларын тагын бер кат дәресләде. Бу җырчыларны моннан бер-ике ел элек тыңлаган һәрбер кеше, бу ике ел эчендә аларда никадәр зур үзгәреш һәм үсеш булганын һичбер кыенлыксыз әйтә алыр иде. Бу үсеш тавышларның дөрес куелуында, җырчыларның үз тавышларына оста контроль була алуларында, җырлау техникасының яхшыруында, җыр-

---

[1] КПСС өлкә комитеты партархивы, 10 ф., 3 тасв., 162 эш, 4—9 бб.

[2] «Советская музыка», 1966, 3 сан, 62—63 бб.

[3] Шунда ук, 65 б.

[4] Муса Җәлил. Фотоальбом. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1976, 93 б.; «Шахматное обозрение», 1983, 4 сан, 2—3 бб.

ларны культуралы башкаруында күренә. Без шунлыктан хәзер бер дә шикләнмичә бу яш армияне чын культуралы җырчыларыбыз дип атарга хаклыбыз». Аннары ул җыр тексты ның сыйфатына туктала. «Җырчы өчен җырлана торган текстның,— дип яза ул,— идея художество ягыннан югары сыйфатлы булуы бер дә иң соңгы чираттагы мәсьәлә тү гел. Җырның сүзләре матур булсыннар, мәгънәле булсыннар, саф татарча булсыннар халтура булмасыннар»[1].

1938 елның ахырында Татар опера студиясен тәмамлаучыларның кичәләре башлана Шундый чыгышларның берсе Мәскәү дәүләт консерваториясенең кече залында үтә М. Җәлилнең шул кичә турында «Татар опера студиясенең йомгак кичәләре» дигән мә каләсенең кульъязмасы сакланган. Ул матбугатта басылмаган.

«... 31 нче октябрьдә һәм 1 нче ноябрьдә оештырылган кичәләр,— дип яза автор,— башлыча студиянең опера өзекләре өстендә эшләгән эш йомгакларын күрсәтүдән гый бәрәт булды...» М. Җәлил студиягә тәҗрибәле дирижер һәм Мәскәүнең күренекле театр ларында эшләүче зур режиссер көчләр тартылуын билгеләп үтә. «Һәр ике кичәдә,— ди ул,— Мәскәү консерваториясенең җитәкчеләре, билгеле профессорлар, педагоглар, атак лы җыр һәм музыка көчләре, Мәскәү театрлары һәм матбугат эшчеләре, Мәскәүдәге татар партия-совет җитәкчеләре чакырылган иде. Зал һәр ике кичәдә шыгрым тулы бул ды»[2].

Опера студиясенең чыгарылыш имтиханнары турында М. Җәлил Казанга телеграф белән хәбәр итә: «30 ноябрьдә Татар опера студиясендә дәүләт имтиханы һәм рәсми чыгарылыш булды. Имтихан җырчы кадрларның хәзерлек дәрәҗәләре югары икәнлекне күрсәтте. Студиядә укучыларның 75 проценты имтиханны «отлично»га тапшырды...

Имтиханда Н. Җиһановның «Качкын», «Ирек» операларыннан өзекләр, студия композиторларының һәм классикларның әсәрләре башкарылды.

Студия, эшен тәгәлләп, 15 декабрьдә Казанга кайтачак.

М. Җәлил»[3].

Муса Җәлил татар музыкасын, үсеп килә торган яшь композиторларның иҗатын пропагандалауга гаять зур әһәмият бирә. Ул Татарстан китап нәшриятында аерым композиторларның хезмәтләрен бастырып чыгару, анда музыка әсәрләре буенча махсус сектор оештырырга кирәклеген күрсәтә. Татарстан Композиторлар союзын оештыру турында тәкъдим кертә. Менә аның Мәскәүдән яшьләр газетасына җибәргән «Музыка әдәбиятын — массага» дигән мәкаләсе. Анда татар музыка үсешенә анализ ясалган. М. Җәлил соңгы елларда татар совет яшьләре арасыннан байтак кына талантлы композиторлар күтәрелүен, күпләрнең Мәскәү һәм Казан музыка уку йортларында (консерватория, музыка училищесы һ. б.) укып, югары музыка культурасын үзләштерүләрен билгеләп үтә. Ул ике оригинал опера язган Нәҗип Җиһановны, татар халык көйләре өстендә күп эшләүче байтак лирик җырлар, романслар авторы Мансур Мозаффаровны, «Ташкыннар» һәм «Шәмсекамәр» пьесаларына язган музыкасы һәм балалар өчен язган әсәрләре белән билгеле Җәүдәт Фәйзине, талантлы композитор-музыкант Заһит Хәбибуллинны, Фәрит Яруллин, Мәсгуть Латыйпов, Заһир Бичурин һәм башкаларны атый.

Автор актуаль темаларга, бигрәк тә комсомол һәм яшьләр тормышына багышлап күп санда массовый җырлар, лирик һәм инструменталь (пианино, скрипка өчен) әсәрләр, симфония, соната, сюита кебек катлаулы формалар иҗат ителүен әйтә. С. Сәйдәшев һәм А. Ключарев хезмәтләренә аерым туктала. «Татар музыкасын тудыруда һәм үстерүдә,— дип яза ул,— зур хезмәте белән танылган, халыкның сөекле композиторы Салих Сәйдәшевнең дә, соңгы еллардагы иҗат эше үрнәкләре һәм Казан фольклор кабинеты аркылы татар халык көйләрен җыю, аларны эшләү буенча зур хезмәтләр күрсәтүче композитор Александр Ключаревның да тәҗрибәсен искә алмыйча үтәргә мөмкин түгел».

Шагыйрь-публицист татар совет композиторлары иҗатына җитәкчелек итү мәсьәләсенә дә кагыла. «Бездә,— дип күрсәтә ул,— шактый санда композиторлар өлгерүгә карамастан, композиторлар союзы шушы көнгә кадәр төзелгәне юк. Хәзер Татар опера театры төзелү һәм татар композиторларының күбесенең Казанда тупланувы уңае белән, бу мәсьәлә һич кичектерми торган реаль булып алга баса...»[4].

[1] Тел, әдәбият һәм тарих институты фәнни архивы, 10 ф., 1 тасв., 110 эш, 1—4 бб.
[2] Тел, әдәбият һәм тарих институты фәнни архивы, 10 ф., 1 тасв., 211 эш, 1—4 бб.
[3] «Кызыл Татарстан», 1938, 4 декабрь.
[4] «Яшь сталинчы», 1939, 4 январь.

М. Җәлил Татар дәүләт опера студиясендә эшләгән чорда да, әйткәнебезчә, композиторлар, музыка белгечләре, шагыйрьләр белән еш аралашып, хатлашып тора. Бу җәһәттән аның танылган музыка белгече, композитор, академик Борис Владимирович Асафьев белән бергә иҗат итүе, аннан күп нәрсәгә өйрәнүе, хат алышуы игътибарга лаек. Мәгълүм ки, «Алтынчәч» операсын башта Б. Асафьев язарга алына. Ул М. Җәлил белән иҗади хезмәттәшлек урнаштыра. Мәскәүдәге СССР Әдәбият һәм сәнгать үзәк дәүләт архивында аларның бер-берсенә язган хатлары саклана. 1938 елның 25 августында Мәскәү янында дачада торган академикка юллаган хатында М. Җәлил: «мин сезнең янга 26 августта килергә уйлаган идем, ләкин мине шагыйрьләр коллективы поэмамны редакцияләү уңае белән 1 сентябрьгә кадәр Казаннан җибәрмиләр»[1],—дип хәбәр итә.

1938 елның җәендә М. Җәлил белән Б. Асафьев бик еш очрашалар. Академикның көндәлекләрендә 2, 3, 8 июльдә, 13, 28, 29 сентябрьдә «М. Җәлил бездә дачада булды, «Алтынчәч» операсын татар операсы җитәкчелегенә уйнап күрсәттем»[2],— дип теркәп куйган. В. Асафьев 1938 елның 8 сентябрендә язган хатында шагыйрьдән хат алуын, М. Җәлилне ихтирам итүен, якын киңәшчесе итеп санавын икърар итә. «Әгәр дә мин шундый кыйммәтле хатларны күбрәк алсам, иҗатымда тагын да зуррак уңышлар яулар идем»,[3]— дип белдерә ул.

Композитор Җәүдәт Фәйзи, Татар студиясендә бергә эшләгән елларны искә алып, Б. Асафьев тарафыннан язылган «Алтынчәч» операсының язмышы турында болай ди: «Муса, Асафьевка барып, мандолинада татар халык көйләре уйнап, композитор ул көйләрнең үзенә кирәклеләрен нотапарга сала, опера өчен материал җыя. Муса, операның яхшы һәм татарча булуын бик теләгәнлектән, боларны эшләргә мәҗбүр иде. Ләкин Б. Асафьевның операсы уңышлы булмады, аның музыкасын җәмәгатьчелек кабул итмәде».

Билгеле булганча, Муса Җәлилнең «Алтынчәч» либреттосына музыканы Салих Сәйдәшевтан яздырасы килгән. «Беркөнне Муса белән Салих Сәйдәшев квартирасына киттек,— дип искә ала Ф. Исхаков.— Салих өйдә иде. Ул безне ачык йөз белән каршы алды... «Алтынчәч»кә музыканы миннән яздырырга теләвегезгә тагын да бик зур рәхмәт. Ләкин үзегез дә беләсез бит, мин опера музыкасы язучы композитор түгел. Җырлар гына язып маташам бит мин»,— дип шаяртып алды»[4].

«Мусаның искиткеч уңышлы либреттосы,— ди Җ. Фәйзи,— бары Нәҗип Җиһанов музыка язганнан соң гына чын сәнгать әсәре — татар опера сәнгатенең гүзәл үрнәге дәрәҗәсенә күтәрелде»[5].

Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы 1938 елның 28 октябрендә «Казанда Татар дәүләт опера театры оештыру турында» карар кабул итә. Карарда болай диелә: «Татар опера студиясенең Мәскәү дәүләт консерваториясендә уку занятиеләренең срогы тәмам булганлыктан, Казанда 1938 елның 10 октябреннән татар милли опера театры оештырырга, аны «Татар дәүләт опера театры» дип исемләргә»[6]. Соңрак, 1941 елның 10 февралендә, аны «Татар дәүләт опера һәм балет театры» дип исемен алмаштыру турында карар кабул ителә[7].

Татар дәүләт опера театрын төзү турындагы хөкүмәт карарын Муса Җәлил хуплап каршы алды. «Бу карар,— дип язды ул матбугатта,— татар совет сәнгате тарихында яңа битне ача. Ул орденлы Татарстан республикасының һәм бәхетле татар халкының культура фронтындагы яңа җиңешен терки.

Татар опера театрының төзелүе — татар совет культурасының һәм, аерым алганда, татар совет музыкасының яңа баскычка күтәрелүен күрсәткән факт. Ул — Октябрь революциясенең җиңеше, ул бөек Коммунистлар партиясенең милли политикасы тантанасы»[8].

Опера театрының әдәби бүлеге мөдире сыйфатында Казанга күчкәч, Муса Җәлил яңа көч, яңа планнар белән илһамланып эшли башлый. Аның шагыйрь-либреттистлар, язучылар, композиторлар, культура работниклары белән аралашуы киңәя, партия, совет һәм идеология оешмалары белән элемтәсе көчәя. Тырыш хезмәте белән ул опера театры коллективы алдында хөрмәт казана. Татар опера театрын үстерүгә зур өлеш керткән театр җитәкчелеге — дирекция, партия һәм профсоюз оешмалары югары бәяли. Бу, аерым алганда, М. Җәлилгә бирелгән характеристикада чагылыш таба:

«Иптәш Җәлилев 1935 елны әдипләрдән беренче булып опера мәйданына килде. Татар опера сәнгатен үстерү эшенә бик күп хезмәт салды. Музыка культурасын үстерү

[1] СССРның Әдәбият һәм сәнгать үзәк дәүләт архивы, 2658 ф., 1 тасв., 544 эш.
[2] Шунда ук, 39—44 бб.
[3] Казандагы М. Горький музее, 6416 эш.
[4] Үлемсезлек таңында. М. Җәлил турында истәлекләр. Татарстан китап нәшрияты, Казан. 1971, 36—37 бб.
[5] Муса турында истәлекләр. Казан, Татарстан китап нәшрияты. 1964, 90 б.
[6] ТАССРның Үзәк дәүләт архивы, 6663 ф., 1 тасв., 1 эш, 1 б. Төп нөсхә.
[7] Шунда ук, 6663 ф., 1 тасв., 34 эш, 178 б.
[8] Муса Җәлил. Әсәрләр, дүрт томда, т. IV, 394 б.

өлкәсендә иптәш Җәлилевның казанышы бигрәк тә зур. Ул, композиторлар белән тыгыз элемтәдә торып, аларны җырлар, романслар һәм башка жанрлар өчен әдәби текстлар белән тәэмин итте. Ул үзе музыка өчен бик күп гүзәл җырлар язды. Классик операларның текстын тәрҗемә итүдә иптәш Җәлилев үзе беренче үрнәкләрне күрсәтте.

Татар опера студиясенең әдәби бүлеге мөдире буларак иптәш Җәлилев студия тирәсенә язучыларны туплады һәм аларга даими консультацияләр үткәреп, либреттолар язарга рухландырды. Ул үзенең тырыш редакторлык-иҗади эше белән беренче либретто язучы кадрларны үстерде. Аның тирән анализлы рецензияләре һәм югары культуралы консультацияләре авторларга яхшы либреттолар язарга һәм тәрҗемәләр тудырырга ярдәм итте. Опера репертуарын барлыкка китерү бөтенләе белән иптәш Җәлилев тарафыннан тормышка ашырылды.

Алардан башка иптәш Җәлилев театр өчен иң яхшы либретто — «Алтынчәч»не язды һәм яхшы сыйфатлы итеп «Фигаро туе»н тәрҗемә итте.

Опера сәнгате мәйданында иптәш Җәлилевның озак еллар редакторлык, консультантлык, әдәби-иҗат эшчәнлеге аеруча игътибарга лаек. Аның беренче татар опера театрын төзүдә катнашы бик зур»[1].

М. Җәлил шул рәвешле татар әдәбиятында яңа жанр — музыкаль драматургияне тудырды. Ул оста либреттист, белемле музыка тәнкыйтьчесе дә иде. Аның җитәкчелегендә 1935-1941 елларны опера театры өчен 28 оригиналь либреттолар әзерләнә[2].

М. Җәлил — опера һәм балет театрына нигез ташларын салучыларның күренеклесе. Тәнкыйтьче Г. Кашшаф язганча, М. Җәлил «татар опера театрының җаны булып әверелә». Шуңа күрә дә театр хаклы рәвештә аның исемен йөртә. Билгеле инде, татар опера театрының ачылуы аның өчен зур шатлык һәм вакыйга була. «Театр бу елгы сезонны,— дип язды ул,— яшь композитор Н. Җиһановның «Качкын» операсы (Ә. Фәйзи либреттосы) белән башлап җибәрәчәк... «Качкын» белән бер үк вакытта, театр тамашачыларга Гетеның классик операсы «Фауст»ны татар телендә күрсәтәчәк. Операның либреттосы М. Максуд тарафыннан татар теленә тәрҗемә ителгән...»[3]

Татар операсының бөек рус халкы һәм башка халыклар ярдәме белән, СССР халыклары арасындагы бөек дуслык нигезендә туганлыгын М. Җәлил ассызыклап күрсәтте. Әйкенче бер мәкаләсендә ул Татар дәүләт опера театры коллективының перспективасы зур икәнлеген басым ясап әйтә: «Ул дөньяда бердәнбер, иң бәхетле социалистик Ватанда бөек Коммунистлар партиясе кайгыртуы астында яши. Шуның өчен аның бөтен көенлыкларны җиңеп, тиз арада Бөтенсоюз опера-балет театрлары белән бер сафта басарлык зур опера һәм балет театры була алуы тәэмин ителгән.

Советлар Союзы Герое Ленин премиясе лауреаты патриот-шагыйрь Муса Җәлил исемен йөртүче театр үзенә нигез салышкан олы шәхеснең алдан күреп әйткәннәрен инде тормышка ашырды, и...езенең күпсанлы сәнгать коллективлары арасында лаеклы урын алды.

---

[1] КПСС өлкә комитеты партархивы, 30 ф., 3 тасв., 162 эш, 30—31 бб. Төп нөсхә.

[2] Юлдуз Исанбет. Муса Джалиль и татарская музыка. Казань, Татарское книжное издательство, 1977, 37 б.

[3] «Яшь сталинчы», 1939, 10 март.

## Мәхмүт Хәсәнов

# ИДЕЛ ҺӘМ МУСА

### БЕР ИСТӘЛЕК

Бу вакыйга булганга бик күп еллар үтте инде. Бәлки шуңа күрәдер, ул көн дә, ничектер, гадәти булмаганча, могҗизалы бер төш сыман гына хәтердә калган. Көне дә искиткеч аяз, күк йөзе дә, бүтән вакытлардагыдан үзгә буларак, иксез-чиксез һәм зәп-зәңгәр иде. Идел турында әйтеп торасы да юк: ул, бөтен галәмне нурга коендырган кояш астында, мең төрле төсләргә кереп, сабыр-тыйнак кына ага да ага. Күзләрне чагылдырган вак дулкыннар өстендә, ап-ак акчарлаклар уйнаклап оча. Хәтта пароходлар да ул көнне гадәти түгелләр кебек иде: җиңел йөзәләр, җитмәсә, нәкъ һавада очкан акчарлаклар төсле, күз явын алырлык, ап-ак үзләре...

Миңа, әле яңарак кына авылдан калага күченеп килгән малайга бар да кызык, бар да тылсымлы әкият сыман гадәти түгел иде. Үземише яшүсмерләргә иярел, мин дә Иделнең аръягындагы Маркиз дип аталган утрауга су коеныргa, комда кызыныргa чыккан идем. Идел өсте тулы көймәләр. Барысы да безнеңише ял итәргә чыгучылар...

Шулчак, арабызда безгә күз-колак булырга тиешле җиткәнрәк кызларның берсе, әле яңа гына яр буена килеп туктаган көймәләрнең берсенә күрсәтеп, әйтә салды:

— Әнә, карагыз... Шагыйрь Муса Җәлил!..

Безгә, гомерләрендә тере язучы күрмәгән малай-шалайларга, җитә калды.

— Кая?.. Кайсысы?..

— Соң, әнә инде!..

— Әле генә ярга сикергәнеме?

— Әй-йе инде...

Сай булгангамы, көймә яр буена ук килеп җитә алмаган. Шунлыктан көймәдәгеләр, аяк киемнәрен чылатмас өчен, ярга сикереп чыгарга тиешләр иде.

Муса абый да көймәнең борын өлешенә якынайды һәм ярга сикереп төште. Аксыл күлмәген җилкәсенә салган. Тәне кояшта тигез булып янган. Йомры җилкәләренә, мускуллары беленеп торган нык беләкләренә һәм гәүдәсен бик тә төз тотуына караганда, ул, шагыйрь булудан бигрәк, атлетка, спортчыга охшаган иде.

Үзе генә булмаган икән Муса абый. Сикереп төшү белән үк, көймә ягына борылып, кулын сузып, нәфис кенә буй-сынлы бер хатын-кызга да төшәргә ярдәм итте. Шунда ук алар, аяк киемнәрен салдылар да, нәрсәдәндер көлешә-көлешә, кайнар комлы сукмак буйлап өскә таба күтәрелә башладылар...

Ул вакытта инде Муса Җәлил безнең сөекле шагыйребез: ялкынлы шигырьләрен йотлыгып укыйбыз, дәртле җырларын җырлыйбыз. Шунлыктан аның белән кызыксынуыбыз да чамадан тыш булгандыр, күрәсең: без аларны күздән яздырмаска тырыштык...

Өскә, куе әрәмәлеккә үк күтәрелерләр дип уйлаган идек. Юк, яр өстендә, бөдрә башын Иделгә таба иеп үскән бер оя таллык күләгәсенә туктадылар. Бераздан инде Муса абый да, аның юлдашы да, мәж килеп ял итүчеләр кебек, кайнар комга сузылып ятып, кызына башладылар.

Шул вакыт Муса абый тал төбенә җыеп куйган киемнәре арасыннан әллә ни зур булмаган зәңгәр тышлы дәфтәр чыгарды да юлдашына нәрсәдер укый башлады. Гади генә нәрсә укымаганлыгы хәрәкәтләреннән үк күренеп тора. Үзенә җайлы урын таба алмаган кеше сыман, ул я тезләнә, я кабат утыра, һаваны ярып, сыңар кулы белән ишарәләр ясап куйгалый. Бер генә мизгелгә укуыннан бүленеп, юлдашына нәрсәдер аңлатып бирергә дә өлгерә...

Аларның чак кына үзәнлерәк урында утыруларыннан файдаланып, якынлаша башладык... Сиздермичә генә, бер дә исебез китмәгән кыяфәт белән, әлбәттә. Янәсе, безнең урыныбыз да алар тирәсендә...

Шул вакыт мин, гомеремдә беренче тапкыр буларак, Муса абыйның тавышын ишеттем. Укыган нәрсәсе дә гади шигырь генә түгел иде аның...

...Балаларым! Алтын Урдадан
Килмешәк хан килеп бу илгә,
Кан һәм кылыч белән ханлык төзеде,

Үз хөкемен куйды Иделгә.
... Тик, улларым, шуны белегез,
Тез чүккәнче ханга кол булып,
Аягүрә сугышып үлегез!

Тугзак ана тирмәдән кылыч алып чыгып, иң кече — тугызынчы улына бирә. Ирек өчен көрәштә бу улы да башын сала... Хан ананың үзен дә әсир төшерә, җәзалый: ике күзен чукытып алдыра, аяк табаннарын ярдыра...

Еллар үткәч кенә мин Муса абыйның атаклы «Алтынчәч» либреттосын укыганлыгын белдем. Һай-й, бу тормыш дигән нәрсә! Соңрак, 1944 елның көзендә, Мәскәүгә театр сәнгате институтына укырга киткәнче, миңа артист сыйфатында, ул операда хәтта катнашырга да туры килде. Әмма либреттоны беренче тапкыр ишеткән вакытым һәрвакытта да күз алдымда булды минем...

Менә ул, чиксез бирелеп, чын-чыннан дулкынланып, кулларын болгый-болгый укый... Тугзак карчыкның бердәнбер исән калган оныгы — Җик инде егет булып үсеп җиткән. Ана-карчык аны да яу-көрәшкә озата...

Ук-җәяңне ал, улым!
Яуга каршы бар, улым!
Тугыз батырның үчен
Кулупайдан ал, улым!..

Ә Муса абый илһамланып укый да укый. Ул бу минутта бернәрсә дә күрми, бернәрсәгә дә игътибар итми иде булса кирәк. Чөнки алар белән без генә түгел, тагын бик күпләр кызыксынган икән. Әнә, Муса абый белән аның юлдашы урнашкан нәни генә үзәнлекне җыелган яшьләр тирә-яктан шактый тыгыз боҗра итеп чорнап та алганнар. Тик Муса абый белән аның юлдашы гына бу турыда белмиләр иде шикелле.

Муса абый укый...

Ниһаять, каты сугыштан соң, хан гаскәре җиңелә. Хан үзе качып котылмакчы була. Әмма аның каршысына Тугзак килеп баса...

Халык шатлана, тантана итә.

Муса абый «Алтын кояш нурларында, ямьле Идел буйларында...» — дип, финал хорының соңгы сүзләрен укыды да: «Менә, шул!..» — дигәндәй тынып калып, дәфтәрен япты. Әмма дөньясын онытып тыңлап утырган юлдашы авыз ачарга да өлгерә алмады, шул вакыт бөтенләй көтелмәгән хәл булды. Үзәнлекнең безгә каршы ягында торган бер төркем яшьләр, дәррәү кул чаба башладылар. Аларга, билгеле инде, без дә кушылдык...

Бу көтелмәгән хәлдән Муса абый аптырашта калды. Уңайсызланды. Аннары сикереп торып, дәфтәрен җәһәт кенә киемнәре астына кыстырды да, үзләрен чорнап алган яшьләрне ерып үтеп, аска таба йөгерде... Һәм йөгереп килгән шәпкә Иделгә кереп тә чумды. Тирә-якка, җәүһәр ташларыдай ялтырап, су гына чәчрәп калды.

Колачын киң җәеп, әле генә өскә таба узып киткән зур пассажир пароходының дулкыннарында чайкала-чайкала йөзде ул. Аның колач салып, илаһи матур йөзүенә сокланып, байтак вакыт карап тордык без. Бераздан ул ярдан шактый ерагайды һәм бер төркем су коенучылар арасында күздән югалды...

Хәзер инде Маркиз утравы юк. Су астында калды. Шулай ук Идел дә үзгәрде... Хәзер инде таң кебек якты булып, җыр кебек матур булып ишелә-ишелә аккан яңа Иделне таный да алмас идең, Муса абый. Өзелеп яраткан, күп сандагы җырларыңда назлаган Иделең, нәкъ синең шәхесең кебек хәзер: биниһая зур ул, бөек ул!..

# ЛАЧЫННАР КАНАТ НЫГЫТА...

Муса Җәлил — Татарстан хезмәт ияләренең генә түгел, ә бөтен Совет халкының горурлыгы. Чөнки ул безнең илебездәге әдипләрдән иҗаты белән Ленин премиясенә, ә батырлыгы белән Советлар Союзы Герое исеменә лаек булган бердәнбер шагыйрь. Менә шушы факт — ике иң зур бүләккә лаек булу — үзе генә дә Җәлил шәхесенең ниндилеге хакында бик ачык сөйли.

Ә менә шушы бөек кеше шәхесе үзе ничек формалашкан соң?

Бу сорауга җавап эзләп без Мусаның Мәскәү дәүләт университетында уку чорына, 1927—1931 елларга күз төшерик. Ул чор, чыннан да, киләчәктә бар халыкларны таң калдырачак беркетнең канат ныгыту вакыты булган икән. Тикшеренү процессында табылган бик күп фактлар әнә шуны раслап тора.

Муса Мәскәү университетының этнология факультетына укырга керә. Биредә барысы 872 студент исәпләнә. Шагыйрьнең сабакташлары арасында бик күп атаклы кешеләр була. Мәсәлән, соңыннан танылган кинодраматург булачак Михаил Папава (аның «Мәскәүдән еракта», «Биеклек», «Иванның балачагы» һ. б. кинолары бар), рус теле буенча зур белгеч, «Вопросы языкознания» журналының баш редакторы Федор Петрович Филин, бүгенге көндә атаклы тәнкыйтьче, галим Григорий Абрамович Бровман, шулай ук зур язучы, СССР Дәүләт премиясе лауреаты, «Рубанюклар семьясы», «Таврида» романнары авторы Евгений Ефимович Поповкин, рус совет язучысы, озак вакытлар «Новый мир» журналының баш редакторы булган Анатолий Кузьмич Тарасенков һ. б. лар барысы бергә укыйлар.

1983 елда Мәскәүдә басылып чыккан «Кеше — кешеләр өчен» китабында Григорий Бровман Муса тормышына кагылган байтак кызыклы мәгълүматлар китерә. Шагыйрь белән соңыннан Волхов фронтында очрашуын язганнан соң, автор үзләренең студент елларына кире кайта. Җәлил белән бер арада, бер бүлектә укыганын сөйли. Шагыйрьнең зур иҗат эше белән шөгыльләнгәнен әйтә, комсомол тормышында кайнап яшәвен мавыгып искә ала. Алар бик күп вакытны алсалар да, Җәлил укуын да уңышлы алып бара иде, ди китап авторы.

Муса белән бергә университетта мари халкының танылган язучысы һәм галиме Яныш Ялкайн да укый. Бу еллар хакында ул үзенең «Шәһәр» исемле автобиографик повестенда матур итеп яза. Әсәрнең төп геройлары икәү: мари егете Ачин (автор үзен шушы герой аша бирә) һәм татар егете Хәсән. Соңгысының бөтен сыйфатлары Мусаныкына охшый. Бу образ, чыннан да, булачак герой-шагыйрь тормышы нигезендә язылган.

Хәсән — тормышны шактый белә торган, байтак тәҗрибә туплаган егет. Ул Казанда рабфак бетереп килгән... Ачин исә бераз тәҗрибәсезрәк, ул әле шәһәрдә үзен кыен сизә. Менә шул чагында инде аңа Хәсән ярдәм итә, аңа терәк һәм таяныч була. Әкренләп Ачин да студент яшәвенә ияләшә башлый. Хәсән аны уку белән, әдәбият белән, җәмәгать эшләре белән мавыктыра. Алар бергә-бергә яңа дуслар да табалар, кызлар белән танышалар.

Повестька эпиграф итеп «Иң зур җиңү — үзеңне җиңү» дигән сүзләр куелган. Әсәрдә бу тулысынча аклана. Ачин гади авыл малаеннан алдынгы студентка әверелә. Аның мондый үзгәрешенә иң нык булышучы кеше булып укучы күз алдында Хәсән гәүдәләнә. Ә хәзер инде без бу Хәсәннең булачак герой Муса Җәлил икәнен бик яхшы беләбез.

Әйе, ике халыкның ике язучысы да үзләренең уртак дусларының яшь чагын бик дөрес сурәтлиләр: Муса яшьтән үк тырыш, актив, кешелекле, бик ярдәмчел. Ул революцион идеяләргә җаны-тәне белән бирелгән. Ул җәмәгать эше дип, комсомол дип көн-төн чаба. Аңа тынгысызлык хас, ул һәр нәрсәне йөрәк дәртен салып, рухланып эшли.

Мәскәү университетында уку еллары — Муса өчен дә һәм без югарыда исемнәрен атап үткән атаклы әдипләр, галимнәр өчен дә, шулай ук барлык студентларга да шәхес буларак үсү, ныгу, чыныгу еллары да була. Яңа революцион идеяләр, вакыйгалар белән кайнап торган чор аларны таныштыра да, дуслаштыра да һәм шуның белән аларның һәрберсенә тагын да киңрәк офыклар ача. Бу кешеләр инде төрле халыклар, милләтләр мәнфәгатен белүче, кайгыртучы киң күңелле интернационалистларга әйләнәләр. Киләчәк зур сынауларда бик тә кирәк булачак чыныгу алалар.

Чыннан да, ул дәвер Мәскәү университеты тормышына карасаң — анда нинди генә кызыклы вакыйга юк! Студентлар алдында нинди генә күренекле кешеләр чыгыш ясамый! Биредә А. В. Луначарский, П. Н. Лепешинский, И. И. Скворцов-Степанов, Ю. Ю. Мархлевский һ. б. лар укыта. О. Ю. Шмидт «СССРның фәнни эшлекләре һәм социалистик төзелеш» дигән темага доклад ясый. Н. А. Семашко чыгышлар белән килә. 1928 елның 17 февралендә М. И. Калинин биредә үзенең атаклы «Культура революциясе турында»гы чыгышын ясый.

1927 елда Советлар Союзына Анри Барбюс килә һәм Мәскәү университеты студентларына мөрәҗәгатендә Совет иленә сокпануын белдерә. 1929 елда Ромен Ролланның үз әсәрләреннән килгән гонорарны университет студентларына стипендия итеп күчерү вакыйгасы да барысының күңеленә сеңеп кала.

Владимир Маяковскийның студентлар белән очрашуы онытылмаслык вакыйгага әйләнә. Бу хакта мари язучысы Иосиф Беляев болай сөйли: «Муса Җәлил, Яныш Ялкайннар укыганда мин беренче курста идем, ләкин алар белән еш очраша идем... 1927 елның 4 ноябрендә, без Октябрьнең чираттагы юбилееен каршыларга әзерләнгәндә, университетка атаклы шагыйрь В. В. Маяковский килде... Залга бик кыенлык белән генә үттек. Владимир Владимирович үзенең «Яхшы» поэмасын укыды. Анда Муса Җәлил, Василий Долгов, Яныш Ялкайн, Петр Лашманов һәм Анатолий Тарасенков бар иде...»

Күргәнебезчә, әдәбиятка зур мәхәббәт белән янган дуслар биредә дә бергә утыралар. Әнә шулай кайсы гына фактны алсаң да, анда олы уйлар белән рухланып яшәгән шәхесне күрәсең...

Менә тагын Г. Бровман истәлекләренә кайтыйк. «1931 елның салкын бер кичендә без Мусаны үзебезнең Нескучная (элекке исеме) урамындагы тулай торакка алып кайттык. Аның яшәгән урыны исә Зур Черкас урамында, җиденче йортта иде. Бүлмәбездә Поповкин белән икәү һәм тагын ике студент булганга күрә, кысан иде. Шуңа күрә коридорда җыйналдык... Муса үзенең шигырьләрен күбрәк татарча укыды. Безнең күбебез телне белми, ләкин Җәлил шигырьләренең музыкаль аһәңе һәм тыгыз, таләпчән ритмы, авторның янып торган күзләре, искиткеч тәэсирле мимикасы — болар барысы онытылмаслык булып хәтердә калган... Ул бер-ике шигырен русча да укыды... Үзебезнең талантлы сабакташыбызны ул кичне без бик озак җибәрми тордык...»

Бровман истәлекләрен алга таба укысаң, Җәлилне гаять тыйнак кеше буларак характерлаган урыннарны да табасың. «Эчке тупланганлык һәм күпмедер уйчанлык хас булуга да карамастан, ул бик аралашучан һәм күңелле кеше иде. Минем кабатланмас студент елларым хатирәсендә ул әнә шундый булып калган...»

Муса белән бер чорда укып, соңыннан мәгариф системасында озак еллар эшләгән В. И. Самсонов та миңа сөйләгән истәлегендә Җәлилнең уңганлыгын аеруча басым ясап күрсәтә. «Уртак лекцияләрдән һәм җыелышлардан кала без аны еш кына дәрестә күрми дә идек. Чөнки аңа партия һәм комсомол эшенә дә, әдәбият ихтыяҗларына да өлгерергә кирәк иде... Ул аларның һәммәсенә җитешергә тырыша иде. Аның характеры шундый иде инде: тиктормас, тынгысыз, эшчән».

Шагыйрьнең сабакташлары сөйләгән сүзләрне Мәскәү дәүләт университеты архивында саклана торган түбәндәге документ та раслый. Ул документ — Муса Җәлилгә бирелгән академик һәм иҗтимагый-политик характеристика. Аны тулысынча китереп китәбез.

«Җәлилов Муса Мостафа улы. Туган елы — 1906. Социаль чыгышы — крестьяннан. Социаль хәле — хезмәткәр. 1923 елдан Союз члены. 1929 елдан ВКП(б) члены. Әдәби эш стажы — 4 ел.

Идеологик яктан тотнаклы. Партиянең төп линиясеннән тайпылышлары булмады. Марксистик-ленинчыл методологияне дөрес куллана. Партия йөкләмәләрен бөтен ячейкада үтәде. Җәмәгать эше: Коммунистик Яшьләр Союзы Үзәк Комитетының татар бюросы члены, МАППның татар секциясендә җаваплы секретарь, татар журналының редколлегия члены, алласызлар үзәк союзының татар секциясе члены.

Методологик әзерлеге җитәрлек. Фактик материал курсын үзләштерде. Милли әдәбият өлкәсендә фәнни эшкә әвәслеге бар.

Эшнең бригада формаларына аңлы мөнәсәбәт күрсәтте.

Практик эшкә әзерлеге җитәрлек (милли матбугатта эшләде).

Татар матбугатында үзбаш эшләүгә тәкъдим ителә».

Муса Җәлилгә бирелгән бу характеристика Мәскәү дәүләт университеты архивында 21 фонд, 1 тасвирлама, 43 саклау берәмлеге булып тора.

Шагыйрьнең студент еллары белән кызыксынганда, миңа саргаеп беткән бер фото да очрады. Ул 1928 елның җәендә төшерелгән фото. Университетның этнография факультеты студентлары хәрби сбор вакытында барысы бергә җыйналып фотога төшкәннәр. Муса Җәлил өстән өченче рәттә, уңнан өченче булып утыра. Яныш Ялкайнны исә без өстән икенче рәттә, сулдан өченче итеп күрәбез... Димәк, бу фото ике халыкның ике әдибе дуслыгын тагын бер мәртәбә раслый. Һәм аларның яшьлек еллары истәлеге булып тора.

**Петр АПАКАЕВ,**
педагогика фәннәре кандидаты.
Йошкар-Ола.

## Вадим Дементьев

# «...ҖЫР ӨЙРӘТТЕ МИНЕ ХӨР ЯШӘРГӘ!»

Муса Җәлил исеме бүген татар халкының рухи батырлыгын һәм күңел аклыгын белгертүче символ булып яши. Илебездәге күп милләтләр үзләре өчен Җәлилне әнә шулай кабул итәләр.

Казан кременең ап-ак диварлары янына мәһабәт бер һәйкәл булып торып баскан Мусаны минем дә байтак күргәнем бар. Алай гына да түгел: ул укыган, эшләгән урыннарда булдым, күптән түгел ачылган музей-квартирасын карадым... Ләкин күңел һаман нидер эзли, нәрсәдер көтә иде... Йөри-йөри аңладым мин моны — Җәлилне үзем өчен җанлы, тере кеше итеп күз алдыма китерә алмыйм икән! Ул әле минем өчен һәйкәл сыманрак яши икән.

Әмма, бәхетемә күрә, мондый хәл озак дәвам итмәде.

Казанга чираттагы килүемнең берсендә, Сибгат ага Хәким белән ихлас әңгәмә корып утырганда, Муса Җәлилне беренче мәртәбә җанлы кеше итеп күз алдына китерә алдым мин.

Ул көнне безнең әңгәмәбез Муса турында сөйләшүдән башланды бугай. Сибгат аганың, үз дустын искә төшерү белән, күзләре дәртләнеп, балкып китүен, кабат яшьлегенә кайткандай булуын әле һаман онытасым юк.

— Кеше тормышында шундый очраклар була,— дип сөйләп киткән иде ул чакны Сибгат ага.— Башта артык әһәмияткә ия түгел кебек тоелган ниндидер бер күренеш синең бөтен гомереңә җитәрлек яктылык, нур биреп калдырган була. Ул, яшен яктысы кебек, синең алдыңда еллар аша балкып тора...

Сугыш алды тормышыннан онытылмаслык бер күренеш сөйләде миңа өлкән шагыйрь.

— Җәй көне иде... Безнең союз җитәкчесе Мусаны, мине һәм минем дус шагыйрәмне очрашуга чакырдылар. Шәһәрдән ерак түгел урманда урнашкан хәрби частька... Очрашу бик матур үтте, урман аланына җыелып, солдатларга шигырьләр укыдык. Аннары сорау бирә башладылар, әңгәмә куерды, кунак иттеләр...

Кыскасы, безне кичкә таба гына җибәрделәр... Кайтканда шулай ук бик күтәренке кәеф белән, уйный-көлә, экспромтлар әйтешә-әйтешә кайттык... Шунда, болын юлы буйлап шаярыша-шаярыша кайтканда, күрми-искәрми дә калганбыз: болыт тартып, яңгыр да коя башламасынмы! Нишләргә? Якында бер яшеренер урын да юк. Әле җитмәсә, яшен дә яшьни! Бүтән чара калмагач, тоттык та кире йөгердек инде. Бүтән барыр җир юк бит!

Күз алдыгызга китерегез: алда да, артта да кап-кара болыт, бертуктаусыз яшен яшьни, яңгыр коя. Муса минем белән барган кызның ап-ак туфлиләрен менә шулай яп-якты шәм кебек итеп югары күтәргән дә, иң алдан чаба... Без яшенгә әнә шулай барып кердек бугай. Муса да минем күз алдымда һаман шулай тора: кара болыт һәм яшен уртасында. Ләкин курыкмый — ул уенчак, көчле һәм яшь! Һәм йөгерә, йөгерә!

Сибгат ага онытылып, рухланып, мавыгып сөйли. Ә мин уйлап утырам: «Иң шәп шигырьләр шулай туадыр инде...» Чыннан да, шагыйрьнең бу хикәяте үзе бер шигырь иде!

Миңа Җәлилнең беренче яңгыр — ләйсән — турында язган шигырьләрен дә укырга туры килгәне бар. Аларның берсе болай бетә:

Безнең тормыш шундый иректә,
Шатлыклы һәм матур түгелме?
Яңгыр алды төсле өметле,
Яңгыр арты төсле күңелле!

Шагыйрь табигатьне көч һәм илһам чыганагы итеп саный, аны ярата. Ә менә Сибгат ага сөйләгән очракны Җәлил исендә калдырды микән? Шигырьләр арасында турыдан-туры моңа кагылган әсәр тапмадым мин. «Моабит дәфтәр»ендә менә мондый образ бар:

Көн яңгырлы иде мин киткәндә,
Карап калды боегып сердәшем,
Юешләтте аның керфекләрен
Яңгыр түгел, назлы күз яше.

Ләкин биредә хикмәт нинди дә булса биографик моментны ачыклауда түгел. Өлкән шагыйрьнең әлеге хикәяте минем алга җанлы Җәлилне китереп бастырды. Аның шигъри образ көче яшен уты сыман балкып, Мусаны миңа нык якынайтты, хәтта үз итте. Ул миңа кешелек ягыннан ачылып китте, Җәлилне кеше буларак, якыннан аңларга булышты. Аның

дуслары күп булган, ул дустын авыр хәлдә калдырмаган, кайгысын да — шатлыгын да алар белән бүлешкән. Әнә шуңа күрә кешеләр аңа тартылган, ул үзе дә бик аралашучан, актив, оптимист кеше булган.

Хәер, аның яшүсмер чагы, яшьлеге дә әнә шундый бит. Туган авылы Мостафада ук Муса балалар оешмасы төзи, унөч яшендә китапханә һәм клуб оештыра, кулъязма журнал чыгара. Авылның комсомол ячейкасы да шуннан башланып китә... Менә бит аның батырлык, оптимизм чыганаклары каян ук килә! «Яшьләр» дигән шигырендә Җәлил бер дә юкка гына болай язмаган бит:

| | |
|---|---|
| Безгә күп булса | Яшьлек — безнеке, |
| Егерме ике. | Яшәү — безнеке. |

Бер караганда артык пафослы һәм оптимистик тоелган бу юллар икенче бер шигырьдәге менә шушы сүзләрдән соң безгә бик тә аңлашыла:

| | |
|---|---|
| Мин яшьлекне | Иң бәхетле илне төзегәндәге |
| Иң күркәм чорда кабызып, | Кайнар тирем итеп агыздым. |

Менә хикмәт нәрсәдә — кешенең фидакарьләрчә бирелгән булуында. Илгә, халыкка, эшкә бирелгәнлегендә!

Ә хәзер бүтән елларга күчик тә менә мондый шаян шигырь укыйк:

Җыеп кырдан бөрлегән
Килгән иркәм, бер генәм.
Ә мин аңа сөюемне
Белдерәлми тилмерәм.

Дәрт, шаянлык, мәхәббәт ташып торган бу шигырь салкын төрмә камерасында — 1943 елның 8 октябрендә язылган. Үзенә үлем җәзасы булачагын белгән шагыйрь тарафыннан язылган! «Моабит» циклында мондый әсәрләр аз түгел.

Уйлап карыйк: шул хәлдә, шигырьләрең ышанычлы кулга барып кererен белмәгән килеш — оптимистик әсәрләр язу өчен кешегә никадәр рухи көч, инангaнлык, ышаныч кирәк! Яза алган — димәк, ул сыйфатлар Мусада мул булган!

Әйе, Җәлилнең иң авыр вакытта да күңелен төшермәве, үзен нык тотуы турында безгә бүтән мәгълүматлар да сөйли. Мәсәлән, ул төрмәдә Ланфрединидан итальян теленә өйрәнә, китаплар укырга тырыша. Үлеменә берничә көн кала Гетеның «Фауст»ын сорап алып укый.

Муса һәм аның дуслары, әлбәттә, үзләренең үләсен белеп торалар. Әмма алар үлемнән курыкмый. Әнә бит Җәлил «Катыйльгә» шигырендә ничек яза:

| | |
|---|---|
| Мин тез чүкмәм, катыйль, синең алда, | Кирәк икән, үләм аягүрә, |
| Кол итсәң дә, тоткын итсәң дә, | Балта белән башым киссәң дә. |

Минем шуны күзәткәнем бар: чын шагыйрьләрдә, зур шагыйрьләрдә ниндидер бер пәйгамбәрлек, вакыйгалар барышын алдан сизенү була. Муса иҗатында да әнә шундый алдан сизенү, алдан әйтү моментлары шактый. Менә барыбызга да билгеле шигырьне, «Сугыштан соң»ны искә төшерик:

| | |
|---|---|
| Май аенда тагын җыйналырбыз, | Бокалларның көмеш чыңы белән |
| Кызыл шәраб килер табынга. | Табын җыры яңрар тагын да. |

Бөек шагыйрьләргә генә хас булган бөек көрәшәлек дими ни дисең моны! 1943 елда язылган шигырь җиңүнең һичшиксез буласын гына әйтми, аның кайсы айда киләсен дә искиткеч төгәллек белән «май аенда» дип белдерә! Әйе, чыннан да, зур шигъри талантларда гына күзәтелә торган күренеш бу.

Җәлил шигырьләрендә үз язмышын алдан сизенү мотивлары да яңгырый: «Яшәсәм дә, үлсәм дә тик туган ил өчен!» Тагын:

| | |
|---|---|
| Әйдә, җырым, | Мин калмасам җирдә, |
| батыр җиңү дәртен | син калырсың |
| Алып керик ялкын эченә. | һәйкәл булып үлмәс эшемә. |

Әйе, кайсы гына чорда язылган әсәрен алсаң да, аларда кызыл җеп булып шундый идея сузыла — бөек эшкә бирелгәнлек, аңа үтә тугрылык, аның өчен һәртөрле, хәтта иң авыр корбанга да барырга риза булу. Җәлил һәм аның дуслары үзләренең әйтелгән сүзләрен, вәгъдәләрен җитди сынау вакыты килгәч ирләрчә үтәделәр. Аларның сүзләре эштән аерылмады. Иң югары шигъри ялкынга ия сүз иң югары батырлык белән расланды! Менә кайда ул шәхеснең зурлыгы, бөеклеге!

Ләкин тагын шунысы бар: Җәлил шигърияте һич тә бер генә үлчәмле, бер генә катлы түгел. Ул тормышның үзе шикелле күп төрле. Иң югары патриотик шигырьләр янәшәсендә бик матур лирик, яисә шаян әсәрләр дә яши. Башта әйтеп узганыбызча,

табигать күренешләре, бигрәк тә, ләйсән яңгырлар, кышкы бураннар аеруча тәэсирле итеп сурәтләнә. Алар янәшәсендә үк диярлек, илнең ныклыгы һәм куәтен белдерүче символ буларак тимер образы да килеп керә. Ә инде барысын берләштерүче образ буларак кояш яши. Аны — бу ягымлы, җылы көчне — Җәлил шигырьләрендә еш очратасың. Ә менә утызынчы еллар шигъриятендә, Германиядә властька фашистлар килгәч, Муса өчен кояш инде болайрак күренә:

Кояш, малай,
бик тәз атучы икән,
Нурын төртте
туры йөраккә.
Әйтерсең, бу йөрәк мишень аңа,
Әйтерсең, ул тирга эләккән.

«Тирга» шигырендә Муса табигать белән дөнья хәлен берләштереп әнә шулай язса, «Походка» әсәре белән ул илебезнең үсешенә комачаулаган әчке җитешсезлекләргә каршы көрәшә.

Өзеклекнең соңгы крепостен
Поход белән ватып ыргытыйк,
Прогулның,
ялкау, исреклекнең
Ут шикелле тамрын корытыйк.

Кимчелекләргә каршы нинди рәхимсезлек яңгырый бу юлларда! Безнең бүгенге яшь иҗатчыларга нинди матур үрнәк ул шигырь!

Муса тормышы... Әйе, ул нык рухлы кеше булган. Әмма ул да кеше булган. Аның да бик нык аптыраган, уйланган чаклары булган. Характерында кайбер елмаю тудырырдай сыйфатлар да яшәгән. Шагыйрьне күргән-белгән кешеләр белән сөйләшкәндә без ул сыйфатлар турында беләбез. Тик алар да безгә Муса образын тулырак, җанлырак итеп күзалларга гына булыша...

Шагыйрьнең бөтен тормышы көчле омтылыш белән бара. Ул кечкенә чагыннан ук укуга, белемгә омтыла — киңрәк һәм актив яшәүгә ашкына. Туганнары сөйләвенә караганда, тугыз-ун яшендә инде авылда ул укымаган китап калмый.

Казанга күчеп килгәч тә, Җәлил белемгә булган көчле омтылышы кушу буенча рабфакка укырга керә. Шәһәрдә кайнаган яңа тормыш аның иҗатына да өр-яңа сулыш өрә. Соңыннан Муса үзе: «Бу елларда минем иҗатымда борылыш булды»— дип яза. Озак та тормый аның беренче китабы дөнья күрә — «Барабыз». Әле аңа нибары 19 яшь. Менә бу исем үзе үк бик күп нәрсә хакында сөйли. Чөнки Мусаның тормышы, чыннан да, гел бару, алга таба хәрәкәттән генә тора шикелле. Ул бик күп җәмәгать эше алып бара, һәммәсенә өлгерә, җитешә. Р. Мостафин үзенең «Муса Җәлил. Шагыйрьнең балачагы һәм яшьлеге турында очерк» дигән китабында шундый бер эпизод китерә.

Шәһәрдән җиде чакрым ераклыктагы бер авылга барып халыкара хәл турында доклад укуны йөкләләр Мусага. Ул риза була, юлга җыенам дип өенә кайтып китә. Тик шул арада буран куба. Укомдагылар борчылып, юлда адашыр дип, докладны икенче көнгә күчерергә булалар һәм бу хакта әйтергә Мусаның өенә кеше җибәрәләр... Баксаң — Муса инде күптән чыгып киткән!

Икенче көнне иртән, берни булмаган төсле, укомга эшкә килеп керә Муса. Һәм рапорт бирә:

— Доклад ясадым. Утыз кеше бар иде!

Уком кешесенең: «Без докладны икенче көнгә күчергән идек бит» дигән сүзенә каршы, Муса елмаеп:

— Мин гаепле, белсәм — бармаган булыр идем!— ди.

Соңыннан шул беленә: теге авыл яшьләре Муса киләсен ишеткәч, сумаладан факел ясап, ут яндырып көйгәннәр икән. Шул ут Мусага маяк булган.

Бу эпизод Мусаны тагын да ныграк аңларга булыша. Тынгысыз җан, кыю егет, эшкә бирелгән кеше буларак...

Җәлил 1927 елда Мәскәү дәүләт университетына укырга керә. Миңа да анда уку бәхете элэкте. Мин дә Муса йөргән коридорларда йөрдем, ул утырган аудиторияләрдә лекцияләр тыңладым. Шул ук китапханәдә семинарларга әзерләндем... Әнә шул чагында мин Мусаны да үз янәшәмдә итеп тойгандай булдым. Ә аннары, Казанга килеп йөри башлагач, шагыйрь дусларым Ренат Харис, Равил Фәйзуллин иҗаты белән танышу бу тойгыны тагын да көчәйтте. Җәлилне кеше буларак, якыннан аңларга ярдәм итүче фактлар, детальләр тагын да күбәйде... Әминә ханым Җәлил белән көтмәгәндә генә килеп чыккан бер очрашу исә минем күңелгә онытылмас хатирә сыман кереп калды. Ул мине Җәлилгә тагын да якынайтты.

Муса Мәскәүгә килгәч белемен арттыру белән генә шөгыльләнми. Ул комсомол эшен дә дәвам итә. Комсомол Үзәк Комитеты секретаре Александр Косарев тәкъдиме

буенча Мәскәүдә чыккан «Кечкенә иптәшләр» журналының редакторы итеп билгеләнә. Аннан соң «Октябрь баласы»н җитәкли. «Коммунист» газетасында әдәбият һәм сәнгать бүлеген алып бара. Бу еллар хакында ул үзе болай яза: «Комсомол эшендә чыныгу, тупланган байтак тәҗрибә һәм Мәскәүгә күчеп килү минем өчен зур этәргеч булды, иҗади активлыгымны арттырды».

Шушы сүзләрне раслаучы юллар аның иҗатында да күп. «Җыелышта» дигән шигырендә Муса, мәсәлән, болай яза:

Чын да...
Менә без бит,
  комсомол бит,
Завод гәүдәсенә йөрәк бит!..

Биредә дә шул ук фидакарь җан йөрәге — киләчәктә сугыш кырында дан казаначак каһарман шәхесе.

1938 елда Муса Казанга кайта, Язучылар союзы җитәкчесе итеп сайлана. Яңадан эш, янып яшәү, өзлексез мәшәкать һәм ялкынлы иҗат... Әминә ханым болай искә ала: «Эше күп булганга күрәдер инде — Муса беркайчан да вакытын әрәм итәргә тырышмый иде, урамда да, барган учреждениесендә дә, хәтта кешеләр белән сөйләшкәндә дә җай табып, берничә юл язып куя иде».

Әйе, сугыш алдыннан Муса искиткеч иҗат активлыгы кичерә: аның яңадан-яңа китаплары чыга, ул «Алтынчәч» либреттосын кат-кат эшли...

Менә композитор Нәҗип Җиһанов истәлеге: «Ул бик тыйнак кеше иде. Һәрчак укыды, өйрәнде. Кешеләрдән өйрәнде, тормыштан өйрәнде. Белемен гел арттырып торды. Аны китапханәләрдә һәм концертларда еш күреп була иде. Язучылар союзы җитәкчесе икәнен күрсәтергә бер дә яратмый иде. Ул үзенең асылы белән шуңа туры килә иде. Үзен зур шагыйрь итеп тә күрсәтергә яратмый иде ул. Чөнки ул чынлап та, зур иде».

Шагыйрьләрне аңлау өчен иң мөһим шигырьләр була... Минем уйлавымча, Җәлилнең ике шигыре — «Мин булырмын...» һәм «Кичер, илем!» әнә шундыйлар. Аларның беренчесе бик күп алдан, шагыйрьгә әле 17 генә яшь вакытта, 1923 елда язылган. Яшь шагыйрь әнә шул чагында ук исән калучыларга, тереләргә мөрәҗәгать итә — игътибарлы булыгыз, корбан булганнарны онытмагыз. Үтенечен образлы аңлату өчен шагыйрь бернечә күренеш тасвирлый: «Өзгәләнгән ул юлаучы — мин булырмын!..», «Җан бирүче мәгъсум егет — мин булырмын...», «Әрни-әрни соңгы сүнмәс вөҗдан белән җанын биргән үле гәүдә — мин булырмын».

Кешеләргә ышаныч, оптимизм яңгырый бу юлларда. Авыр корбаннар онытылмаячак. Кешелек батырлыкны онытмаячак.

Җәлилнең атаклы «Кичер, илем!» шигыре турыдан-туры әлеге әсәрне дәвам итә.

Тик бер өмит, дуслар, сезнең сафта
Табар соңгы көрәш теләген.
Яраланган, ләкин тар коллыкка
Баш имәгән керсез йөрәгем.

Герой шәхеснең гомер юлы менә шундый... һәлакәтле, трагик һәм, шул ук вакытта, оптимистик! Шагыйрь үзе дә өмит дип яза, ышаныч турында яза.

Шагыйрә Лариса Васильеваның Җәлил турында мондый юллары бар: «Җәлилнең хәле физик яктан да, рухи яктан да үтә авыр иде. Андый хәлне төрле кеше төрлечә үтә һәм кыен чагында бөтен кеше дә үзе булып кала алмый. Яшәп калу түгел, ә нәкъ менә үз-үзен саклап кала алмый. Җәлил иң авыр вакытта да үзе булып кала алган. Чөнки, минем уйлавымча, аңа шигърият бик булышкан: ул шигъри образ ярдәмендә хыялы белән теләгән җиренә бара алган, теләгән күренешне күз алдына китергән, үткән һәм киләчәк турында җитди уйлана һәм хыяллана алган...»

Л. Васильева шагыйрьнең поэзиясен әнә шулай билгели. Аңа көч бирүче итеп. Чыннан да, күреп белүчеләр әйтүгә караганда да, Җәлил иң соңгы чиккә хәтле язган, иҗат иткән. Күбесенең ирекә чыга алмаячагын белсә дә — барыбер язган, туктамаган!

Моабит төрмәсендә язылган «Җырларым»да без шагыйрьнең йөрәген тоябыз:

Сездә минем бөтен тойгыларым,
Сездә минем керсез яшьләрем.
Сез үлсәгез, мин дә онтылырмын,
Яшәсәгез, мин дә яшәрмен.

Совет кешеләре үзләренең батыр ватандашлары Муса Җәлил исемен бүген зур горурлык белән телгә алалар.

Мәскәү.

Эдуард Касыймов

# ҖИР БАЛКЫШЫ

РОМАН

## 18



Түгәрәк кичә...»

Болай карап торырга яшьләрнең тоташтан уен-җырларга корылган гап-гади кичәсе ул. Ләкин бер хикмәте бар: «түгәрәк кичә» тик солдатларга, аларның да әле армиядән хезмәтләрен тутырып кайтканнары хөрмәтенә уздырыла.

Солдат егетләр шушы кичәдә кабаттан туган җир белән күрешү-очрашу шатлыгын татып, аның бар йолаларын үтәгәч кенә, ягъни кичәнең икенче көнендә генә өсләреннән солдат киемнәрен салып, чөйгә элеп куялар. Тик шуннан соң гына алар, үзләре әйтмешли, «гражданский» тормыш ыгы-зыгысына чумалар. Бергә икән бергә!.. Ә салып куйган погонлы киемнәре инде бүтән киелми, алар җилле яшьлекнең онытылмас истәлеге булып, кием шкафларында саклана. Әҗердә бүген йорт саен диярлек бар андый киемнәр!

Көзен китеп көзен кайткан егетләр «түгәрәк кичә»не гадәттә кышка кергәч үк клубта үткәрә, язын китеп җәен кайтканнар исә Шилнә буена пар тирәк тирәсенә, ягъни табигать кочагына төшә.

Ләкин «түгәрәк кичә»нең мәгънәсен нибары гадәти очрашу-күрешү һәм аның соңында кием алыштыру, ягъни төс-кыяфәт үзгәртүгә генә кайтарып калдыру, аның асылын аңламау булыр иде.

Солдат хезмәтеннән алданрак кайтып төшкән егет аңарчы ил-көн хәл-әхвәлен белешми генә йөрер димени? Юк, әлбәттә! Ул инде туган-тумачасы белән дә, авылдашлары белән дә күрешеп, туйганчы гәп куерткан, ул гынамы, исән-сау кайтуының чиксез куанычы төсендә тиешле мәҗлесне үткәргәндә дә маһирлык күрсәткән була. Ләкин ул үзе белән бергә киткән, тик әле кайтып өлгермәгән иптәшләрен көтә, аларны юксына, алар соңгысына кадәр кайтмый торып, күңеле түгәрәкләнмәячәген белә...

«Түгәрәк кичәнең» иң күрке, аның иң түрендә янар чәчәк булып балкыганы, кичәгә нур өстенә нур булып коелганы — ул вәгъдәләләр тантанасы. Нәкъ менә шушы кичәдә вәгъдәләләр бәйрәм итә дә инде! Алар гадәттә өч-дүрт пар була, кайчагында бер-ике белән генә дә чикләнә. Әмма күпме генә булсалар да, аларны «түгәрәк кичә»ләрнең тоткасы да

---

Ахыры. Башы 1 санда.

җаны белән каны да дип бәяләү һич күпертү булмастыр. Юк, алар, «менә без шундыйлар, менә без ил күзе өстендәге каш», дип лаф ормас, киресенчә, бик тә тыйнак, ыспай һәм ипле кыланыр, хәтта үзләрен күләгәдәрәк калдырырга, «вәгъдә тугрылыгын» әле һаман яшерергә тырышкандай кыланыр. Ләкин кая инде! Бар сагыну-юксынулар, бар шикшөбһәләр, бар борчылу-өзгәләнүләр инде артта калган, күк гөмбәзләренә менеп елмайган кояшлары ул томаннарны инде капыл таратып өлгергән — шундый чакта бергә кушылып дөрләп киткән һәм тышка ургылып торган ялкынының яшереп кара син! Әнә шулай вәгъдәләрен күз карасыдай саклый белеп, бәхетләрен «түгәрәкли» алганнар үзәктә булганга күрә, кичәнең үзенә дә шундый исем бирелгәндер әле.

«Түгәрәк кичә»нең икенче көнендә үк вәгъдәле парларның әле бусы, әле тегесе хакында: «Фәлән солдат белән фәлән кызыйның туйлары озакламас инде», дигән юрау хәбәре тарала. Әйтергә кирәк, мондый хәбәрнең моңа кадәр әле бер генә тапкыр да ялганга чыкканы юк: юраганнары гелән дә юш килеп тора!

Тагын шунысы да бар бит әле: нәкъ менә «түгәрәк кичә»гә аумыйтүнми, абынмый-сөртенми тәгәрәп килә белгәннәр, соңыннан уртак язмышларын тыгыз йомрыга укмаштырып, Әҗер авылының, аның гына да түгел, бөтен тормыш-яшәешнең карап туймас күркенә әверелә дә бит инде. Андыйларга үтәсе үрләр дә ансатрак бирелә, диләр!

Рәмзи моны белмиме, аңламыймы әллә? Бик белә, бик аңлый да кана...

Юк, «түгәрәк кичә»дә аңа вәгъдәлеләр тантанасының куанычынтәмен татып карарга насыйп булмаган икән шул. Ә бит хыялланган иде, өметләре җылы гына түгел, кайнар иде. Әле кайчан гына! Нибары былтыр, юк, нибары узган кыш урталарында...

«Бәхет» дигәннәре дә пар канатлы булырга тиеш, күрәсең. Сыңар канатың каерылган булса, ниләр кыла аласың инде? Тилпенүен дә тилпенерсең, тик очып кына китә алмассың. Вәгъдәлеләргә сокланып та, кызыгып та, хәтта көнләшүдән җир тырмап та йөрүеңне белерсең...

Ләкин егет алай да өметен өзми иде әле.

Менә инде шимбә киче дә килеп җитте, менә инде күңелле уенҗырлары, җыен шуклыклары-мутлыклары белән гөрли-шаулый үтеп тә китте. Әлбәттә, егет солдат дуслары алдында да, кыз-кыркын каршысында да сер бирмәде, матур йола кичәсен артыгын йолкынмыйча, шома гына уздыра белде. «Түгәрәк кичә»дә үз түгәрәгеңнең китек икәнлеген сиздерүдән ни мәгънә?

## 19

Түбәндә сыек караңгыда пар тирәк. Аның артында — Шилнә.

Уен-җырның шашкынын янә бер тыңлады бүген пар тирәк. Инде хәзер изрәп йокыга китүедер. Ә гармун тавышы әнә инде авыл эчендә ерагаеп бара. Шәп өздерә гармунны Рәмзинең авылдашы, солдат дусы Фәнил. Авыл инде төн уртасының татлы йокысына чумган дип тә тормый. Өздертмәскә, вәгъдәлеләр бәхетенә ирешкәннәрнең берсе ләбаса ул!

Рәмзи алар төркеменә ияреп китә алмады. Арткарак кала төште, аннары инде, берәр кирәкле нәрсәсен җуйган кеше сыман, түбән караган хәлдә әкрен генә кире Игәч үренә таба атлады.

Каршы якларында офык читләре тоташтан ут диңгезе булып балкый — КамАЗ һәм Яңа Кала балкышы. Ут диңгезе хәтта чак кына дулкынланып та тора сыман. Һава шулай тирбәлгәләп торганга күрә микән? Югарыга менгән тузан катламнары әле һаман таралып һәм җиргә иңеп бетә алмый. Иртәгә тагын тузан болытлары күтәрелер, берсекөнгә тагын... Берәр көнне, ниһаять, чиге булырмы моның?

Егетнең күз карашы янә түбәнгә, пар тирәккә төбәлде. Әле кайчан гына ул сабантуйның чуар шәлъяулыкларына, аллы-гөлле сөлге-тастымалларына төренеп, көяз һәм купшы кыяфәттә балкып утырган. Әйләнәсендә

халык бөтерелгән, көрәш ярсуы кайнаган. Бүген ул тып-тын. Үзән төштә дымга туенып рәхәтләнеп утыра. Аның тирәсендә гомумән рәхәт, хәтта һавасы ук йомшаграк та, җиләсрәк тә кебек. Тиккә генә яшьләр күңелен гелән дә үз тирәсенә тартып торыр димени пар тирәк?

Ярларына тулып торган, тымызык Шилнә суында ут диңгезенең бер өлеше чагыла — бу исә пар тирәкнең ян-якларга сибелеп киткән җилпәзәле канатлары сыман булып тоела. Сихри бер күренеш.

Авылда Фәнил әле һаман туктый алмыйча гармунын сыздыртуын белә. Бәхетле егет! Юк, ул гына түгел, сөйгән кызын мотоциклына атландырып, әнә теге җемелдәгән утларга кереп югалган Үтәдем Васясы да, арткы якка, караңгыга, әмма озакламый сызылып таң атар тарафка элдерткән Калмаш Зиннуры да аның сыңары. Бәхетлеләр түбәләре белән күкне сөзәр ди! Тансык куеннарга көзгә хәтле үк керергә ниятлиләр. «КамАЗ кызулый», имеш. Әлбәттә, туйларына бармый ярамас.

Якында тоныкк кына булып аяк атлаган, үлән кыштырдаган тавыш ишетелде, һәм менә инде сыек төн караңгысында ыспай гына йөзеп килгән сылу шәүлә, үр кашында басып торган егет янына җиткәч, тукталды, тирән иттереп сулап куйды. Рәмилә иде бу.

— Син, абый, нишләп әле болай япа-ялгыз?.. Тегеләрдән бүленеп...

Кызый моны, әлбәттә, ихтыярсыздан гына сорады. Ул абыйсының хәлен бик белә, бик аңлый иде. Хәер, аның үз хәле дә хәл ич: сөйгән яры әллә кайда, дөнья читләрендә, ә ул монда, вакыты белән ут-ялкыннар эчендә яна, вакыты белән салкын дәрьялар кочагында ага. Ләкин аның ышанычы әле һич какшамаган, өметләре һич тә киселмәгән. Ә абыйсының? Бигрәкләр дә ай-һай шул. Андый чакта бертуган абыеңның пошаманнарын таратмага үз иңнәреңне куймыйча ярыймы соң?

Рәмзи сеңлесе кебек үк киң һәм тирән иттереп сулыш алганнан соң, һич көтмәгәндә бик тә көр тавыш белән әйтә куйды:

— Төн һавасы нинди рәхәт — урамда йөрүләр дә бөтенләй икенче, ә?

— Ие, бөтенләй бүтән...

Югарыдан бик биектән, җете кызыл утын җемелдәтеп, бер самолет үтеп китте. Аңа иярең, Рәмиләнең иреннәре арасыннан ирексездән, ахры, сузынкы пышылдау авазы сытылып чыкты:

— Сабыр төбе — сары ла алтын...

— Нәрсә-ә-әү?

— Юк ла, болай гына. Нишләптер гап-гади бер мәкальне җыр итеп җырлыйсым килеп китте.

Рәмилә, бу минутта, пар тирәккә төбәлгән хәлендә, сөйгәне Женя Мынданы уйлаган иде. Йолдызлар астыннан кызыл күзен йомгалап үткән самолет исә аның уй-тойгыларын ничектер нечкәртеп җибәрде, хәтта тышка ук бәреп чыгарды. Кыз күңеле сизенә иде шул: аның молдаван «мыеккае» чит бер калага командировкага киткән җирендә бу сәгатьләрдә аэропортта үзенә тиешле рейсны көтеп, төн кыскартуда иде. Озакламый алар, әлбәттә, янә очрашачак, кайнар хисләрен янә чәбәләндерәчәк... Рәмиләнең йөрәге, шуны сизгәнгәдер ахры, бу минутта ашкынып-ашкынып тибәргә тотынган иде.

Дөньяда «телепатия» дигәннәре чыннан да бар микән әллә? Һай, юктыр, юктыр ла!

Рәмзи солдат та кич буе, юк, көннәр буе сөйгәне Язиләне уйлаган һәм әле дә аны уйлый иде. Ул аңа һәм бары тик аңа гына — армиядән кайчан һәм ничек кайтасын хәбәр иткән иде бит! Язилә ул чагында Алабугада иде ич әле. Хатны алмый калмагандыр. Ә хәзер кайда икән ул? Кайда булса да, солдат кайткач, авылда матур бер йолага әйләнгән кичә үткәреләсен белә бит. Ичмаса, берәр хәбәр салса икән!

«Түгәрәк кичә» хакында ишетеп әллә кемнәр кайтты, җыелды бит әнә. Инде хәзер төн уртасы. Авылга орынып ук диярлек сузылган асфальт юлдан ут йомрыларын елтыраткан автомобильләр дә бик сирәк тәгәрәп үтә. Шулай да...

Бәлкем Язилә юлга бик нык соңарып чыккандыр да төн уртасына калгандыр? Бәлкем сирәк тәгәрәп килгән әнә шул утларның берсенә утыргандыр яисә утырырга чамалап, тоткарлануыдыр? Ә бәлкем, утырудан өметен өзеп, шома асфальт юлдан яулыгын селкә-селкә, РИЗның үзеннән үк җил-җил җәяүли торгандыр? Әллә каршысына китәргәме? Их, кайдалыгын хәбәр иткән булсачы!

Тегендә авыл эчен гизгән йөгәнсез гармун кинәт хәтәр-хәтәр иттереп сыздырып алды да тынып калды. Мөгаен, инде хәзер аңа, ялганса да, беренче этәчләрнең зыңлы яңгыравык авазлары гына ялганып китәрдер.

— Әнә инде Фәнил дус та арыды бугай.

— Һи, арыды синә! Алар бүтәннәр төркеменнән генә аерылды. Кызын озатканда, гармун акыртып барыр димени акылын җуймаган егет?

Рәмзинең уйлары караңгы авыл эченә кереп киткәндәй булды. Төркем-төркем кереп югалды анда яшьләр. Һәр төркемдә ике-өч кызга дүрт-биш егет! Хәер, күбесенең алай егет диярлекләре юк та әле. Әмма үзләрен җегәрле чын бөркетләрчә тоталар: кызларны канат асларына алганнар да якын килгәннәрне «чүкергә» генә торалар. Ә кызлары бөтенләй яшь, бөтенләй сыек — байтагы нибары Хәтирә яшендәгеләр.

Хәтирә... Тыйнак та, мөлаем дә, сөйкемле дә кызый. Туган авылы туфрагына аяк баскач, Рәмзинең күңеленә менә кем сәер һәм сихри дулкыннар булып үтеп кергән иде. Аңа ул сокланып та, ымсынып та куйган иде. Әмма, бактың исә, сөйкемле нечкәбилең яшь кенә булса да, инде «няле» икән: янында бөтерелгән бөркете бер дә әллә кем түгел, Рәмзинең тыкрык күршесе Фәрит, алдагы көзне армиягә китәсе егет. Бүтән кызыйларның да хәле шулайрак сыман. Тиккә генә өч-дүрт кызны бер өер егет-җилкенчәк озатып йөрер димени?

Кызлар, кызлар... Инде «няле» икәнсез, алдагы көннәрегездә бер-берегезне онытмый-җуймый гына, таркалмый-каерылмый гына «түгәрәк кичә»ләргә шома тәгәрәшеп килсәгез иде сез!

Ә ул инде...

Каршысында офык тутырып балкыган ут диңгезен карашы белән бердән иңләп алды егет. Әйе, нәкъ менә шул ут диңгезе аның бәхет кошын харап итте дә ахры, бүтән ни тагы? КамАЗ диләр, КамАЗ, ә ул аның өчен, бактың исә... Бу хәлләрдә яман көрсенми, ни кыла аласың тагы? Ә бәлкем... бәлкем нәкъ менә шушы утлар уйнаган дөньядан килеп чыгар аның фәрештәсе? Юк, Язилә түгел, бөтенләй бүтәне. Искәрмәстән генә, җилләр уйнатып кына... Утка ут килеп кушылсамы?!

Рәмилә, үр кашындагы сукмакка акрын гына баскалап, кайтыр якка таба атлады. Абыйсы да аңа иярде.

— Үз ирегеңдә йөрү нинди рәхәт, иеме, абый! Рәхмәт инде, бераз соңарсаң да, вакытында кайта белдең. Кичләрен өйдә томаланып ятулардан тәмам гарык булган идем.

— Тәмам укмы?

— Ие. Ә син кайткач, синең белән бергә булганда, өйдәгеләр ләм-мим.

Кызый абыйсын култыклап алды, аңа сыена төште. Тагын да назлана төшебрәк, пышылдады:

— Ә хәзер кайтырга да түнәргә. Онытма, миңа иртән иртүк торып Чаллыга китәсе бит. Айдаш абый белән Вәсим абыйга ияремен дигән идем. Йоклап калырга ярамас.

— Чаллыга? Тагын бер җенләнеп кайтыргамы?

— Җенләнсәм соң... Яшьлек ике киләме әллә?

— Ярар, кайгырма: йоклап калсаң, мотоциклда җил-җил үзем илтеп куярмын. Үземә дә, янә бер дөнья айкап, җилләп кайту зыянга булмас. Мин бит әле иректә. Муенга камыт кимәгән.

— Әле киярсең. Кигезерләр! Тик камытның ниндиен, кайда?

— Ярар, сеңлем, тиккә башыңны катырма, үзем белермен.

Абыйсының аврткан төеренә басты ахры, икесе дә бер мәлгә шым калдылар. Ләкин дәшми-тынмый гына атлавы күңелсез иде, моңсуландыра

иде, Рәмилә күз карашы белән караңгы авыл өстенә төбәлгән килеш, һич көтмәгән җирдән:

— Әсин, абый, беләсеңме микән, бик элгәредә сабантуйларны авылның теге очында, түбән тугайлыкта үткәргәләгәннәр бит. Хәзерге теплица урыннарында,— дип куйды.

— Белмәскә. Минем хәтергә әкияттәгедәй матур булып сеңеп калган ул. Бик бәләкәй чагым булса да...

— Шулай да пар тирәк тирәсендә күңеллерәк, име?

— И-йе, күңеллерәк.

Адымнары ирексездән диярлек әкренәйгәннән-әкренәя барды, һәм менә инде үр кашындагы сукмакта янә тукталып калдылар.

— Әсин, абый, пар тирәкнең ябалдашлары ни өчен кушылганлыгын чамалыйсыңмы?

— Ни өчен? — Моны абыйсы аптыраганнан гына сорады, ахрысы.

— Соң, тамырлары бик тирәнгә китеп, үзара кушылып, чәбәләнеп беткәнгә күрә инде. Ансыз ябалдашлар кушылыр ди сиңа.

Хакыйкатьнең бик тә бәләкәе, кычкырып торганы иде бу, алай да Рәмзи сискәнеп куйды:

— Хикмәт тамырда, димсең...

Игәч үре кашыннан кыйгачланып сузылган тар сукмак белән атлаган чагында, Рәмзи тылсымлы пар тирәк ягына янә каерылып-каерылып карамыйча һич булдыра алмады.



## 20

Инде менә капка төбендәге эскәмиядә япа-ялгызы утыра.

Күк гөмбәзенең көнбатыш ягында эленгән яктылык элпәсе әкренләп көнчыгыш тарафка күчте.

Авылда сихри бер тынлык. Әмма озакламас, таң ныграк беленә башлау белән, бер купканнан соң әлегә тынып-йокымсырап калган әтәчләр өере, дөньяны тизрәк уятырга җыенып һәм монысында тагын да куәтлерәк авазлар чыгарып, янә «җиз быргыларын» уйнатырга тотынырлар. Мәңгелек шөгыльләре.

Уйлар, уйлар... Уйлар диңгезендә һәркем үзенчә дулкыннар куптара, һәркем яр-кыяларга үзенчә чайпалып бәрелә.

Солдатның күз алдыннан пар тирәк китми иде. Куш ябалдаш — кушма тамырлар. Сеңлесенең шул хакта серле бер гыйбарәт иттереп пышылдаганы әле дә колак төбендә эленеп тора сыман. Ә бит, бактың исә, чекрәеп торган гап-гади хакыйкать үзе, ә сере тирәндә.

Моңа өстәлеп, егет күңелендә әтисе әйткән хикмәтле сүз дә җилләр уйнатып ала иде.

Анысымы?

Рәмзи «түгәрәк кичә»гә чыгып китәр алдыннан гына ишетте аны. Алар, өч туган, өч агай-эне, җелекләрне куырырдай эссе мунчада дөбершатыр чабынып чykканнан соң, бераз хәл җыйгач, табын артына утырышканнар иде. Табында әчедәндер, төчедәндер мул нигъмәт тезелеп киткән, бер кырыйда, кайнар бу болыты бөркеп, ак самовар утыра, тик әтиләре генә күренми дә күренми иде.

Ниһаять, бусагадан ул да атлап керде. Кыяфәтенә карыйсың юк: күз аклары белән тешләре генә елтырый.

— И, син дә инде! — дип чәпчергә тотынды әниләре, каш-күз җимереп.— Ичмаса, шимбә көнне малайларың җыелып беткән чагында батып җатмасаң икән дөнҗаңны онытып.

Әтиләре беравык тотлыгып торды:

— Соң ни бит.— Аннары куе төкләр баскан какча ияк-яңакларын сыпырып узды да бер сулыш белән диярлек күкрәгеннән сыгып чыгарды:— Җир рәнҗемәгәе дидем инде.

Абыйларына бу сүз ничек тәэсир иткәндер — алар бер-берсенә сәер иттереп күз генә атып алдылар шикелле — ә Рәмзинең исә йөрәген телемнәргә кискәләп үтте гап-гади гыйбарә!

Әниләре дә, кулларын күкрәк өстенә менгереп, бер мәлгә сулышын тыеп торды, аннары, тавышын капыл гына йомшартып җибәрде:

— Җарый инде, карт, җарый. Җиргә дым дия-дия, үзең элеп киптергәнгә калмагаең дип куркудан гына әйтүем.

Рәмзи «түгәрәк кичә»гә чыгып киткәндә, этисе тәмам арган сеңербуыннарын язып, пакьланып, адәм кыяфәтенә керер өчен, эссе мунчага җыенып калды. Авызыннан ни дәрәҗәдә хикмәтле, ни дәрәҗәдә гыйбрәтле сүз ычкындырганлыгын үзе бар тирәнлеге белән абайладымы икән ул?

«Җир рәнҗемәгәе». Хакыйкатьнең иң олысы һәм иң ачысы түгел микән әле бу?

Шуның төбенә төшмәкче булып уйга бирелүенә, егетнең тыны ук куырылып китә иде. Куырылып китә дә күз алдында әллә ниләр булып җанлана. «Җир рәнҗемәгәе...»

Инде ни кылырга?

Таң алдының йомшак салкыны, ниһаять, аның кителе эченә дә үтеп керде, егет бар гәүдәсе белән калтыранып куйды һәм, тәненә җылы йөгертү өчен, аз гына кымшангалап алды. Бу солдат киеме аның өстендә соңгы төнен үткәреп, азаккы таңын каршылый. Көндезен егет аны кием шкафына абыйларыныкы янына онытылмас бер ядкарь итеп элеп куяр. Аннары инде бүтән кагылмас. Әмма хикмәт кием алыштыруда гынамыни?

Этисенең хәле мөшкел, дөресе, совхоз хәлкәйләре мөшкел: кеше җитми, кеше! Бу кызу җәйдә бигрәк тә. Рәмзи этисе янында өенчекөн дә, кичә дә булды. Вакыты тигәндә басуда торба салучыларга булышты. «Дым, диләр, күктән яумаганда үзебез сиптерик, ансыз азык булмас, азыксыз ни сөте-мае, ни ите өстәлгә менмәс», диләр. Әлбәттә, хак сүз әйтәләр, үз яңгырларын булдырмакчы булып, җиде кат тир түгәләр. Әмма этисенең булышчылары эчтим-печтим генә. Ә көн тәмугтагы шикелле иләмсез кыздыруын белә, су сиптерергә тотынганнар күпме генә эш кыйратып өлгерер икән? Этисе аңа: «Менә син дә, улым, арыслангдай егет башың белән мотоциклда ваҗдырт-выҗдырт каңгырап йөрүләрдән әле һаман бушана алмыйсың»,— дип орынмый әле орынуын, улы килеп чыкса, эреп кенә киткәндәй итә, әмма кай арада аның солдат улына серле һәм сынаулы караш белән төбәлүендә әллә ниләр бар ич!

Бүтән туганнары да — ни этисе белән әнисе, ни абыйлары белән сеңлесе, хәтта Туры бабай булып Туры бабасы — аңа ни кыеклатып, ни турылап бәрелми әле. Мыштым гына көтәләр. «Үзең чамала, иманың кушканны сайла!» — диләр ахры.

Совхоз директоры Таиповка тикле көрешкән чагында: «Эһе, астыөскә актарылган дөньябызга янә бер батыр иңгән ләбаса! Шәп, шәп!»— дип төчеләнүдән артыгын ычкындырмады. Әмма аның да сынаулы күз карашында әллә ниләр чагылып китте шикелле.

Айдаш белән Вәсим абыйсына туган туфрактан кубарылып китүе, мөгаен, җиңелрәк булгандыр. Дөрес, аларга да каршы торучылар, киртә куючылар аз түгел иде шикелле. Ләкин елы-ае бөтен ил буйлап җилләр убырылып искән һәм намусыңны да, вөҗданыңны да үз дулкынында тибрәлдереп алып киткән чаклар иде лә.

Хәзер инде һава аз гына тына, тынычлана төшкән сыман. Атлар юлына алай дуамалланып киртә куючы да күренми. Әмма этисе белән әнисенең, Туры бабасының, совхоз директоры Таиповның, бүтәннәрнең күз карашы, тирән-тирән сулыш алуы... Сынау аша аңа туган авылы ук томырылып карый шикелле. Бары да йөрәген уч төбенә салып күрсәтүен көтә.

Айдаш белән Вәсим абыйсы келәттә йоклый. Үзләре белән будильникны бу юлы да алганнардыр. Юкса, ни пычагыма инде будильник! Барыбер әниләре дуылдатмыйча торып кузгала алмаслар. Аннары инде ишегал-

ларында дөбер-шатыр мотоцикл гөрелтесе кубар. Кубар да авыл читендәге шома юлдан еракларга китеп югалыр. Таң атып, кояш күренүгә, бер алар ишегалдында гынамыни куба андый дөбер-шатыр? Аннары бер Әҗер авылында гынамы?

Рәмзи дә хыялланган иде, армиядә чагында корылып ятучы завод корпусларын әллә нинди хәлләрдә күреп интегеп бетәр иде. Ә соңгы өч-дүрт көнендә ул инде төштә түгел, өнендә завод корпусларын аркылы-буйга айкап чыкты. Җитмеш җиде төрле һөнәрең бар икән, рәхим ит: җитмеш җидесенә дә җегәр салырга җай табылыр. Җир йөзендә һөнәр сөйгән адәмгә мондагыдан да кулайрак урын тагын кайда бар икән? Аерата Чаллының үз төбәгендә яшәүчеләргә мач: күңеленә охшаганны сайлый гына бел!

Мәхәббәттә канаты каерылса да... Тормышта, хезмәттә каерылмаган лабаса! Тирәнгәрәк тамыр гына җибәрәсе...

Рәмзи олы төзелешне гизеп йөрүләренә кичә, ниһаять, йомгак ясап, күңеленә ныгытып куйган иде инде: КамАЗның кою заводына тотыначак ул — йөрергә дә якын, заводы да ни җитте генә түгел. Башта бетон түшәр, аннары, тырыша-тырмаша торгач, бәлкем, монтажчылар югарылыгына да үрмәли алыр.

Ләкин менә монда, туган авылында...

Югарыда күк гөмбәзе инде шактый сыекланып, зәңгәрсу төскә керде һәм йолдызлар төпсез зәңгәрлектә эреп югалды. Инде сызылып таң атып килә. Авыл тынлыгын ярып, этәчләр өере янә купты. Зәһәрдер тавышлары.

Ә ул агач эскәмиядән һаман куба алмый. Ләкин озакламый кузгалыр. Печәнлектә аның алдан ук хәстәрләп куйган урыны бар. Хуш исләр кочагында! Җәйләрен яраткан ятагы!

Әтисе әйтә: таң алдының уйлары хәтәр тыгыз да, хәтәр саф та ди. Бу таңда егет керфеген дә какмас...

Түбә ярыкларыннан сөзелеп төшкән кояш нурларын тояр, ишегалдында абыйлары куптарган дөбер-шатыр колагында чыңлап торыр, аннары үзе дә ятагыннан кубар.

Соңрак туп-туры басуга элдертер. Мотоциклы ызан читендә торып калыр. Үзе исә чишенеп атар да, ялан аяклары белән җир җылысына рәхәтләнеп, торба сузучыларга кушылыр. Басуга үз яңгырларын сиптермәкче булып тир түккәндә, ара-тирә билен яздырырга теләп, сынын турайтыр, әйләнә-тирәсенә күз салыр. Офык читендә куе рәшәгә күмелгән завод корпуслары абайланыр, мондарак исә күз явын яшел кыр-болыннар алыр. Аерата — яшелчә басуы. Яшелчәлектәге аллы-гөлле чәчәкләр — КамАЗ чибәрләре. Күңеле тулып, ихтыярсыздан көлемсерәр: шул матур чәчәкләр арасында аңа дигәне дә нур чәчми микән әле? Мәттин агай юраганы юш килмәсме?

Ә бер мәлне, тын алырга тукталгач, ул ярыйсы гына юан су торбасына утырган хәлдә, бармаклары аша җылы туфракны или-или пышылдап кына әйтер:

— Әти, ичмаса, шушы кырыс җәй үткәнче, мин синең яныңда нитсәм? — дияр. Аннары, тирән сулыш алгач, сорау белән төбәлер: — Гаризаны кем исеменә язасы? Таипов исеменәме?

Әтисенең маңгай җыерчыклары кисәк тирәнәеп һәм ишәеп китәр, какча яңаклары тартышып алыр, тирән сулый-сулый, сөялле салмак кулын аның иңбашына салыр:

— Таипов исеменә, улым.

Көн уртасында яшь солдат белән карт солдат арасында әнә шулай гади генә гәп булып алыр. Һәм бу гәп өелеп торган буаны ерып та җибәрер.

Ләкин аңарчы ярты көн бар әле. Авыр һәм киеренке уйлар алда әле. Нибары ярты, әмма дилбегәдәй озын көн!

Аны атлап үтмичә һич ярамый — солдатның вакыт чаңы суккан иде инде.

Рәмиләнең баш өстендә җил сызгыра. Кузовта ул япа-ялгызы. Тәбәнәк кенә үр кашында сузылып утырган туган авылы Әҗер торган саен ераклаша бара. Игәч түбәсендә ул укыган таш мәктәп. Бу җәйне саргылтяшел төскә буярга керешкәннәр аны. Ерактан бигрәк матур күренә! Үр астында, инеш буендагы киң тугайда купшы ябалдашлы пар тирәк. Сабантуйларда аларга аллы-гөлле сөлге-яулыклар эленә — пар тирәк чәчәк аткандай була. Әле кайчан гына алар әнә шулай бизәнеп, чибәр кыяфәттә балкып утырганнар иде. Тирәндә кушылган тамырлар, югарыда кушылган купшы ябалдашлар. Әлегә сау булып тор, туганкаем пар тирәк!..

Бик еракта, Шилнә авылы ягындагы каен посадкасы буенда, күзгә чак кына эленеп, әфлисун төсендәге трактор озакламый чәчеләсе басуны эшкәртеп йөри. Артыннан, тәмам кибеп, җилләп беткән җирдән тузан болыты күпереп күтәрелә бара. Хәзер кем йөртә икән ул әфлисун тракторны? Авыл артындарак, шулай ук шактый еракта, күккә дугайланып менгән су тасмасы абайлана. Нибары бераү генә. Әмма суны, культуралы көтүлектә дә, яшелчәлектә дә, күп иттереп җиргә торбалар сузып салган көйгә сиптерәләр. Тик болары ерактан күзгә күренми, абайланмый гына. Анда әтисе Хәнәфи, абыйсы Рәмзи, тагын кемнәрдер тир түгә. Әйе, бу эсседә, җиргә дым сеңдергәндә су белән бергә маңгай тирләре дә аз таммый торгандыр. Ә мондарак, инеш яры өстендәге юл буйлап, артына зур арба таккан бер «Беларусь» элдертә. Арбасында туракланган яшь люцерна өеме ахры. Абыйсы Вәсимнән калган «елгыр» түгелме икән? Хәзер кем утыра аңарда?

Рәмиләнең аяклары арасында җыйнак кына, матур гына өр-яңа чемодан. Кавказ тарафларында сатып алынган солдат чемоданы. Югыйсә өйләрендә аңа алырдай юньле-башлы чемодан калмаган да иде. Зур, иске күн букча тирәсендә чуалган Рәмиләгә абыйсы Рәмзи үзе тоттырды аны: «Ал минекен, сеңлем. Солдат чемоданы бәхетле булырга тиеш»,— диде. Шыплап тутырылган чемоданында бер алмашырлык кием-салым, кирәкле кәгазьләре. Нибары икәү алар. Мәктәп секретаре Мәликә апасына бик тә рәхмәт инде: әллә ни карышмады, белешмәне бирде. Ә менә авыл советында... Нигә дип ул хәтле кыланчык икән Иннек Саниясе? Йомры иңбашларын тагы да йомрылап, авызын гына кыйшайтты: «Иң әүвәл Таипов абыең янына кереп, рөхсәт сора, кыйгач кашым! Чаво-то ишәеп киттегез әле сез, сөремлеләр!»— имеш. Директор Таипов янына керергәме? Ул калын кашлары астыннан бер көйдереп карасамы? Тәтенсез янып, көлгә каласыңны бел дә тор! Ләкин Рәмилә төшеп калган кызлардanмы соң? Үзе дә чәтердәп ябышты: «Нишләп керим мин аның янына? Көзен, октябрь аенда миңа инде унҗиде тула. Паспортсыз яшимме? Законны бозарга ни хакыгыз бар?» Иннек Саниясе авыз тирәсен ямьшәйтсә ямьшәйтте, әмма күнмичә булдыра алмады. Ләкин документ юнәтүе ни әле ул? Иң яманы — өйләрендә туган киеренкелекне атлап үтү иде.

Монысында аңа солдат абыйсы Рәмзи ярдәмгә килде. Аның да үз хәле хәл, ул соңгы көннәрдә бөтенләй җитдиләнеп, уйчанланып киткән, әмма ул сеңлесенә теләктәшлек күрсәтеп, тыныч кына:

— Монда, сезнең янда мин үзем калам бит. Алай бик тели икән, бер йөрәген басып, ябагаларын коеп кайтсын булмаса,— диде.

Моңа тагы фатирчылары Людмила Крутько да кушылды. Алар инде үзләренә аерым вагон алуга ирешкән, иртәгә-берсекөнгә инде бөтенләйгә күченеп китәргә тиешләр, әмма, шуңа да карамастан, бу киң күңелле, мөлаем йөзле хатын читтә торып калырга теләмичә, ипле сүзе, йомшак тавышы белән болар гаиләсендә туган киеренке хәлне тәмам йомшартып җибәрде:

— Төзелешкә килсә, без аны үз бригадабызга алырбыз. Мин үзем күз дә, колак та булырмын. Һич тә ким-хур булмас кызыгыз,— диде.

Мондый хәлләрдә әнисе нишләсен, күнсә дә күнде, күнмәсә дә күнде Рәмиләнең китүенә. Әтисенең риза булгандай итүе дә бик ярап куйды. Асылда Рәмилә әтисеннән шүрләп йөргән иде: тагы солдат каешы белән өстәл шапылдатырмы? Кыз бала булгандыр, аңа сугуын сукмый, әмма хәтәр итеп шапылдата! Ләкин бу юлы чөйдә эленеп торган каешына үрелмәде дә. Ишек яңагына сөялеп, сулык-сулык иткән кызына — әнисеннән инде бер баш югары калыккан нәфис үсмеренә озак кына текәлеп карап торды да, һавада бармагын уйната-уйната:

— Кара аны, кызый, җимерек танау белән тупсага кайтып егыласы булсаң, барып та йөрмә! Матур йөз белән, күкрәк киереп кайтырдай булсаң гына капканы атлап чык! — диде.

Һай, җиңел түгел икән шул япь-яшь көе туган йортыннан кубарылып китүләре!

Әнисе: «Кемнәр генә котыртты, кемнәр генә исәрлеккә салды башкаеңны?» — дип теңкәсенә тигән иде. Дөнья үзе — томырылып искән заман җилләре лә!

Ә Женя Мында, аның «мыекбае»? Егетнең күкрәгендә чын ялкын дөрләсә, ирекка чыккан кошын табар, тапмый калмастыр...

Барып төшкәч, әлбәттә, абыйлары Айдаш белән Вәсим янына сыеныр, әгәренки алар: «Әле син шулаймыни? Ташлап киттеңмени әти белән әнине!» дип артык каты ябырылсалар, авылдашы, яшьтәше Шәмси Әминәсен эзләп табар. Ә бәлкем көр күңелле, чая холыклы Людмила апасы аңа тулай торакта тиз генә урын да юнәтә алыр әле. Бер үҗәт баласын үз куенында сыендырмасмыни Чаллы тикле Чаллы!

Сыгылса да сынмас өчен купты лабаса!

Кызның бу көндә, бу сәгатьтә күңелендә нык урнашканы, ап-аныгы бер: кулына кергән иң тәүге хезмәт хакына ук ул һәйбәт куртка сатып алыр да аның шома аркасына эре ак хәрефләр белән кыйгачлатып: «Әҗер авылыннан» дип язып куяр. Ә нигә, төзүче яшьләргә гелән дә зур шәһәр исемнәрен генә язарга димәгәндер ич? Аннары, бер дә бер көнне туган авылына кайтып төшәр дә урам-тыкрыкларны буйлап йөрер. Хәтта чалбар да киеп йөрер! Гарәфша түрә өе турысыннан юри әллә ничә үтәр: күреп бер сөенсен әле үзенең «ата кәҗәсенә»!

Рәмилә, менә шундый уйларга уралып, зәңгәр рәшәгә күмелгән Чаллы каласына килеп керде.

## 22

Бүген иртән Хәнәфи Бариев, улы Рәмзине ияртеп, үз эшенә, сугарулы көтүлеккә килсә, моторист Мөбәрай эшкә чыкмаган иде. Бераз сабыр иттеләр, көттеләр. Ләкин юк, килмәде, күренмәде ир уртасы адәм.

Мөбәрай совхозда уңган механизаторлардан исәпләнә, ул инде үз комбайнын әллә кайчан төзәтеп куйган, аны әзерлек сызыгына бастырган һәм бүтәннәргә булышырга тотынган иде. Ләкин совхоз директоры Яхъя Таипыч аны, уракка төшкәнче болын сугаручыларга ичмаса бер нygытып ярдәм итешерсең дип, болар янына җибәргән иде. Иплe һәм күндәм холыклы, үтә тырыш бу кешенең, кул араларына кереп, һәрчак төпле һәм эшлекле ярдәм күрсәтә белүе мондагыларга, әлбәттә, бик ярап куйды. Бүтән көннәрдә Мөбәрай гадәттә кояш белән үк торып эшенә юнәлә һәм, Хәнәфи белән аның улы Рәмзи сугарулы көтүлектә күренгәнче, ул инде анда тегесен караштырып, бусын рәтләштереп, бигрәк тә буа ярындагы насосны майлап-көйләп куйган була, хезмәттәшләрен исә офык артыннан чыгып килгән кояштай балкып каршы ала торган иде. Ник күренми соң әле ул, ни тоткарлады икән аны бу тып-тыныч иртәдә?

Килмәгән кешене көтеп, көн үткәзеп булмый, әнә инде кояш терсәк буе диярлек күтәрелеп тә өлгергән, ул арада сулышлары каба язып ике-өч яшүсмер егет тә килеп житте — болар, бары бер булып, житез генә эшкә керештеләр. Сугару бөтенләй эләкмәгән кишәрлекләр хәтсез иде

әле. Сузаеп-агарып яткан дюраль торбаларны кичә үк дымга туенып калган өлешләрдән сүтеп-таратып, болынлыкның бөтенләй дым татымаган өлешләренә ташыйсы-күчерәсе дә яңабаштан ялгаштырып-сузып җибәрәсе. Рәтлисен рәтлисе, көйлисен көйлисе. Шактый ук четерекле һәм мәшәкатьле хезмәт. Тегендә иелеп, монда бөгелеп, анысын күтәреп, монысын төшереп әрле-бирле йөри торгач, иртәнге сәгатьтә үк билләрсыннар калмый. Иң ахырда, кишәрлектә бар нәрсә дә тәмам әзерләнеп беткәч һәм кабаттан тикшерелеп чыккач, буа ярына төшеп, андагы насосны эшкә җигәсе...

Менә, ниһаять, бу четерекле эшләр һәммәсе дә артта калды — төп линиягә челтер-челтер су тулды, аңардан ялгаш торбаларга күчте һәм бихисап җайланмалар бары берьюлы диярлек челт тә пелт иткән тавышлар чыгарып, әрле-бирле хәрәкәтләнергә тотынды — шул чакны ярыйсы ук киң кишәрлек тоташ яуган ясалма яңгырга күмелде. Хәнәфи дә, ярдәмчеләре дә һәр иртәдәгечә бары бердәм булып җиңел сулап куйды, кул аркалары белән маңгай тирләрен сыпырып төшерде.

Әмма моның белән генә эш бетмәгән иде әле. Хәнәфи төп линиядән бүленеп киткән аерым торба җепсәсен ачып куйды да читтәрәк, икенче бер кишәрлектә тын гына, моң гына көтеп торган тракторга таба юнәлде. Агай әллә ни озак матавыкланмады, тракторны кабызып һәм аны ары табарак күчереп, икенче бер олы гидрантка тоташтырды да насосны көйләп җибәрде — рәхим ит, әнә инде анда да юан гына су бавы югарыга чөелде дә, һавада чуклы-чачаклы киң тасмага әверелеп һәм дугай-дугай сибелеп-чәчелеп, түбәнгә, җир өстенә, яңгыр булып коела да башлады. Хәнәфи, мондагылар янына кире әйләнеп килгәч, канәгатьләнү аша тамак кыргалап, әмма гадәтенчә саран гына елмаеп:

— Хәзер менә тәмам булды дисәк тә ярый, егетләр! — диде.— Бар тырышканнарыбыз куе, сусыл үләннәр булып үссен дә иң азактан, сөткатык, май-каймак рәвешендә, кемнәрнеңдер өстәленә менеп, тамакларыннан татлы сый булып үтсен, диик!.. Инде хәзер үзегез дә бер иркенләп тамак ялгап алсагыз була, ә мин чәйләп килмичә булдыра алмамдыр ахрысы.

— Бар, эти, бар! Әни сине көтә торгандыр анда,— диде Рәмзи.

— Бүген, Мөбәрай югында, зинһар, улым, уяурак-саграк бул, үзең дә беләсең: буа насосы да, тракторныкы да чыгымлаучанрак.

— Кайгырма, сынатмабыз!— диде Рәмзи, ак тешләрен елтыратып.

— Беренче көнебезмени? Чәеңне тәмләп эч, Хәнәфи абый!— дип елмаешты әле мыек тибәргә дә өлгермәгән яшүсмер егетләр дә.

Алар — Рәмзи үзе дә, бу ерык авызлар да — инде бая ук, нибары плавкилардан гына калып, өсләреннән салып атканнар, ул да түгел, ясалма яңгыр астында инде чыланып та өлгергәннәр, шул сәбәпле аларның янып-көеп кара-кучкылланган таза кулбашларында, тыгыз тәннәрендә елык-ялык кояш нурлары уйный иде.

Хәнәфи аларга бүтән сүз катмады, уң кулы белән биленә таянган килеш, әйләнә-тирәгә, шаулап торган ясалма яңгыр болытына, су сиптерелгән кишәрлекләрдә күпереп күтәрелгән куе-яшел үләннәргә, бер мәл күз йөрткәләп торды. Хозурлык! Күңел куаныч белән тула. Их, җир өсләтә киңрәк, колачлырак, иттереп сузып салырга торбалар җитенкерәми, шуның аркасында инеш насосын бар куәтенә эшләтә дә алмыйлар. Өч-дүрт сәгать сиптереп, бүлеп алынган кишәрлекне дымга тәмам туендыргач, насосны янә туктаталар, торбаларны кабаттан сүтеп-күчереп, кабаттан — инде бүтән кишәрлектә, дымга тилмергәндә — ялгарга һәм көйләргә керешәләр. Иртәнге кояштан алып кичке эңгергә тикле әллә ничә тапкыр шулай. Бүгенгә бүтән әмәлләре юк. Авыр дип чигенергә дә ярамый. Дөньяда гап-гади: «Кирәк!» дигән сүз бар. Шул сүз җигә эшкә, шул сүз өнди адәмне алга табан.

Болынлыкта иртәнге сәгатьтә үк эшне шушылай гаять кызу тотып, байтак тирләр агызгач кына, тамак ягы исләренә төшә. Рәмзи дә, яш-

үсмер егетләр дә коры-сары белән, сөт белән канәгатьләнә. Төшкелеккә исә алар чиратлашып кайтып килләр, әмма яшьләр анда да еш кына авыл ягына кырын карап, үзләренең кыр бакчалары янында, ризыгын-нигъмәтен, уенын-шуклыгын бергә кушып, утырышып кала. Хәнәфи, әлбәттә, үзен алай чикли алмый инде. Үз гомерендә ул туган басу-кырларында, коры-сары белән генә тукланып, бик күп йөрде. Аңа хәзер кайнар аш кирәк — ансыз булмый. Иртәнге чәй аерата кадерле. Хатыны чәйне инде кайнатып куйган була. Ул ике күзен дүрт итеп, иренең кайтуын көтә. Тынып калган өйдә, аулакта алар кара-каршы утырышып чәй эчәләр. Ашыкмыйлар. Тегесе-бусы турында ипле генә гәп куерталар. Кызлары Рәмилә Чаллыга китеп барганнан бирле Рәсүлә үзен кая куярга белми. «Ул гарасатка никләр җибәрдем соң? Аның теге мыекбае да кемдер бит әле, җүнләп белгән жук. Бик җәшләй харап итеп ташламасалар гына җарый инде бердәнбер кызыбызны!»— дип ачыргалана, үкенеп бетә алмый. Иртәнге чәйләре исә күңелләренә кунган яисә кунарга торган ачы юшкын тузанын юа да җибәрә. Рәсүлә үзе әйткәнчә, моның соңында инде ул җаны тәмам тынычлануын, хәтта сөякләре җиңеләюен тойган хәлдә, яшелчәлек бакчасы төбендә торган поход кухнясының казанына су салып, учагын кабызырга дип, җәт-җәт чыгып китә. Ие, иртәнге чәй аның хатыны Рәсүлә өчен икеләтә кирәгрәк.

Хәнәфи кайтыр ягына таба атлады. Авылга тикле ара әллә ни ерак түгел иде: мәнә шушылай үз җаеңа ашыкмыйча гына атлаганда, нибары ун-унбиш минутлык юл үтәсе. Ләкин Хәнәфи, тез тиңентен күтәрелгән куе һәм сусыл үләнне ерып, алай бик ерак китәргә дә өлгермәде, адымнарын әкренәйтә төште: авыл ягыннан болай таба кемдер килә иде. Үзе кыска җиңле ак күлмәктән, башында салам эшләпә. Бәрәч, Мөбәрай лабаса! Ерактан ук авызын ерып килә, атлаулары да кыеш-мыеш кебегрәк. Салмыш түгелме соң бу?

Мөбәрай, килеп житүенә, кулын киң изәп күреште.

— Син нәрсә, Мөбәракша, ни ураза, ни бәйрәм дигәндәй. Кызу эш өстендә, ә?— дип төбәлде аңа Хәнәфи, тавышын шактый коры тотып, әмма тегенең исемен тулы әйтеп.— Ә мин тагы монда... Кичәгенәк ишеткән идем: имеш, «Сельхозтехника»га сугару торбалары кайткан ди, шуны эләктереп калырга Гарәфша үзе барырга ниятләгән ди. Миңа әйтмичә генә, әллә сине дә үзе белән иярткәнме дигән идем бу иртәне. Ә син, бактың исә, әнә кайсылайда...

— Барды ди! Төкерәм мин Гарәфшага! Төкерәм сугару торбаларыгызга!— Мөбәрай буш сүз әйтмәвен расларга теләп ахры, аягы астына төкереп үк куйды.— Китәм мин! Гаризам директор өстәлендә, секретаренә әйтеп калдырдым... ягъни дә бүгеннән башлап дүрт ягым кыйбла!

Хәнәфинең өстенә капыл гына бер чиләк салкын су койгандай булды, гәүдәсе бөрешеп куйды, сулышы буылды, һәм ул җәт кенә Мөбәрайның беләгеннән кысып тотты.

— Шаштыңмы әллә син? Бер кешене кырыкка ярырга торганда... Безнең мондагы эшләргә төкерсәң дә, ике-өч көннән штурвалга басасың бар ич!

— Әнәтерә Гарәфша үзе бассын!— Мөбәрай башын кыегайтып, күзләрен ямьсез чекрәйтеп карады, тавышы кисәк сынып китеп, тотлыга ук башлады.— Ә нишләп ул минем хатын белән малай чабып, киптереп куйган өч чүмәлә печәнне... машинага төяттереп...

Бераздан Хәнәфи аңлап алды: кичә кичке уңайда болар, ат җигеп, Әҗер урманы янына җыеп-өеп куйган печәннәрен алып кайтырга дип менсәләр, аңардан җилләр искән икән. Куак араларыннан, чокыр-чакырлардан мең җәфа белән чабып-җыеп алган ул печәнне — бер Мөбәрайныкын гына түгел, тагын берничәләп кешенекен — Гарәфша машинага төятеп, ферма янына кайтарып аударткан.

— Син әйт әле менә миңа, Хәнәфи абый: шушылай зәһәр корыткан елны совхоз печән-саламнан бирәр күтәрәм өлеш чыгара аламы? Тот капчыгыңны! Үзең дә сыер-сарык асрыйсың, аңларга тиешсең! Ә ул?

— Кемнәр алып кайткан?

— Үзебезнең авыл шоферы тияме соң? Шул Чаллы акайганнары инде, урманга яфрак, ботак-санак ботарларга килүчеләр. Аларга нәрсә: синеке ни, совхозныкы ни.

— Директор беләме?

— Белмәсә, белер. Монда сыер асрыйм, балаларга сөте-катыгы кирәк дип интегеп ятканчы... Әнәтерә Чаллыда мае да, сөте-катыгы да кибет тутырук, ди. Анда аның акчасын да күрәп кенә алалар!

— Җир кешесе бит син! Беткә үч итеп, туныңны утка ташларга булдыңмы?

— Ычкындыр кулны! Төкерәм мин синең туныңа! Бүген гүләйт итәм мин! Җәл, үзебезнең кибеттә җилләр уйный. Өйдәге запас тәк сибә генә иде. Әмма аптырамыйм. Әйдә, син дә төкер дөньясына, Ханәфи абый! Ичмаса, бер иркендә сәйран йөреп кайтырбыз, ә!

Ханәфинең Мөбәрайны тотып торырлык түгел, авызын ачып, аңа сүз әйтерлек тә хәле калмаган иде шикелле. Мөбәрай, алпан-тилпән килеп, кишәрлек кырыйлатып, түбәнгә, инеш буена, анда яр өслатә Илбактыга илтә торган сукмакка таба атлады. Менә инде ул карлыккан, ачы тавыш белән җыр да сузып җибәрде:

Уңга атлап, сулга кит,
Мәскәүләргә барып җит!
Кыз дип алып, хатын булса,
Ат урнына сыер җик! Их ләй!

Ләкин әллә ни ерак китмәде, кисәк чалгы тиеп чабылган рәвештә, түбән чүкте һәм, әйләнә төшеп, җиргә утырды да, башын кочып, тынып калды.

Әле кайчан гына, нибары биш-ун минут элек кенә, Ханәфи өчен дөнья хозур иде, күңеле куаныч белән тулган иде. Хәзер исә күктәге кояш та, җир өстенә яңа сауган сөттәй парланып яуган яңгыр да, кишәрлекләрдәге хәтфә үләннәр дә — бары да соры томан эченә кереп күмелгәндәй булды. Ярсудан җаны ут булып яна башлады. Әнә анда куллары белән башын кочып утырган сәрхуш адәмне, үзләре су сибеп үстергән үлән арасына егып салып, бер туйганчы изәсе, яргалыйсы килде. Юк, Мөбәрайны түгел, аны шушы хәлгә төшергән икенче берәүне, куш иякле, каклаган каздай симез йөзле бүтән бәндәне, уңлы-суллы яңаклыйсы килде. Менә хәзер үк, көне-сәгате белән! Халык алдында! Ләкин Чаллыдан торбалар төяп кайтып төште микән әле ул лагыйнь?

Ә юк, кызмау хәерлерәк. Иң әүвәл чәйләр эчеп, җанны тынычландырырга, акылны җыя төшәргә кирәк. Тик шуннан соң гына берәгәйле иттереп ямыйсы булыр! Сеңерләренә тикле сеңдереп, онытмаслык иттереп!

Хатыны Рәсүлә, әлбәттә, иртәнге чәйне дә кайнатып куйган, аның инде төшкелек өчен, тәмле ис таратып, итле шулпасы да кайнап утыра, әмма ул, алгы бүлмәдә табын әзерләүнең кирәклеген онытып, түр өстәл янында утыра. Алдында ап-ак, чиста кәгазь битләре, кулында авторучка. Ә өстәлнең каршы ягына исә аягоч күршеләре Факыйлэттәй кереп сыенган — бусы, борынын тарта-тарта, яулык очы белән күз төпләрен сөртештергәли иде.

Ханәфи бу ни әкәмәт бу дисә, Фагыйлэттәй йорт-курасын сатарга ниятләп, шул хакта игъланнар яздырту өчен, Рәсүлә янына кергән икән. Ир заты, бу хәлгә хәйран аптырашта калып, ары таба сорашса, сәбәбе һаман да шул бер Гарәфша кылган явызлыктан икән.

— Алла боерса, кантур ишегенә дә элеп куям, авыл советына да ябыштырам, берәрсеннән Чаллы автовокзалына ябыштыруын да үтенәм. Җә инде, жазуыңны бел дим, Рәсүлә җаныкаем! Күрше хакы — алла хакы диләр ләбаса!— дип ялваруын белде Фагыйлэттәй.

— Әнә шул күрше хакы булганга күрә, җаза алмыйм, булмый миннән!— диде Рәсүлә, кулындагы авторучканы өстәлгә куеп, һәм, ярдәм

эзләгәндәй рәвештә, дымлы күзләрен иренә төбәде.

Хәнәфинең сулышы янә куырыла язган иде, ул, бая культуралы көтүлектәге шикелле үк, үз тавышына үзе буылып эндәште:

— Акылыңны җый, исеңә кил, Фагыйләттәй!

Моңа җавапка түти, җиңнәрен сызганып, тамырлары каралып бүселгән ике кулын да Хәнәфигә таба сузды:

— Менә шушы пенсионер кулларым белән чапкан да, җыйган да ием ләса ул ике чүмәлә печәнне! Ә ул мөртәт? Баермы шуның белән савхуз? Кышка ни белән керим мин? Җу-ук, сатам дигәч сатам! Өем белән абзар-кураны да, кәҗә белән сарыкны да! Әнә анда Сталинград төбендә Идел җарында гөрләтеп җәшәп җаткан улым белән киленем әледән-әле: «Җатма анда җапа-җалгызың җәфалар чигеп, кил үзебезнең җанга!» дип чакырып кына торалар. Озакка сузмыйм, кубам булгач, кубам!

— Ул иблис колы Гарәфшаны утлы табага бастырып бер биетәбез әле, печәнең дә кире кайтарылыр, исеңә кил, дим, Фагыйләттәй!

— Искә киләсе җук. Әле рәхмәтләр әйтәм ул мөртәт Гарәфшага: моңа тикле ни вакытлар әйле-шәйле, икеле-микеле булып җөргән ием, маладис, ичмаса, култык астыма кычыткан кыстырса кыстырды, әмма ләкин туган туфрагымнан капыл гына кубарга иттерде!— Фагыйләттәй, яулык очлары белән күз төпләрен янә бер сөртеп алгач, ялварулы караш белән Хәнәфигә текәлде:— Син инде, күршегенәкәем, алай-болай өй-кураларыма ия чыкмаса, аның тәрәзәләрен, ишек-капкаларын кадаклашырга килерсең әле, җәме!

— Уйлама да!— дип кырт кисте Хәнәфи.

Мондый җавап ишетүгә, Фәгыйләттәй утырган җиреннән купты да, бер тын ара әле Хәнәфигә, әле Рәсүләгә күз атып торды, аннары, тавышы сынып куйса да, ачусыз гына, йомшак кына иттереп әйтте:

— Син җазмыйсың, ә син теләмисең. Җарый айсам, бигайбә! Авылыбыз зур, арадан берәр кулай кешене тапмый калмам әле.

Һәм ул, күлмәгенең киң, озын итәген җыя төшеп, үзалдына укына-укына чыгып китте.

— Тәмам җиңеләйгән сыман,— диде Рәсүлә, авыр көрсенеп.

— Җиңеләерсең дә!— дип сыкранды Хәнәфи дә. Аның хәтта тешләре үк шыгырдап куйды кебек.— Бер селтәнүдә ничәмә кешенең бәгыренә хәнҗәр чәнчегән бит ул нәгъләт!

Хәнәфи чәйләп утырырлык хәлдә түгел иде. Күкрәгендә ярсып дөрләгән ялкынны басарга теләп, голт-голт иттереп бер чүмеч салкын су гына эчте.

Машина-трактор утары янындагы складлар тирәсе буп-буш, анда беркем күренми иде. Әле кайтып төшмәделәр микәнни? Әллә торбаларны туп-туры культуралы көтүлеккә илтергә булып, анда бушатып яталармы?

Ә юк, әнә эчкәредә, аулаграк почмакта койма буенда бер машина туктаган. Аның ачып куелган кузовына исә... сугару торбалары урынына нәп-нәзек водопровод торбалары төялгән иде. Шунда ук шофер егет белән Гарәфша да тора: йөкне кая, ничегрәк бушату хакында баш ваталар ахрысы.

Хәнәфи сәлам биреп тә тормастан, тегеңәргә:

— Ни кылып йөргәннәреңне азрак уйлыйсыңмы-юкмы син, Гарәфша? Авылдашларыңа этлек эшләүләрдән берәр кайчан туктый белерсеңме?— дип кадалды.

Гарәфша башын ялт кына болай таба борды, әмма ул кашларын җыерып бер мәл генә торды, симез йөзе җәелеп китте, үзе ашыга-кабалана йомшак-төче тавыш белән сипли дә башлады.

— Ә-ә, син икәнсең әле. Ни бит... сугару торбалары бу юлысында тәтемәде бит безгә. Ярый әле, Минзәләле дуслар очрады. Алар белән тегеләй кыйландырып, болай әйләндереп, менә боларны юнәттем барган унайда. Совхоз өчен әллә ни кирәге дә чыкмас, бәлкем, әмма үзебез

өчен үтергән дә куйган инде! Колонкадан чиләнеп сулар ташыганчы, үз өендә водопровод краны, дим, шаулап утырса, ә! Һе, әлбәттә, үз кеше итеп, сине дә читкә какмабыз!

Гарәфшаның йөз-кыяфәтеннән дә, сүз сөрешеннән дә аларның бу сәфәре төбендә кыек-мыек эшләр ятканлыгын шәйләве әллә ни кыен булмас иде, ләкин бу минутта Хәнәфинең күңелендә торбалар хәсрәте идеме соң?

— Кадалсын ла ул нәрсәләрең!— дип кычкырып куйды Хәнәфи, күзләрендә усал чаткылар чатнатып.— Ни җан белән син авылдашларыңның хәләл көчләр куеп әзерләгән печәнен кичәгенәк ферма янына кайтарып аударттырдың, ә? Ни хакың бар?

— Әһе, әнә ни артыннан йөрисең икән әле син басудагы эшеңне ташлап.— Гарәфшаның авыз тирәсе шундук җыелып, күз алмалары агарып алды — гомумән аның бар йөзе минуты белән кырыс һәм төксе рәвешкә керде. Әнә койма буендагы соры таш ни дә, бу ни. — Хакларым үзем белән — белдеңме? Ә син гәүдәңне сузайтма монда җыен ертлачка терәү булып! Эшләр болай да таркау. Аздырмасыннар халыкны!

— Синең аркада Фагыйләттәй әнә өен сатып китмәкче, э Мөбәрай эшне ташлавы хакында директорга гариза илтеп тоттырган да инде. Ә бит ул алдынгы комбайнчы — озакламый аңа штурвалга басасы!

— Печән кемгә кирәкми?! Ырвачланмасын, иң әүвәл уртак хезмәт хакында уйласын! Комбайнчы, имеш! Кайгырасы юк: әнә Чаллыда дөнья тутырук механизатор — безгә таба юл күрсәтүче тиз табылыр!

Моңа сөйләдең ни, әнә теге бетон баганага аңлаттың ни.

Хәнәфи, бу түң йөрәк белән инде кычкырып сөйләшер тәкате калмаганга, азаккы сүзләрен теш аралый кысып чыгарды:

— Ишетсен колагың, Гарәфша: йомшыйсыңмы-йомшамыйсыңмы, әгәренки авылдашларның күңелен күрә белмәсәң и шулай ук Мөбәрай иртәгә үк эшкә чыкмаса, мин дә тегендә иртәгә үк яңгыр сиптерүләрне туктатам! Минем да гариза директор өстәленә Мөбәрайныкы белән янәшә барып ятачак!

— Өркеттең бик! Куркудан менәтерә мыек чолгыйларым тырпайды! Үзең син киртләп куй: моңарчы, совет власте яшәгәндә, колхозның таркалганы булдымы? И совхоз да таркалмас! Ирек бирмәбез!

Булмаган мыек чолгыйларың ничек кенә тырпаер әле, үзең дә бер тончыкмый калмассың! — Монысын Хәнәфи өенә таба атлый-атлый үз алдына тәкърарлады. Әмма ул кинәт тукталды да, ике уйлап тормастан, кирегә, культуралы болынлыкка таба юл тотты.— Тукта, нишләп иртәгәгә калдырырга соң? Су сиптерүне ник бүген үк туктатмаска ди? Рәмзи белән егетләр аптыраса аптырар. Тик бәгырьне генә Гарәфша кебек үк ныгытып катырасы. Ичмаса, аңларлар бүгенге көндә механизаторларның чын кадерен — Гарәфша да, аны үз канаты астында асраган Яхъя Таипыч үзе дә...

## 23

Түбә кыегыннан тып-тып яңгыр тамчылары тама. Тама да уйларны әллә кайларга алып китә...

Шәп булды әле бу! Рәхмәт инде, әллә ни озак булмаса да, утырыбрак, сеңдеребрәк ява да белде.

Җиргә тансык, җанга тансык. Югыйсә көн урталарына рәхимсез кыздырган кояш эссесеннән җелекләр кибеп, баш миләре кайнар дәрәҗәгә җитә иде. Ачыграк, шәрәрәк төшләрдә җир әллә кайчан яргаланып бетте. Урманнарга тиктомалдан чыгып йөрүләр дә җәй башыннан ук тыелды — Казан радиосы көн туды исә бу хакта кисәтеп кенә тора. Чишмәләр тибәр-типмәс хәлгә килә, инешләр күзгә күренеп саекты, басуларга чыктың исә, игеннәр белән бергә җаның көя... Дөрес, моңарчы да яңгыр, җаннарга җылы бөркеп, үз исен сиздергәләгән, алай гынамы,

бер-ике тапкыр кара-кучкыл болытның күк гөмбәзен иңләп, ишелә-актарыла һәм җир өстен ялт та йолт камчылый-чыбыркылый килгән чаклары да булды, ләкин — ни гаҗәптер — дөньяның яман тузгынуы кысырга булып чыга, җиргә тамчы да яңгыр төшми иде. Күңел кыллары әрнүсыкранулардан, хәвефле пошаманнардан инде соңгы чикләргә җитеп киерелгән иде. Ичмаса, табигатьнең бу куркыныч зәһәрләнүенә кешеләрнең үз тормышында, үзара мөнәсәбәтләрендә, чи ярага тоз булып, төрле читак-чатаклык, ярсу-усаллanулар әледән-әле туып һәм өстәлеп тормаса икән.

Их, чак кына элегрәк, сабантуйларга хәтле, шушылай бер-ике явып киткән булса соң! Ярый, монысына да шөкрана кылып, сөенә бел! Арышка файдасы тимәс инде, аны иртәгә-берсекөннәргә урырга да керешәчәкләр, ә менә сабан иґеннәренә килгәндә исә... тәмам көеп-кибеп беткәнче, боларының дымга сусаулары басыла төшеп, бөртекләре аз булса да тукланыбрак китәр, ичмаса. Ә кукуруз, чөгендер, бигрәк тә бәрәңге ишесенә файдасы ни тиклем? Көзге чәчүгә кадәр тагын шушылай берике явып китсә, табигать үзе дә иркен сулыш алып, рәхәткә чумып ятар, игенченең дә кителгән күңеле тәмам түгәрәкләнә язар иде.

Бариевларның өйалдылары ярыйсы ук киң дә, иркен дә. Аның бер кырыенда җайлы гына сәке бар. Берүзеңә җәелеп, аяк сузып ятардай гына. Хәнәфи бүген менә шунда урнашып алды. Башы йомшак мендәрдә, аста тузгый төшкән түшәк, өстендә иске толып — мондыен йомшак төнне тагын ни кирәк!

Җәйләрен еш кына өйалдына чыгып яткалый ул шулай. Төнге дөньяга колак салган килеш рәхәт тә инде оеп китүләре!

Ә бүген, көндезен ни алҗыган булса да, тиз генә изрәп китә алмый иде. Хәер, турысын әйткәндә, алай оеп китәргә бик үк теләми дә иде. Хәнәфи ни нәрсә уйласа да, күңеленә ни килсә дә, бар уй-хисләре, тора кайтып, хатынының бертуган абыйсы Ризван-агроном белән булган бәхәсле гәпкә ялгана иде.

Һәм ул сөйләшүне дә бер дә әллә ни түгел, нәкъ менә шушы җылы һәм шифалы яңгыр үзе алып килгәндәй булды.

* * *

Хәнәфи, аягына тирән кәвешләр киеп, өстенә кожан элгән килеш, ишегалдында кыштыр-кыштыр яңгыр суларын җыеп йөри иде. Күктән иплe генә явып торганда, мунчадагы олы чапчак белән мич казанын йомшак су белән тутырмыйча ярый димени!

Бер мәлне, келәт ышыгына посып, чиләк-ләгәннәрнең тулуын көтеп торган чагында, бикләре авыр шылтырап капка ачылып китте, һәм ишегалдына калку гәүдәле берәү килеп керде. Тәрәзәдән төшкән яктыга әләгүенә, Хәнәфи аның кемлеген шундук абайлап алды һәм:

— Монда кил, кордый!— дип үзе янына чакырды.

Ризван да өстенә башлыклы плащ киеп алган, аягында резин итекләр. Әллә ни йомышы да юк, кәнсәдән кайтышлый болай хәл белешергә генә сугылуы икән. Агроном кеше, билгеле инде, иң әүвәл шушы яңгыр уңае белән чиксез куанычын белдерде:

— Тели торгач, тәки килде бит, ә! Югыйсә, тәмам янып-көеп бетәсе идек.

Әмма ул бу юнәлештә сүзне әллә ни тирәнгә җибәрмичә, өйдәгеләр хәленә күчте һәм беренче итеп сеңлесе Рәсүлә турында сүз кузгатты.

— Соң, ничек дип... шул инде,— диде Хәнәфи, җилкәсен тартыштыргалап.— Рәмилә Чаллыга китеп барганнан бирле, башын кая куярга белми йөди. Аның бит хәбәрен дә юньлесеннән битәр ямьсезен, хәтта куркынычлысын күбрәк ташып торалар.

— Хәлләр диген.

— Әле ярый, көндезләрен үзенең кыр кухнясы тирәсендә кайнаша,

халык арасында була — бер онытылып торырга җай. Ә кичләрен... әнә телевизорга төртелеп утыра. Ул да булмасамы? Әйдә, керик, хәл-әхвәлен үзең сорашырсың. Берга-бергә чәйләп тә алырбыз.

— Юк-юк, борчымыйк аны, утыра бирсен. Әле бер иркенләбрәк сугылырмын,— диде Ризван һәм монда, ишегалдында гына калырга ныклы ният тә булуын аермачык сиздереп, келәт сайгагына җәелеп утырды.— Әле ярый, Рәмзи үз янызында торып кала белде, егет икән. Ә Вәсимегез теге чакны, хәзер әйтсәм дә ярый инде, китәр алдыннан минем янга да киңәш сорап килгән иде.

— Соң?

— Ни әйтәсең инде аңа? Ак димәдем, кара димәдем, «үз акылың үзеңдә, энем, әмма иң әүвәл йөрәгең кушканны тыңла», дидем.

— Ишкәнсең икән,— диде Хәнәфи теш аралый гына.— Үзең, житмәсә, баш агроном тагы, совхоз тоткаларының берсе.

Мондый төрттерүгә Ризванның тамчы да исе китмәде.

— Үзебезнең егет чакларны искә төшерик, кияү! Егет чакларыбызны!— диде ул киң бер сулыш белән.— КамАЗ куптарган мондый дулкынга син чыдар идеңме, мин чыдар идемме? Аның дулкыны без күргәнбелгән дулкын гынамы... тап «цунами» лабаса!

Хәнәфи кожаны эченнән муенын сузмыйча булдыра алмады:

— «Цунами» дидеңме? Анысы ни тагы?

— Улмы? Океандагы дулкынның иң хәтәре, иң дәһшәтлесе. Су төбендә дә, жир өстендәге шикелле үк, зур-зур тау сыртлары тезелешеп киткән ди, төрле чоңгыллар тагы. Менә шул тау сыртының берәрсе ишелеп төшсә яки анда каты жир тетрәү була калса, цунами дулкыны куба. Галәмәт зур тизлектә океаннар буйлата чабуын белә ди, жир шарын бер генә әйләнеп үтми, ди. Ә инде ярларга килеп бәрелсә, ни барын пыран-заран китереп, җимерә-тузгыта ди. Диңгез ярлары танымаслык булып үзгәрә, ди. Ә болай үзе ерак океан эчендәге кораблар өчен берни түгел, аларны тик тирбәтеп кенә уза, ди...

— Беренче ишетүем. Ә син... ни... КамАЗны шул «цунами» дигән хәтәр дулкынга тиңләмәкчеме?

— Әллә тиңләмәстәйме? Дулкыны бөтен ил күкрәге буйлата тәгәрәп узды, әллә нинди авыл-калаларны кузгатты, ә ябырылып килеп айкалуы-чайкалуы безнең үзебездә ләбаса! Юк, пыран-заран җимерде дә тузгытты димим, киресенчә, дөньябызның, тормышның тамырдан үзгәреп яңарасы җаеннан әйтәм.

Шыбыр-шыбыр яңгыр ява торды, Хәнәфи, келәт кыегы астында муенын киң җилкәсенә батырган килеш, уйга чумып торуында булды.

Менә шул чакны Ризван тел төбендә саклаган иң әһәмиятле сүзен әйтте дә инде — мөгаен, ул шуның өчен генә кергәндер дә әле:

— Ә без синең белән, яшьти, утны да, суны да кичкән бәндәләр. Тамырларыбыз җиргә тирән киткән безнең. Инде алай-болай авабыз, егылабыз икән, шундук баш калкытырга тиешлебез. Калкытырга да, җиңнәрне сызганып, кабаттан маңгай тирләрен агызырга. Кем әйтмешли, җиребезнең җанлы кыялары сыман.

Хәнәфи монысында тагын да озаграк дәшми торды.

— «Җанлы кыялары» димсең?

— Шулай, кияү. Ә син теге чакны, хәтерлисеңдер, кыр-басуларда бүтән йөрер тәкатьләрем калмады, фәлән дип, төгән дип, Таипов кабинетында вай-вай ла шәлберәеп төшкән идең!

— Соң, актык чиккә җитеп җан кыйналулардан ич ул.

— Әллә минем йөрәккә кан саумыймы ул каймактай җирләр өчен? Ярый, син шәлберәйдең, мин шәлберәйдем, ди, бүтәннәр тагы. Совхоз таркалсынмы?

— Әллә кайчангыны кузгатмасана, кордый,— дип шыңшып алды Хәнәфи.— Хәзер үз эземдә бит инде мин: басуда яңгыр яудырам, әллә начармы?

— Һе, яудырасың. Ә бүген иртәнге якта ук, тел әрәм итеп, Гарәфша белән әчеләнешүең? Аңа үч итеп, болынлыкта су сиптерүләрне туктатуың?

— Анысымы? Менә шушы күк яңгырының киләсен алдан ук сиздем мин,— диде Хәнәфи, ачы көлемсерәп.

— Ул да җитмәсә, «үзем дә гариза язам, китәм», дип янауларың?

— Ә ник аза, нишләп рәнҗетә ул халыкны? Бер бүген генәмени? Тукта, әллә син дә шул адәм актыгын яклау ягына авыштыңмы?

— Авышты ди. Аның белән ныгытып сөйләшү булды инде. Каты кисәттек. Печәнне дә үз куллары белән кире өләшер. Әлбәттә, Мөбәрайны да беркая җибәрмәбез, бүтәннәрнең дә күңелен күрү җайларын уйлаштык.

— Ул кисәтүләр күпме тапкырлар инде? Артына тибеп куасы урында.

— Кызмасана! Мин сиңа Гарәфшамыни? Безнең, дим, үзебезнең җанда корт оялмасын, иң әүвәл без үзебез...

Хәнәфи баскан җирендә таптангалап алды:

— Тукта, сабыр, әнә чиләк тулып җиткән икән, мунчага илтеп бушатыйм әле. Җеп очыңны ныгытып төенли тор!

Ләкин Хәнәфи мунчадан әйләнеп килеп, буш чиләк төбенә шалдыршылдыр яңгыр саудырырга тотынуга, Ризван — Хәнәфинең сөенечәнә, инде хәзер Гарәфша исемен бөтенләй телгә дә алмыйча — сүзне һич көтелмәгәнчә яңартты:

— Менә син дә пехотада хезмәт иткән солдат, мин дә пехотада. Сугыш дәһшәтен бердәй күрдек, дигәндәй. Аерма тик шунда: төрле фронтларда булдык та, син бер елга алданрак кайтып төшкәнсең.

— Старшина погоннарына кызыкмаган булсаң, син дә иртәрәк кайтыр идең.

— Кайтуыңа минем сеңелкәшне эләктереп тә өлгергәнсең. Әкәмәт инде!— дип кеткелдәп алды Ризван.— Мин киткәндә, юньләп буй да җиткерә алмаган унбиш тирәләрендәге кызый гына иде. Кайтып төшсәм, бер әзмәвернең куенына кереп, ана булырга, бәби табарга чамалап йөри сеңелкәш.

— Анысын аның ходай үзе хуплаган, хе-хе...

— Аз гына читкәрәк тайпылдык әле, минем әйтер сүзем ул түгел иде,— диде Ризван. Бер мәл тын торгач, капыл җитдирәк тонга күчеп, гәпне янә куертып җибәрде:

— Син, яшьти, пехота солдаты булгач, «марш бросок» дигән нәрсәне шәп беләсең инде, аны бер генә татып карамагансыңдыр.

— Татымаганнар кая! Җаннарың чыгар иде!

— Шулай. Бер җиргә килеп егыласың, инде беттем бугай дисең, тамчы да җегәрең калмаган, сулышың каткан. Әмма шул чакны: «Алга! Атакага! Ватан өчен!» дигән әмер яңгырый. Нишләмәк кирәк? Капыл кубасың да үлле-мәлле чабасың, ятып автоматтан сиптерәсең, торып янә йөгерәсең, «Ур-ра!» дип тә акырасың. Каян килә диген шул чакны җегәр, каян килә гайрәт!

— Хәйраннар инде!

— Сугышта күп булды инде алар. Аннан кайткач та, теге авыр елларны, турысын әйткәндә, «марш бросок» ише нәрсәләр баштан бер генә узмады. Егылып борын канаткан чакларыбыз да булгалады.

— Булгалады, яшерәсе юк.

— Инде менә, яшьти, КамАЗ куптарганы. Монысы, бәлкем, синең белән минем ишеләргә азаккы «марш бросок» булыр. Ниләр, ничекләр килеп чыгасын, дөресен әйтим, мин үзем дә тулаем күз алдына китерә алмыйм, әмма бирешмиек, җебемик, дим. Бүгенгесе көнне үрле-кырлы сикергәләгән яшьләргә кемдер азмы-күпме үрнәк тә күрсәтергә тиештер ич. Хак сөйлимме?

— Хак булмыйча.

Аннары алар капка төбендә дә беравык басып тордылар. Яңгыр инде туктый язган, сирәк-мирәк вак тамчылар гына төшкәли иде. Икесе дә күз карашларын дәшми-тынмый гына еракка, караңгы басу уңаена төбәделәр: анда әллә ни хәтле яктылык көлтәләренең яңгыр томаны эчендә әрле-бирле кармалануы аермачык шәйләнә иде. Әле һаман туфракны каезлый бирәләр, өя бирәләр.

— Икенче җәен бит инде: ни көн сиңа, ни төн. Яңгыр димәсләр, ачы җил, зәһәр чиллә димәсләр. Тап фронттагыча! Тик чын асылы белән генә андагының нәкъ кирәсе!— дип пышылдады Ризван һәм, «яшьти киявенә» тыныч йокы теләп, аның кулын кысты да лыштыр-лаштыр урам караңгысына кереп югалды.

Ә Хәнәфи исә түбә улаклары астында тулып ташыган чиләк-ләгәннәргә кул селтәп, өйалдында үзенә ятак хәстәрләргә керешге. Яңгыр тамчыларының сихерле тамуын мыштым гына тыңлап ятарга.

* * *

Каян сизенгән дә ничекләр керә белгән бу Ризван — әүлия жан. Соңгы араларда үтә пошаманланып торган җанга менә кем белән бер иркенләп сөйләшү кирәк булган икән лә...

Ә «Кара тау»ны тегендә, инде төн уртасы димиләр, җирне изрәтте димиләр, өя бирәләр. Чын-чынлап чиксез куәтледер ахры Ризванның «цунами» дигән хикмәтле нәрсәсе.

Бер-бер артлы әнә шул дәһшәтле «цунами» эченә кереп киткән ике улы белән кызы күз алдына килеп басты: Айдаш, Вәсим һәм Рәмилә.

Яшьләргә ни? Тәртәгә ныгытып тибәләр, тибә белеп тибәләр. Инде хәзер яшьләр генәме соң? Ә өлкәнрәкләр, Мөбәрай кебекләр? Хәнәфи үзе? Йөгән кимәгән, ияр белмәгән яшь ат кебек, ул да кайчагында чыгымчылап куйгалый башлады түгелме соң?

Сирәгәйде, әмма әле һаман тып-тып тамгалый иде төнге тамчылар...

## Икенче өлеш

### I

Кырда эшләр тәгәлләнгән, ашлыклар амбарга кергән, орлыкка дигәне тазартылып һәм калибрланып сорты сортка бүленгән — агроном кеше, әлбәттә, бер иркен сулап куйгандыр.

Сулавын сулагандыр. Әмма совхозда агрономның эше бетәр димени? Авылда хезмәтнең чиге бармыни?

Барыбер соң гына кайтып керә. Кайтып керә дә, тамак ялгап алгач, түр якның түр өстәле янына утырып, китап һәм дәфтәр-кәгазьләргә чума. Кайчагында зур колакларын кысып таянган хәлдә тын гына утыра, кайчагында кыштыр-кыштыр нидер сырларга тотына.

— Улмы? Ни булсын, «Кырлар тарихы»н яза бит ул!— дип аңлатырга тотынды бер мәлне Сабир һәм, Назар белән Габделбәрнең аптыраган кыяфәттә каш җимерүләрен күреп, үзе дә күзләрен шакмакландырды.— Ни нәрсәме? Һи, әллә шуны да белмисезме?

Тегеләр чынлап та белми икән. Андый тарих хакында хәтта ишеткәннәре дә юк икән. Үз авылларында берәр агроном тирәсендә ышкылыбрак йөргән булсалар, әлбәттә, колакларына чалынмый калмас иде.

— Алайса аңлатам. «Кырлар тарихы» теге ни...— Сабир тамагын кыргалап алды: шушындый җаваплы бер чакта, укытучы апалар сыман, тавышны бераз йомшартып җибәрмичә ярыймыни?— Андамы? Анда кайсы кырның ничек эшкәртелгәне, аңа ни чәчелгәне, нинди уңыш җыеп алганнары теркәлә. Шулай ук нинди трактор яисә машина-механизмнар кулланганнары тагы... Дөресме, әти?

Болар өйнең олы ягында киң диванга утырышып пышын-пышын гына сөйләшсә дә, түр өстәл янында үз эшенә чумып утырган Ризван-агроном аларның сүзенә колак шәбәртмичә калмаган иде.

— Бик дөрес, улым! — диде ул, боларга таба бөтен гәүдәсе белән борылып. Җылы гына иттереп елмайды.— Элеккерәк елларда эшләнгән хәтлесен юньле-башлы теркәмичә зур хата җибәргәнбез. Ә бүгенгесе көнне ансыз һич булмый, һич ярамый.

Ризван өстәл өстендәге өем арасыннан журнал сыман калын гына бер нәрсә табып алды да болар янына килде, пружинасын каты шыгырдатып, диванга утырды. Китергән нәрсәсенең катыргы тышына, эре һәм симез хәрефләр белән сырландырып, чыннан да «Кырлар тарихы» дип язылган иде.

— Әүвәлге елларның нәтиҗәсенә карап, алдагы елында ни кыласын чамалыйсың да инде. Сез икегез дә крестьян малайлары, төптән аңларга тиешсез,— диде агроном, журналдагы кырлы-сырлы язмалар өстендә бармак чиерткәләп.— Чәчү әйләнеше икән, ул бары фән кушканча истәисәптә булсын! Шулаймы?

Кай арададыр яннарында пәйда булган Туры карт исә:

— Шушы язганнарына таянып, абзагыз... бүген булмаса, иртәгә совхозга алтын кукәй салып бирмәкче, хе-хе,— дип, тамак төбе белән генә кеткелдәп алды.

— Ярый, көлмичә генә. Салып бирербезме-юкмы, алдагы көн күрсәтер,— диде аңа агроном улы, тавышына сизелерлек дәрәҗәдә коры төсмер биреп.— Ә совхозда хәлләр хәл шул әлегә. Кискен борылыш алдында торабыз, әмма ул борылыш кына түгел, текә сикереш тә булырга тиеш ич!

— Әлбәттә!— дип куәтләп куйды Назар.

Алар, фатирчы ике егет, боларның КамАЗ зонасына кергән совхозында нинди зур үзгәрешләр буласын инде ишеткән, шул уңайдан хәйран калуларын ачык сиздереп телләр-дә чәпелдәткәләгән иде.

— Нибары безнең совхозда миллионнар салынасы, миллионнар китәсе бит! Аны ничек инде тизрәк кайтармыйсың ди, шул хакта ничек инде баш ватмыйсың ди? — Ризван-агроном, күзләрен зур ачып, егетләрнең әле берсенә, әле икенчесенә караш ташлап алгалады.— Сез — авылда үскән егетләр, йөзәрләгән гектарда җәелгән яшелчәчелекне күз алдына әйбәт китерәсез инде. Әмма аны җиренә җиткереп башкарып чыгасы бар бит әле. Мул яшелчә алам дисәң, шәпләп сугарасы бар! Әйтүләре генә ансат шул... Яки, алыйк терлекчелектәге хәтәр дәү комплексны. Бер ябышкач, салынасы нәрсәләр салынмыйча калмас, әлбәттә. Кирәк кадәр нәселле терлеге дә кайтартылыр. Хикмәт анда түгел, хикмәт бүтәндә: каян азык җиткерергә, ни белән туендырырга ул меңләгән мал-туарны? Сөт чишмәсенең башы кайда? Культуралы көтүлекләр, сугарулы болыннар дип бик әйбәт искәртәләр дә искәртүен — монысын да әйтүләре генә җиңел шул. Ие, җиңнәрне сызганып, маңгай тирләрен агызасылар күп әле, чын-чынлап көрәшәселәр алда әле!

Шул арада артлы урындыкка утырып алган Туры карт, чал кашлары астыннан улына сөзеп караган шәйгә, авызын кыйшайтты:

— И улым, ни пычагыма барысы өчен дә нибары сиңа гына ми черетергә, ди? Әле өстә утыручылар бар, яндагылары тагы. Хәзергесе заманда аның исәбен-чутын да җаңгыр урнына җаудырып кына торалар бит.

— Яудырсалар соң. Без үз җаебызны онытмыйк, үз исәбебезне белик! Син, әткәй, үз сүзеңне исеңә төшер әле: чигә тамыры ничек дип, ни дип тибә, ди? «Үз акылың үзеңә якын» дипме?

Бер мәлгә тынып калган өйдә нибары кәгазь кыштырдаган тавыш кына ишетелеп торды. Туры карт, әлбәттә, алай тиз генә чигенүче адәмнәрдән түгел, менә инде аның тамак төбеннән чыккан карлыкканрак тавышы янә ишетелде:

— Шулай инде, адәм баласының бар тырышлыклары дөнҗа көткәндә өстәлендә күпереп торган ипекәй дә, бүтән ризык та булсын дип инде ул. Төптән торып уйлап бактың исә, тарих-бабакай чабатасын үргәндә аны шома гына иттерми, шадра-шадралатып үрә, ди. Әүвәлтен дә, хәзер дә. Жәл, дөнҗа көткәндәгенең, җазмыш-бармыш үзе китереп чыгарганнарның бик күп җаклары менәтерә синең «Кырлар тарихы»ңа кермиенчә кала.

Ризван әтисе ягына күз ату түгел, башын да борып тормады, кулларын кушырып тез капкачы өстенә салды да эре сөякле, таза иңбашларын сизелер-сизелмәс кенә хәрәкәткә китерде:

— Ярар, әти, читкә тайпылдырма, зинһар!

— Тайпылдырсам да... Сәбәпсезме әллә? Менә син, улым, көрәш дип әйтеп әйтәсең, көрәшми булмый дип... Элекке заманнарда әллә көрәшмәгәннәрме?

— Зинһар, дим, күмереңне кабаттан дөрләтмә әле!

Бу хакта ата белән ул арасында сүз-бәхәс бер генә купмаган, әлбәттә. Туры картның, гәп корып, тәмләп сөйләшкән чакларда ике сүзнең берендә «тарих бабакай»га ишарә итүләре тиккә генә түгел ләбаса! Ә бүген, бу сәгатьтә янында, авыз ачкан шәйгә барын да йотарга әзер булып ят шаһитлар утырганда, сүзне нигә тагын бер куертып җибәрмәскә ди? Чыннан да, бу минутларда мари егете Назар гына түгел, хәтта җай чыккан саен туган авылының данын алсу төсләргә манчып таратырга яратучан Вятка егете Габделбәр дә авызына май капкандай, өнсез-тынсыз калган иде.

Ризван исә, мин инде әйтер сүземне әйттем, иләктә калганын үзегез иләп бетерегез дигәндәй, бүтән ләм-мим дәшмичә, утырган җиреннән авыр гына купты да, идән сайгакларын ыңгыраштырып, түрдәге өстәлгә таба атлады. Менә өстәлдәге лампага ут кабызды, менә өстәл янындагы урындык та шыгырдап алды...

— «Җирем» дип, «көнем» дип, кристиән тирен аз түккәнме элекке заманда? Җаны да кыйналган, хәтта, әйтер идем, каны да аз таммаган аның «җир-кыр» дигәнебезгә. Ишетәмсең? Ашлама гына түгел, каны да, дим. Кырлар дәшми, кырлар җавапсыз. Әгәренки, телгә килеп, сөйләп бирсәләр иеме?

— Бик аңлыйм, бик беләм. Соң, анысы аның социаль тарих була, аның үз галимнәре бар — тикшерәләр, кирәк хәтлесен чамалап китапка язалар. Ә миндә бит коры агрономия!

— Ә син алайса коры агроном гына булма, сатсиал агроном да бул! Адәмнәр агрономы да!Ием, үзеңнең агрономия дигәнеңдә дә адәмнәр тир түкмимени, көрәш дигәнең дә адәмнәр җанын айкап-актарып үтмимени? «Кырлар тарихын» ни дип ул тикле кыерсытырга инде, ә? — Бу минутта Туры картның тавышы ук сынып куйды һәм аның сынуында бабайның үпкә-рәнҗү тойгысы аермачык абайланды.—Ием, әгәренки, төптәнрәк уйлап баксаң, үз тирәбездәге авыл исемнәренә орынуыңа ук исен сизәрсең чын тарихның. Хәтта ки исемнәреннән ук!

Улы зур колакларын дәү куллары белән ике яклап кыскан килеш, башын иеп, мыштым гына утыруын белде. Туры карт ахырда, авызын ямьсез кыйшайтып, улы тарафына кул селтәде: алайса, ник кадалып китмисең, янәсе...

## 2

Женя Мынданың Чехословакиягә киткәненә шактый булды инде. Кайтып төшәр вакытлары бик җитте кебек. Ник күренми әле ул? Нигә ичмаса берәр хәбәр салмый, телеграмма сукмый аңа «мыеккае»?

Юк, сөйгән ярың бүгенге заманда артыгы белән булдыклы да, күндәм дә булмасын икән. Завод җитәкчеләре баштарак бик үк абайламаган ахры, әмма, сизеп һәм төшенеп алгач, егетне киң Туган ил буйлата

әле теге тарафка җибәрергә, әле бу тарафка очыртырга тотынмасыннармы! Имештер, ул гади электрик кына түгел, имештер, электроника тикле электрониканың да чын остасы, имештер, бүгенге заманның иң катлаулы, иң нечкә һәм нәзберек техникасының теләсә кайсына егетнең теше үтә. Нәкъ сихерче, имеш!

КамАЗның РИЗ дип аталган беренче карлыгачына, җитмәсә, дөньяда бар булган станок-җиһазларның иң яңасын, иң берәгәйлесен генә туплыйлар ди. Арада бик тә нечкә, бик тә «акыллы» автоматика, хәтта программалы идарә итүгә корылганнары да әллә никадәр буласы, ди.

Юл йөрүләрдән тәмам туеп, Чаллыга кайткан чакларында егет Рәмилә алдында үзенчә акланып:

— Соң, ул хикмәтле станок-җиһазларның бар серенә төшенмичә, һәммәсен энә күзе аша үткәрмичә ничек инде? Аларны бит, күз карасыдай саклап, РИЗга кайтарткач та, үзебезгә үк эшкә җигәсе, эшкә җиккәндә, бүтәннәргә дә өйрәтәсе,— диде.

Рәмилә, әлбәттә, сөйгән егетенең әнә шулай бүгенге заман техникасын һәйбәтләп авызлыклый алуы, аның асыл сихерче булуы белән чын-чынлап горурлана да иде, ләкин бер үк вакытта, инде менә чит илләргә дә җибәргәли башлагач...

Билләһи, чын әгәр, сөйгән ярың зиһен үткенлеге белән дә, уңганлыгыкүндәмлеге ягыннан да кирәгеннән артык ялтырамасын икән шул. Андыйларга замана йөгәннең дә шәбен, тазасын-чыдамлысын кигертерә икән лә!

Килдең дә Чаллыма, елмаеп кердең дә
Салкынны-ялкынны белмәгән күңлемә.
Карашың сихерле, сулышың көйдерә,
Чуалды зиһенем, киләлмим ядемә.

Серемне сөйләми көемне көйлим мин,
Яшьлегем — КамАЗда, нишләргә белмим мин...

Әйе, бу аның үз җыры, үз көе. Гел үзенеке генә! Хәер, чын дөресен әйткәндә, ул аның сүзләрен башлангыч хәлендә бүлмәдәше һәм хезмәттәге терсәктәше Фаягөл дәфтәреннән күчереп алган иде. Фаягөл — Туймазы кызы, эшендә үтә елгырлык күрсәтеп, утлар уйната белсә дә, тормышта болай юаш кына, йомшак кына холыклы җан иясе. Бер кичне ул мыштымбикә Рәмиләгә күңелендәге тирән серне ачып салды: теркәлгән шигырьләрнең байтагын ул үзе уйлап чыгарган икән ич. Рәмиләнең исләре китте. Аннары, акылын җыя төшкәч, бик тә төпле киңәш рәвешендә әйтте аңа:

— Соң, апаем, әдәби берләшмә үзебезнең Чаллыда гына бит! Барып бер укып күрсәтсәң, үсеп-тернәкләнеп китәргә үзеңә дә шифалы яңгыр булыр иде, ичмаса.

Фаягөл аңа әйтеп бетерергә дә ирек бирмичә, болай да зур кара күзләрен тагын да зурайта төшеп, өздереп карады:

— Син нәрсә? Мин бит үзем өчен генә, үземә дип кенә! — Аның соңында үпкәләгән рәвештә дымлы иреннәрен турсайтты да авызына чәч төлгәшен капты: — Шифалы яңгыр, имеш, «Ләйсән», имеш. Бөтен кеше дә анда бара башласа, бетәр димени Чаллыда минем ише исәрләр?

Ләкин «исәр» кызыйның бер шигыре Рәмиләгә бик тә ярап куйды. Әкренләп, Рәмиләнең үз хиссиятенә ияреп һәм буйсынып, шигырьдәге бик күп сүзләр, сүзләр генәме, юллары да бөтенләй бүтән төсмер һәм рух алды. Шашкын җилләр искәндә Кама-Идел дулкынланмый-шауламый тормас ди, озакламый, әллә ничек, үзеннән-үзе генә, җырның көе дә табылды. Шулай икән, яшьлегеңдә тилемсә йөрәгең бер җилкендерсә, бу фани дөньяның шигырь язучысы да, көй чыгаручысы да буласың ла икән!

Их, РИЗ диләр, РИЗны тизрәк корып бетерәсе дә сафка бастырасы иде диләр! Ашыктыралар, кызулыйлар, яналар — мәхшәрнең дә мәхшәре инде!

Ләкин бу дөньяда РИЗның тизрәк корылып, сафка басуын Рәмиләдән дә ныграк теләүче тагын кем бар икән? Бик кирәк, үлеп кирәк аңа бу заводның тизрәк сафка басуы! Ул чагында, ичмаса, сөйгән яры Женя Мында әллә кая җир читләренә китеп, олагып йөрмәс, шул йөрүләре белән аны, әллә нинди шик-шөбһәләргә күммәс иде. Ул чагында егет гел аның янында, аның канаты астында булыр һәм Рәмилә аны үзенең кайнар хисләре белән ничек уратып аласын бик белер иде...

Чит илгә, ят җиргә китәмен дигәндә,
Буылып яшьләргә, тотмадым җиңеңнән.
Киттең дә югалдың. Ничек тә түзәсең
Саф җилләр искәндә үз туган илеңнән?

Серемне сөйләми көемне көйлим мин.
Яшьлегем — КамАЗда, бомба мин, бомба мин!..

«Бомба? Әйе, чынлап торып шартлап куйсаң, ни булыр иде икән? Чаллыңны да, КамАЗларыңны да сагыш сөреме басып алыр иде микән, әллә бары-бары да ялкынга уралыр иде микән? Бер Рәмилә генә түгел, аның кебек йөзләр, меңнәр шулай бер-бер артлы шартларга тотынса? Һай, бу исәр башка нинди генә уйлар керми!»

Авылга кайтты исә, Рәмиләгә әнисе гелән-гелән исенә төшереп: «Берүк!» — ди. Әтисе дә алай ук еш булмаса да: «Ыштубы!» — дип искәртеп куйгалый. «Берүк! Ыштубы!..» Үткен кылыч белән кистереп салгандай рәвештә әйтелгән бу кырыс-кыска сүзләрнең мәгънәсен Рәмилә бик аңлый, бик белә...

Хәер, әтисе белән әнисе әйтмәсә дә, Чаллы кебек мәхшәр купкан җирдә үз кадереңне үзең белеп, итәгеңне җыеп йөрмәскә монда! Әнә шулай төтенсез янган ут йомрысы булып йөрүләре белән ул чын-чынлап бәхетледер дә әле. Үзе дә, сөйгәне Женя Мында да! Икәве бергә!

Ләкин яшь күңел ирекка чыгарга иләсләнми торамыни? Киносына-концертына да барасы килә, «парк» дип аталган яшь наратлык та үзенә тартып кына тора, ә инде кичләрен «пятачок» дип аталган нәрсәдә яшьләрнең очкыннар очыртып биюе-җырлавы күңелне ни дәрәҗәдә җилкендереп торуы хакында әйтәсе дә юк! Ләкин анда-монда чыктың исә, әйләнә-тирәңдә әллә ни хәтле хәтәр ымсынулы күзләр елтыравын шәйләп аласың, бер ишесе килеп бәйләнергә дә күп сорамый. Арада бик тупас, бик әшәке теллеләре дә килеп чыккалый. Андый чакта Рәмиләнең янында, ярый әле, сердәше һәм терсәктәше Фаягөл була. Ике кызый, күк күкрәве шикелле үк дөбердәмәсәләр дә, кырт кискәндә, яшен чаткыларын шәп кенә чатната белә үзе. Ярый әле, кайсыбер вакыт аеруча ябышкакларга киртә булып, әллә каян гына кызыл тасма таккан дружиначылар килеп чыга.

Соңгы вакытларда, шөкер дигәндәй, кызлар халкы күзгә күренеп күбәя, ишәя бара. Бу көзгә кергәч, бигрәк тә Идел буе һәм Урал якларыннан да, Себер булып Себердән дә, тагын әллә кайлардан да, киек казлар шикелле төркем-төркем укмашып, әллә никадәр очып төшкәләде инде. Әле һаман килеп торалар. Әйдә, бик шәп, ишәйсеннәр, ияләшсеннәр дә нygытып тамыр җибәрсеннәр!

КамАЗ корпусларына да, Яңа Каланың үзенә дә, чырай кертеп, нур өстәп торыр өчен, меңәрләгән хатын-кыз кулы кирәк булыр инде. Буяу-бизәү эшләре озакламый хәтсез җәелеп китәчәк, ди. Әмма, чынлап торып уйласаң, мондагы хикмәтле дөньяның тышкы ягы, нибары ялтыравыклысы гына ич әле бу. Тормышның күзгә бик үк ташланып тормаган ягы — җан асрау, гыйшык-мыйшык тоту, ярәшү, гаилә кору дигәне, эчкәредәгесе һәм иң әһәмиятлесе, ансыз һич мөмкин булмаганы бар бит әле аның. Житәкче агайлар яшәешнең шушы хикмәтлерәк ягын да аңнарында асрыйлар икән, асрау гына түгел, изге уй-ниятләрен озакка сузмыйча тормышка ашыра да беләләр икән, аларны хупламый һәм мактамый ни диярсең инде?

Дөньяның үткән җәйдәге шикелле яман эсседән корышып, дымга тилмереп ятуы кемгә тансык, кемгә кызык? Кояшның да кирәгенчә генә балкып торулары, яңгырның да тиешенчә генә явып китүләре хәерленең дә хәерлесе ич! Әйе, дөньяда ир-егетләр белән кызларның да таңгалга-таңгал килеп торуына ни җитә инде! Ичмаса, бер иркенләп сулыш алырлар иде!

Тик бу — әлеге матур теләк, татлы хыял гына шул.

Рәмилә бик еш туган мәктәбен искә ала. Нибары былтыргы хәлен. Аның чын кадерен соңыннан, инде аерылгач кына аңлыйсың икән шул. Һай, күңелле һәм рәхәт чагы булган ла икән! Укуы да әллә ни кыен түгел иде, уку аңа гомумән ничектер җиңел бирелә иде. Укытучылар да бик әйбәтләр, бик үз иделәр. Ә малайларның, дөресе, инде егет булып өлгереп килгән сабакташларының серле һәм көйдерүле күз карашлары, кайчагында әтәчләнеп куюлары яисә, киресенчә, суга төшкән тавыктай бөрешеп калулары, алар белән хат алышулар — гыйшык-мыйшык утын көйрәтергә тырышып кыйланулары? Болары да бик рәхәт һәм бик татлы иде җанга. Әмма анысы әле кызыйның гыйшык өермәсендә бөтерелеп, мәхәббәт ялкынына беткәнче уралып, чын-чынлап яна башлавы булмаган икән, нибары иртәнге йомшак саба җиленең җанын иркәләп һәм назлап сыйпап китүе, нибары күңел кытыклануы гына булган икән...

Инде хәзер? Монда, Чаллыда?

Кичке мәктәптә укуы ифрат авыр. Көндезен ыгы-зыгылы, мең четерекле хезмәттән соң алҗыган гәүдәңне, әлсерәгән җаныңны җәт кенә сафландыра-тазарта бел һәм, зиһенеңне җыя төшеп, ачылдырып җибәр, аннан соң, өлгерә алсаң, дәресләреңне аннан-моннан гына булса да караштыргалагандай ит тә тизрәк мәктәпкә йөгер. Русча укыйсы — шунысы аерата читен. Дөрес, математика, физика кебек фәннәрдән аңа һәрчак булышырга әзер торган «башлы» егетләр берәү түгел, әллә ничәү. Ялынасы да юк, үзләренә ым гына как. Ләкин бу дөньяда бер генә нәрсә дә бушка эшләнми, тиккә генә бирелми ахрысы. «Башлы» егетләр, берсеннән-берсе уздырырга чамалап, кызның күңеленә үк үтеп керергә, аның җанын яулап алырга тырыша иде. Югыйсә, Рәмилә аларга ничә тапкыр инде:

— Күңелем йозакта, ачкычы бүтән берәүдә! — дип бик кырыс төстә кистереп тә куйгалаган иде.

Ләкин тегеләрнең мондый гына кисәтүләргә бер генә дә исләре китми:

— Без теләсә нинди йозакка да ачкыч ярата беләбез, сеңелкәш, һич аптырама! — дип авыз гына ералар иде.

Арада үтә дә ачкүзләнүчеләр, үтә дә әрсезләнүчеләр дә бар иде.

Әллә кичке укуны ташлап, берәр елга тукталып торырга микән? Ичмаса, бу тарафтан күпмедер вакытка җан кыйналулардан котылыр иде.

Ләкин сөйгән яры Женя Мында кызыйның шушындый моң-зарын ишетергә дә теләми, кайтып төшкән һәм назлы-иркәле күрешкән бәхетле сәгатьләрендә ул кыз күңелендә инде пыскый гына башлаган чаткыны минуты белән дөрләтеп җибәрә иде:

— Уйлама да, акыллы акылсызым! Тик торганда бер елны әрәм итәләр димени? Алдагы якты, матур көнебез хакына түзә алмасаң да түз дим! Менә юл йөрүләрдән бераз бизә төшсәм, янында иң ышанычлы таянычың үзем булырмын,— ди.

Бераз тын алырга, азрак җегәр тупларга дип туган авылына кайтса, кызның анда да хәлләре хәл. Яшь күңел өйдә бикләнеп, әти-әнисенең бетмәс үгет-нәсихәтен тыңлап утырулардан инде әллә кайчан туйган, телевизорга төртелеп утырулар да куандырмый, җаны һәрчак ирекккә, дөньяга, яшьләр арасына ашкына. Шимбә, якшәмбе кичләрендә аларның авыл клубы гөжләп тора. Тегеннән, зур төзелештән әллә нихәтле

егет-җилкенчәк кайтып төшкән була. Үз авылдашларына ияреп, әллә ни тикле чит-ятлары да бутала. Тик Рәмиләнең үз ишләре, ягъни кыз-кыркын гына чагыштыргысыз аз күренә. Менә шушы хәл, нәкъ Чаллыдагы шикелле үк, җәфалый да иде кызыйны. Егетләрнең чиксез ымсынып караган күз карашлары, ягылып-тагылып китәргә тырышкан бәйләнчекләр, суырып-йотып алырга әзер булган төрле әрсезләр... нишләп шул хәтле күп икән алар? Ярый әле, кичләрен клуб тирәсендә сыеныбрак йөрергә абыйсы Рәмзи бар. Ләкин гелән дә аның канаты астында ышыкланып тормассың бит, бу мөмкин дә түгел. Рәмзинең дә, егет кешенең, кызлар җәһәтеннән үз хәсрәте хәсрәт ич...

Арада иң елгыры, иң кыюы, дөресе — астыртын үткене һәм шул сәбәпле Рәмилә өчен иң куркынычлысы — Туры бабасы өендә оялап алган квартирант Габделбәр. Вятка егете. Чибәрлеккә болай ярыйсы гына, төз һәм таза гәүдәле. Тик авызы гына зуррак кебек, әллә сөйләшкәндә гелән дә елмайганга күрә шулай тоела микән? Туры бабасын ул әллә кайчан ук инде бөтенләй үз итеп бетергән, тегесе бусын мактап бетерә алмый. Ул да түгел, Габделбәр кай арададыр Рәмиләнең абыйсы Рәмзи белән дә якынаеп, дуслашып өлгергән. Хәер, солдатта булып кайткан ике егетнең дуслашып китүенә алай гаҗәпләнерлек тә түгел үзе. Алар бит, җитмәсә, икесе бер тарафта, бер төбәктә хезмәт иткән икән. Тик берсе, Рәмзи мотопехотада, ә тегесе десантник булган да хезмәтен бер елга алданрак тутырып кайткан. Икәвесе дуслашып киткәч, билгеле инде, Габделбәр алар өенә һич тарсынмыйча бөтенләй үз итеп йөри. Алай гынамы, тегеннән зур төзелештән кайтып төшеп, вакыты тигән чакларында, Туры бабасы йортында гына түгел, боларда да тегенди-мондый эшләрендә катнашып китә, анысын төзәткәләргә, монысын рәтләштерергә керешә иде. Инде хәзер Рәмиләнең әнисе Рәсүлә дә:

— Һич тә иренчәк түгел, тынгысыз! Эш-хезмәт дигәндә куллары гел дә кычытып тора ахрысы бу Вәтке җегетенең! — дип, Габделбәрне мактап, авыз суларын корытырга тотына иде.

Рәмилә бик сизә: әнисе шушындый сокланулы-төрткеле сүзләре белән аңа: «И кызым! Җаныңда әллә ниткән билгесез бер бәндәне асраганчы, күңел күзеңне менә кемгә төбәсәнче, ичмаса!» дип аермачык киная ясый, хәтта киңәш бирә сыман иде.

Гаҗәп хәл: Рәмилә, бүтән ач күз егетләргә кырт та пырт кистереп, аларны үзеннән читләштерә белсә дә, Габделбәргә мөнәсәбәттә исә андый катылык һәм кырыслык кыла алмый: күңеле ничектер туарылып китә, хәтта йомшаклык күрсәтә иде. Әле көзгә кергәндә, үз бакчаларында бер төсле өмә сыман нәрсә оештырып бәрәңге алган чакларында, Рәмилә Вятка егете кузгаткан шуклыкларга кушылып шаярды-көлде, аны тәмам үз итә язып, әллә нишләп бетте. Ә октябрь уртасында Рәмиләнең туган көнендә исә тагын да хикмәтлерәк хәл килеп чыкты. Дөрес, җиңел кулдан гына, үз гаилә кешеләре белән генә үткәрелгән ул кичәгә Габделбәр чакырылмаган иде. Әмма егет, дусты Рәмзидән ишетеп ахры, икенче көннең кичендә Рәмиләне туган көне белән ихлас күңелдән котлап, аңа зур бер бүләк — «Москва» ислемае тоттырды. Рәмиләнең андыйны моңа кадәр хыялында да тотканы юк иде, куанычтан сулышы капты, аннары, кызарынып-бүртенеп, ягъни үтә дә хискә бирелеп, бутала-чуала егеткә рәхмәт сүзләрен әйтте. Егет аның шушындый халәткә төшүеннән үзенчә нәтиҗә ясамагандыр дисеңме?

Әле күптән түгел Габделбәр «Урал» мотоциклы сатып алды. Алар авылында андый, үтә дә шәп җегәрле, иркен әрҗәле мотоцикл нибары милиционер Фәйзрахманда гына бар. Габделбәрнең байтактан хыялланган нәрсәсе икән. Чаллыда исә аның кебек алдынгы эшчегә өлеш чыгару чүпкә дә тормый икән. Шушы уңайдан бабалары Туры карт:

— Шулай инде: туңган туңкаеп калыр, уңган уңаеп узар! — дип егетне янә бер мактап алды.

Габделбәр үзе исә: «Вахта машинасын көтә-көтә кайчакны көтек бу-

лып бетәсең, килми калган вакытлары да аз түгел, инде хәзер транспорт кайгысы онытылыр»,— дигән. Аңа бу шәп мотоцикл һич тә җәл түгел имеш: тели икән хезмәттәше Назар утырып чапсын, тели икән солдат дусты Рәмзи. Сабир-чуерташка исә, ныгытып өйрәнеп китәр өчен, бөтенләй мач.

Бер иртәне Габделбәр әлеге шәп мотоциклының әрҗәсенә утыртып, Рәмиләне дә Чаллыга китереп куйды. Әйтәсе юк, бик җилле, әмма бик тә ыспай алып килде. Мотоциклны ул туп-туры Рәмилә яшәгән тулай торак подъезды каршысында туктатты, һәм менә шунда, кызга әрҗәдән төшәргә булышкач, кинәт бер сулыш белән диярлек әйтә салды:

— Син, Рәмиләкәй, бер генә ым как, мин минуты белән янында булырмын! Турысын әйткәндә, бу мотоциклны да мин синең хакка дип алган идем. Телисең икән, икенче хуҗасы, чын хуҗабикәсе була аласың!

Бу сүзләргә Рәмиләнең исе-өне китте, ул ни дип җавап бирергә белмичә, бер мәл ык-мык итеп торды, ахырда, башын тилегә салындырган рәвештәрәк:

— Акылыңнан язмагансыңдыр ич? Әллә ниләр сөйлисең син! — дип шаркылдап көлеп җибәрде.

Әнә шулай Габделбәр торган саен дәвәеп-зураеп Рәмиләнең күңеленә таба якынлаша бара иде. Әллә аның бу юлына бөтенләй дә киртә торгызып азапланмаска микән? Бер иш кызлар кебек кыланыргамы әллә? Бер иш кызлар шулай бит: берәүгә күзе төшеп, аның белән мәхәббәт көйрәтеп йөргән була, үзе шул ук чакны икенче берәүне, хәтта өченче егетне үзеннән биздерми, запаста тота. Аннары инде, берсеннән уңмаса, икенчесенә барып сыена, инде монысы белән дә эше пешмәсә, өченчесенә барып сылана. Юк, юк, Рәмилә алай итә аламы соң? Ул андыйларга ишмени? Күкрәгендә аның йөрәк гөле бөреләнеп чәчәк аткан икән, ул тик берәүнеке генә булсын, тик берәү өчен генә шау чәчәктә утырсын! Бүтәнчә булмый, бүтәнчә ярамый.

Габделбәр, сүз дә юк, шәп егет, уңган-булган егет, тырышып эзләсәң дә, бәлкем, бер гаебен дә таба алмассыңдыр, аңа әллә кемең дә кызыгырлык, әмма ул егет моннан ары үз күңелендә өмет чаткыларын дөрләтеп йөрмәсен, моннан ары Рәмилә аңа мөнәсәбәттә үтә кырыс, хәтта усал булырга тырышачак! Һичшиксез шулай! Әнә шул күкрәгендәге бердәнбер гөле хакына...

Әйе, үз әйләнә-тирәсендә бөтерелгән егетләрнең берсеннән дә гаеп эзләргә теләми Рәмилә, бәлкем алар барысы да бик әйбәтләр, бик шәпләрдер, ләкин шулай да... кызый соңгы вакытларда читлеккә томаландырылган ялгыз күгәрчен кебек хис итә, күкрәген нидер кыса башлый, җаны бер көйрәп китә, бер өшеп куя. Мондый халәтеннән ул тик сөйгән яры ерак сәфәрдән әйләнеп кайткач һәм аның белән кайнарланып күрешкәч кенә котыла. Ләкин нишләп соң әле ул, аның сөекле молдаван «мыеккае» шуны читтән торып, ерактан торып та эшли алмый? Чехословакия — җәһәннәм арты түгел ләбаса. Нишләп ул, кош теле кадәр генә хат язып булса да, кызны күңелен кысып торган кыршаудан, җанын богаулаган зынҗырдан котылдырырга теләми? Һич югы, телеграмм сукмый? Әллә ниме... карлыгандай күзле кара чәчлекәен инде оныта башлады микән? Юктыр, юктыр, һич алай түгелдер! Түгелдер!

ЗАГС Рәмиләләрнең тулай торагыннан бер-ике йорт аша гына урнашкан. Кызлар ул тирәдән күз акларын алмыйлар диярлек. Анда бит көн саен ничәмә-ничә пар, ничәмә-ничә җан «бергә — гомергә!» дип, йөрәк вәгъдәсенә тамга сала.

Шимбә, якшәмбе көннәрендә урамнардан тузаннар туздырып чабучы туй автомобильләренең исәбенә чыгасың юк. Аларның шома борыннарына атланып һәм тыгыз һава дулкынын ярып, чибәр курчаклар чаба. Автомобильләр аллы-гөлле тасмаларга, купшы чәчәк бәйләмнәренә күмелгән була, өсләрендә, тормыш түгәрәклегенә ишарә рәвешендә төрле төсләрдәге шарлар җилферди.

Бер заман Рәмилә белән Женя Мынданың да шундый көне килеп җитәр әле... Хәзергә йөрәгеңне уч төбендә кысасың да түземеңне беләсең! «Сабыр төбе — сары алтын» диләр бит әнә.

Сары алтын... Бүгенгесе көнне аннан да кадерлерәк һәм кыйммәтлерәктер әле сабырлык, тыйнаклык һәм намус сафлыгы!

Ә бит кайберәүләр шуңа төкереп карый, әмма төкерегенең җилгә каршы икәнлеген, кире үз өстенә төшәсен һич уйламый.

Берәүләр хәтта ЗАГС ишеге төбенә дә барып җитә алмый.

Бүлмәдәше Юля исенә төшә Рәмиләнең. Кыланды кызый, һай, кыланды да инде! Күбәләк сыман бер чәчәктән икенчесенә оча-куна йөри торды, тумбочка өстендәге егет сурәтен атна саен диярлек алмаштыра торды. Ахыры ни? Кереп ятты ул бала тудыру йортына, ләкин тудыру өчен түгел, котылу өчен. Аннарымы? Узган айда күп-күмгәк күз төпләре белән кайтып китте ул үзенең Ока буена йөрәк майларын сыгарга...

Ә күрше тулай торактан икенче берәү? Анысы тудыруын да тудырган, әмма тудыру йортыннан чыккан чагында, бәгырь парәсен язмыш дулкынына ташлап, тизрәк сызган ди Чаллы каласыннан. Баласыз берәр гаилә куангандыр инде куануын, ә үзе? Тора-бара ни уйлар, ни кичерер? Җир ансат кына күтәреп йөртә бит шундыйларны да!

Бригадирлары Людмила Крутько — аны, моннан ике ай чамасы элегрәк бригадалары артык дәвәеп китеп, икегә бүленгәч, кызлар үзләре сайлап куйган иде — менә шул кирәк чагында бик тә таләпчән, бер үк вакытта мөлаем-йомшак та була белүчән Мила апалары әледән-әле искәртеп тора ла үзләренә:

— Эш эшләгәндә, аеруча безнеке кебегендә, сеңелкәйләрем, күңелнең һәрчак бик саф, бик матур булуы кирәк! Йорт-биналарга безнең буяу-бизәүләребез белән бергә зур куанычлар, матур теләкләр дә сеңеп калсын! — ди.

Балалар бакчасы белән яшьләр кафесын бизәгәндә дә шулай дигән иде, монда культура сараена — күчкәч:

— Кеше шушында күңел көрлеге эзләп килер. Монда матур-матур шигырьләр, җырлар яңгырар, хисләр яңарыр. Ә хис яңартучылардан без — иң беренчеләр, зинһар, сынатмыйк инде, гөлкәйләрем! — дип бигрәк тә еш кабатлый.

Шулай бер мәлне ни мыштым Фаягөл ничектер кыюлана төшеп аңардан:

— Ә моңланырга, сагышланырга ярыймы соң? — дип сорады.

Людмила апалары шул чакны кызыйның башын буяулар сеңгән күкрәк турысына ипле генә китереп кысты да көлеп үк җибәрде: — Нишләп ярамасын? Сагышлана-моңлана бир! Тик, чибәркәем, уй-хисләрең ак та булсын, пакь та булсын — нибары шул!

Әнә шундый инде аларның Людмила апалары!

### 3

Актаныш марие Назарның да, Вятка егете Габделбәрнең дә үз туган авылларының тарихы, хәтта аның исеме белән алай тирәнгә чумып кызыксынганнары юк иде. Хәер, дөньяда андыйлар азмыни?

Мәгәр Ризван-агрономның улы Сабир хакында алай дип әйтеп булмый. Ни дисәң дә, әледән-әле «тарих-бабакай» яисә «җазмыш-бармыш» дип искәрткәләп торган, искәртү генә түгел, үткән заманнарның кызыклы һәм гыйбрәтле хәлләрен, хәтер сандыгыннан актарып алып сөйләп килгән Туры бабайның сөекле оныгы ич ул!

Җәйге җылы төннәрдә ак келәткә квартирант дуслары янына кереп кунып калган чакларында, Сабир, билгеле инде, үзе ишеткән-белгән хәтлесеннән төрле «кызыклы әкәмәтләрне» байтак сөйләп биргән иде. Тегеләр аны бик рәхәтләнеп, хәтта йокыларын качырып тыңлаганнар иде. Сабир, кызыклы хәлләрне төенләгән чагында, әлбәттә, авыл исемнәрен

дә читтә калдырмаган һәм моның белән тегеләрнең күңел кылларын әйбәт кенә чирткәләп тә алган иде.

Әйтик менә, аның туган авылы Әҗер. Каян килгән, ничек туган ул? Чын булса, болай: бик күп заманнар әүвәл, имештер, бер иш йомышлы татарга патша хәзрәтләренә күрсәткән хезмәтләре өчен, «Әҗере шул булыр сезгә» дип, Шилнә буеның аулак кына бер почмагын бүлеп биргәннәр. Җире алай дан түгел ди, җитмәсә, җыен әрәмә баскан түмгәклекләр, ди. Нишләсеннәр, әрчергә ябышканнар, аннары инде «Әҗер» булып төпләнеп тә утырганнар. Калмаш авылы исеменә килгәндә дә, шуңа тартымрак хәл. Кама аръягында Бәзәкә дигән зур авыл бар. Шул авылдан берәүләр, һәйбәтрәк, тынычрак җир эзләп, бирге якка чыккан ди бер дә бер заман. Йөриләр ди болар, йөриләр ди, йөри торгач, кара урман эчләрендә зур гына бер аланга тап булганнар. Бу аланга кыр ягыннан кемнәрдер килеп утырган да аны калдырып киткән, имеш. «Калмыш алан» тора-бара Калмашка әверелә дә куя. Ә Үтәдеме? Монысының да атамасы ук кычкырып тора: андагы татарлар патша боерганны, чиркәү кушканны үтәгән, ягъни чукынып, урыс диненә күчкәннәр. Боларга инде җирнең дә берәгәйлесен тоттырганнар, үзләренә, җитмәсә, кәсепчелек итәргә — итек басу, кием-салым тегү, пыяла куеп йөрү кебек эшләр белән шөгыльләнергә дә рөхсәт биргәннәр. Диннәрен алыштырганнарга, шул рәвешле, тормыш итүләре, җан асраулары күп җиңелгә килгән.

Әмма иң кызыклысы — Гәрдәле исеме! Монысын сөйләгәндә Сабир, иреннәрен ялаштырып, тел чәпелдәтүләрдән дә котыла алмады:

— Шулай бервакыт берничәләп татар патша башлаган сугышта зур гайрәт күрсәткән, ди. Боларга да шуның өчен бүләк иттереп, җир бүлеп биргәннәр, ди. Каян булсын? Безнең Шилнә буеннан инде. Шуннан бу татарлардан берәү юл буйлап барганда, урыс белешен очраткан, ди. Сораган ди, урыс: «Я, князь-туганкай, хәлләр ничек? Җир бирделәрме?» — дигән ди. «Хәлләр хәл әле, знакум. Гара дали, гара!» — дип әйткән бу. Боларга шәрә тау битләрен тоттырганнар икән. Чабаталы татарның әнә шулай дип әйтүе боларның авылына ябышкан да калган бик әйбәтләп кенә. Аннары инде, тора-бара моның «Гара дали» дигәне әкертенләп «Гәрдәлегә» әверелгән дә куйган.

Ә менә Чуар авылына җиткәч, Сабир төртелде дә калды. Монысы хакында аның әлегә кадәр берни дә ишеткәне юк иде. Ә болай бик кызык исем бит! Тик каян килгән, нидән туган икән ул?

Хәзер исә сорашырга-белешергә бик әйбәт җае чыкты кебек: ник дигәндә, әтисе Ризван белән маңгайга-маңгай бәрелешеп, бәхәс куерткanda, бабасы үзе үк: «Авыл исемнәренә генә орынып кара, тарихның чын исен шундук сизәрсең» — дигән сүзне әллә ничә ычкындырды бит. Шушындый форсатны кулдан җибәрергә ярыймыни?

Алар өйнең алгы өлешенә чыгып, кайсы кая утырышып алган иде. Морҗада басынкы гына җил сызгыра, ә тәрәзә өлгеләрен кырпак бозлы вак яңгыр четердәтә иде. Бу исә күңелдә пошаманлы, моңсу уй-хисләрне кузгата иде.

Ләкин Туры карт, тышкы кыяфәтенә караганда бик тыныч кебек күренсә дә, телен язып җибәрергә ашыкмады. Чал кашларын җыера төшеп, оныгы Сабирга, ике фатирчы егеткә берәм-берәм күз йөртеп алды. Гомер сөрмешнең кызыклы һәм гыйбрәтле хәлләрен сөйләгәндә дә тиешле шарты һәм җае кирәк, төрле гыйбрәтләрне тирәнгә сеңдерердәй җаннар булуы кирәк шул. Фатирчы егетләрнең Туры карт өеннән бөтенләйгә чыгып китәренә дә әллә ни күп калмагандыр инде: тулай торакка чиратлары әкренләп булса да алга таба үрмәли ди. Инде тәмам ияләшкәннәр иде — сагындырырлар. Хәер, үзләре дә монда яшәгән көннәрен,— менә болай кич утыруларны исләренә төшерми калмаслардыр әле. Әнә җирән сакалбай Назарның туган авылы, туган болын-кырлары бөтенләйгә, тулаем су астына күмелеп юкка чыгачак, ди. Кая барсын кеше? Үзенә юл

ярып, бәхет эзләп килгән. Олы төзелештә завод һәм кала җирен үзенчә бизәмәкче, шунда инде бер уңайдан, әлбәттә, үз язмышын да яңартмакчы. Шөн егете Габделбәр, әйтик, шушында, мәхшәр купкан җирдә, үзенә түл җыеп, төпле һөнәр иясе булмакчы, төрле эшләргә болай да оста куларын тагын да шомартып җибәрмәкче, аннары инде, гөрләтеп яшәгән туган авылына кайтып, аны тагын да ямьләндереп җибәрмәкче. Җәл, андыйлар сирәгрәк очрый шул бүгенгесе көнне. Нәкъ менә шуңа күрә, туган туфрагын тагын да баетып җибәрергә ниятләве, җитмәсә, сирәкләрдән булуы белән ул Туры картның күңеленә чагыштыргысыз якын иде. Ә бит тора-бара бу асыл егетнең алар белән бөтенләй якынаеп, хәтта туганлашып ук китүе дә бик ихтимал ич. Теге кызый — аларның бердәнбер чибәр чәчлекәйләре генә тырт та пырт кыландырмаса инде... Хәер, бик кыландыра алмас, киртә буе сикерсә сикерер, әмма беркая да китә алмас! Егет бер дә җебеп йөрми кебек. Туры карт бик әйбәт сизенә: егетнең шәп әрҗәле менә дигән мотоцикл алып җибәрүе бер генә дә тиккә түгел — бар аның хикмәте! Аннары егетнең соңгы вакытларда артык уйчанланып йөрүләре, бар йөз-кыяфәте белән тартыла төшүләре тиккә генәдерме?

Әнә ул алгы өйнең олы миче төбенә аяк бөкләп утырган да зур күзләрен мөлдерәмә тутырып, аңа төбәлгән. Туры бабасының авызыннан әкияттәгедәй берәр асыл кошның пырхылдап очып чыгуын көтә сыман.

— Чуар турында дидек бит инде. Ни дип уйга баттың әле, бабай? Сабирның түземе җитәме соң?

— Кһем... Чуар димсез... Чуар? Соң, үзләре дә чуар, хәлкәйләре дә чуар ие шул аларның. Нигәме?

Туры бабай сыңар кулын өстәлгә сузып салды да кәкре бармакларын кыймылдата-кыймылдата янә бер мәл тын торды, аннары, маңгай җыерчыкларын ишәйтеп, сөйләр сүзенең исенә килгән хәтлесен ашыкмыйча, иппе генә төенләргә керешге:

— Җаман нуҗадан котылып булмасмы дип, алар килеп утырган Минзәлә җагыннан, кырдан. Сәет, Күгәш, аннары килеп, Сәмәкәй дигән авыллардан ахрысы. Урман-куак арасыннан җир әрчергә җабышканнар, төпләнә башлаганнар әкертенләп. Әмма ләкин, әйткәнемчә, үзләре дә чуар, хәлкәйләре дә чуар ие: боларга җирнең күпмедер өлешен Гәрдәле басуыннан да кисеп биргәннәр икән. Шуннан ни? Чуарлар көндезен бура бурый ди, ә гәрдәлеләр төннәрен барып сүтә ди. Җыларсың да, көләрсең дә. Ә ике арадагы межада тәпәләшүләр? Сансыз инде, сансыз. Хәер, безнең үз авылыбыз Әҗердә соң? Җир бүлгәндәге ызгыш-талашлар, хәтта ки кан коешлар? Җәки шундый хәл: үзегез дә күреп торасыз, Шилнә җылгасы безнең авылга орынып ук ага. Буеннан-буена. Ә патша заманында ничек ие? Җылганың теге җак җарыннан ук бүтән авыл җирләре башлана. Урыс җирләре. Шунын аркасында купкан низаггаугаларны исәпләп китсәңме? Әйтик, безнең авыл казлары җылгада җөзгәндә арҗак җарга мендеме, тегеләр куалап алып китә, ә инде тегеләрнең дуңгызы алай-болай безнең җиргә керә калса, бөтен Әҗер куба, күсәк-сәнәк күтәреп чабалар: «Нәҗес кергән, җиребезне харап итә лә!» — дип... Икмәктер, оланнар! Сез җылмаясыз, ә теге заманнарда җәш коешлы ие. Ни дип авыл белән авылны үзара ул тикле җарсытырга кирәк булгандыр инде? Хәзер менә, оланнар, акылга да сыймый, ә теге чакны көнкүрмешнең, җәшәмәкнең фигыле шул рәвешләйрәк ие шул. Безнең тирәдә авыл халкы усал булмый нишләсен?

— Ә сезнең якларда читкә китеп йөрүләр булмаганмыни? Шахта җиренә яки алтын эзләмәгә? — дип төбәлде Габделбәр.

— Алай җыракка китүләр... жук, белмим, булмагандыр. Ә менә Кама арҗагында утырган Бондюг заводына баргалар ие. Кышларын ат җигеп, завод хуҗасына кирәк-җаракны ташымага. Бер кышны, җегет булып килгәндә, мин үзем дә шунда эшләп уздырган ием.

— Ә безнең авылда бик күпләр киткән шахтыга. Әле дә өй саен диярлек шахты лампысын табып була. Шуңа күрә бездә колхоз оешкач та

аңа «Кызыл шахтер» дип исем кушканнар. Шахты җирләрендә әле дә безнекеләр әллә ни хәтле. Аннары, алтын эзләүчеләр дә булгалаган. Урал белән Себернең җәһәннәм тишекләрен айкап кайтучылар. Җыен зимагур тагы. Шулай бервакыт бер йолкышы, өстерәлеп кайта торгач, Вятка ярына килеп җиткән дә бугазын ертып акырырга ябышкан: «Лудкы давай, лудкы давай!»— дип. Көймәче агай берзаман, суны аркылы кистереп килеп җиткән. Кичәләр икән ипле генә. Шул чагында бу зимагур мактанырга ябышкан: «Галәмәт баеп кайтам бит әле, бәхетләр басты, якташ, ходага рәхмәт!»— дип әйтә, ди. «Ышанмасаң, менә!»— дип әйтә, ди. Шуннан, ыштыры эченә чабата киндерәсе белән нygытып бәйләп куйган янчыгын алып күрсәтә бу. «Менә, ди, алла боерса, агач мәчетне сүттереп, таш мәчетләр салдырам әле — дөньяда бер шаулап алсын әле безнең Түбән Шөннәр! — ди. Син минем кыяфәткә, минем сәләмәләргә карама, җыен алтын белән якут кына булыр бу янчыкта, билләһи!»— ди. Шулай мактанып-селтәнгәләп барган чагында, моның янчыгы кулыннан ычкынып китә дә суга-чулт! Тап идел уртасында!

— Күр син җебегәнне! — дип шыңшыды Туры карт.— Тәки тәкилэй батырган, ә?

— Батырган. Шуннан ябыша бу, мин сиңа әйтим, акырырга-бакырырга, күз яшьләрен түгәргә. Үзе суга сикермәкче була ди, көймәче агай көчкә тотып кала. «Соң сиңа түләргә сукыр бер тиенем дә юк бит, бар байлыгым шул янчыкта иде!»— ди бу.

Өстәл почмагында борын мышкылдатып утырган Сабир пырхылдап көлеп җибәрде:

— Аның янчыгында алтын белән якут булмаган дадыр әле!

— Менә анысын инде Вятка иделе генә белә!

— Ә бездә җук, андыен кәмитләр алай бик ишетелмәс ие,— диде Туры карт.— Булмый тормас ие төрле хикмәтле хәлләр, тик хикмәтләрнең дә һай ачысы, һай канлысы! Бай бай инде ул — җанын шайтанга саткан бәндә. Әмма ләкин җавызның да җавызы Калмаш баяры булгандыр бу фани дөнҗада.— Бабай авыр иттереп сулап куйды, аның йөзе бөтенләй караңгыланып, чал кашларына тикле кушыла язды.— Урманында чабатага җүкә каезлаганда тотса, үзеңнең җиде кат тиреңне каезлар — син дә адәм баласы бит димәс. Авылыңнан өч ат аның басуына керсә, берсен тотып калыр. Җавызлыкның чиге бармыни? Авыл кешесе дигәч тә, мескен-бичара дигәч тә... Болар да усаллык күрсәтә белгәннәр үзе! Электә дә баяр җирен басып алулар, байлыгын талаулар булмый тормаган. Мин бәләкәй чакта безнең Әҗер белән Гәрдәле дә купты. Шул фетнә башлангачмы, әллә шуны бастыргачмы, патшаның манифесты чыкты да бугай. Анык кына әйтә алмаем. Бер заман авылга килеп тулды кылычлы, мылтыклы солдат, солдат. Прәме мәхшәрнең үзе инде! Туктагыз, оланнар, аның бәете дә бар, бәете дә...

Туры карт, кәкре бармакларына текәлгән килеш, бер мәл тын гына утырды, ниһаять, бәетнең очын хәтеренә китерде булса кирәк, чал башын күтәрә төште, һәм менә инде аның кысык иреннәре арасыннан, морҗадагы җил улавына кушылган рәвештә, өзек-төтек кенә көй сөзелеп чыга башлады:

Әҗер җире әвенле,
Гәрдәледә җалан тау,
Зилзиләләп котырды
Җалмавыздыйн җаман җау.

Шилнә суы нидән болганыр?
Дөнҗа көтүләре һай авыр!..

Бабасына ияреп, Сабир да иреннәрен тибрәндерә: бәетнең ишеткән хәтлесен күңеленә тирәнрәк сеңдерергә тырыша иде ахрысы. Ә Туры карт исә, тын алырга тукталган мәлендә, теге замандагы яман хәлләргә аңлатма бирергә дә онытмый иде:

— Соңга таба, герман сугышы барганда, Калмаш баярлары җомшый

төшкән дип сөйләрләр ие. Сизенгәннәр, ахрысы. Алты семья ие алар. Калмаш тавы битендә ие утарлары. Шәп утарлар! Октябрьдән соң көл иттеләр. Халык ачуын бер җомшару белән генә басып буламыни? Сәвитне җаклап безнең тирә авыллар күкрәген куйган икән, тиккә генәме әллә? Көрәш тамырлары ай-һай ла җыракларда, ай-һай ла тирәндә!

Баяр аты тимер күк,
Чабар җире бигрәк күп.
Кибән-кибән игеннәр —
Көле калды күптин-күп!

Шилнә суларында тегермән,
Авызым тулы каннар... төкермәм!

— Дөнҗада бер генә нәмә дә тиктән генә булмый, көрәшсез генә бирелми. Адәмнәрнең тире дә, каны да һай күп тамган шул туган җиркәебезгә! Кыр-басулар сөйләп кенә бирә алмый. Җу-ук, КамАЗ дигән баһадирыгыз бер генә дә коры-буш җирләрдә корылмый шул, оланнар!

Көзге ачы җил морҗада улый, боз катыш яңгыр тәрәзә өлгеләрен зеңгердәтә.

Түр өйнең түр өстәле янында берәү китап-дәфтәрләргә чумып утыра. Совхозның алдагы язмышын кайгыртып, киләчәккә ышанычлы юллар эзләп.

Ә монда, алгы өйдә? Хәер, Туры картның кипшергән иреннәре арасыннан агылган моң-сагыш та бүгенге, иртәгәге көннәрнең сафлыгы һәм тазалыгы хакына куертыла түгелме соң?

## 4

Вахта автобусыннан төшеп, аскы урам белән беркадәр баргач, Туры карт йортына якынлашып килгән чагында, Габделбәр янәшә атлаган мари дустын кинәт кенә туктатты да:

— Әллә дим, Назар, бу юлы да тулай торакка чират җиткәнлеген әйтми калабызмы? Чиратны тагын бераз вакытка чигендереп торабызмы? — дип текәлде.

Кичке эңгер инде тәмам куерып беткән, тик караңгыда да Назарның күз аклары елтырап алгандай булды, йонлач бүреген баш артына шудырып җибәреп, бияләйле кулы белән сакалына ябышты:

— Син нәрсә, Рәмилә дия-дия, инде бөтенләй тегеләйгә әверелдеңме әллә? Моннан бер ай чамасы элгәре үз чиратыбызны бер бирдек бит инде, шул җитмәгәнме?

— Ләкин без чиратыбызны үзебезгә караганда күп нужалыракларга биргән идек бит, андыйлар бригадада әле тагын да бар. Ә без монда, шөкер, җылыда, рәхәттә, сые-хөрмәте дә муеннан...

— Һе, без икебез өчен генә вахта автобусы куарлармы? Кайтканда үзең күрдең ич: бу авылда торып эшләүчеләр нибарысы унлап-уникеләп кенә калган ич инде. Шушы атна азагына аларның һәммәсе дә, кайсы тулай торакка оялап, кайсы вакытлы поселокларга китеп, тәмам таралып бетәчәк бит. Кайтканда сөйләшкәннәре колагыңа эленмәдемени?

— Эленде. Әмма безнең монда, әнә теге капка артындагы ишегалдында, үзебезнең корыч айгыр бар лабаса! — диде Габделбәр, якындагы йортка таба кулын киң изәп.— Вахта көтеп, ми катырганчы, минуты белән утыр да чап, рәхәтлән!

— Әллә ни кадәр араны ачы суыкта, зәһәр җилләрдә ыжгырттырып бару-кайтулары әкәмәт тә рәхәт инде! Тукта, соң син ул корыч айгырыңны Кама белән Вяткада бозлар катып, юлларны көрт басканчы, туган авылыңа кайтарып куймакчы идең түгелме соң? Кама аша машиналар йөри дә башлаган ди.

— Кышын безнең авылда мотоциклның хаҗәте шул тиклем генә. Монда кирәк ул миңа! Ә тотар урыны мы? Кайгырма, анысын да табарбыз!

— Юк инде, рәхмәт! Минем тулай торактан бу юлы колак кагасым килми! Үзебез салган йорт лабаса! Андые кайчан эләгә тагын? Яңа еллар үтеп, язга чыккачмы? Аннары, апаем, синә да, мондагы тылыңны бик шәпләп ныгытып алгач, һөҗүмеңне тегендә җәелдерергә вакыт бик җиткән түгелме?

Габделбәр кинәт көлеп куйды:

— Ярый-ярый, күндердең, җирән сакал! Шулай да тулай торак хакында Туры бабайларга бүген әйтеп тормасак, әйбәтрәк булыр.

— Ник тагы?

— Соң, буш кул белән кайтып киләбез ич, килешмәс. Әле иртәгә дә монда кайтып кунасы. Көндезен бер ара кибетләрдә йөреп, истәлеккә әйбәтрәк бүләкләр сатып алырбыз, кабарга-йотарга дигәндәй. Аннары инде, шул әйберләрне күтәреп кайтып кергәч, куанычыбызны капыл гына әйтеп тә салырбыз.

Ниһаять, җирән сакалбайның да авызы ерылып китте:

— Шулай дисәң генә инде.

Туры карт өенә кайтып кергәч, ике егет, әлбәттә, берни сиздермәде: гадәттәгечә көр тавыш белән хәл-әхвәл белеште, аннары юл киемнәрен мич аралыгындагы чөйләргә элеп куйгач, юынды-чистарынды да әзер табын янына тыйнак кына килеп утырышты. Тик тәмле ризык-нигъмәт белән ачыккан карыннарын туендырып, аны хуш исле чәй белән бастырып куйгач кына, Туры бабай белән Тәзкия апаларына гадәттәгедән матуррак, җылырак иттереп рәхмәт әйттеләр.

Хоккей дигәннәренә Габделбәрнең әллә ни исе китми иде. Телевизордан футбол күрсәтсәләр генә ул дөньясын онытып җибәргәли, ник дигәндә, малай чагында үз туган авылында ул туп артыннан үлле-мәлле аз куышмады, армиядә хезмәт иткән чагында да, полк командасына эләгеп, җитәрлек йөгергәләгән, кыскасы, бу уенны ул үз итә, аның рәтен һәм тәмен белә иде. Ә хоккей башлангач, ул шуңа күрә:

— Клубта берәр кызыклырак кино түгелме икән, әйләнеп кайтыйм әле булмаса,— дип урыныннан купты.

Тышта дөнья тып-тын, һава ярыйсы ук салкын иде.

Капка төбендә, дөнья тынлыгына колак салган килеш, бераз вакыт басып торды. Егетнең өстендә тик әйбәткә генә, әмма соңгы вакытларда бик сирәк киелә торган киемнәре иде. Менә ул башындагы куян бүреген батырыбрак киде, соры драп пальтосының мутон якасын күтәртеп куйды. Аннары акрын гына кузгалды. Ләкин клуб ягына борылып та карамады.

Күңеле тулы моң һәм сагыш иде егетнең. Инде менә ачы юксыну хисе дә оялап алды шикелле. Хезмәттәш дусы Назар хаклы кебек: егет соңгы араларда Рәмиләне уйлый-уйлый, чынлап та «тегеләйгә әверелеп бара» ахрысы. Авыр хезмәтендә тирләр түгеп эшләгәндә дә күңеленнән шул чибәр кызый китми, юлда барганда-кайтканда да, тамак ялгарга утырса да, йокларга ятса да күз алдында һаман да шул бер сурәт. Ә монда Әҗергә кайтып төшсәләр, бөтенләй әллә нишләп бетә: кызның төсе-кыяфәте генә түгел, көлү-шаярулары, сулыш алулары, хәтта исе үк сеңгән шикелле бу авыл һавасына, урам-тыкрыкларга, йорт-коймалар буйлата сузылган сукмакларга...

Менә шушы тыкрык белән ул, зифа сынын бөгелдерә-сыгылдыра, көянтә-чиләкләп Туры бабасына колонка суын китерә торган иде. Зәһәр җәй челләсендә әлсерәп кайткан тәнгә дә, җанга да үтә тәмле һәм шифалы тоелыр иде ул су. Суыклыгыннан тешләр камашыр, ләззәтеннән башлар әйләнеп китәр иде. Әмма ләззәтнең тагын да нечкәрәгенә, исәрләндергеч тылсымлысына Габделбәр ирешә алмый калды. Молдаван егете Женя Мында чаярак һәм үткенрәк булып чыкты: кай арада кызыйның чиләгенә үрелде, чиләгеннән беләгенә, беләгеннән йөрәгенә! Ә бит Габделбәр дә бер күрүдә үк аңа кызыгып куйган, шул сәгатьләрдә үк янында чаткы кабынган иде. Ләкин юк, иң кирәк чакны чын егетлек күрсәтә белмәде, җебеп калды. Инде хәзер менә мең үкен!

Шушы тыкрыкта молдаван «мыеккае» шул чибәр нечкәбил хакына авыл егетләре белән бик кайнарланып тәпәләшкән иде. Үзе күз төбенә йодрык кадәр фонарь алса алган, әмма тегеләрнең берсен читән төбенә кычыткан арасына сеңдергән, икенчесен киртә аша чөеп аткан. Габделбәр дә махы бирмәс иде, бер түгел, әллә ничә тапкырлар сугышыр иде, күз төпләренә берне түгел, әллә ничә фонарь алыр иде, әмма барыбер үзенекен итәр, җиңми калмас иде. Аның үз авылында егетләр белән тәпәләшкәне аз булмады, тәҗрибәсе җитәрлек, ни әйтсәң дә, десант гаскәрләрендә хезмәт иткән, чигенүне белмәскә өйрәтелгән солдат лабаса ул! Ләкин кайда хәзер ул чибәр кыз, кайда аны күзләп, аны сагалап йөргән авыл егетләре? Эзләре күптән инде суынган! Әнә читән төпләрендәге кычытканнар да әллә кайчан шиңеп, җиргә сыланган, караңгыда, күңелне сызландырып, читән таяклары һәм киртә казыклары гына тырпаешып тора...

Ә менә тыкрык чаты башында Рәмилә туган өй. Тәрәзәләренә зәңгәр якты сирпелгән. Рәмзи дә хоккей карап утыра ахры. Әллә сугылып, хәл белешеп чыгаргамы соң? Ә юк, кирәкми, иртәгә саубуллашу мәҗлесе үткәрәчәкләр, менә шунда бик иркенләп, бик тәмләп сөйләшеп алырлар әле.

Телевизорларын аларга җәй уртасында Женя Мында төзәтеп биргән иде. Шуннан бирле ватылганы юк шикелле. Аны кабындырганда ул оста куллы егетне исләренә төшерми калмый торганнардыр инде. Женя Мында... Чынлап та, һай оста куллы, һай гаярь егет булып чыкты шул! Әнә инде хәзер КамАЗ тикле КамАЗ заводларына бөтен ил буйлата, хәтта хәзер инде чит илләргә дә чыгып, заманның өр-яңа станок-җиһазларын юнәтеп йөри. Андый югарылыкка Габделбәр буй үрелдерерлекмени?

Габделбәрне үз кеше диләр, ә теге исә чит милләт, җитмәсә, билгесезрәк, томанлырак адәм. Өлкәннәр өчен шулайрак инде. Ә яшьләргә, Рәмилә кебекләргә ничек? Егетнең оста кулы, төпле белеме, гаярьлеге-тәвәккәллеге өстенә әнә шул чит милләттән булуы, ягъни гыйшык тотуның романтик рухы, романтик бизәкләре кызның җанын иләсләндереп җибәргәндер дә әле. Әлбәттә, шулайдыр! Әмма ул шома егетнең йөрәгендә, җанында ни? Гомер иткәндә иң кирәклесендә? Тамырларында Дон Жуаннар каны типмиме икән? Әйе, үз ялкынында нәфис җанлы, матур омтылышлы, сөйкемле кызыйның канатларын көйдереп, аны вакытыннан иртә харап итеп ташламасмы? Габделбәргә дә чәчкәнең кемдер тарафыннан өзелеп, юл читенә ташланганы түгел, аның саф һәм нәфис хәлендәгесе, чиксез нурланып-балкып торганы кирәк ич!

Җәл, ул үзенең ярыйсы гына уңган һәм булган егет икәнлеген тиз арада гына күрсәтеп, ачып сала белмәде. «Акрын киткән — морадына җиткән» диләр. Дөресме бу тәкъбир бүгенге көндә? Бигрәк тә КамАЗ кебек мәхшәр купкан җирдә акланамы икән? Югыйсә ул көнкүрештә, бигрәк тә авылда, крестьян тормышында һава кебек үк кирәк булган әллә никадәр эшләрне эшли белә һәм ул аларны һәрчак яратып, җиренә җиткереп башкара лабаса. Тик торуларны өнәмәү, кулының һаман да берәр эшкә кычытып торуы, кешегә ярдәм итешү, аңа һич риялланмыйча, шулай кирәк, шулай тиешле дип тотыну һәм моңардан тәм табу — аның канына күптән инде сеңгән сыйфатлар иде. Мондагылар да, егетнең холык-табигатендәге менә бу якларын, акрынлап булса да, бик әйбәт сизеп алдылар шикелле. Әнә бит, беркем әйтеп тә, үтенеп тә түгел, шулай ук кемгә дә булса алай бик ярарга тырышып та түгел, нибары тик тора белмәгәннән һәм кыек-шыекларны күрүдән, шуңа җаны әрнегәннән генә, булмаган вакытын бар итеп, Туры картларның болдырын сүтептаратып һәм өр-яңадан корып, аңа менә дигән шома култыксалар ясап куйды. Ул да түгел, какшаган ишекләрен төзәтеп бирде, арт һәм ян тәрәзәләренең рамнарын ныгытып, аларга өлешчә өр-яңа, чиста пыялалар куеп чыкты. Йорт хуҗалары аңа ничек дип рәхмәт әйтергә белмәделәр.

Әнә Рәмзиләрнең өй морҗасыннан төтен ургылып чыга, югарыга

тигез һәм матур булып күтәрелә. Әнисе Рәсүлә, өйләре төнгә җылы булсынга, мич ягып җибәргән, күрәсең. Ә бит ул төтеннең шушылай ургылып, матур булып бөркелүенең төп сәбәпчесе Габделбәр ләбаса. Һай, күңелле хезмәт булган иде лә ул, аннан да битәр, инде эш тәгәлләнгәч, куерткан гапләре матур һәм мәгънәле булган иде! Тик, җәл, ул ялда шушы йортта туып үскән нечкәбил ни сәбәптәндер кайтып төшмәгән иде, шунлыктан чибәр кызый берни күрмичә, берни ишетмичә калды...

Инде суыклар башлангач беленде: Рәмзиләрнең моржалары юньләп тартмый, мич авызыннан төтен чыгып, бөтен өйләрен тутыра икән, инде тәмам йөдәп беткәннәр. Якшәмбе иртәсе иде. Габделбәр тиктән генә аларга барып кергәч, казалы хәлне аңлап, мичне тегеләй караштырып, болай караштырып чыкты һәм тәвәккәлләп эшкә тотынды. Иң әүвәл мичнең югары өлеше белән моржасын бөтенләе белән сүтеп ташлады. Аннары, мичнең исән калган өлешендәге бар төтен юлларын бик әйбәтләп тазартып чыккач, сүтелгән кадәресен яңабаштан салырга кереште. Ул, билгеле, һәммәсен үзенчә иттерде, үзенчә кыландырды. Әйе, кулларында чын-чынлап ут уйнатып күрсәтә белде егет ул көнне! Измә изүдә, иске кирпечләрне кырып, чистартып, әзер хәтлесен югарыга биреп тору кебек эшләрдә аңа дусы Рәмзи булышты. Кичке эңгер куерганчы, эшләрен түгәрәкләп тә өлгерделәр.

Түгәрәкләп куйгач, билгеле, яңартылган мичне көне-сәгате белән үк сынап карыйсылары килде. Мичкә яртылаш кына, артыгын кызып, каты куырып куймаслык иттереп кенә, утын тутырдылар да кабызып җибәрделәр. Мич галәмәт шәп суырта иде, коры утын минуты белән ялкынга уралды һәм дөрләп-гөләп яна да башлады.

Менә шул чагында йорт хуҗабикәсе Рәсүлә мич янында идәндә аяк бөкләп, җәйрәп утырган, куллары, бите-йөзе корымга, тузанга буялып беткән Вятка егетенә, үз куанычын бер төсле сорау рәвешенә төребрәк, әйтте дә инде:

— Әфсенен бик әйбәт беләсең икән, сырхаулар күрмиенчә меңнәр җәшә, улым! Тик ни... үзең сөйләгән шул мичче Мәсгут абыең җанында остарганнан-остара барып, үз авылында шәһәрткә күмелеп җәшисе урынга ниләр эзләп килдең соң син мондагы Чаллы мәхшәренә?

Моңа Габделбәр гадәтенчә киң һәм мөлаем елмаеп җавап кайтарды:

— Ә безнең Мәсгут абый әле илленче еллар башында ук Мәскәүнең Ленин тауларында өр-яңа университет бинасын коруда катнашкан, аннары аны, иң шәп ташчылар рәтендә, Варшава каласына галәмәт дәү культура сарае салышырга җибәргәннәр. Яшьлегенең әнә шул матур елларын ул бик сагынып, бик горурланып әледән-әле исенә төшереп тора, аны тыңлаулары ук күңелле!

Моның соңында шунда мич каршысында тез чүгеп утырган дусты Рәмзигә күз сирпеп алды:

— Син, Рәмзи, Чаллы юлларыннан аз йөрмисең бит. Олы юл белән выжлатып үтеп барган чакларыңда, бер кырыйда зур хәрефләр белән буйдан-буйга галәмәт сузайтып, «Исталеккә... шәһәр бүләк итәм!» дип язылган плакат күзеңә чалынганы бармы?

— Чалынмыйча. Андый плакат КамГЭС поселогының бер йорт маңгаена да беркетеп куелган, кичләрен ут булып яна! — дип җуплап куйды Рәмзи.

— Менә шул-шул. Минем дә, дим, соңыннан горурланып, хәтта мактанып сөйләрлек бер эшем калсын әле үз гомеремдә!

Рәсүлә бу сүзләргә бик канәгать, бик риза кыяфәттә баш каккалап алды. Ләкин аның әйтер сүзе әле бетмәгән икән, ул инде хәзер тавышына тагын да серлерәк, мәгънәлерәк төсмер бирергә тырышып, егеткә төбәлде:

— Ә бәлкем... соңыннан кала салган җирендә урнашып та калырсың, туган авылыңа бөтенләй дә кайтып тормассың? Ә бәлкем, шушы данлышаулы тирәнең берәр авылында төпләнеп калырга ниятләрең туар, ә?

Габделбәр менә монысына инде җавап бирергә ашыкмады. Аның авыз тирәсе бер җыела төште, бер җәелеп китте, маңгае җыерчыкланып сырланды, ахырда, тирән сулап куйгач, сүзен турыдан бәрмичә, читләтебрәк, әмма шулай ук үзенчә тирән мәгънәгә төрендереп, әйтә салды:

— Язмыш китабын актарып караган юк бит әле. Бәлкем, аның алдагы битләрендә шулай дип язылгандыр да, Рәсүлә апа!

Дөрләп янган мич каршысында, йөзләрендә ялкын шәүләләре уйната-уйната, бик матур, бик мәгънәле сөйләшү булды ул тымызык кичне, һәм менә шуннан соң алар үзара бик якынаеп, тәмам үз кешеләр булып киттеләр дә шикелле!

Ә Туры бабай өендә, төп йортларында кич утырып, матур һәм серле гәп корулар? «Кырлар тарихы»... аңа сеңгән кызыклы һәм гыйбрәтле вакыйгалар, авыллар язмышы, адәмнәр көрәше? Ә авыл исемнәре? Аларның асыл мәгънәләре, аларга төренгән серле һәм хикмәтле хәлләр? Менә болар һәммәсе дә Габделбәрнең күңеленә тирән уелып керде, һәм ул, туган ягы Вятка буйларына кайтып төшсә, бу җәһәттән барын да тирәннән өйрәнеп-белеп алырга ниятләп куйды — моңа аның иманы камил иде. Димәк, бу тарафтан Туры карт үз максатына иреште дисәң дә була иде. Ләкин нечкә күңелле, хәйләкәррәк зиһенле бабайның теләге моның белән генә чикләндеме икән? Ул үзе сөйләгән кызыклы вакыйгалар, гыйбрәтле хәлләр белән тыңлаучыларында, бигрәк тә Габделбәр күңелендә, бу тарафларга, үзенең туган якларына олы ихтирам һәм хөрмәт хисләре уятырга, шуның белән аларны тагын да якынайта төшәргә, ахыр килеп, бөтенләй үз кеше итеп куярга да теләде шикелле. Габделбәргә мөнәсәбәттә ул монысына да ирешә дияргә мөмкин иде. Алай гынамы, егет күңелендә әлеге күркәм тойгылар гыйшык хисләре белән дә үрелеп-кушылып киткән, ягъни тагын да нечкәрәк, нәфисрәк һәм кайнаррак рәвеш алган иде. Әйе, егет кичләрен серле һәм хикмәтле гәп корып җибәргән чакларында үзе янында чибәр кызның да утырганын, хәтта аның сулыш алуларын тоя кебек, «Кырлар тарихы»на, аларга сеңгән кызыклы вакыйгаларга, хикмәтле язмышларга ияреп, күңеле һәм уе белән бик-бик еракларга китеп бара, җанын тәмам иләсләндергән кызның коры-буш җирдә тумаганын, аны тарихның гыйбрәтле язмышлары тудырып үстергәнен һәм бүгенге көнгәчә китереп, сокландыргыч матур гөлгә әверелдерүен бик әйбәт аңлый — бу исә егетне чиксез куандыра да иде.

Әнә ул кырлар-басулар. Юка кар астында туңып-өшеп яталар. Инде сап-салкыннар. Ә юк, әнә шул туңып-бөрешеп, тын гына яткан мәлләрендә дә сап-салкыннан да туфрак исе, киләсе яз һәм җәйнең җылысы бөркелә сыман. Күзләреңне йомдың исә, күз алдыңда ямь-яшел басулар, гөрләп үскән игеннәр шәйләнә, хәтта аларның шавын колагың белән дә ишетәсең кебек. Алай гынамы, шул яшеллек дөньясыннан, шул игеннәр арасыннан болай таба, аңа таба, җилдә чәчләрен тузгытып, зәңгәр яулык болгый-болгый, көләч йөзле кызый кирә сыман, ул йөгерә-ашкына, бер оча, бер куна, торган саен якыная, менә инде кайнарланып кочагыңа керер, менә инде ялкынлы күкрәгеңә сыеныр кебек — нәкъ инде кайбер кинолардагы шикелле. Ләкин бу — нибары җанлы-җансыз сурәт кенә, нибары мираж гына, аны кочагыңа алыйм дисәң, кочагыңда коры һәм салкын бушлык кына. Назар әйтмешли, әллә чынлап та хыялыйга әверелеп бара инде ул соңгы араларда?

Ә совхозларында бүген хәлләр хәл... Ризван агроном, Хәнәфи Бариев белән аның улы Рәмзи кебекләр тырышмыйлар түгел, бик тырышалар, көне-төне баш ваталар, тирләр түгәләр, болай кыландырмакчы, тегеләй итмәкче булалар, әмма атлап үтәсе кыенлыклары хәтсез шул әле. Тегесе җитми, бусы җитми, бигрәк тә төрле һөнәр ияләренә зур кытлык. Ә бит турысын әйткәндә, Габделбәрнең күкрәк кесәсендә трактор йөртергә таныклыгы бар — моны ул урта мәктәпне тәмамлаганда ук алган иде, шоферлыкка да хокукы бар — монысын армиядә чакта үзләштерде, ягъни хезмәтнең бу төрләреннән дә сынатырлык егет түгел иде. Тик ул боларын




*Тавил Хаҗиәхмәтов рәсеме.*

әлегә әйтмичә тора, үз туган ягы Вятка буйларын искә төшергәндә тегеләй дә авыз суларын корытып сөйли, белгән-өйрәнгән һөнәрләре җәһәтеннән исә алай бик кәпрәеп кыланырга теләми иде. Яисә, әйтик, кирәге чыкса, дусы Рәмзи белән бергәләп, җәен болыннар сугаруда тир түгеп, кышын ремонт эшләренә ике куллап ябыша алмас идемени? Күңел сала белсәң, совхозда үз сәләтеңне беткәнче күрсәтердәй эшләр азмыни? Шулай, Габделбәр менә бу кыр-басуларда үз буразналарын бик теләп сызар иде. «Кырлар тарихы»ның алдагы сәхифәләренә үз исемен җуелмаслык иттереп, матур иттереп яза белер иде. Ләкин моның өчен ике җанның бергә кушылып чәчәк атуы, аларның бер-берсенә тиң булып, кулга-кул тотынышып яшәп китүләре, ягъни кырлар тарихына, авыл язмышына иң матур сыйфатларда сеңеп китүләре кирәк ләбаса! Егетнең бердәнбер шарты шул. Әйе, бер Бариевлар гаиләсе өчен генә түгел, шушы авыл, шушы кыр-басулар өчен дә иң кирәк кеше бит инде ул югыйсә. Нигә моны аңламый икән ул кызый?

Кырлар эндәшми, кырлар җавапсыз. Ә юк, алар тын гына хәл җыеп, җегәр туплап яткан мәлләрендә дә, сап-салкыннан да әнә:

— Алдагы матур һәм якты көннәрнең хакына, безнең дә бәрәкәтле һәм хозур булуыбыз хакына, саф намусың белән чын-чынлап кыюлык һәм тәвәккәллек күрсәт инде, егет! — дип, кайнар пышылдап, киңәш бирәләр сыман...

Кыш башының тымызык бу кичендә Әҗер урамнарын һәм тыкрыкларын байтак буйлап йөрде Вятка егете. Кайтып керсә, хоккей инде тәмамланган; өйдәгеләр, бары бер булып, «Вакыт» программасын карап утыралар иде. Арада, диван почмагына чумып, Ризван агроном үзе дә кырын яткан иде.

— Нәрсә, клублары бик суыкмы әллә, җүнләп җакмыйлармы? — дип төбәлде Туры карт, алгы өйдә утны яндырып һәм егетнең кызарып янган йөзенә игътибар итеп.

— Суык,— дип көлемсерәде бусы һәм түр якта кәнәфигә чумып утырган хезмәттәше Назарга гына күз төшереп алды да, һәммәсе ишетерлек иттереп, бер сулыш белән диярлек әйтә салды: — Кайткач та әйтергә онытканбыз. Тулай торакка чират җитте бит безнең! Иртәгә сезгә азаккы көн кайтабыз!

Тегендә Назар башын ялт кына болай таба борды, беравык иптәшенә күз тасрайтып карап торды, аннары, үзе дә авызын киң җәеп, җирән сакалын селеккәләп алды:

— Ие, ничектер онытып җибәргәнбез. Берсекөнгә күченәсе!

Югыйсә мондый көн киләсен беләләр дә, аны көтәләр дә иде, шулай да, хәбәр капыл гына әйтелгәнгәме, Туры бабайның чал төкләр баскан, тирән җыерчыклы үз йөзе дә кинәт кенә күе кызарынып китте.

— Менә бит, ә! Инде көне җитте диген, ә! Һай, тиз үтә дә соң гомеркәйләр! — дип, тыны беткәндәйрәк рәвештә, карлыккан тавыш белән сөйләнеп куйды карт һәм Ризван улы белән килене Тәзкиягә эндәште: — Ишеттегезме? Син инде, улым, иртәгә кичен кантурыңнан вакыт чамасын җуймый кайта бел! Ә син, килен, мунча җагып җибәрерсең, мичкә итле бәлеш салырсың. Берәгәйле иттереп кенә бер мәҗлес корып утырмыйча, һич җарамас, диюем!

— Ярый, әткәй, шулай итәрбез! — дип җавап кайтарды Тәзкия һәм, менә хәзер үк эшкә керешергә җыенгандай, утырган урыныннан ук купты.

Ризван да, ачык елмаеп, очлы ияген каккалады:

— Андый кичне кантурда батып яталармы соң! Әлбәттә, коры-буш көйгә генә үткәрмәбез аны! Мәҗлескә Рәсүлә сеңел белән Хәнәфи кияүне дә дәшеп алырбыз, уллары Рәмзине дә.

Тик Сабир гына моңсуланып:

— Инде саубуллашасы да икән,— дип куйды. Аңа инде тәмам үз булып беткән абыйлары белән генә түгел, бер уңайдан аларның харап та шәп мотоциклы белән дә хушлашырга туры киләчәк иде.

Ниһаять, ут сүнде, өй эче тынып калды. Бу кичне Ризван агроном да озаклап утырырга теләмәде, хәер, ул соңгы вакытларда кич озайтуларын сирәгәйтә төшкән иде: яше дә бәләкәй түгел, өстәвенә, эштән чыгып алҗый да торгандыр. Ләкин бу төнне аны да, бүтәннәрне дә йокы тиз генә җиңә алмады.

Назар белән Габделбәр гадәттәгечә алгы өйнең чаршау төшермәле киң караватына ятты. Башлары уртак ястыкта. Бер мәл тын гына яткач, Назар пышылдап кына, әмма үпкәсен аермачык сиздереп, әйтә куйды:

— Бүгенгә тишелмичә торабыз дип сүз куешкан идек, ә син, сыбызгы?

— Син гафу ит инде. Мин капыл гына киресен уйладым. Никме? Тылның чыннан да ныкмы икәнен беләсем килде. Әйбәт икән! Үзең күрдең ич: ниләр кыландырмакчылар!

— Оста да инде син.

— Ә син, Назар, хаклы: миңа хәзер Чаллыда яшәгән килеш җилләр истерергә бик вакыт. Теге мыекбай дусның ныклыгын бик шәпләп сынап карамыйча ярамас! Рәмилә аның ялтыравык укасына гына кызыгып җенләнмиме икән? Бик яшьләй үз укасы коелмагае кызыйның...

Назар молдаван егете Женя Мынданы да чит күрми, аны якын итә, ә Габделбәр хакында әйтеп торасы да юк. Ул аларның маңгайга-маңгай бәрелешүен һич теләми иде. Ләкин, ни хәл итәсең, мәхәббәт юллары кисешми тормас шул: берәү җиңә, икенче берәү чигенә яисә җиңелә... Назар авыр сулап куйды:

— Бик тә кызганыч, мәхәббәтнең күзләре сукыр диләр шул.

— Әнә шул мәхәббәтнең сукыр күзләрен ачтыру — асыл егетләр шөгыле түгелме соң, дускай?

## 5

Таиповның кулында келәшчә-чүкечтер, өтергедер, ян сәкедә вак кадак белән калайдыр, олы кайчыдыр, алдында исә күпне күргән иске сандык.

Хатыны Марзия аңа: «Зинһар, шуны адәм карар кыяфәткә кертеп, рәтли күр инде, картым»,— диде. Үтенече зурдан. Ә үзе Яңа Калага куна китте.

Бүген Таипов болын хәтле өендә япа-ялгызы матавыклана.

Иске сандык — әүвәлге тормышларының күркәм бер истәлеге. Ул карар күзгә әле шактый нык күренсә дә, инде картайганлыгын ярыйсы ук сиздерә: борганда-органда, авыр-авыр ыңгырашып куйгандай итә.

Аларга өр-яңа квартирны унике катлы мәһабәт йортның бишенче катыннан бирделәр. Өлкәнрәк яшьтәгеләр өчен бераз югарырак инде югарылыкка, әмма артык зыяны булмастыр, шәт: лифт дигәннәре өзелми эшләп торачак, имеш. Ә болай квартирлары әллә кемең кызыгырлык: шоп-шома линолеумлы, ялтырап торган өч бүлмә, ике балкон, урам якка караганын «лоджия» диләр икән. Кафель диварлы бик пөхтә кухня. Ни дисәң дә, чын осталар салган «мәскәүский» йорт шул. Әмма иң әһәмиятлесе: суның салкыны да, кайнары да килеп тора, озакламый газын да үткәрәселәр ди. «Мичкә утын ягып, сулар ташып иза чигәсе булмас, бер рәхәтләнер көннәр килер икән безгә дә»,— ди карчыгы. Якында, кул астында гына диярлек кибете-мазары, урам аша гына иләмсез дәү поликлиникасы да корылып ята. Картаймыш көннәреңә оҗмахның үзе буласы инде. Карчыгының куанычы эченә сыймагандай күренә.

Ике бөртек җан дигәч тә, алдагы көннәрдә, мөгаен, алай калмаслардыр, ишәерләрдер. Шулайрак абайлана. Әнә Козьмодемьянск каласында үзләренә оя кормак булып тырмашкан кызлары Әлфинур белән кияүләре Вазыйх азакцы хатларында бу якларга тартылырга ниятләре барлыгын аермачык сиздереп яздылар. Көннәрнең бераз йомшарта төшүен генә көтәләр. Нәниләре бар, әле тагын булырдыр. Ярый, хуп, кайтсыннар, төпләнсеннәр. КамАЗ өчен әзер механик бик тә ярап куяр, врач кызлары

да эшне тиз табар, читкә кагылмас. Ганлә тормышлары да картлар янында, ичмаса, түгәрәкләнә төшәр. Әйе, бергә-бергә күңеллерәк булыр.

Яңа квартирга, әлбәттә, мебельнең өр-яңасын, күзнең явын алып торганын гына кертерләр. Заманчасын! Марзиянең күптәнге хыялы. Яңа квартирга савыт-сабаның, урын-җирнең бер кадәресе күчерелде инде. Әмма Марзия, әкәмәт җан, Яңа Калага иң башлап гөлләрне, аларның да иң купшысын, иң матур чәчәклесен илтте: «Изге сәгатьләрдә туры килсен дә, алдагы көннәребез картлык җәфасын әллә ни күрми-нитми генә, гөлдәй балкып торсын!»— диде.

Ә мондагы, иске йорттагы байтак нәрсә — шактый таушалган өстәл-урындыклар, тимер караватлар, шкаф-комодлар үз урыннарында калыр. Әйдә, үз җайларына әкрен генә туза бирсеннәр. Хәер, алай онытырлык итмәсләр: ике арада җепләр барыбер өзелмәс, туган авылларына эзләрен барыбер суытмаслар.

Бу иске сандыкны исә үзләре белән алырлар. «Яңа фатирда елтыр-ялтыр мебель арасында аңа гына урын табылыр, сыйдырырбыз»,— диде карчыгы.

Шулай димәскә, иске сандык — аның иң кадерле истәлеге. Бирнәсе! Ул көннәрне онытырлыкмы соң! Кышка кергәннәр иде инде. Сугыш беткән елның беренче йомшак карына беренче чана эзләре төшкән чак иде. Кошевкага иңне-иңгә терәшеп утырган шәйгә, туй атында, аллы-гөлле сөлге-тасмаларын җилфердәтеп һәм җиз шөлдерләрне матур чыңлатып, Әҗер урамнарыннан әллә ничә тапкыр гөрләтеп уздылар. Иң ахырдан, кояш тарафыннан әйләнә килеп, аларның шушы нигез капкалары төбендә тукталдылар. Кошевка артына исә шушы сандык бәйләп куелган иде.

Рәхәт һәм татлы көннәре иде. Егерме сигез ел әүвәл...

Инде хәзер Яңа Калага карчыгы ниләрен тотырып алып китәр микән? Иң кадерле савыт-сабасынмы? Әллә элек-электән сакланып килгән китап-журналларнымы? Арада гарәп хәрефләре белән бастырылганнары бар, латин шрифтындагылары да.

Ә бәлкем, шушы сандыгына янә кием-салым, чүпрәк-чапрак тутырып алып китәр? Теге замандагы иң олы байлыгы булган бирнәсенең үзенчә бер төсе һәм өлеше иттереп?

Бер көнне карчыгы комодның иң астагы тартмасын актарырга тотынды. Бу сандык ул чакны әле келәтнең бер почмагында, ягъни тыныч аккан еллар куенында, әкрен генә искергәннән-искерә барып, тузан җыеп ятуда иде.

Марзия комод тартмасыннан байтак нәрсә тартып чыгарды: үзенең кыз чагында яратып кигән, матур-матур бизәкле күлмәкләрен, яулык-кыекларын, килен булып йөргәндәге киң күкрәкчәләре, каймалы алъяпкычларын, бүтәнен... Барының да төсе уңган, бары да тузган, тик тотып карарлык кына. Шунда, и хикмәти хода дигәндәй, тартма эченнән җилкә башлары тәмам уңып, хәтта агарып беткән ертык якалы гимнастерка белән кыршылган пилотка килеп чыкты. Яхъя Таипыч хатынының мондый хәстәрлегенә исләре китеп карап торды, шул минутта хәтта бугазына төер дә менеп кунды шикелле. Әмма хикмәтнең дә хикмәте бу түгел икән әле.

Берзаман чүпрәк-чапрак арасында пергамент кәгазьгә бик пөхтәләп төрелгән дүрт кырлы төргәк күренде. Мөгаен, карчыгы Марзиянең шуны эзләве булгандыр да әле. Тапкач, тегеләй әйләндереп, болай боргалап карады, аннары ашыкмыйча-кабаланмыйча, сакланып кына сүтеп җибәрде. Яхъя Таипыч шул минутта аһлар итте: төргәктә тип-тигезләп өсте-өстенә салынган кулъяулыклар иде! Дистәдән артыктыр! Бәз-батист чүпрәкләр, дөрес, чак кына саргая төшкән, әмма чигүле чәчәкләре, билләһи, менә шул сәгатьтә генә бакчадан өзеп алып кергән сыман! Фронтовик егет булып йөргән чагында аз бүләк иттемени ул аңа шундый кулъяулыкларны? Соңыннан, бергә кушылып, җан юлдашлар булып бер сукмактан атлап киткәч, күрәмсең, барын да кире җыеп алган да, хәстәрен күреп, саклауга куйган.

Карчыгы Марзия ул кичне кулъяулыкларның һәркайсын диярлек җәеп җибәреп, аларга дымлы күзләрен төбәгән хәлдә озак кына уйчанланып утырды, аларны иснәп-иснәп тә куйгалады, ахырда берсен иренә дә сузды:

— Мәле, иснәп карале! — диде.

Чын әгәр, зур роза чәчкәле батист кулъяулыктан әле һаман хушбуй исләре аңкый иде!

Карчыгы бар булган истәлекләрен, әлбәттә, иң яктыларын, иң кадерлеләрен, Яңа Калага шушы сандыкта алып китәргә җыенгандыр.

Өлкән ир затының кулында келәшчә-чүкеч уйный, олы кайчы ялтыравык калайны телемнәргә телгәли, өлкән ир затының ихтыярына буйсынып, иске сандык торган саен ныгый бара, яшәрә бара иде.

Гомер юлдашының олы гозерен җиренә җиткереп үтәү аның үз йөрәгенә дә ял бирә сыман иде.

Кинәт абзый, чүкечен күтәргән хәлдә, сагаеп калды: тышта кемдер болдыр баскычына каты-каты иттереп аяк бәргәләп алган кебек тоелды аңа. Кайсы йөри икән тагын эш бүлдереп?

Теге озак көттермәде, ишекне киң ачып һәм үзе белән бер болыт салкын ияртеп, бусагадан атлап та керде. Хәнәфи Бариев икән лә.

Хуҗа кеше аңа үтә сәерсенеп төбәлде: Хәнәфинең өстендә гадәттә кия торган каеры туны, башында колакчын читләре шактый ук кыршылган күн бүрек, әмма аягында... бик озын кунычлы резин итекләр иде. Менә сиңа — бу җилдә, бу суыкта!

Хәнәфи ипле генә исәнләште, аннары бияләенең кыры белән генә куе төкләр баскан какча яңагын сыпырып узгач, ярыйсы ук каушаган тавыш белән әйтә куйды:

— Ни... Яхъя Таипыч, кодаң Гайнан Кама уртасында бозда батып калган бит әле. Машинасы-ние белән.

Таипов сандык янына чүгәләгән җирендә, кисәк буыннары йомшап, лып иттереп идәнгә утырды, хәтта кулындагы чүкече дә аяк арасына төшеп китте:

— Нәрсә-әү?

— Син, зинһар, алай ук бик нитмә әле, Яхъя Таипыч: үзе исән ул, исән! Акмаган да, нитмәгән дә. Машинасы гына ике боз арасында кысылып калган, ди. Аның бозы да, кадалгыры, ике катлам булып каткан бу елның кышында.

— Ник алай?

— Шул инде, югарыдагы ГЭС хикмәтләре: кыш уртасы җиткәндә боз өслә тә шаулатып су агызып ятмасалар соң. Инде хәзер аста да боз, өстә дә боз, ә ике арада су, ди.

— Уф, рабочком, бу хәтле котны алмасаң соң. Җүнләп аңлата да белмисең, иблис! — Таипов идәннән авыр гына кубарылып күтәрелде дә ян сәкегә утырды. Аның сулыш алуы, ниһаять, җайлана төште сыман.— Атна-ун көннәр элек колакка чалынган иде шул: ни Алабугага, ни Менделеевскига чыгып булмый, елга өслә тә шаулап су ага дип. Гыйнвар азагында, чатнама суыкта, ә! Бу Каманың рәтен тәмам бетерделәр: ни җәй сиңа, ни кыш. Ә Гайнан ни пычагыма дип күрәлә тә барып кергән соң? Шул хәтле акай-чукайланмаса соң!

— Чукайланмаска. Аның Алабугада бер нефтьче әшнәсе бар икән. Менә шул бәндә берничәләп баллон кислород ышандырган булган. Ремонтның самый кызган чагы бит. Кислородсыз гына, бар, җүн чыгарып кара!

— Кислород күгәрчен сөте түгел лә. Ярый, хуп, миннән ни?

— Ни дип... Төнгә каршы кешене машинасы-ние белән Кама уртасында калдырмассың бит инде.

— Дөрес, ярамый. Әмма ләкин мин бит инде, үзең бик беләсең,— Таиповның тавышы кисәк сынып китеп, карлыгуга күчте,— власть түгел бит инде, власть түгел! Акбашев беләме? Кем булсын, мине алыштырган яңа директор!

Хәнәфи бияләй кыры белән янә какча яңагын сыпырып узды, авыр гына көрсенеп куйды:

— Миңа, Яхъя Таипыч, власть түгел, трос кирәк иде.

— Трос? Нинди трос?

— Соң, тарттырмагә инде. Мастерской лапасы төбендә рулонда берәү бар иде. Инде җилләр искән. Күргән-белгән кеше дә юк. Әллә дим сез...

— Һы, мин каян белим, каравылда утырдыммыни?

— Әллә дим, Гарәфша кодаң бер-бер җиргә...

— Гарәфша? Тагын шулмы? Тфү, әйтмә миңа бүтән ул исемне! — Таипов ян эскәмиядән капыл гына кубып, алгы өенең идән сайгакларын шыгырдата-шыгырдата ишекле-түрле йөренергә тотынды. Аның калын кашлары кушыла язып, йөзе үтә ачулы, хәтта куркыныч төс алган иде.— Әйтмә! Кода, имеш! Тегесе дә, бусы да... бөтенесе дә! Ә бит Гарәфшаны артына тибеп авылдан озатканыма өченче ай китте түгелме? Югын да, барын да бер төшкә аударырга.. Һы, таптыгыз ташландык коены!

Хәнәфи челт-мелт күзләрен йомгалады:

— Соң бит мин.. әллә дим...

— Әллә дә әллә! Ә бәлкем ул тросны печән-салам тарттырганда ук тураклап бетергәннәрдер? Ә син һаман миннән таптырасың.

— Соң анда Кама уртасында берәү интегеп ята лабаса! Җитмәсә, тышта җәяүле буран...

— Сез үзегез җәяүле буран! Дөнья мәшәкатьләреннән котылып, инде үз җаема әкрен генә кыймылдап ятыйм әле дисәм, ургылып кына ла керәсез!

Хәнәфинең дә тавышы кинәт каяндыр, бөере яныннан ук күтәрелеп, калын ирен араларыннан сытылып кына чыкты:

— Ярый алайсам, үзең әйтмешли «хуп». Бер-бер әмәлен тапмый калмабыз әле.

Таипов бүлмәдә йөренгән җирендә капыл тукталды һәм кинәт айнып киткән, аптыраган кыяфәт белән Хәнәфигә баштанаяк сөзеп карады — теге уң кулы белән ишек тоткасына ябышкан иде.

— Тукта, җен орган! Тукта! Кама уртасында, димсең.. тфү, анысы да кода! Әзер машинаң бармы?

— Булмаска. Мастерской ишек алдында гына.

— Әһе, бар алайса, машинаң белән кил әле син кәнсә янына — Таипов бер кулы белән такыр баш түбәсен кашыштырды, икенчесе белән чөйдә эленеп торган билле туныша үрелде.— Менә сиңа аяклы казалар...

Әлбәттә аңа — кичәге директорга — бүтән берәү өчен проблема рәвешен алган нәмәрсәне хәл итүе чүпкә дә тормады: телефоннан гына шалтыратып, төенне чишеп җибәрергә бик тиз әмәлен тапты.

Ул совхоз кәнсәсеннән урамга чыкканда, «МАЗ» кабинасы янында Хәнәфи көтеп тора иде инде.

— Әһе, рульгә үзең утырмакчысың, ярый, хуп. Менә болай, Хәнәфи туган, син туп-туры Чаллыга, «Сельхозтехника»га чаптыр. Анда Газизов үзе дә белә, тросы да табылыр, әгәренки үз «МАЗ»ың белән генә өстерәргә чамаң булмаса, өстәп машина да сорарсың. Ул Гайнан, оешмаган алла колы, шуны да абайламаска, Чаллысы борын төбендә генә бит югыйсә.— Таипов сукрангандай иттерсә дә, аның йөзенә елмаю иңгән, гомумән, абзыйның төс-кыяфәттеннән: егетлектән мәхрүм түгел әле без, дигәнрәк чалым аермачык сизелә иде.

— Карале, ни... Хәнәфи...— Таипов инде кабина күтәрмәсенә басарга итенгән Хәнәфинең җиңеннән эләктереп алды, тавышы ничектер бөтенләй йомшарып, хәтта пышылдауга күчеп куйды:— Син... ни... кайткач, миңа киләлмәс идеңме, ә? Хатын да өйдә юк, япа-ялгызым аулак-

та утырам. Сулышны-сулышка кушып дигәндәй, бер сөйләшеп утырырга, ә? Иренмәсәң, кәнишне. Аерылышасы бит, ичмаса, бушаның идек бер, ә?

Хәнәфи, сәерсенеп һәм соң дәрәҗәдә җитдиләнә китеп, Таиповка күз төбәми булдыра алмады: тегенең каратут йөзенә шул арада моңсагыш та, инәлү дә, хәтта нәүмизлек тә иңеп өлгергән иде.

— Ярый, Яхъя Таипыч. Тегендә батып ятмасам...

«МАЗ» вак кар көртләренә зәңгәр төтен бөркеп һәм бар гәүдәсе белән шалтырый-дыңгырдый китеп тә барды.

Җил карны шәп себерә иде. Таипов зәһәр җилгә бер тын йөз тотып торгач, тун якасын күтәреп һәм олтанлы киез итекләре белән шыгыршыгыр кар изеп, урам белән югарыга, үз өенә таба юнәлде. Анда аны хатыны үтенгән һәм көтмәгәндә бүленеп калган олы бер эше көтә иң. Ләкин бу минутта Яхъя Таипычның уй-хисләре иске сандыкны яңарту-яшәртүләрдән бик-бик еракта иде.

## 6

Бүген, төшке ялга тукталгач, Рәмилә иптәшләре белән бергә ашханәдә тиз-тиз генә тамак ялгап алды да җәһәт кенә тулай торагына йөгерде. Җил-җил барып кереп, вахтер өстәленә күз салса, ни күрсен, аның исеменә телеграмма ята. Сөйгән яры Женя Мындадан!

«Алдагы якшәмбедә Мәскәүдән кичке рейс белән кайтып төшәрмен, көт, үбеп калучы Женяң».

«Алдагы якшәмбедә?» Димәк, иртәгә!

Күктән көтмәгәндә шушындый куаныч ишелеп төшсә, ни була?

Аякларың җирне тоямы? Очар кошка әвереләсеңме?

Рәмилә бүген очар кош булып та, җырланасы җыр булып та күкләргә менде! Әйе, җыр булып та!

Үз җырының моңа кадәр җырланмыйча, тыелып торган өлеше, күңелендә менә шушы көн, шушы сәгать өчен генә сакланган хәтлесе, кинәт күкрәгеннән өр-яңа төсмерләргә уралып, тышка ургылып чыкты, кешеләр ишетмәсә дә, дөньяга дулкын-дулкын булып таралып китте:

Зәңгәрсу күгемдә самолет күренде,
Сәламләп һавадан канаты тибрәнде.
Кояшым елмайды, күзләрем нурланды,
Ак лачын, бәгырем, ул синдер, ул синдер!

Серемне дә сөйлим, көемне дә көйлим,
Яшьлегем КамАЗда иртәнге чәчкә мин!..

Рәмиләнең хәлен Фаягөл шундук аңлап алды:

— Утларда янып йөргән идең, әйттем бит мин сиңа,— диде ул, сердәше өчен чиксез сөенеп.

Күңелең тулы куаныч булганда, кулыңда ут уйнамыймыни? Диварларга матур буяулар белән бергә синең якты һәм саф хисләрең дә сибелмимени, бүлмәләр кояш нурларына күмелмимени!

Ике кыз, шатлыклы тойгылар дулкынында айкала-чайкала, көлепелмаеп эшли торгач, бер заман ни күрсеннәр, культура сараеның кече залына караган интерьерын инде очлап та чыкканнар. Менә бит сизелмәде дә диярлек! Буяу-бизәү әйберләрен коридорга чыгарып куйдылар да өс-башларын аз-маз төзәткәләргә тотындылар. Смена бетәргә шактый вакыт бар иде әле, бригадир Людмила апалары аларны нинди эшкә кушар икән: спорт залындагы измә сылаучыларга булышырга җибәрерме, әллә «кафе-бар» дигәненә бүгеннән үк бизәү төшерә башларга диярме?

Алар шулай икеле-микеле баш ватып торган арада, бригадир Людмила Крутько яннарына килеп тә басты, чакырып-дәшеп тә йөрисе булмады үзен. Сынаулы карашы белән интерьерны буйлап та, иңләп тә чыкты, аннары ике яңагын да чокырайтып елмайды да тел шартлатып алды: димәк ки, мактавы.

— Кипкәч, ни әйтер бит әле,— дигән булды Рәмилә.

— Әйбәт дияр! Булдыргансыз! Инде хәзер нишләтергә икән сезне? Күкләргә чөеп мактаргамы, әллә... кабып кына йотаргамы?

— Кабып йотарга!

— Чәйнәмичә генә.

Бер рәхәтләнеп көлешеп алдылар. Моның соңында Людмила Крутько, маңгаена төшкән сары чәч тәлгәшен генә төзәтеп куйды да, гөлдәй балкып торган Рәмиләгә текәлде:

— Сиңа, чибәрем, кичке мәктәпкә барасы бит әле, аңарчы дәресләреңне дә караштырып куярга кирәктер, иеме?

— Бүген шимбә бит — кичке укү юк. Мин, Мила апа, авылга, әни янына кайтып килермен дигән идем. Инде ике атна кайтып күренгәнем юк.

— Авылга? Бик әйбәт, кайта гына күр. Сиңа алай озак күренмичә тору килешми дә, ярамый да, кызый! Кайткач, әниең белән әтиеңә миннән бик күп сәлам ирештер, иң матур теләкләрдә калды диген! Алайса...

Бригадир Людмила Крутько мәсьәләне шактый кызу тотты. Алар тирәсенә янә бер-ике кыз тартыла төшкән иде, Людмила апалары һәммәсен бер караш белән иңләп алды:

— Рәмиләбез бүген туган авылына кайтып китмәкче икән. Ә тышта буран кубарга җыена сыман. Иртәрәк кайтып китсенме? Җибәрәбезме, кызлар?

Бу минутта: «Женя Мынданың телеграммасы хакында белми әле. Их, аны да белсә идеме!» — дигәй уй Рәмиләнең күңелен кымырҗытып узды.

Иптәш кызлары исә, дәррәү кубып җавап кайтарды:

— Җибәрмичә... Кайткач, солдат абыең иңнәренә тау-тау сәламнәр аудар, яме!

— Бер килеп күренсен әле, ичмаса!

И рәхмәт яугырлары!

Рәмилә тулай торагына таба очты. Бер сулыш белән диярлек үзенең бишенче катына йөгереп менде. Бүлмәсенә кергәч, эш киемнәрен салып атты да, аларны стенадагы шкафка урнаштырды, моның соңында душ бүлмәсенә сугылып, краннарны боргалап карады: и боларына да мең рәхмәтләр инде, соңгы араларда суның ни кайнарыннан, ни суыгыннан өзмиләр. Түйганчы кинән!

Тиз генә юынып, чистарынып чыгар да өстенә җылырак киемнәрен кияр. Башына, әлбәттә, мамык шәлен урар... Тик былтыр сатып алган кышкы пальтосы гына шәптән түгел инде, шактый ук туза төште, инде күкрәк тирәләре, иңбашлары кыса, якасы да кыршылганрак. Әнисе аңа: «Унынчыңны бетергәнче житсен ыштубы!» — дигән иде. Ә кызлар монда хәйран шәп киенә, авылдан килгәннәре дә мода җәһәтеннән әлләниләр кыландыра, кала кызларыннан һич калышмый. Кибетләрдә менә дигән, модный пальтолар исәпсез. Рәмиләнең әллә ничә тапкыр шуларны кереп караштырып йөргәне булды инде. Туплаган акчасы да җитәрлек. Ләкин, сабыр, сабыр, Женя Мындасы кайтсын әле, бергә-бергә карап йөрерләр, бергәләп сатып алырлар. Пальтоның иң һәйбәтен, иң моднынен, иң шәп мехлысын! Якасына карап, иң модный хатын-кыз бүреге тагын! Сатып аласы әйбере иң әүвәл аның күңеленә ошасын!

Әллә абыйлары Айдаш белән Вәсимнең сменадан кайтуларын көтәргә микән? Алар бу атнаны нишләмәкчеләр, авылга кайтырга исәпләре бармы икән? Ә юк, бу суыкта, бу ачы җилдә мотоциклда ыжгыртып кайтканчы монда... Олы юлга чыкса, шушындый көнне берәр сакалбай-шофер Рәмиләне туган авылына хәтле үк илтеп куймасмыни?

Кайткач, әлбәттә, әнисе-әтисе, Рәмзи абыйсы белән күрешер-сөйләшер дә Туры бабаларына барып килер, аннары клубка чыгып, бер кинәнеп кайтыр. Әнисе мунча ягып куйган булса, бүген кич керер, өлгермә-

гән булса, иртәгә иртүк үзе ягып җибәрер, парланып, җиңеләеп һәм саф-ланып чыгар. Ә төш тирәләрендә инде кире Чаллыга кайтыр да кич булганын көтә башлар. Анда инде аэропортка элдертер... Моңа кадәр Рәмиләнең сөйгәне Женяны ерак сәфәргә ике тапкыр озатып җибәргәне генә булды. Каршы алганы әлегә кадәр юк иде. Хәер, моңа чаклы егетнең телеграмма сукканы да булмады ич. Ә бу юлы суккан! Димәк, сагынган, бик-бик сагынган ул да! Рәмиләсен тизрәк күрәсе килгән!

Авылга әле бик күптән түгел генә тектереп алган, алсу өслектә күксел яшеннәр яшьнәгән, саргылт-яшел йолдызлар җемелдәшкән күлмәген киеп, башына да мамык шәл астыннан шундый ук яулык кыегын ябып кайтыргамы әллә? Монда аны бер киеп күрсәтүенә, бүлмәдәш кызлары һуштан егыла язды. Тегендә туганнарының да исе китмичә калмас, ә инде клубка чыгып, берәр җиллерәк биюдә шул күлмәк итәкләрен җилфердәп, бөтерелеп күрсәтсәме! Ә юк, юк, аны иң әүвәл Женя үзе күрергә тиеш! Бу затлы материяне ул бик ерак бер сәфәреннән алып кайтып, Рәмиләгә унҗиде яшь тулу уңае белән октябрь уртасында бүләк иткән иде — зәвыгы хәйран аның, сөйгән ярының күңеле ни теләгәнен, аңа ни килешәсен бик белә! Яңа елга күп калмады инде — нибары бер атнадан чак кына артыграк. Менә кайчан киячәк ул аны! Женясы аңарчы, әлбәттә, бер кая да китеп югалмаячак, бергәләп берәр мәҗлесфәләндә катнашырлар, һич югы тулай торакның кызыл почмагына төшәрләр. Әнә шул чакны инде Женясы да, бүтәннәр дә яшенле-йолдызлы «кырлар чәчкәсенә» бер сокланып куйсыннар әле! Әйе, иң әүвәл сөенсен үзе!

Ә хәзер исә Рәмилә кичке эңгер куерып киткән бүлмәнең түренә үтеп, тәрәзә каршысына басты. Тышта, болай таба кыекланып торган йортларның байтак тәрәзәләренә ут кабынган, ә шактый арырак, сыек буранлы рәшә эчендә, басу түрен кисеп, үткән олы юлда автомобильләрнең фара яктылары чабыша — елга кебек ут агыла диярсең.

Тәрәзәдән бөркелгән салкынча, әмма йомшак һава дулкынының рәхәтен тойган халдә, ике кулын да күтәреп тыгыз күкрәкләре өстенә салды да күзләрен йомды. Инде әллә ни күп көтәсе калмады... Әйе, вакыты житкәч, әйтер ул аңа:

— Менә, бәгърем, тәнемне дә, җанымны да синең өчен саф көе, керсез көе саклап килдем. Инде теләсәң нишлә минем белән,— дияр.

Бәлкем, РИЗне худка җибәрүләрен дә, Рәмиләнең кичке мәктәпне тәмамлавын да көтмәсләрдер әле. Үзе ни дияр бит?

Киң дәрья буенда ак кала салабыз,
Чаллыда ялкынсыз янучы бер минме?
Җил-давыл уйнатып яныма килерсең,
Шашынып үбәрмен үземнең тиңемне!..

Бер кадәр вакыт үтүгә, «кырлар чәчкәсе» җәйнең-җәй буена көязләнергә бик тырышып та, кышка кергәнче көязләнеп бетә алмаган Муса Җәлил проспекты буйлап, инде шактый көчәеп киткән җәяүле буран эчендә, әмма үзе дә чокыр-чакырлар аша бик тә җилле сикерә-атлый, зур күзләре караган тарафка элдертә иде инде.

## 7

— Син, Хәнәфи энем, турысын гына әйт әле: үзебезнең Әҗердә сиңа авыз тутырып, күбәүләрме «жизни» яисә «кода» дип эндәшә? Бик күпләрме, дим?

Яхъя Таипыч табынны фолындай иркен өенең түр ягына әзерләгән, әмма ул табада бәлеш төбе кыздырырга яки чәй куярга алгы бүлмәгә, газ плитәсе янына да чыкмыйча булдыра алмый һәм керган-күренгән арада диванда җәйрәп утырган кунагы Хәнәфигә әнә шулайрак дип төбәлә иде.

— Соң, алай әллә ни күп түгел түгелен, әмма дәшми йөрмиләр,— ди монысы.

— Дәшсәләр, эрепләр дә китәсеңме?

— Эремичә. Хәер, төрле чак була: кәеф ничек бит, шарты тагы...

— Менә-менә: хикмәт кәеф белән шарт дигәнендә! Яшьрәк чакта минем дә шартлар шәптән иде: авылда өч кенә бөртек кеше миңа шулай эндәшә торган иде. Һы, тансык булмый ни! Ә хәзер? Ыру-тамыр, туган-тумача һай ишәйде, һай җәелде. Инде куян шулпасының шулпасы гына да түгел — кул, диңгез!

Хуҗа, иңе аша салынган чуар башлы сөлгегә кулларын сөртә-сөртә, янә чыгып китә, ә Хәнәфи шоп-шома итеп кырылган какча яңакларын учы белән сыпыргалый-сыйпаштыра утырып кала.

Монда килгәнче, өендә мыштым гына кырынып, көязләнеп маташкан чагында, хатыны Рәсүлә аңа: «Син нәрсә, көндезләр беткәнмени сиңа? Әллә кызлар җанына, төнката аулак өйдә утырмага җыенасыңмы, карт-лач?» — дип күз чекерәйткән иде. «Әйе, аулак өйгә — тап өстенә бастың, карчык!» — дип, ярыйсы ук эресымакланып, җавап кайтарды аңа Хәнәфи. Аңлатып бирүенә хатыны ботлар чапты: «Кит аннан! Әстәгъфирулла диими, Таипов була торып Таиповмы?!» Рәсүләнең авызында сүз тормаучанрак, түзмәгәндер, күршеләрнең берәрсенә кереп: «Шулай-шулай бит әле, безнеке Яхья Таипычка аулак өйгә эчләр бушатырга китте бит әле, әкәмәт!» — дип, төрле имеш-мимешне күпертергә оетки салып чыккандыр инде. Әй, салса соң, имеш-мимеш таралса соң? Директор булып эшләде дигәч тә, Таипов кеше түгелмени?

Ниһаять, табынга олы табада бәлеш түбе килде, өстәл читендәрәк, кайнар буын бөркеп, чәйнек тә урын алды. Табын әзерләүнең ни икәнен юньләп белмәгән хуҗага хатыны югында ризык-нигъмәт хәстәрләве җиңел булмады ахры: Таиповның җәенкерәк борыны һәм маңгай җыерчыклары өстенә бөрчек-бөрчек тир бәреп чыккан иде.

— Әйдә, Хәнәфи энем, гаеп итештән булмасын, җиңел кулдан гына инде,— ди-ди ул табын күрке бәлешне кунагына таба этебрәк куйды, аннары уртада җем-җем итеп торган җыйнак кына графинга үрелде, рюмкаларны чыңлатып алды.— Кабарга менә тозлы кыярдыр, кәбестәдер. Әйдә, исәнлеккә-саулыкка! Менә шулай. Тегендә, Кама өсләрендә, дим, чынлап та ай-һай булгандыр шул, ә?

— Әйтәсе юк. Анда тәгәрмәч төпләреннән, ягъни боз арасыннан фонтан булып су бәреп ята! Нефтьчеләрнең ике машинасы чумган, арырак тагы бер «Волга»...

— «Волга»?

— Әйе. Нәчәлнигы, күрәсең, корыга чыгып, Чаллының үзенә шылган җәтрәк. Ә шоферы, мескенкәй, нибары курткадан, ботинкадан гына. Төнгә каласы булса, машинасы да, үзе дә Кама уртасында шакыраеп катасы иде.

Итле бәлеш галәмәт тәмле иде, тозлы кыяр белән кәбестә дә бик һәйбәт — кабуга эреп кенә китә. Таипов елтыр графинга янә үрелгән чагында, ниһаять, сүз дилбегәсен баягы тарафка тартыбрак куйды:

— Шулай, туган, баҗалар, кода-кодагыйлар, балдыз-кайнешләр үзебезнең Әҗердә ярты авыл, инде хәзер Гәрдәле белән Чуарда да әллә ни хәтле. И яшьрәк чакта рәхәт булган шул! «Кода» дип әйтүләренә алай бик үк таралып төшмәсәм дә, «җизни» дип җибәрсәләр, ипидер, эреп кенә китәр идем. Андыйларга учы-учы белән көнбагыш өләшер идем. Кесәмә юри тутырып йөртер идем. Ә хәзер, өләшәм дисәң, җилкәңә биштәр асып йөрергә кирәк, билләһи!

— Алай ук түгелдер лә,— диде Хәнәфи, көлемсерәп.

— Һи, эш башында утырып карале, Хәнәфи туган! Синең дә нәсел-нәсәп тамырларың шактыйга җәелгән кебек, һәммәкие дә бик тиз сиздерер үзен менә шул чагында. Һы-һы! Әле без синең белән, Хәнәфи, чын-

лап торып, нечкәләп, тамыр очларын тикшереп караганыбыз юк, шөкер, хатыннар да житенне бик үк талкыштырмаган. Бәлкем, синең белән дә узара кода-мазардыр, ә? Һы-һы, ярый, булмавыбыз, дөресе, аны белмәвебез хуп.

Хәнәфи, үзенчә тирән мәгънә салып, баш каккалап алды:

— Анысы шулайрак инде, Яхъя Таипыч, адәм баласы ничек тә власть тирәсенә, түрәләргә сырпаланучан...

— Ә син миңа үзең ник сырпаланмыйсың? Нигә һич югы «кода» дигәнен актарып чыгармадың, ни жебеп йөрдең, ә? Югыйсә түтәлләр янәшә бит, нәсел-нәсәп орлыклары көчми калмагандыр, дим. Димәгән ки, хикмәт адәмнең үзендә. Тамырларында типкән каннары һәммәкиенең дә кызыл төстә, әмма ләкин тибү җайлары төрлечәрәк, күрәмсең.

«Эһе, керә башлады бу чытырманлыкка...» дип уйлап куйды Хәнәфи, ләкин үз сүзен итагатьле һәм сабыр рәвештә әйтте:

— Шуңа күрә дөнья диләр моны.

— Шулай, адәмнең төрлесе бар, әмма ләкин үз туган авылыңда яшәсәң яшә, тик баш булып йөрмә икән! Гап-гади механизатор булуыңа куанып яшә, Хәнәфи туган!

— Анысы хак: күктән алай йолдыз чүпләргә үрелгән юк үзе,— диде Хәнәфи, ипле генә ым кагып.— Шулай ук адәмнәр арасында ерганак ерып азапланганым да булмады шикелле.

— Шуңа, дим, куанып яшә! Яңа директор Акбашевка: «Минем монда үз туган авылымда хәлләр шулайрак бит әле, бик тә хикмәтле»,— дип төшендерергә тотынган идем, авызын ерып көлде генә: «Минем дә, ди, үз туган авылымда байтак кына вакытлар колхоз житәкләгәнем булды, нәсел-нәсәп тә ярыйсы ук ишле иде, әмма ләкин туган-тумачаның алай басымчаклык иткәнен тоймадым»,— ди.

— Шулай диме? — Хәнәфи, яңа директор турында сүз купкач, ак күлмәгенең изү төймәсен ычкындырып, муенын суза төште, терсәгенә таянды.

— Шулай димичә, яшьрәк чагы бит: кардәш-ыруы, күрәмсең, ишәеп, әле тармак жәяргә өлгермәгән. Бәлкем, аяк арасында буталучыларны үзе баштук тибәрә белгәндер. Мактавым булсын, үтә дә жилле кеше! Әле сизәрсез...

— Жилле алайса?

— Жилле дә, жегәрле дә. Мин Чаллыга гариза илтеп тоттыргач, ике айга якын урыныма кандидатура эзләп азапландылар. Бөтен республика буйлап! Һич күпертмим, өлкә комитеты булып өлкә комитеты үзе шөгыльләнде шикелле. Шулай булмый ни: совхозыбыз КамАЗга орынып торганнардан ич! Күз өстендәге каш кебек. Акбашевны күргәч исләрем китте: вакантный урынга эзли торгач, тәки тапканнар бит нәкъ тиешлесен!

«Яңа директорны күкләргә чөюе белән үз абруеның да аңарчы түбән булмаганлыгына, күр, ничек оста ишарә ясый, ә!» дигән уйдан Хәнәфинең авызы жәелә төште, тик алай да ул, бу хакта сүз катмыйча, ыспай гына колак торгызып тыңлавын белде. Яхъя Таипыч исә кинәт авыр сулап куйды һәм әйтер сүзенә дә гер элгәндәй иттерде:

— Ә минем монда аяк-куллар тәмам чәбәләнгән инде. Башны кемнәр ашады дисәң, шул инде, кардәш-ыру, туган-тумача, аерата Гарәфша кода кебекләр!

Хәнәфинең күңелендә: «Бар абыну-чәбәләнүләреңне нибары туган-тумачаң иңенә аудару дөрес булырмы икән? Кардәш-ыруыңны бөтенләе белән эт эчәгесенә тиңләп хаклыкка хилафлык кылмыйсыңмы соң, Яхъя Таипыч?» дигән сорау купкан иде кубуын, ләкин аның Гарәфша турында да уй-фикере күптән өлгергән, күптәннән анык — иң әүвәл соңгысын ярып салырга итте:

— Гарәфшаны белмәскә?! Аның ише болганчык суда балык сөзәргә яратучыларны эзләп табасы әле. Ата комбинатор!

— Шулай: иң атасы. Ни җитми кешегә? Урыны җылы, элекке кыланмышларын да кичергән идек югыйсә. Ә ул һаман үз юлында. Соң, җәен сугаруга торбалар китерткәндә минзәләлеләр белән алыш-биреш итешүләре, ә? Ярый әле, болыннан печән ташырга тотынгач, койрыгына баскандай иттек, алай да шушындый кытлык елны ни кадәр печәнне сулга шылдырган — чуртым белә. Андыйларга бит дөнья ни кадәр болганып торса, шул хәтле шәп!

— Характеристика да сорап тормады бугай?

— Сорар сиңа: имеш, гөнаһсызга рәнҗетелгән. Тфү, бакыр елан! Шул инде, чыбык очың туп-туры Каракай башкисәрләренең берсенә барып тоташсын ди сиңа, бүтәнчә булсын, ди.

— Каракай дидеңме?

Авыл халкы телендә батыр сыманрак йөртелгән кеше турында Хәнәфи алай ук ямьсез уйларга гадәтләнмәгән иде, аның хәтта гәүдәсен нидер кымыржытып узгандай булды.

— Һы, шуларга барып тоташмый сиңа. Авылда итәк астыннан ут уйнатып, дөньяны төтенгә сасытып ятулар Әҗердә кайчан тамыр җәйгән дип беләсең? Шул заманда булмый сиңа, кайчан тагы? — Яхъя Таипыч, йөрәгенә түзә алмады ахры, утырган җиреннән капыл кубып, шыгыр-шыгыр бүлмә буйлап йөренеп китте.— Каракайлардан калган тамырлар берәр кайчан корып бетәрме безнең авылда, юкмы? Ник дәшмисең, Хәнәфи? Каракайлык берәр көнне бетәрме, дим?

Монысы аптырашта калды: авылдашлары хакында шушылай киң һәм күңелсез нәтиҗәләр ясарга аның һичкайчан уена килгәне юк иде. Ни дип җавап кайтарырга белмәстән, сүзне, авыз кыйшайтып кына, икенче тарафкарак боерды:

— Ә Гарәфша, Чаллыга киткәч, Камснаб хәтле Камснабның үзенә борын тыккан ди, әнәтерә.

— Тыгар да. Әшнә өстенә әшнә өелгән бит аның Чаллысында да, атын алгыры!

— Чуртанны олы күлгә җибәргән кебегрәк булды шул.

— Үзебез җебегәнгә, үзебез!

— Анысы, бәлкем, шулайдыр. Әмма гаеп башкаларда гына микән, Яхъя Таипыч?

Таипов ишеккә таба атлаган җирендә тукталып, болай таба борылды һәм, табын янына килеп, Хәнәфи янәшәсенә утырды да өстәл читенә таянды. Аның күз карашын, юк, аптырау-каушау да, рәнҗү-үпкә дә түгел, тәмам алҗу-хәлсезләнүдән туган сәер бер томан каплаган сыман иде. Хәнәфинең аңарда мондыйны беренче тапкыр күрүе иде.

— Катырак орындың түгелме, Хәнәфи энем? — Моны пышылдап кына кысып чыгаргач, ул карашын читкә күчерде, уфылдап куйды.— Хәер, катырак булса соң, чын дөреслеккә тартым лабаса. Йомшарган агачны ни баса ди? Кортмы? Мин менә шушы кулым белән Гарәфшаның гаризасына имза салсам, шул ук көнне, дөресе, шул ук кичне шушы ук кулым белән үзем дә гариза яздым... китүем хакында. Әмма ләкин шәһәр комитетына илтергә ашыкмадым, гаризамны менә монда күкрәк кесәмдә, йөрәк янында ай буе диярлек асрап йөрттем. Шундук ерткалап ташларга нишләптер йөрәгем җитмәде. Бер какшасаң, шулай икән шул, их, чәнчелсен лә инде!

Таиповның күз карашы гына түгел, бөтен төс-кыяфәте хәтәр үзгәреш кичергән иде: кушыла язган калын кашларын әйтәсе дә юк, аның тирән җыерчыклы маңгае һәм аңа ялганып киткән баш шомасына да тимгел-тимгел булып кызыллык иңгән иде. Югыйсә әллә ни күп тә эчмәделәр — аның рюмкалары да нибары уймак хәтле генә, сыйдырган эчемлеге кече телне чылатырлык кына — Яхъя Таипычка хәмер ярамаганлыгы әллә каян беленә иде. Ә бәлкем аның чуалчык уй-хисләре әнә шул рәвештә тәненә үк бәреп чыккандыр? Хәнәфинең күңелен кинәт кызгану хисе эсселәтеп җибәрде.

— Саулык булсын, Яхъя Таипыч.

— Дөрес, саулык булсын. Әмма, кызганыч, анысы да соңгы вакытларда ташкүлчимгә генә калды шул.

— Ә мин сине, Яхъя Таипыч, алай бик үк җебеп төшкән димәс идем. Бар әле синдә дилбегәләр кагарлык кына җегәрләр!

Таипов кунагына төбәлеп карады:

— Син моны ихлас күңелдәнме?

— Ихластан!

Хуҗаның йөзенә бераз нур кайтты сыман, иреннәре җәелә төште, калын кашлары да җай гына селкенгәләп алды. Тик маңгай өсләрендәге кызыл тимгелләр генә әле һаман таралып-сеңеп бетә алмый иде.

— Шулай да кыен әле. Бер хәлдән икенче хәлгә атлап чыгулары дим. Һай кыен, белсәң иде, Ханәфи! Әйе, хушлашу көне килеп җитә икән лә шулай бер заман. Җитмәсә, совхозны да авыррак хәлләрдә тапшырам шул. Аз гына түзсәм, шушындый кыен елны гына уздырып җибәрсәм соң? Булмады, сабырым җитмәде, җен оргыры. Ә бит баштарак, алланың кашка тәкәсе сыман, һич аны-моны уйламыйча йөргән буласың. Ә көне килеп җитә барыбер! Дөньяда бер мин генәме соң шулай? Юк, күпләрдер, бик күпләрдер!

— Өметсез шайтан булмыйк сана, Яхъя Таипыч!

— Рәхмәт, Ханәфи энем, жылы сүзләреңә! — Таипов шулай дип, уң кулын кунагының иңбашына салды.— Синнән яшерә дә алмыйм, яшерәсем дә килми, ә хәлкәйләрем шушылайрак: бер аягым белән тып иттереп кала җиренә китереп бассам да, ягъни үземә менә диган фатир тоттырсалар да, икенче аягым белән бот төбеннән үк туган туфракта бит әле — суырып аласы бар. Суырып алалсам да сыңар итегем туфрак кочагында ятып калыр кебек. Ятып калыр да сыңар аягым белән ялан тәпиләп китеп барырмын кебек.

Ханәфинең күз алдына бу күренеш бар бөтенлеге, бар чалымнары белән килеп баскандай булды һәм ул аны куып таратырга теләп, хәтта баш чайкаштырып алды:

— Син алай ук чайпалма, зинһар, Яхъя Таипыч. Сыңар итекләрне суырып алырлык кына көч-кодрәт бар әле синдә. Хәтта күбрәк тә! Дөнья белән алыш-биреш итәселәребез әле бетмәгән, дим.

— Әллә сүз куешкансыз инде: тегендә, шәһәр комитетында да шулайрак дигәннәр иде киңәш-табыш итешкәндә.

— Кем?

— Кем, кем... соң Низамов инде! Беренче үзе! Чын әгәр, үтәли күрә, чукынган! Аның белән бер гәп корып җибәрсәң...

Әнә шулай үз хәлләрен авыл хәлләренә ялгап, авылныкын дөньяныкы белән талкыштырып, байтак сөйләшеп утырды бу кичне сугыш утында да янган, хезмәт ялкынында да көйгән ике ветеран.

* * *

Өй жылысында һәм тынычта утырган чакларында җәяүле буран инде бик бимазаламый сыман иде: ни тәрәзә өлгеләренә каты-каты орынып китми, ни морҗада шомландырып уламый иде.

Әмма юк икән әле, җил бөтенләй үк тынмаган икән: кунагын капка төбенә кадәр озата чыккач, Таипов тун якасын күтәрмичә булдыра алмады. Аның өе олы урамнан чак кына эчкәре кереп торган тар тупый уентыаралыкта урнашкан иде, әмма җил монда да әле теге яктан, әле бу яктан килеп, әйбәт-әйбәт кагылып уза иде.

Капка төбендә, җилгә арканрак басарга тырышкан хәлдә, беравык дәшми-тынмый тордылар. Клуб моннан әллә ни еракта түгел иде, ул яктан тонык кына булып музыка ишетелә, яшьләрнең көлешкән авазлары яңгырап куйгалый иде. Әнә олы урам белән, җәяүле буранны тагын да көчәйтеп җибәрергә жыенган сыман, выж-выж әрҗәле мотоцикл узып кит-

те. «Иж-планета» булдымы ул, әллә «Урал» идеме — Хәнәфи абайламыйча калды. Бу ачы җилдә кайсы исәре юл чыгарга исәп итте икән? Хәер, исәргән башлар азмыни бүгенгесе көнне?

Яхъя Таипыч, ыжгыртып узып киткән әрҗәле мотоциклны әллә күрмичә калды, әллә күреп тә аңа бөтенләй ис-өн җибәрмәде, капыл гына Кама бозында бәлага тарганнарны исенә төшерде.

— Казага юлыкканнарга вакытында ярдәм кулы сузу — аңардан да саваплырак эш бармы икән, Хәнәфи туган?

— Савабы саваптыр, әмма адәм үзе дә шундый чакта сынала.

— Хак сүз. Ә җәяүле буранны минем җенем сөйми.

— Нишләп? Котырма буран әллә шәбрәкме?

— Анысында аның, ичмаса, кеше ни буласын чамалый, тыелып тора. Ә җәяүле буранмы? Авылда ул әллә ни түгел кебек, әмма кырга-яланга чыксаң... Шул инде адәмне саташтыра да, адаштыра да!

Бер-берсенә хәерле кич, тыныч йокылар теләп, куллар кысышкач, Хәнәфи шыгыр-шыгыр олы урамга таба атлады, ә Таипов борылып ихатасына керде. Кергәч, болдырга таба атларга ашыкмыйча, капка баганасына сөялеп, күзләрен йомды.

Аның күңеле хәзер инде ярыйсы ук тынычлана төшкән, җаны әллә ни айкалмый сыман иде.

Ләкин күзләрен ачып җибәрүенә, кинәт бар гәүдәсен өшетеп салкын дулкын йөгерде: ихатаны әйләндереп алган шәп-шәрә каралты-куралар, аерата ни гомер инде сыер-тана мөгрәүләре, сарык бәэлдәүләре, ә үткән көздән бирле каз кыйгылдаулары, тавык кытаклаулары ишетелмәгән җылы абзарлар, үтә дә шомлы булып күренде аңа төн караңгысында.

Өенә кергәч, шул көе — өстеннән ни билле тунын, башыннан ни йонлач бүреген салмаган көе — ян сәкегә килеп утырды. Аяк очында идәндә иске, инде хәзер ярыйсы ук ныгыган һәм яшәргән сандык. Түр якның ишек пыяласы аша сөзелеп төшкән яктыда сандыкның бер иш калае, тонык кына булса да, ялтырагандай итә. Үрелеп сандыкның эчен ачып карады, тагын ябып куйды. Аннары, тирән-тирән сулап алгалагач, сандыкка төбәлгән хәлдә, әмма күз алдында хатыны Марзияне тотып, акрын гына иренен кыймылдатты:

— Бөтенесен дә сыйдыра алыр микән, карчык, бу нәрсәң? Ә бит һай күп алар, иң кадерле һәм иң якты истәлекләр! Күпмесе кала әле! Әнә түшәмдә сиртмә бөҗрасы — балаларның һәр кайсын бишектә тирбәндереп торган затлы тимер, ә менә монда олы мич — ни хәтле тәмле-томлы ризык пешермәдең син аңарда! Бары, бары да кала! Әле сагынырсың! Сагындырыр арт бакчадагы миләш белән куралар да, капка төбендәге чирәм дә, күрше-күлән белән кичләрен гәп корып утыруларың да.

Ә картың, ягъни үзем? Язын беренче ярган буразнадан килгән туфрак исен яисә серкә очырганда тирбәлгән арыш-бодай дулкыннарын әйтмим дә, хәтта авылдашларга акыл өйрәтәм дип, ызгышуларымны да искә төшергән саен зар-интизар булырмындыр. Үткән елларны, узган гомерне бер сандыкка гына сыйдырып буламыни?

Тормышны яңартабыз, дип ду кубабыз. Ә бит аякны туган туфрактан суырып аласылар бар әле. Суырып аласылар...

## 8

Юлга канатланып-очынып чыккан Рәмиләне, туган авылына кайтып төшсә, бик күңелсез яңалык көтә икән: әле җәй башында ук, аны да чиксез кызыктырып һәм иләсләндереп, зур төзелешкә китеп барган чаяүткен сабакташы Шәмси Әминәсе, тулай торакта кешe әйтеп ышанмаслык тәртипсезлек эшләгән ди, аның яман хәбәрен ишетүгә, ни юаш, ни сабыр әтисе, йөрәгенә чыдый алмыйча, кызын эшеннән дә, торагыннан да чыгартып, үз өенә алып кайткан ди.

Бу ямьсез хәлне Рәмиләгә әнисе Рәсүлә, өстәлгә табын әзерләргә керешкәч, гадәтенә сеңгәнне дә онытып, ягъни кызының хәл-әхвәлләрен юньләп белешеп тә тормастан, бердән тезеп салды.

— Мактарлыгы булса, мактарлар ие, ә җаман хәбәр ябалак канатларына атланып кайта да, бөтен авылны бетереп, кычкырып җөри ул, олан.

Рәмиләнең йөрәге жу итеп куйган, күз аллары караңгыланып киткән иде. Аның: «Юк, юк, булмагандыр андый хәл!» — кычкырып җибәрәсе килде, ләкин кычкыра алмады, тавышы сынып, әнисенә пышылдап кына төбәлде:

— Ә ни кылган соң ул?

Ләкин әнисе кызының агарынып киткән йөзенә дә, сынып-сытылып чыккан тавышына да игътибар итмәстән, һаман да шул зәһәрле рәвештә үзенекен дәвам иттерде:

— Ирекка ирештем дигәч тә, үз-үзеңне белми кыйланып җөрсәң, шулай булмый ни!

— Ни булган, ни кылган, дим!

— Мин алар белән тулай торакта бергә иемме әллә? Бүлмәдәш ике кыз ике җегетне балкон ашамы, әллә вахтерларына сиздермичә генә, ничектер бүтәнчәме эчкәрегә үткәргәннәр дә бүлмәләрендә мыштым гына мәҗлес корып җатканнар. Ул ике җегетне кундырып ук калдырмакчы булганнар ахры, берсе исергән дә төн уртасы авышканда акырып җырлап җибәргән бугай — шундук өсләренә басканнар. Кызлар торагында андый хәл өчен баштан сыйпамыйлардыр, моны үзең миннән шәбрәк тә белә торгансыңдыр әле?

— Белмичә!

— Беренче кыланмышлары гына булмаган ахрысы: җыелыш җыеп, бик хәтәр тузынып, тулай торакларыннан сөрергә үк җыенганнар, ди, әмма әтисе, вакытында барып җитеп, бу ахыргы хурлыгыннан җолып калырга өлгергән.

Авылда олы төзелешкә китеп эшләүче яшьләр әллә ни хәтле — кырык-илледән дә ким түгелдер. Моңарчы һичберсенең андый ямьсезлек кылганы юк, бу җәһәттән шылт иткән аваз да ишетелгәне булмады, инде макталып телгә кергән кызлар-егетләр дә аз түгел. Әмма макталганның даны нибары үзе һәм иң якын кешеләре өчен генә кебек, ә менә яманлык кылганның хурлыгы бик күпләргә зур күләгә булып төшә, син дә керсез күңелең, якты омтылышларың белән аның яманатын үз иңнәреңдә күтәреп йөртергә тиешлесең. Дөньяның нинди гаделсезлеге бу?

— Инде әнәтерә: ни укуда түгел хәзер, ни эштә. Урамга чыгып йөз күрсәтерлеге дә калмаган, өендә томаланып җата ди. Ә сабакташ кызлары исә, бернинди хәсрәт белмиенчә, җөреп җаталар мәктәпләренә.

Рәмиләнең элгәрәге кайтуларында да әнисе, Чаллы төзелешеннән күңелсезрәк, яманрак хәбәрләр ишетеп, аларны чәйнәштергән чагында, үзенең сүзен әнә шулай: «Анда интегепләр эшләп тә, укып та җәфаланганчы, кайта гына күр үзеңнең иркен өеңә, үзеңнең җәшлек рәхәтлекләреңә!» — дигән рәвештәрәк, ап-ачык үгет-чакыру белән төгәлли, җаен үзенең йомшаклык кылып, бердәнбер кызын җилләр уйнаган мәхшәрле тарафка очыртып җибәрүгә риза булуларына кат-кат үкенә иде. Ә хәзер, Шәмси Әминәсе китереп чыгарган хәлдән соң, ул инде мәктәп директоры белән дә барып сөйләшкән, теге исә Рәмиләне мәктәпкә кире алырга ике куллап риза булган икән. «Укуында азрак аерма туган икән, анысын гына тиз бетерер, башлы кыз ул, аның каравы, русчасы шомара төшкәндер — монысы аерата әйбәт», — дигән имеш.

Әнисенең тавышында хәзер ачы зәһәрлек сизелми иде инде.

— Кичкедә дә минем уку начар бармый, соңгы вакытларда икеле алганым юк. Эшем дә әйбәт — хәйран шәп безнең бригада!

— Икеләләр алмый, хәйран бригада, имеш! — Әнисенең тавышы капыл гына янә кырысланып китте. — Ә тормышның бүтән җаклары?

Ахыры житеп, үзең дә чоңгылга бер төшеп киткәнеңне күтәсеңме? Әтиең җәисә абыйларың сине дә берзаман җилтерәтеп апкайтсынмы?!»

Карыны шактый ачыгып кайткан булса да, Рәмиләнең ризык кабарлыгы калмаган иде. Ул бер-ике чынаяк кайнар чәй генә эчеп куйды. Әнисе кузгаткан юнәлештә ары таба сүзне һич кенә дә куертасы килми иде аның. Куертасылары әле алда булыр — монысында һич шикләнмәскә мөмкин иде. Борын мышкылдатып, бермәл тын гына утыргач, кыз кыюсыз гына:

— Әти кайда соң? — дип сорап куйды.— Рәмзи абый да күренми.

— Атаң Яхъя Таипычка кич утырмага дип менеп киткән ие. Ә Рәмзи абыеңмы? Соң ул сине алырга дип мотоциклында Чаллыга очкан иде ләбаса, әле әйтмәдеммени? Юлда аймыл булгансыз, күрәмсең. Ул тегендә Айдаш абыең белән Вәсим абыеңнарга да сугылмыйча калмас, бары бер булып кайтып төшүләре бик тә ихтимал.

Менә шул чагында гына ана кешенең, җыен күңелсез һәм шыксыз сүз-хәбәрләр аркасында миңгерәүләнеп торган зиһене, ниһаять, ачылып китте сыман. Йөзенә мөлаемрак, җылырак нур кайтты, тавышы да йомшаруга таба үзгәрде:

— Теге атнаны да мунчалар кыздырып көткән иек җугыйсә. Арадан ник берегез кайтып төшсен!

— Соң, ел азагы бит, тегендә яман да куыралар, әни,— диде Рәмилә, саран гына елмаеп.

— Ә бүген, ичмаса, берегез өйдә инде! Бар әле, кызым, бар, иренмичә генә эшкә тотын әле. Мин инде алай-болай кайтып төшсәләр, кер уарга-нитәргә туры килмәгәе дип, мунча казанында суны җылытып куйган ием. Син инде, теге мичгенә дә ут тамызып җибәр, утыны инде тутырылган. Аннары, бар булган савытлар, бидоннар туларлык су ташып куярсың. Сырхаулы әнәеңә барына да житешергә бер генә дә жинел түгел шул. Их, үз өеңдә, үз җаннарымда җәшәгән көйгә генә укып жатсаң, жорт эшләрендә кул арасына кергәләр иең, ичмаса!

Рәмилә шундук, бик теләп, бик рәхәтләнеп урыныннан купты: монда әнисе белән яман хәлләрне әвәләштереп, сүз чәйнәп һәм бәхәс куертып утырудан ул тәмам туйган иде. Әнисенең искерәк киемнәрен киеп алды да саф һавага чыкты. Мунча мичгенә туз яндырып ут салды, кисәүләре пыскып кына яткан казан астындагысына да, утын өстәп, ялкын тергезде. Аннары иңнәренә көянтә чиләк элде.

Тышта шактый ук караңгы, җилләп-буранлап тора, әмма бәхетләренә, су колонкасы аларның тыкрык чаты башында гына иде. Эш белән мавыкканда, ичмаса, күңеле бераз тынычлана төшәр дип өметләнде. Ләкин, юк, күз алдыннан һаман да сабакташы Әминә китми аптыратты.

Мәктәптә чагында ук шаянрак, егет-җилкенчәккә сырпаланучанрак иде шул. Әмма кайчагында, кинәт кенә айнып киткәндәй, шуклану-сырпалануларын кырт кына кисеп, ара да саклый белә иде. Тегендә, КамГЭС поселогында, аларның тулай тораклары икесенең ике очта иде, шул сәбәпле анда очрашканнары булмады да диярлек. Әминә дә, Рәмилә шикелле үк, кичке мәктәпкә укырга кергән, әмма озакламый, аның авырлыгына чыдый алмыйча, ташлаган иде. Авылга да ул Рәмиләгә карaганда сирәгрәк кайта, менә шул чагында гына алар, я юлда, я кичен авыл клубында күрешкәлиләр иде. Әминә моннан бер ай чамасы элегрәк, гадәтенчә шукланып-көләчләнеп, хәтта артыгын кыландырып һәм, билгеле, күбрәге егет-җилкенчәк хакында сөйләнеп, авызыннан саесканнар очырткалаган иде. Аңардан берни сизәрлек, бу кызый озакламый зур бәлага тарыр дип уйларлык та түгел иде. Бәлкем, ул кадәр куркыныч, яман төсләргә манчып сөйләүләрнең җирлеге әллә ни юктыр да, бәлкем, барысы да ачы оеткылар куша-куша, чамасыз күпертү генәдер? Менә боларны тәгаенләми торып, Рәмиләнең җаны тынычлана алмастыр ахры.

Әйе, мунчага су гына ташып бетерсен дә — аның миче яна, ташы

кыза торыр — ә ул, өстен-башын алыштырып һәм, әлбәттә, әнисеннән рөхсәт сорап, тиз арада гына клубка барып килер. Анда Эминәнең чын әхвәлләрен тәгәлрәк һәм әчкәртенрәк белгән берәрсен очратмый калмастыр.

Ока кызы Юлия, авылдашы Әминә шикеллеләр тегендә, бәлкем, уннан бер, юк, йөздән бер генәдер, әмма син монда бер гөнаһсыз башың белән әнә шундыйлар куптарган ачы «тузанны» йотып йөр инде менә. Аны хәтта шушы ачы җилле җәяүле буран да таратып, себереп ташлый алмый, киресенчә, күңелдәге ачысын тик көчәйтә генә сыман.

* * *

Клубка яшьләр әллә ни күп җыелмаган иде. Ел азагы икәнлеге үзен монда да нык сиздерә иде.

Ләкин, сабыр, сабыр. Яңа елга инде бөтенләй күп калмады, ул чагында шушы киң фойе хәтәр купшы бизәлгән булыр, шыгрым тулып, шаулап-гөрләп торыр!

Җыелганнарның күбрәге, әлбәттә, егет-җилкенчәк, әмма арада кызлар да — мондагылары да, тегеннән кайтып төшкәннәре дә күренгәли иде.

Музыка мул булып һәм төрлеләнеп яңгырый: әле радиоланы борып җибәрәләр, әле магнитофонны әйләндерергә тотыналар.

Бер кырыйга мыштым гына баскан килеш тик тору уңайсыз иде, Рәмилә моңа күнекмәгән дә иде, ул шундук биюгә катнашып китте. Аның өстендә «мәктәп пальтосы», башында кызгылт-көрән берет, аякларында исә шәп күннән тегелгән, каты үкчәле модный сапожкилар. Ритмны тиз тапты. Клубта ярыйсы ук салкын, күбесе пальтодан, әмма арада инде кызып өлгергән һәм өс киемнәрен салып атканнар да бар иде.

Менә Рәмилә каршысына басып, чандыр гәүдәле, кылычрак борынлы бер егет тез бөккәләргә, бил сындыргаларга кереште. Рәмиләнең аны моңарчы күргәне юк иде, егет ара-тирә авызын киң җәеп, елмаеп җибәрә, нидер әйтеп тә куя, ләкин ул әйткәннәр кызның аңына барып житми иде. «Калмаштан»,— диде ахрысы. Армиядә хезмәт итеп кайтып та бәхетен «түгәрәкли» алмаганнардан шикелле. Хәзер әнә, болар клубына килгән дә тырыша егет, бик тырыша! Хәер, мондый хәлләргә Рәмилә инде күнегеп, ияләшеп бетә язган иде. Ул, гамьсез бер кыяфәт сакларга тырышып һәм карашын әле тегеләйгә, әле болайга юнәлдереп, залны күзәтүен белә иде.

Ниһаять, ишектән түрә Гарәфша кызы Фәрхәнә килеп керде. Рәмиләнең әүвәлге сабакташы. Яшел пальтодан, башына шакмаклы шарф ураган. Тукталды. Ян-якларга карангалап алды. Укытучылардан шүрли торгандыр әле.

Фәрхәнә болай ярыйсы гына кыз кебек. Укуы да әйбәт кенә, әмма астыртынрак холыклы, укытучылар алдында юхаланучан — менә шул ягы күпләрнең җен ачуларын чыгара. Ярый, кадалмый анысы, Фәрхәнә Әминәләр күршесендә генә яши, ул шуның хәлен тикшерми-белми ятмагандыр әле.

Музыка тынуга, Рәмилә Фәрхәнә янына килде һәм, әллә ни таралмыйча гына, Әминә турында сорашырга кереште. Әйе шул, тулай торакларында әкәмәт ямьсезлекне чынлап та кылганнар имеш, инде хәзер авылда кеше күзенә күренерлеге калмагач, бүген иртән әнисе аны читтә яшәп яткан олы кызы белән кияве янына алып киткән имеш.

Элегрәк ул Рәмилә белән Әминә кебекләрнең тәвәккәллегенә кызыгыр, алардан көнләшеп тә куйгалар иде, ә хәзер исә үзенең өстенлеген ярыйсы ук вәкарь аша, хәтта мәсхәрә белән аермачык сиздереп сөйләнде.

— Унсигезен тутырып килгәндә, сабый баламыни, әнисе җитәкләп йөртсен әле. Кызык бит, иеме?

— Ә ние кызык аның?

— Соң ни... анда Чаллы күгендә ач тилгәннәр өзлексез баш өстендә очып йөри, кызларны, бәбкә-чеби урынына тибеп-чукып кыуа торалар бугай. Әминәне «төпсез чуманга утырып» калмагандыр дисеңме? Әнисе аны Зәй шәһәренә болай гына алып киткән мәллә? Котылырга итсә, анда бит этем дә сизми калачак.

Атасы Габдфша ни, кызы Фәрхәнә ни — боларга дөньяны тагын да болгатыбрак, сасытыбрак җибәрергә генә булсын. Рәмилә үзе дә түзмәде, шулай ук ачы мыскыл белән кысык иреннәре аша сытып чыгарды:

— Көтеп карыйк әле: син үзең «төпсез чуманга утырып» калмагаең.

Аннары, кырт-кырт баскалап, бер читкә китеп барды. Аңа клубтан бөтенләй чыгып китәргә ярамый иде әле. Кызый: «Шуны гына белешергә килгән икән, бусының да канына тоз салып җибәрдем, ичмаса»,— дип куанмасын әле.

Юк, күңеленә җиңеллек килмәде, җан тырналулары кимемәде, киресенчә, көчәйде генә кебек.

Янә музыка яңгырап, бию башлануга, Рәмилә каршысында кабаттан Калмаш егете пәйда булды. Ул инде хәзер тагын да дәртләнебрәк, тагын да тырышыбрак кыйландырырга тотынды. Рәмилә хәтта ихтыярсыздан көлемсерәп куйды. Егет исә аңа җавапка бар кыяфәте белән балкып елмайды. Тукта, ни дип авызына ачуташ капкандай чырай җимерергә — караңгылыкка бирешергә, ди? Нигә бер иркенәеп-рәхәтләнеп, «җенләнеп» алмаска ди? Ичмаса, иңнәреннән тузаннар коелыр, рухы ачылып китәр! Ул арада гына мунчаларына ут капмастыр әле, кирәксә, әнисе үзе дә чыгып карый ала. Әйе, һавадагы сөрем, күңелдәге эреннәр таралсын, ә Фәрхәнә кебекләрнең йөрәге янсын! Тырыш, егет, кыйландыр, егет — әнә шулай, әнә шулай! Кителгән бәхетең бүген булмаса, иртәгә түгәрәкләнер әле! Ахыр заман җитмәгән, галәм сүнмәгән, дөньяда олы һәм саф хисләр бар, дөньяда чын мәхәббәт бар! Үз ярым түгелсең, алай да... әнә шул матурлыкны раслап, бер ут булып яныйк, бер гөл булып балкыйк әле, егеткәй!

— Рәмилә апа! Алмапа, дим!

Рәмилә инде тәмам кызып киткән, инде чын-чынлап ут булып кабыныр чиккә җиткән, ул инде өстендәге пальтосын, башындагы беретын салып атарга ниятли башлаган иде. Колбашына кат-кат орынудан ул, аңына килеп, борылып карады. Борылып караса, янәшәдә туганнан туган энесе Сабир басып тора. Бүрек колакчыннары җилбәгәй, кашлары җимерек.

— Ни булды, Сабир?

— Чыгыйк әле.

Бу кичне, ниһаять, бәхетен түгәрәкләүгә өмет чаткылары кабызган һәм шул сәбәпле үтә тырышып, үтә дәртләнеп биегән Калмаш егете, сынын турайтты да тораташтай катып калды, күзләрен челт-челт йомгалады: күр инде, әле мыек та типмәгән бер нәрсәкәй аның балкып, күтәрелеп килгән алтын кояшын, бүрегенә томалагандай иттереп кенә, алып чыгып китсен әле!

— Ни бар, ник дәштең, Сабир?

— Сине алырга мендем мин. Өйдәгеләрең кушты. «Нычытып бер сөйләшәсе бар, кайтсын әле!» — диделәр. Аннан инде, бер сөйләшеп алгач, клубка кабаттан менсәң дә булырдыр. Әйдә, утырасыңмы?

Урамда, клуб баскычы төбендә, сүндерелмәгән көенчә, тоныкына гүелдәп, мотоцикл тора иде. Габделбәр мотоциклы — «Урал» лабаса!

— Нәрсә, Габделбәр дә шундамыни?

— Шунда. Рәмзи абый белән Вәсим абый да кайтып төшкән. Шулар җибәрде дә инде. Ә Габделбәр абый иң башта безгә сугылды, анда Туры бабай белән бергәләп чәй эчкәч кенә, икәүләп сезгә килдек. Мотоцикл ачкычын бу юлы үзем сорарга да өлгермәдем: «Барыбер тынгылык бирмәссең, мә, тагын бер кинән инде алайса!» — дип кулыма тоттырды.

Габделбәр... Ул хәзер инде Чаллыда яши, әмма әледән-әле алар

авылына килеп төшкәли икән. Сизенеп-белеп килгәнме, әллә болай очраклы төстә генәме? Димәк, ныгытып сөйләшмәкчеләр? Аз гына сабыр итәргә, чак кына кичектерергә ярамады микәнни?

— Нәрсә, алмапа, утырмыйсыңмыни?

— Утырмыйм, рәхмәт, энем!

Сабир кабат ялынып тормады, мотоциклын бик яман иттереп гүелдәтеп алды да җәһәт кенә кубып, ыжгырттырып, урам белән түбән таба төшеп китте. Ачы җил димәс, кызлар ташып кинәнер ул бу кичне дә!

Рәмиләнең алай ашыгыр җире юк иде. Салкын җил үтеп, тирләгән аркасын шул арада чиркандыра да башлады. Таралган зиһенен ничек итеп җыеп бетерәсе дә ничек иттереп сабырлык һәм түземлек саклый беләсе?

Адымнары акрынайганнан-акрыная барды...

* * *

Әтисе әле кайтып кермәгән икән.

— Тегендә аулак өендә Яхъя Таипыч бушанасын бушатып бетерә алмый торгандыр ахрысы,— дип аңлатты аңа әнисе.

— Айдаш абый да күренми.

Монысына түрдә, телевизор төбендәрәк утырган Вәсим, калын кашларын җимерә төшеп һәм авыр көрсенү аша җавап кайтарды:

— Ел азагы лабаса — үзең дә бик әйбәт беләсең ич. Туфракның туңы тирәнгә киткәнче, актарасын актарып, каезламый-өйми булмый шул, сеңелкәш. Бәлкем, төн урталарында кайтып төшәр әле. Аннан иртүк кузгаласы булыр. Минем үземә дә иртүк торып китәсе. Ял дип исәпләшеп торыр чакмыни?

«Әһе, әнә ни өчен монда да кызуларга кайткансың икән. Уптым әйләндереп салырга дигәндә, сиңа бир инде»,— дип уйлап куйды Рәмилә.

— Ә нишләп Туры бабайны дәшеп алмадыгыз?

— Олы кешенеме? Тик торганда аны да борчыргамы? Юк, сеңелкәш, кирәкле эшне бик әйбәтләп, тиешенчә иттереп без монда үзебез генә дә хәл итә белербез!

— Соң, Туры бабайның оныгы ич мин, нәсел-нәсәбендә бердәнбере,— диде Рәмилә, килешергә теләмичә.— Язмышымны хәл итәргә тотынсагыз, ул минем файдага түгел, сезнең файдага каерачак ла... Шулай булгач, ник дәшмәскәди?

— Тукта, ни лыгырдыйсың син? — дип, капыл кабынып, сүзгә кушылып китте әнисе.— Синең файда — безнең файда, безнең файда — синең файдаң түгелмени? Һай, кызым!

Рәмилә әле алгы бүлмәгә чыга, әле түр якка үтә, аның бит урталары янып тора, гәүдәсе клубтагыдан болайрак кайнарланып киткән иде. Менә өстендәге саргылт-яшел кофтасын салып, аны урындык артына элде, инде хәзер миләүшә төсендәге күлмәктән генә калды. Кара чәч өемен төзәткәндәй иттергәләде, әмма болай да күперенке чәче аның саен таралып кына китә иде. Шул рәвешле йөренгән, кыландырган чагында, ул бер читтә кәнәфигә сеңеп утырган Габделбәр ягына күз атып алгалый иде. Габделбәр терсәкләрен кәнәфи култыксаларына куйган, аның өстендә көрән төстәге һәйбәт йон костюм, ак күлмәк, көрәнле-кызыллы матур гына галстук. Ул чип-чиста иттереп кырынган, чәчләре тигез булып чак кына кабарып тора. Бары да һәйбәт, бары да килешле! Әмма егет, кызның күз карашын эләктерүгә, үзен бик уңайсыз хәлдә тоя, аның да киң маңгае, яңаклары, эчке халәтен аермачык сиздереп, ялкынланып янып чыккан иде.

Габделбәр бүген дә Рәмилә яшәгән тулай торакка сугылып чыкты. Дөрес, аның элегрәк тә анда кагылып үткәләгәне булган, әмма кызны һич туры китерә алмаган иде. Бүген исә вахтер аңа кызның үз туган авылына кайтып киткәнлеген төп-төгәл иттереп, ышандырып әйтте, шун-

лыктан ул күңеле төшкән нечкәбилне бүген үз өендә очратасына ышанып һәм ашкынып килде. Тик егет бу кичне Рәмилә белән туганнары арасында бик тә мөһим һәм кечектергесез сөйләшү буласын гына белмәгән иде. Монысын аңа, күрешеп, беркадәр утыргач, дусты Рәмзи төшендереп куйды. Әлбәттә, Рәмилә киредән үз авылына кайтып, шушында урнашып калса һәм үз мәктәбенә укырга йөрсә, Габделбәр өчен күк капусы яртылаш ачылып киткән шикелле була лабаса! Анда инде, туасы һәм балкыйсы бәхетен тизрәк тудырыр, ныграк балкытыр өчен, бөтен уңайлыклар, бар кинлекләр аңа атап яратылган ич! Менә моны аңлау, шуңа өметләнү егетне эчтән генә чамасыз куандыра, әмма шул ук чакны шушы куанычлы тойгыны тышка чыгармаска тырышу, моның өстенә, гаилә эчендәге үтә дә әһәмиятле, үтә дә үз булган эшне уртага куеп сөйләшкәндә аның монда катнашырга һич хакы юклыгын белү аны шактый ук кыен һәм четерекле хәлгә куя иде. Рәмиләнең ара-тирә усал иттереп, яндырып карап куюлары исә аны бөтенләй әллә нишләтеп җибәрә иде. Ахырда түзмәде:

— Ярый, хәлләрегезне белдем, әйбәт кенә ятасыз икән. Ара якын түгел, кайтыр вакыт җитте кебек инде,— дип утырган урыныннан тора башлады.

Әмма шул чакны, моңа кадәр диван почмагына посып, каш-күз җимеребрәк мыштым гына утырган Рәмзи дә капыл гына кузгалып куйды:

— Уйлама да, әле өлгерерсең! Менә хәзер тамак ялгап алырбыз. Аннары, без сөйләшкәндә, син чит кешемени? Алай бик яшерен сүзебез дә булмаячак, курыкма.

— Әйе, утыруыңны бел! — дип куәт өстәп куйды Вәсим дә.— Әнә кабарга-йотарга бар, безнең белән бергә булганда, бер дә хәрамга китмәс! Аннары, мин сөйләгәнне, ичмаса, җупләп-ныгытып куйгаларсың. Чаллыдагы хәлләрне син дә миннән ким белми торгансыңдыр.

Моңа Рәмилә ни дип тә кысылмады, ул янә бер тапкыр — монысында инде ике абыйсына берьюлы — усал һәм яндыргыч караш ташлап алды. Әмма абыйлары моңардан эреп төшмәде.

— Син әйт менә,— диде Вәсиме,— тегендә, Чаллыда алга таба ни майтарып ятмакчы буласың, кызый?

Рәмзи кискен бер хәрәкәт ясап, кулы белән абыйсының авызын томаларга теләгәндәй иттерде:

— Соңрак, абый, соңрак. Сабыр ит бу хакта!

Ул сөйләшәсе сүзнең менә болай текә һәм тупас төстә башланып китүен теләми иде. Тупаслык һәм усаллык белән юньгә ирешә алмаячакларын ана күңеле дә әйбәт сизенә иде. Җәен кырысрак булырга тырышып карадылар, җинә алдылармы? Үзләре үк чигенде, хәтта җебеп калды ич...

Әнисе белән сеңлесе алгы өйгә чыгып китүгә, Вәсим, ачык мәсхәрә сиздереп, авызын ямьшәйтте:

— Күр кыланмышларын, күр түш кабартуларын! Хан кызымыни! Ярый-ярый, азрак сабыр итик: әле сыгылу түгел, сынып та куячаксың син, кызый!

Әнисе самавырга су салган арада, Рәмилә өстенә, бая колонкадан су ташыгандагы шикелле, иске плюш жакетны киеп алды, башына иске мамык шәлне япты.

— Син кая, кызым?

— Мунчага утлы күмер алырга. Монда чыра белән азапланганчы...

— Ие-ие, бик әйбәт булыр, кызым. Анда утлы күмер гөждер әле. Аннары мунчаны томалап та куярбыз.

Рәмилә кулына озын аяклы, юан бүксәле тимер савытны тотып чыгып барган чагында, әнисе, чүмеч белән чапчактан су алган җирендә тукталып, кызы артыннан карап калды. Кызының клубтан кайтып кергәч тә тырт-пырт сырт кабартулары аңа һич ошамаган, тик ачыну хисе, тик шикшөбһә генә кузгаткан иде, инде эш самавырга килеп төртелгәч, монысы

аңа кызыйның йомшаруга, күңүгә таба авыша баруына аермачык ишарә булып күренде — бу исә ана кешенең күңелендә жылы һәм өметле тойгыларны кузгатып җибәрде.

Җиз самоварны мич янына үз урынына күчереп куйгач, Рәсүлә ян сәкегә утырды да кулларын тез өстендә кушырган көе, кызын көтә калды. Ләкин теге тиз генә әйләнеп кайта белмәде. Ахырда, көтеп тә җиткерә алмагач, Рәсүлә үзе дә китте.

Мунчага барып керсә, тимер савытка утлы күмер инде тутырып куелган, әмма мунча миченә янәдән утын өстәлеп, яндырып җибәрелгән иде. Рәмилә исә мич каршына бәләкәй эскәмиягә утырган да карашын ялкынга төбәгән.

— Һай, кызым! Ни кыланмышларың бу? Инде томаларга дигәндә генә, ник тагын?

— Янсын...

Ана кеше тавышын кабаттан йомшартуга, хәтта бераз төчеләнүгә таба борды:

— Әллә ниме... иң башта үзең кермәкче буласыңмы?

— Минем кайчан беренче мунчага кергәнем бар? Иң азактан!

— Җарый, җарый. Иң әүвәл абыйларың керер. Теге кунак җегет тә мунча җанлылардан, җыйнаулашып, чабынып чыгарлар. Тик үзеңнең генә менә төн урталарына калуларың... курыкмассыңмы, кызым?

— Мунча җеннәре үзебезнеке әле, ят итмәсләрдер.

— Һай, кызым, әллә ниләр сөйләнәсең син. Җарый алайса, утыра бир, самавыр кайнауга дәшеп алырмын.

Әнисе утлы күмер тутырылган тимер савытны күтәреп чыгып китте, ә Рәмилә мичтә биешкән ялкын телләренә дымлы күзләрен төбәгән килеш, утырып калды.

* * *

Мунча ишеге шыгырдап китүгә, Рәмилә: «Шул арада самавыры кайнады да микәнни?» — дип, эчке калтырану аша, башын күтәреп карады. Әмма ачылган ишектә әнисе түгел, туганнан туган энесе Сабир пәйда булды. Бөтен мунча эченә саф һава тутырып керде һәм шунда, бусага төбендә үк, идәнгә чүгеп утырды. Утыруына бүреген арткарак этеп куйды, пальто изүен чишеп җибәрде. Куллары күн перчаткада, уң кулының имән бармагында мотоцикл ачкычы селкенә.

— Нәрсә, бүген кызлар күңелен күрмисеңмени, Сабир? — дип сорады Рәмилә, ирексездән елмаеп.

— Һе, бу ачы җилдәме? Кайсы чыксын ди?

— Ә сине монда... мине сакларга дип җибәрделәрме әллә? Сабир утырган җирендә кымшангалап алды, көлеп куйды:

— Сакладылар ди. Менә син авылга кайтып, үз мәктәбеңә киредән йөри башласаң, ул чагында инде... Берәрсе синең данны сатарга ниятләп, авызын гына ачып карасын, мин аны... йодрыклар нык минем, алмапа, курыкма!

— Ә син андый хәл булыр дип уйлыйсыңмы?

— Булса-булмаса... синең иреккә балта чабалар бит инде. Әнә анда Вәсим абый: «Аны моннан ары Чаллыга җибәрмәскә кирәк, бүгеннән өйдә томалап калдырырга кирәк, калган хәтлесен тегендә үзем хәл итеп бетерермен»,— дип сөйләнеп утыра. Усал кизәнә ул, иеме?

Рәмиләнең бөтен гәүдәсен кымырҗытып, салкын дулкын йөгереп үтте. Димәк, инде хәл итеп тә куйганнар. Аңа ни кала инде? Еларга-сыктарга, бәргәләнергә-чәбәләнергә генәме?

Бермәл тын гына утыргач, Сабир кинәт бик тирән иттереп сулап куйды.

— Ә Женя абый Мында синең бу хәлеңне белми дә торгандыр, иеме? Ул кайда хәзер? Үзебездәме, әллә берәр чит илдәме?

— Чехословакиядә иде, ә хәзер Мәскәүдәдер инде. Иртәгә кайтып төшәргә тиеш ул. Телеграммасы бар.

— Иртәгә үк?!

Рәмилә ым какты. Аның бите инде кибә язган иде, әмма менә хәзер күз төпләренә яңа яшь бәреп чыкты. Ләкин ул аларга бармак тидермәде, дым элпәсе аша мичтәге ялкынга төбәлеп утыруын белде.

— Ә синең аны күрәсең бик киләме соң?

— Килмичә!

Сабир да күз карашын мич ялкынына текәгән иде, менә ул янә тирән иттереп тын алды да кисәк ярып салды:

— Соң алайса... әйдә качабыз, алмапа!

Рәмилә башын ялт кына болай таба борды, дымлы күзләрен челт-челт йомгалады.

— Син уйнапмы, уйлапмы, энем?

— Уйнады, ди. РИЗга тикле илтәм дә куям, ә теге ягын автобуста элдертерсең.

Кызның хәтта сулыш юллары кысылып куйды: тукта, аның күк капусы ачылып китәргә җыена түгелме соң? Аның ачкычы да әнә энекәшенең имән бармагында гына ич.

— Женя абый белән күрешкәч-сөйләшкәч, калган хәтлесен,— каласынмы-кайтасыңмы,— үзең карарсың инде анда, иеме?

— Ие, Сабир, ие.

Кабаланып өстен-башын кармалап чыкты: иске плюш жакет, иске мамык шәл, ярый әле аякларындагы модный сапожкиларын моңарчы салмыйча йөргән.

— Өйгә кереп өс алыштырсаң, сизәрләр, алмапа. Өйалдыгызда иске толып эленеп тора — үзем орынып үттем...

Рәмилә утырган җиреннән ять кенә калкынды да туганнан туган энесен кайнарланып кочагына кысты:

— Их, Сабир — җаныкаем минем! Их, бәгырь кисәгем минем!

Бу минутта өйдәгеләр, әлбәттә, берни белми дә, сизми дә, алар дөньяда Сабир исемле, инде егет булырга җыенган малай яшәвен гомумән оныткан, исләренә төшерсә дә, аның үз күңеле, үз холкы-фигыле барлыгын, кирәк дигәндә, кыю һәм тәвәккәл була белүен бөтенләй уйламый да иде.

Әнә инде самавыр кайнап та чыкты, менә инде ул өстәлгә табын күрке булып менеп тә утырды. Ләкин шул мәлне капка төбендә пытырт иттереп мотоцикл моторы кабынган тавыш яңгырап китте.

Вәсим, урыныннан җәһәт кенә кубып һәм гәүдәсен янтайтып, түр тәрәзәгә күз салуына, шәрран ярып кычкырып җибәрде:

— Ах, нәгъләтләр! Толыпка төренеп утырганы Рәмилә! Сызмакчылар!

Урындык-кәнәфиләр читкә тибәрелде, ишекләр каерылып ачылды. Атылышып урамга чыктылар.

— Рәмиләү! Рәмиләү!..

Әнә анда, урам белән югарыга таба, инде шактый арада, җәяүле буран пәрдәсен фара яктысы ялаштырып бара, ул тарафтан тонык кына булып гөрелте ишетелә, әмма күз ачып йомган арада фара яктысы юкка чыкты, гөрелте дә ишетелмәс булды.

— Күр син мөртәтне! Күр хыянәтчене! — дип чамасыз авыртыну аша сукранды Габделбәр, ул хәтта кулындагы куян бүреген җиргә атып бәрде. Ләкин хыянәт идеме соң бу? Чынлыкта гаделлек һәм тугрылык галәмәте иде түгелме?

Әмма иң ярсыганы Вәсим булды. Ул әле җиргә типте, әле изүләрен ертырга итенде:

— Күрәләтә адәм мәсхәрәсенә калдырып тайсыннар әле! Юк, болай калдырамыы соң! РИЗдән ары китә алмаслар. Кая, Рәмзи, синең «Ява»ң куәтлерәк тә, елдамрак та, куып җитеп, якаларыннан эләктерим әле!

— Үзең генәме? Юк, син анда куып җитеп, әллә ниләр кыландыруың бар. Мин үз «Ява»ма атланам, син үзеңнекенә атлан!

Алар, агалы-энеле, өсләренә җылы киемнәрен киеп алыр өчен, апын-төпен өйгә кереп киттеләр. Монда капка төпләрендә әниләре Рәсүлә:

— Минә күрәселәрең булса, минә әкәмәтләр! — дип шыңгырдап, еламсырап торуында булды.

Ул арада җиргә саллы-саллы басып, йорт хуҗасы Хәнәфи кайтып житте. Аңа хәлне аңлатырга тотындылар, әмма ул, тыңлап та бетермәстән, бу икене — хатыны Рәсүлә белән Вятка егете Габделбәрне:

— Тормагыз монда ахылдый-ухылдый! — дип ихатага куып кертте.

Ишегалдында Васим белән Рәмзи мотоциклларына атланып өлгергән, анда галәмәт дөбер-шатыр купкан, алар кул изәп, капканы киңрәк ачып куярга кушалар иде. Ләкин этиләре капканы киңрәк ачу түгел, аны шапылдатып ябып куйды һәм, болар янына килеп, мотоциклларын бер-бер артлы үз кулы белән сүндереп чыкты. Аннары:

— Акылыгыздамы сез? Явыз бәдбәхетләр урлап качканмы әллә сеңелегезме? — дип гүелдәде ул ачы тавыш белән.— Качсалар соң! Үз энекәшенә утырып лабаса! Сез нәрсә, Шәмси кызыныкы кебек, яманаты бөтен авылга таралсын дисезме? Тыныгыз чыкмасын — шым булыгыз! Юллары таныш, киткән икән, кайта да белер!

## 9

Инде берничә сәгатьләр Бигеш аэропорты ябылып тора — кырда буран котыра.

Көндезен җил алай ук түгел иде. Самолетлар очкан, Мәскәү рейслары да булган иде. Әмма кичке эңгер куера башлаганда, җил капыл гына көчәеп китте. Тышта буранның инде җәяүлесе генә түгел, җир белән күкне тоташтырганы, тәмам котырмасы — җеннәр туе.

Тегендә, Мәскәү тирәсендәге аэропортта, очып китә алмыйча ул тилмерә торгандыр, монда исә, ничек көтеп житкерергә белмичә, Рәмилә тилмерә.

Вокзал эче халык белән шыгрым тулган. Утыру түгел, иркенләбрәк басып торырга да җайлар юк. Кысылып-буталып йөргәндә, тирләп-пешеп бетәсең. Урамга чыксаң, ачы җилдә тыннар буыла.

Рәмилә, тамагы кибүдән йөдәп, инде ике-өч тапкыр буфетта кара кофе эчеп чыкты. Сусыны беркадәр басылган кебек тоелса да, ул әчкелтем нәрсәдән саруы гына кайный башлады.

Аңа, әлбәттә, тулай торакка кайтып китсә дә булыр иде. Бүлмәдәш-ләре ипле, ятар ястыгы йомшактыр, җылыдыр — тынычта рәхәтләнеп йоклый бир. Сөйгәне Женя Мында да, мөгаен, сүз әйтмәс иде: моңарчы аны каршы алганы булмады, ул әле андыйга ияләшмәгән, тик өметләнә генә торгандыр, аның өметенә җавап йөзеннән килде бит менә, аэровокзал-да җәфа чигеп йөри бит менә, аннары кире кайтып киткән тәкъдирендә дә аның, «Мин сине көтә-көтә хәлләрдән тайдым»,— дип акланырга житди сәбәбе дә бар ич. Ләкин ул алай итсә, егете аңа үпкәләр, хәтта рәнҗеп куяр, тиктән шик-пошаманнарга чумып сызланыр, дип хафалана иде. Бу хафасы өстенә, шушы кичендә тулай торакта янә берәр көтелмәгән борчу-бимаза тумагае дип тә шүрли иде. Бигрәк тә аны абыйларының килеп керү ихтималы куркыта иде.

Кичә авылдан качу галәмәте дә әледән-әле исенә төшә аның. Юк, үкенү хисе кичерми, алай да җаны берөзлексез сызланып тора, тамак төбенә кунган ачы төерне дә йотып җибәрә алмый.

Тора-бара туганнары, бәлкем, аны аңларлар, зур дуамаллыгын кичерерләр, елга, язгы ташу вакыты үткәч, үз ярларына кайткан шикелле, аларның тормышы да әүвәлгечә тыныч кына, үз җайлары белән агуын дәвам итәр. Ләкин кайчан булыр әле ул?

Ә хәзер исә Рәмиләгә сөйгән яры Женя Мынданы көтеп житкерергә кирәк. Күктән кар урынына таш яуса да, иң әүвәл аның йөзен күрергә,

аның сулышын тоярга тиеш! Ул аңа, әлбәттә, барын да сөйләп бирер һәм егетенең аңа мөнәсәбәтен, аны ни дәрәҗәдә яратуын сүз сөрешеннән битәр, күз карашыннан ук аңлап алыр.

Элегрәк аның чит миллэт булуына басым ясарлар иде, соңгы вакытларда исә: «Йөри-йөри шомарып беткән эт каешыдыр әле»,— диебрәк шик белдерәләр. Бигрәк тә әнисе. Рәмилә бик аңлый: үз сукмагыннан җил-җил атлаган мәлендә, чоңгылга төшеп, зур бәхетсезлеккә юлыкмагае бу кызый дип, туганнары аның өчен хафалана. Шул сәбәпле аны, кире авылга кайтарып, үз яннарында, үзләренең күз алдында тотасылары килә. Әмма бер киселгән ипи телеме кире ябышамы соң? Аннары, Рәмилә үзе сайлаган сукмагының нинди икәнен белмимени? Аңардан ул уңны-сулны абайламый атлап барамыни? Рәмиләнең ышанычлы таянычы, тайпылмас терәге булган Женя Мында турында да дөрес уйда түгелләр. Кеше үзенең асылда кем икәнен раслар өчен, күкрәгеn ярып һәм йөрәген учына алып күрсәтергә тиешме инде? Ә Рәмилә сөйгән ярына ышана, ихлас күңелдән бик-бик ышана! Ансыз чын мәхәббәт була димени?

Төнге унберенчеләр киткәндә, ниһаять, буран күзгә күренеп басыла төште. Бетон полосаларны берөзлексез чистартып тордыларны, әллә буран аларга кар көртләрен өя алмаган идеме, озакламый самолетлар оча да башлады. Әле бу тарафтан, әле теге тарафтан төшеп кунганнары турында да игълан тавышлары яңгырарга тотынды. Аэропорт хәрәкәткә килде, ул бертуктаусыз диярлек гүләп тора башлады.

Рәмилә дә җиңел сулап куйды. Ләкин ул иртәрәк куанган икән.

Инде менә төн урталары авышты. Аэропорттан соңгы рейс автобуслары да китеп бетте. Вокзал каршындагы мәйданда берничәләп такси «Волга»сы һәм шәхси автомобильләр генә торып калды. Әмма Мәскәү самолеты әле һаман очып төшә белмәде. Рәмилә хафага калды.

«Әллә анда да бер-бер хәл микән?» — дип пошамангa чумып, справочныйдан барып белешмәкче генә иде, шул мәлне баш өстендәге куәтле динамиктан Мәскәү самолетының төшеп кунуы турында хәбәр иттеләр. Аның рейсы!

Рәмиләнең йөрәге ашкынып тибәргә тотынды, ул ять кенә капка төбенә барып басты. Буран күзгә күренеп басыла төшсә дә, җил үзен әле һаман ярыйсы ук сиздерә иде. Рәмиләнең өстендә мутон якалы соры пальто, әмма ул аңарда капчык шикелле булып эленеп тора — бүлмәдәге Фаягөл гәүдәгә Рәмиләгә карый карсаграк булса да, аның иңбашлары, күкрәкләре күпкә тулырак шул. Башында исә ак куян мамыгыннан бәйләнгән яулык — бусы Светаныкы. Женя Мынданың аны мондый киемнәрдә беренче күрүе булыр, аптырашта калыр инде. Калса калыр, ярый әле, бүлмәдәш кызлары киендерә белде. Рәмиләнең бу минутта бите-йөзе кызып, янып тора, ә гәүдәсе исә, бизгәк тоткандагы шикелле, тыелгысыз калтыраудан туктала алмый иде.

Менә инде Мәскәү самолетында очып төшкән пассажирлар бер-бер артлы капкадан чыга да башлады. Рәмилә ике күзен дүрт иттереп эчкәрегә төбәлде һәм бер мизгелдән күреп тә алды: әнә ярым-караңгыда, урталыкта, җиргә нык-нык басып, ул атлый. Башында козыреклы кара бүрек, өстендә тар якалы кыска пальто. Бер иңенә сумка аскан, икенче кулында дипломат. Аның да әнә купшы мыек тирәсе җәелеп, ак тешләре елтырап китте. Капкадан чыгуына, кулындагы әйберләрен капыл җиргә төшерде дә, колачын киң җәеп, Рәмиләне кочып та алды.

— Ә мин инде сабыры җитмәгәндер, каршыларга килсә дә, инде кайтып киткәндер дип уйлый идем.

Рәмилә тыны кысылганлыктан, сүзен әйтә алмый торды.

— Ә мин... ә син...

— Күр әле, бөтен гәүдәң белән калтыранасың ич син. Бик туңдыңмы әллә?

— Нишләп?

Егет кызны аз гына читкә тайпылдыра төште, аннары янә күкрәгенә

нығытып кысты. Рәмилә аның болай итүен үзенчә юрап, үз хәлен аңлатып бирмәкче булды, әмма тавышы өзек-төтек чыкты:
— Син инде аптырыйсың бугай... мин бит... минеке түгел бу киемнәр, минекеләр тегендә калды. Мин бит авылдан толып киеп качтым.
— Ни сөйлисең син?!
— Башыңа төшсә...
Кыз, егетнең күкрәгенә капланган көенчә, сулкылдап елап җибәрде.
— Менә сиңа әкәмәт! Ни сәбәптән, дим? — Кыз җавап кайтара алмагач, егет башын боргалап, әйләнә-тирәсенә күз салгалады.— Тормыйк монда, әйдә, кайтыйк алайса. Юлда сөйләрсең.
— Юлда? Чит кешеләр янындамы? Тукта, аз гына сабыр итик, ашыкмыйк әле.
Ләкин ашыгырга теләсәләр дә, берни барып чыкмаячак иде: такси «Волга»лары да, шәхси автомашиналар да инде китеп беткән — аэровокзал мәйданы бөтенләй бушап калган иде.
— Һе, менә сиңа кирәк булса! Ярый, монда бөрешеп торганчы, җылыга керик ичмаса.
Вокзал эче дә бөтенләй диярлек бушап һәм иркенәеп калган иде. Иң кырыйдагы диванга бер-берсенә сыенышып утырдылар. Женя Мында аклы-зәңгәрле сумкасыннан Рәмиләгә кызгылт йөзле алма алып тоттырды. Кыз аны керт-керт кимерергә кереште. Бераздан, алманың яртысын гына ашаудан да, ул үзенең тынычланып китүен тойды һәм сөйгән ярына соңгы вакытларда үз башыннан кичергәннәрне бәйнә-бәйнә сөйләргә тотынды. Женя Мында аны, һич бүлмичә, сабыр гына тыңлап утырды. Аның да йөз-кыяфәте үтә җитдиләнгән иде. Сүзенең ахырына таба Рәмилә Вятка егете Габделбәр турында да әйтмичә булдыра алмады. Аның исемен ишетүгә, Женяның маңгае җыерчыкланып, купшы мыегының бер чите сәер генә кыймылдап алды.
— Габ-дел-бәр? Менә көтмәгән идем! — Женя Мында кинәт уч төбенә көлеп куйды.
— Әй син көлмә! Яман булса, йөзенә төкереп, тибәреп кенә атар идең, ә ул... Аның уенда гел яхшылык, гел изгелек кылу кебек. Шул ягы белән ул куркыныч та! Әнә безнекеләрне үз ягына тәмам аударып куя язган бит!
— Яхшылык белән изгелек куркыныч дисең, ә? Кызык шул! Ә без әллә начарлык кылырга җыенабызмы?
— Аннары ул астыртын да, хәйләкәр дә сыман. Әллә нинди планнар корып йөрүе бар.
— Астыртын? Менә монысы шәп түгел. Ә хәйлә дигәнең... Менә монысы, бәлкем, безгә дә зыян итмәстер, ә? Уйлашмый ярамас, шулаймы, кара күзем?
Женя Мында Рәмиләне янә күкрәгенә кысып алды һәм бармаклары белән аның башыннан, иңнәреннән сыйпаштырырга кереште. Рәмиләнең хәзер инде тамак төбендә бернинди төер дә юк, җаны да тап балавыздай эреп куйган, ул хәзер илаһи бер җиңеллек кичерә иде. Ә сөйгән егете исә аны сыйпавын-иркәләвен белде, аның йомшак, бәрхет тавышында чиксез моң белән сүрелмәс дәрт бергә кушылган сыман иде:
— Без дә яманлыкка бармабыз, без дә гел яхшылык, гел изгелек кылу ягын карарбыз, дөрес бит? Ие-ие. Менә инде болытлар таралып, күк йөзе аяза башлады, менә инде елмаеп, матур нурланып кояш та күренде, менә инде Рәмилә — кара күзнең үз йөзе дә...
Әйе, бу — ул, аның Женя Мындасы чын үзе иде.

## 10

Вахтер хатын Рәмзине сынаулы караш белән баштанаяк сөзеп чыкты да, иңнәренә салган йон яулыгын төзәткәләп, ачы көлемсерәп куйды.
— Абыйсы дисең, алайса? Һе, кызык, өченче көнне дә шулай бер майлы күзлесе килгән иде, ул да «абыйсы» дигән иде. Ни телләнсә дә,

үткәзмәдем мин аны: үзенең документы да юк, үзе, җитмәсә, салмышрак та иде. Ә синең документың бармы соң?

Рәмзинең күңелен: «Вәсим тәки кергән икән, юньсез,— дигән уй кеп-дереп узды.— Ярый әле үткәрмәгәннәр».

— Бар. Әмма мин аның бүлмәсенә керергә уйламыйм да. Аны монда чакырып төшерергә кирәк.

— Бер Рәмилә булмады инде. Теге атнада шулай менә синең кебек башына чүлмәк кигән бер егет тә кергән иде. Дөрес, «абыйсы» димәде, киңрәк йөзле, зуррак авызлы, үзе болай матур гына, йомшартып кына сөйләште.

«Анысы, әлбәттә, Габделбәр булгандыр»,— дип уйлап алды Рәмзи.

— Әмма ул мөлаем егетнең дә юлы уңмады: ул кечне чакырып төшерергә Рәмилә үзе юк иде. Инде хәзер, әнәтерә, аның кайдадыр югалып торган үз «мыекбае» да кайтып төшкән югыйсә: кабаттан күренгәли башлады. Чем-кара күзлесе, сумала кашлысы, кайсы халыктыр үзе...

Рәмзи кулындагы төргәкне өстәл читенә куйды, тавышын кырыслан-дыра төште.

— Аның мыекбаенда да, халыгында да эшем юк, апа. Миңа шушы төенчекне генә тапшырасы да азрак сөйләшеп аласы... нибары шул!

— Алайсам... соң хәзер...

Вахтер алтын балдаклы бармакларын өстәл читендә биеткәләргә тотынды. Әмма ул як-ягына карангалаганчы, Рәмзи артыннан йомры гына, таза гына бер кыз калкынып чыкты — ул аларның сүз куертуын тыңлап торган, күрәсең.

— Мин хәзер чакырам аны, абый! Кичке мәктәбенә әле китеп өлгермәгәндер, җыена гына торгандыр.— Йомры кыз шундук баскыч буйлап югарыга элдертә дә башлады.

— Мин аны тышкы якта көтәрмен. Анда минем мотоцикл тора,— дип кычкырып калды Рәмзи.

Тышта биек баганага эленгән лампа яктысында кар чебеннәре бөтерелгәли. Җил юк үзе, суыгы да алай бик куркытырлык түгел. Рәмзи кулындагы төенчекне селкештергәләп һәм җылы эчле күнитекләре белән шыгыр-шыгыр кар изештереп, мотоциклы тирәсендә әрле-бирле йөренергә тотынды.

Абыйсы Вәсим исенә төшеп, ул ирексездән тешләрен шыгырдатып куйды.

Рәмилә качкан кичне аларның бик яман ачуы чыккан, әмма барыннан да битәр Вәсим ярсыган иде. Сабир, алмапасын РИЗгә тикле илтеп куйгач, мотоциклны да, аның әрҗәсенә төреп салынган толыпны да боларның капка төпләрендә калдырып, ятьрәк үз өенә тайган иде. Вәсим иң башта әнә шул малай актыгына каныкты, аны үз өенә барып бик әйбәтләп ярмакчы булып тузынды, әмма мондагылар аны анда җибәрмәде, иң әүвәл Рәмзи үзе абыйсының чыгар юлына киртә булып басты. Үз өендә Сабир, әлбәттә, Туры бабасына булган хәлне һич яшермичә сөйләп биргән. Бабасы аны, билгеле, астыртын, хәйләле эш кылганы өчен мактамаган, киресенчә, бик каты тиргәп ташлаган, әмма ул шул чакны үзенең сөекле онытын икенче онытыннан, инде тәмам әзмәвергә әверелгәненнән, рәнҗетергә юл куяр идеме соң?

Вәсим, Сабирга кул суза алмаячагын төшенгәч, Габделбәргә ябырылды. Дөрес, егетнең монысы да бу кичне боларда бернинди дә эш пешмәячәген аңлап алган һәм, шул сәбәпле, озак та тормый мотоциклына атланып, үзенә бик таныш булган юл белән кайтып киткән иде. Үзе юк дип тормады, Вәсим Габделбәрне җебегәнлектә гаепләде: «Азрак үткенрәк булып, кыюрак кыланса, бу кыска акыллы чәчлекәйләре, ичмаса, әллә ниткән мыекбай аркасында җенләнеп йөрмәс, киртә буе сикермәс иде»,— диде. Аннары: «Алга таба араларына үзем чын-чынлап кысылмыйча булмас, ахрысы»,— дип тә өстәде.

Бераз соңрак, кызу мунча кереп, анда ах-ух килә-килә чабынып чыгу-

лары Рэмзине генә түгел, Вәсимне дә ярыйсы гына йомшартып җибәргән сыман иде. Әмма мунчадан соң, бер стакан зәмзәм суын тоташтан эчеп, гәүдәсенә сеңдереп куйгач, Вәсим кабаттан зәһәрләнеп китте.

Әтисе-әнисе болай да акылларын җыя алмыйча иза чигә иде, улларының янавына аларның өн-котлары бөтенләй югалды. Каш-күз җимереп:

— Барып кына кара! Аның соңында шушында, үз туган йортыңа атлап керәсе булмассың! — дип кисәттеләр.— Синең гөрбиянлыгыңнан, синең шушындый тупас кыланмышларыңнан өркеп качты да инде сеңелкәшең үз туган җортыннан. Син кысылмасаң, ипләп кенә, җайлап кына, бәлкем, көндерә дә алган булыр иек үзен.

Рэмзи дә әтисе белән әнисе ягына авышкан иде.

— Буталып кына йөре! Анда инде тиреңне миннән алырсың! — дип кисәтеп һәм янап куйды ул да.

Ахырда Вәсим чигенде, болар әйткәнгә күнде сыман, ул хәтта сеңлесе яшәгән тулай торакта бөтенләй күренмәскә дип сүз дә биргән иде. Ләкин барыбер килгән бит, җитмәсә, салган баштан килгән. Ярый әле, аны эчкәре үткәрмәгәннәр. Югыйсә, кыландырып күрсәтер иде ул фиргавен! Алай да бертуган абыйсының кызмача хәлдә килүе хакында Рэмиләгә җиткерми калмаганнардыр, бу исә аның күңел җәрәхәтен тагын да тирәнәйтеп җибәрмәгәндерме?

Ана күңеле күп нәрсәне алдан ук сизенә, күрәсең: Капка төпләрендә әлеге төенчекне мотоцикл багажнигына бәйләп маташкан чагында, әнисе Рәсүлә кайта-кайта әйтте аңа:

— Үпкә-рәнҗүләребезне аермачык сиздер, улым, әмма берүк илаһи уптым кубып бәреләсе итмә! Аңа да җиңел түгелдер. Сырт уңаена сыпыргалап, җомшаграк иттереп кенә... алай әйбәтрәк сеңүчән ул!

Бу хәтлесен Рэмзи үзе дә бик белә, бик аңлый. Аның да күңелендәге ачуы эреп юкка чыкмаган, сеңдерәсен сеңдерә белер, әмма шул ук чакны Рэмилә ят кыз түгел, аның сөекле сеңлесе ләбаса!

Ләкин алар үз авылларында тегеләй дип, болай дип уфтанышып һәм башлар катырып яткан чакларында, монда янә бер күңелсез һәм ямьсез вакыйга булып алган икән. Шулай, чүп өстенә чүмәлә өелүчән инде ул!

Монысын Рэмзи моннан ярты сәгать чамасы элегрәк кенә белде. Ул шушы тулай торакка килеп кергәнче, дусты Габделбәр белән күрешеп өлгерде. Әлбәттә, ул Габделбәр яшәгән торакны эзләп йөрмәде, мотоциклын урам белән туп-туры төзелеп яткан йортлар тирәсенә юнәлдерде. Рэмзи аларның кай төштә өр-яңа йортлар торгызуын белә иде. Кичке эңгер инде тәмам куерып беткән, әмма куәтле прожекторлар яктысында шактый ук калкып өлгергән таш йорт тирәсендәге бар нәрсә, көндезге кебек үк, бик әйбәт күренә иде. Рэмзи биектә ике тәрәзә арасына ак кирпечләрдән тигез һәм матур иттереп дивар торгызып матавыкланган Габделбәрне бик тиз абайлап алды. Теге дә, түбәндә көтмәгәндә мотоцикл гөрелтесе ишетеп, игътибар белән күз салды һәм, аның иясен танығач, мастерогын югары чөйгән хәлдә, каты гүелдәп, җавап бирде:

— Чак кына сабыр ит, дускай! Менә сменаны гына түгәрәклик тә, яныңа төшәрмен!

Биш-ун минуттан алар, асларына күн тышлы бияләйләрен салып, кирпеч өемнәрендә кара-каршы утырышканнар иде инде. Рэмзинең Габделбәрне бу киемнәрендә күргәне юк иде әле: өстендә сырган чалбаркуртка, бүрек колакчыннарын артка чыгарып бәйләп куйган, аякларында исә тирән галошлар кигезелгән киез итекләр. Ләкин иң гаҗәбе шул иде: Габделбәрнең суыкта кызарган йөзе бик ямьсез булып җәрәхәтләнгән иде — уң күз төбендә йодрык кадәр фонарь күгәреп тора, борыны ямьшәеп шешеп чыккан, ияк тирәсе дә сыдырылып киткән.

— Нәрсә, абайламый егылдыңмы әллә? — дип сорады Рэмзи, үтә сәерсенү аша.

— Егылды, ди. Теге кем... «мыеккай» белән «җентельменнәрчә» сөйләшүнең җимеше,— диде Габделбәр, ачы көлемсерәп, һәм чулт иттереп

аяк астына төкерел куйды.— Дөресе: чәчкәсе генә әле, жимеше соңрак өлгерер! Әй болай чәпәләшү ару булды безнең!

— Кит моннан!

— Китмичә торыйм.

Габделбәр башыннан кичергәнне яшермичә сөйләп тә бирде. Бер көнне кинодан соң ул Рәмилә белән Женя Мында артыннан ияреп киткән. Әлбәттә, читтән генә күзәтеп барган. Тегеләр Рәмилә яшәгән тулай торак төбендә озак кына сөйләшеп торсалар да, түзгән, егетнең кыздан аерылып киткәнен көткән. Женя Мында, ниһаять, кайтыр ягына борылып, урамга чыгуга, Габделбәр аның юлын кисеп: «Синең белән, туган, бер бик әйбәтләп сөйләшәсе бар»,— дип тегене туктаткан. Менә шунда инде ул, ничектер чыгырыннан чыгып, үзенең кайсы авыл егете икәнлеген күрсәткән: молдаван «дускаеның» изүеннән ныгытып эләктереп тоткан, ә тегесе мондый тупаслыкны өнәмичә, Вятка егетен этеп җибәргән. Шуннан, киткән инде, киткән... Әмма болар шулай бик тәмләп һәм бик кызып тәпәләшкән арада, өсләренә дружиначылар килеп чыгып, ике әтәчне ять кенә аерганнар. Габделбәр үзе дә ара-тирә тәртип саклауда катнашкалаган кеше, әлеге дружиначылар арасында аның таныш егетләре дә була, артык җәфаламыйча, икесен ике якка борып җибәрәләр. Югыйсә, штабларына алып китеп, эшне тирәнгә җибәрү мөмкинлекләре дә була ич әле аларның.

— Йодрык белән генә какшатырлык түгел, нык тора, чукынган! Тик җәл, йөзен артыграк бизәдем, ахры... Бусына өстәп, үземә фонарьлар кундырса кундырыр, әмма аңа кирәкмәс иде алай ук ямарга.

— Ник тагы? — диң текәлде Рәмзи, мондый текә борылышка хәйран калып.

— Соң, аны җимерелгән йөз белән чит илгә; һич югы, үзебездәге берәр калага җибәрерләр, дисеңме? Ә миңа бу араларда аның югалып торуы, монда булмавы кирәк! Кичәгенәк синең Вәсим абыеңны очраткан идем, ул да шулай ди: «Йөзен бизисең калмаган, чәнчелгере» — ди.

— Вәсим?

— Әһе. Соң, син Женя Мынданың кылларын чиртеп карау шушының белән беткәндер дисеңме? Бетә-әр! Сынауның икенче төрлесе алда әле. Тик инде хәзер уйлабрак, нечкәрәк итеп эш йөртәсе булыр.

— Ничек, ничек?

— Әлегә сорашма син. Ни кыласын мин үзем дә уйлап бетермәдем әле. Ә син курыкма: сеңелкәшеңнең бер бөртек чәче дә коелмас. Ул молдаван дусны кабаттан, инде бүтәнчәрәк иттереп сынап карамыйча да ярамый. Соңыннан үкенечкә калмасын, дим, аңа да, миңа да, сезгә дә!

Рәмзи ары таба сүз куерта алмады. Габделбәрне бер төркем иптәшләре, ашханәгә барырга дәшеп, аваз салып тора иде. Вятка егете утырган җиреннән җәһәт кенә купты да:

— Өеңә кайткач, алай-болай мине сорашсалар, бик әйбәт ята, диген! Үзләренә миннән тау-тау сәламнәр ирештер! — дип, гадәтенчә киң һәм дустанә елмаеп, Рәмзигә ым какты.

Рәмзи исә, мотоциклына атланып алды да, аны ничек кабызырга оныткан шикелле, бермәл уйга тарып калды. Нинди планнар белән ни эш кырырга чамалый икән бу Вятка егете? «Сеңелкәшеңнең бер бөртек чәче дә коелмас»,— диде дә динюен... Аның Вәсим белән якынаеп китүе юньлегәме соң? Сеңелкәшләренең баш өстендә көтелмәгән берәр кара болыт куерырга җыенмыймы икән? Әллә абыйсы Айдаш белән киңәшеп алыргамы? Айдаш, ел азагы — җир каезлауда план үтим дия-дия, көнне-төнгә ялгап эшли, бу араларда аның дөньяда бүтән гаме юк та сыман. Ул авыррак кубучан, әмма эшне һәрчак диярлек төптән уйлап, башын-ахырын беткәнче исәплләп башкарырга ярата. Яңа елга инде күп калмады, анда инде Айдаш та бушый төшең, иркенәеп китәр, Рәмзи үзе дә шушында «Сельхозтехника»га ремонт эшенә килергә тиешле. Ике туган, ике фикер-

дәш бу четерекле хәлләрдә ни дә булса уйлап табарлар әле. Мөгаен, ул «мыеккай»ның чын-чынлыгын бер дә әллә кем түгел, үзләре сынап карарга тиешледер. Чын ирләрчә иттереп.

Бу уй-ниятләрен, шик-шөбһәләрен Рәмзи əти-әнисенә, әлбәттә, сиздермәячәк. Гомумән, ул Чаллыда абыйсы Вәсимнең салган баштан тулай торакка килүе хакында да, Габделбәр сөйләгән ямьсез хәл турында да әйтмәячәк. Аларның болай да хафалы башларына нигә дип күңелсез уйисәпләр өстәргә, ди?

Бетон баганага эленгән лампа яктысында кар чебеннәре уйный. Рәмзи дә мотоциклы тирәсендә әрле-бирле йөренүдән туктала алмый. Аның бер кулында төенчек...

Тулай торакка керүчеләр, аннан чыгучылар өзелми. Төркем-төркем укмашып чыкканнары да булгалый. Кызларның шат һәм күңелле көлешкән авазлары суык һавада чыңлап яңгырап куйгалый. Ләкин аның сеңелкәше нишләп чыкмый соң әле? Кичке мәктәпкә шул тикле озак җыеналармы инде? Әллә бөтенләй күренмәскә исәп иткәнме? Санга сукмавымы? Рәмзинең күкрәгендә йокымсырап торган ачуы кинәт күперә башлады. Иң әүвәл үзенә, җәй көне йомшаклык кылганы өчен... аның соңында кабаттан сеңлесенә. Шул бер иләс-миләс чәчлекәй ничәмә кешенең каныңа тоз салып, ничәмә кешенең башын катырсын әле!

Ниһаять, ишек ачылып китте һәм аннан япа-ялгызы гына бер кыз килеп чыкты. Өстендә шәп мехлы модный пальто, башында шундый ук мехтан йомры бүрек. Баскычтан төште дә модный сапожкилары белән кырткырт баскалап атлый да башлады. Рәмзи аңа бер генә күз тидереп алды да карашын читкә борды. Әмма шундук янәдән күз салды: кызның атлау рәвеше аңа бик тә таныш кебек тоелды. Үзе, җитмәсә, туп-туры болай таба килә. Бер кулында төенчек, икенчесенең беләгенә дүрт почмаклы, чем-кара тәстәге ридикюль сыман нәрсә эленгән. Рәмзи кинәт өнсез калды: чү, бу аның сеңлесе Рәмилә ләбаса!

Кыз аның янына бөтенләй якынлашкач, туктап калды, күзләрен мөлдерәмә тутырып карады да ап-ак тешләрен балкытып елмайды:

— Исәнме, абый! Әти белән әни ни хәлләрдә калды?

— И-исәнме, Рәмилә. Ә-әйбәт э-элеккечә... — Рәмзинең капыл каушап китүе, әлбәттә, аның телен дә тотлыктырды. Егет бу халәтеннән тизрәк котылу нияте белән, кулындагы төенчекне селеккәләп күрсәтте: — Ә мин сиңа... теге киемнәреңне... бишмәтең белән яңа мамык шәлеңне алып килгән идем. Ә син монда бактың исә... һе, танырлык та түгел!

— Мәктәп пальтосынмы? — Кыз җиңелчә кеткелдәп куйды.— Аның хәзер кирәге шул тиклем генә инде. Өйдә ярап торыр, һич югы, баш астына салгаларсыз. Бер истәлек булыр. Ә мамык шәл әйбәт әле, әни үзе ябып туздырыр.— Моны әйткәч, Рәмилә үз кулындагы төенчекне селкеткәләп алды.— Син, абый, миңа бусын да алып китәрсең. Плюш жакет белән иске шәл... теге кичнеке...

Бу төенчек тә Рәмзи кулына күчте. Егет, ниһаять, сеңлесенә игътибар белән рәк, җентекләбрәк күз тидергәләп алды. Рәмиләнең өстендәге искитмәле һәйбәт киеменә тиң-тәңгәл төстә йөзе дә нык үзгәргән сыман: иреннәре, бит алмалары, әллә иннек якканга, алсуланып яна, күз төпләрендә исә әз генә, тоныК кына күләгәләр, әмма, аның каравы, чем-кара күз төймәләрендә куанычлы, шаян чаткылар биешә.

Рәмилә абыйсына нинди тәэсир ясаганлыгын бик әйбәт сизенә, ләкин ул, аның кабат-кабат тутырып каравыннан ничектер уңайсызланыбрак киткән иде, кисәк акылына килгән рәвештә, кабаланып, пальтосының шәп мехлы җиң очын чак кына кайтарды да сәгатенә күз салды.

— Нәрсә, кичке мәктәбеңә ашыгасыңмы? Илтеп куйыйммы?

— Һе, миңа шушы биш катлы йортлар артында гына бит ул безнең мәктәп — нибары өч-дүрт минутлык юл. Бүген соңгы кичебез, иртәгәдән каникул.

Янәшә атлап киттеләр. Рәмзи: «Яңа елга өйгә кайтасыңмы соң?» —

дип сорамакчы булды, әмма нигәдер авызы ачылмады. Ә сеңелесе аның ни уйлаганын белгән төсле әйтә куйды:

— Иртәгә без сәфәр тотабыз.

— Нинди сәфәр? Кая?

— Соң, туристик экскурсия инде. Үнсигез көнлек. Мәскәү, Ленинград, Киевларда буласы. Юл уңаенда тагын ниндидер калаларда тукталасы, ди. Ә поезд Казанда оеша. Иртәгә шунда очасы.

— Мәскәү, Ленинградларга-ау?— Рәмзинең хәтта сулышы кырылды.

— Ие. Бригададан без Света белән икәү китәбез. Ул да әйбәт эшләве өстенә кичкедә дә болай ару гына укый. Шулай инде, кайберәүләр безне санга сукмагандай иттерсә дә, бөтенләй үк төшеп калганнардан түгел икәнбез, кадерне белүчеләр бар икән.— Кызның тавышы аз гына чатнап куйса да, аңарда ярыйсы ук вәкарь-һавалану һәм моңардан да битәр нечкә төрттерү аермачык сизелде. Әмма кыз үз хатасын шундук төзәтү ягын карады.— Ә Яңа елны без Мәскәүдә каршы алачакбыз.

— Мәскәүдә димсең...

Рәмзи барган җирендә тукталды да сеңлесенә янә сөзеп карады. Егет күңелендә инде хәзер берниндиачу-ярсулар, үпкә-рәнҗүләр калмаган, алар инде өн дә сиздерми — каядыр таралып, бөтенләй юкка чыккан иде. Хәзер аның күкрәгендә нибары гаҗәпләнү һәм соклану, болар өстенә чиксез үз итү, чын туганнарча ярату хисләре генә ташып тора иде.

— Ярый, абый... Кайткач, эти белән әниләргә, Туры бабайларга күп иттереп сәлам әйт, яме! Бу төенчектә азрак күчтәнәчләр дә бар: чәйдер-конфеттыр шунда. Яңа елны әйбәт каршылагыз! Сау булып тор!

— Сау бул, сеңлем! Хәерле юллар сиңа!

Рәмзи басып калды. Аның ике кулына ике төенчек — сеңлесенең үткәне, артта калган язмышы — эленгән иде. Рәмилә хәйран затлы пальтосы эченнән зифа сынын бөгелдерә-сыгылдыра, йөгерә-атлый үзенең кечкә мәктәбенә — моннан күренмәгән, әмма зур, якты тәрәзәле үз бинасына таба юнәлде һәм, кышның сыек караңгысында биш катлы йорт артына борылып, күздән дә югалды.

## 11

Директор кабинетында шактый ук салкын иде, шул сәбәпле Мөслим Акбашев өстәл артында киң якалы тышлы тунын иңнәренә салган көенчә утыра иде. Менә ул, аз гына кымшангалап алгач, сынаулы караш белән Хәнәфигә төбәлде:

— Сез, Хәнәфи Бариевич, шәп механизатор булуыгыз өстенә, ялгышмасам, «рабочком» да әле? Чуарга, дим, әллә икәү китәбезме?

Хәнәфи юантык буынлы бармакларын өстәл шомасында шудыргалап, ачыклык кертергә ашыкты:

— Алай «рабочком» ук түгел түгелен, нибары урынбасары гына. Зиннур үзе, инде ишеткәнсездер, укуда бит.

— Кайда укый?

— Соң, Мәскәүдә инде. Профсоюзларның иң югары курсындамы шунда, әллә мәктәбендәме, ди.

— Бәлки институттадыр?

— Чуртым белә. Инде диплом яклamaга китте шикелле. Тик кайчан тәмамлап кайтасын аермачык белгән кеше генә юк. Шул инде, үзе булмагач, «рабочком»ны аз-маз өстерәгәндәй кыландырасың.

Хәнәфи тыелып калды: Зиннур хакында аның фикере бик үк әйбәт түгел иде. Тегe, имеш, дипломын яклагач, кире совхозга кайтып эшләргә һич уйламый да, ди, КамАЗга таярга ниятли, ди. Булыр да: шома егет, тәмам каешланып беткән адәм. Тиккә генә КамАЗ профсоюзы тирәсендә кирәктә дә, кирәкмәгәндә дә ышкынып йөрмәгәндер ич? Ләкин яңа директорның боларны әлегә белмичәрәк торуы хәерле булыр, ичмаса, ул икеле-микеле уйларда йөрмәс, һич югы алдан ук кәефе кырылмас.

— Тәк, Чуарга дим, нишлибез?
Хәнәфи уфтангандай иттерде:
— Ә нигә, партком Садыйков яисә баш агроном Ризван иптәш була алмыймыни сезгә? Алар абруе янында минеке чагыштырырлыкмы соң?
Акбашев инде хәл-әхвәл белешкәләп, Үтәдемдә дә, Гәрдәледә дә булып кайткан һәм берсенә барганда үзе белән партком секретаре Садыйковны, икенчесенә чыкканда баш агроном һәм бер үк вакытта директор урынбасары булган Ризван Әүхәдиевне ияртkән иде.
— Абруй? Онытмыйк: «рабочком» сез, Хәнәфи Бариевич! — Директорның тавышы шактый ук югарыга менеп яңгырады, әмма аның саргылткара йөзендә ачулану яисә зәһәрләнүнең эзе дә сизелми иде. Әллә эчтән генә көлеп утыра инде? Менә ул, урындыгын шыгырдатып, урыныннан купты һәм, иңбашына тышлы тунын элгән көенчә, бүлмәдәге озынча өстәлне әйләнә үтеп, мич янына килеп басты, кулларын аның акшарына тидергәләп алды.— Ә Садыйков чирле икән, ангина, ди. Аны ничек кузгатасың инде? Ризван-агроном да әнә, «кырыкка ярыла алмыйм, бүген кич агроукулар», ди. Анысын да өзәргә ярамый, минем дә көнне әрәм итәсем килми. Нишлибез соң? Әллә рабочком баш тартты дип, үзем генә барып кайтырга инде, ә?
Хәнәфинең моңа кадәр күрше авылларның берәрсенә барып җыелыш уздырып йөргәне булдымы соң? Юк, әлбәттә. Әле үз авылларында уздыра торганнарына бара белсә дә, тамагна гына килә иде. Рабочкомга башны тыктылар дигәч тә, күңеле белән ул җәмәгать эшенә артыгы белән суыртылуга һич риза түгел иде.
Акбашевның исә, уч төпләрен җылы мичкә тидергәләп алгач, тавышы тагы да йомшарып китте сыман:
— Ниткән җыелыш булсын, ди! Барып, кешеләр белән сөйләшәбез, Чуардагы хәл-әхвәл белән танышабыз — нибары шул! «Рабочком»га да бер җилләп кайту, шәт, зыян итмәстер, ә?

«Кылларны чирткәләп, ныклыкны юри сынап каравы... Юк, Яхъя Таипыч түгел бу: кырт та пырт кистерми, каты игәү белән йомшак иттереп игәүли...»
Акбашевның тавышында гына түгел, күз карашында да кырыслык чыннан да сизелми иде. Киресенчә, аның җиңелчә елмаю аша үз итеп, якын күреп каравыннан ук җанны эретүчән һәм ихтыярыңны буйсындыручан нур агыла сыман иде.
Хәнәфинең холкына ярарга тырышу яки риялану кебек нәрсә бөтенләй ят иде, алай да, тирән сулап куйгач, урындыгын шыгырдатып, урыныннан купмыйча булдыра алмады:
— Мастерскойда ремонтны самый кыздырып җибәргән чак иде. Ярар инде алайсам, барсак барырбыз.
— Менә бу егетләр сүзе, ичмасам! Кичке савымга ничек тә өлгерергә кирәк безгә!

## 12

Мастерскойда төшкелеккә тукталгач, Хәнәфи өенә кайтып керде дә, авызын киң җәеп, хатынына бүген кичке уңайда кем белән кая барасын әйтеп салды. Рәсүләсе, бу хәбәрне ничек сеңдерергә белмичә, беравык күз йомгалап торды:
— Чуаргамы? Җаңа директор беләнме? Күр сине... Кунып ук жатмассыздыр бит? Айсам, җарый-җарый, бик әйбәт.— Шулай дип аяк каккалагач, ул кинәт иренең иңбашына төртеп алды.— Туктале, дим, син нишләп соң җаңа директорыңны үзебезгә төшке ашка дәшмәдең? Әнә ит белән бәрәңге плитәдә буларын бөркеп утыра! Аны бит төзүчеләр ашханәсендә генә тамак җалгаштыргалап җөри, диләр. Семьясыз кешенең...
Хәнәфинең өстеннән тунын, бүреген салып маташкан чагы иде, күзләрен шакмакландырып хатынына карады:

— Син нәрсә? Шундый олы кешене... капыл гына...

— Әҗер карачкычы булма, бар, дим! Үзең «рабочком» тагы, кеше турында кайгыртмаска монда. Ичмаса, бер җүнле ризык кабар авызына.

Күнмичә мөмкин түгел иде, Хәнәфигә киредән күн бүреген башына батырып киярга туры килде.

Бәхетенә, Акбашев «Автозаводстрой» ашханәсенә китеп бармаган икән әле, әмма ул, елмаеп рәхмәтләр яудырса да, Хәнәфинең тәкъдимен кискен рәвештә кире какты: имеш ярамый, уңайсыз, килешми. Мондый чакта Хәнәфи дә төшеп калганнардан түгел:

— Мин бит сез әйткәнгә күндем — Чуарга барудан баш тартмадым, ә сез киреләнәсез. Анда хатын да, дуамал кубып, буран кузгатты. Ризыктан өстен булырга ярамый бит инде,— дип ныклык күрсәтте һәм шул ныклыгы белән тегене аударып та куйды.

Алар кайтып кергәндә, Рәсүлә өйләренең түр ягына табын әзерләргә керешкән иде инде. Әмма Хәнәфи аптыраудан тамак кыргаламыйча булдыра алмады: түр якта Рәсүләгә табын әзерләшеп, каенатасы Туры карт та үзенчә эш кыйратып маташа иде. Кай арада килеп кергән, диген! Бая Хәнәфи өенә сугылган чагында ук аларда булып, түр якта күзгә чалынмыйча утырып калды микәнни? Юктыр, Рәсүлә аңа ять кенә хәбәр салгандыр. Килеп җитәргә ара еракмыни?

Хәер, Туры картның монда булуына алай бик аптырарлык та түгел иде: соңгы араларда ул әледән-әле аларга килеп керә дә: «Теге бәпкәчтән андый-мондый хәбәр җукмы?» дип сөекле сөяге хакында сорашырга тотына иде. Кызлары Рәмиләнең һич уйламаганда зур һәм бик тә мактаулы сәяхәткә чыгып китүе һәммәсен дә чиксез дулкынландырган һәм куандырган иде. Күңелләрендә: «Ерак җирләрдән әйләнеп, дөнья күреп йөргән мәлләрендә, бәлкем, җенләнүләре коелып, азрак акылга килмәсме? Читкә китсәң, җыен ыбыр-чыбыр, вак-төяк юкка чыгып, күзгә күренмәс була, аның каравы, тормыш өчен иң хаҗәте һәм әһәмиятлесе, бигрәк тә туганлык-кардәшлек хисләре дәррәү үсеп, кабарып китә. Бу кызый белән дә шулай булуы бик тә ихтимал», дигән өмет ялкыннары дөрләп куйгалый иде. Әмма шул ук чакны шик-шөбһәгә чумган вакытлары да булмый калмый иде: ә шуның нәкъ киресе килеп чыкса? Кызый әнә шундый данлы җирләрдә булудан бөтенләй масаеп һәм һаваланып кайтса? Үҗәтләнүләре күпереп кенә китмәсме?

Рәмиләнең кайтыр вакытлары инде узып бара, әмма аңардан моңа тикле ни хат, ни хәбәр килгәне булмады. Бу исә мондагыларның пошаманлы уй-исәпләрен көннән-көн көчәйтеп тора иде.

Туры картның боларда булуының Хәнәфи бик үк абайламаган икенче сәбәбе дә бар иде: бабай, яңа директорны урамда очраткалап, аңа итагать һәм әдәп белән баш каккалап киткәләгән булса да, аның белән күзгә-күз иркенләп сөйләшергә җай көтебрәк йөрүдә иде. Менә хәзер дә, картларча әкрен, әмма эре кыйланып табын әзерләшкән җирендә дә, кипшергән иреннәрен ялаштырып куйгалаулары ризык тәмле күренгәнгә генә түгел иде, билгеле.

Ләкин ул өстәл артында үзе белгән тәртипкә һич хилафлык кылмады, ягъни гәпкә капыл гына керешмәде. Тозлы кәбестәне кетертләткән шәйгә ит белән бәрәңгенең үтә кайнар шулпасын болгаткалый-суыткалый, бер үк вакытта кунагын да ныклап кыстарга онытмыйча, әкертенләп һәм иплән кенә тегенең кылларын чирткәләргә тотынды. Акбашевның армиядә хезмәт итүче улы, җитеп килгән кызы һәм болар өстенә хатынының да фельдшер булып эшләвен ишеткәч, «Тормыш җаклары әздә икән, рәхмәт энем!» дип авыз шәпелдәтте һәм шуның арты ук кунагын тынычландырырга ашыкты:

— Ә син, энем, һич кенә дә хафа җотып җөрмә: тулай торакта алай озак чиләнеп җатмассың, чакыртырсың үзеңнекеләрне. Җаңа калада өр-җаңа фатирны тоттырырлар сиңа да! Әнә бит Таип Яхъясы ай-һай өлгерлек күрсәтте! Ә нигә, әллә лаек түгелме? Әйтерлегең җук: бик тә лаек!

Таиповның директорлыктан китү сәбәбен авылда төрле кеше төрлечә аңлата иде. Шулай булмый ни, күчәр башында дилбегә тотып, ни гомерләр утырсын да, күпләр һич уйламаганда, капыл гына төшеп калсын әле сиңа — хикмәтле хәлнең дә хикмәтлесе түгелмени? Мәгәр Туры карт, әлгәреге елларда Таипов белән никадәр еш, никадәр каты чәнчешкәләгән чаклары булмасын, аның хәлен аңлау, хәтта яклау ягына авышкан иде:

— КамАЗ шартларына җараплар бетмәде, борчак пешерә белмәде — иң чын дөресе шул! Җугыйсә, бер искән җилгә генә авардай имән иемени? Җарар, пошынмыйк, үз җаен белми кыланмас. Әнә болай бик тә заслуженный инде, үз иңнәрендә азнымы өстерәгән адәм!

Ярыйсы ук күтәренке тавыш белән сиптерелгән шушы сүзләрдән соң Туры бабай, кинәт өн-аңына килгән рәвештә, табын артындагыларга берәм-берәм күз йөртеп чыкты, кашыгын кулына алды, ләкин тәгамны бер-ике кабып куйгач та, кире кайтып, әмма йомшаграк, ягымлырак тавыш белән Акбашевның үз хәлләрен төпченергә кереште.

## 13

Басу юлына килеп кергәч тә, чана түренә оялап алып, сыртын урәчә башына кырын салган Хәнәфи, бүрек колакчыннарын тарта төшеп, каеры тун якасын күтәреп куймыйча булдыра алмады. Аңа шундук диярлек юлдашы да иярде. Шөкер, аңарда да тун иде,— кышын, аерата юл йөргәндә, иң кулае, иң ышанычлысы. Тик аякларда гына аермалы: Хәнәфидә йомшак киез итек, ә тегеңәрдә, «җылы» дип макталып әйтелсә дә, нибары ботинка иде. Шуңа күрә Акбашев аякларын йомшак саламга тыгыбрак утырды.

Чуарга кадәр җиде-сигез чакрымнар. Юл чокыр-чакырларны, куак-әрәмәләрне әйләнә-чолгый үтә. Кышын, әлбәттә, машинада борын төртәсең юк. Нибары трактор юлы да, чана юлы. Ян-якларда, анда-санда, әмма бөтен юл озынлыгына, чыбыклар төртеп чыкканнар.

Туры алаша — ышанычлы һәм тугрылыклы мал, юл тигезләнеп, шомарып китсә, дилбегә какканны да көтмичә, юыртуга күчә, ә инде салулырак өлешкә керсә, атларга тотына, әмма шул чагында да, кызулыгын чак кына да җуярга теләмичә, адымнарын тибеш-тибеш сала иде.

Хәнәфинең күптәннән инде, менә болай чана түренә оялап, кышкы юлларны гизгәне юк иде, һай, тансыклаган икән — күңеле әллә нинди рәхәт дулкыннарда тирбәлүгә күчте:

— Һәй, малкай гынасы ла!..

Бүген тагын, күр инде, җәяүле буран кубарга чамалый кебек. Тик зәһәр җил бу юлы юнәлешен беркадәр үзгәрткән сыман: салкын һава дулкыны, бөтерелеп-айкалып, инде тап котып ягыннан түгел, бәлки кояш чыгышы тарафыннанрак агыла иде.

Бу кышны җир йөзенә болай да юка кунган кар инде хәзер үзәниңкүлекләргә, чокыр-ерганакларга себерелеп бетә дә язды. Ак, йомшак юрганнарыннан мәхрүм калган басулар, аерата чалкыйрак өлешләре, имансыз туңудан кара шадралы йөзләрен чытып, һавага, күккә рәнҗеп яталар шикелле. Кыш уртасында бит!

Ел, җәйгә чыккач, тагын яманга әйләнеп китәр микәнни? Әүлия җанлы ил картларының былтыр чиксез уфтану аша: «Өч ел рәттән шушылай корылык булыр»,— дип юраганы юш килер микәнни?

Акбашев урәчә буйлатыбрак кырын яткан җиреннән капыл гына тез өсләренә күтәрелде дә:

— Ә Үтәдем хатыннары чая да соң! Телләренә шайтан үзе төкергәнмени! — дип һич көтелмәгән тарафтан сүз башлап җибәрде.— Аларның мунча ташлары элек тә шулай кызу идеме, әллә КамАЗ кыздырып җибәрдеме?

— Икесе дә булгандыр, Мөслим Гайнаныч. Керәшендә мунча ташының, әйтергә кирәк, суынганы да юк, һаман да «җәрле» яшиләр! Аерата хатын-кыз...

Күңелле генә көлешеп алдылар.

— Тик, җәл, совхозга ябышып торганнары нибары шул дуңгыз фермасы гына икән. Әле анысын да бу елны бетерергә ниятләгәнсез икән.

— Соң, безмени? Тресттагы агайлар тырыша инде.

— Тресттагы?

— Әйе. Нибары сөтчелек белән яшелчәчелек кенә булсын, диләр бит.

— Алай бик ашыкмаганда да ярар иде. Юк, бер-бер әмәлен тапмый булмастыр. Дөньяда бер трест кына түгел, бүтәннәр дә бар. Аңлаучылар, дигәнем.

Хәнәфи юлдашына текәлебрәк күз атып алды: «Күрче, совхоз җитәкчесенең кулына ныклап тотканы юк әле, инде шәпләп кизәнергә дә җыена түгелме соң бу?»

Ләкин Акбашев шушы юнәлештә сүзне артык куертырга теләмәде ахры, көлемсери төшеп, янә багы эзенә кайтты:

— Ә гәрдәлеләр сабыррак күренә.

— Алар җиргә ябышканрак. Һайт, малкай!

Ярыйсы ук кар салулы юлдан ат авыр-авыр атлауга күчкән иде, Акбашев янә үрәчә уңаена кырын ятты, әмма бермәлдән кабат калкынды:

— Ә партком секретаре Садыйков, акбур белән кара тактаны сагына башлаган ди, имеш, чын булса...

— Кара тактаны? Ә, әйе, сагынмаска, партком булганчы, математика укыткан кеше бит.

— М-м-да,— дип сузды Акбашев, бу икеле-микеле ымлыкка үзенчә мәгънә салып.

Инде күз бәйләнергә тора, юл читләрендәге маяк чыбыклары да тонык абайлана иде. Йомры алаша янә юыртуга күчкәч, Акбашев гәүдәсен тагын кырын салды һәм бүтән калыкмады. Ул, йөзен тун якасы белән каплый төшеп, хәтта күзләрен үк йомды шикелле. Йокымсырап китүеме? Әллә бар белгән-ишеткәннәрен тизрәк сеңдермәкче булып, тирән уйларга таруы гынамы? Ни әйтсәң дә, үзе өчен бөтенләй ят җиргә, өр-яңа тарафка күчеп килүе бит.

Чуарга нибары җиде-сигез чакрымлык юл. Нибары. Буран һаман җәяүли бирә, ә Хәнәфи, чана түренә укмашкан хәлендә, күңеле белән уйлар диңгезенең әллә нинди дулкыннарында чайпалуын белә.

Күз алдына Яхъя Таипыч килеп басты. Ә бит чынлыкта бабасы Туры карт хаклы: тиз генә бирешердәй имән түгел кебек иде — тамырлары тирән, һич какшамас сыман иде. Әмма үткәндәге кырысрак заман өчен. Ә бусына, яңасына чыдамады. КамАЗ өермәсе аударды аны. Ризван яшьтиенең «цунами» дигәне. Аумас-бирешмәс өчен җайларын таба алмады, әмәлләрен белмәде. Ярый әле, вакытында үз хәлен аңлап, йөгәнне икенче кулларга тапшыру турында кайгырта алды. Ышанычлырак кулларга. Аның бу хәтлесе дә чын егетлек түгелме соң?

Ә бу «кара башлы» Акбашев?Ниләр җимертер икән? Җимертә алырмы? Ә болай үзе дуамал кубучаннардан түгел шикелле. Үткен акыллы, хәлне аңлаучан кебегрәк.

Кичке эңгер шактый ук куера төште. Юл инде начар абайлана иде. Әмма туры алаша, рәхмәт яугыры, кай төштә юыртып китәсен, кай төштә саллы-саллы атлауга күчәсен үзе дә бик әйбәт чамалый иде.

— Һайт, малкай гына ла!

Инде күп калмады: әнә сөзәк үр каршындагы куаклар артында Чуар утлары җемелдәшә. Үзәнлектәге чокыр-чакырларны әйләнә төшеп үтсәләр, үргә күтәреләсе генә кала.

Тик нигә соң әле аның юлдашы өн-тын сиздермичә мәрткә китеп ята? Мондый юлда гәп коруның никадәр тансык һәм татлы икәнен аңламый микәнни? Сугышларда катнашкан яшьтие бит. Һич югы шул истәлекләрен янә бер селеккәләп алсалар да зыян итмәс иде.

Акбашев түрдә дилбегә тотып утыручының ни теләгәнен күңеле

белән сизенде ахры, менә ул кырын яткан җирендә башта кымшангалап алды, аннары ат тигез юлдан җиңелчә юыртып китүгә торып ук утырды, әмма сүз итеп Хәнәфи көткәнне түгел, бөтенләй бүтәнне башлап җибәрде:

— Чуарда хәлләр ничегрәктер инде, Хәнәфи Бариеч, ә?

— Чуардамы? Безнең Туры бабай әйтмешли, үзләре дә Чуар, халкайләре дә чуар, һе-һе...

Хәнәфи бу авыл турында тәмләп сөйләмиме соң! Әмма ул, кеткелдәвен басып, бер тын сүз башламыйчарак торды. Ни турында сөйләргә икән? Юк, хуҗалык хәлләре, фермасы торып торсын әле — качмас, баргач барын да үз күзләре белән күрер. Ә менә авылның үзе турында, аның сәеррәк халкы, аеруча уңган кызлары һәм киленнәре, бу бәләкәй генә авылдан чыккан укымышлы кешеләр хакында җәелебрәк сөйләсәң дә, шәт, гөнаһ булмастыр.

— Хәзер анда, кәнишне, күз явын алырлык берни дә юк,— дип тотынды ул, ниһаять, дилбегәне җиңелчә каккалаган шәйгә. — Ә менә җәйләрен билләһи, исләр китәрлек! Курорттай урын инде! Яшеллек эчендә күмелеп утыралар. Урам дигәннәре берәү — болын хәтле! Шулай булмаска, алар бит элгәредә Минзәлә өязенең төрле авылларыннан килеп укмашкан. Урамның бер ягыннан икенче ягына чыкканчы утлы кисәү сүнә, ди, бер якның әтәч кычкырганын теге яктагысы ишетми ди.

— Телгә җор алайса.

— Бар инде, бар. Алар бит сабантуйны да авыл уртасында урамда гына үткәрә.

— Кит аннан!

— Китмичә торыйм: мин белгәннән бирле шулай, ипидер! Соң, рәхәт булмый ни! Телисең икән алыш-көрәшне өеңдә ачык тәрәзә янында чәй-мәй капкалаган шәпкә генә күзәтәсең, телисең икән өй түбәсенә яисә тирәк ботагына кунаклап карыйсың, ә инде урамдагы хәтфә чирәмдә аунаган яки утырган шәйгә карауларның уңайлыгын әйтәсе дә юк.

— Идиллия икән.

Бу сүзнең асыл мәгънәсен Хәнәфи, әлбәттә, белми иде, алай да аны матурга юрап, ияк каккалады:

— Үзе инде. Аннары, Мөслим Гайнаныч, шунысын да әйтим әле: менә безнең совхоз «Йолдыз» исемен йөртәме? Йөртә. Ә бит заманасында бу матур исемне безгә Чуарлар биргән.

— Ничек?

— Ничек дип, күптән инде. Колхозлашу елларында ук. Дөрес, Чуарда да бөтенесе дә алай шома гына бармаган. Иң башта әртил кормага ир-ат тотынган. Корганнар да. Коргач, «Кызыл Ләпәй» дип атаганнар. Ә «Ләпәй» дигәнеме? Анысы аның урман исеме,— теге як басуларына тоташып китә. Ярар, коруын корганнар болар әртилне, әмма озак яши алмаганнар: ике-өч ай үтүгә үк, язгы чәчүгә чыккач, ат-арбаларын, сукатырмаларын киредән бүлешә-бүлешә ызгышып, канга батышып беткәннәр. Таралган боларның әртиле. Шуннан соңмы? Шуннан соң, хатын-кыз тотынган. «И мескенкәйләр, сездән буламы соң?»— дип. Җиллеләрдә хатын-кыз, бигрәк тә яшь киленнәр, кызлар. Арада берсе, комсомолка Гайшә дигәне, баш булып йөри. «Ләпәй» дә булсын исем, ди, юк, безнең әртил Чаллы-Минзәлә төбәгендә йолдыз булып янарга тиешле»,— ди. Хатын-кыз ике уйлап тормый, моны әртилләренә председатель итеп сайлап та куя. Ир-атның, билгеле, буйсынасы килми, ат бирми интектерәләр. Ә болар югалып калмый, сыер җигеп булса да, уртак җирләрен сөрә дә, тырмалап чәчә дә!

Юк, заманасында Чаллы тарафларында даны шәп яңгыраган комсомолка-председатель турында Хәнәфигә бу минутта җәелебрәк сөйләргә язмаган икән: кисәк туры алаша, әйбәт кенә юыртып барган шәпкә, ярыйсы ук тирән чокырга төшеп, чанасы-ние белән муеннан тирән карга батты. Бер тилпенде малкай, ике тилпенде, әмма аның саен карга тиранрәк чума гына барды. Камыт-дугалары әллә кая менде.

— Тфү, кадалгыры!— дип сукранды Хәнәфи.— Шулай инде ул, яшьти, сүз тәменә чумсаң, юл җаен онытасың.

— Ярар, уфтанмыйк! Хәерле каза булсын, арт ягы таза булсын, диик, яшьти! Туармыйча гына котыла алмабыздыр.

Атны туарып, чананы тирән кардан өстерәп чыгарганда да, кабаттан җиккәндә дә Хәнәфи юлдашының беләкләрендәге җегәргә соклanмыйча булдыра алмады — Алып батырлар нәселеннәнмени!

— Булды гына бу. Әйдә утырышыйк, Хәнәфи яшьти!

Чуарга барып кергәндә, кичке савымга шактый ук соңгарган булып чыктылар.

14

Клуб бәләкәй генә иде: нибары кырык-илле кешегә генә исәпләнгән зал, түрдә идәннән ярты метр чамасында гына күтәрелеп торган сәхнә, анда җыйнак кына өстәл, трибуна. Шоп-шома диварларда исә сурәт-плакатлар, лозунглар, схема-диаграммалар, тагы әллә ниләр — Чуарлар үз клубларын артыгы белән чуарлап җибәргән лә дияргә булыр иде хәтта.

Артлы урындыкларны исә урталыкка түгел, ян-якларга диварлар буйлата тезеп чыкканнар. Күрәсең, монда күбрәге күңел ачарга, уен-җыр корырга җыела торганнардыр.

Ишек янындарак тигез акшарланган бәләкәй генә мичнең, залга караган ышыгында бәләкәй генә биллиардта ике бәләкәй малай, бүрек-бишмәтләрен салып атып, шар сугып ята иде. Ике абый тупсадан атлап керүгә, алар, кызыклы уеннарыннан шып тукталып, күз тасрайткан иде.

Әйе, монда бары да үтә җыйнак һәм үтә бәләкәй иде. Зур культура сарайларына күнеккән күзләргә беренче карауга монда бары да уенчык кына булып күренүе дә ихтимал иде. Әмма нибары кырык-кырыкбиш хуҗалыктан торган авылга моннан да артыгы ни булыр иде икән тагы?

Акбашев канәгатьләнү аша тамак кыргалап алды:

— Ярыйсы гына икән бу. Әйбәт бу!

Алар инде фермада кичке савымның азакkы өлешен генә булса да күзәтеп өлгергәннәр иде. Анда йөргәндә дә Акбашев савымчылар эшенә тыкшынмыйча, тик хәл-әхвәл генә белешкәләп, һәм менә шушылай канәгатьләнү аша тамак кыргалап кына йөргән иде. Хәнәфи үзе дә кеше мәш килеп эшләп ятканда тыкшынырга яратучылардан түгел иде— яңа директорның бу гадәтен күңеле белән бик ошатып куйды.

— Я, ник туктaлдыгыз?— диде Акбашев, биллиард янында күз тасрайтып өнсез калган ике малайга таба кинәт кенә борылып.— Авызыгызны ябыгыз, дим, югыйсә чыпчык очып керә бит! Ие, менә шулай, тотыныгыз җәһәт кенә. Егет дигән затларга кул шомартып, күз үткенәйтүләр бер генә дә зыяга булмас!

Аннары алар, уң тарафтагы ян ишекне ачып, клубның аргы өлешенә үттеләр. Монысында уку залы, дөресе, бәләкәй генә китапханә икән.

Бүлмә карар күзгә тагын да пөхтәрәк һәм җыйнаграк күренә иде. Диварлардагы төрле язучыларның сурәтләрен, китап сөяргә өндәгән плакат-язуларны яисә бер кырыйда ачык шүрлекләрдә тыгыз итеп тезелгән китапларны әйтәсе дә юк, түрдә биек кенә тумбочкалар өстендә урта зурлыктагы экранлы телевизор һәм радиоалгыч белән магнитофон да күз яуларын алып утыра иде. Әйтерең юк, бай гына яшиләр икән ләбаса!

Бүлмә уртасындагы озынча өстәл артында дүрт-биш кызчык китап-журнал актарып утыра иде. Алар, әлбәттә, көтелмәгән кунакларны күреп, каушап калдылар, әмма, каушасалар да, матур гына иттереп исәнләшә белделәр.

— Гыйлем сеңдереп утырабыз инде, алайса. Шәп, шәп!— дип эндәште аларга Хәнәфи, җылы гына иттереп.— «Избач» апагыз кайда соң?

Кызлар, бер-берсенә күз аткалап, шыпырт кына көлешеп алдылар, бер-икесе хәтта муенын җилкәсенә батырып куйды: «Избач» дигән сүзне үзләре өчен хикмәтле дип таптылар, ахры. Ниһаять, берсе бүтәннәрдән чак кына дәүрәк күренгәне, өирәк сипкелле йөзе бүртенеп кызарса кызарды, әмма кыюлык күрсәтте:

— Зәйтүнә апамы? Ул өй борынча почта өләшеп йөри әле.

— Алайса ул югында сез хуҗа монда?

— Шулай инде.

Хәнәфи хәлне Акбашевка аңлатып бирмичә булдыра алмады:

— Зәйтүнә апалары теге ни... бер үк вакытта клуб мөдире дә, китапханәче дә, өстәвенә почтальон да! Мактавым булсын, Чуарның иң уңган киленнәреннән.

— Күренә,— дип ым какты Акбашев, бүлмәгә янә күз йөртә-йөртә.

Сораша торгач, белделәр: авылда шушылардан өлкәнрәк булган җиде-сигез малай белән кыз Әҗер урта мәктәбенең интернатында яшәп укый, ә болар үзләре Гәрдәледәге башлангыч мәктәпкә көн саен төшеп йөриләр икән.

— Кыен түгелме соң?

— Нишләп? Күңелле генә. Ат җигеп, төшереп куялар, уку беткәч, алып кайталар. Умартачы Рәҗәп бабайны белмисезме әллә? Җәйлектә совхоз умартасын карый, ә кышлыкта безне йөртә.

— Белмәскә, әйбәт абзый!— диде Хәнәфи һәм янә Акбашевка күз атып алды.— Боларның үз авылларында да элгәрерәк мәктәп бар иде, дөресе, мәктәпчек: барын бергә, ягъни дүрт классны берьюлы бер укытучы укытыр иде, уптым! Соңрак авыл халкы үзе үк андый тәртипне яратып бетермәде шикелле.

— Хәлкәйләрен бик аңлыйм,— дип елмайды Акбашев.— Үзем дә Зәй буеның шушындый ук бер бәләкәй генә авылында туып үскән малай. Йөреп укуларның нәрсә икәнен бик беләм.

Аннары ул киң бер хәрәкәт белән бүлмә һавасында кул изәп алды:

— Бу кадәр китап кочагында утырулар рәхәттер шул, ә!

Кызкайларның күзләрендә шундук чаткы-йолдызлар ялтыр-йолтыр җемелдәшергә тотынды.

— Рәхәт булмыйча!— дип күтәреп алды кара кашлы кыз, авызын киң җәеп.— Без, берәр кызыклы тапшыру булса, телевизор да карыйбыз, кайчакларда, кирәк дисәк, музыка да тыңлыйбыз әле. Зәйтүнә апа шундый да әйбәт ул безнең!

— Алайса, бик күңелле яшисез?

— Аның әле бөтенләй күңеллесе атна азагында була. Шимбә белән якшәмбе кичләрендә. Анда инде Әҗердә укып ятучылар да, КамАЗ төзүче егетләр белән кызлар да кайткан була. Безнең клубка бер кичне килеп карасагызчы! Зрә дә әкәмәт инде!— Сирәк сипкелле кызый, ялгыш артыгын ычкындырдым ахры, дип шүрләп куйдымы, кинәт тыелып калды һәм, башын кыңгыр салды да, ике абыйсына да җәт кенә күз атып, әмма басынкы гына тавыш белән сорау бирергә итте:— Бүген кич безнең клубта берәр җыелыш буламы әллә, абыйлар?

— Әйе, кызларым,— дип җылы гына иттереп ым какты Хәнәфи.— Бер сөйләшеп алырга дип килгән идек әле менә.

— Ә безнең әнәйләр белә микән соң?

— Белгән хәтлесе беләдер, ә белмәгәне... Туктале, нишләп «әнәйләр» генә? «Әтәйләрнең» дә булуы бик хәҗәт бит, кызым!

Шул сүз җитә калды: бүлмәдә кинәт кискен җил исеп куйдымыни, кызлар, бары бердәм кубып, өстәл артыннан йөгерешеп чыктылар. Аларның шәл-бишмәтләре почмактагы урындыкка тигезләп, өс-өсләтеп өеп куелган иде, ашык-пошык киенергә тотындылар.

Бер минут үтүгә китапханә бүлмәсендә аларның исе дә юк иде инде. Бу шул хәтле тиз булды, Хәнәфи Бариев белән Мөслим Акбашев кызларга сүз катарга да өлгермичә калдылар.

Бүлмә бик якты булуы өстенә шактый ук җылы да иде, болар да өсләреннән туннарын салып, кызлардан бушаган урындыкка өеп куймыйча булдыра алмадылар.

— Әнә шулай итеп алар, Мөслим Гайнаныч,— диде Хәнәфи, өстәл янына утырып һәм кулына беренче эләккән журналны алып, әмма аны битләп карарга ашыкмыйча,— «әтә» димиләр, иң әүвәл «әнәй» диләр. Хәтта ки җыелышка дәшәргә дигәндә дә.

— Нигә икән?

— Соң, аңлаттым шикелле бит инде, бу авылда элек-электән үк хатын-кыз баш бит. Гайшә апа председатель булып йөргән заманнардан ук. Ие, сугышка хәтле дә, сугыштан соңгы елларда да председатель үзе генә түгел, бригадир янсә завферма белән кладовщик ишесе дә нибары хатын-кыздан булды. Ә бит үзләренә, әртилгә баш булулары өстенә, семья карыйсы, бала-чага үстерәсе дә бар.

— Бер төсле «матриархат» сыманрак икән алайса,— дип көлемсерәде Акбашев.

Хәнәфи «матриархат» сүзенең асыл мәгънәсен исенә төшерергә тырышып, маңгай җыерчыкларын ишәйтте, аннары, зиһене ачылып китеп, иреннәрен җәеп җибәрде.

— Әйе, шуңа охшаш. Тагы шуны да әйтим әле: шуны карап торырга караңгы гына кебек тоелган авылдан укымышлы халыкның ниндие генә чыкмаган: укытучы белән врач дисеңме, инженер яки анда геолог дигәннәреме. Хәтта ки, полковник белән прокурорга кадәр бар! Әллә кемнәр. Безнең Әҗер белән Гәрдәлене, аларга өстәп Үтәдемне кушсак та, укымышлылар ул кадәр үк җыелмастыр, чын әгәр.

Бермәл тын гына журнал актарып утырдылар. Ләкин бу хәл алай озакка сузылмады, Хәнәфи бер кызык сөйләргә тотынгач, ахырына җитик инде дигән сыман, җиңелчә көлемсерәү аша, ары алып китте:

— Хикмәтнең дә хикмәте болар түгел әле, Мөслим Гайнаныч. Сез үзегез дә Зәй буеның бәләкәй генә бер авылыннан, дисез. Бәлкем, сездә дә хәл шулайрактыр: шушы Чуар авылында, аңлашыладыр шәт, үз араларыннан кыз алыш, кыз биреш, ягъни өйләнешү күптәннән юк инде, ник дисәң, болар күптәннән үк инде үзара туган-тумачаланып беткәннәр. Шул сәбәпле, үз кызларын чит авылларга очырталар, үзләренә киленне бүтән җирләрдән төшертәләр. Болай гап-гади хәл кебек, әмма иң кызыгы шул: әле бик күптән түгел Чуардан берәү, әнәсеннән җебенә кадәр җитеп, тикшереп караган: боларга төшкән киленнәрдән әлбәттә, уртачага куеп исәпләгәндә, өч баланың берсе генә малай булып туа, ди, калган икесе кыз була, ди. Ә бүтән авылларга киткән үз кызлары исә тегендә тупырдатып малай тудырып ята, ди. Ягъни тегендәгеләрнең ыру канын яңартып, нәсел-нәсәп ботакларын ныгытып...

— Үз авылымда минем мондыйны ишеткәнем дә, искәргәнем дә булмады. Менә бу, ичмасам, гаҗәпнең дә гаҗәбе! — дип, тел шартлатты Акбашев.

— Ә ни сәбәпле? Имештер, Чуарның карт тирәк төпләреннән бәреп яткан көмештәй саф чишмә суының шифалыгыннан, аннары тагы юка урманының аланнарында пешеп өлгергән җиләкләрнең куәтеннән килә, ди, гел малай тудырып ятмага сәләт, һе-һе. Авыл уртасында үтә торган сабантуйларына да егет-җилкенчәк, ярыштан битәррәк, әнә шул кызлар җәһәтеннән җыела да инде. Тагы әйтерем булсын...

Хәнәфи инде сөйләгән хәтлесенә тагы ни өстәргә җыенгандыр, әмма аңа ары ялгап алып китәргә әлегә насыйп булмады: тегендә, клубның зал өлешендә ишек ачылган, идән сайгакларын кыштырдаткан тавышлар ишетелде, һәм менә инде китапханә бүлмәсенең дә ишеге төбенә кадәр ачылып китте.

Иң алдан башына кырпулы бүрек кигән, сызылып киткән тар мыеклы абзый килеп керде — бусы совхозның умартачысы һәм ат җигеп балаларны мәктәпкә йөртүче Рәҗәп карт иде. Аның артыннан ак мамык кал-

факлы, көләч кенә йөзле хатын — клуб мөдире дә, китапханәче дә, бер үк вакытта почтальон да булган Зәйтүнә һәм киң, калын җилкәле, әмма ябыграк чырайлы бригадир Сәгыйть атлап үтте.

Болар тыйнак кына исәнләшеп, хәл-әхвәл белешергә өлгермәде, тегендә янә аяк кыштырдаган тавыш ишетелде һәм китапханәгә, тыштан әллә ни кадәр саф, салкын һава ияртеп, бары да диярлек мамык шәлләргә төренгән җиде-сигез хатын-кыз килеп керде. Болары — ферма эшчеләре — башлыча сыер савучылар иде.

15

— Юк ла, җыелыш та, утырыш та түгел, без менә Хәнәфи Бариевич белән сезнең янга бераз гәпләшеп алыр өчен, ягъни хәл-әхвәл белешү нияте беләнрәк килгән идек.

Акбашев бүлмәдәгеләргә күз йөртеп чыкты. Халык әллә ни күп җыелмаганлыктан, алар клубның зал өлешенә күчмичә, шушында китапханә бүлмәсендә генә утырышып калганнар иде. Хатын-кызларның күбесе башларыннан мамык шәлләрен иңнәренә шудырып төшергән яисә пальто, плюш жакет эчләреннән суырып алып, урындык артларына элеп куйган, һәм барысы да диярлек, изү төймәләрен ычкындыра төшеп, бик иркен сулыш алуда иде. Акбашев аларның байтагын фермада кичке савым вакытында күреп өлгергән, хәтта кайберләре белән аз-маз сөйләшеп тә алгалаган, тик ул һичберенең исемен белми иде.

— Гәпләшергә икән гәпләшергә. Без әзер! — дип елмайды нәкъ Акбашев каршысында, өстәлнең икенче ягында урнашып алган ярыйсы ук өлкән яшьләрдәге хатын. Ул коңгырт чәчен шома иттереп тарап, баш артында бәләкәй генә төенгә укмаштырган һәм аңа дәү генә тарак та кадап куйган иде. Елмайган чагында аның тигез кара кашлары югары чөелеп, маңгаенда байтак кына сырлар хасил булды, әмма иң хикмәтлесе — ике яңагы да матур булып чокыраеп куйган иде. Бригадир хатыны Рәхилә иде бу. Рәхилә, шул арада елмаюын сүрелдереп һәм гәүдәсен чак кына бора төшеп, иренә эндәште: — И син дә инде, Сәгыйть, җүнләп дәшә белмәгәнсең. Өебез иркен, өстәлдә самовар гөжләп калды, бергәбергә чәй җоткалап кына гәпләшеп утыруларга ни җитәр ие!

Ишек төбендә Рәҗәп карт белән янәшәдә калын сырмасын җилбәгәй җибәреп утырган Сәгыйть, какча йөзен чытып, үзенчә акланган итдай иттерде:

— Соң ни бит, фермада җөргән чагында ук әйткәнием дә бит, үзләре инде...

— Иркенләп сөйләшү өчен монда да бик әйбәт,— дип үз сүзен кыстырды Хәнәфи.— Ә тегесе аның соңыннан әйбәтрәк булыр, тамаклар кипкәчрәк.

Шул мәлне Рәхилә янында утырган зур, алтынсу алкалы хатын, күршесенең колагына таба иелә төшеп, шыпыртлап кына әйтә куйды:

— Көн тәртипләре дә җук икән. Болай хәл-әхвәл белешү генә булгач, тегеләрне дә, дим, телевизор төбеннән кубарып алып, үзебезгә ияртәсе калган ла, Рәхилә апа!

Монысы кулы белән борыны төбеннән чебен-черкине кугандай гына иттерде:

— Таптың: аларның тегесе теге җакта, бусы бу җакта ич. Җүнле сүз чыгарып, уңайга сукаларлар дип беләсеңме әллә?

Ике хатын, үзара шыпыртлап кына сөйләшсә дә, аларның сүзен барысы да диярлек ишетеп алды. Бу исә Мөслим Акбашевка сүз очын эләктереп алып, йомгакны тәгәрәтеп җибәрергә бик әйбәт булды.

— Килми калганнарга үпкә тотмыйк, вакыты җиткәч, алар белән дә сөйләшенер, әле бер генә дә түгел,— диде ул, мөлаем гына көлемсерәп.— Сез көн тәртибе, дисез инде. Бу юлга җыелыш ук түгел түгеллеккә, әмма, шулай да, бәлкем сез хаклыдыр: бәләкәй генә булса да, көн көтүебезгә караган нәмәрсә кирәктер, ә? Алайса, һем, фермагыздагы хәлләр хакында чак-чак кына...

Һәммәсе дә сагайган бер кыяфәттә директорга төбәлде. Ләкин Акбашев фермадагы эшләренә бәйләнү-нитү түгел, киресенчә, боларның сырт йоннарын уңай якка таба сыпыргалагандай иттерде: ферма каралтыларының төзеклеген, мал-туарның ярыйсы ук көр булуын мактап алды, азыкка шушындый кытлык елны әрәм-шәрәм итүләргә юл куелмавын аерата хуплады, ул да түгел, ел тәүлегенең шушы чоры өчен савымның да әйбәт кенә булуы куанычлы күренеш икәнлеген әйтте. Ахырда, бар күзәтүләренә нәтиҗә ясагандай рәвештә, Чуар авылында чын-чынлап уңган куллар эшләгәнлегенә беренче килүендә үк тәмам ышана язганлыгын сиздерде.

Мондый сүзләрдән бүлмәдә утыручыларның һәркайсының диярлек йөзенә җылы һәм якты нур иңде, авызлар ихтыярсыздан җәелеп китте. Рәхилә дә рәхәт елмаюда эреп киткән иде, әмма ул, иң беренчеләрдән булып уч төбенә йөткергәләп алды да, үткен күзләре белән Акбашевка текәлде:

— Салпы ягыбызга салам кыстыруыгыз гына түгел микән, Мөслим Гайнаныч, ә?

— Нишләп? Уйлаганымны ихлас күңелдән әйттем,— диде Акбашев, шаяртырга һич уй-исәбе юклыгын аермачык сиздереп.— Ә теге фермаларда исә совхозның ай-һай ла икән хәлләре! Бигрәк тә Әҗердә.

— Бу кышны һәркайда да кытлык,— диде алтынсу алкалы хатын, карашы белән һавада чебен күзләгәндәй рәвештәрәк, янәсе яңа директорның сүзләрендә аның өчен ис китәрдәй һич кенә дә яңалык юк.

— Килешәм,— дип ияк какты Акбашев.— Әммаездә азык ягы мулрак, ә фермагыз иркенрәк күренде әле миңа. Әллә, дим, симертәсе малларның бер кадәресен Әҗер фермасыннан сезгә күчерергә микән? Бер илле-алтмыш башны, ә? Менә шул хакта...

Акбашев әйтер сүзен әйтеп бетермичә, кисәк сулышы киселгәндәй, бүленеп калды: бүлмәдәгеләрнең һәммәсе дә шул арада йөзләренә караңгылык иңдереп, каш-күз җимереп өлгергән иде.

Иң әүвәл өстәлнең түр башындарак утырган бәләкәй генә, йомры гына хатын купты:

— Әҗерданме? Шул хәтле малнымы? Үзләре анда азыкны әрәм-шәрәм итеп ятсын да...

— Көзгелектә ни караганнар? Анда бит малны азыкка карабрак булганнар ие,— дип күтәреп алды алтынсу алкалы да. Аның күз карашы, һавада «чебен күзләүдән» капыл түбән иңеп, төкселәнеп директорга төбәлгән иде.— Жу-ук, азык җәһәтеннән безнең үзебездә дә хәлкәйләр хәл әле, җаманның да җаманы!

Тәрәзә төбендә, читтәрәк утырган янә бер хатын, урыныннан кубып, һавада кул селтәргә кереште:

— Һаман да шул бер Әҗер! Җәшелчәчелекләренә барып булышмага да, урманда җәшел җафрак-ботак җыйганда да, бүтәнендә дә җәрдәмгә безләр. Һаман да шулар чоңгылда! Иманнары кайда икән?

Акбашев аптыраган, хәтта каушаганрак кыяфәттә калган иде. Бу хәлдә Хәнәфи өлгерлек күрсәтергә ният итте:

— Инде дә корыган чытырман үзегез: шырпы тидермәс борын чатыр-чатыр кабынырга гына торасыз! — дип гүелдәде ул калын, күкрәк тавышы белән.— Соң, монда мал китертү турында болай гына, киңәштабыш итешү төсендә генә әйтелде ләбаса! Сынап карау өчен, дигәндәй.

Рәхиләнең тигез, кара кашлары шундук маңгай сырлары өстенә менеп китте:

— Сынап карау өчен? И Хәнәфи, туганкай, безне сыныйсы жук, без инде күптән сыналган! — Ул өстәлгә таянган хәлендә, учын җәеп җибәреп, бүтәннәргә тыелып торырга ишарә итте, үзе исә күзләре белән кемнедер эзләштерде.— Эһе, зоотехник Заһидә Гәрдәлесенә кайтып киткән икән инде, ну, жарый.— Моның соңында борылып, бригадир иренә төбәлде: — Сәгыйть дим, ул тиклем өстәмә малны сыйдырып булырмы? Ни уйлыйсың?

Тегесе малахай бүреген бөтәрләгән шәйгә тартыштырды:
— Соң, бик тырышсак, бик кысынкыланcак кына инде. Аннары өстәмә фураж биреп, бардасыннан-мазарыннан җитәрлек өлеш чыгарсалар гына.
— Анысы, әлбәттә, тиешенчә бирелер,— диде Акбашев.
— Ярар, ничек тә сыйдырырбыз, Мөслим Гайнаныч,— диде Рәхилә.
— Менә бит,— дип елмайды Акбашев.
Шул мәлне, Хәнәфи, Әҗер кешесе буларак, үз әрнүен сиздермичә түзә алмады:
— Шул хәтле дә каныгырсыз икән безнең Әҗергә! Тетмәсен тетү генә түгел, җир йөзеннән себереп үк ташлар идегез бугай!
Болай дию белән ул, әлбәттә, сөйләшүне бөтенләй бүтән тарафка борып җибәрде, ләкин инде хәзер гәп дулкыннары, баягыча чал сыртланып, әпен-төпен чайпалмыйча, йомшак һәм ыспай гына тирбәлү җаен алды.
— Бик тә хәҗәте бар ие! — диде тәрәзә төбендәге хатын көр генә тавыш белән: аның йөзенә карагандa, ул менә-менә көлеп тә җибәрер иде шикелле.— И Хәнәфи гөлием, инде онытгың дамыни теге чакларны? Сугышлар бетеп, дим, беренче корган сабан туебызны? Тырыйк-тырыйк, һай, кыйландырган да иең соң җаралы аякларың белән кичке уенда! Җаныңда көмеш җәшләрен җылтыратып Рәсүлең бөтерелмәсә иеме? Мин үзем, ни тол солдатка башым белән, суырып кынайлар алырдай хәлләрдә ием! Ә безнең кызлар соң?.. Кая анда каныгу-кыерсытулар! Үзеңә дә, Хәнәфи дускаем, ыру-тамырыңны җаңартмага безнең авылныкы бик кенә дә җарап куйгае булыр ие җугыйсә.
Хатын-кыз, бары бердәм булып, шау-гөр көлешеп алды. Хәнәфи дә бирешергә теләмәде:
— Һы, минем Рәсүлә сынаттымы әллә? — дип күкрәк киерде.— Тупырдатып өч малай, бер кыз табып бирде!
— Хет анысы җарый, шәп, булдырган! Рәхмәт үзенә!
— Ә каныгу-кыерсыту дигәннән,— дип үз сүзен кыстырды алтынсу алкалы хатын, Хәнәфине авырттырыбрак чеметергә чамалап.— Соң, сез үзегез теге заманны хәтсез авылларны кушып колхозны эреләндерергә тотынгач, безнең Чуарны төбе-тамыры белән җотарга аз тырыштыгызмы?
— Безмени? Бөтен Әҗермени? Яхъя Таипыч бит ул. Ул да югарыдан кушкангарак кына,— дип төшендермәкче булды Хәнәфи.— Ә соңыннан чигенмәдеме, буйсынмадымы сезгә? Менә бит культура учагыгызны ничекләй яңарттырды! Телевизор белән магнитофонга тикле бар, бүтәнен әйткән дә юк!
— Һе-һе, җаңарттырды! — дип кинәт көлеп җибәрде Рәхилә.— Председатель булуы өстенә үзен Татарстан депутаты итеп сайлагач бит инде болары!
Бу минутта һәммәсе дә күз карашы белән Акбашевның күкрәгендәге депутатлык значогын да, аның үзен дә кармалап, сыйпаштырып алгандай итте, янәсе: «Менә инде син дә депутат икәнсең, ни яхшылыклар кылырсың безләргә?..»
Шул мәлне Рәҗәп карт, сүзгә катышмыйча утыруына, ниһаять, чик куеп, әйтергә дип килгәнен тамак кыргалый-кыргалый чыгарып салырга булды:
— Син... кем... Мөслим энем, безнең авылның күчерелүсе хакында беләсеңдер инде, име? Эһе, беләсең. Мин ни, әгәренки, алтын алмам тәгәренки дигәндәй, безнең Чуар шушында утырган җирендә утырып калса, ничек булыр ие, дим? Җәгъни дә бөтенләйгә күчерелмиенчә, куптарылмыенча, э?
Үтәдем белән Гәрдәледәме, Чуардамы яки Әҗернең үзендәме, берәр җыелыш-мазар булса, һич югы, менә болай гап-гади гәп корып җибәрсә дә, халык бу хакта сүз кузгатмый калмый иде. Бүтәннәр белән бергә,

әлбәттә, Хәнәфи дә колак торгызды. Әмма яңа директор, билгеле, һичнинди яңа сүз әйтә алмады.

— ҚамАЗның санитар зонасына эләккәч, ни хәлләр кыласың инде,— дип муенын әчкә батыру белән генә чикләнде.

— Зона, диләр шул, зона. Безгә ким дигәндә бер унике җыллар кагылмыйнча түзсәләр икән хет.

— Нишләп тап унике ел?

— Соң, минем бу дөнҗада җәшәр чамам шул хәтле генә калды. Минем бабай да, әтәй дә житмеш дүртне тутырып, житмеш бишенчегә чыккач, вафат булган. Аларныкыннан һич уздырасым килми. Бу фани дөнҗада артык мәшәкатьләр тудырып җөргәндә, тегендә мәңгелек җалга, дим, барып җатуларың рәхәтрәк булырдыр.

— И җәшәрсең әле, Рәҗәп агай, җәшәрсең! Әле кияү җегетләредәй күренәсең, сөбханалла!

— Инде, әгәренки, ходай әмер биреп, артыгын җәшәргә насыйп була икән, ул чагында барыбер хәтта Җаңа Қаланың таш капчыгына да башымны тыгасым килми!

Бу сүзләре белән Рәҗәп карт бүлмәдәгеләрне бер көлдереп алмакчы да иде бугай, ләкин һичбере иренен дә кыймылдатмады.

Ул арада өстәлнең түр башында:

— Ә ҚамАЗны без чакырып алганмыни, аның зонасына без үзебез теләп кергәнмени? — дип чытырдап алды йомры хатын.— Бик кирәксә, әнәтерә, үзе чигенсен! Без, ичмаса, зона дигәннәренең читендәрәк калыр иек.

— Һе-һе, син нәрсә, ҚамАЗны арба җәисә чана, һич югы паравъяз дип белдеңме әллә! — дип, башын артка таба чайпалдырып, гүелдәп көлеп җибәрде бригадир Сәгыйть.

Ләкин аның шаркылдавына да кушылып китүче булмады.

Моннан ары инде, әле бу тарафтан, әле теге яктан, кайсы моң-зарын ачык сиздереп, кайсы моң-зарга ачы юмор да катнаштырып, түгелергә тотынды:

— Күченәсе булгач, жорт бурасын түгел, хәтта ки мунчаныкын да бураттырмыйлар. Авыл советы тыкшынырга күз тозырайтып кына җөри!

— Их, үзебезнең прокурор Зөфәр әллә кайда Казахстанның Күкчәтавында законнар саклап җата. Монда бер кайтып, актарынып караса, безне җаклардан берәр нәмәрсә китереп чыгармас ие микән?

— Ә сез законның үзенә орынмыйчарак кыйланыгыз, кайчагында, үзенә каты кагылмасаң, күз йомып та калгалый бугай ул.

— И Хәнәфи, сиңа шулай сөйләнергә жинелдер шул: сезнең Әҗер ҚамАЗга сигез-тугыз чакрымнарда ук, ә безгә?

— Мунча дигәннән. Шимбә-якшәмбеләрдә авылыбыз төтенгә күмелә. ҚамАЗны «нервы тегермәне» диләр әнәтерә. Безнең мунчаларда аны коручыларның ничәмә җөзе җан җаңартып, дәрт-дәрман җыеп китмәгәндер инде, ә? Ичмасам, шунысын аңласыннар ие!

— ҚамАЗ анысы хөкүмәткә кирәклеккә бик тә кирәктер инде. И шулай да... без дә хөкүмәтнеке түгелмени?

— Хөкүмәтнеке булганга күрә, кайгырта да бит инде: зонага бикләнеп, черешә күрмәсеннәр, сау-сәламәт яшәсеннәр, тәрәкле булсыннар, ди.

— Әнәтерә Казан каласының үзендә әллә ни хәтле завод-фабрик. Арада әллә ниндиләре бар. Берәрсенең әйләнә-тирәсеннән берәр кайчан берәр кемсәне читкә себергәннәре булдымы икән? Рәхәтләнеп җәшәп җата халык, аны-моны уйламый да.

— Ием, җәшләр ни кылса кылыр, җаңа поселокка күчәме җәисә Җаңа Калага китәме, үзләре белер ие. Ә безгә туган туфрагыбыздан кубарылмыенча гына Чуарыбыз белән бергә-бергә картаясы гына ие шул.— Карт имән кебек, тәмам корыганчы диген.

Рәхилә, үзенчә дәрәҗә саклагандай кыланыпмы, әллә болар түгелә-

сен түгел бетерсен дә яңа директор Чуарның бар булган нечкә якларын миенә сеңдереп калсын дипме, моңа кадәр дәшми-тынмый гына утырган иде, менә инде ул да кымшангалап алды һәм:

— Унике-унбиш җыллар безгә тимиенчә түзә алсалар икән шул, җаннарыбыз тынычланыбрак торыр ие, ичмаса,— дип, бик тә авыр көрсенеп куйды.

Шундук аңа янәшәсендә утырган алтынсу алкалы үзенекен кушылдырып җибәрде:

— Казан вокзалында поезд көтеп, чемодан өсләрендә утыргандай җәшәп ятулары бер генә дә рәхәт түгел шул.

Бу минутта һәммәсе дә күтәрелеп яңа директорга күз төшерде. Акбашев, ике кулын да өстәлгә салган көенчә, керфек тә селкетмичә, бер ноктага төбәлеп, утә житди кыяфәттә уйчанланып калган иде. Ямьле Зәй буенда утырган үз туган авылын исенә төшереп, онытылып китүе булды микән? Бераздан ул да, ниһаять, бик тә тирән иттереп көрсенеп алды:

— Ярар, ничек тә сез теләгәнчә итәргә тырышырбыз...

Бүлмәдәгеләр бары бердән җиңел сулап куйды.

## 16

Икенче көнне иртәнге планеркада яңа директор Хәнәфигә бөтенләй бүтән кеше булып тоелды. Юк, әлбәттә, Акбашев алай карап торырга һичнинди дә үзгәреш кичермәгән, шул ук мөлаем ачык чалымнар, тавышын күтәрмәс, кубарылып орынмас, әмма аның сүз сөреше, китереп чыгарган хикмәтләре...

Утырышка җыелырга тиешле кешеләр җыелып беткәч, Акбашев бер тын үз эченә бикләнеп, уйчанланып утыргач, кинәт барысына берьюлы күз йөртеп чыкты да сәер генә көлемсерәү аша әйтә салды:

— Заманында үз туган авылымда, аннан ахыргы совхозда менә шушылай ук баш булып тотынгач, беренче елның язында сыерларга түбә саламнарын төшереп ашаткан идек. Анда ферма түбәләре гел диярлек салам иде. Ә сездә ферма каралтылары шәп, түбәләре тоташтан шифер, нәселле мал-туар. Әмма ләкин шул нәсел сыерларына шифер ашатып була микән?

Бу һәммәсен дә сискәндереп җибәрде. Иреннәр калын кысылды. Ә директор тавышын тамчы да үзгәртмичә янә сорау белән төбәлде:

— Совхозда малга ашатырга силостыр, печән-саламдыр, тагаен күпме калды икән, кем әйтә ала?

— Кара исәп белән исәпләгәндә,— дип тотынган иде баш зоотехник Гомәр, әмма аны Акбашев капыл бүлдерде:

— Юк, ак исәп белән. Эһе, белмисез? Бер айга микән, әллә ай ярымга ук микән? Тәк, тәк. Ә бит җәйгә чыкканчы ай-һай күп яшисе әле! Былтыр көз, ишетүемчә, сезнең Чаллы тирәсендәге кайбер хуҗалыклар Украина, Кубань якларына барып, салам пресслатып алып кайткан, ә сез?

— Үзебезнеке житәр дә кышны-язны ничек тә җырып чыга алырбыз әле диебрәк уйланылган иде шул,— дип аңлатмакчы булды Гомәр.

— Басу хәлләренә арт белән борылып, күктәге болытка карабрак уйланылды микәнни?

Җавап кайтаручы булмады. Байтагының йөзендә кырыс-уйчан да, хафалы да чалым. Хәтта моң-сагыш төсмере дә бар сыман. Ә Акбашев исә һаман да шул бер тон белән һәм әйтер фикерен һаман да шулай сорау рәвешенә төребрәк, ут тамызгалауда булды:

— Ары таба да төрле әрәм-шәрәм итүләргә, бигрәк тә Әҗер фермасында, күз йомып йөрүләр килешерме бу хәлләрдә? Азыкның бөртеге дә кадерле чакны, кыенлыкны ходайга сылтап, бер үк вакытта сансапне бар дип тә белмичә, борын салындырып яшәү шәпме? Һәркем-

нең дә персональ җаваплылыгын онытып торыйкмы? — Кинәт ул бик тә авыр сулап куйды. — Ә бит мал-туарны җәйге чорга күтәрәм хәлендә чыгаруның мактанырлыгы ни? Сау-сәламәт булсын ул! Сау гына да түгел, көр булсын! Җитмәсә, әнә КамАЗ төзүчеләре дә сөт-май, ит дип, аның да һәйбәт сыйфатлысы дип сорап ята түгелме?

Янә дә тынлык. Йөзләрдәге күләгә куера гына төште кебек.

Акбашев өстәлгә сузып салган кул сәгатенә карап алды:

— Нәкъ сәгать тугызда Чаллыда киңәшмә. Төш турларына әйләнеп кайтырмындыр. Аңарчы алты-җиде автомашина әзерләп булырмы? Әлбәттә, ышанычлы, шәп кузовлыларны!

— Булмаска, булырдыр,— диде Әҗер управляющие Мөхлис.

— Булыр! — дип кырт кисте баш инженер Рәкыйп.

— Сәфәр озын гына, дөрес, юл гел асфальт диярлек. Монысында үзем дә китәрмен. Ә шоферларны кисәтерсез: бу юлында куна калырга туры килер. Машиналарның икесенә печән оны, ягъни яшь маллар өчен витамин төясәк, калган хәтлесенә прессланган салам. Анда безнең совхозның... — Акбашев кисәк бүленеп калды, әмма сүзен шундук төзәтеп куйды: — Андагыларның ким дигәндә бер ел-ел ярымлык резервлары бар әле. Бөлмәсләр! Әле бер генә дә барасы булмас, нишлисең.

Кабинеттагыларның йөзенә чак кына яктылык нуры инде шикелле. Күбесе җиңел сулап куйды, ә беришесе, сизелер-сизелмәс кенә үзара күз атышып алды: янәсе, «сизденме, тегендәгеләрне нинди рәхәттә калдырган!»

Монда, түр өстәл артында утырган директорның да калынча кара кашлары язылыбрак китте шикелле.

Ә болай совхоз авылларында халыкның күңеле көр диярлек. Дөрес, ыңгыр-шыңгыр йөрүчеләр дә, пыскып кына җан асраучылар да бөтенләй үк юк түгел сыман. Бер җыелышып сөйләшеп алганда зыян итмәстер.

— Нәрсә, совхоз активын җыябызмы? — дип сорады партком секретаре Садыйков.

— Актив? Нишләп? Иң әүвәл үзебезгә шушында дирекция белән парткомда ныгытып сөйләшәсе булыр. Әлбәттә, рабочком белән комсомолны да тартып. Хәер, совхозда бер җыелышны уздырмыйча да ярамас, тик ул тантаналы булыр.

— Тантаналы?

— Әйе. Соң, ничек инде Яхъя Таипычны озатмыйча гына ярасын ди? Бу кышны бер безнең совхозда гынамыни, бөтәннәрдә дә хәлләр хәл бит — анысын инде ходайга сылтыйк. Ә Яхъя Таипычның үткәндә кылган хезмәтләре, яулашкан үрләре? Үкенечкә калмасын, дим. Үзенә бик әйбәтләп бүләк тоттырып, җылы сүзләр әйтеп вә һәм шәп концерт биреп, ә!

— Әле чирләбрәк киткән ул: йөрәк, ди, кан басымы, ди, аннары нервы, ди тагы. Санаторийга дигән путевкасын да кире тапшырмакчы бугай. Больниска салмагайлары үзен,— дип күпләр өчен күңелсез яңалыкны әйтеп салды Мөхлис.

— Шулаймыни? Менә бит. Димәк ки, тантаналы кичәне һич кичектерергә ярамас. Бәлкем, аның шифасы да тияр: йөрәге дә үз оясына тынычлап кереп утырыр, нервысы да үз эзенә басар, ә?

Йөзләр, ниһаять, тәмам ук нурланып китте шикелле.

Ләкин Акбашев, өстәлдә яткан сәгатенә янә күз төшереп алгач, шундук кире кайтып, көндәлек мәшәкатьләр сукмагына басты:

— Ә партком утырышында, кһем, безгә, мөгаен, шулай ук һич кичекмәстән, белгечләрне генә түгел, аерым коммунистларны иң җаваплы участокларга беркетмичә ярамас. Фермалардагы хәлләр хакында көннекен — көнгә менә шушында исәп тотардай иттереп!— Моны әйткәч, ул башын партком секретарена таба борды.— Менә шул беренче утырышта

ук, Әхсән Садыйкович, сезнең «акбур белән кара тактаны сагынуларыгыз» турында да ачыграк сөйләшмичә булмас. Директор иң әүвәл парткомга таянмыйча, кемгә таяна ала инде, ә?

Садыйков ык-мык итеп калды, маңгаендагы күзлеге кулына күчте.

— И шулай ук рабочком. Берәүнең гыйлем сендереп, укып йөрүләре, ярый, бик әйбәт диик. Ләкин рабочкомны айлар буена иясез тотулар шәпме? Яман түгелме? Ә бит бар сездә рабочкомны уртага җигелеп тартырдай кеше. Бар! Хезмәт юлы зур, халык алдында абруйлы, сүзе үтемле.— Соңгы сүзләрен әйтеп бетергәндә, Акбашев күз кырые белән генә, әмма тирән мәгънә салып, Хәнәфигә карап алды.

Бу мизгелдә Хәнәфинең йөрәге жу итеп, бар гәүдәсен салкын дулкын кымырҗытып узды.

Биш-ун минут үтүгә, яңа директор, куе-яшел «УАЗик»ка утырып, Чаллы тарафларына китеп тә барды.

Конторада эш бүлмәләре булган белгечләр, маңгай җыерчыкларын сырландыра-сырландыра, колак артын кашып утырыр өчен, әкрен-әкрен генә үз урыннарына таралышты. Калган халык урамга, саф һавага чыкты.

Шунда ни турында сүз кузгатырга белмичә аптырабрак торган төркем эченнән берәү папиросын бик тырышып суырды-суырды да:

— Борчакны ныгыттырып куырырга чамалый бу! — дип, һәркайсының уртак уен ярып салды.

Хәнәфи, башын түбән игән көенчә, тыгыз карны изә-изә мастерскоена таба атлады.

Көн тып-тыныч иде. Җәяүле буран алар Чуарга барган төнне тукталып, әлегә зәһәр шаярудан тыелып тора иде.

Юл-сукмак кырыйларында кар бөртекләре җем-җем итә. Табигатьнең бураны тынган да тынуын... Хәнәфинең үз күңелендә зилзилә бураны кубарга җыена — иңнәренә күтәрә алмаслык йөк булып, коточкыч кыя-тау аварга тора сыман иде.

«Менә сиңа яшьти! Баштук Чуарга бармаска кырт кисәсе калган үзенә! Барган тәкъдирдә дә артыгын белдекле булып кыланмаска, тиккә тыкшынмаска итәсе икән. Димәк ки, Чуарга баруларында аны сынавы булган. Инде менә Хәнәфинең үз хәлләре дә чуарланып китте. Бөтен дөньясы чуар! Их, яшьти, яшьти, минем башны тыгарга итмәсәң, «рабочкомлык»ка бүтәннәр беткәнмени совхозда?»

## 17

Хәнәфи көне буе шул хакта уйлады. Мастерскойда, азрак онытылып торырга тырышып, теге эшкә тотынып, бу эшкә ябышып карады, әмма күңелендә инде хәсрәт булып оялаарга өлгергән нәрсәне тарату мөмкинлекләрен таба алмады. Кулыннан эш бармады. Әлбәттә, озакка сузмаслар, рабочком утырышын шушы көннәрдә җыярлар да. Зиннур барыбер китәсе кеше — болар совхозыннан шулай ансат кына котылуына чамасыз сөенер инде. Хәтта, кемгәдер ышандырганча, бер ящик коньяк куюы да ихтимал. Ә Хәнәфи? Моңа кадәр гелән дә бүтәннәр ышыгында гына яшәргә күнеккән җаны белән ул андый йөкне күтәрә алырмы? Берзаман, юк кына нәрсәгә дә сөрлегеп, авыз-борын канатмасмы? Кичә Акбашевка ияреп Чуарга барганына кайта-кайта үкенде Хәнәфи.

Көндез, төшкелеккә кайткач, Хәнәфи башына төшкән хәсрәтне хатыны Рәсүләгә сөйләп биргән иде, тегесе, бер мәл күзләрен челт-челт йомгалап торгач, гадәтенчә кулларын күкрәге өстенә кушырды да:

— Жаңа директор әйтте, дисеңме? Һай гынам, андыен җөкне синямы соң өстерисе! — дип ухылдап куйды. Бүтән сүз әйтмәде дә.

Аның ухылдап куюы исә Хәнәфинең пошаманын көчәйтеп кенә җибәрде.

Хәер, хатыны Рәсүлә әллә ни төпле киңәш-табыш бирердәй хәлдә дә түгел иде: аның күңелен дә, зиһенен дә бүтән төрле хафа — һаман шул бер кызлары Рәмилә турындагы уй-исәп янә биләп алган иде. Һәм ул ачы нәрсә, әлбәттә, Хәнәфинең үзен дә читләтеп үтмәде. Шулай инде: сөремгә сөрем кушылучан.

Кичә инде шактый соңарып, Чуардан кайтып килгән чагында, Хәнәфинең кәефе болай ярыйсы гына көр һәм күтәренке иде. Әмма өенә кайтып керсә, аны кызлары Рәмилә турында һич тә матур булмаган хәбәр көтә икән. Бу күңелсез яңалыкны аларга Чаллы Сельхозтехникасында куна-төнә эшләп яткан уллары Рәмзи алып кайткан иде. Аның сөйләгәне шул: тегеннән, дөнья бетереп әйләнгән туристик экскурсияләреннән, чаллылар һәммәсе дә кайтып төшкән, әмма алар арасында Рәмилә генә юк, ди. Моны Рәмзигә Чаллыда барын да күзәтеп һәм белеп яшәгән Габделбәр әйткән. Рәмзи, билгеле, өнсез калган һәм, йөрәгенә түзә алмыйча, сеңлесенең юлдашы булган Светаны эзләп киткән. Тапкан ул аны: шул ук тулай торакта, күрше бүлмәләрнең берсендә яши икән. Ул кызый баштарак: «Мәскәүдә бер төркем Казан яшьләре белән төшеп калды ул. Мәскәүне тагын да әйбәтләбрәк йөреп чыгарга, бар булган музейларын карап бетерергә дип. Озакламас, кайтып та төшәр»,— дигән. Әмма Рәмзи: «Нинди яшьләр, кемнәр ул?» — дип төпченебрәк, кырысланыбрак сорашырга тотынгач, Света чын-дөресен әйтеп салган: «Рәмиләне аны теге мыеклы егете моннан бер атна элек үк Киев каласында алып калды. Анда аның нииндидер туганнары яши икән, әнә шуларда кунак булып ятарга, кинога, театрларга йөрергә дип». Менә шул: сер дигәне хикмәт, хикмәт дигәне михнәт. Кыз башы белән бөтенләй уйламаган-белмәгән ят кешеләрдә ниткән кунак булулар ул? Инде атнадан артык бит! Кайда монда әдәп һәм намус, кайда, һич югы, оят?

— Ул бит әле эштәге кеше исәпләнә, укырга йөрисе дә бар,— диде Хәнәфи, бу ямьсез яңалыкны ни рәвешле сеңдерергә белмәстән.— Ичмаса, әнә шунысын җайлау хакында теге кем... үзебездә яшәгән белорус марҗасына бирәр үтенеч хәбәре салгандыр бәлкем, мутлак җан?

— Анысы шулай инде: җыен җахшылык белән изгелекне аңа Мила апасы эшләп тора. Син, улым, зинһар, аның үзен табып, барын да төпченеп белеш әле! — дип үтенде Рәсүлә, җанлана төшеп, әмма ул шуның артыннан ук тирән көрсенеп куйды: — Аңа, ул ипле җанга да бөтенесенә бер җулы күз-колак булулары бер генә дә җиңел түгелдер инде. Аның канаты астында бер безнең Рәмилә генәмени? Ике дистәләп бугай бит алар, ул җенлеләр.

Рәмзи, бүген Людмила Крутьконы күреп, аңардан берәр нәрсә ачыклый алса, кайтып төшәргә тиешле иде. Инде берни дә белешә алмаса, озын юллар үтеп, кайтып йөрмәячәге турында да кисәтеп куйды. Әмма бүген аның өйгә кайтып төшүе этисе Хәнәфи өчен үлеп кирәк иде. Бу төпчек улы инде хәзер хезмәттәге уң кулы гына түгел, гаиләсендә иң ышанычлы һәм төпле терәгенә әверелеп куйган иде. Рәмзи белән киңәш-табыш итәсе бик-бик килә иде аның: көтмәгәндә куркыныч рәвештә калкынып чыккан «рабочком» мәсьәләсендә ул ни әйтер икән?

Кичке караңгыда мастерскоеннан кайтып килгән мәлендә, үз урамына кергәч, Хәнәфи өйләренең бар тәрәзәләре дә балкып торуын күреп алды. Рәмзиләре өйдә булганда, шулай ялт иттерә инде ул бар өйне. Бүтән ихтималны исәпкә кертмәстән, Хәнәфинең эченә җылы йөгерде, җилкенеп китте: «Тегеннән берәр юньле хәбәр алып кайткандырмы-юкмы, әмма бүген алар төпчек улы белән әйбәтләп киңәш-табыш итәчәк, димәк».

Шул уй белән капкадан керде, шул җылы өмет белән өй ишеген каерып ачып, бусагадан атлап үтте.

Атлап үтте дә кисәк тораташтай катып калды. Алгы өйнең ян элгечендә һәйбәт мех якалы ике пальто эленеп тора: берсе хатын-кызныкы, икенчесе ирләрнеке — кыска итәкле, элгеч өстендә шундый ук шәп мех-

тан тегелгән ике бүрек, берсе йомры, күперенке, икенчесе кыскарак йонлы, козыреклы. Әлгеч астында идәндә исә модный сапожкилар белән янәшәдә җылы эчле, шәп күнле ирләр ботинкасы. «Димәк, димәк, менә сиңа пәрәмәч икән лә!..»

Кабаланып өстеннән сырмасын, башыннан бүреген салды, әмма аларны элгечкә элеп тормыйча, алгы өйнең ишек төбе сәкесенә генә атты. Аның соңында киез итекләрендәге галошларны ычкындырды.

Хәнәфи, какча яңакларын кыймылдаткалап, түр якка бусага аша атлап үткәндә, тегеләр — кызы Рәмилә белән «мыеккай» Женя Мында — утырган җирләреннән кубып, аңа каршы киләләр иде инде.

— Исәнме, әтәй! Сау-сәламәт кенә эшләп йөрисеңме?

— Әлегә шөкер диярлек. Үзең соң? Үзегез... Күрәм-күрәм: буш кул селтәп кенә кайтмагансың, үзеңә сыңар да ияртқәнсең икән.

— Соң, әти...

Күрешүләре болай җылы гына булды. Женя Мында аның кулын аерата нык итеп кысты:

— Сез, зинһар, кичерегез инде безне!

Утырыштылар. Хәнәфи гадәтенчә диван почмагына сеңде. Күр инде: табын өстәле бөтенләй балкып тора лабаса: озын аяклы вазаларда иртәнге алтын кояш төсле эре-эре әфлисуннар, алсу йөзле алмалар тутырылган, мае, шикәре-вареньесы куелган. Өстәл башында кукыраеп һәм тигез гөҗләп көмеш самовар утыра. Теге кичне Рәмилә моннан качып киткән сәгатьтә дә ул шулай моңлы җырын сузып утырган иде. Ул, гомумән, урыныннан кузгатылмаган һәм бүгенгәчә үз җырын өзмичә саклап калган, тик шушы кич өчен табынны гына бөтенләй бүтән рәвештә үзгәртергә мәҗбүр иткән сыман иде. Ләкин табын янына утырышырга дәшүче булмады, булмәдә кинәт кенә авыр һәм киеренке тынлык урнашып алды.

Хәнәфи күз карашын кызы Рәмиләгә күчерде. Кызының өстендә бик тә килешле тегелгән, әмма әкәмәт сәер бизәкле — алсу өслектә зәңгәр яшеннәр чатнаган, яшькелт йолдызлар җемелдәгән — күлмәк, үзе колак яфракларына алтынсу бөҗралар элгән, чәч өемен дулкын-дулкын иттереп күпертеп куйган, иреннәре һәм бит алмалары да, күлмәге төсенә кереп, пешеп-янып тора. Тик күз карашында гына сизелерлек җанлану белән бергә азрак инәлү-ялвару катыш өркү дә оялап алган сыман. Әйе, әле кайчан гына, нибары бер ай элгәре генә, бөтенләй бүтән кыяфәттә иде лә бу! Инде хәзер аның кызы Рәмилә дә кебек, ул да түгел кебек.

— Ишетмәсәң, ишет, әтисе: өйләнешергә рөхсәт сорарга дип кайткан болар. Рәсүләнең тавышы кисәк чатнап китеп, еламсырауга күчте.

Хәнәфи түр урындыкта тез өсләрендә кул кушырып утырган хатынына ялт кына карап куйды. Башта ук аңа игътибар итмәгән икән: хатынының кыяфәте үтә моңсу, күз төпләре дымлы, йөзенә тимгел-тимгел кызыл чыккан.

— Нәрсәү?

— Соң, әти, аның ни гаебе бар? Безнең бүтәнчә әмәлебез калмады. Сез инде...

— Аның Киевта менә бусының туганнарында кунак булып ятабыз дигәне дә күзгә төтен җибәрү генә булган икән.

— Соң, әни, анысы бит бүтәннәр өчен. Вагонда калганнарга. Чит-ят халыкка барын берьюлы ничек әйтеп саласың ди? Ә сиңа мин чын-дөреслəп һәммәсен сөйләдем дә бирдем. Алайса син дә, әти...

Рәмилә ашыга-кабалана әтисенә дә сөйләп бирде: Киевта чынлап та Женя Мынданың бернинди туганнары да юк, алар анда театрга-мазарга йөрергә уйламаганнар да, Рәмилә иптәшләреннән аерылуга, Женя Мында белән икесе самолетка утырып, Одессага очканнар. Аннан алар шул ук Одесса өлкәсенең Молдавия белән чиктәш бер районына юл тотканнар — шунда зур гына поселокта егетнең туганнары яшәп ята

икән. Женя Мынданың әтисе гомере буе слесарь-электрик, әнисе медсестра булып эшләгән, хәзер икесе дә пенсиягә чыккан икән. Поселоклары бик матур, үзләре дә бик хозур яшиләр, ди. Ә Женя аларның төпчек уллары икән.

— Алар бик ошатты миңе, хәтта ки яраттылар диярге дә була!

— Башларың тәмамлай әйләнгән икән, и кызым! — диде Рәсүлә ачы иттереп.— Әллә инде туй хикмәтләрен дә хәл итеп куйгансыз?

— Ансыз ничек инде, әнәй? Аның бәләкәен, җиңелчәсен тегендә уздырырга исәп, ә зурысын үзебездә, ягъни Чаллыда үзебез салган бәрәр кафе-мазарда.

— Үзләре рөхсәт сорарга кайттык дип кыланган була, үзләре әнә ниләренә тикле хәл итеп куйганнар инде! — дип уфылдап җибәрде Рәсүлә.

Женя Мынданың йөзе кызарып яна, ул әлбәттә, татарча белми, әмма сүзнең ни турында куертылуын бик әйбәт чамалый һәм, баш каккалап, русчалатып, үз сүзен кыстырырга тырыша иде:

— Сез гафу итегез инде, без бер-беребезне югалтмаска уйладык.

— Соң, кызым, сиңа унсигез дә тулмаган бит әле.

— Ә син үзең кияүгә чыкканда, унсигезне тутырган идеңме соң? — дип күзләре белән яндырып алды Рәмилә.— Авыл советына язылышырга Айдаш абый тугач кына баргансыз түгелме соң?

Мондый сорауның биреләсен ана кеше бик абайлый иде: кайчакларда шулай аналар язмышы балалар язмышына да әверелеп куя, күрәмсең. Рәсүләнең тавышы кисәк пышылдауга күчә язды:

— Ул чакны заманасы нинди ие соң, кызым?

— Хәзер дә замана кимен куймый, бик әйбәт куыра белә. Кайчагында башыңны кая куярга белми йөдисең.

— Без, ичмаса, авыл советына барганчы, үзебезчә, мөселманча иттереп никахланып алган иек. Ә сез? Моның белән чиркәүгә барырга җыенасыңмы әллә?

— Чиркәүгә? Һе, бардылар, ди. Сез, әнәй, әтәй, бер дә хафаланмагыз, без инде... без... — Рәмилә түш кабарта төшеп, әти-әнисенә бик тә серле-мәгънәле рәвештә караш ташлап алды һәм моңа тикле саклап килгәнен кисәк кенә ярып салды: — Без инде тегендә поселок советларына язылышуга гариза биреп кайттык.

Бу сүзләр ата белән анага өсләренә капыл гына бер чиләк салкын су койгандай тәэсир итте:

— Ничек, ничек?! — дип төбәлде Хәнәфи, муенын сузып һәм кашларын югары чөеп.

— Һай гыналарым, ни сөйлисең син, кызым! — дип кычкырып куйды Рәсүлә. Аның куллары ирексездән муены төбенә менде.

— Алар республикасында, Украинада закон тәртипләре йомшаграк икән: кызларга унҗидедә үк кияүгә чыгу рөхсәт ителә икән. Безнең РСФСРда гына ул...

— Нәрсә, анда дуңгыз итләре ашап, аны йөзем ширбәтләре белән бастырып куйганга кызлар иртәрәк өлгерәме? — дип авызын кыйшайтты Хәнәфи.— Ә безнең мондагы итләр-майлар, җиләк-җимешләр, һавасынисе ярап бетмиме, тоткарландырамы әллә?

— Белмим, бәлкем, шулайдыр. Әмма безнең ише ашыгучыларга анда барып сыенырга бер җай, ичмаса...

— Тапкансың икән барып сыенырга оҗмах! — Рәсүлә яндырыпяндырып, молдаван егетенә карап куйгалады. Ул аның урынында бөтенләй бүтән берәүнең утыруына зур өметләр баглаган иде шул.

— Соң, әни, бик теләмәсәгез, каршы торсагыз, анда бармаска, гаризадан баш тартырга да була ич.— Рәмилә шулай диде, әмма аның тавышыннан да, үз-үзен тотышыннан да алай итәргә һич теләмәве аерым-ачык сизелә иде.

— Сез гафу итегез инде: без бүтәнчә булдыра алмыйбыз шул — бусын, янә кайнар пышылдап, Женя Мында әйтте.

— «Гафу, гафу», имеш. Борылырга да җай калдырмыенча, почмакка китереп терәгез дә, без монда бердәнберебезне... Белмим инде, мондыен хәлләрдә...

Рәсүлә әйтәсе сүзен капыл өзде. Ана бәгыреннән кáтылана баруын ничектер туктатырга, ничектер сабыр җыя белергә кирәк иде. Ул усал иттереп ире Хәнәфигә карап куйды.

Хәнәфи исә бу минутта кияү булырга тиешле егеткә төбәлеп, аны күзли иде. Егетнең өстендә карасу-көрән төстәге һәйбәт костюм, кардай ак күлмәк, тимгел-тимгел кызыл төшкән көрән галстук. Чәчләре коңгырт-кара. Үзенең бөтен йөзе бурлаттай янып тора. Әйтерең юк, чибәр генә үзе. Әмма нишләп соң әле аның сул кашы өстендә һәм түбәндә, купшы мыегыннан иягенә таба, нindидер җөй эзләре беленә? Уң күз төбе дә күгәренке. Аларга җәен телевизор рәтләргә килгәндә, андый нәрсәләр беленмәгән кебек иде ич. Ни хикмәт икән бу? Ниһаять, Хәнәфи егетнең күз карашын эләктереп алды: аңардан инәлү-ялварудан битәр мөлаем өмет һәм тәвәккәллек нурлары бөркелә сыман иде.

## Роза Хафизова

# ӘТИ КАЙТКАН КӨН

ХИКӘЯ



Бу тавык дигәнеңнән дә әрсез мал бармы икән дөньяда? Иртән әни пешереп калдырган бәрәңге кабыгын урыпмы уралар. Алларына сибә торасың, тып-тып чүпли торалар. Ул гына җитми әле, әтәче кызыл кикриген кукрайтып, «ко-ко-ко»лап өстеңә килә. Авыз ачып торсаң, табагыңа очып кунар. Көш-ш-ш, килбәтсезләр, убырлар!

Мин шулай туймас тавыкларны тирги-тирги ашатып маташа идем, бәрелә-сугыла йөгереп, Солтан килеп керде.

— Малай, яшьләр быел җиңү хөрмәтенә сабан туе ясыйбыз, дип әйтәләр, ди. Югары оч Ибрай абый: «Көч җыеп торыгыз, сыбызгы борыннар, сабан туенда иң элек сезне көрәштерәбез»,— ди.

Иптәшем, Ибрай абыйга охшатып кукрәгең киереп, тавышын калынайтып сөйли. Киндер күлмәк астыннан очлы кулбашлары тырпаеп тора. Куллары килбәтсез озын, үзе ябык. Хәер, ябык булмый нишләсен, бер дә туйганчы ашаганы юк ич аның. Карт әбисе белән генә тора. Әтисе Сәгыйть абзый сугышка минем әти белән бергә китте. Китте дә югалды. Бер генә хаты килде. Әнисе белән ике энесе кышлаган башак ашап агуланып үлделәр. Солтан мәктәптә булып кына исән калды. Язын әниләре кырдан башак җыеп кайтып, ботка пешергән дә, өйдәгеләр туйганчы ашаганнар. Әбиләрен сөлек салырга дип, түбән очка алып киткән булганнар. Юкса, Солтан да, әбисе дә сау каласы түгел икән.

Минем бер дә сер бирәсем килми:

— Көрәштерсәләр, көрәшәбез аны,— дигән булам. Үземнең йөрәк еш-еш тибә. Их, яшьтәшләреңне җиңеп, батыр калсаң! Җиңүче кешене бер кулын югары күтәртеп мәйдан әйләндерәләр, аннары бүләк тә бирәләр, диләр. Сугышка хәтле сабан туйларын күргән зуррак малайлар сөйли.

— Әйдә, хәзер үк көч сынашабыз. Ибрай абый әйтә, өйрәнә торыгыз, ди.

— Әйдә соң! — Мин бушаган көрпә савытын тавыклар алдына куйдым. Без ишегалды уртасына, яшел чирәмгә чыгып, чын көрәшчеләр шикелле кара-каршы бастык та, бөтен кагыйдәләрен җиренә җиткереп, көрәшергә тотындык. Минем чалбар каеш белән буылган, әтидән калган каеш. Солтанның чалбары киндерә белән генә бәйләнгән. Шуңа күрә аңа мине әләктерүе җиңел. Аннары ул, ябык булса да, буйга миннән бераз калкурак. Шуңа күрә тиз генә селкеп салырмын, димә.

Без мышный-мышный шактый әүмәкләштек. Әле ул өскә чыга, әле мин. Безнең көрәшүне сагаеп күзәтеп торган әтәч, «ко-ко-ко»лап аваз салды, аннары бөтен бикәчләрен җыеп, лапас астына тирес тибәргә алып китте.

Ниһаять, хәлдән тайдык. Чирәмдә аунаган җирдән, еш-еш сулу алып, тезләрне кочаклап торып утырдык. Шул чак мин кинәт энем Фатихның ишегалдында юклыгын абайладым. Тиз генә сикереп торып, каударланып урамга йөгердем. Минем арттан юан тавышы белән һау-һаулап Актүш ташланды. Шайтан малай, кая киткән инде тагы?! Һич өйдә генә тормас. Ар-

тыннан гел ияреп йөрергә генә кирәк. «Фатих! Фатих! — дим.— Фатих!»
Урамда шылт иткән тавыш юк, кош-корт, бала-чага да күренми. Кайдан килсен ди ул бала-чага. Булганы тау астында каз көтә, әрәмәдән үлән ташый.

Солтан белән чишмә буйларын әйләндек, бакчалар аша гына тау астына. Шушма буена йөгереп төштек. Күктә кояш кыздыра, бөтен җирдә яшеллек. Җылы, рәхәт. Әрәмәлектә кошлар сайрый. Ә Фатих юк. Шушмага баткан булса, әнигә ни җаваплар бирермен? Утауга киткәндә, миңа ышандырып калдырды ич ул аны! «Тугыз яшеңә җитеп, шул баланы да карамагансың»,— дияр. «Фатих! Фатих!» — дим. Бәлки, өйгә дә уралгандыр инде дип, җан-фәрман чаба-чаба кире кайттык. Юк. Ишегалды да тып-тын! Инде нишләргә? Кемнән ярдәм сорарга! Тагын кайлардан эзләргә?!

— Силсәвиткә барып әйтергә кирәк,— ди Солтан.

Тирә-күршеләрдән берәү дә күренми, ичмасам. Әй, Зөлхия апа өйдә ич бүген! Мин, Солтанга берни әйтми, Зөлхия апаларга йөгердем. Сулуым кабып, дөбер-шатыр барып керсәм, ни гаҗәп: идәнгә җәйгән палас өстендә безнең Фатих белән Зөлхия апаның малае Тәлгать шуышып йөриләр. Фатих кәҗә булып Тәлгатьне сөзәргә килә, тегесе шырык-шырык көлә. Зөлхия апа почмак сәкесендә табак-савыт юа. Күрәсең, хәзер генә ашаганнардыр. Фатих миңа игътибар да итеп тормады, уйнавында булды. Мин аны чатыр чабып эзләп йөрим тагы. Үземнң үзем шундый кызгандым, күземә яшьләр килде. Зөлхия апа: «Әйдә, уз, үскәнем»,— дигән була тагы.

— Мин аны бөтен җирдән эзләп йөрим...

— Баядан бирле уйныйлар инде алар, уйнасыннар,— диде Зөлхия апа.— Бәрәңге пешереп ашаттым үзләренә...— Ул зур коңгырт күзләрен тутырып миңа карады. Әйтерсең лә, аның минем алда да зур гаебе бар. Тәлгатьне ул каядыр урман кисәргә барган җиреннән алып кайтты. «Җилдән туган»,— ди аны Солтан. Зөлхия апаның әнисе, Фатыйма әби, Тәлгать туганчы ук дөнья куйды. Исән чагында ул гел безгә керә, әни белән озаклап сөйләшеп утыра иде. «Язмыш шулайдыр инде, күрше, бу хурлыкларны күрермен дип үстермәгән идем кызымны», — дип кабатлый, әледән-әле күзләрен сөртә иде. Башта мин Зөлхия апаның гаебе нидә икәнен аңламый аптырадым. Бәләкәй булынган. Аннары Солтан аңлатып бирде...

Нихәл итәсең?! Ни генә булса да, яратам мин Зөлхия апаны. Үзебезнеке белән бергә алар кәҗәсен дә көтүдән юыртып кайтам. Бер-бер йомыш кушса, рәхәтләнеп үтим. Чибәр ул Зөлхия апа, башка хатыннарга охшамаган да. Билләре сыгылып тора. Чәчләре саргылт, толымнары тезенә җиткән. Йөзе ап-ак. Ул колхозның яшелчә бакчасында эшли. Тәлгатьне шунда бәләкәй арба белән тартып йөри. Эшкә бармаганда өеннән бик сирәк чыга. Үзләренә дә безнең әнидән башка кеше керми. Хатын-кызларның аның белән сөйләшкәнен күргәнем юк, никтер озак итеп артыннан гына карап калалар. Кызганалармы, гаеплиләрме? Өлкәннәрнең уен кем белсен?!

Уф! Ярый әле суга батып үлмәгән икән. Фатихны әйтәм. Мин берни дәшмәстән, тиз генә чыгып киттем. Уйнасын әйдә. Озакламый әни дә кайтыр. Минем әле кисмәккә су ташыйсым, утын ярасым, казларны барлыйсым бар. Әни кайтуга самавыр тергезергә дә кирәк.

Солтан белән Актүш мине урамда көтәләр иде. Фатихның табылуын кыяфәтемнән үк чамаладылар. «Без чабулап йөрибез, ул уйнап ята икән»,— диде иптәшем теш арасыннан чыртлатып. Тик минем энемә сүз әйттерәсем килмәде: «Бәләкәй бит әле ул, аңламый»,— дидем. Солтан ничек килсә шулай, кисәк кенә китеп тә барды. Мин шактый югары күтәрелеп, сөйкемле елмаючы кояшка карап алдым. Вакыт үтә, эшлисе эшләр тау чаклы. Озакламый төшке ашка әни дә кайтыр.

Мин тиз генә лапас астына кереп, чыбык-чабык чапкалый башладым. Лапас асты утыннан бушап бара. Соңгы чыбык-чабыкны турыйм. Көзгә хәтле эти кайтмаса, тагын ничек утын юнәтәсе булыр. Күптәннән аунап яткан түмәрләрне ярмакчы булып карыйм. Их, көч җитеп бетми шул әле минем, ни әйтсәң дә тугыз яшь кенә шул әле. Шундый бер тылсымлы машина уйлап табасы икән ул. Утынны үзеннән-үзе турасын иде. Машинаны китереп терәгәч була, түмәрләрең чаж-чож килеп, үзеннән-үзе ярыла да китә. Мин үзем тураган бер кочак чыбык-чабыкны күтәреп, өйгә юнәлдем. Шулчак өнсез калып, кулымнан чыбык-чабыкларым коелмасынмы: бер ир кеше безнең капканы ачып маташа. Капка ярыгыннан аның кояшта уңган гимнастеркасы күренеп калды. «Эти, эти кайткан!» Мин урынымнан кузгалмакчы

булдым, кузгала алмадым, нидер эндәшмәкче булдым, телем тотлыкты. Ул арада ир кеше, капканы ачып, ишегалдына керде. Як-ягына каранды. Юк, минем эти түгел икән бу, үзе яшь, буе да озынрак, кап-кара кашлары кылыч борыны өстендә бер-берләренә килеп үк тоташканнар. Җилкәсендә солдат капчыгы. Юк, бу абый безнең авыл кешесе түгел.

Кәефем китте. Ымсынуым гына булган икән шул. Солдат минем белән авызын ерып исәнләште. Аннары:

— Энем, бу Зөлхия апаңнар йортымы? — дип сорады.

— Зөлхия апаларныкы тегесе, абый. Сиңа алар кирәк идемени? Әйдә, күрсәтәм. Минем энем дә аларда әле.

Без солдат белән урамга чыктык. Зөлхия апалар капкасы төбендә абый кеше туктап калды.

— Энем, Зөлхия апаңны чакырып чыгара алмассыңмы? — дип үтенде ул. Аның тавышы ничектер бик кыюсыз чыкты. Ник чакырмаска, чакырабыз аны.

Мин ук кебек атылып Зөлхия апаларга кереп киттем. Кергә-керешкә үк: «Зөлхия апа, сине бер абый чакыра!» — дип сөрән салдым.

Зөлхия апаның кулындагы әйбере идәнгә төшеп китте. Ул агарынды, аннары коңгырт күзләрен зур итеп ачып миңа карады да ишеккә атылды. Мин аңа иярдем.

Әлеге абый капка баганасына сөялеп тора иде. Зөлхия апаны күрүгә, аңа таба бер адым ясады да туктап калды. Зөлхия апа да аңа җитәр-җитмәс, никтер туктады. Тик торалар катып. Үзләрен читтән күзәтү кызык. Ниһаять, солдат абый кымшанып куйды, кочагын җәйде. Зөлхия апа исә: «Тимербай!» дип аңа таба атылды.

Зөлхия апа Тимербай абыйның кочагына капланып үкси-үкси елый иде. Тимербай абый аның чәчләреннән, аркасыннан сыйпый, тынычландырырга тырыша. «Я, булды, булды, гүзәлем»,— дип бертуктаусыз кабатлый.

Зөлхия апа башын күтәреп, яшьле күзләре белән елмайгач, әйтерсең лә кояшлы яңгыр явып узды. «Мин, мин синең килереңә ышандым, Тимербай!» — диде ул. Аннары миңа таба борылып, горур тавыш белән: «Бу синең Тимербай җизнәң була, үскәнем»,— диде. Кунак абый кесәсеннән яшькелт саплы пәке чыгарып: «Мә, егет, Зөлхия апаңнан сөенче алган өчен!» — диде дә миңа сузды.

Мондый пәкенең әле дөньяда да булганы юктыр. Биш япьле! Мин аларны шундук ачып карадым. Зурлы-бәләкәйле ике пычагы, боравы, чәнечкесе, кашыгы бар. Сабы кояшта елык-елык итеп, әле яшькелт, әле зәңгәрсу төскә керә. Пәкене шундук Солтанга күрсәтәсем килсә дә түздем. Аны йомарлаган йодрыгымны чалбар кесәмә тыктым да, Зөлхия апа белән Тимербай абый артыннан өйләренә кердем.

Тимербай абый сәкедә тәгәрәп йоклап яткан Фатих белән Тәлгать янына килеп басты да, бер Зөлхия апага, бер малайларга карап тик тора. Әллә аптырабрак та калган тагы. Шулчак Зөлхия апа оялчан гына елмаеп куйды. Аннары, салкын җил тидемени, йөзе кинәт никтер кырысланып китте. Ул Тәлгать өстенә иелеп, аның башыннан сыйпады. Мин әле Зөлхия апаның бу хәтле чибәр икәнен күргәнем юк иде. Тәлгатькә аның кулы түгел, аккош канаты кагылды, диярсең. Саклык белән генә, ләкин бик горурланып кагылды ул аңа. Тимербай абыйга да астан гына сөзеп карады. Үз артыннан карап калучы эбиләргә ул гел шулай күз сала иде.

Тимербай абый тәмам шашты. Ни әйтергә белми, бер Тәлгатькә, бер Зөлхия апага төбәлде. Кулын әле кесәсенә тыга, әле ала. Аннары кинәт Зөлхия апага таба атлады да, аны күтәреп алып, идән буйлап әйләндереп йөртә башлады. Үзе аның битләреннән, чәчләреннән үбә. «Зөлхиям, бәгърем»,— дип кабатлый иде. Зөлхия апа бер үк вакытта елый да, көлә дә иде. Тимербай абый аны сәкегә утыртты да, үзе Тәлгать каршына килеп тезләнде. Аның чәчләреннән сыйпады. Тәлгать берни сизми тәгәрәп йоклый иде. Их, җүләр малай, әтисе кайтуын да сизми калды бит, әй! Һи, ни әйтәсең аңа, бәләкәй ич әле ул, әтисен бөтенләй күргәне дә юк. Мин шулчак Тәлгатьнең нәкъ Тимербай абыйга охшаган икәнен абайлап алдым. Шундый ук борын, шундый ук кашлар, шундый ук авыз. Бик көнләштем мин аннан. Әнә аңнинди бәләкәй булса да, әтисе кайтты. Йокларга ятканда әтисе юк иде, уянгач — бар!

Өйдәге ыгы-зыгыны тоептыр инде, безнең Фатих та уянды. Гаҗәпләнеп бер Тимербай абыйга, бер миңа карады. Зөлхия апа күбәләк кебек очынып аш

әзерләп йөри, үзе Тәлгать алдында тезләнгән Тимербай абыйга әледән-әле карап куя. сөйкемле елмая. Минем аның бүгенгедәй шат, бәхетле чагын башка беркайчан да күргәнем булмады.

Фатихның уянганын күргәч, Зөлхия апа киштәдән ике конфет алып, берсен миңа, берсен Фатихка бирде. «Барыгыз, өегезгә кайтыгыз, нәниләрем, иртәгә тагын килерсез»,— дип, йомшак кына аркабыздан сөеп, безне ишектән чыгарып җибәрде.

Минем күңелне җылытып, кесә төбендә биш япьле пәке ята. Бармакларым белән капшап, аның япьләрен барлыйм, сыйпыйм. Минем әле беркайчан да, мондый пәкене тотып караганым да юк иде. Фатих кына күрә күрмәсен, «бир дә бир», дип дөнья җимерер. Тизрәк Солтаннарга барасы иде дә бит, озакламый әни кайтыр, ә минем әле эшем дә эшләнмәгән.

* * *

Сабан туе да килеп җитте. Мин һаман әтинең кайтуын көтәм. Әни дә: «Бу арада хат-хәбәре дә юк, юлда түгелме икән»,— дип сөйләнә. Колхоз эшенә киткәнче, иртә-кич өйләрне, ишегалларын ялт иттереп тазартып куя. «Әтиегез кайтуына чиста торсын»,— ди. Фатихның гына исе дә китми. Чөнки аның әтине бер дә күргәне юк. Көчле икәнен дә, бәләкәй чагымда мине уч төбенә утыртып, баш өстенә күтәрүен дә белми. Батыр Мисбах кушаматлы икәнен дә белми дә белми инде. Мин энемне кызганам да, кайчакларда ачуым да килә. Теле ачылганнан бирле бар белгән сүзе: «Бир, миңа, мин дә барам!» Һич кая барыр хәл юк, чабуга тагыла да бер тотам калмый. Тукмаклап булса да калдырыр идем, соңыннан әнидән үземә эләгер дип тыелам. Әләкләвен генә кара әле син: «Әни, абый тия!» Менә шундый инде ул минем энем. Шуңа күрә пәкене аңа күрсәтмим әле. Ул йоклаган чакта, я әни янында кайнашканда гына ялгызым качып уйныйм. Кесәдә пәке булгач, сөлге котлатып йөрүче егетләр артыннан да иярәсем килмәде. Ни кызыгы бар инде сөлге котлатуның. Берәр йорт янына килләләр дә апалардан күкәй, кызлардан кулъяулык даулыйлар. Солтан белән бер-ике урамда йөреп караган идек, туйдырды, аларга кайтып, пәкеле уйнарга утырдык.

Солтанның да күзләре кызды пәкегә. Үзләренең Зөлхия апалардан ерактарак яшәүләренә үкенеп бетә алмады. Тимербай абыйның үзләре турыннан узганын да күрә алмый калган. Күреп каршысына чыкса, пәке аныкы буласы икән. Пәкесе дә бик хикмәтле шул. Сабы елкылдап торгач, Солтан башта аны «фашист пәкесе» дип хурлап маташкан иде дә, әйләндерә-әйләндерә карый торгач, пычак сыртында «Союз» дип язылган җирен күреп алдык. Димәк, үзебезнеке! Пәкене күргән саен Солтан хәзер авыр сулап куя. Мин аңа пәкене тотып карарга бирәм, кызганмыйм.

Солтан пәке урынына үзләренең бәрәңге әрчи торган пычаклары белән уйный. Үткен пычак ул. Сугышка киткәнче, әтисе аны чалгы тимереннән ясаган. Үзе бәләкәй генә. Солтан аны гел кесәсендә йөртә. Пәкем юк чакта мин дә аңа бик кызыга идем.

Солтан үз чиратында чалгы пычагын һавада мәтәлчек аттырып йомшак кара туфракка батырды. Аннары кинәт әсәрләнеп әйтеп куйды:

— Әгәр дә ки сабан туена әти кайтса, сөенче алучыга мин бөтен булган малымны бирергә дә риза!

Минем дә сынатасым килмәде:

— Сөенче алучыга мин пәкемне дә кызганмас идем әле,— дидем.

Солтан очынып китте: «Чынмы, малай, чынмы?!» — дип сөйләнә-сөйләнә капка төпләренә йөгереп барып юлга карады. Аларның йорты калкулыкта утыра. Районнан кайта торган юл уч төбендәге кебек ярылып ята. Әтисеннән инде өч елдан артык хәбәр-хәтәр булмаса да, Солтан һаман юлдан күзен алмый, аны көтә. «Безнең әти разведчик иде. Разведчиклар бик җитез була алар, исәндер, кайтыр»,— дип мине дә ышандырырга тырыша.

— Чынлап та, бирәсеңме, малай, сабан туена түгел, теләсә кайчан кайтса да бирәсеңме?

— Сөенчесен алганга бирәм!

Солтан пәкенең япьләрен ачып-ябып карады. Кашыгын, чәнечкесен капшады. Кызык, мондый бәләкәй кашык белән ашны ничек ашыйлар икән? Без бәрәңге шулпасын агач кашык белән генә ашыйбыз. Анда да әле эчендә берән-сәрән йөзеп йөргән бәрәңгеләрен башта кашык белән алабыз да, шулпасын савыты белән күтәреп кенә эчәбез.

Ашау искә төштеме, борып эч авырта башлый, уенның да кызыгы калмый. Мин пәкене кысып тоткан кулны кесәгә тыктым да өйгә йөгердем. Озаграк йөрелде шул биләмдә, әни мине нык кына тиргәп ташлады.

— Көне-төне биләм дә биләм. Кәҗәгә кышлык печәнне кем әзерләр дисең соң син?! — Ул мине тирги-тирги сәкегә ашъяулык җәеп, аш урыны әзерләп маташты.— Ашагач ук Фатихны ияртеп әрәмәлеккә менеп төш, ишетсен колагың. Ярты капчык булса да үлән җыеп кайтырсыз. Иртәгә сабан туе дип көнең узар юкса...

Без әрәмәлектән чыкканда, көн кичкә авышкан иде инде. Шушма буендагы таллыкта өзеп-өзеп кошлар сайрый. Үлән арасында чикерткәләр чырылдый. Сарут исе борыннарны яра. Әрәмәлектә, ышыкта үскән үлән каты булмый, капчыкны Фатих белән уйный-көлә генә бик тиз тутырдык. Энемнең куллары бәләкәй генә булса да, миннән күрмеш, җыепмы-җыя. Тик ул бөкрәеп эшли алмый, тезләнеп шуышып йөри. Чалбар балагын пычратып бетерә. Ни әйтсәң дә, бәләкәй шул әле ул. Биш яше дә тулмаган. Кайткан чакта арбага утырт дип теңкәгә тиячәк әле ул. Мин аңа карап-карап алам. Әти кайтса, бер кәҗәлек кенә печән юнәтер иде инде дип тә уйлап куям.

Капчыкның авызын бәйләдем. Аннары Фатих белән ыкаулап аны бәләкәй арбага күтәреп салдык та, пар ат булып җигелеп кузгалдык. Әрәмәне чыккач, үр менәсе. Аннары олы юлга чыгабыз, кайгы китә. Такыр юлдан арба үзе үк тәгәрәп барачак. Үр менгәндә, мин алдан тартам, Фатих арттан этә.

Уф, менеп җиттек! Олы юлга чыгуга хәлебез бетеп, юл читендәге чирәмгә аудык. Мин кулымны кесәгә тыгып, пәкене барладым. Аны бик алып карыйсым килгән иде дә түздем. Фатих күрсә, бир, дип теңкәгә тияр. Бирсәң, я югалтыр, я кулын кисәр. Ул үлән арасыннан ниндидер бөҗәк тапкан да, дөньясын онытып, аны күзәтә. Мин кулымда пәке салкынын тойган хәлдә, чирәмгә сузылып ятып, зәңгәр күккә төбәләм. Кояш күкнең теге ягына тәгәри. Чикерткәләр тавышын тыңлап ятуы рәхәт, күзләр үзләреннән-үзләре йомыла. Колак төбендә генә Фатих чыркылдый: «Абый, дим, абый, минә, камка тоттым». Мин, күземне көчкә ачып, торып утырам. Фатих йодрыгын язып, кулын миңа сузды. Камка, шуны гына көткәндәй, башта үтә күренмәле канатларын чыгарды, аннары кара бөрчекле кызыл канатларын җәйде дә очып китте. Мин аның кайсы якка очканын карар өчен урынымнан сикереп тордым һәм юл буйлап безгә якынлашып килүче солдатны күреп өнсез калдым. Аны Фатих та күреп алды. Солдат зур-зур адымнар ясап, ашыга-ашыга атлый. Өстендә гимнастерка. Гимнастерка өстеннән буган каешының пряжкасе ялтырап тора. Солдат миңа никтер таныш кебек тоелды. Аяк атлавымы, кулларын селтәвеме? Безнең әти түгелме соң бу?! Мин үзем дә сизмичә: «Әти!» — дип кычкырып, солдатка каршы йөгердем. Әти, чынлап та әти. Әнә ич, кашлары, күзләре нәкъ әтинеке. Тик, карт ич бу, ябык, безнең әти тазарак иде. Мин кинәт туктап калдым. Солдат та миңа житәрҗитмәс, күзләрен зур ачып туктады. Никтер каушады, аптырап, бер миңа, бер Фатихка карады. Аннары кинәт: «Улым, Мансур!» — дип алга ыргылды һәм мине кочаклап алды. Мин башымны әтигә төрттем һәм күптән онытылган, ләкин бик таныш, тәмле ис, әти исен тойдым. Артык түзәрлегем калмады, шатлыктан үксеп җылап җибәрдем. Шулчак Фатих исемә төште. Соң аның әле әтине беркайчан да күргәне юк ич. Башымны күтәреп карасам, Фатих инде безнең янга килеп тә баскан, бер әтигә, бер миңа карап тора. Үзе менә-менә җылап җибәрергә әзер. «Әти, бу Фатих»,— дидем мин. Әти үзе дә аңлап алды бугай. «Кара, нинди дәү булган минем Фатих улым»,— дип аның алдына чүгәләде, аннары чүгәләгән килеш кочагына алып сөйде.

Мин дә әтигә килеп сыендым. Әти ничектер бик авырлык белән генә тураеп басты. Юл уртасында торган бәләкәй арбага игътибар итте һәм аның ике күзеннән мөлдерәп ике тамчы яшь атылып чыкты. Ул күз яшьләрен кул аркасы белән сөртеп алды һәм шат тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Яле, кайсыгыз арбага утыра! — Әти тиз генә биштәрен аркасыннан салып үләнле капчыкларыбыз өстенә куйды. Мин шул чагында гына сугышка киткәндәге әтинең тавышын, үзен танып алдым. Күңелемә рәхәт бер җылы йөгерде, елмаеп җибәрдем. Фатих «аһ» дигәнче печән тулы капчык өстенә менеп атланды. Мин аның артыннан арбага менәргә оялдым.

Без өчәү — әти, Фатих, мин — өйгә кайтып киттек. Әти арба тарта. Мин аның бер алдына, бер артына төшеп чабулыйм. Арба тартмагач, рәхәт, күңелле. Шуңадыр, телгә ни килсә, шуны такылдыйм. «И, әни шатланыр

да инде, бүген ул утауга бармады. Иртәгә сабан туе. Без сине сугыш беткәч үк көтә башладык инде. Әнидән сөенче алам хәзер». Фатих бер дә юкка кычкырып көлә. Эти дә бара-бара да «алуяу» дип кычкырып, юыртып ала.

Без шулай шау-гөр авылга килеп кердек. Мин ерактан ук Солтанның капка төпләрендә басып торганын күреп алдым. Ул безнең якка текәлеп карап торды да кирегә йөгерде.

— Солтан әнидән сөенче алырга йөгерде, йөгерсен әйдә,— дидем. Фатих күрмәсен өчен, эти алдына чыгып, аңа тиз генә пәкене күрсәтеп алдым.— Син кайтканны беренче күреп, миннән сөенче алса, мин аңа пәкемне бирмәкче идем. Зөлхия апаның ире Тимербай абый аны миңа сөенчегә бүләк итте.

— Солтанның этисе дә кайтмаган, пәкесе дә юк икән алайса...

Миңа никтер уңайсыз булып китте. Шулчак безгә таба йөгергән әнине күреп алдым. Әнине күрүгә, эти никтер туктап калды. Арба тәртәсен җиргә куйды. Әни килә-килешкә, этинең кочагына ташланды. Алар бер сүз дә эндәшешмәделәр. Мин тагын эти белән әнигә барып сыендым. Фатих кына арбада кукраеп утыра бирде. Беләм мин аны, гомер буе да арбадан төшмичә, үзен тарттырып йөртергә риза ул.

Безнең әвәрә килүебезне Солтан бер читтән генә күзәтеп торды да исе китмәгән кыяфәттә өйләренә таба атлады. Ул ничектер бөкрәеп, кечерәеп калган кебек күренде, күлмәк астыннан калак сөякләре тырпаеп тора. Бик кызгандым мин аны: этисе дә сугыштан кайтмады, пәкесез дә калды. Сөенче ала алмады ич...

Өйдә эти булгач, бик күңелле иде. Безнең шундук кадер артты. Ул миңа перәшкәсе йолдызлы чын солдат каешы да алып кайткан әле. Минем хәзер этием дә, пәкем дә, солдат каешым да бар. Ләкин никтер күңелемне корт кимерә. Солтанның калак сөякләре калкып торган аркасы, ябык йөзе, ничектер бик ямансу карашы күз алдымда тора. Без өйдә бәйрәм итәбез, күрше-тирә керә-чыга. Әни өстәлгә табагы белән бәрәңге пешереп утыртты. Эти бер симез тавыкны суеп бирде. Үзе «ике малайга — ике бот»,— дип елмаеп сөйләнә. Фатих аның чабуына ябышкан да бер адым калмый тагылып йөри. Кирәксә-кирәкмәсә дә, «эти, эти», дип кабатлый, туйдырып бетерер әле менә. Әнә муенына Тәлгатьне атландырган Тимербай абый белән Зөлхия апа да килеп керде. Тәлгать этисенең муенында патша кебек утыра. Бер Солтан өйләрендә ялгызы. Мин түзмәдем, аларга йөгердем. Бөтен рәхәт миңа гына булса, әчем күбәр!

Солтан лапас астында чыбык-чабык чапкалап маташа иде. Мине күргәч, балтасын сүзсез генә түмәргә ыргытты. Мин килә-килешкә аңа биш ярьле пәкемне сузып:

— Сиңа булсын,— дидем.

Солтан ышанырга да, ышанмаска да белмичә, бер миңа, бер яшелле-зәңгәрле булып ялтыраган пәке сабына карап катып калды.

— Чынлапмы, малай?! — Солтан кыяр-кыймас кына кулын миңа сузды. Бит очларындагы, борын яфракларындагы сипкелләре кып-кызыл булып кызарды, күзләрендә нәни очкыннар биеде.

— Ал әйдә. Сиңа булсын.— Үзем, пәкегә карамас өчен, күземне читкә бордым.

Солтан минем кире уйлавымнан курыккан кебек, пәкене тиз генә кесәсенә салды.

— Эти кайтканчы гына алам, малай, эти миңа моннан да яхшысын, алты ярьлесен алып кайта, менә күрерсең,— диде.

Аннары без кулга-кул тотыныштык та урамга атылдык. Сабан туена әзерләнергә!

# Спартак Әхмәтов

# «МАЙ АЕНДА»...

## ФАНТАСТИК ХИКӘЯ

### 1



Узе теләгәнчә, ул нәкъ иртәнге алтыда уянып китте. Биологик сәгатьләрнең әле У-Маныйны беркайчан да төп башына утыртканы юк иде. Тик ул уянса да, үзен вакыт һәм пространствода яхшырак тояр өчен, бермәл түшәгендә кымшанмый гына ятты. Аннары стеналарны үтә күренмәле итә торган төймәгә басты. Шәмәхә караңгылык шундук эреп бетеп, бүлмәгә кояш нурлары һәм попугай сызгырулары кереп тулды. Күк йөзе ап-аяз. Җирнең тышкы боҗралары гына, стратопланнар эзен хәтерләтеп, офыктан-офыкка бормаланып сузылган иде.

У-Маныйның озын керфекләр күләгәләгән йөзендә нур шәүләләре уйный. Ул, күз кабакларын йомып һәм ихтыяр көчен җыеп, Мәлик белән Камал һәм алдагы эшләре хакындагы уйларын онытты да тигез сулыш алырга керешге. Аннары, берсеннән икенчесенә күчә-күчә, әкрен генә йог күнегүләрен ясый башлады.

Сыгылмалы гәүдәсендә пәйда булган мускуллар шатлыгы, ион ваннасына кергәннән соң, тагын да арта төште.

Сәгать сигезенче яртыда стереовизор автоматик рәвештә эшләргә тотынды. Яшь диктор, серле елмаеп, үткән төн вакыйгалары белән таныштырды. Гадәттән тыш берни дә булмаган иде. «Фикерләү Мәҗлесе икенче мәртәбә укыганнан соң Магеллан Болытларына очыш программасын раслады. Антарктида шахтерлары барелий чыгару планын үтәде. Куриль утрауларында янә бер янартау йокысыннан уятылды. Рүф гарасаты Кариб диңгезендә туктатылды һәм тулысынча юкка чыгарылды... «Яңалыклар» программасы тәмамланып килгәндә генә стереовизорда Камалның бераз йончыган йөзе пәйда булды. Ул, пеләшен ялтырата-ялтырата, «Байканур» аппаратының барлык сынауларны уңышлы узып бетүен һәм билгеләнгән вакытта яңа очышларга әзер булачагын белдерде.

У-Маный елмаеп җибәрде. Димәк, ун көннән соң алар тагын бергә җыйналачаклар һәм аның өчен яңадан гадәти кораб врачы хезмәте башланачак. Аннары ул, компьютер төймәләренә басып, иртәнге аш шифрын тиз генә җыйды да уйга талды.

Ярты ел элегрәк аңардан Фәннәр Академиясенең Вакыт Институтына, ягъни ФАВИга булышуны үтенделәр. «Байканур» очкычы хәрәкәтен психо-

---

Спартак Фатих улы Әхмәтов 1938 елда туган. Казах политехника институтының геология факультетын тәмамлаган, минералогия буенча кандидатлык диссертациясен яклаган. Муса Җәлил һәм башка татар шагыйрьләрен русчага тәрҗемә итә. Әдәбият дөньясына Спартак Әхмәтов фантастик хикәяләре һәм повестьлары белән килеп керә.

логтан башка да сынау мөмкин булганлыктан, ул, әлбәттә, ризалык бирде. Моңа әле дә куанып бетә алмый. Чөнки ФАВИчылар шаккатырлык бер нәрсә — объектларны үткәннән бүгенгә кайтаруны уйлап тапкан иде. У-Маный шушы мәсьәләгә багышланган барлык язмаларны фантастик романнан да артыграк күреп, мавыгып укыды.

ФАВИчылар соңгы тугыз-ун ел эчендә, Госман төркеме тикшеренүләре нәтиҗәсендә барлыкка килгән Сөләйкин кыры теориясенә тулаем, хронокыр теориясенә исә өлешчә таяналар иде. У-Маный теоретик исәп-хисапларны бөтенләй диярлек аңламады. Әш әллә нинди кырлар тәэсирендә тирән бушлыкларның Дирәк аралыгына йогынты ясавыңа бәйләнгән иде ахры. Объектлар хронокыр энергиясе хисабына күчерелә, шул күчерү барышында әлеге энергия тискәре потенциал туплый иде. Бераз вакыттан, әйтик, җиде яки, күп дигәндә, унтугыз сәгать узгач, хронокыр тотрыклы хәлгә килергә омтыла һәм теге объектны пространство-вакыт координатларындагы элекке урынына кайтара иде.

ФАВИчылар үткәннән бүгенгә шикәр шакмагы һәм бүлмә гөленнән алып, дрозофил чебене һәм кулга иялəштерелгән Сүбүдәй гепардына кадәр төрле нәрсәләр күчереп карый. Аларның координатын исәпләп тапканда бераз ялгышуны исәпкә алмаганда, тәҗрибәләр гадәттә бик әйбәт уза.

Ниһаять, Госман төркеме тарихчы һәм психологка мохтаҗлык кичергән көн дә килеп җитте...

## 2

Элеккечә үк җиңел хәрәкәтле һәм сыгылмалы булмаса да, җитмешен тутырган Госман әле һаман егетләрчә төз гәүдәле иде. Тау табигате, яхшы скульптор шикелле, таза һәм шома тире астына яшеренгән тыгыз мускулларын гына калдырып, бөтен кирәксез нәрсәне юкка чыгарган. Табигать бер үк вакыт Госманның йөзенә тирән җыерчыклар буразнасын уеп, кара тут та төшергән иде.

Хәзер ул тирән креслога иркенләп җәелеп утырып, бер аягын икенчесенә атландырып, психолог һәм тарихчыга төбәлгән иде.

Майя — тумыштан тарихчы. Аның ерак бабаларының берсе соңгы бөтендөнья сугышында һәлак булган. Каһарман ир-егетнең алтын йолдызын һәм вакыт узу белән саргайган документларны алар әле дә кадерләп һәм пөхтәләп саклый иде. Ул кәгазьләр белән балачагында ук кызыксынып киткән Майя, мәктәп җитәкчелеге булышлыгында үз вакытында хәрби архивларга керергә рөхсәт алды һәм бабасының батырлык күрсәтүен әзлекле һәм җентекле рәвештә минутка кадәр диярлек күз алдына китереп бастырды. Җирле Фикерләү Мәҗлесе аның докладын хуплавын әллә ни яшереп тә тормады.

Ул «күлмәк киеп» туган иде — эзләгән чыганакларына бер-бер артлы юлыгып кына торды. Герой-шагыйрь Муса Җәлилнең харап ителгән өченче шигырь дәфтәре калдыкларын да нәкъ менә ул тапты һәм, мәгълүм әдәбиятчы Чатауэй ярдәмендә, язмаларның зур өлешен яңадан аякка бастырды.

Чатауэй да монда иде. Аның куплы чәчләре тузгыган һәм юньләп кояш күрмәгән зәңгәрсу-ак йөзен ялкын телләредәй чолгап алган. Ул хәзер гаять дулкынланган һәм шуңа күрә берөзлексез кулларын уып тора иде. Аны, моннан бик күп еллар элек яшәгән тере шагыйрь белән очраштырырга өметләндерделәр һәм ул хәзер бу вәгъдәнең тормышка ашырылуы өчен көрәшергә әзер иде.

Бүлмәнең бер почмагында рухи кыйммәтләр күчерү төркеменең кайбер яшьрәк хезмәткәрләре җыйналган һәм хәзер үзара җай гына гәпләшәләр.

Госман түземсезләнеп аякларын селкетте һәм йөткереп куйды. У-Маный белән Майя шундук гәпләрен туктатты, яшьләр дә тынып калды. Шуннан соң Госман телгә килеп, әмма һәр сүзен үлчәп:

— Без монда уздырылачак тәҗрибәнең төрле якларын бизмәнләр өчен җыйналдык,— диде.— Басым ясап әйтәм: абсолют уңыш тәэмин итүебез кирәк. Физика, этика һәм тарих өлкәсендә нәни генә аксавыбызны абайласа да, Фикерләү Мәҗлесе эшебезне шунда ук туктатачак һәм ул хаклы булачак.— Ул бераз тыныш ясаганнан соң, тагын дәвам итте: — ФАВИныкылар тәҗрибәне уңышлы уздыру һәм хронокыр аркылы ихтимал хәбәрләр таралышын критик микъдардан хәтсез киметер өчен барысын да эшләде. Аппаратлар үз бурычын үтәргә әзер һәм һәлакәттән коткару җайланмалары белән тәэмин ителгән.— Госман, барысын да әйттемме икән, дип бераз уйланып торгач, әдәбиятчыга текәлебрәк эндәште: — Мин сездән объект сайлауны тагын бер мәртәбә нигезләвегезне үтенәм.

Майя алдарак урыныннан торып:

— Миңа рөхсәт итегезче! — диде. Аннары рөхсәт бирелүен дә көтеп тормастан, кискен һәм ышанычлы төстә сөйләп китте: — Без, әлбәттә, тәҗрибә уңышлы узачак, дип гөмән кылабыз. Тәҗрибә объекты үз чорына, һичшиксез, исән-имин әйләнеп кайтачак...

— Хронокыр кайтарачак,— дип аныклык кертте Госман.

— Шулай да булсын... Белеп өлгергән мәгълүматларын ничектер файдалансын да, ди. Ләкин ничек итеп? Безгә мәгълүм язучыны терелтү иң ышанычлы юл, чөнки китап — чорыбызның вакыт агышына тиз генә бирешми торган нәрсәсе, дигән нәтиҗәгә килдек. Без башта фантаст язучыларны истә тоткан идек. Әмма Уэллс, Брэдбери, Ефремов, Әзимов кебек иң яхшы фантастлар, күренекле социолог буларак, үз әсәрләрендә киләчәк казанышларыннан бигрәк экстраполяция һәм үз сизенүләрен күбрәк файдаланалар. Чататуэй менә шуңа күрә, тәҗрибә өчен шагыйрь Муса Җәлилне сайларга тәкъдим итте.

Ниһаять, дулкынлануын бераз баса алган әдәбиятчы да телгә килде. Тик ул, хисләреннән тәмам арына алмаганлыктан, кабаланыбрак һәм кычкырыбрак сүзгә кушылды:

— Чөнки Җәлил тәҗрибә шартларына идеаль туры килә. Шагыйрь озак вакыт рәхимсез изоляциядә тотыла. Тышкы дөньядан аерылган һәм без күз алдына да китерә алмаслык чиктән тыш мохтаҗлыклар кичергән хәлдә яхшы шигырьләр иҗат иткән. Ул әсәрләрне ничәмә буын яшьләр ятлап үсә, алар әле хәзер дә безне озак рухландыра торган тәэсирләр бирә. Әмма эш анда гына да түгел...

Чататуэй нидер җитмәгән төсле як-ягына каранды, У-Маный сузган стаканны алып һәм аңа рәхмәт хисе белән күз ташлап, ашыга-ашыга берничә йотым су эчте. Аннары сүзен тынычрак дәвам итте:

— Миңа аның сугыштан соңгы чорга багышланган шигырьләре бик озак тынгы бирмәде. Шагыйрьнең җиңү турында инде булган хәл шикелле итеп язуы гаҗәп. Әгәр безнең тәҗрибәне уңышлы узачак дип фараз кылсак, мондый әсәрләрнең барлыкка килүе аңлашыларак төшәр иде.

Госман сораган шикелле әйтә куйды:

— Ләкин һәрбер олы шагыйрь — пәйгамбәр ич?

— Әлбәттә! Ул гына да түгел, әгәр Җәлил җиңүгә ныклап ышанмаса һәм аны барлык рухи куәте белән якынайтырга омтылмаса, язып та маташмас иде. Әмма кайбер шигырьләрендә киләчәктән хәбәр алмыйча кертелүе мөмкин булмаган детальләр дә бар. Моңа:

Май аенда тагын җыйналырбыз,
Кызыл шәраб килер табынга.
Бокалларның көмеш чыңы белән
Табын җыры яңрар тагын да,—

дигән юллар да мисал була ала.

— Без барыбыз да җиңүгә кайчан ирешелүен беләбез,— диде Майя.— Һәр май аен бәйрәм итәбез һәм һәлак булганнарны шулай искә төшерәбез!

— Әй-йе-е,— дип сузды Госман.— Тик бу очраклы туры килү генә түгелме икән?

— Моның ихтималлыгы чамадан тыш чикле,— дип кырт кисте Чататуэй.— Математиклар ясаган исәп-хисап киресен исбатлый.

— Һемм, ярар,— диде Госман, кулы белән өстәлгә суккалап. Аннары У-Маныйга борылып: — Ә син, гадәттәгечә, дәшми-тынмый гына күзәтәсеңме? — дип сорады.

Тегесе иңнәрен сикертеп:

— Чататуэй дәлилләре әзлекле күренә. Хәер, сугыштан соңгы цикл турында минем үз фикерем дә бар,— диде.

— Нинди?

— Сезгә кызык булырмы икән ул? Аннары... минем фикернең тәҗрибә үткәрүгә зыяны тимәячәк.

— Яхшы. Тик мине бер нәрсә кыенсытып тора: без Җәлилне аның үз ризалыгын сорамыйча гына терелтәбез ич. Акланырмы икән бу?

— Син үзең киләчәкне күрергә теләр идеңме?

— Мин? Әйе.

— Һәрбер нормаль кеше шулай. Җәлил дә тели, һәм ул үз иленең киләчәген, әлбәттә, күрергә тиеш.

— Шулаен шулай да... Тик аңа соңыннан үзен үлем көтеп торган зинданга кайтып китәргә туры киләчәк ич.

— Минемчә, ул бу җәһәттән икеләнеп тормаячак. Мин хәтта аның, үз эшен ахырынача үтәп җиткерер өчен, кире кайтып китәргә ашкыначагына да ышанам. Без үзебез дә шулай эшләр идек. Ә бит ул — Җәлил!

Бүлмәнең бер почмагында ниндидер ыгы-зыгы күзгә ташланды. Чәчләре иңенә сибелгән озын буйлы нечкә бил урыныннан сикереп торган иде. Күршеләре аны кулыннан тартып кире утыртырга тырышты, тик кызыкай алардан кисәк ычкынып китте дә:

— Сез ничек инде шулай булдыра аласыз?! — дип шәрран ярды.— Шулай сөйләнергә ярыймыни? Тыныч кына, ваемсыз гына, «кайтырмы, юкмы янәсе, үлем җәзасы, фәлән-төгән»... Ә мин...

Кыз, кискен талпынып, урындыкларга бәрелә-сугыла залдан чыгып китте. Ишекләр тавыш-тынсыз ачылды да шом гына ябылып калды.

Госман, киеренке тынлыкны өзеп тамак кырганнан соң, тыныч кына:

— У-Маный, син әйтәсен әйтеп бетердеңме инде? — дип сорады.

— Бетердем.

— Алайса тәҗрибәне әзерлибез. Сугышка кадәрле цикл кайчан башланган әле? — дип эндәште Госман Майяга.

— Октябрьдә.

— Димәк, вакыт координатының башлангыч ноктасы — 1943 елның сентябре!

3

Бу интектергеч төш аны инде ике елдан бирле газаплый иде. Ул гүя йокыдан уянып киткән шикелле була. Тирә-як дөм караңгы. Мие эшләсә дә, гәүдәсе ят кешенекедәй ихтыярсыз. Ул кабер тынлыгына чумган да катып калган сыман иде. Муса бераз борылып, торышын үзгәртергә омтылды, ләкин гәүдәсен селкетә алмады. Әле бервакыт сугышка чаклы ук салкын тидергән һәм көтмәгәндә аяктан язган иде ул. Түшәккә егылып, озак кына чирләп ятканда зәгыйфьлек дәһшәтен тоеп тетрәнгән иде. Тик, Муса хәзер моның төш кенә икәнлеген, үзенә бернинди куркыныч та янамавын, бөтен барлыгын күптән беләп алган шигырьләр дөньясында иртәме-соңмы барыбер кире уяначагын төгәл белә иде. Үзен әнә шулай юатса, тынычландырса да, гәүдә хәлсезлегеннән тинтерәгән мие аңа буйсынмый, аңын өметсезлек чолгап алган.

Хатыны бик якында, янәшәдә генә торган шикелле тоела иде. Муса аңа: «Әминә, син мине уят... Я, уят инде!...» — дип ялынды. Ләкин тегесе берни ишетмәде. Кызы Чулпан да, нәни куллары белән карманып, әтисенең күкрәгенә үрмәләмәде. Башка чара калмагач, Муса салкын идәнгә егылып төшәр өчен үтә тәвәккәл бер көчәнеш ясады. Ләкин бу юлы да нияте эшкә ашмады. Шуннан соң ул гәүдәсенә гасабиланып: «Уян! Уян!»— дип боерды һәм кинәт уянып китте.

Албастылар, кайсы кая ташланып, караңгы диварларга һәм почмакларга сыланды...

Ул, күзләрен шар ачып, чалкан ята иде...

Шул чак җылы сүзләр дулкыны пәйда булып, аны йомшак кына өскә калкытты да, талгын гына тирбәтә-тирбәтә, чиксез иркенлеккә таба йөздереп алып китте. Ул елмаеп җибәрде, тик әле генә күргән авыр төше һаман күз алдыннан китми. Муса, кара канатлы хыялый күләгәләрне хәтереннән тизрәк юкка чыгарыр һәм аларны саф шигърият ялкынында яндырыр өчен, дәрманлы, егәрле сүзләр-баһадирларны ярдәмгә чакыра башлады.

Аның кипшергән иреннәре әкренләп селкенергә тотынды, йөрәге нәфрәтләнеп һәм ачынып тибә, кирәкле сүзләр үзләреннән-үзләре теленә килә башлады. «Яза алмыйм никтер, саташканмын, Каләм тота алмый куллярым...» Бу — шигырьнең оеткысы, беренче юллары. Аннары, набат каккандай, менә болай дәвам итәргә кирәк: «Минем уйлар, янар таулар кебек, Ялкынланыр ирек таңында. Киң далада үскән чәчәкләрдәй, Чәчәк атар ирек сагында!»

Муса рухланып урыныннан сикереп торды. Богауларын зыңлатып, ярыкка яшерелгән карандаш төпчеген, түшәгенең сүтелгән почмагыннан озын гына тасма — газеталардан тигезле-тигезсез кисеп алынган дәфтәрчек тартып чыгарды.

Пышылдаган сүзләрне колак кына тоя, аның исә шигырь юлларын күзләре белән күрәсе, аларны бармаклары белән капшап карыйсы килә иде.

Барлык шагыйрьләр дә шундыйдыр инде, мөгаен...

Якты күл өстенә очып төшеп, җитез генә йөзеп киткән әкияти кошлар кебек кәгазьдә сыгылмалы гарәп хәрефләре пәйда булды.

Ә күрше сәндерәләрдә әкрен генә Фуат мышный, итальян Рениеро авыр гына сулый һәм төшендә гырылдап кычкырып куя; уңдагы һәм сулдагы күрше камераларда йончыган тоткыннар шулай ук төрлесе төрлечә йокыга талган. Бөтен төрмә нәүм базарына киткән, бары коридордагы сакчылар гына, кадак каккан төсле бөтен җирне яңгыратып, ары-бире йөри. Бу минутта илле өченче камерада яңа шигырьләр туа башлавын мондагыларның берсе дә башына китермидер, мөгаен.

Аннары төрмә әллә ничек берьюлы уянды. Надзирательләр богауларны салдырырга һәм кием таратырга керește. Муса гадәти физик күнегүләрен ясап, салкын су белән тәнен сөртте. Фуат белән бер-ике авыз сүз алышты, җәзалап үтерүдән хәзер үк коты алынган һәм бөтен көннәрен гыйбадәт кылып кына үткәрә башлаган итальянга рух кертергә тырышып елмайды.

Иртән, кофе дигән булып, әллә нинди бер тәмсез болганчык эчемлек китерделәр. Аннары һавага чыгардылар. Биш нәни бәрәңге салынган төшке шулпаны ашаганнан соң, Муса белән Фуат татарча җыр башлады, Рениеро аларга хөрмәт белән карап, өнсез генә колак салып торды: ул аларны гыйбадәт кыла дип уйлый иде.

Муса яңа шигырен Фуатка укып күрсәтте. Дусты тыңларга хирес кеше иде. Шигырь тәэсирендә аның йөзе әле киеренке, әле моңсу кыяфәткә керде, аннары күзләрендә ярсулы үч һәм көйдергеч нәфрәт утлары кабынды. Шуннан соң үз эченә бикләнеп, берни дә ишетмәс булды, иреннәре исә әле һаман: «Киң далада үскән чәчәкләрдәй, Чәчәк атар ирек багында!» — дигән шигъри юлларны тәкърарлавын дәвам итте.

### 4

...Иртәнге сәгать алтыда коридорда аяк тавышлары ишетелде. Муса колак салып тыңлый башлады. Менә күршеләренең ишеге шыгырдады, каравылчылар чеңгелдәргә тотынды. Аннары читлекнең «күзе» зыңгылдады. Надзирательнең түгәрәк бәбәге Мусаны, сәндерәдә йоклап яткан Булатовны һәм Рениероның бушап калган урынын капшап алды — итальянны кичә бүтән камерага илтеп япканнар иде. Тиздән йозак шалтырады һәм киң итеп ачылган ишектән ике карачкы килеп керде.

Мусаның белүенчә, аларның берсе госпитальдән надзирательлеккә килеп эләккән сыңар күзле инвалид иде. Аксыл чырайлы, балта түтәседәй озынча йөзлесе таныш түгел иде.

Озынча йөз, төкле кулына кысып тоткан кәгазь кисәген күтәрә төште дә, көтелмәгәнчәрәк чәрелдәп:

— Пулатоф! Чәлилеф? — дип кычкырып җибәрде.

Бу кычкыру яшь этәч тавышын хәтерләткәнлектән, әсирләр ирексездән елмаеп куйдылар.

— Нәрсә кыландырмакчы икән болар?

Булатов Мусага хәвефләнеп күз ташлады, тегесе аны тынычландырып:

— Борчылма син, туган, бүтән төрмәгә генә күчерәләрдер. Гитлер бик күп салган аларны,— диде.

Муса вак-төяк нәрсәләрен җыештырырга керește. Чынаяк, кашык, төрмә фоторәсеме. Иске күлмәге эченә, надзирательләрдән яшереп саклый алган шигырьләре язылган, берничә бит кәгазьне тыгып куйды. Аларын калдырып китергә туры киләчәк. Аның каравы, шигырьләре теркәлгән ничә дәфтәрчекне моннан ирекkә озата алды ул. Андре дусты, Шәрипов, Хафизов, Иконников, Саттаровлар... Гарәфнең искиткеч хәтере дә аның әсәрләре гомерен озайтмасмыни? Бәлки әле камерага падре Георгий Юрытко алып кергән китаплар да эзсез юкка чыкмас. Муса алар кырыена да байтак шигырьләрен язды. Аның бирелдә туган җырларын теге меңнәрчә-меңнәрчә татар, башкорт, рус әсирләре онытa алырмыни?

Ни дә булса калыр, Ватанына аларның кайсы да булса исән-имин әйләнеп кайтыр әле...

Аларны инде барлык җәлилчеләр җыйналып өлгергән коридорга алып чыктылар. Каршыдагы камераның ачык ишегеннән алҗыган кыяфәтле Рениеро карап тора иде. Моннан соң инде итальян бөтенләй ялгызы гына моңаер... Муса аңа ачык йөз күрсәтеп, баш какты:

— Сәлам!

Автоматчылар аларны камап алды да, үлемгә хөкем ителгән әсирләр камерасы янынннан узып, аркылы тимер рәшәткәне кичеп, беренче каттагы тар коридор буйлап алып китте. Аннары канатларын җәйгән ерткыч кош-тай тәбәнәк һәм кап-кара Шпандау төрмәсенең ишегалдына алып чыга торган икенче коридорына аяк бастылар.

Ишегалдында аларны өсте ябулы машина көтә иде.

Төялү белән кузгалып та киттеләр. Машина бик каты сикертә, борылмаларда тормозы чучка баласыдай чиный иде. Тар ярыклар аша иртәнге саф һава бәреп керә. Кысанлыкка карамастан, тоткыннар тирәнрәк суларга тырыша иде.

Машина янә бер йолкынып алды да туктады. Аннары әкренлек һәм авырлык белән тагын бераз алга тәгәрәде. Ниһаять, тимер ишекләр яңадан ачылды.

— Чыгарга! Тизрәк, тизрәк!

Муса җиргә сикереп төште дә, буыннарын язды. Күзләрен кысып яссы түшәмле тәбәнәк кирпеч корылмага, аның орчыктай нечкә манарасына карады да:

— Плетцензее төрмәсе бу,— диде.

Ул Берлинны яхшы белә иде.

Яңа фатирга урнаштырыр алдыннан аларны, гадәттәгечә, душка алып керделәр. Челтәр эчендәге лампа караңгы диварны, уртадагы улаклардан су агып чыга торган тупас цемент идәнне көчкә яктырта иде.

Муса, нечкә су агынтысы астына кереп басты.

— Дуслар! Без ниләр генә кичерсәк тә, усал җилләр башыбызны кая гына илтеп ташласа да, дөньядан горур рәвештә китә белик.— Ул, шаулаган һәм шыбырдаган су тавышына охшатып, сүзләрен тиз-тиз пышылдый иде: — Алкын Иделне һәм мәгърур Урал сыртларын безнең күзләребез беркайчан да күрмәсә күрмәс, тик рухыбыз...

Әсирләр Җәлилне тын гына тыңладылар.

— Язлар җиткәч, киек кошлар кебек без дә туган урманнарыбызга әйләнеп кайтырбыз. Без һәрвакыт халкыбыз йөрәгендә яшәрбез...

## 5

Чататуэйның тыны кысылды, чырае качты, күзләре балыкныкы кебек шар ачылды. Карлыккан тавыш белән ул:

— Әнекәчкенәем! — дип пышылдады.— Бу — Җәлил ләбаса! — Аннары ул нишләгәнен дә белми: «Бу — Җәлил!» дип кычкырып алга ыргылды.

У-Маный тыныч кына Мусаны, аның суырылган, әмма спортчыларга хас нык гәүдәсен күздән кичерде.

Мусаны, Волховтагы кебек, ниндидер минаның шартлавы сукырайтты. Ул, күзләрен сакларга теләп, ирексездән йөзен каплады, аннары әкрен генә кулларын төшерде дә як-ягына каранды. Нәкъ аның алдында зәңгәр халатлы әллә нинди кешеләр утырып тора иде.

Бирегә ничек килеп эләкте соң әле ул? Бу кешеләр кемнәр? Халатлары да әллә нинди сәер... Врачлармы? Кинәт аның җаны сискәнеп, бәгыре телгәләнеп китте: фашистлар, әсирләрне корбан итеп, тәҗрибәләр ясый лабаса. Камераларда бу хакта инде күптән хәвефләнеп сөйлиләр иде түгелме? Әллә аңа да шундый язмыш әзерләгәннәр? Газаплаячаклар... Газ белән агулаячаклар. Ә дуслары кая китеп югалды соң әле?..

Фикерләр ары-бире ташланып, баш сөяген кыйный, арка буйлап чиркандыргыч салкын шуыша башлады. Әмма ул үзен төз торырга мәҗбүр итте.

У-Маный, барысын булмаса да, Җәлил уйларының бер өлешен шактый җиңел чамалады. Бу коңгырт-кара акыллы күзләрдән түгелгән нәфрәт дулкыны аны тетрәндереп җибәрде. Ул берни дә аңламый ич әле! У-Маный, серләрен яшерергә тырышкан мигә үтеп керергә теләп, янә шагыйрьнең күзләренә төбәлде. Җәлил бирешмәгәнлектән, бу бик кыен эш булып чыкты, шулай да өченче көчәнештән үз максатына ирешә һәм җиңел сулап җибәрде.

— Минем исемем У-Маный. Мин — врач. Сез үзегезнекеләр арасында.

Бары менә шуннан соң гына Мусаның җаны урынына утыра башлады. Әллә ничә айга сузылган киеренкелек еракка-еракка очып китеп, башында бер генә газаплы уй, хәтта газаплы уй да түгел, борчылу, дуслары хакында хафалану гына торып калды. Тик, мөгаен, алар да шушында янәшәдә

генәдер, аларны да үлем тозагыннан барыбер йолып алганнардыр, онытмаганнардыр.

Тик ул шулай да:

— Ә дусларым? Алар да мондамыни? — дип сорамый булдыра алмады.

Ул йөгерек һәм үткен карашлы бер хатын-кызның һәм кояшта нык кына янган йөзле ир-атның нидер аңлатырга тырышуларын бер дә башына сыйдыра алмады. Алар барысы берьюлы ниндидер тәҗрибә, киләчәккә күчерелү, аңлаешсыз Дирәк аралыгы һәм хронокыр турында төшендерә, әмма берсе дә аның дуслары Кормашны һәм Сәйфелмөлекевне, Гарифны һәм Әхәтне телгә алмый иде. Ниһаять, ул түземсезләнеп һәм тавышын күтәреп:

— Бүтәннәр кайда соң? — дип мөрәҗәгать итте.

У-Маный сабыр гына:

— Муса иптәш, сез могҗизалы көч тәэсирендә ерак киләчәккә килеп эләктегез. Барысы да бик гади монда. Без хәзер төрле нәрсәләрне вакыт агышында бик җиңел күчерергә өйрәндек. Әйтик, бер бүлмәдән икенчесенә урындык күчергән кебек.

Муса моны үз аңы иләгеннән үткәрергә тырышты.

— Ә минем дусларым кайда калды соң?

— Үз чорларында.

— Аларны минем шикелле коткарып булмыймыни?

Барысы да башларын түбән иде. Тик У-Маный гына салкын канлылыгын саклап:

— Юк шул,— дип җавап бирде.

— Алайса мине дә үз чорыма кайтарыгыз!

Аңа каршы берәү дә эндәшмәде.

— Бүген безгә җәза биреләчәк, аңлыйсызмы? Мин ялгызым гына аннан тайчанып кала алмыйм. Без ахыргача барыбыз да бергә булырга тиеш. Мин әле аларга әйтәсе сүзләремнең һәммәсен дә әйтеп бетермәдем...

— Нинди җәза?! — Госман, Майяга ярсулы караш ташлап, кычкырып җибәрде.

Кыз кискен рәвештә башын чайкап:

— Бу мөмкин түгел,— диде.— Без сезне кырык өченче елның сентябреннән бүгенгә кайтардык.

Муса иңнәрен сикертеп:

— Бүген бит кырык дүртенченең август көне,— диде.

— Ә көне? Кайсы көн?

— Егерме бишенче август...

Госман каударланып приборларга ташланды.

— Исең китәр! — дип пышылдады Җәлилгә сокланып төбәлгән Чатауэй.— Димәк, мин ялгышканмын. Шигырьләр инде әллә кайчан язылган икән.

— Шигырьләр? — дип җанланып китте Муса.— Нинди шигырьләр ул?

Әдәбиятчы тантаналы төстә сөйли башлады:

— «Май аенда тагын җыйналырбыз, Кызыл шәраб килер табынга...»

Муса агарынып китте.

— Алар сезгә килеп җиттемени? — Аның күзләре берьюлы елый да, көлә дә, тантаналы ялтырый һәм балкый да башлады.— Димәк, алар сезгә килеп җиткән...

— Әйе. Без аларны инде күптән яратып укыйбыз.

— Ә лагерьдан... кем дә булса Ватанга кайтып җиттеме соң?

Майя шатлыклы тавыш белән саный башлады:

— Хисаметдинов, Солтанбеков, Терегулов, Хафизов, Фәхретдинов, Шәрипов...

— Габбас шигырь дәфтәрчеген саклый алганмы?

— Аны Терегулов алып кайтты. Алиш шигырьләрен дә варисларына ул китереп тапшырды.

— Без элемтә урнаштырырга Рәхим Саттарны җибәргән идек...

Майя кайгылы көрсенеп:

— Килеп җитмәде ул,— диде.

— Ә Андре Тиммерманс?

— Исән калды һәм сугыштан соң Бельгиягә әйләнеп кайтты.

— Сугыш кайчан бетәчәк соң?

— Сезнең һәла... нидән соң тугыз ай узгач.— Майя бер дә уйламаганда төртелеп калды. Аннары: — Кырык бишенченең маенда,— дип өстәде.

— Димәк, без нибары тугыз ай гына көтеп җиткерә... Кызганыч!

Муса, тирән уйга талып, башын түбән иде. Аңында хатыны, кызы, ирекка чыгып киткән шигырьләре, туган ягы турында меңләгән сораулар кайный. Яшисе килә иде... Әллә нинди ялтыравык приборлар тулы бу бүлмәне ташлап киту нинди кыен! Мондый сәламәт акыллы, булдыклы (үлемгә хөкем ителгәннәрне төрмәдән генә түгел, үткәннән йолып алырга кирәк ләбаса!) кешеләрдән һич тә аерыласы килми иде. Ләкин...

Ул җитди һәм кискен хәрәкәт белән аягүрә торып басты.

— Хәзер мине дусларым янына кайтарыгыз инде!

Шул чак чәчләре иңенә сибелгән нечкә бил алгарак чыгып:

— Җәлил, син үлемнән курыкмыйсыңмыни? — дип мөрәҗәгать итте.

Муса аның киеренке зәбәрҗәт күзләренә төбәлеп:

— Үлемнәнме? — дип кайтарып сорады. Аннары көлемсерәп дәвам итте: — Әйе, мин үлемнән курыкмыйм. Бу буш сүз генә түгел. Бу чынлап та, шулай. Мин үлемнән куркуны башыма да китерә алмыйм. Куркудан да көчлерәк хисләр бар дөньяда... Мин менә хәзер безнең тормыш чигеннән ары да тормыш барлыгын күрәм. Бу кемнәрдер вәгъдә иткән оҗмах түгел. Бу — халык хәтере. Яшәү мәгънәсе нәкъ менә үлемнән соң да тере калуда...— Ул бераз тынып торгач, тагын телгә килде.— Әмма безнең үлемнән курыкмавыбыз һич тә яшәргә теләмәүне белгертми! Без тормышны бик-бик сөябез, яшәргә ашкынабыз, шуңа күрә үлемне күрәлмибез.— Муса, йодрыгын кысып, югары күтәрде: — Без яшәешне шушылай тоябыз. Бу ап-ачык хакыйкать булып каныбызга сеңгән. Сез һәм сезнең эшләрегез минем сүзләремне раслый торган иң әйбәт дәлил!.. Син барын да төшендеңме, кызыкай?

Бүлмәдәгеләр һәммәсе ихтыярсыз катып калды: шагыйрь, томандай әкрен-әкрен генә эреп, күз алдында юкка чыга бара иде.

Госман башын чайкап:

— Мин берни дә аңламыйм,— диде.— Вакыт координатын билгеләгәндә без ничек болай күпкә ялгыштык икән? Хронокыр Җәлилне безнең заманда ни өчен нибары кырык минут кына тотып торды икән?

— Мин хронофизиканы аңлый алмыйм,— диде У-Маный салмак кына,— тик мин Җәлилнең кемлеген чынлап торып таныйп һәм белеп калдым. Гаҗәп һәм ышанмаслык булса да, без аны кырык дүртенченең августыннан да алдарак терелтә алмас идек, чөнки ул моңа үзе каршылык күрсәтәчәк иде. Дуслары янына ашыкканлыктан, ул бездә тагын да озаграк булырга теләмәде.

Камал җанланып:

— Син нәрсә, әллә ул хронокырга тәэсир иткәндер, дип уйлыйсыңмы? — дип сорады.

У-Маный бу юлы җавап бирергә ашыкмады.

6


...рендә яшәрбез. Безне һәрвакыт хәтердә тотарлар. Оныкларыбыз, оныкларыбызның оныклары шәһәрләр салыр, чүлләрдә бакчалар үстерер, йолдызларга очар. Бу эшләргә безнең рухыбызның да бер өлеше кушылган булыр. Мин моны өндәгедәй ачык күрәм, ышаныгыз миңа!

Ул әчке бер горурлык белән елмайды, иптәшләре дә аңа елмаю белән җавап бирде.

Менә шулай елмайган килеш алар төрмә ишегалдыннан уздылар һәм чабылган баш шикелле түгәрәк кояшка, соңгы мәртәбә караш ташладылар.

Артык эчүдән махмырлаган надзиратель ярдәмчесе Пауль Дюррхауэр гильотина янында үз вазифаларын көчкә үти алды. Очлы башлы чүкечләр бертуктаусыз аның чигәсен кыйный иде... Ә бу кыргыйлар хәзер үләчәкләренә хисап та бирмиләр. Елмаеп торалар. Азиатлар! Пауль эше җиңел һәм дәрәҗәле булган җәлладка өнәмичә карап алды. Рейх дошманнарын юк ит тә шуның өчен баш исәбеннән өчәр йөз марка акча ал — тормыш түгел, кура җиләге бу! Дюррхауэр ачуы килеп, авыр сулап куйды. Бәхет басса баса да инде кешеләрне! Ә аңа иртәгәге эсседә Шарлоттенбург округының Штандесамт авылына барып, карт дуңгыз Глюкка унбер татар әсиренең үз күз алдында җәзалап үтерелүен теркәтергә туры киләчәк. Глюк исә, мышный-мышный һәм тиргә баткан хәлдә, авыр әйтелә торган Азия фамилияләрен ашыкмыйча гына штербебухка яза башлаячак...

..................




Өчиле авылы. Тукайның бабасы — Зиннәтулла хәзрәт нигезе. Бу өянке, мөгаен, сабый Габдулланы да онытмагандыр...

*Тавил Хаҗиәхмәтов рәсеме*

# ӨЧИЛЕ

Шагыйрьнең тормыш юлында бу авылның урыны аеруча мәгънәле. Өчиледә ул сабый вакытында шактый кадерсез бала булып күп-медер яшәп алган. 1907 елда Уральскидан солдатка каралырга кайткач та монда килгән. Бу юлы инде — җиткән егет, өстендә-башында затлы кием. Танылган журналист һәм шагыйрь.

Өчиледә шагыйрь гомеренең соңгы өлешендә дә яшәп алган: авыл халкы, авыл һавасы тарткан, бәхетсез үткән балачак истәлекләре шагыйрьнең күңелен бу төбәккә чакырган. Дөньяда Тукай яшәгән авыллар күп түгел. Алар арасында Өчиле үзенчәлекле: бу авылда мәшһүр шагыйрьнең «Мич башы кыйссасы» исемле сатирик очеркы, «Авыл мәдрәсәсе», «Бәет», «Читтәге бик күп өяздә» кебек шигырьләре язылган. Өчиледән башка Казан артының кайсы авылы «Тукай безнең авылда фәлән шигырен язган?» дип горурлана ала? Башка андый авыл юк.

Өчилене шагыйрь ник якын иткән? Беренчедән, анда үткәргән ятим, кимсетүле көннәрендә кителгән күңеленә яшерен генә булса да сузылган шәфкать нурын беренче тапкыр ул шунда тойган. Күп балалы фәкыйрь гаиләдә аңа: «Ичмасам, чәнчелсә, бер тамак кимер иде»,— дип караган чакта, Сәҗидә апасы «үги әбидән яшереп кенә» аны юата һәм сөя алган. Ятим, кимсетелгән, канатсыз кош вакытында үзенә күрсәтелгән аз гына игътибарны да шагыйрь иң кадерле истәлек итеп саклый.

Икенчедән, Өчиле — үзенең табигате белән нәкъ инде Кушлавыч. Әнисе Мәмдүдәнең ир туганы Кәбир мулланың өе дә нәкъ Кушлавычтагы Мөхәммәтгариф абзый өе кебек урнашкан: өй алдында урамга сыгылган акация, шомырт, сирень, өйнең арткы планына тоташкан мәдрәсә башын каплап карт өянке сыгылган (бу өянке әле дә исән). Алгы тәрәзәдән күз ташласаң — түбәнгә, инешкә таба сузылган иңкүле тау бите, аста борыла-сарыла аккан инеш. Инешнең теге ягында — яшел текә тау, аның башында да бөдрә таллар. Кәбир мулланың өе буеннан гына юл уза, аннан аска төшеп тау битенә бераз төньяккарак күтәрелсәң — бормалы юл балачакның азмы-күпме җылы истәлеген саклаган Кырлайга алып бара. Ә Кырлай — әнә генә, офыкны узгач ун чакрымнар гына булыр. Шагыйрь Кырлайдагы шул якты мизгелләрне сагынып бервакыт Өчиледән анда барып та килә.

Тукай Өчилене бик яраткан, табигатен сөйгән, фәкыйрьлеген кызганган. Бик нык авыру булуына карамастан, соңгы кайтуында (1911 елның декабре — 1912 елның феврале) күп укыган, иҗат иткән, ишегалдындагы мәдрәсәгә кереп дәресләрне дә күзәткән. Әлбәттә инде, Уральскидагы әдәби рухлы, шәкертләре рус классларына йөри торган яңача мәдрәсәне узган шагыйрь, дөнья күргән Тукай фәкыйрь авылның фәкыйрь мәдрәсәсе белән танышкач ачынган, сызланган. Аның «Авыл мәдрәсәсе» дигән усал шигыре әнә шул Өчиле тәэсирендә язылган, һәм шагыйрь Казан артының хәлсез, караңгы язмышка дучар ителгән авылларындагы уку-укыту эшләренең торышын бер шигырендә ялтыратып алган.

Шагыйрь базар көннәрнең берсендә, зәмһәрир суыкта абзыйсы белән Арчага да барып килгән, рус агайның мич башында җылынып яткан. Базар көннәрендә татар авылларыннан килгән атлыларны бик телəп «фатир төшерүче» Покровка русларының (Арчаның элеккеге үзәк урамы) безгә мәгълүм булмаган бер йортында шул кышта Тукай булган. Бу урамга мемориаль такта куйсаң да урынлы!

Шагыйрьне Өчиледә хәтерләп калган тау бите, Кәбир мулла йорты артындагы карт өянке, өй түрендәге карт юкә, күрше дә генә җилгә шыгырдап авам-авам дип утырган манарасы тузган мәчет бар. Тукайның тормышында зур роль уйнаган бу авылны истәлекле урын итәсе, тарихи корылмаларын бераз яңартасы, тиешле язулар эләсе, каршы тау битен дә матурлыйсы иде. Өчиле туфрагында бит шагыйрь иҗат иткән...

**Мөдәррис Әгъләмов**

# Тукайдан хатлар

ПОЭМА

## Багышлау

*«... Мин Казанны тәхте пай һәм Казан арты татарларын шушы көнгә кадәр милләтен югалтмаган вә киләчәктә дә югалтмаячак төп халык дип саныйм. Милли әдәбиятыбыз фәкать шулар телендә, шулар рухында гына булуын телим».*

*1910 ел, 9 январь.*
Сәгыйть Сүнчәләйгә язган хаттан.

Бу поэма[1] Сезгә, игенчеләр, —
Хөр фикерле җырлар игүчеләр,
Җырларыгыз уңсын ишелеп!
Сездән һәркөн акыллы сүз көтә,
Мәгънәле сүз көтә кешелек.

Бу поэма Сезгә, нефтьчеләр, —
Дөнья сөйли икән — белеп сөйләр,
Чөнки Европаның яртысы
Сезнең ягулыктан җылы ала:
Өйләрендә илем яктысы.

Бу поэма Сезгә, төзүчеләр,—
Баш өстенә түбә бирүчеләр,
Эшегез авыр,
Авыр — болгавыр.
Үзегез дә беләсез бит инде,
Баш булганда түбә кирәк ул.

Бу поэма Сезгә, язучылар, —
Язганыгыз, әйе, матур чыга.
Әйе, кирәк,
Кирәк матурлык.
Тик сорала шигъри матурлыктан —
Матурлыкта булсын батырлык.

---

Танылган шагыйрь М. Әгъләмов 1946 елда Татарстанның Зәй районы Биш Субашы (Пустошит) авылында туган. «Кыңгырау», «Учак урыннары», «Исәнме, йөрәк» кебек киң билгеле китаплар авторы. Ред.

[1] Поэманың журнал варианты. Автор.

Бу поэма Сезгә, тәнкыйтьчеләр,—
Әлли-бәүдәй татлы Сезнең көйләр,
Изрәп йоклый азмы даһилар.
Тик шагыйрьләр, уятырга теләп,
Төннәр буе тәрәз шакыйлар.

Бу поэма Сезгә, шигырьчеләр,—
Чәчрәп чыгып һәркем шигырь сөйләр,—
Тукай ераклашкан заманда
Азмыни ул көлеп йөрүчеләр
Тик Шүрәле кытыклаганга...

Бу поэма Сезгә, уяу халык,—
Бу уйларны кичә Сездән алып
Үткәрдем дә көнлек яктыдан,
Бүген менә, куркып, калтыранып —
Дулкынлануымнан ләззәт табып,
Үзегезгә инде тапшырам.

Бу поэма Сезгә — һәммәгезгә.
Үзенә дип кабул итә аны
Бу юлларны язган бәндәгез дә...
Бу поэма Сезгә — һәммәгезгә!

## Ак биләүләр кебек ак өйләр...

*«...Ниһаять, авылга кайтып җиттем. Сандык шикелле кечкенә генә, агачтан салган ак өй үземнеке. Кәнәнә ике ягылганга, бик җылы, тәмам чишенеп йоклыйм».*
Әхмәт Урманчиевка хаттан.

Тормыш әйбәт,
Дөнья матур, беләм,
Әмма шул матурлык кушканда
Мәҗбүр булып мин авылга китәм,
Авыл кабул итә кышларга.

Ә шәһәрдә гамьле гамьсезлектән
Бәйрәм шаулый һәрбер тарафта,
Ә мин кайтам төрле юллар белән —
Кайткан кебек кайтам пар атта.

Ак биләүләрмени ап-ак өйләр,
Без дә үстек шул ак биләүдә.

Акны, пакьны күрер өчен килә,
Михнәт чигәр өчен бирәү дә
Килми җиргә.
Бары үзгәрә ул
Үтеп Ачы Еллар аркылы...
Ишегеңнән кергән ап-ак уйның
Үзе белән кергән салкыны
Азмы әллә?!

Сине ярма кебек
Салып төйсәләр дә килегә —

Барыбер син жылытырга тиеш
Мичкә яккан жылы өйне дә.

Ишек тышлар өчен чыпта итеп
Суксалар да сине телгәләп,
Син түзәргә тиеш —
Сабырлык ул
Халкың белән туган бер гадәт.

Кунак булып кына кайтасың шул,
Хужа икәнеңне белмиләр.
Шәмдәлләрдә утлар... Киндер-җепне
Эрләгәндәй, кызлар эрлиләр.

Аерылган бераз, ниндидер көч
Аерган шул моннан,
Аерган.
Вакыт бөккән чана табаныдай,
Вакыт тәртә итеп каерган.

Җигелгәнбез шулай чор атына,
Йөк салынган инде,
Салынган!
Ә шулай да телне, илне һаман
Таныйм сыман бала чагымнан.

Тик яшәрә бара халык җаны
Вакыт кына бары үзгәрә.
Туган якны сөйсәң,— көйләр өчен
Тавыклары җырлый бездә дә.

Яланаяк йөргән Апушлары
Җир җылысын тоялар әле,
Төзелешләр кыса...
ә җиләкне
Чиләк белән җыялар әле.

Юк, бетәчәк түгел иреннәрдә
Беркайчан да туган җир тәме.
Киләчәге шунда яши аның,
Яшәгән күк авыр үткәне.

Мин үземне монда һәр фасылда
Яшьлектә итеп хис итәм.
Арган-талган чакларымда, кышта
Язгы авазларны ишетәм.

...Тирбәләләр кышкы киңлекләрдә
Ак биләүләр кебек ак өйләр.
Нәкъ шуларның берсендә мин бүген —
Ак өйләре кебек ак уйлар
Бураннарда калган мосафирдай
Күңел тәрәзәмне шакыйлар.

Уянмыйча, уйланмыйча кара
Колак салмый кара —
Заманың
Һәр көн кичен искә төшерәчәк
Көннең көнне кабатламавын.

Ничәнче көн язып булмый менә,
Язарга дип кайттым лабаса!
Тәүге ләззәт кебек калтыранам,
Әгәр шулай әйтү яраса.

Кешеләргә әйтәм, юаталар.
Юаталар, рәхмәт аларга:
«Җилләп килсә, тамарга ул, диләр:
Болай булгач, димәк, яварга».

Уйлыйсы да, язасы да килми
Хикмәтләре искә төшсә дә...
Укыйм әле, бәлки йоклап булыр —
Ялкау гына үреләм киштәгә.

Йокы кача, юллар мәгънә ача,
Күтәрелә башым аннары...
Ишелеп төшә гүя минем өскә
Киштәдәге Тукай томнары.

Битләрендә агач яфраклары,
Килеп чыга хәтта айбагыр...
Бер утыз ел элек чыгарылып
Базаларда яткан кайдадыр.

Ә мин бүген укыйм
Салкыннарда
Туңа-туңа язган хатларын...
...Гасыр башындагы капиталның
Ярсып котырынган чаклары...
Шуңа каршы баскан яшь Тукайның
Янып үлгән шигъри чаптарын
Хәтерлим дә...
Янган учакларның
Күмерләрен, димен, актарыйм.

## Җирдә апрель

*«...Бүлмәмдә ары-бире карандым да, каләм заты таба алмагач, карандаш белән генә язарга керештем. Дөнья искедән бирле шулай инде: итекченең аягы ялангач, язучының...»*

1910 ел, 4 декабрь.
Казаннан, Сәгыйть Сүнчәләйгә.

Курку белмәс кыю Курсавиның
Юлларыннан китәр һәр сабыйның
Сулыш юлларына баса-баса,
Егерменче гасыр якынлаша.
Җирдә апрель... Язгы тантана...
Россия — йорт. Түбә кыегында
Боз сөңгеләр, аннан кан тама.

Бәргәләнүләре Кандалыйның
Халык җаны булып барганының
Сәбәпләрен еллар тана-тана

Халык авазыннан эзләп таба.
Җирдә апрель... Язгы ташулар...
Ничә гасыр буе агып килгән
Чүп тыгылган,
Азмы шакшылар?!

Әче телле чәчән Акмулланың
Фаҗигале юлга тап булганын
Хәбәр итеп, сөрән сала-сала,
Тәмамлана гасыр,
Тәмамлана...
Җирдә апрель... Язгы тамчылар...
Самодержавие Россияне
Иярләгән,—
Уйный камчылар.

«Йосыф-Зөләйха»сын Кол Галинең
Тыңлаучылар белән тулган өйнең
Киштәсеннән, борын тарта-тарта,
Апушлары тыңлап, карап ята.
Җирдә апрель... Язгы бөреләр...
Ул бөреләр язлар каршысына
Йөгереп чыккан —
Шундый тереләр!

Бер фидакарь Каюм Насыйриның
Башкаенда туган изге уйның
Чынга ашачагын белә-белә,
Бишенче ел күкрәп күтәрелә.
Җирдә апрель... Гомум ашкыну...
Үз телендә Рәсәй буйлап ага
Гәҗит белән китап ташкыны.

Ерак гасырлардан Мәрҗанинең
Чокып-чокып алган мәрҗәненең
Киләчәктә ялтырасы көнен
Якынайтып,
Канат кага-кага,
Бишенче ел күкрәп кабатлана.
Җирдә апрель... Язгы гөрләвек...
Син агымны туктатырмын, димә,
Актарылып чыкса, бер бөреп.

## Исе китеп ята күле Кабан

*«...Минем һәр минутым бөтен дөнья бәһасенә тора».* 15 ноябрь, 1911 сәнә.
Сәгыйть Сүнчәләйгә хаттан.

Уйланырга Казан җан атмаган,
Халкым диеп үлеп җан атканны
Бер заман да әле яратмаган —
Кабатлаган Тукай үз-үзенә,
Бара-бара кат-кат кабатлаган:
«Мин әле кая барам?»
«Мин әле кая барам?»

...Үз-үзенә беркем бирми сорау,
Хөр акылга тоташ төшкән кырау.

Күгәрүдән касмакланып беткән
Иске богау кыскан —
Рухи богау.

Исереге дә шул, аегы да,
Казаны да шул ук, Җаегы да —
Баер өчен җанын фида кылыр
Җае гына чыксын,
Җае гына...

Әстерханы да шул, Оренбур да,
Җибәрүдән куркып эшне зурга —
Гомер кичерәләр тын гына —
Чиртеп, имеш, «кяфер борынына».

Белә алар хәлен бәндәнең дә,
Алла түгеллеген алланың да...
Милләтенең кайда калганын да...
Ваксытулар һәм изүләр аша
Тукайларның кая барганын да
Белә алар...

Син зур шагыйрь,
Син зур кеше, диләр...
Кая инде безнең эше, диләр...
Симерәләр «дин вә милләт» өчен.
...Синең туңу, синең күшегүләр
Алар өчен бүген шундый кирәк —
Кемдә тулы күңел,
Кемдә кесә...
Ә ил җылый көзге җилгә кушылып,
Җилләр исә җанны кисә-кисә.

...Ә ил җылый... Кемнең кайгысы бар
Бу зур илнең кайгы-зарларында,
Тик дөньясы тыныч булып аның,
Маллар тулы булсын амбарында.

...Ә ил җылый... Кемнең кайгысы бар
Моңнар белән аккан күз яшендә,
Һәркайсының үз кайгысы кайгы,
Вакыты юк илгә эндәшергә.

...Ә ил җылый. Аның елавыннан
Безнең өчен нәрсә үзгәрә, дип,
Шамакайлар җырлый-җырлый бии,
Үз җырыңны синең йөзгә бәреп...

Баш өстендә чорның кара кулы,
Дөнья тулы аның кара колы,
Күрсәт бармак белән төртеп кенә,
Ярылачак!— Эче кара тулы.

Юкка гына шагыйрь Ишмиләрнең
Исләренә моны төшермәгән...

Чор үзенең кара колларына
Кагылганны буган,
Кичермәгән...
Моны белгән шагыйрь.

Егерме җиде ел гомер яшәп,
Шагыйрь һәммәсенә өлгерәчәк...
Кара чорның кара кулы шунда
Бугазына аның үреләчәк.

Шагыйрь биек,
Чорның кулы җитми —
Күкрәгенә барып тыгылачак.

Егылачак шагыйрь, мәңгелеккә
Халык йөрәгенә егылачак.

Әле еллар кара сөлек сыман
Суырганда соңгы саулыгыңны,
Сава Тукай, соң кәррәсен сава
Үзеннән соң илгә калыр моңның.

Бара Тукай, хәрәкаттә һаман,
Исе китеп ята күле Кабан,
Кабатлаган кат-кат үз-үзенә,
Һәркем кабатлар дип кабатлаган:
«Мин әле кая барам?»
«Мин әле кая барам?»

## Йортлардан моң бәрә

*«...Февраль урталарысыз монда сыерлар бозауламас. Минем максады аслыем булган сөт вә катыкны шуңарчы туйганчы эчеп булмас, ахры... Миңа «Горе от ума» белән Лермонтов Полное собраниесен җибәрә күр әле, кирәк... Әле авыл хатирәсе булыр дип бер йөрган, ике мендәр эшләтеп алдым...»*
Январь, 1912 ел. Авылдан Казанга, Гыйльметдин Шәрәфкә язган хаттан.

Кулларыма каләм алмый гына,
Саулыгымны барлый-барлый гына,
Парлы сөтләр эчеп дәвага,
Барсын эшләп алдан уйлаганча,
Ятыйм, дигән идем, читән аша
Йодрыгымны селкеп калага...

Уйландыра...

Авыл йортларыннан
Аерылган егерме елым
Стенага терәп сорау ала:
«Шуңа лаек егерме юлың
Бармы синең?».

Өйдә шундый эссе,
Тимер мичкә яккан утыннар
Сискәндерә шартлап,
Капкачының
Читләреннән төшкән утыннан
Стеналар буйлап йөгерә дә,
Битләремә җәелә кызыллык...

Шундый эссе өйдә,
Киңлекләрдә
Ап-ак буран,
Ап-ак хозурлык.

Шундый эссе өйдә,
Җитми һава,
Кайнар сорау керә тын белән,
Йортлардан моң бәрә —
Бу йортларны
Мүкләгәннәр мәллә моң белән?

Нәселләрнең генә түгел, монда
Моңнарның да очы еракта.
Кайгы моңлы — монысы аңлашыла,
Шатлык моңлы — гаҗәпләнәм шуңа,
Уйларга да ярый бу хакта.

Мин тынлыкка качтым дигән идем,
Ил авазы кермәс урынга,—
Бер том аша килеп керде уйлар
Ил турында, шагыйрь турында.

Казаннан бит, юкса, чордашларның
Биштәр белән алдым китабын.
Йоклаганчы,
Күз тонганчы укыйм.
Уянуга инде онытамын.

Уйлагандыр авыл: «Тәти егет
Озак тормас монда, кыяклар!»
Хатлар укыйм. Йөзләп шагыйренә
Сабак бирә торган бу хатлар.

...«Акча кирәк, киләчәкне тәэмин
Итеп калу кирәк», янәсе...
Ә шагыйрьгә әйтеп калу кирәк,
Һәр минуты дөнья бәһасе.

Киләчәкне тәэмин... Үзләренең
Булмас киләчәге хакына
Баш ияләр, бил бөгәләр килеп
Үлеп яткан шагыйрь катына.

Имеш, алар хезмәт кешеләре,
Һәм яшиләр, имеш, тилмереп.
Килеп бил бөгәләр,
Кемнең әле
Баеганы булган бил бөгеп.

...Мичтә утын яна,
Яна йөрәк,
Син янасың, салмак, тын гына...
Һәрбер яну тиеш аваз биреп
Сискәндереп уйландырырга.

Сорау белән миңа карап яна
Түрләмәләрдәге чигешләр.
Монда бөтенесе сорау ала,
Сорау белән бага:
«Ни эшләр?»

Ә ятакта änә, хәтерләтеп
Гомеремнең татлы көннәрен,
Тигез генә сулыш алып ята
Ак күкрәкле ике мендәрем.

Авыр сулап куям.
Ут яндырып
Меңләп сорау керә тын белән,

Йортлардан моң бәрә
Бу йортларны
Мүкләгәннәр, чынлап, моң белән.

## Учак сүнеп, тимер калачак...

*«...Эчем, тышым Ишми вә игъбаны-*
*на злоба белән тулды... Күз алларым*
*караңгыланды...»*
1911 ел... Сәгыйть Рәмиевка хаттан.

I

Килә хәбәр... Тетрәндереп килә...
Иж-Бубины тар-мар иткәннәр.
Зыя Камалидай зыялылар
Этап белән киткән икәннәр.
Бу тетрәнү ярты гомереңне
Алып китә инде барыбер.—

Бәргәләнә шагыйрь.
Алай гына
Кемдә дә ул була... арыныр.

Кушлавычта тәүге авазыннан
Бизмәннәрдә үлчәсәк әгәр —
Аны гына кичермәгәнме ул
Апуш чактан Тукайга кадәр.

...Үз дигәнчә бара халык һаман,
Үз дигәнчә бара кешелек.
Казан өязендә кыссаң аны,
Ул Җаектан чыга бүселеп.

Бәреп чыга башкорт даласыннан,
Себерелеп чыга Себердән —

Сындырам дип тоткан Столыпин
Тотып кала бары сеңердән.

Син сөрәсең аны мәсләгеннән,
Ә ул урап бөтен Җир шарын,
Бер гасыр да узмый — кире кайта
Эзләп тамырын, эзләп туфрагын.
Нишләтергә мөмкин бу халыкны,
Елаганда хәтта җырласа.
Ул барыбер кайта сөргеннәрдән,
Җырда кайта ни дә булмаса.

Самодержавие, бетерәм, дип,
Утка сала барысын,— яндыра.
Материя бетә, кала, имеш,
Күктә очып йөргән җан гына.

Күперләрне яга чигенмәскә,
Һәм үзенә юлны яндыра.
Бөтенесен яга, кала, имеш,
Җир ашларга көлле кан гына.

Ничә гасыр буе кара төтен
Күтәрелә һәрбер тарафтан —
Ак каурыйлар очып кала барыбер
Иске китап дигән канаттан.

Ул яндыра, мәңгелеккә ясый
Үзе өчен иркен дөньяны.
Ул яндыра һәм үзе дә сизми
Янган утка сала руданы.

Янган утта ул көчәя генә,
Хыяллана: имеш, сындыра.
...Тукай булып ул Җаекта яна,
Бишенче ел көтеп тын гына.

Ул хәзергә әзерләнә генә:
Хәзрәти Мотыйгулланы
Тыңлап дәрес ала — шигърияттә
Кузгатырга төрки дөньяны.

Дөрләп учак яна, ул да яна...
Гомере буе шулай яначак.
Революция дулкынында
Учак сүнеп, тимер калачак!
Калачак.

II

*«...җәберләренең җәрәхәте җәннәте гаденгә керсәм дә йөрәгемнән китмәс».*

*30 июнь 1903 сәнәи миладия.*
Апасы Сажидәгә хаттан.

Кайсы гына яктан килсәләр дә,
Кай шивәдән, кайсы төбәктән,
Фикерләрен әйтә алырлыклар —
Зыялылар белән беррәттән,—

Кай арада гына өйрәнәләр,
Кемнән генә үрнәк алалар:
Казан урамнарын бер әйләнсә,
Койрыкларын сыртка салалар.

Ә сабыйга туган теле өчен
Дәреслекне кемнәр хәзерләр?—
Погон бирер җылы урын булса,
«Алла булырга» да әзерләр.

Билгеле бит кычкырасылары
Койрык каткач кына бәкегә,
«Алла булса», артык ерак йөрми
Пәйгамбәрлек галәмәте дә.

Чын халәтен күрсәтүдән куркып
Яшеренә, гүя, томана —
Яшеренә фиркаләргә кереп,
Фирка аша олуг Думага.

...Мещаннары такта ярыгыннан
Курка-курка гына тын ала.
Бер төркеме дингә яшеренгән,
Бар мәкерен төреп чалмага —
Ныгытмага кереп поскан сыман
Мөхәммәткә поскан, аллага.
Үрмәлиләр мыдыр-мыдыр килеп
Мөнбәренә кеше җанының,
Саранча күк тоташ үрмәлиләр
Гөлләренә милләт багының.
Нәкъ коръәндә язган күренештәй,
Афәт булып, сары бу кавем
Уңдырышлы җирне бетерәчәк —
Көтеп торсаң ашап киткәнен.

Һәркем әкәм-төкәм, һәркайсының
Йомранныкыдай оясы...
Бар әле ул күпме битлекләрне
Сыдырасы, ачып куясы.

Һәм Габдулла төрки дөньясында
Шаккатырып һәммә тарафны,
Мәдрәсәләрдә нәкъ үзләре
Ничә еллар биргән сабакны
Искә төшерәчәк...

Үзләренчә
Сыек чыбык белән ярачак.
Казан стенасын икенче кат
Шартлатачак әле, алачак!
Алачак.

## III

*«...Керпе үзенең кабыгына кереп яшеренгән төсле, мин дә сөю хакында бер нәрсә язсам, ялган имзалар астына сыгынам».*

23 июнь 1908 ел. Фатих
Әмирханга хаттан.

Ә хәзергә барысы яшеренгән.
Барысы яшеренгән...

Замана
Үзе шуны сорый...
Мәхәббәтең
Яшеренми икән — талана.

Каралама килеш рәнҗеп карый
Сөю-хакның язылып беткәне —
Янәшәдә һаулап кәтеп ята
Печән базарының этләре.

Яшермәсәң изге хисләреңне,
Күрә алмый калсаң бер чара;
Татар кызын эштән чыгаргандай,
Алар аны эштән чыгара.

Җибәрәсең пәрәнҗәгә каплап
Якты уйларыңны дөньяга,—
Чиләгенә күрә капкачы бар,
Сыгынасың ялган имзага.

Үксез ятимлекне аңламаган,
Ана назын тойган киләчәк,
Тукай хатын-кызны яратмаган,
Дигән ялган уйга киләчәк.

Уйлап чыгарырга мөмкин моны
Шакшыланып беткән бер надан,
Ул алардан өстен,
Тик үзеннән —
Табигатьтән өстен булмаган.

...Булган саен чишмә тирәнрәк,
Булган саен суы сафрак —
Үзеннән зур күләгәсен сала
Өзелеп төшкән һәрбер яфрак.

Ятим үскән сабый чакларында
Төшеп калган кара күләгә,
Чишмәдәй саф, тирән күңелендә
Шушы яфрак булып тирбәлә.

Сабый чакларында Кырлайда ук
Ишетелгән «үксез баланы»,
Авыз-борыннары канга баткач,
Искә алыр Печән базары.

Ул — Шәрифә карчык тупсасы да,
Тими калган ана назы да —
Ятимлек ул хәтер дәфтәренә
Йөрәк каны белән языла.

Шагыйрь аны гомер дәвамында
Тик кәгазьгә генә төшерә.
Ятимлек ул үзе ярты гомер
Табигатьтән шагыйрь кешегә.

«Хөр мәмләкәт, хөр Русия»— хәтта
Балачагын искә төшерә.
...Яңа гасыр башы.
Кынындагы
Хәнҗәр әле Тукай шигыре.
Нурлы йөзен бер ачачак әле
Пәрәнҗәле Тукай шигыре.

Ул балкып та, ул сагышланып та
Килер заманнарга барачак.
Һәрбер заман аның үз хәленчә
Пәрәнҗәсен йолкып алачак.
Алачак!

### IV

*«Мин әле кая барам?»*
23 июнь 1908 ел.
Фатих Әмирханга хаттан.

Хасталанып «Болгар» номерында
Язып салган гади хатында
Уйламагандыр да заманнарның
Болай үзгәрәсе хакында.

Уйламагандыр да халыкларның
Кышкы сарайларны аласын,
«Тәфтиләү»не җырлап егетләрнең
Гильотиналарга барасын
Уйламагандыр да...
Ә ул менә
Әверелеп халык җанына,
Кирәк чакта алгы сафка басты
Ил сагына,
Ватан сагына.

Татар егетләр Европага
Азат дөнья илтә барды бит —
Биштәрендә Тукай томы булса,
Күкрәк кесәсендә — партбилет.

Калаларга урам булып керде,
Исем булды сарай-йортларга.
Юл күрсәтте халык дөньясына
Дәвам булып калырлыкларга.

Алда торган яңа гасырда да
Ул эталон булып калачак.
Җырларыбыз белән — безнең белән
Бездән соң да бергә барачак.
Барачак!

## Ә халык — җыр...

*«Торам-торам да: «Ярабби! Ятимләкләр, фәкыйрьләкләр, ачлыклар, авылдан-авылга сатылып йөрүләр, рәхимсез татар байларында хезмәт итүләр, татар мәдрәсәсендә черүләр арасында да саклап килдегем истигдад очкыны шушы исерекләр, исерек иптәшләр арасында бер дә кабынмаслык булып сүнәрмени инде?» — дим.*
23 июнь 1908 ел. Фатих
Әмирханга хаттан.

### I

...Аларның да саллы канатлары
Сабый чагында ук каерылган.

Ә халык — җыр,
Ул мәңгелек җырның
Сүзе белән моңы аерылган.

Тарих төпләреннән күтәрелгән
Моңнары бар аның,
моңланырлык!
Моңнары бар аның...
Нәкъ бүгенгә
Тәңгәл килә алыр сүзләре юк.

Болыт куе... күкрәп яшен килә,
Шул сүзләрне язар Тукай кирәк...
Монда булса бетерерләр иде,
Ә Җаекта...
анда башка иләк.

Җиделе лампа түбе тирәсеннән
Ерактарак төшә һәрчак якты...
Күзе ачылганчы буар идең,
Бу бит Җаек,—
түгел Казан арты.

...Бераү итәк, бераү китап үбә,
Бераүләре җуйган ышанычын.
Үзгә иман кирәк сүзләреңне
Халык көйләренә кушар өчен.
Фидакарьләр утка барып керә,
Белә-белә керә янасын да.
Ә халык җыр,—
яңа аваз кирәк
Яңгырарга чорның яңасында.
...Бераү хатын, бераү алтын үбә:
Чат сыланып кала селәгәе.
Чабышкыдай янып Ямаш үлә,
Бу томаналарга: «Үлмәгәе!»

Атла гасырлардан-гасырларга,
Ит чираты булса — тавыш-гауга!
...Үзгә иман кирәк мәдхияңне
Ямаш исеменә багышларга.

Яңа буын!
Ил хәсрәте булса,
Әнә кайда синең җырлар җырың —
Күр, үткәне аша киләчәген,
Киләчәге аша үткән чорын.

Хөр мәмләкәт һәм җиделе лампа,
Еллар арты күпме еллар акты.
Ильич утларының яктысында
Төбенә дә төшә... хәзер якты!

II

...Билгелеме, билгесезме юлың,
Турыданмы, әллә бик ураумы?
«Кая барам?..» Кеше үз-үзенә
Кабатларга тиеш шул сорауны.

Һәлакәткә дучар сабыйларны
Коткарамы кереп янган утка,
Җәлилчеләр белән «Тәфтиләү»не
Җырлап үләме ул Моабитта;

Я Газинур булып күкрәк белән
Үлем авызына капланамы,
Я кагамы каләм киңлегендә
Ни дәверләр бикле капкаларны,

Күтәреләме ул трибунага,
Я БМОда иле исеменнән,
Яки иртән эшкә барамы ул
Горурланып гади эше белән,

Үз-үзенә сорау бирә алган,
Яманатын җирдә таратмаган...
Кабатлаган Тукай үз-үзенә,
Заман кабатлар дип кабатлаган:
«Мин әле кая барам?»

Кая барам? Биргән шул сорауны
Кая барганын да белгән хәлдә...
Һәрбер континентта ике дөнья
Маңгай белән маңгай бәрелгәндә,
Күз алдында «мәңгелеккә килгән»
Дәүләт хуҗалары алышына.

Ул без — шаһит ике системаның
Билләр кыскан мәшһүр алышына...

## Соңгы сүз

*«...Мин кайтып җиттем. Бер нәрсәгә дә аптырамадым. Әлегә җитәр».*

12 май, 1912 ел.
Уфадан Казанга. Кәбир
Бәкергә хаттан

Дүртенче том кулда... Егерме хат,
Иҗат түгел, бары хат кына...
Күк капусы ачылгандай, алда
Көрәшче һәм шагыйрь яктыра.

Көрәшче һәм шагыйрь,
Сиксән биш ел
Элек язган язма, хатларын
Кулга алыйм дисәм, кулым пеште,
Уттан гайре берни тапмадым.

...Бүген менә бераз
Үрелеп кенә
Утлы күмерләрен актардым.

*1974—1984.*

**Рәфыйк Нәфиков,**
профессор, тарих фәннәре докторы

# ТУКАЙНЫҢ ДУСТЫ, ПАРТИЯ СОЛДАТЫ

Казан. 1908 елның 28 марты. «Әльислах» газетасы редакциясе яшьләре әдәби-музыкаль кичә оештыралар. Бу кичәдә тамашачылар буларак та, чыгыш ясаучылар буларак та, рус, татар һәм башка милләт вәкилләре катнаша. Сәхнәдән җыр-моң агыла, шигырьләр яңгырый, В. Апанаевның кыллы оркестры төрле халык көйләрен уйный. Чыгыш ясаучылар кемнәр диген?! Әнә Тукай «Утырышу» шигырен укый, С. Рәмиев «Алданган»ны. Аларны Г. Коләхмәтов алыштыра. Ф. Агиев җитәкчелегендәге шәкертләр хоры зур күтәренкелек белән үзбәк, казах җырларын башкара. Бу кичә, ислахчы яшьләрнең бик күп башка кичәләре кебек үк, шигъри, максатчан. Россия халыклары культурасының гүзәл үрнәкләрен, халыклар дуслыгы идеяләрен пропагандалауга багышланган була һәм югары профессиональ дәрәҗәдә үтә. Ф. Әмирхан белән янәшәдә утырган казах, үз халкының җырларын башкаручы кешенең татар икәнлеген белгәч, хәйран кала.



Әлеге кичә турында тәфсилле информацияне безгә, «Әльислах» газетасының 1908 ел 3 апрель санында басылган язмасында әдәбиятыбыз классигы Фатих Әмирхан теркәп калдырган.

Кичәне оештыручылар һәм чыгыш ясаучылар турында сөйләгәндә, Ф. Әмирхан Гликерия Алексеевна Трейтерның ролен аерым билгеләп үтә. Әдәбият-сәнгать мәсьәләләрендә таләпчәнлеге белән аерылып торган Ф. Әмирхан Трейтер ханым һәм аның тарафыннан оештырылган кызлар хоры чыгышы кичәгә «аерым бер ямь вә камаль» бирде дип яза.[1] Бу кичәдә Трейтер ханым бер озын, бер кыска җыр һәм, хорга кушылып, «Ашказар»ны башкарган. Тамашачыларны таң калдырды, аның чыгышы «озак-озак кул чабуларны» яулап алды, дип яза Ф. Әмирхан.

Татар җырын тирәнтен аңлаган язучы: «Трейтер ханым махсус бер дәрт белән җырлап, Россия мөселманнарының гасырлардан бирле күңелләренең иң төбендә сакланган кайгы хисләрен мөҗәссәм (гәүдәләндергән — Р. Н.) бер кыяфәттә халык алдына чыгарып, һәркемнең хисләрен кузгатты»,— дип билгеләп үтә.

Безгә Ф. Әмирхан һәм Г. Тукайның дусты, аларның фикердәше Вафа Бәхтияров белән берничә тапкыр очрашырга һәм әңгәмәдәш булу бәхетенә ирешергә туры килде. Ул Казан сәхнәләрендә еш чыгыш ясаучы Трейтер ханым турында бик җылы фикердә иде. В. Бәхтияров күренекле татар язучыларының Г. А. Трейтер белән шәхси дуслыгы, аерым алганда бөек Гете әсәрләрен үз телендә укырга хыялланган Г. Тукайның Трейтер ханымга немец телен өйрәнергә йөргәнен дә искә ала иде[2]. Трейтер ханым белән Г. Тукай кичәләрдә, шул исәптән берләштерелгән рус-татар кичәләрендә дә очрашканнар.

Хәзер, күп еллар буе архивларда эзләнгәннән соң гына, бу әдәби-музыкаль кичәләрдән һәм спектакльләрдән җыелган керемнең бер өлеше большевикларның Казан шәһәр комитеты кассасына тапшырылуы, ә бер өлеше исә үзәк большевистик матбугат органнарына, шул исәптән ленинчыл «Правда» газетасына язылу өчен тотылуы билгеле булды. РСДРП (б)ның Прагада үткән VI Бөтенроссия конференциясенә Казан һәм Баку оешмаларыннан делегат итеп А. Н. Догадованы җибәргәндә дә шул акча тотылган. («Казан утлары», 1980, 11 сан, 150—162 бб; 1981, 9 сан, 165 б).

---

[1] Әмирхан Ф. Сайланма әсәрләр. 2 т., Казан, 1958, 239 б.

[2] Кызганычка каршы, В. Бәхтияровның Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты архивында саклаучы истәлекләрендә бу кыйммәтле фактлар теркәлеп калмаган.

Ф. Әмирхан — татар музыка сәнгатен үстерүдә катнашкан Г. А. Трейтерның югары миссиясен документаль рәвештә чагылдырган бердәнбер автор түгел. Бу турыда Казандагы рус көндәлек матбугаты битләрендә дә мәгълүматлар бар.

1908 елның 7 мартында «Новый клуб»[1] бинасында, башында Казанның прогрессив интеллигенциясе вәкилләре торган Халык университеты тарафыннан оештырылган «Шәрык музыкасының этнографик кичәсе» була. Кичәнең беренче өлешендә халык җырлары эшкәртүсез, халыкта ни рәвешле яши, шул килеш башкарыла, курай моңнары да яңгырый. Кичә турында язган газета хәбәрчесе Россия халыкларының музыкаль сәнгате үзенең матурлыгы белән ул чактагы Көнбатыш Европа һәм Американың модалы җырларыннан, көйләреннән һич тә калышмый дип билгеләп үтә. Кичәнең икенче өлешендә Бородин, Глазунов, Кюи, Чайковский, Мусоргский, Римский-Корсаков, Григ кебек күренекле композиторлар һәм башка музыка белгечләре тарафыннан эшкәртелгән шәрык көйләре башкарыла («Волжско-Камская речь», 1908, № 141).

Кичәгә халык күп килгән була, бигрәк тә татарлар. Татар, үзбәк, казах һ. б. халык җырлары башкарыла. Кичәнең икенче өлешендә Г. А. Трейтер тарафыннан башкарылган «Ашказар» һәм «Озын көй» җырларын газета корреспонденты аерым билгеләп үтә. («Волжско-Камская речь», 11 март, 1908, № 151).

Бу хәбәрне «Волжско-Камская речь» редакциясенә җибәрелгән хат тагын да тулыландырып җибәрә. Әлеге хатның азагында 24 фамилия санала һәм һ. б. дип өстәлгән. Алар барысы да «мөселманнар исеменнән» Гликерия Алексеевна Трейтер ханымга рәхмәт хисләрен белдерәләр. «Ул безнең тарафтан инде онытылган милли көйләрне, татар җырының рухын сәнгатьле итеп яңадан терелтте. Безгә моңа кадәр беркайчан да туган көйләребезне мондый гүзәл башкаруда, хатын-кыз башкаруында... ишетү мөмкин булмаган иде. Һәм моның өчен хөрмәтле Г. А. Трейтер ханымга чын күңелдән рәхмәтебезне белдерәбез» («Волжско-Камская речь», 1908, № 153).

Бу документ татар демократларының Трейтер ханымны никадәр яратуларын, үз итүләрен ачык күрсәтсә кирәк.

Шулай итеп, без күп кенә татар язучылары һәм җәмәгать эшлеклеләре тормышындагы мөһим бер эпизод турында ачык мәгълүматларга таянып фикер йөртә алабыз. Рус культурасы эшлеклеләренең ярдәме бик вакытлы була һәм гүзәл нәтиҗәләр бирә. Бу ярдәмнең интернационалистик рухта булуы, илебез халыклары арасындагы дуслыкны үстерүгә һәм ныгытуга юнәлдерелгәне бик ачык күренеп тора. Туып килүче татар интеллигенциясенең иң алдынгы вәкилләре моңа милли горурлык белән сугарылган тирән патриотизм һәм интернационализм хисләре белән җавап бирәләр. Югарыда атап үтелгән хатка иң беренчеләрдән булып кул куючылар арасында сәнгатьне тирән аңлаучы һәм кадерен белүче сөекле шагыйребез Г. Тукайның фамилиясе бар. Аның белән бергә бу документта Г. Камал, С. Рәмиев, В. Апанаев, Г. Кәрам, М. Вахитов һәм Ф. Әмирханның дуслары И. Кулиев һәм Ф. Агеев, Г. Коләхмәтовның сеңлесе — С. Коләхмәтова, идея ягыннан җитәкчесе большевик Х. Ямашев булган әдәби түгәрәк әгъзасы студент М. Сәетов фамилияләре теркәлгән.

1908 елның 28 мартында ислахчылар тарафыннан оештырылган концертта булган икенче бер рус корреспонденты үзенең язмасын «Татар кичәсендә» дип атаган. Г. А. Трейтер чыгышын ул да аерым билгеләп үтә: «Г. Трейтер күренүгә, мөселманнарның куануы үзенең апогеена җитә». Ислахчылар аңа чәчәкләр һәм истәлек альбомы бүләк итәләр («Волжско-Камская речь», 1908, №188). Корреспондент Г. Тукай һәм С. Рәмиев фамилияләрен дә атый һәм аларны халык «чын күңелдән алкышлый» дип билгеләп үтә. Бу шул ук, югарыда искә алынган һәм Ф. Әмирхан тарафыннан тасвирланган кичә. Ф. Әмирхан ул кичәдә катнашкан Тукайның исемен атамаган. Ә рус корреспонденты исә Г. Тукайның да, С. Рәмиевнең дә фамилияләрен атап яза. Димәк, бу кичәдә Г. А. Трейтер белән бергә Г. Тукай да чыгыш ясаган. Кичәнең рус тыңлаучылары күңеленә дә хуш килгәнлеге корреспондент сүзләреннән ачык чагыла.

«Казан мөхбире» газетасында да романслар кичәсе булачагы һәм анда «татарлар өчен күп эш башкарган Трейтер ханым» чыгыш ясаячагы турында хәбәр ителә. Автор кичәдә татарлар күп булыр дип өметләнә, чөнки аның фикеренчә «Трейтер ханымның гүзәл тавышын» ишетү тыңлаучыларга зур ләззәт бирәчәк. («Казан мөхбире», 1908, 24 март, 272 нче сан).

Казанлыларның хәтеренә тирән уелып, аларны таң калдырган Г. А. Трейтер кем соң ул?

Казан университетына иреклe тыңлаучы булып кергән Гликерия Алексеевна Трейтерның шәхси эше (личное делосы) 1907 елның 18 сентябреннән алып 1909 елның 8 августына кадәр булган вакытны үз эченә ала. 1907 елның 13 августында университетның ректоры исеменә бирелгән гаризада Г. А. Трейтер үзен, «әгәр дә медицина факультетында вакансия булмаса», физика-математика факультетының табигать фәннәре бүлегенә кабул итүләрен

[1] Новый клуб — 1905 елда ачыла (хәзерге Горький урамы, 3 нче йорт), 1912 елда ул хәзерге Татар дәүләт академия театры бинасына күчә.

үтенә[1]. Ул врач булырга тели. Университетка кадәр Г. А. Трейтер Павловск институтында алтын медальгә курс бетерә һәм шәфкать туташы исемен ала. Аның шулай ук Мәскәү филармониия җәмгыяте тарафыннан ирекле художник исеме алуы турында бирелгән дипломы да була. Ул чакларда мондый диплом алу югары уку йортын бетерү белән (бу очракта консерватория) тиңләштерелгән.

Г. А. Трейтер Флафицкий, Поленов кебек күренекле галимнәрнең лекцияләренә йөрергә язылса да, аңа Казан университетында озак укырга туры килми. Ул җәмәгать эшләре белән мәшгуль була: Идел буе халыкларының, бигрәк тә татарларның, музыкаль культурасын һәм сәнгатен үстерүгә күп игътибар бирә, беренчеләрдән булып халык җырларын башкаручы кызлар хорын оештыра, үзе дә, сәхнәдән татар җырларын пропагандалап, бик еш чыгышлар ясый. Аның бу өлкәдәге эшчәнлеге жандармнар һәм полицейскийларның да игътибарын җәлеп итә. Һәм, озак та үтми, аларның басымы аркасында Г. А. Трейтер ханым Казаннан китәргә мәҗбүр була. Вяткага (хәзерге Киров) сөрелгән Г. А. Трейтер үз документларын Вятка шәһәр полиция идарәсе аша ала.

Казанда аның Л. Шумкова ханым кулында булган шәхси мәктәптә музыка дәресләре бирүе дә билгеле. Казан университетының медицина факультетын тәмамлаган бертуган энесе С. А. Трейтер — 1907 елда Л. Шумковага өйләнә. С. А. Трейтер хөкүмәткә каршы демонстрацияне хәзерләүдә катнашканы өчен 1902 елда Казаннан сөрелгән була, 1904 елның 28 декабрендә ул халык алдында «Бетсен самодержавие, яшәсен азатлык!» дигән лозунглар кычкыра, ә 1905 елның октябрендә кораллы чыгышларда актив катнашучыларның берсе була[2].

Шумковаларның фатиры, аның хуҗалары махсус сөйләүгә лаек, чөнки алар узган йөзнең 80 нче еллары башыннан алып революцион подполье, В. Фигнер гаиләсе, аларның туганнары Куприяновлар, эмигрантлар белән бәйләнештә торалар. Реакция елларында да аларның мәктәп бинасында яшерен җыелышлар, ярымлегаль кичәләр үткәрелә, заман проблемаларына багышланган рефератлар укыла. Шумковалар даими рәвештә полиция һәм жандармерия күзәтүе астында торалар.

Киров өлкәсе дәүләт архивы тарафыннан 1980 елның 8 гыйнварында (№ 25—84) бирелгән белешмәдә Г. А. Трейтерның Вяткадагы эшчәнлеге турында кайбер мәгълүматлар китерелгән. Мәсәлән, ул шәһәрдә Л. В. Собинов исемендә музыка училищесы ачу артыннан йөри, архивта Л. В. Собиновның Вяткадагы музыка училищесына үз исемен кушуга ризалык белдереп, Г. А. Трейтер исеменә язган хаты да саклана[3].

Архивның директоры З. В. Подавалова Г. А. Трейтерның туганнары турында да хәбәр итте. Моның алга таба яңа материаллар туплауга зур ярдәме тиде.

Ленинград өлкәсендә яшәүче Е. А. Трейтер сүзләреннән түбәндәгеләр билгеле булды: Трейтерлар — чыгышлары буенча Германиядән, аларның Россиягә Веймардан күчеп килгән борынгы бабалары, гаилә риваятьләренә караганда, Гете белән таныш булган.

Цусима сугышы вакытында Г. А. Трейтер «Орел» йөзмә госпиталендә шәфкать туташы булып эшли. Туганнары, Г. А. Трейтер Вяткада яшәгәндә (аның Казанда яшәү фактын алар белмиләр — Р. Н.), Беренче империалистик сугыш алдыннан чит илләргә чыккан һәм анда В. И. Ленин белән очрашкан дип сөйләсәләр дә, аларда бу турыда документаль мәгълүматлар юк. Ләкин гаиләдә уникаль белешмә — Советларның 2 нче Бөтенроссия съезды утырышларына керү өчен Советның медик-санитария секциясе председателе Рабинович тарафыннан кул куелып 1917 елда Г. А. Трейтерга бирелгән мандатның төп нөсхәсе саклана. Архив материалларыннан Г. А. Трейтерның 1917 елда Петроград Советы члены булганлыгы да ачыкланды[4]. Һичшиксез, ул В. И. Ленин чыгышларын тыңлаган һәм дөньяда беренче декретларын игълан итү кебек бөек вакыйгаларга аның да катнашы булган.

В. И. Ленин җитәкчелегендә аңа илебездә пролетариат диктатурасын ныгыту өлкәсендә дә эшләргә туры килә. Ул 1919 елның сентябрендә Мәскәүдә большевиклар партиясе сафларына керә һәм бөтен гомерен эшче-крестьяннар сыйныфы эшенә багышлый.

Ул партия кая җибәрсә, шунда эшли. 1918 елда Вяткада губерна сәламәтлек саклау бүлегендә, ә 1919 елда Мәскәүгә күчерелә һәм анда да губерна сәламәтлек саклау бүлеге месткомы секретаре булып эшли. Аннан соң бер ел профсоюзларның губерна бүлеге секретаре вазифаларын башкара. Эштә үзен яхшы яклардан гына күрсәткән Г. А. Трейтерны 1921—1922 елларда Профинтернда эшләргә күчәләр. НЭПның авыр елларында ул Новороссийскида мәгариф хезмәткәрләре профсоюзы председателе, Ростов-на-Донуда ВКП(б) Үзәк Комитетының Көньяк-Көнчыгыш бюросы инструкторы, Сухумида Грузия КП(б)ның өлкә комитетында хатын-кызлар бүлеге мөдире була, ә 1929—1931 елларда Лондонда СССР Тышкы сәүдә Халык Комиссариаты аппаратында эшли.

---

[1] ТАССР Үзәк дәүләт архивы, 977 ф., 1 тасв., 44705 эш.
[2] ТАССР ҮДА, 1 ф., 5 тасв., 735 эш, 1, 20—22, 23, 27 бб.
[3] Киров өлкәсе дәүләт архивы, 582 ф., 152 тасв., 16 эш, 35—30 бб.
[4] КПССның Татарстан өлкә комитеты партия архивы, 30 ф., 3 тасв., 603 эш.

Г. А. Трейтер рус теленнән тыш француз, немец, инглиз һәм итальян телләрен дә камил белгән. Югарыда күренгәнчә, татар сөйләм телен дә үзләштергән. Туганнарының әйтүенә караганда, Г. А. Трейтер В. И. Ленин хезмәтләрен чит телләргә тәрҗемә итүдә дә катнашкан.

1925 елда ул Тышкы эшләр Халык Комиссариаты референты сыйфатында яңадан Мәскәүдә эшли башлый. Ф. Э. Дзержинский аның чекистлар сафында эшләвен кирәк дип таба, һәм ул берничә ел буе шунда эшли. Гомеренең соңгы елларында Г. А. Трейтер ВКП(б) Үзәк Комитеты аппаратында, соңыннан Коммунистик Интернационалның Башкарма Комитетында редактор булып хезмәт итә, бары тик олы яшькә җиткәч кенә пенсиягә чыгып, лаеклы ялга китә. 1872 елда туган Г. А. Трейтер 1938 елда Мәскәүдә вафат була.

Г. А. Трейтерның тормышы — туган илгә чиксез бирелгәнлек, ленинизм, коммунистлар партиясе программасын гамәлгә ашыру өчен үз-үзеңне аямыйча хезмәт итүнең гүзәл үрнәге булып тора.

Революциягә кадәр үк ул, чыгышы белән дворянка булуына карамастан, бу катлау белән араны өзеп, намуслы хезмәт белән үз көнен үзе күрә башлый: музыкадан, чит телләрдән һәм җырдан хосусый дәресләр бирә, хезмәт ияләренең һәм патша армиясе солдатларының авыр тормышын уртаклашып, больницада яки госпитальдә шәфкать туташы булып эшли.

Аның биографиясенең күп кенә сәхифәләре әле тагын да тулырак яктыртуны, тикшерүне таләп итә. Ләкин әлегә билгеле булганнар да безнең алга бөтен гомерен царизмга һәм капитализм изүенә каршы көрәшкә, социалистик төзелеш эшенә багышлаган батыр көрәшче образын күз алдына китерергә мөмкинлек бирәләр.

# ӘДИПНЕҢ МАТБУГАТКА КАРАШЛАРЫ

Халыкның язмышы, аның хәле, бүгенгесе һәм киләчәге белән гражданнарча кызыксынган һәм аңа катнашкан иҗади шәхес матбугатка мөрәҗәгать итмичә, аны үз идеалларын пропагандалауда, тормышка ашыру өчен көрәштә корал итми кала алмый һәм, табигый инде, матбугатны үстерүгә өлеш кертмичә кала алмый. Бигрәк тә социаль һәм политик хокук-ирекләрдән мәхрүм ителгән халыкларда әдәбият белән журналистика алдынгы карашлы шәхесләр өчен төп көрәш коралына әверелә.

Габдулла Тукай, башка милләт һәм халыклар әдәбиятының мәшһүр эшлекләләре кебек үк, прогрессив татар матбугатына нигез салучыларның күренеклесе булды. Аның журналистикабызны үстерүгә салган хезмәте үзенең колачы, юнәлеше, иҗтимагый тормышта уйнаган роле, публицистик җәһәттән камиллеге белән милли әдәбиятны алга җибәрүгә керткән өлешеннән һич тә ким түгел. Сүз дә юк, Г. Тукайның төрле матбугат органнарын аякка бастыру һәм үстерүдәге хезмәте тәкъдир ителгән, публицистик мирасы җентекләп тупланган (әсәрләренең 1975—1977 елларда Татарстан китап нәшриятында чыккан дүрт томлыгы һәм яңа биш томлыгы — моның ачык мисалы), аңлатмалар бирелгән. Бу мирас әдипнең иҗтимагый-политик һәм эстетик карашларын, гомумән, татардагы мәгърифәтчелек һәм революцион-демократизм юнәлешләрен, марксизм-ленинизмның тамырлануын, татар культурасы һәм әдәбияты тарихын өйрәнгәндә фәнни әйләнешкә кертелгән, анализланган, аңа бәя бирелгән. Бу эшкә иң зур өлешне, әлбәттә инде, тукайчылар керттеләр. Әмма XX йөз башы татар журналистикасының, аерым алганда, аның революцион-демократик канатының иң көчле һәм иң характерлы вәкиле буларак Г. Тукайның эшчәнлеге журналистика фәне предметы һәм закончалыклары күзлегеннән тиешенчә өйрәнелмәгән әле.

Бу мәкаләдә шул зур эшчәнлекнең бер генә ягы — Г. Тукайның матбугатка карашлары яктыртыла.

Г. Тукайның бөтен аңлы гомере матбугат белән бәйле булган. Иҗтимагый эшчәнлекнең әлеге өлкәсе, бер яктан, аның 1905 елгы революция тәэсирендә казандай кайнап киткән тормышка актив катнашу, халык массаларының аңына бәрәкәтле йогынты ясау, үзенең иҗтимагый-политик карашларын конкрет тормыш вакыйгаларына, фактларына, төрле сыйнфый көчләрнең, аларның вәкилләренең кылган гамәлләренә нисбәтән көне-сәгате белән әйтеп бару чарасы булса, икенче яктан, ул әдипнең политик җәһәттән дә, идея-

эстетик җәһәттән дә бик тиз өлгерүенә, революцион-демократ шәхес булып формалашкач инде гел алгы сызыкта атлавына, әдәби иҗатының халыкчанлык һәм реализм үзәнендә үсә-җитлегә баруына ярдәм иткән. Г. Тукайның соңрак үзе хакында горурлык белән: «Мин бит... саф, коеп куйган поэт кына түгел, мин дипломат, политик, общественный деятель дә бит», дип белдерүе законлы иде. Шушы раславы белән аның барыннан да бигрәк журналистлык эшчәнлеген күздә тотуын ассызыклап күрсәтик. Чөнки журналистлык эшчәнлеге иҗтимагый-политик эшчәнлекнең мөһим бер тармагы санала, ул теге яки бу сыйныфның үз идеологиясен, политикасын формалаштыру һәм тормышка ашыру чарасы булып хезмәт итә.

Иң элек Габдулла Тукай татар матбугатын күренекле оештыручыларның берсе иде. Оештыручыга журналистиканың материаль-техник базасы турында кайгыртырга да, идея-политик юнәлешен билгеләргә һәм эзлекле төстә тормышка ашырырга да, бердәй мәсләкле авторлар тупларга да, газета-журналларны бизәргә, укучылар табарга, аларга тиражны вакытында җиткереп барырга да кирәк. Ул вакытта матбугат эшендә хәзерге кебек хезмәт бүленеше булганмыни! Ул чагында бер кеше үз җилкәсендә әллә ничә вазифаны берьюлы күтәреп барган. Г. Тукай әнә шундый шәхес булган. Ул яшь-яшь килеш матбугатның бөтен нечкәлекләрен үзләштергән, әлеге өлкәдәге эшчәнлекнең барлык тармакларында хезмәт иткән: хәреф җыючыдан редакторга кадәр юл узган.

Мәгълүм булганча, Беренче рус революциясенең бәрәкәтле йогынтысы астында Уральск шәһәрендә демократик юнәлештәге «Фикер» газетасы, «Әлгасрел-җәдит» журналы, соңрак «Уклар» исемле сатирик журнал чыга башлый. 19 яшьлек Г. Тукай «Фикер» газетасы һәм башка басмалар типографиясендә хәреф җыючы, корректор, конторщик, фактик секретарь. 20 яшьлек Г. Тукай «Әлгасрел-җәдит» журналында җаваплы секретарь. «Уклар»ның фактгагы редакторы. Ул — әлеге басмаларның иң актив авторы. Һәр санда диярлек я шигырь, я публицистик әсәр, я тәрҗемә. Профессор М. Гайнуллин, Г. Тукайның аерым алганда «Уклар» журналындагы эшчәнлегенә кагылып, болай да: «Уклар»ны Тукайның сатирик әсәрләре җыентыгы дип санарга мөмкин, чөнки анда урнаштырылган материалларның күп өлеше шагыйрьнеке иде». («Татарская литература и публицистика». Тулыландырылган икенче басмасы. Казан, 1983, 55 б.)

Уральскидагы демократик татар матбугатын оештыруда башлап йөрүче К. Мотыйгый 1914 елда менә нәрсә ди: «...Габдулла Тукаев минем матбагамда иң әүвәл наборщик булып кергән дәрәҗәсеннән мөсаххиклык дәрәҗәсенә менеп, соңрак бик тизлек илә шул матбагада басыла торган «Фикер», «Әлгасрел-җәдит» вә «Уклар» исемле газет вә журналларның иң мөктәдир (көчле) шагыйре вә мөхәррире дәрәҗәләренә ирешеп, бөтен эшне үз кулына алырга якынлашты». (Мәшһүр шагыйрь Габдулла Тукаев турында хатирәләрем. «Тукай турында замандашлары». Казан, 1960, 66 б.) К. Мотыйгыйның үз-үзен яратучан булуын һәм үз хезмәтен киметеп күрсәтергә юл куймавын исәпкә алсак, аның бу раславы күп нәрсә турында сөйли.

Иң әһәмиятлесе шунда, Г. Тукай, Уральскида татар телендә матбугат органнары оештыруда һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итүдә бер җитәкче вазифаларын башкарып, аларның идея-политик юнәлешен сугышчан демократик рухта алып баруда хәлиткеч роль уйнаган. Бер үк вакытта башка шәһәрләрдә чыккан татар газета-журналларында автор буларак катнашып, алар эшчәнлегенә дә демократик рух өргән.

Казанга килгәч тә, Г. Тукай журналистлык эшенә муеннан чума. Ул үз рухына якын булган «Әльислах» газетасында Ф. Әмирхан белән бергә җитәкчелек вазифасын башкара, аны революцион-демократик рухлы орган итүгә күп көч сала. «Ул үзен мәзкүр (бу) газетның һәйәте тәхририясеннән (редколлегия) саный, үзенең шигырьләрен вә төрле имзалар белән язылган мәкаләләрен «Әльислах»ка җибәргәли тора иде»,— дип искә ала Ф. Әмирхан. Габдулла Кариевка язган хатында Г. Тукай: «Үзем теләп «Әльислах»ка хезмәт итәм»,— ди.

1908 елда ул Г. Камал белән «Яшен» исемендә сатирик журнал чыгаруга керешә. Мондый журналны нигезләү идеясен Г. Тукай бирә, Г. Камал әлеге журналны «аның димләве буенча» чыгара башлавын таный. Г. Тукай үзе дә бер хатында «Яшен»нең секретаре мин булганга, анда бик күп язарга туры килә. Шул сәбәпле төрле-төрле мөстәгар исемнәр (псевдонимнар) астына яшеренәм»,— ди. «Яшен» ябылгач, аның урынына чыгарыла башлаган «Ялт-йолт» журналы сугышчан демократик традицияне дәвам иттерә. Нәшир һәм редактор булып Ә. Урманчиев исәпләнсә дә, журнал эшенә җаваплы секретарь Г. Тукай һәм Г. Камаллар юнәлеш биреп тора. Шул ук истәлегендә Г. Камал: «Ул «Ялт-йолт» журналында бер ялгызы эшли, мин тик ташка төшерү өчен карикатуралар гына эшләп бирәдер идем»,— ди. Г. Тукайның таланты, тырышлыгы, осталыгы, оештыру сәләте аркасында бу журнал үз чорының иң яхшы сатирик басмасына әверелә. Әдип үлгәч, «Ялт-йолт» редакциясе аның журналга нигез салучы икәнен, беренче номерыннан башлап үзенең вафаты көненә кадәр шунда хезмәт итеп килгәнен басым ясап күрсәтә һәм Тукайның сатирага сәләте, мәкаләләренең кыйммәте укучылар тарафыннан тәкъдир

ителергә тиешлеген искәртә. «Яшен» һәм «Ялт-йолт» журналларының вакытлы матбугатыбыз тарихындагы әһәмиятен Г. Халит бик дөрес билгеләгән: «... Ул журналлар аша Тукай реакциянең иң караңгы елларында татар ирекле матбугатының традицияләрен дәвам иттерде, татар телендәге көлке журналының нигезен салды, һәм аның юмор, сатирасы үзәгендә заманасының әһәмиятле иҗтимагый-политик мәсьәләләренә демократик кыю караш һич тә сүнмәде. (Тукай үткән юл. Казан, 1962, 79 б.)

«Аң» журналының дөнья күрүендә дә Г. Тукайның турыдан-туры катнашы булган. Исемен дә ул тапкан. Әдип вафаты уңае белән урнаштырылган некрологта аның журналга нигез салучы һәм даими редакторларының берсе булганлыгы әйтелә. Әлеге журнал милли культураны һәм әдәбиятны үстерүгә сизелерлек өлеш керткән.

Г. Тукай балигъ булганнан башлап соңгы сәгатьләренә хәтле матбугат белән бәйләнештә торган. Ул кая гына барып чыкмасын, иң элек теге яки бу редакциягә юл тота торган булган. Менә ул Уральскидан Казанга килеп төшә, һәм беренче эш итеп газета редакцияләренә визит ясый. Тукай Астраханьда. Ул анда да редакцияләрне читләтеп үтми. «Әстерханда чакта Тукай редакциягә (сүз «Идел» газетасы редакциясе хакында бара: — Ф. Ә.) көн дә диярлек килә иде»,— дип искә ала анда хәреф җыючы булып эшләгән хезмәткәр (Утабалиев Габдерәхим. Тукай «Идел» газетасы редакциясендә. «Тукай турында замандашлары», 148 б.).

Тукай Петербургта. Хәле шәптән үк булмауга карамастан, ул «Нур» газетасы редакциясенең очрашуга чакыруын кабул итә... Әдип төрле телләрдәге газета-журналларны даими күзәтеп бара.

Ул татардагы барлык матбугат органнары белән таныш булган. Аның публицистик һәм шигъри иҗатында теге яки бу уңай белән телгә алынмаган бер генә татар газетасы һәм журналы да юк. Шулай ук рус матбугаты органнары да булган аның укып бара торган газета-журналлары арасында.

Шунысы әһәмиятле, ул аларның һәркайсы адресына эчтәлекләренә, авторлар составына, теге яки бу иҗтимагый проблемага мөнәсәбәтләренә карап үзенең катгый фикерен матбугатта кистереп әйтә барган, ягъни, хәзерге терминны куллансак, матбугат күзәтүчесе булган. Һәм ул шушы хезмәте белән нәширләргә дә, авторларга да, укучыларга да зур йогынты ясаган.

Кыскасы, Г. Тукай гомере буе матбугат казанында кайный һәм ул казанны кайнатучыларның иң активларыннан һәм авторитетлыларыннан берсе була.

Шагыйрьнең журналистик эшчәнлеге хакында сүз алып барганда аның әлеге иҗат тибына карашларын игътибардан читтә калдырырга тиеш түгелбез. Журналистиканың иҗтимагый тормыштагы тоткан урыны, аның төрле сфераларына йогынтысы, милләтне рухи яктан үстерүдәге вазифәсы, принциплары, эш алымнары, журналистикага куела торган таләпләр, реакцион матбугатның асылы хакында Г. Тукайның турыдан-туры да, читләтеп тә әйткән кыйммәтле фикерләре революцион-демократик журналистика фәнен үстерүгә бер өлеш булып тора. Төрле юнәлешләрдәге һәм төрле телләрдәге матбугат органнарының эшчәнлегенә Г. Тукай биргән бәяләмәләр, искәрмәләр, фикерләр күпмилләтле журналистика тарихын өйрәнүдә абруйлы чыганак була алалар.

Г. Тукай XIX гасыр мәгърифәтчеләре йогынтысындагы иҗат чорында матбугатның төп вазифасын аң-белем таратуда, милләтне агартуда, аңа әхлак тәрбиясе бирүдә күрә. Бу фикерләр татар дөньясында пәйда булган беренче газета-журналларга карата язган әсәрләрендә аеруча калку чагыла. Петербургта «Нур» газетасы чыга башлагач, Г. Тукай аңа, зур өметләр баглап, махсус шигырь багышлый, анда гомумән газетага карата үзенең карашларын бәян итә. Аның фикеренчә, газета милләткә байлык, бәхет алып килә, ул милләт авыруына шифа булырга мөмкин. Газета — «тиңдәшсез нәрсә», «якты көн», «зур куанычь». Ул, искелекне, кирелекне, ишанлыкны җиңеп, бар халыкны бер юлдан тырышып атларга ярдәм итә. Газетаның файдасы бу дөньяда кат-кат сыналган, ул кешечә яшәргә булыша.

«Фикер» газетасы чыга башлауга багышлап язылган шигырьдә дә матбугат күкләргә чөеп мактала. «Фикер» йөзендә газета — милләткә төрле уй уйларга ирек бирүче, читлекләрне ватып иркен сулыш алырга ярдәм итүче. Г. Тукай үзенең матбугатка карашларын теләк формасында бәян итә. Аерым алганда, «Фикер» халыкны таркатучы җилләрне истермәсен, истереп милләтнең берләшү юлларын кистермәсен.

«Әлгасрел-җәдит»кә багышланган шигырендә Г. Тукай журналга да мәдхия җырлый. Журнал — ул гыйлем чыганагы, фикерләр хәзинәсе, үзара якынаю, дуслашу, каршылыктан, дау-ызгыштан саклану чарасы. Журнал — милләткә мая, зур байлык; ул һәркемгә ана телендә төшендерә, һәртөрле кирәк нәрсәләрне тәкъдим итә.

Газета-журнал нәширләре һәм мөхәррирләре, әлбәттә инде, Г. Тукай мактавына лаек. «Мөхәрриргә» исемле шигырендә ул К. Мотыйгыйны реакцион газета-журналларның һөҗүменнән яклый, аны юата: наданнар гына сиңа дошман, гыйлем ияләре бары да сиңа дус, ди. Дүрт газета-журнал иясе булуың белән бәхетле син, чөнки сиңа дүрт яктан мәгърифәт елгасы ага, ди.

Г. Тукай газетада хәреф җыючыларны да онытмый. Хәреф җыючылар — бар гомерләрен милләткә бирүчеләр, наданлыктан коткаручылар, һәрвакыт милләткә хезмәт итүчеләр.

Шагыйрьнең үз идеалларын тормышка ашыруда матбугатка гаять зур өмет баглавы, бер яктан, чыннан да, аның культураны үстерү һәм таратудагы вазифасын дөрес аңлавыннан килсә, икенчедән, әлбәттә инде, аның иҗтимагый-политик карашларының әле XIX гасыр татар мәгърифәтчелеге йогынтысында булуы, конституцион иллюзияләре белән бәйле. Аның фикеренчә, социаль прогрессның төп юлы, алга киткән милләтләрне куып җитү чарасы — аң-белемне үстерү, аң-белем тарату. Милләтне йокыдан уятып, тәрәккый иттерүнең нәтиҗәле юлы — «әдәбият гөл-сулары» белән беррәттән, «газета мәрвәхәләре (веерлары) илә йомшак җил истерү».

Демократик матбугат — мәгърифәт чыганагы, аны таратучы, дигән фикер Тукайның матбугат хакындагы концепциясенең нигез ташы. Чыннан да, матбугатсыз культура тәҗрибәсен җәмгыять членнарына җиткерү, аларга әхлак тәрбиясе бирүне күз алдына китерүе кыен. Шуңа күрә Г. Тукай матбугатның җәмгыятьтәге, шәхес язмышындагы ролен арттырып җибәрә. Дөресрәге, мәгърифәт һәм культура таратучы чара буларак матбугат эшенең иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең характерына бәйлелеген күз уңыннан ычкындырып җибәрә.

Соңрак, революцион демократизм позицияләренә күчкәч, ул матбугатка тиешле бәясен бирә. Ягъни матбугат-мәгърифәт һәм культура тарату чарасы дигән концепция сыйнфый җирлеккә куелу белән, төрле газета-журналларның мәгълүм сыйныфларга хезмәт итүен аңлау белән матбугатның халыкчанлыгына һәм гуманизмына нигез булып ята. Ә милләтне алга җибәрү дигәннән, мәгърифәт тарату дигәннән, Г. Тукайның халык массаларының мәнфәгатьләрен игътибар үзәгендә тотуына бернинди шик юк. Әмма Тукай — мәгърифәтче карашынча, матбугат гомумән халыкка, гомумән милләткә хезмәт итә ала һәм итәргә тиеш. Дөрес, ул милләтнең капма-каршы сыйныфларга бүленгәнлеген яхшы күрә, әмма байларны акылга китерү, аларны, әхлакларын төзәтеп, халыкка хезмәт иттерергә мөмкин дип саный.

Г. Тукай башта матбугат органнарының сыйнфый характерда булуына төшенеп бетә алмый. Ул һәркемгә үз ана телендә төшендерә торган һәр матбугат органының дөньяга килүен шатланып каршылый, һәркайсының беренче санында урнаштырылган программасына ышана, аны мактый, якларга чакыра. Хәтта «Тәрҗеман»ны «төзәтү» өметендә яна: аңа милләтнең авыруын әйтүче булуын тели. Аныңча, «Нур» да агарту эшеннән беркайчан тукталмасын.

Әмма патша хөкүмәте һәм буржуазиянең кылган гамәлләре, аларның мәнфәгатьләрен гәүдәләндерүче матбугат органнарының кара эшләре, революцион хәрәкәтнең кискенләшүе Г. Тукайның күзен тиз ача. Феодаль-клерикаль һәм буржуаз матбугат органнарының («Бәянел-хак», «Дин вә мәгыйшәт», «Тәрҗеман», «Өлфәт» h. б.) төп мәсләген, тоткан юлын, кем җырын җырлавын чамалап алу белән Г. Тукай үз талантының бөтен куәтенә әлеге органнарның җитәкчеләренә һәм авторларына ташлана. Һәм ул нәкъ менә идеологик һәм политик көрәштә матбугатка бик зур урын туры килүенә үз тәҗрибәсендә конкрет мисалларда ышана. Хосусан алганда, Г. Тукай матбугатның көченә иң элек Уральскидагы демократик органнар үткәрә торган идеяләргә каршы чыккан «Бәянел-хак»лар һәм карагруһ рухлы Ә. Сәйдәшевләр белән каләм чәкәштерүдә сыный. «Дөрест телеграм хәбәрләре», «Ялкаулык, яхуд җиңел кәсеп», «Алай-болай», «Хакны белем инкяр кыйлу», «Гаҗаиб», «Мосаләхә» һәм башка әсәрләрендә ул кадимче әһелләрнең һөҗүмнәрен кире кайтарып кына калмый, ә аларның чын йөзен, сыйнфый асылын фаш итә. Г. Тукай канәгатьләнү белән болай ди: «Зәһәрне зәһәр җиңәр өмиде илә сезгә (Сәйдәшләргә — Ф. Ә.) вә исламыбыз ачуы им атылдык. Шулкадәр атылдык ки, кыяматкәчә һичкемнең иманына тимәскә кат-кат тәүбә итәрсез. Инде сезгә бу мәкаләнең яшен шикелле тәэсир иткәнлеге беленде, чөнки үзен кыйный башлагач: «Әнигә әйтәм, әтигә әйтәм!» — дип кычкыра торган урам баласы төсле, окружныйга бирәм, макружныйга бирәм, дип лыкылдарга керештеңез». Шушындый конкрет мисаллардан, башка басмалар тәҗрибәсеннән чыгып, Г. Тукай гомумән матбугатның үткен идеологик һәм политик көрәш коралы булуын нигезли. Ул хәзер инде матбугатның вазифасын мәгърифәт тарату, халыкның аң-белем дәрәҗәсен күтәрү белән генә чикләми, ә аны «кеше иреген һәм бәхетен буып торучы иске тәртипләргә, шул заманның политик строена каршы көрәш коралы итеп карый». (Нуруллин И. Тукай иҗаты. Казан, 1964, 78 б.) Матбугатның бу сыйфатын Г. Тукай сатирик журналларга багышланган әсәрләрендә аеруча ассызыклый.

«Уклар» журналында мөхбир уланлара тәнбиһ» (хәбәрче, язучы булганнарга кисәтү) исемле шигырендә ул, бер яктан, юк-барга атып, укларны исраф итмәскә чакыра, икенче яктан, фәрман бирә: «кирәк җиргә атканда патроннарны не жалеть!» «Кирәк

жир» диганнән авторның кемнәрне күздә тотканлыгы ачык аңлашыла. Хикмәт шунда, Петербург генерал-губернаторы, революцияне канга батыру өчен, гаскәрләргә һәм полициягә «Холостых патронов не давать и патронов не жалеть!» дип приказ бирә. Палачның үз сүзләрен кулланып, Г. Тукай патроннарны кемгә сибәргә кирәклеккә турыдан-туры ишарә ясый.

«Тавыш хакында» исемле әсәрендә исә, әлеге газетаның хуҗалары: басма эшчеләр авазы булачак, дип игълан иткәнгә ышанып, эшче газетасының кемгә һәм ничек хезмәт итәргә тиешлеген бәян кыла. Анычча, газета һәркемгә, һәрнәрсәгә фәкать эшче карашыннан бәя бирергә, эшче хакын даулар өчен кузгалырга тиеш. Г. Тукай үзенең шигырен эшче туганнарны тартышка чакыру белән тәгәлли.

Шул рәвешле, Г. Тукай алдынгы матбугатның, аң-белем таратып һәм изүче сыйныфларга, аларның идеологларына каршы рәхимсез сугыш ачып кына, кешелексез җәмгыятьне фаш итеп кенә халыкка хезмәт күрсәтә алуын раслый. Әгәр матбугат халыкчан булсын дисең икән, ул аның мәнфәгатьләре белән яшәргә, К. Маркс сүзләре белән әйтсәк, «өметләрен һәм хафаларын, мәхәббәтен һәм нәфрәтен, шатлыкларын һәм кайгыларын гадел бүлешергә» (Маркс К., Энгельс Ф. Әсәрләр (рус телендә), 1 т. 166 б.) тиеш. Г. Тукай әсәрләрендә дә шуңа охшаш фикерләрне очратабыз. Матбугатның аерым кешеләр мәнфәгатенә карап түгел, ә иҗтимагый мәнфәгатьләрдән, димәк, халык мәнфәгатьләреннән чыгып эш итәргә тиешлегенә басым ясап, Г. Тукай: «Һичкемнең хәтерен саклама, милләтнең дәртенә кара»,— дип яза. «Фикер» газетасын укучыларга исә: «Сезнең уйлар — безнең уй, безнең уйлар — сезнең уй»,— дип мөрәҗәгать итә. Бу фикер революцион-демократ чагындагы Маркснык: «Матбугат халыкның көндәлек уй-хисләренең көчле яңгырашы булып тора һәм шулай булырга тиеш тә»,— диган нәтиҗәсенә аваздаш (шунда ук).

Димәк, искелеккә, наданлыкка, шуларны тудырган шартларга, шуларны яклаган көчләргә каршы, социаль һәм политик изүгә каршы көрәш, халык мәнфәгатьләрен алга куеп эш итү матбугатның халыкчанлыгын билгели. Г. Тукайның төп мәсьәләләрнең берсендә — халыкчанлык мәсьәләсендә — революцион позициядә торуы нәкъ менә матбугатның җәмгыятьтәге ролен халык азатлыгы, халык мәнфәгатьләре өчен көрәш белән бәйләп каравында бик ачык чагылды.

Әлбәттә, ул халыкчанлыкның башка якларын да яхшы белгән. Әйтик, матбугатның теле халыкчан булырга тиешлеген кат-кат дәгъва иткән.

Әдип-публицист менә шушы төп таләпләргә җавап биргән газета-журналларны хуплаган, пропагандалаган, ярсып яклаган. Бер сүз белән генә әйткәндә, халык мәнфәгатен үз күргән бер генә матбугат органы да аның хәер-фатихасыннан читтә калмаган. Мәсәлән, ул, Р. Нәфиков раслаганча, «Урал» газетасын укып барган һәм аерым әсәрләрне аннан «Фикер» газетасында күчереп бастырган. (Карагыз: Нафигов Р. И. Формирование и развитие передовой татарской общественно-политической мысли. Казань, 1964, 301 б.) Әдипнең тормыш юлын өйрәнүчеләр аның ленинчыл «Новая жизнь» газетасын күзәтеп барганлыгын әйтәләр. (Карагыз: Төхвәтуллин Х. Чыныгу.— Социалистик Татарстан, 1976, 3 май.) Алдарак бәян ителгәннәрдән күренгәнчә, Г. Тукай демократик рухтагы башка матбугат органнарына карата да дустанә мөнәсәбәттә булган, алар турындагы уңай фикерләрен халыкка җиткерә барган.

Ә инде журналист шәхесенә килгәндә, аның өчен иң дәрәҗәле, иң сада кеше революционер-журналист Хөсәен Ямашев булган. Аның якты истәлегенә багышланган атаклы мәдхиядә халык мәнфәгатен чын кайгыртучы шәхес сыйфатларын калкытып куйган.

Ләкин Г. Тукай демократик мәсләктән читкә тайпылган, максат-идеология мәсьәләләрендә ялгышып киткән союздаш журналистларны, элекке зур хезмәтләренә дә карамастан, каты тәнкыйтьли. Әйтик, «Бәянел-хак» газетасына эшкә күчкән С. Рәмиевка, «Азат халык» газетасын буржуаз «Йолдыз»га кушып, шунда эшкә күчкән Г. Камалга да аңардан нык эләгә.

Г. Тукай иҗатында реакцион матбугатка һәм аның вәкилләренә бирелгән сыйфатламалар аның журналистикага карашларының состав өлеше буларак бик кыйммәт безгә. Ул изүче сыйныфларның мәнфәгатьләрен яклау хакына реакцион журналистиканың халык белән, аның уй-теләкләре, ихтыяҗлары белән һичничек исәпләшмәвенә, принципсызлыгына игътибар итә. Эксплуататорлык җәмгыяте шартларында халыкка каршы булган матбугат органнарының материаль яктан да, политик яктан да, идеологик яктан да байлар белән аерылгысыз элемтәдә торуларын, баш-аяклары белән аларга бәйле булуларын яхшы аңлый. Ул феодаль-капиталистик мөнәсәбәтләр хөкем сөргән җәмгыятьтә һәр нәрсәнең, шул җөмләдән халыкка каршы матбугатның һәм реакцион тип журналистларның сатлык һәм алдакчы булуларын күз уңында тота, аларны конкрет эш-гамәлләре мисалында утлы табага бастыра. Бу җәһәттән бигрәк тә урта гасырчылыкны, кадимчелекне, феодаль тәртипләрне, наданлыкны, кара динчелекне ярсып яклаучы «Бәянел-хак»ка һәм аның редакторлары Ә. һәм М. Сәйдәшевларга, авторларына бик каты эләгә.

Г. Тукайның публицистик эшчәнлеге һәм демократик органнарның бердәм линиясе аркасында Ә. Сәйдәшевлар һәм аларның газетасы «Бәянел-хак»ның халык алдында дәрәҗәсе төшә, йогынтысы кими.

Реакцион матбугатның һәм аның эшлекләләренең сатлык булуларын, акча дигәндә берни белән дә исәпләшмәүләрен, бөтенесен, хәтта динне дә сатып җибәрергә әзер торуларын фаш иткәндә, Г. Тукай аларны изүче сыйныфлар белән бәйләп карый, матбугатны байлар кубызына биетә торган төп чараларның берсе — реклама, татарча әйтсәк, игъланнар иконен күздә тотып эш итә. Мәгълүм булганча, игъланнар изүче сыйныфлар матбугаты керемененң төп өлешен тәшкил итә. Шуңа күрә дә изүче сыйныф вәкилләре, игъланнарын үз мәнфәгатьләренә хезмәт итүче матбугат органнарына биреп, аларның хуҗаларын экономик һәм политик бәйлелектә тоталар, ягъни үз арбаларына утыртып, үз җырларын җырлаталар. Г. Тукай менә шушы политиканы, асылына төшенеп, конкрет матбугат органнары мисалында бик оста фаш итә. «Бәянел-хак» газетасының «дин, дин» дип авыз суы корытуы, Г. Тукай язганча, аның «Аркадия» бакчасы фәхешханәләренең, сыра заводларының игъланнарын басуына һәм табыш алуына бер дә комачау итми. Миллионер улы В. Хөсәенов чыгарган «Дин вә мәгыйшәт» исемле дини-клерикаль журнал да шул ук юллар белән эш итә. Г. Тукай әлеге журналның игълан эшенә «Өч баш» исемле атаклы фельетонын багышлый.

Г. Тукайның халыкка каршы журналистикага карашлары зыялы саналган матбугат органы «Тәрҗеман»га һәм аның редакторы И. Гаспринскийга мөнәсәбәтендә аеруча ачык чагыла. Мәгълүм ки, башка матбугат органнары булмаганда «Тәрҗеман» кирәк булган, дип саный Тукай. Һәм хөррият җилләре исә башлагач, аның юнәлеше үзгәрер дип өмет итә ул. Ләкин күп тә үтми, аның «Тәрҗеман»га карата күңеле суына. Чөнки газетаның, аның редакторы И. Гаспринскийның мәсләге бөтенләй башка, халыкча түгел, ул изүче сыйныф мәнфәгатьләре, хосусый мәнфәгатьләр белән уралып беткән. Ник дисәң, газетаның редакторы И. Гаспринскийның «торуы капитал өчен», язуы капитал өчен, миллилек сатуы капитал өчен, «Мөселман иттифакы» ни эшкә ярамаса да, мактавы капитал өчен, нәфес заты мөхәррирлеге дә капитал өчен...

Г. Тукай башка телләрдәге реакцион матбаганы да тәнкыйть утына тоткан. Ул, мәсәлән, русның алдынгы матбугатын һәм культурасын нык хөрмәт иткәне хәлдә, реакцион матбугаты барлыгын һәм аның халыкка каршы эш йөрткәнлеген яхшы аңлаган. «Новое время», «Телеграф» кебек газеталарның милли дошманлык политикасы үткәрүләрен фаш иткән.

Реакцион журналистикага һәм аның вәкилләренә Г. Тукай биргән бәяләмәләр бүген дә әһәмиятләрен югалтмаганнар. Узган чордагы матбугат принципларының сыйнфый йөзен ачыклау җәһәтеннән генә түгел, билгеле. Ә бүгенге капиталистик һәм феодаль мөнәсәбәтләр системасы хакимлек иткән илләрдәге вакытлы матбугатның асылын, халыкка, прогресска каршы юнәлгәнлеген, изүче сыйныфлар җырын җырлавын, капиталга табынуын, икейөзлелеген, сатлык һәм алдакчы булуын фаш итү өчен. Хәзерге дини-клерикаль һәм буржуаз матбугат органнары (радио һәм телевидениене дә өстәп) нәкъ Г. Тукай фаш иткән алымнар белән эш итәләр.

Күренә ки, Г. Тукайның иҗтимагый-политик эшчәнлек мәйданы булган журналистикага карашлары күпьяклы. Ул үзенең практик эшчәнлегендә әнә шул карашларына һәрчак турылыклы булды, чөнки алар шул чор матбугатындагы төп тенденцияләрне, андагы көрәшне күзәтү, шул көрәштә җиң сызганып катнашу җирлегендә формалашканнар иде.

**Флорид ӘГЪЗӘМОВ,**
Казан дәүләт университетының журналистика
кафедрасы мөдире, тарих фәннәре кандидаты.

**Рәис ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ.**



**И. Г. Зәйнуллин,**
КПССның Буа райкомы беренче секретаре.

# БУА РАЙОНЫ

1785 елда Санкт-Петербургта басылган «Сембер урынчылыгының топографик язмалары» дигән китапта Буа турында мондый юллар бар:

«Озынлыкка 450, киңлеккә 360, әйләнәсе 1 500 сажень. Тавык тырнакларыдай өч юнәлештә утырган Дубовка, Юрясы, Скочиха бистәләреннән тора. Сембердән 77, Санкт-Петербургтан Мәскәү һәм Сембер аша 1578 чакрым.

Хөкүмәт сенаты доклады буенча, 1780 елның 22 декабрь көнендә, императрица Екатерина II указы белән өяз шәһәре дигән титул бирелгән бу авыл 1191 елда барлыкка килгән.

Шәһәрдән өч чакрым көньяккарак, Зөя белән Сура елгалары арасында тирән чокырлы нығытма ясалган булган. Ике калкулык күренә. Аларны «Тын» һәм «Кичү» манаралары дип йөртәләр. Күпьяшәрләр бу нығытманы Казан ханлыгын саклау өчен салынган дип ышандыралар. Шунда ук селитра өчен җир чыгарылган. Дары заводлары да булган.

Шәһәрдә ясаклы крестьяннар яши. Ирләр 647, хатын-кызлар 728 җан. Һөнәрчеләр тире иләү, күн ясау, итек тегү белән шөгыльләнәләр. Тимерчелар, балта осталары да бар».

Буа, шәһәр булып, 100 ел үткәч тә без тирән үзгәрешләрне әле күрә алмыйбыз. Бу чорда халык саны бары тик ике тапкырга арта. Бер классы чиркәү мәктәбен ачу өчен генә дә 112 ел кирәк була. Анда ир балалар гына укый. Алары да югары катлауныкылар. Шул елларда кызлар өчен ачылган училищега шактый күп акча түләргә кирәк була.

1914 елда чыгарган «Сембер губернасының йорт башы переписе» дигән җыентыкта да кызыклы һәм гыйбрәтле белешмәләр китерелә. Ул вакытта Буа өязенә хәзерге Чувашия АССРдагы Шыгырдан тимер юл станциясеннән башлап Олы Тарханга кадәр һәм хәзерге Ульяновск өлкәсенең бер өлешен биләүче 19 волость кергән. Аларда 284 авыл һәм поселок, 40 хутор исәпләнгән. 236 648 кеше яшәгән.

Шул ук перепись материалларында язылганча, 42 506 крестьян хуҗалыгыннан 42 процентының бары тик берәр дисәтинә (1,09 гектар) җире булган. Ә 0,12 процент кына тәшкил итүче югары катлау хуҗалыклар 1 700 дисәтинә җир биләгән. Атсыз хуҗалыклар өяздәге барлык йортларның 41,5 процентын тәшкил иткәнлеген дә искә алсак, Буа ягы крестьяннарының революциягә кадәрге хәлен аңлау кыен булмастыр. Шуңа алар, гаиләләренең тамагын туйдыру өчен, эш эзләп, Донбасс шахталарына, Себердәге алтын приискаларына барып җиткәннәр. Иске Суыксуда, мәсәлән, борынгы шахтер семьялары авылның яртысын тәшкил итә. Күп волостьларга һөнәренә карап исем бирелгән. Тимбай волостен — тегүчеләр, Мөчәли — чыпта сугучылар, Шамкино — дегет кайнатучылар, Иске Суыксу — күмер чабучылар, Тарханныкыларны көтүчеләр дип йөрткәннәр. Буаның үзендә исә күмәч белән клиндер пешереп көн иткәннәр.

Бөек Октябрь социалистик революциясе җиңгәннән соң Буа өязенә дә яңа тормыш килә. Еракларда йөреп, эшчеләр сыйныфы йогынтысында, актан караны аерырга өйрәнгән халык коммунистлар җитәкчелегендә, өяздә Совет власте урнаштыра.

Ул каһарманнарны буалылар бүген дә онытмыйлар. Шәһәрнең үзәк урамнарыннан берсе РКП(б)ның өяз комитеты беренче председателе И. С. Космовский исемен йөртә. Ул яшәгән йортка мемориаль такта куелган. Революцион массаны туплаучыларның һәм оештыручыларның фоторәсемнәре КПСС райкомы бинасындагы истәлек-күргәзмәдә тора.

Совет власте урнаштырылуның беренче көннәреннән үк өяз коммунистлары массаны туплау буенча зур эш җәелдерәләр. Халык йорты (хәзерге культура йорты тибында), музыка мәктәбе ачыла, беренче халык театры эшли башлый.

Авылларда революцион үзгәртеп корулар киң күләм ала. 1918 елда ук 60 потребительләр оешмасы төзелә. 15 мең кешене берләштергән кредит товариществосы оештырыла. Шулар базасында җирне бергәләп эшкәртү ширкәтләре үсеп чыга. Алпавытлар биләгән җирләрдә беренче коммуналар туа. 1918 елның 6 мартында Буа өязе крестьяннарына фронттан демобилизацияләнеп кайткан 2 600 ат бирелә.

РКП(б)ның өяз комитеты һәм эшче, крестьян, солдат депутатлары Советы крестьян хуҗалыкларын эш кораллары белән тәэмин итү юлын да табалар. Һөнәр училищесы мастерскойларында сука тимере, тырма тешләре, сугу машиналары өчен кирәк-яраклар чыгарыла.

Яңа тормыш шулай башлана. Крестьяннар коллектив хуҗалыклар төзиләр. Культура революциясе тормышка ашырыла. Мисалга районның бер Иске Суыксу авылын гына алыйк. 1929 елда биредә 16 гаиләдән күмәк хуҗалык оеша. Хәзер бу колхоз игенчелек һәм терлекчелек хуҗалыгы булып үсте. Ашлыкны ул беренче еллардагыга караганда гектардан 4,5 — 5 тапкыр күбрәк җыя. Терлек саны 50—60 тапкыр артыграк. Аң-белем үсешен 15 балалык мәдрәсәдән башлаган бу авылда урта мәктәп, культура йорты, балалар бакчасы, спорт залы, дистәләгән башка учреждениеләр эшли. Авыл халкына 7 кибет, кафе, кулинария цехы, көнкүреш йорты хезмәт күрсәтә. Аларда югары һәм махсус урта белемле һөнәр ияләре генә дә 50 дән артык. Һәр өч колхозчының икесе вузларда, техникумнарда, экономик белем, коммунистик хезмәт, алдынгы тәҗрибә мәктәпләрендә укыйлар. Колхоз байрагында Ленин ордены балкый. Хуҗалыкның 39 уңганы СССР орденнары һәм медальләре белән бүләкләнгән. Колхозны инде 30 еллап бер үк председатель Ленин ордены, Октябрь революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары кавалеры Нургали Сабирҗанович Сабирҗанов җитәкли.

Тагын бер тарихи факт. Авыл хуҗалыгын коллективлаштыру тәгәлләнгән чорда — 1933 елга аяк басканда районда 120 колхоз, совхоз, аларның һәрберсендә уртача 17 сыер, 5 дуңгыз һәм 34 баш сарык була. Авыл хуҗалыгында 13 агроном, 3 ветврач, 2 зоотехник эшли.

Хәзер районда терлекчелек шәһәрчекләре үсеп чыкты. Аларда механиклар, операторлар, югары дәрәҗәдәге оста терлекчеләр эшли. Сөт, ит җитештерү комплекслары төзелде. Кошчылык тулысынча индустриаль нигезләргә корылды. Бүген район хуҗалыкларында 36 меңләп мөгезле эре терлек, 42 меңнән артык дуңгыз, 28 меңнән артык сарык исәпләнә. Бу тармакта 47 зоотехник, 43 ветеринария белгече эшли. Алар 23 хуҗалыкка хезмәт күрсәтәләр.

Азык-төлек программасын үтәүгә үзләреннән лаеклы өлеш кертүче алдынгыларыбыз күп безнең. Тельман исемендәге колхоз сыер савучылары А. Мостякова һәм Л. Журавлева быел һәр сыердан 5000 литр сөт савып алу өчен көрәшәләр, «Ватан» колхозыннан Ф. Сабирҗанова, Ф. Хәбибуллина, «Рассвет» колхозыннан М. Мартынова дүрт мең литр чиген узып киттеләр. Кыят тәҗрибә-производство хуҗалыгыннан О. Железова, «Татарстан» колхозыннан Г. Юнысова, К. Хөснетдинова, «Мир» колхозыннан М. Хәкимова тәрбияләгән терлекләр тәүлегенә уртача 1023—1118 грамм артым бирәләр.

Игенчелек тармагына да яңадан-яңа үзгәрешләр керә. Җирне сугару, туфракны саклау, хезмәтне отышлы иттереп оештыруның яңа ысулларына таяну мөмкинлекләребезне арттыра.

Буа — республиканың бай ашлык районы һәм ул үзенең бу дәрәҗәсен сакларга тырыша. Район игенчеләре табигать көйсезлекләренә үз осталыкларын, фәнни ачышларны, уңай тәҗрибә казанышларын каршы куялар. Коры җәе, яңгырлы көзе белән үзәккә үткән 1984 елны да «Татарстан» колхозы, Кыят тәҗрибә-производство хуҗалыгы бөртеклеләрнең һәр гектарыннан 25—28 центнер ашлык алдылар.

Республикада беренче геройларны Буа җирләре тудырды. 1948 елны бөртекле ашлык җитештерүдә һәм аны югалтуларсыз җыеп алуда югары күрсәткечләргә ирешкән өчен Коминтерн исемендәге колхозның звено җитәкчесе А. Николаева, Буа МТСы директоры А. Ефремов, комбайнчы Г. Сторожев һәм трактор бригадасы бригадиры Г. Сафин Социалистик Хезмәт Герое дигән исемгә лаек булдылар. Бу югары исем 1966 елда «Память Ленина» колхозы председателе Р. Әһлиуллинга, 1973 елда «Гигант» колхозы председателе Н. Кадыйровка бирелде.

Элекке Буа шәһәренең гербына яшел болын һәм алтын сарык сурәте төшерелгән булган. Бу өязнең киң болыннарын һәм халыкның сарык асравын искә алып ясалган. Буа төбәге озак еллар буена аграр район булып кала килде. Промышленность үсеше кырыгынчы елларда, район илнең бердәм тимер юл челтәренә тоташтырылганнан соң гына билгеле бер темп ала. Хәзер исә район предприятиеләре, суммар яктан исәпләгәндә, авыл хуҗалыгы җитештергән кадәр үк продукция чыгара.

Шикәр заводыбыз район промышленностеның флагманы булып тора. Ул елга 26 мең тонна шикәр комы, җиде мең тоннага якын чүпрә җитештерә. Әхмәт электромеханика заводының продукциясен кырыклап урында кәтеп алалар. Шәһәрдә көнкүреш техникасын һәм радиотелеаппаратуралар ремонтлау заводлары, мамык, тегү, туку фабрикалары бар. Буа электр челтәре үзәге, «Энергосбыт», сыеклатылган газ базасы республикабызның берничә районына хезмәт күрсәтәләр.

Бөек Ватан сугышы елларында безнең район хезмәтчәннәре һәм фронтта, һәм хезмәттә батырлыкның гүзәл үрнәкләрен күрсәттеләр. 3089 кеше Советлар Союзы орденнары һәм медальләре белән бүләкләнделәр.

Зур Фролово авылында туган генерал-полковник Петр Григорьевич Шафранов Советлар Союзы Герое исеменә лаек булды. Сугышның соңгы этабында ул 31 нче армия белән командалык итә. Аның сугышчан юлы Калининнан алып Прагагача. Буа шәһәренең бер урамына герой полководец исеме бирелде. Аның туган авылында мемориаль такта бар.

Районыбызның Шигали авылы егете Михаил Тихонович Гарнизов үзенең үлемсез батырлыгын Харьков юнәлешендә барган сугышларда күрсәтте. 19 яшьлек автоматчы фашист танклары белән тигезсез бәрелештә һәлак булды. Советлар Союзы Герое исеме аңа үлгәннән соң бирелде. Буа шәһәре урамнарының берсе шулай ук аның исеме белән аталды.

Әлших авылыннан Александр Карташов Александр Матросов батырлыгын кабатлады. Биредәге урта мәктәп укучылары аның истәлеген изге итеп саклыйлар.

Буалылар үзләренең атаклы якташлары: революциягә кадәрге татар әдәбиятының күренекле вәкиле, язучы Шакир Мөхәммәдов, прозаик һәм әдәбият галиме Гомәр Толымбайский, язучы Гомәр Гали, РСФСР һәм ТАССРның атказанган художнигы, Татарстанның Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Бакый Урманче, танылган драматург Шәриф Хөсәенов, ТАССРның атказанган культура работнигы язучы Барлас Камалов, М. Җәлил исемендәге премия лауреаты шагыйрь Ренат Харис, чуваш язучылары Владимир Ухли, Николай Дедушкин, Василий Краснов-Асли, Григорий Казеки-Краснов, Валентин Урдаш, Александр Калган белән хаклы рәвештә горурланалар. СССР Фәннәр Академиясе член-корреспонденты, психология фәннәре докторы, профессор Т. А. Власова, филология фәннәре докторы, Казан дәүләт университеты профессоры Вахит Хаков, медицина фәннәре докторы, профессор И. А. Салихов, медицина фәннәре докторы, профессор Н. В. Розовский кебек галимнәр дә — Буа якларыннан.

Татар культурасының байтак кына күренекле эшлеклеләре безнең якларда иҗат иткәннәр. Алар арасында шагыйрә һәм җәмәгать эшлеклесе Гыйффәт туташ (Заһидә Борнашева), драматург Фәтхи Борнаш, композиторлар Салих Сәйдәшев һәм Мансур Мозаффаров, концертмейстер Фәйзи Биккинин, театр рәссамы һәм драматург С. Кальметов бар. Утызынчы елларда татар сәнгатенең күренекле вәкилләре Камал I, Камал II, Бари Болгарский, Зөләйха Богданова тарафыннан Буада профессиональ татар театры оештырыла. Ә Салих Сәйдәшев музыка мәктәбенә нигез сала.

Революциягә кадәр Буада ике чиркәү, ике мәчет, ресторан һәм ун сыраханә булган. Ике китапханәдә нибары 1500 ләп китап исәпләнгән. Клублар бөтенләй юк.

Хәзер район эшчәннәре карамагында 34 культура йорты, 36 клуб, 46 ки-

тапханә, 60 тан артык кинокүрсәтү җайланмасы, культура паркы, стадионнар, музыка һәм сынлы сәнгать мәктәпләре бар.

Культура өлкәсендә озак еллар һәм яхшы эшләгәннәре өчен «Ләйсән» җыр һәм бию ансамбленең җитәкчесе Сәет Зәйнуллин, Түбән Наратбаш авыл культура йорты директоры Әлфия Камалетдинова, район культура йорты каршысындагы художество-бизәү мастерское җитәкчесе Мәсгуть Сәлахов «ТАССРның атказанган культура работнигы» исемнәренә лаек булдылар.

«Әйлән-бәйлән» балалар ансамбле җитәкчесе А. Гарифуллина — бу мактаулы исемне алу белән бергә Муса Җәлил премиясе лауреаты да булды.

Районда үзешчән халык сәнгате киң үсеш алды. Хәзер анда 13 меңнән артык кеше катнаша. Соңгы елларда культура-агарту чаралары төрләнә бара. «Беренче буразна», «Беренче көлтә», «Кызыл олау» бәйрәмнәре, терлекчеләрне җәйге лагерьларга озату, авыл хуҗалыгы алдынгылары слетлары, хезмәт даны кичәләре үткәрү гадәткә керә.

Шәһәрнең махсус уку йортлары Идел буе республикалары өчен урта белемле медицина работниклары һәм зооветеринария белгечләре әзерлиләр.

Буа ягы авыллары да күзгә күренеп матураялар. Һәркайда төзелеш, үзгәреш, үсеш. Район үзәгеннән сузылган олы юл, «Память Ленина» колхозы аша, «Рассвет»ка алып килә. Бу ике колхозның беренчесе дә төшеп калганнардан түгел. Аның урта мәктәбе, культура сарае, сәүдә комплексы, көнкүреш йорты өр-яңадан төзелгән. Авыл генераль план буенча үзгәртеп корыла. Йортлар күз явын алырлык итеп, милли бизәкләр белән матурлап салынган, өчәр-дүртәр бүлмәле. Колхозның терлекчелек шәһәрчегендә, машина-трактор паркларында кул хезмәтен җиңеләйтүче ярымавтомат линияләре, күптөрле механизмнар эшли. Игенчелектә исә механикалаштыру дәрәҗәсе 97 процентка җитә.

«Рассвет» колхозы биләмәләре исә тагын да аерымлырак. Алар бер типтагы, юлның ике ягына тезелеп киткән яңа йортлар белән башлана. Колхозчыларга льготалы шартларда сатып бирү өчен дүртәр бүлмәле бу йортларны бердәм проект белән төзүне колхоз үткән бишьеллыкта ук башлаган иде. Хәзер инде аларның саны кырыктан артык, гомуми мәйданы 2 500 квадрат метрга җитте. Авыл кешесенең психологиясен дә, теләкләрен дә, ихтыяҗларын да исәпкә алып проектлаштырылган бу йортларның каралтыкуралары да, җиләк-җимеш бакчалары да бар.

Авылны социаль үзгәртеп коруның генераль планында кечкенә авылларның ихтыяҗын канәгатьләндерү дә исәпкә алынган. Яңа йортлар хуҗалык үзәгеннән читтәге, инде тузып бара торган Протопопово авылына килеп кушылган һәм аны да бер үзәк эченә алган. Ике авыл тоташкан урында урта мәктәпнең күп катлы бинасы калкып чыкты.

Авылны үзгәртергә акча кайдан алына соң? Алар колхозның еллык кеременнән аерып куела. Димәк, үсеш турыдан-туры колхозчыларның хезмәтенә бәйләнгән. Колхоз планнарын уңышлы үти, хуҗалыкның рентабельлеге 30 процент тәшкил итә.

Районнардагы 22 колхозның 16 сында хәзер шәһәрдәгечә бөтен уңайлыклары булдырылган культура йортлары эшли. Тельман исемендәге колхозның культура йортын гына алыйк. Бирегә пианино, тынлы оркестр, тавыш көчәйтү җиһазлары, вокаль-инструменталь ансамбль өчен кирәкле музыка кораллары бар.

Авылны социаль үзгәртеп кору планнарын тормышка ашырганда без: «Бар яхшыны — балаларга!» дигән максатны алга куйдык. Һәр колхозның яслесе һәм балалар бакчасы бар. Ясле-бакчалар елдан-ел киңәйтелә, алар да яңадан-яңа уңайлыклар тудырыла.

«Ватан» колхозы идарәсе, партия оешмасы һәм авыл Советы үз авылларында район үзәгендәге музыка мәктәбенең филиалын ачуны сораганнар иде. Аларның үтенече канәгатьләндерелде. «Әйлән-бәйлән» ансамбле быел үзәк телевидение аша ике тапкыр чыгыш ясады. Хәзер авылларда музыка, художество һәм спорт мәктәпләренең дистәгә якын филиалы бар.

Болары әйбәт. Әмма башкарасы эшләр дә аз түгел. КПСС райкомы һәм халык депутатларының район Советы башкарма комитеты авылларны социаль үзгәртеп коруның комплекслы планын үтәү мәсьәләсен даими контрольдә тоталар. Чөнки кешеләребезнең торак һәм көнкүреш ихтыяҗларын, культура таләпләрен тулырак канәгатьләндерү илебез Азык-төлек программасының мөһим өлеше булып тора.

**Сәлам Алишев,**
тарих фәннәре кандидаты

# БАТЫРША БАТЫРЛЫГЫ

## ТАРИХИ ОЧЕРК

Шлиссельбург крепосте. 1762 ел. Гомерлеккә шул таш капчыкка ябылган, аяк-куллары богаулы тоткынны махсус каравылчылар саклый. Төн. Сакчы йокымсырый. Тоткынның очлы күзе камерага нигәдер китерелгән һәм онытылып калган балтага төшә. Балтаны ул богаулы кулларына ала һәм һөҗүмгә ташлана. Уңга-сулга кизәнеп төрмә сакчыларын яралый, ләкин аларның барысын да кырып бетерү мөмкинме соң?! Ялгыз тоткынның бу дәһшәтле адымын ничек аңлатырга?! Ни өчен аны крепостька япканнар? Кем ул?

Тарихта «Батырша восстаниесе» буларак мәгълүм хәрәкәтнең идеологы, җитәкчесе Абдулла Галиев ул. Восстание 1755 елда хәзерге Башкортстан җирендә була. Бу кадәресе билгеле, әмма Абдулла-Батыршаның ниндирәк кеше икәнлеген күпләр белми. Абдулла Карыш авылында (хәзерге БАССРның Балтач районы) 1715 елда татар крестьяны Гали семьясында туган. Үз авылында башлангыч белем алгач, аны вакытында шактый атаклы булган Тайсуган авылы (хәзерге ТАССРның Әлмәт районы) мәдрәсәсенә биргәннәр. Мәдрәсә тотучы имам һәм мөдәррис Абдрахман тирә-юньнең зур укымышлыларыннан саналган. Тарихчы Риза Фәхретдинов әйткәнчә, ул «матур, дөрес һәм игътибар белән» күп кенә китаплар да язган. Мәдрәсәсенә белемле, ачык фикер йөртүче укытучыларны җыйган. Казан һәм Оренбург губерналарыннан мәдрәсәгә шәкертләр күп килгәннәр.

Абдулла зирәк акыллы булып, бу мәдрәсәдә гарәп, фарсы телләрен һәм ул вакыт укытыла торган гыйлемлекләрнең барысын да яхшы үзләштергән. Аннан соң ул шундый ук зур даны таралган Ташкичү авылы (хәзерге ТАССРның Арча районы) мәдрәсәсенә килеп Абдессәлам Ураев ахуннан дәресләр алган. Егетнең мәдрәсәләрдә ничәшәр ел укуы төгәл билгеле түгел, ләкин соңгысында озаграк торган булса кирәк. Ике мәдрәсәдә аның барысы ун елдан артык гомере узган. Шулай итеп, Абдулла Галиев зирәк акыллы, зур белемле кешеләрдән санала башлаган. Кулга алынгач, патшага язган хатында мәдрәсә тәмамлаганнан соңгы тормышы турында ул: «Ел ярым микъдары Гәйнә илендә Илеш мулла авылында тордым гыйлемлекдә, вә дәхи Исет провинциясендә Мөслим старшина авылында тордым 4 ел микъдары гыйлемлекдә. Андин соң үз җиремә кайтып, Яныш командасында Карыш авылында тордым 6 ел кадәре. Бу яд кылынган авылларда имамлык кылып, мәдрәсә тотып, угланнар укытып...» — дип язган. 1755 елга кадәр унбер ел ярым укытып, имамлык итеп йөргәч, 1743 елга кадәр ун еллап, үзе гыйлем алгач, авылыннан ул 1733 елда киткән булып чыга. Гадәттә зур мәдрәсәләргә 17-18 яшьтә кабул ителгәннәр. Моннан түбәндәге нәтиҗәне ясарга мөмкин: аңа восстание башланыр алдыннан, П. И. Рычков әйткәнчә, «46 яшь чамасы» түгел, ә үз авылы старшинасы Яныш әйткәнчә, 40 яшь кенә булган. Туган елы да 1710 түгел, ә 1715 нче елга туры килә.

Абдулла мәдрәсәләрдә укыган 1733—1743 еллар халык өчен бик авыр дәвер, патша реакциясенең котырынган чоры булган. Моңа түзә алмаган татар-башкорт крестьяннары 1735 елда — Акай һәм Килмәк, 1740 елда Карасакал җитәкчелегендә восстание күтәраләр. Патша гаскәрләре бу восстаниеләрне коточкыч катылык белән бастыралар. Шул чор галиме П. И. Рычков болай язган: восстаниегә кушылган татар-башкорт авылларының 696 сы яндырылды, 16 893 кеше үтерелде һәм төрле җәзага тартылды, 9194 хатын-кыз һәм бала-чага алпавытларга коллыкка таратылды, 3236 кеше каторгага җибәрелде, 18 359 баш терлек, 9 828 сум 29 тиен акча штраф итеп алынды...

1735 елда җирләреннән качып киткән ясак түләүче татар крестьяннарын солдатка җибәрү, 1736 елда татарлар белән башкортлар арасындагы мөнәсәбәтләрне бозу, алар арасында була торган никахларны тыю, мишәр старшиналарга элеккеге башкорт җирләрен бирү, 1737 елда рус булмаган крестьяннарга икмәк налогын икеләтә арттыру турында һ. б. төрле указлар чыгарыла. Шул ук вакытта дини-милли изү дә көчәя. Поплар,

архиерейлар, православие диненең төрле «изге аталары», рус булмаган авылларга солдат командалары белән чыгып, кешеләрне көчләп чукындыра башлыйлар. Чукынырга теләмәгәннәрне төрлечә җәзалыйлар. Христиан диненә күчкәннәргә кызыксындыру чаралары табалар: әйтик, гаепле кеше, христиан диненә күчеп, гадел хөкемнән котыла алган. Мөселманның хуҗалыгы, үзе үлгәч, шул диндәге балаларына түгел, чукынган булсалар, ерак кардәшләренә бирелергә тиеш дип тә закон чыгарылган. Шундый чаралар нәтиҗәсендә элек мәҗүси булган мордва, мари, чуваш, удмуртларның төп массасы православие диненә күчеп беткән. Бер 1741 елда гына да 9159 кеше (шулар арасыннан 143 татар һәм башкорт) чукындырылган. Ә 1750 еллар уртасына Казан губернасында аларның саны 269 213 кешегә җиткән. Боларның 3670е татарлар булып, аларны яңа керәшеннәр дип йөртә башлаганнар. Үз динендә 100 меңләп татар ире калган. Православие динен кабул итмәүчеләргә ачулары чыккан фанатик поплар тагын да көчлерәк чаралар тапканнар. Яңа керәшеннәрне 3 ел буе салымнардан коткарып торганнар. Алар өлешен (рекрутка алынуны да кертеп) өч ел буена үз динендә калучылар түләргә тиеш булган. Православиене кабул итүчеләр ун меңәрләп арта торган. Алар өчен налог түләү срогы да озая барган. Батырша бу турыда болай яза: «Вә дәхи ул ислам диненнән чыкарылганнарның ясакларыны вә һәм үзгә хезмәтләрене калган мөселманнарның өстенә салдылар. Ул мөселманнарны, үзләренең диннәрендә торган өчен, анларны хур күреп, элек-электән өсләренә тиеш булмаган йөкләрне йөкләделәр, анларның дин вә дөньяларына тарлык вә авырлыклар етешсен дип. Бәгъзе старшиналар биниһая залимлыклар илә халаекларның малын җыеп вә исерткечләр эчеп вә адәмиләрне кылыч берлә чабып, кулларыны кисеп — моңа охшашлы хәдсез җәфалар кыйлдылар». Бу хәл халыкны бөлгенлеккә төшереп, аларны бик нык ярсыткан. Шул чорда яшәгән Батыршаның уй-фикерләре дә халык күңеле белән бер юнәлештә үскән. 1742 елның 19 ноябрендә мәчетләрне бетерергә, яңаларны салмаска, дип закон чыгарылган. Казан губернасында 536 мәчеттән 418 мәчетне җимереп ташлаганнар. Алар белән бергә мәктәп-мәдрәсәләр дә җимерелгән. Мәдрәсә белеме алган Батыршага бу хәлләр бик нык тәэсир иткәннәр, әлбәттә. Авылда берничә генә кеше православие диненә күчсә дә анда чиркәү салырга, үз динендә калучыларны саф татар авылларына күчереп утыртырга боерык чыгарылган. Дини изү халыкны мыскыл итүгә, гомум изүгә тоташкан.

1748 елда Казан губернасындагы крестьяннар моңа каршы хәрәкәт итә башлыйлар, ләкин алар тиз бастырыла.

В. И. Ленин, дини эзәрлекләү һәм кимсетүләр диннең үзен, дини фанатизмны көчәйтергә мөмкин һәм көчәйтә, дип күрсәтте. Бу хакыйкать Батырша язмышында да чагылыш таба. Абдулла Галиев халыкка чыгарган Өндәмәсендә социаль-экономик һәм политик изелү турында сөйләп, шуңардан азат булу өчен көрәшкә чакыра. Халыкның дини һәм башка яктан изелүен аңлатып, ул барлык «кяферләргә» каршы, мөселман динен яклап сөйли. Бу — әлбәттә, югарыда күрсәтелгән хәлләр йогынтысында, шуңа җавап төсендә туган фикернең яңгырашы. Идеологиясендә халыкларны дини күзлектән чыгып кына аеру сизелсә дә, без Батыршаны клерикаль карашлы гына кеше дип бәяли алмыйбыз. Чөнки Батырша, көрәш максаты итеп, халык массалары мәнфәгатенә туры китереп, социаль-экономик таләпләр дә куя. Үз ихтыяҗларын гына алга сөргәннәре өчен, шул ук мөселман динендә булган түрәләргә, старшиналарга каршы да көрәшкә өнди. Колонизацияләү процессының әшәке якларын ачып күрсәтә һәм җирле администрацияне юк итәргә чакыра. Болары — Батырша җитәкләргә җыенган көрәшнең политик максаты лабаса!

Батырша дин өчен дә көрәшкә чакыра, дидек. Инде В. И. Ленинның, дини кабык астында политик протест чыгышы бер Россиягә генә хас түгел, бәлки үсешләренең билгеле стадиясендә барлык халыкларга хас булган күренеш ул, дигән күрсәтмәсен искә төшерик. Батыршаның да барлык чакырулары нигезендә азатлыкка өндәү ята. Шунлыктан без аның фикерләве прогрессив юнәлештә, ә Батырша үзе — чорының алдынгы көрәшчесе булган, дип бәялибез. Батырша халык ихтыяҗларын тирәннән аңлаган, үзенең практик эшчәнлеген шуларга туры китереп билгеләгән. Авылларда да ул мөгаллимлек итеп кенә яшәмәгән. Казан, Уфа, Оренбург, Троицк якларында йөреп, күпләр белән аралашкан, халыкның кайгысын күргән. Тирән белемен, үткен фикерен искә алып, Батыршаны галим дип атаганнар. Ул батыр йөрәкле, физик яктан да көчле, бәхәсләрдә дә, көрәшләрдә дә җиңелми торган кеше булган. Шуңа аны Батыр шаһ дип тә йөрткәннәр. Батырша исеме шуннан калган.

Батыршаның укымышлылыгы аның патшага язган хатыннан да, халыкка тараткан Өндәмәсеннән дә, башка тарихи язмаларда да күренә. Батыршаның 1756 елда төрмәдән патшага язган хатын Гайсә Хөсәенов 1979 елда «Башкорт әдәбиятының текстологиясе мәсьәләләре» китабында Уфада бастырган иде. Аңа кадәр «Агыйдел» журналында да бу хат турында хәбәр булды. Без аларның Мәскәүдәге дәүләт үзәк борынгы актлар архивындагы төп нөсхәләрен дә карап чыктык. Хатларда гаять тирән фикерләр бар. «Китапларда язылганча һәм күрсәтелгәнчә,— дип яза Батырша,— безнең бабаларыбыз болгарлар бер диндә булып бердәм иделәр һәм потларга табынучыларны үз җәмгыятьләренә динне өйрәтү юлы белән генә кертә иделәр...» Аның хаты татарча җиңел тел белән язылган. Бер мисал китерик: «Мондагы түрәләр кирәк залим, кирәк гадел улсыннар, аларның хөкеме бозылмыйдыр. Угрыны тугры дисәләр, тугры буладыр, тугрыны угры дисәләр, угры буладыр... Түрәләре андин акчалар алдылар. Байларның малы төкәнде, ярлылар бурычлы улдылар. Көндә бетәр эшне айга суздылар, айда бетәр эшне

елга суздылар». Бу хәт тарихи чыганак кына булмыйча, татар әдәбияты тарихында да өйрәнелә. Ул авторның телгә бай каләм остасы икәнлеген дә күрсәтә.

Батырша царизмның яшерен колониаль политикасын дөрес аңлау дәрәҗәсенә җиткән. Әле Оренбург губернаторы, атаклы колонизатор И. И. Неплюев казахлар һәм башкортларны бер-берсенә каршы котыртып, суеш-кырылыш чыгарганчыга кадәр үк, Батырша халык массаларын кисәтеп куярга өлгерә.

Дөрес, аның һәр фикере диярлек дингә барып тоташа. Сүз һәрвакыт дини татулык һәм туганлык турында бара, әмма тел төбеннән социаль гаделсезлеккә каршы ачу бәркелеп тора. Батырша татар-башкорт старшиналарын шәфкатьсезлектә гаепли, халык массаларын изеп яшәгәнлекләрен ача һәм җирле автономия таләп итә. Батырша һәм аның фикердәшләре урындагы властьларның котырынып халыкны талаганын патша белми, белсә, бу хәлләргә чик куяр иде, дип уйлаганнар. Төрле чиновниклар гаделсезлекләрне патшадан яшерәләр, аңа җиткермиләр, дип фикер йөрткәннәр. Восстаниегә кадәр дә һәм аннан соң да Батыршаның иң зур теләге халыкның җәбер-золым астында яшәвен, гадел булмаган чиновниклар, старшиналар бозыклыгын патшага җиткерү булган. Ул, кулга алынгач та, үз уйларымны бары тик патшага гына сөйләячәкмен, дип игълан итә. Петербургта да аны патшага кертмиләр. Шуннан соң ул, сорау алучыларны, патшага тапшырырбыз дип, ант иттереп, үзенең атаклы хатын язган. Бу факт та Батырша һәм аның көрәштәшләренең «ак патшадан» ваз кичмәүләрен, ә бары урыннарда халыкның үз автономиясен булдырырга тырышуларын күрсәтә. Бу — колониаль-милли изү политикасы тудырган милли-азатлык хәрәкәтендәге бер юнәлеш. Мондый юнәлешнең аерым формалары XIX йөздә дә дәвам итә.

Батыршадан соң, мәсәлән, әле 1760 елларда ук мулла Морат кабат милли азатлык өндәмәсе белән чыккан. Аның төп омтылышы «Болгарны торгызу вакыты җитә» дигән тезис булган. Аны кулга алып, кайбер иярченнәре белән Петербургка озатканнар, ләкин тиздән азат иткәннәр. Әгәр Болгарны торгызу тезисы Рус дәүләтенә каршы куелган булса һәм аерылырга теләүне аңлатса, аларны һич тә азат итмәсләр иде.

Без, Батырша җитәкчелегендәге хәрәкәт, объектив рәвештә караганда, автономия таләп итүгә кайтып кала, дидек. Ләкин, әлбәттә, ул вакыттагы кешеләр автономия турында аңлы фикер йөртмәгәннәр. Хәзерге «автономия» терминын без ул чор таләпләренең объектив эчтәлеген күрсәтү өчен генә кулланабыз. Тагын шунысы игътибарга лаек: Батырша юлыннан барган мулла Моратның иптәшләре, мәсәлән, аның белән Петербургтан әйләнеп кайткан Аит Уразматов, Пугачев җитәкчелегендәге крестьяннарның бөек сугышында актив көрәшчеләр булып киткәннәр. Пугачевка кушылган татар-башкортлар һәм аларның әйдәп баручылары Пугачевны үзләренең патшасы дип тә, рус патшасы Петр III дип тә таныганнар. Чөнки Пугачев аларга киң рәвештә җирле автономия хокуклары вәгъдә иткән.

Тагын шунысы бар: Батырша хәрәкәте чорында халык төрле чиновникларны, власть кешеләрен, солдаттан башлап түрәләргәчә, «руслар» дип атап йөрткән. Шунлыктан Батыршаның администрациягә каршы сөйләгәндә, «рус» сүзе кулланыуы да халыкта кабул ителгән төшенчә буларак аңлатылырга тиеш. Аның мәгълүм хатындагы төп фикер дә гомум халык теләгенә тәңгәл килә: «Йорт-җирләрне туздырдылар һәм таладылар,— дип яза ул,— кыз һәм ир балаларны алып хезмәтче ясадылар, күбесен саттылар, бүләк итеп өләштеләр... Халаекларга җәфалар күргәзделәр, кыйнамак, сукмак, алым алмак берлә, малларны угырламак берлә вә һәм кешеләрне үлтермәк берлә...»

Шуның кебек күп золымнарны тасвирлагач, Батырша түбәндәге таләпләрне куя: Җирле халыкны бөлдермәскә һәм алар канын агызмаска, йорт-җирләрен таламаска, үзләрен хезмәтче итеп әсирлеккә алмаска, залимнарның чабаталы хезмәтенә йөрмәскә, аларга шәһәрләр салмаска, авылдан-авылга, шәһәрдән-шәһәргә олаулар белән озатып йөрмәскә, ясак һәм фураж бирмәскә, җиребездә крепостьлар һәм шәһәрләр салдырмаска, үзебезгә кул күтәрергә ирек бирмәскә... Динебезне мәсхәрәләүгә юл куймаска... алар тарафыннан билгеләнгән явыз татар-башкорт старшиналарын арабыздан юк итәргә һ.б.

•

Восстаниене хәзерләү һәм башлау вакытын Батырша шактый дөрес сайлаган. 1750 еллар — патша дәүләтенең көнчыгыш чикләрдә үз колониаль властен ныгыту чоры. Хәзерге Башкортстан территориясендә заводлар салу, крестьяннарның җирләрен киметүгә китергән. Чик буе крепостьлары, ныгытылган хәрби линия төзү, казах гаскәрләрен оешыру халыкны шулай ук бик күп җирләреннән мәхрүм иткән. 1754 елда патша хөкүмәте дәүләт кибетләреннән тоз сатып алу турында указ чыгарган. Моңа кадәр башкортлар һәм татарлар тозны үзләре, Батырша әйтүенчә, «алла биргән күлләрдән һәм таулардан» түләмичә ала торган булалар.

Батырша төрле якларда ныклы элемтәләр урнаштырган. Гадел хөкем итүе, туры сүзле һәм бәйсез, ачык күңелле булуы аны тиз арада билгеле кеше иткән. Зур авторитетка ия булганлыктан, 1754 елда хөкүмәт аны Себер юлының ахуны итәргә тели. Ул вакытта Уфа провинциясе 4 административ өлешкә бүленеп йөртелгән. Алар юл дип аталган: Себер юлы, Ногай юлы, Казан юлы, Оса юлы. Юллар эчендәге кечерәк бүленешләр волость дип йөртелгән. Алар башында старшиналар торган. Батыршаның ахунлыгы турында указ да чыга, ләкин Батырша моңа риза булмый. Беренчедән, башка сатлык җаннар рәтенә басып, халык җилкәсенә утырудан курка, икенчедән, бу вакытта ул восстание хәзерләү уе белән янып йөри башлаган була.

Халыкның беренче дулкынлануы 1754 елның көзенә, тоз сатып алу турында указ чыккан вакытка туры килә. Уфага килгән морза Котлымөхәммәт Тәвкилев, төрле ялган вәгъдәләр һәм турыдан-туры куркыту ысулы белән, массаларның тоныкына башланган хәрәкәтен кыш айларында ук туктатуга ирешә. Бу морза турында Батырша болай яза: «Котлымәт морзаны белдекемез заманыннан бирле һәр елда ничә мәртәбәләр аның ишетәбез: Ырынбур губернасы халаекларына падишаның күп мәрхәмәтләре вә күп рәхимле указлары бардыр дип... Ул ялганчы карт дуңгызның сүзенә инанып кай вакытта ыруза да кыйламыз... Хәл бу кем, бу көнгәчә өстемезгә бер катрә мәрхәмәт тамчысы таммыш юктыр». Хәзерләнеп килә торган восстаниедә төп көч булып Ногай юлындагы, бигрәк тә Бөрҗән һәм аңа якын волостьлардагы халыклар саналган. Восстаниене яклап чыгарга Оренбург янындагы Каргалы бистәсе әзерләнгән. Гәйнә волосте крестьяннары хәрәкәтнең икенче төп терәге булып торганнар.

Восстание Казан, Оса, Себер, Ногай юлларын чолгап алыр дип күздә тотылган. Алар күтәрелеп чыккач, аңар Казан губернасы һәм башкалар ярдәм итәр дип фараз кылынган. Әгәр Батыршаның бу планы тормышка ашса, патша хөкүмәтенә бик зур куркыныч янаган булыр иде.

Батырша шундый зур күтәрелешне планлаштырып кына калмый, восстание идеяләрен төрле җирдә агитацияләп тә йөри. Восстаниечеләр, казахлар белән элемтәгә кереп, корал алмашып, феодаль-колониаль стройга каршы чыгу турында сөйләшүләр алып барганнар. 1755 елның мартында Батырша, бөтен Урта Идел һәм Урал буе халыкларын восстаниегә чакырып, Өндәмә-Программа төзергә керешә. Бу документ ике ай буе язылган. Восстаниенең башлану көне 1755 елның 10 июленә билгеләнгән. Батырша восстание хәзерләү чараларын туктатмый. Яз айларында ул икенче мәртәбә Исет провинциясенә барып кайта, июль башында Ногай юлы волостьларында була. Ул китү белән үк монда восстание башлана. Бу хәлне Батырша эшчәнлеге нәтиҗәсе итеп аңларга мөмкин. Гәйнә волосте белән тагын да тыгызрак элемтә урнаштырыла. Батырша Гәйнәдә үзе җитәкчелек итәргә ниятли. Восстание башлангач, аның утын башка якларда, Кама буйларында, Казан тирәсендә дә дөрләтергә чамалый.

Ләкин бу план тормышка тулысынча үк ашып җитми. Восстание, әле Батырша әзерләп бетергәнче үк, стихияле рәвештә тиешле вакыттан элек башланып китә. 1754 елда Ирәндек буена, асыл ташлар эзләп табу өчен, тау тикшерү экспедициясе начальнигы Брагин дигән кеше җибәрелгән була. Ул үзенең иптәшләре белән Ногай юлы башкортларының җирләрен тартып ала, малларын талый, тарихи документлар раславынча, «аларның хатыннарын һәм кызларын ата-аналары һәм ирләре каршында көчли». Бөрҗән волосте башкортлары бу хәлгә түзеп тора алмыйча, 1755 елның 15 маенда Брагин экспедициясенә һөҗүм итәләр, үзен үтерәләр, якындагы Сапсаль почта станын (почта олаулары, атлар, ямщиклар тупланган пункт) тар-мар китерәләр. Бу хәл бөтен Исет трактын, ягъни Оренбургтан Исет провинциясенә бара торган юлны, эштән чыгара. Ләкин бу күтәрелеш, көтелмәгәндә башланганлыктан, үзен яклаучыларны тапмый. Кайбер старшиналар хәтта восстаниегә каршы да чыга. Бөрҗән волосте старшиналары исә, баш күтәрүчеләр казахларга китеп торырга һәм шулай итеп, патша гаскәрләренең җәза чараларыннан качарга тиеш, дип карар чыгаралар. Восстание тукталып торырга мәҗбүр була, ә патша гаскәрләренә көч тупларга мөмкинлек туа. 22 майда хәрби көчләр бөтен волость буенча ау оештыралар: качканнарның гаиләләре, туган-кардәшләре, хәтта старшиналар да, кулга алынып, крепостьларга ябыла.

Бөрҗән волостендагы халыкны канга батырып җәфалау восстаниене тиз арада әзерләп бетерүне зарури итә. Каргалы татарлары, Урал арты башкортлары, Оса юлында яшәүчеләр восстаниене яклап чыгарга теләкләрен белдерәләр. Батырша әйтүе буенча, июль аенда «500 мишәр һәм 1000 типтәр»нең отряды төзелеп, Оса һәм Себер юлында хәрәкәт итәргә хәзер тора. Гәйнә волосте шулай ук, восстаниегә әзербез, дип хәбәр иткән. Бу вакытка Батырша үзенең атаклы Өндәмәсен төрле якларга тараткан була. Авылларда аны укыйлар һәм хуплыйлар. Восстаниенең срогы 10 июльгә билгеләнгән булса да, май аенда ук аның кабынып китүе һәм сүндерелүе массаларның бердәм күтәрелешен тоткарлаган. Восстание яңадан 8-9 августта шул ук Бөрҗән волостенда кабынып китә. Восстаниечеләр отряды патша хөкүмәте куйган старшина Абдул Ваһапны һәм писарьларны үтереп, тирә-яктагы заводларга, почта станнарына һөҗүм ясый. Берничә көн эчендә Ногай юлының башка волостьлары да баш күтәрә. Байтак башкортлар, казах җирләренә күчеп, шуннан хөкүмәтнең терәк пунктларына һөҗүм оештыралар. Восстаниечеләрнең төп көчләре Агыйдел буенда Бөгелчән крепосте тирәсендә туплана. Заводлар яндырыла, крепостьларга һөҗүмнәр ясала, хөкүмәт гаскәрләренең кайберләре тар-мар ителә. Ләкин башка төбәкләр восстаниегә кушылмаганлыктан баш күтәргән башкортларның күбесе казах ягына күчеп китә.

Батырша август башында, Ногай юлындагы эшен тәгәлләп, яңадан Карыш авылына кайта. Ләкин Гәйнә волосте белән тиз генә элемтә урнаштыра алмый. Ул көньяк-көнчыгышта барган хәлләрнең нәтиҗәсе турында уйлана: Ногай юлы тулысынча восстаниегә кушылмады, Себер юлы да хәзергә тын тора, алда ничек булыр? 20 августта Батырша Гәйнә волостенә үзенең 4 кешесен җибәреп, восстаниегә сигнал бирә. 27-28 августта

гәйнәчеләр баш күтәреп, хөкүмәт агенты, халыкны җәберләп, үз файдасына ясак җыючы старшина Абдул Хуҗагол улын үтерәләр һәм авылларда отрядлар оештыра башлыйлар. Чурагол, Исхак, Акчура Ягутеев кебек актив көрәшчеләр халыкка восстаниенең бурычларын аңлатып йөриләр. Баш күтәргән отрядлар 1 сентябрьдә Оса һәм Кунгур юнәлешләрендә киң фронт белән һөҗүм башларга тиеш булалар. Ләкин монда да феодалларның бер өлеше восстаниегә хыянәт итә. Башкорт старшинасы Туктамыш Ишбулат улы, үз отряды белән һөҗүм итеп Кызыл Яр авылына җыелган восстаниечеләрнең бер өлешен таркатып ташлый. Бу хәл восстаниечеләр арасына шом сала һәм хәрәкәтнең киң җәелә алмавына, тәвәккәллекнең югалуына китерә. Алар монда үзара тарткалашып ятканда, дәүләт гаскәрләре тизлек белән Гәйнәгә җибәрелә. Документлар гәйнәчеләр икегә бүленделәр, алар арасында үтерешләр булды, ә тирә-якта яшәүчеләр, восстаниене якла給га әзер тордылар, дип сөйлиләр. Ләкин Гәйнә баш күтәрүчеләре ярдәм көч булып өлгерә алмаганнар, зур отрядлар аларга килеп кушылмаган. Алар, ярдәм сорап, Батыршага хат язганнар. 1-2 сентябрьләрдә гәйнәчеләрнең бер отряды Карыш авылына килеп чыга, ләкин ул инде шактый соңга калган була...

Батырша үзенең якын кешеләре һәм гаиләсе белән 1 сентябрьдә авылыннан чыгып китә. Аның авылдан китүенә дә шул ук таркаулык сәбәп була. Феодал старшиналар, төгәлрәк әйткәндә, Карыш авылы татар старшинасы Яныш восстаниегә каршы чыга, аңа җәелергә ирек бирми. Аларның Батыршаны хәтта авылда килеш тә тоткарлап торган булулары ихтимал. һәрхәлдә, Батырша восстаниенең үзәгенә керми кала. 1 сентябрьдә таң белән аның өе старшина Яныш җибәргән коралланган төркем белән камап алына. Ул үзе болай дип яза: «Таң атканда күрдем: йортым тирәсе, авылым тулы халык. Йөз илле микъдары кеше кораллар белән хәзер торалар. Хәвефкә төштем: бу кадәр халыкның эчендә миңа дошманлык итәр кешеләр дә бардыр дип. Мөмкин булмады ул тарлык хәлдә халаекларны өндәп, нәсихәтләп үз яныма алырга. Ахыр начар улып бер ходаема тәвәккәл итеп, җәмәгатем вә шәкертләрем илә алты садак, бер сөңге коралымызны алып, ул халыкның уртасыннан чыгып киттек. Алты чакрым урманга җиткәнчә сәламәтлек илә озаттылар. Без урманга кердек, алар кайтдылар. Белдем: ул халык арасында безгә дошманнар юк икәндер». Батыршага кул күтәрергә, старшина җибәрүгә карамастан, берәүнең дә батырчылыгы җитмәгән.

Батырша шул тирәдә качып йөрергә мәҗбүр ителә, ул хәтта гәйнәчеләргә дә барып ирешә алмый. Ә восстание, дөресрәге гәйнәчеләрнең чын восстаниегә әверелеп җитмәгән хәрәкәте, акрынлап сүнә, бетә бара. 20 сентябрьдә Оса юлына дәүләт гаскәрләре килеп керә. Гәйнә һәм башка волостьларда эзәрлекләүләр башлана, кулга алулар, төрмәләргә озатулар...

Гәйнә волостенда кузгалган бу күтәрелеш кыска вакытлы һәм оешмаган рәвештә булса да, ул патша властен куркуга сала. Моңа охшаш бәрелешләрнең Казан ягында, алпавыт утарлары шактый күп булган элекке Казан ханлыгы территориясендә дә башлану ихтималы аларның котларын алган. Куркынычны булдырмый калу өчен, ягъни татарларны восстаниедән читләштерү өчен, патша хөкүмәте сентябрь башында ук татарларның таләпләрен үтәргә керешә. 3-4 сентябрьләрдә ул ике указ чыгара. Беренчесе — йомышлы татарлар һәм морзаларның теләкләрен истә тотып, аларны Казан губерна канцеляриясе карамагыннан Казан адмиралтейство конторасы карамагына тапшыра. Адмиралтействога урман хәзерләгән өчен аларга хезмәт хакын тулысынча түләргә боерыла. Икенчесе — православие диненә чыкмаган татарларны керәшеннәр булган җирләрдән күчереп утырту вакытлыча һәр җирдә туктатыла. Шулай ук бу указда мөселманнарның дини эшләрен архиерей өендә түгел, ә губерна канцеляриясенең бер бүлегендә карарга кушыла.

27—28 сентябрьләрдә яңа указлар чыга. Беренче указда яңа керәшеннәр өчен салымнарны һәм рекрутларны, моңа кадәр булганча, үз динендәге татарлардан алмаска, диелә. Икенче указ нигездә йомышлы татарлар өчен чыгарылган. Анда: башкортлар ягындагы восстаниене бастыруга тартылган кешеләргә 2 айга алдан жалование түләргә, элек хөкүмәт гаскәрләрендә хезмәт итү вакытында законсыз алынган салымнарны кире кайтарып бирергә һәм 1755 елда җан башына төшкән салымны ясаклы татарлардан да түләтмәскә дип язылган. Шул ук ташламалар рәтенә татарларның үтә ачуын чыгарган Казан архиерее Лука Канашевичны башка җиргә күчерү карары да кертелгән. Восстаниенең идея җитәкчесе Батырша тотылгач, 1756 елда мәчетләр салуга рөхсәт указы да чыгарыла.

Шул ук вакытта хөкүмәт Казан губернасындагы хәрби көчләрне дә ныгыткан. Шундый политика нәтиҗәсендә, мондагы татарлар, 1748 елдагы кебек көрәшкә әзер торсалар да, Батырша восстаниесенә катнашмый калганнар. Патша хөкүмәте политикасы төрле халыклар арасында дошманлык уяту, аларны бер-берсенә каршы котырту чараларын

да оста куллана. Башкортлар белән татарлар арасын бозу өчен, моңа кадәр дә, Батырша җитәкчелегендәге хәрәкәт вакытында да күп төрле чаралар күрелгән. Бу политиканың иң фаҗигале нәтиҗәсе казахлар белән башкортларны дошманлаштыруда ачык чагыла. Оренбург губернаторы И. И. Неплюев, башкортларның беренче чыгышларыннан соң ук, казахларга үзенең агентларын җибәреп, аларны восстаниечеләргә каршы котырта башлый. Баштан ул, казахлар ягына күчеп чыккан башкортларны әсир хөкемендә тотарга, балаларын һәм хатыннарын бүлешергә дип, феодалларны кызыктыргыч тәкъдим ясый. Казах солтаннарына һәм ханнарына зур бүләкләр бирелә, алар белән сыйлы мәҗлесләр үткәрелә, мәҗлестәгеләргә бүләкләр өләшәләр. Нурали ханга 600 сумлык еллык жалованиe дә билгеләнә. Шулар бәрабәренә 10 меңнән артык восстаниечеләрне Россиягә кире кайтару аларның малларын, гаиләләрен казах феодаллары кулында калдыру турында сөйләшүләр бара. Нәтиҗәдә казахларның бер группасы башкортларны сыендырган икенче группага һөҗүм итә, башкорт качкыннарын талыйлар, үтерәләр, әсир итеп алалар. Хәтта казахның үз ыруглары арасында да канлы бәрелешләр була. Неплюев исә башкортларны да котырта, казахлардан «үч» алырга мөмкинлекләр тудыра. Башкортлар, Җаекны кичеп, казах авылларына һөҗүм иткәннәр, аларның малларын куып китә башлаганнар. Ике тугандаш халык тәмам дошманлашкан. Казахлар качкан башкортларны хөкүмәт кулына биргәннәр, ә хөкүмәт башка башкортларга Җаек аркылы чыгуны тыйган.

1756 ел восстаниечеләрне эзләп табу, кулга алу, аларның гаепләрен тикшерү белән узган. Үлем җәзасы бирү башта тыелган булган. Ләкин чынлыкта восстание вакытында да, төрмә-крепостьларда да бик күп кеше үтерелгән. 1757 елда эзәрлекләүләрне туктату турында указ чыгарылган, чөнки восстание инде бастырылган, куркыныч саналган кешеләр бетерелгән булган.

Восстаниенең җиңелү сәбәпләреннән түбәндәгеләрне күрсәтү кирәк: Батырша никадәр генә әйбәт итеп әзерләргә тырышмасын, восстание барыбер оешып җитмәгән һәм стихияле төс алган. Милли колониаль изүгә каршы юнәлдерелгән булса да, халыклар бердәм чыгыш ясамаганнар, халыклар арасында нык дуслык әле булмаган. Патша хөкүмәтенең политикасы моңа киртә корган. Җирле феодалларның бер өлеше үз халкына ук каршы чыгып, патша хөкүмәтен яклаган. Үз феодалларына да каршы көрәшкән халыкларда сыйнфый бердәмлек бөтенләй сизелмәгән, алар әле сыйнфый карашка ия дә булмаганнар. Восстаниене әзерләү буенча актив эшләсә дә, Батырша кыю һәм хәлиткеч тестә аны җитәкләмәгән. Көрәш юлбашчысыз калган.

Батырша восстаниесе, нинди генә кимчелекләре булса да, алдагы көрәшләргә юл яруы ягыннан, тарихи әһәмияткә ия. Ул Пугачев җитәкчелегендәге гаять мөһим хәрәкәтнең алшарты булып хезмәт иткән.

Инде Батыршаның үз язмышына тукталыйк. Авылы янындагы урманда бераз торгач, ул ераккарак китәргә мәҗбүр булган. Азыклары беткәч, ул хатыны Зөлхәбирәне, ике баласын иптәшләре карамагына калдырып, үзе Яхъя исемле шәкерте белән тагын да ары, Казан якларына юл тота. Үзе укыган тирәләрдә кыш чыгарга мөмкин булыр дип исәпли. Ләкин 1755 елда барлык җирләрдә тикшерүләр бара, Батыршаны һәм аның көрәштәшләрен махсус агентлар, хәрби командалар эзли. Хөкүмәт Батыршаны тотып, властьларга тапшырган кешегә 1755 елның октябрендә — 500, соңрак 1000 сум акча вәгъдә итә. Батырша белән Яхъя, без шәкертләр дип, авылдан-авылга йөреп хәер сорашалар. Иске дигән авылның мәчете астына баз казып, яшерен урын әзерлиләр, шунда кыш чыгалар. Яз җиткәндә, аларның кыяфәте куркыныч төс алган була: сакал-мыек баскан, ачлыктан-салкыннан бик өшәнгәннәр, киемнәре тузып, пычранып беткән. Алар тагын урманга качалар. Хәер сорашып, бераз рәткә кергәч, ярлыкавын сорап, патшага барырга, аңа халыкның ни хәлдә яшәвен сөйләп бирергә уйлыйлар. Шулай юлга җыенган көннәрнең берсендә алдан баручы Яхъяны ниндидер кешеләр уратып алалар һәм җитәкләп китәләр. Батырша үзе генә калгач, Сөләйман старшинага барып, аның белән Оренбург, Уфалар аша патша янына җитәргә чамалый. Хәзерге Башкортстанның Борай районы Әҗик авылына килә. Бик арыганлыктан, мәчет чормасына менеп, йоклап ала. Шул төнне авылдагы берәүнең умартасын басалар. Батыршаны күреп калган хатын, угры шул түгелме дип, мәчеткә күрсәтә. Мәчетне чолгап алалар. Халык тавышына Батырша уянып китә, сикереп төшеп, качарга омтыла. Ләкин тотыла. Бу хәл аның өннән чыгып китүенә бер ел тулар алдыннан, 1756 елның 8 августында була. Старшина Сөләйман Диваев Батыршаның кул-аякларына богау салып, конвой белән Уфага алып китә. Халык исә, син икәнне белмәдек, гөнаһ шомлыгы дип уфтанып кала. 12 августта, Неплюевның күрсәтмәсе буенча, Батыршаны бик тиз һәм яшерен рәвештә Уфадан Оренбургка илтергә тиеш булалар. Моның өчен иң ышанычлы бер капитан, бер обер-офицер, 60 драгун һәм 40 казактан торган конвой оештырыла. Батырша янында тәүлек буе ике сакчы торырга, тоткынны берәү белән дә сөйләштермәскә, кешеләрне аңа якын китермәскә, хәтта ашамлыкларны, үзенә берәр хәл эшләмәсен дип, тикшереп бирергә, халык бар җирдә туктатмаска тиеш

булалар. Власть вәкилләре юлга кемне алып чыкканлыкны халыкка сиздерүдән курыккаиннар. 26 августта Сенат үзенең карарын да чыгарып өлгергән: Батыршаны, бер кемгә белдермичә, Петербургка, яшерен эшләрне тикшерү канцеляриясенә озатырга!

Чорына күрә, чагыштырмача, гаҗәп тизлек белән Батырша турында Уфа, Оренбург, Петербург арасында хәбәрләшүләр бара. Аны саклау чаралары ук хөкүмәтнең аннан уттан курыккандай куркуы турында сөйли. Сенат карары буенча аны капитан һәм поручик җитәкчелегендәге 38 драгун командасы, 25 олаудан торган этап белән Самара — Арзамас — Муром — Владимир — Мәскәү юнәлешеннән Петербургка алып китә. Абдулла ялгызы бер кибиткада унтер-офицер, капрал һәм драгун сагы астында бара, аны яхшы ашаталар, киендерәләр. Батыршаның иң якын көрәштәшләре дә ныклап оештырылган сак белән, Петербургка хөкемгә озатыла. Алар арасында татарлардан ун кеше: Мәкъсуд Аксин, Урускул Исламов, Мирәхмәт Акъегетов, Ибрай Тимергазин, Мөслим Ибраһимов, Әхмәт Корюков, Мостафа Әсәнов, Акчура Ягутеев, Дәүләтбай Хуҗагулов, Исмәгыйль Алкин бар. Башкортлардан биш кеше: Исхак Мурзалиев, Кучукбай Имангулов, Нури Баскунов, Чурагол Минлибаев, Сәфәр Ягъфәров була.

Батыршаның язуынча, ул, юлда барган унике көн эчендә богауларын кисә һәм качарга омтылып карый. Мин патшага сак астында түгел, үз ихтыярым белән бармакчы идем, ди. Аны, әлбәттә, тоталар. Шул кадәр сакчыдан бер кеше ничек котылсын?! Ләкин бу турыда конвоирлар сөйләмиләр, рәсми документлар язмыйлар. Рәсми документлар күрсәтүенчә, Батырша юлда авырый һәм Мәскәүдә бераз тоткарлана. Монда беренче сорау алу була. Батырша, патшадан башка беркемгә берни сөйләмәячәкмен, ди. Ахыр чиктә патшага бирәбез дип, ант итеп, аңардан язма җаваплар алалар һәм Петербургка озаталар.

Петербургта да ул үзенең көрәшен дәвам иттерә. Православие руханиларын чакыртып, кайсы диннең өстенрәк булуы турында бәхәс кузгата. Хөкем әһелләре белән дә бәхәскә керә. Ниһаять, 1757 елның уртасында аны гомерлеккә Петербургтан ерак булмаган Шлиссельбург крепостена ябалар. Монда да ул үз омтылышларына тугры кала. Патша исеменә төрле вариантта табак-табак хатлар язып, ерак провинцияләрдәге халыкларның фаҗигале тормышын аңлата. Ни өчен көрәшкә күтәрелгәнлеген сөйләп, аларның хәлен җиңеләйтү чаралары турында фикерен уртаклашмакчы була. Биш ел үтә. Патшадан берниндн җавап та юк. Бу вакыт эчендә Батырша, бәлки, патшага карата моңарчы күңелендә йөрткән ышанычын, өметен дә җуя башлагандыр. Чөнки, хатына да шундыйрак юллар килеп керә: «Бу падишаһымыз заманында тәкать тотарлыкымыз калмады,.. залимлык — түрәләремездә, янаралларымыздадыр. Бәгъзесе әйтде: падишаһ гаделдер, вә ләкин үз куенныннан китмәгән, безгә килеп җитмәгән гаделлектән безгә ни файда?.. Әгәр хакыйкать падишаһлык тикшерүе илә тикшерелсә, күзе җитмәсме булыр иде?!»

Бу өзектән күренгәнчә, көрәшченең уйлары шикләнүләргә, гасабилануга таба юнәлгән. Һәм, ниһаять, ул түзми — таш капчыкта гомер буе тоткын булып, акрынлап үлгәнче, сугышып үләргә кирәк таба. Богауларын шалтыратып, балта күтәреп, патша сакчыларына ташлана. Дүрт сакчыны үтерә. Шул чак, үзе әле аяк өстендә чакта, Батыршаның йөрәге тибүдән туктый.

**Зиннур Мансуров**

# ЙӨРӘК БӘЙРӘМЕ

## ШАГЫЙРЬ РӘШИТ ӘХМӘТҖАНОВ ТУРЫНДА ЭТЮДЛАР

Туган көнемнән үк бәхет бирел,
Азат балам диеп атадың.
Авыр чакларыңда Кол Гали күк
Колың булыйм, газиз Ватаным.

Алма сортлау җайланмасына карап торам. Тегермән ташыдай әйләнмәле әрҗәгә эреле-ваклы бакча җимешләре коела. Энә төртер урын юк. «Спортлото» шарлары кайнаша шикелле. Җиде юл чатындагы алмаларны алда нинди язмыш көтә? Хәер... Биредә һәркайсы үз бәһасен үзе билгели. Югары сыйфатлы алма, әнә, беренче юлдан китеп бара. Җиз иләктән үтмәгәннәрен икенче юл бөтереп ала. «Өчле» билгесенә лаек булганнары да шактый....

Алмалар этешә-төртешә юл сайлаганда, ничектер, шагыйрьләр язмышы турында уйлана башладым. Югыйсә шигырь белән алма арасында уртаклык та күренми шикелле. Күзәтәм һәм уйланам. Үзенә күрә ОТК вазифасын да үтәүче җитез хәрәкәтле апа әледән-әле беренчеләр рәтенә ялгышып керүче «әрсез» алмаларны өченче конвейерга күчерә. Чынлыкта «Ньютон алмасы» була торып, үз бәһасен белмәүче «тыйнагы» да очраштыра. Гадел хөкемдар анысын да үз урынына куя. Уртачалар юлындагы тыгылуны да җайга салырга ашыга...

Барыннан да бигрәк менә «стандарт булмаган» алмалар төркеме уйландырды. Бөтенләй аерым урында торган шушы алмалар белән чын шагыйрьләр арасында нинди уртаклык күренә. Стандартсыз, димәк, үзенчәлекле. Талантларның үзьяшәешлелеген калыплашуга бирелмәү билгеләмиме? Мәгълүм хакыйкатьне кабатлап әйтик: сәнгать — шәхси тормыш тәҗрибәсе, дөньяны тулысынча индивидуаль рәвештә танып-белү нәтиҗәсе. Производствоны, әйтик, стандартлаштырып була, ә иҗатны...

Алмадан башланып киткән әлеге этюдларда мин, күпләрнең билгеләвенчә, стандартлыкка сыймаганлыгы күзгә бәрелеп торган шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов турындагы күзәтү-уйлануларым белән уртаклашырга телим. Мондый аерым төркемгә аны нинди сыйфатлар керткән? Шагыйрьнең сирәк очрый торган үзенчәлекләре нидән гыйбарәт? Бергәләп ачыклыйк.

* * *

Бишкә кадәр һәрбер бала падиша булыр... Борынгылар сүзен җөпләмичә булмый, әмма падиша булу һәркемгә дә тәтемәгән. Бигрәк тә кырык беренче елгыларга... «Без барлык газапның тәмен имдек ана сөтендә...» Газизанә баштан кичереп язылган әлеге сүзләр астына шагыйрьнең барлык яшьтәшләре кул куярга ризадыр.

Карт дөньяның иң яшь кисәге
Безнең маңгай үзе иде бит.
Сугышларга чапкан атларның
Тояклары аңа тиде бит.

Адәм баласы, гадәттә, өч яшьтә генә үзен-үзе ача башлый, ә аңарчы хәтта көзгедәге сурәтен дә юньләп танымый икән. Мәхшәр көнне сабыйларның чәче агарыр, дигәндәй,

сугыш өрәге белән күзгә-күз очрашу еларга өлгермәгән малайларны да ирсетә. Кешелек җәмгыяте үсешендәге мәгълүм бер баскычны сикереп үткән шикелле, кырык беренче елгыларның шактыена сабый чакны «әйләнебрәк» узарга туры килгәндер. Көтүгә беренче мәртәбә әндри әбәте илткәндә, Рәшит әле үзе дә төенчек чаклы гына булган. Борыныннан шаулап аккан канга (алабута күмәче гаепле) сәерсенүле күзләре белән исе-акылы китеп караганда, тәүге тапкыр әнә шулай «канын койган» чакта да ул әле кечек падиша яшеннән узмаган. «Гел хәтердә... Беркөн Ачытауның яшеннәрдә янды кылганы...» Авылга таба йөгерүче утлы кылганнар өстенә бөтен чандыр гәүдәсе белән егылуы һаман истә, чөнки балачак илендәге шушы «утлы амбразура»га барысын да аңлап-төшенеп ташланган. Гарасатлы сугыш кырыннан кайткан әлеге кылганнар шагыйрь тәнен хәзер дә өтеп-өтеп ала шикелле.

Ә җанымда — тоташ күкрәүләр...

Хәтер чаңы уяу. Күңелдәге балачак хатирәләре һәрдаим яңарып торалар, чөнки алар сөт белән генә түгел, кан-яшь белән дә язылган. «Сугыш елы» хроникасы күз алдыннан үтә. Гадәти бер т ө ш в а к ы т ы үзен-үзе бик иртә белештерә башлаган сабый хәтеренә бүгенге тормыш рәхәтлекләре дә юып ала алмаслык тирәнлектә уелган.

Әнкәй кайта кояш баткач кына,
Төнлә генә туктый кырда эш.
Кояш, гүя, ач энемне җәлләп,
Төш вакытында баерга тиеш.

Сугыш елы баласы и к м ә к к ә, шагыйрь булып танылгач, дөньяда беркемне дә кабатламыйча, үзенчә билгеләмә бирә. Бугазда яшен ташы булып торучы хатирә:

Тышта буран. Инсаф бабай үлә...
Мин тын гына аны озатам.
Соңгы сүзе:
— Мин ипигә барам,
Сез көтегез, балам, тиз кайтам...

«Өлкәннәрнең барысы да башта бала булганнар. (Әмма моны һәркем дә хәтердә тотмый)». Гомер буе үзен балачак илчесе итеп санаган Антуан де Сент-Экзюпери хаклыдыр, әмма сугыш чорына туры килгән балачак беркайчан да онытылмый. «Мин балачагымнан килгән көтүче егет булам...» Әгәр үзенең авыр балачагына кайтырга теләмәсә, Рәшит Әхмәтҗанов шагыйрь була алыр идеме? Шигырьләрнең барысын да безгә, гомумән, балачак әйтеп яздыра шикелле. Иҗатыбыз гомер башында яралган күңел катламнарын актарудан гыйбарәт түгелме? «Сабыйлар күк елмаерга көчем булырга тиеш»,— дип, дөньяга һаман да балаларча беркатлылык белән карыйбыз, балачакта барлыкка килгән рухи плацдармга таянып торабыз.

Балачагыңда җылыткан кояш
Җылыта икән гомер буена.
. . . . . . . . . . . . . . .
Барлык картайганнар
Үз яшьлеген
Сагынудан үлә, күрәсең...

Әдип үзенең әсәрен «биография» атлы каләм белән яза. Аксиомага әверелгән әлеге хакыйкатьне без теләсә кайчан кабатларга яратабыз. Халыкныкын кушып, биографиябезне зурайтабыз. Барысы да дөрес. Инкарь итеп булмый. Әмма... Тәрҗемәи хәлнең балигъ булганнан соңгы чоры турында күбрәк сөйлибез. Кайчандыр бала булганлыгыбыз онытыла. Биография балачактан башлана. Талант үзәгендәге субъектив натура да... «Мин үземнең балачагымны «яралы балачак» дип әйтер идем...» Әгәренки үсмер чоры сугыш елларына туры килгән прозаик Вакыйф Нуруллин гомум әдәби геройлар галереясына керүче гыйбрәтле язмышлар тудыра алган икән, ул «ниләр күргәнне, ниләр кичергәнне сөйләп кенә бетерә алмаслык» гомер башлангычына, йөрәген сызланулы итеп калдырган «яралы балачак»ка шактый дәрәҗәдә бурычлы. Әдипнең сүзне гомер юлына керүдән башлавы урынлы. Шулай да соңыннан «Балачакның яраланмавын телим», дип әйтеп куюы белән килешәсе килми. Балачак гыйбрәтле булсын, берүк идиллик булмасын. Күпме «какканны вә сукканны» күтәргән бөек Ятим дә үзенең сабый вакытын күз яше белән сагынып искә төшергән, зуп-зур Тукайның кечкенә Апуш чагын «ачы-тәмле хыял» итеп күргән.

Җәмгыятькә файдалылык һәм шулай ук җитештерүчәнлек ягыннан караганда, әйе, кул арасына керергә өлгермәгән балачак тау-тау матди байлыклар тудырмый. Әмма балачак илендә тупланган рухи хәзинә бөтен гомергә җитә!

Бишкә кадәр һәрбер бала падиша булыр, дигән борынгылар, ә ир уртасы Рәшит Әхмәтҗанов үзенең балачагын «шикәр биреп» сөендерергә тели. Иркәләнү һәм назга коену, тамак туклыгы һәм өс бөтенлеге җәһәтеннән падиша булмаса да, сугыш елларында чыныккан гыйбрәтле балачак киләчәктә шагыйрь иҗатын баетырлык кыйммәтле рухи байлыкларны куплап җитештерергә өлгергән.

Күзендә яшь, күңелендә моңнар —
Балачагың синнән карап тора...

* * *

Кандыз елгасы. Җиденчеме тапкыр коенып чыккан Рәшит зәңгәрсу какча гәүдәсен кояшта кыздыра. Рәхәт!.. Кинәт комлыкны сары кырмыска күче сырып алды. Эреләр! Кармакны җимләп, балык каптырырлык. Күченүләреме?! Комлыкта кара болыт күләгәсе шуыша шикелле... Көтү башы аларны кая алып бара?..

Иртәгесен көтүгә әбәт илтер алдыннан Рәшит таллыкта үзе генә белгән кош оясын карап килергә ниятләде. Борынлап кына чыккан бәгырькәйләре үзләрен ничек хис итәләр?.. Үрелеп караса! Йөрәге жу итте — оя тулы кырмыска. Кошчыкларны ашап бетерә язганнар!..

Кичелмәгән шушы вакыйга аны тәмам әсәрләндерде. Гомерендә беренче тапкыр ул үзен битарафлыкта гаепләде, чөнки яманлык кылучыларның юлына аркылы чыга алмады. Шушы тойгы күңел катламнары астыннан әле хәзер дә саркып чыга. Төзәлмәс яра каны шикелле...

Этиканың төп категорияләреннән саналучы яхшылык һәм яманлыкның шагыйрь иҗатындагы яшәеше гыйбрәтле әкияти вакыйга буларак күңелдә уелып калган шушы фаҗигадән башланмыймы? Яхшылык һәм яманлык... Әлеге төшенчәләрнең диалектик концепциясе Рәшит Әхмәтҗанов әсәрләрендә шактый ачык төсмерләнә, һәм, гомумән, шәхестәге көрәшчәнлек сыйфатлары нәкъ менә шушы җирлектән баш тертә.

Бәхетләрдән
Дөньягызны онытмагыз.
Изгелекнең
Дошманы бар — бигрәк явыз!

«Йөрәк авырулы» шагыйрь, гомумән, битараф була алмый. Шигърият беркайчан да нейтраль дәүләт шикелле яшәмәгән, һәм ул борынгы заманнарда ук Данте авызыннан әйттереп искәрткән: җәһәннәмдә дә иң кызу урыннар, имеш, бөек мораль сынаулар вакытында битарафлык күрсәткәннәргә билгеләнгән. Шигърият каршылыклы, фаҗигале һәм бөек гасырда яшәүче Рәшит Әхмәтҗановтан да гамьсезлекнең көрәшчене үтерүен халык алдында инде ничәнче тапкыр кабатлата. Эчтәлек сораучы таләпчән укытучы төсле, шагыйрьне «үз сүзләре» белән сөйләттерә.

Изгелекнең дошманы белән көрәшү мотивы, шагыйрьнең поэтик предметы буларак, бөтен иҗаты аша калку рәвештә үткәрелә. Көрәш мәйданын ул үзенчә сайлый. Гыйсъянчыдай чәчрәп чыкмый — шагыйрьләрнең «эчке янулы»сы. «Көрәш булмаган җирдә әдәбиятның кирәге юк»лыгын тирәнтен аңлаган хәлдә, кешелекнең алга барышына ярдәм итүче кешелеклелек өчен рухи алышны үзәккәрәк чыгара.

Дөньяның караңгы ягына
Барыбер төшкәндер бер нурым.
Хәтта мин агулы еланга
Эндәштем: саумы, дип, матурым...

Әлеге юлларда шагыйрьнең яшәү-көрәшү принцибы ачыла. Шагыйрәнә гражданлык кодексы борынгылар этикасы таләпләрен сызып ташламый — яхшылыкка яхшылык һәр кешенең эшедер, яманлыкка яхшылык ир кешенең эшедер. Яманлыкка — яхшылык... Мондый мөнәсәбәт яманлыкка карата килешмәүчән булырга чакырган этика таләпләренә туры киләме? Яманлыкка яхшылык белән суктыру көрәш тактикасы гына түгелме? Таш атканга аш ату... Барысы да халык этикасыннан. Агулы еланга да, матурым, дип эндәшүче шагыйрь менә шундый көрәш алымын сайлый. Шунысы гаять әһәмиятле: әлеге сыйфат аңа ана сөте белән кергән, ягъни тумыштан килгән һәм, әлбәттә, балачакта ныгып зураюга ирешкән. Синнән гомер буе балачагың карап тора икән, димәк, ул үзенең эчкерсезлеген югалтмыйча уяу саклый. Яхшылык нәкъ менә шушы нигез сыйфаттан ярала. Әсәрләрдәге көрәш мотивының үзенчәлеге дә шәхес күңелендә тамырланган яхшылык башлангычыннан киләдер. Казаныңа нәрсә салсаң, чүмечеңә шул эләгә...

Үз җиремә иңсен минем игелегем,—
Изгелеге кадерләде бу башымны.
Шул изгелек тотып калды, дөнья, синең
Минем башка бәргән чакта ташларыңны.

Дөньяда яхшы кешеләр бетмәгән... Шагыйрь борынгылар этикасы кануннарына таяна, үзе дә рәхимҗаннар сафында атларга омтыла. Күңеленә игелеклелек оялаган. Һәрбер гамәлендә Хозыр-Ильяслык сизелеп тора, әр-яңа чалбарын дустына биреп киткән Такташны хәтерләтүче адымнары да шактый. Стиль — кеше. Язу рәвешен ничек кенә аңлатма, асылы барыбер шәхескә кайтып кала. «Үзең яшәгәнчә яз»... Шигърият фәненең беренче кагыйдәсен Рәшит Әхмәтҗанов йөрәк каныңа сеңдереп үзләштергән. Шагыйрьнең тормышы белән иҗаты арасында каршылык сизелми. Шулай булуы кыйммәт. Лирик «мин»енең прототибы була алмаучылар әдәбият дөньясында болай да шактый.

Стиль — кеше... Язарга өйрәнгәндә үк калыплашкан почеркта да кешенең холык-фигыле ачык чагыла. Кардиограмма йөрәкнең ничек эшләгәнен күрсәтә. Шушы уңайдан Социалистик Хезмәт Герое Рәшит Саттаровның тормыштагы шәхес белән иҗаттагы шәхес игезәклеген аңларга ярдәм итүче кызыклы күзәтүләренә мөрәҗәгать итик. «Еш кына мин аның эшләгәнен күзәтә идем,— дип яза атаклы төзүче.— Стенаның тышкы ягына салыр өчен бер өем кирпеч арасыннан үзенә ошаганын эзләп ала иде ул. Кайчакларда цементлап салган кирпечне ераккарак барып карый да, нидер килештермичә, кабат алыштырып куя. «Нигә алай итәсең?» — дип сорагач, ул: «Бусы матуррак,— ди.— Кешеләр, караганда, чыраен сытарлык булмасын».

Рәшит салган кирпечләр арасыннан бервакытта да цемент бүлтәеп тормый, аның кирпечләре бер-беренә шундый тигез яталар, аларның җөен дә күрмисең. Ул, эшен тәгәлләгәч, йортның стенасына озак кына карап, хезмәттән ләззәтләнеп тора иде. Кайчакларда мин аның эшләгән вакытында авыз эченнән генә нидер көйләгәнен дә ишетә идем. Ул җырлап эшли...»

Ташчы егетнең хезмәткә карашын ачып күрсәтүче әлеге күзәтүләрдә, кешеләргә игелеклелек кылу омтылышы гына түгел, шагыйрьнең иҗатка мөнәсәбәте һәм бигрәк тә сүз белән эш итү рәвеше күзалланырлык булып чагыла. Индивидуаль шигъри морфология үзенчәлекләренә соңрак тукталырбыз, ә хәзер сүзебезне иҗатның тирәндәге агымын ачу юнәлешендәрәк дәвам иттерик.

Үзлегеннән аталану... Биологиядә шундый төшенчә барын беләсездер. «Үзенең тәпиен суыручы аю»ны хәтерләткән шагыйрьләр булгаласа да, тулаем поэтик кыйммәтләр үзеннән-үзе генә яралмый. Шагыйрьнең күңел тамырлары — милли тарих тирәнлегендә. Халкыбыз культурасы шәхеснең яшәешенә, поэтик язмышның эчке нигезенә әверелгән. Һаман саен үсә баручы иҗат өскормасының ныклы нигезе булмаса, әйтик, Хәсән Туфан яшь каләмдәшенә биреп калдырган фатихасында мондый нәтиҗәләр ясар идеме: «Үз кичерешләрен генә түгел, халык йөрәгендәге кичерешләрне дә чын шигырь югарылыгына күтәреп... бирә ала...»

Әсәрләрнең идея-эстетик асылын билгеләүче рухи культура, әйе, шәхеснең яшәү рәвешенә аерылгысыз төстә бәйләнгән. Мондый бәйләнеш Рәшит Әхмәтҗанов язмышында ачыграк сизелә. «Барысын да кешеләргә бирим, нәрсә бар бу җанда — һәммәсен». Шагыйрь ап-ак кәгазьгә күңелдәгесен генә түгә, кешеләрне гаҗәпләндерергә тырышкан күз буучы шамакайдай, авызыннан көтмәгәндә йомырка чыгарып азапланмый. Күңеленең «культуралы катлам»ында һәркемне дә сокландырырлык табышлар болай да җитәрлек. Һәм шунысы кыйммәт: шигыйрьнең философик культурасы китап укуга гына нигезләнмәгән, ә гомер тәҗрибәсенең катлам-катлам утырымнарыннан күтәрелгән.

Мин яшенне юкка гына
Җанга яшердеммени!

Җанга яшерү... Шагыйрь барысын да яшереп бетерә алмый. Табигате шундыйдыр: эчендәге — тышында... Дөньяга сабыйларча беркатлылык белән карау кайчак үзенә дә өстәмә кыенлыклар китерә. Балалар самимилеге белән яшәр өчен, әйе, әлегә дөньясы көйләнеп бетмәгән.

Таш өстендә гөлләр...
Гөл өстенә
Соңгы йотым суны коясың.
Һәм актарып ташны,
таш астыннан
Тапканым бар елан оясын.

Шагыйрь иҗатының үзәгенә куелган проблемалардан берсе — яхшылык һәм яманлык концепциясе чагылышына гына тукталыйк. Гомуми күзәтүләрдән чыгып караганда,

яманлык категориясе тулаем иҗат җирлегендә тарихи тәрәккъыяткә мөнәсәббәттә бирелә. Кешелекнең алга баруына комачаулык итүче көчләр, аерым алганда, социалистик җәмгыятькә каршы күренешләр яманлык итеп бәяләнә. Көрәш кырының әсәрләрдән аңлашылган гомуми манзарасы шундый. Яхшылык һәм яманлык концепциясенең шагыйрь иҗатында чагылышын тагын да төгәлрәк күрсәтеп буламы? Өстәмә шәрехләүләр, әлбәттә, кертергә мөмкиндер. Шулай да сурәт томанлырак килеп чыга. Сәбәбе? Барысы да һөҗүм юнәлешен билгеләүдә аныклык җитмәүдән киләдер. Шагыйрьнең кемгә каршы көрәшүе кайчак тоныграк күзаллана. Ачыклагычта тиешенчә тотылмаган фоторәсем шикелле.

Кагылулар, сугылулар булса,
Дошманнарга каршы чыгарбыз...

Аныксызлыктан килеп чыга торган гомумилек, әйе, әсәрләрдәге вакыт тибешен төгәл тоярга комачаулый. Шагыйрь кайчак замана елъязмачысы булудан тайпыла. Яшәгән еллары да билгеле булмаган борынгы әдипнең иҗат үрнәкләрен өйрәнгәндәгечә, кайвакыт китап бите читенә шундый сорау язу теләге уяна: әсәр кайсы чорга карый? Киләчәк «заман мөһере» булган канатлы сүзләрне генә кабул итәдер.

«Изгелекнең дошманы бар — бигрәк явыз!..» Шагыйрьнең әлеге искәртүе, җырның кабатланулы кушымтасы төсле, төрле авазларда яңгырый. Яхшылык онытыла, яманлык онытылмый. Каршылыклы дөньясында әледән-әле кабатланып торучы яманлык күренешләре канат җилпергә дә өлгермичә корбан булган балачак кошчыкларын һәрдаим хәтердә җанландыра. Алай гына да түгел... Астыртын көлүче кырыс язмыш шундый ук хәлне берничә дистә еллар үткәч яңадан залимнарча кабатлый. Искитмәле кабатлану!

*...Әле уянып та җитмәгән дача тәрәзәсенә кемдер берничә тапкыр чиертеп үтте... Болдырга чыккач барысы да аңлашылды — тәрәзәгә уҗым чыпчыгы шакыган! Томшыгы белән тукылдаткан... Чү! Очышында гасабилану сизелә. Якындагы җиләк түтәле өстендә бөтерелә башлавы исә сагаеп калган күңелне тәмам тәшвишләндерде. Оясына куркыныч яныйдыр!.. Җиләк яфракларын аралап карарга иелүе булды һәм кинәт утка пешкән төсле читкә тайпылып куйды. Ояны ниндидер елан урап алган!.. Тагын соңга калды. Кошчыкларны явызлык авызыннан тартып алырга янәдән соңгарды. Уяулык җитмәде. Инде ничәнче тапкыр!..*

Кошчыклар фаҗигасенең кабатлануы ниндидер табигый очраклылыкмы? Зиһен төшенеп җитми. Кабатлану... Яра өстенә яра. Балачакның битарафлыкта гаепләп җәзалавымы? Яхшылык эшләргә соңгаруның җинаять булуын искәртәмә? Кошкайлар үлеме шуны аңлатамы? Ап-ачы хакыйкатьне бәгырьгә уеп төшендерер өчен нигә әле кошлар җаны кирәк булды?

Кошлардагы матурлыкны кайчак
Канатсызлар күреп яратмыйлар.
Ә бит кошлар кешеләрнең кылган
Батырлыгын күктә кабатлыйлар.

• • •

Хаклык, яхшылык, матурлык... Теләсә кайсы сәнгать әсәре, гадәттә, шундый категорияләрдән чыгып бәяләнә. Шагыйрь иҗатының кайбер үзенчәлекләрең «яхшылык рентгены» инде азмы-күпме ачып күрсәтте. Игътибарны хаклык һәм матурлык гәүдәләнешенә юнәлтик, шигъри морфология табигатен ачыкларга тырышыйк. Күзәтүне нидән башларга? Мәсьәләгә урау юлларсыз гына якын килү өчен Ибраһим Нуруллинның мондый сүзләрдән башланган мәкаләсен искә төшерик: «Поэзиябездә үзен сиздерә башлаган бер тенденция — үтә катлауландырып язу, ассоциативлык белән кирәгеннән артык мавыгу, форма оригинальлеге артыннан куу күңелне күптән кытыклап килә иде. Рәшит Әхмәтҗановның «Ак канатлар» исемле җыентыгы чыккач, ...кулга каләм алырга булдым». «Аңлаешлы» һәм «аңлаешсыз» шигырьләр турындагы күзәтүендә тәнкыйтьче, шагыйребезнең «табышмакчылык»ка шактый өлеш кертүен билгеләп, күп кенә шигъри мисалларга карата мондыйрак фикерен белдерә: «Я, укучым, берәр нәрсә аңладыңмы? Ни әйтергә теләде шагыйрь? Мин, оятыма каршы, берни аңлый алмадым».

Сүзегезне ефәк белән бүләм, Ибраһим ага, әмма фикерегезне тулаем инкарь итәргә җыенмыйм. Шулай да кешедәге кешелеклелекне яклаучы адвокат шикелле, шагыйрьдәге шагыйрьлекне булдыра алганча яклап чыгарга уйлыйм. Кискенрәк яңгыраучы әлеге чыгышыгызда «тагылган гаеп», минемчә, объективлык ягыннан бик үк ышандырырлык нигезгә таянмаган. Бәяләмәләрдә тәнкыйтьнең кайчак яхшыны да, начарны да чамасыз зурайтып

күрсәтүе, барыннан да бигрәк, аерым дулкыннарны гына кабул итүче радиоалгыч төсле, рецензентның ничектер шәхси зәвыкка ныграк ышануы, хөкемдар карашларына туры килмәү аркасында гына теге яки бу әсәрнең «аңлаешсыз»лар төркеменә кертелүе сиздертә шикелле. «Аңлаешсыз»лыкта гаепләүче дәлилләргә тукталыйк.

...Тайгада учак яккан юлчылар, үзләре дә сизмәстән, шундый җинаять эшләп ташлыйлар: яндырылган агач ябалдашында сандугач оясы булган... «Учак» шигырен автор болай төгәлли:

Сандугачлар янган утта
Җылынырга ярыймы соң?!

Тәнкыйтьче әлеге юлларга карата үзенең мондый дәгъвасын белдерә: «Сандугач дигәндә бөек шагыйрьләр күздә тотыла дип уйлыйк. Пушкин, Лермонтов, Байрон, Петефи, Тукай һ. б. лар янып үлмәделәрмени? Без алар янган утта җылынмыйбызмыни? Шагыйрь югарыдагы ике юлның мәгънәсе белән кызыксынып тормаган...»

Әсәрнең идея чишелешен күп кенә очракта апофеоз-бетемдә белдерүче шагыйрь бу юлы «шартлатып әйтелгән» соңгы сүзнең мәгънәсе белән кызыксынып тормаган. Шулаймы? Шигырьдә үткәрелгән фикер, минемчә, шактый уңышлы төйнәлгән. Шулай да соңгы ике юлга нинди мәгънә салынган икән. Ачыклап карыйк. Барыннан да элек шуны әйтик: әсәрдәге үзәк фикер ачыктан-ачык көрәш мотивларына түгел, ә кешелеклелекне билгеләүче әхлакый башлангычка нигезләнгән. Шагыйрь сандугач һәм юлчы йөзендә үзара килешә алмаслык дошманнарны күрсәтергә омтылмый. Учак ягып җылынырга теләгән юлчылар, юк, Мөҗәйләрне крематорийда яндырган тираннар түгел. Зөлфәткә кушылып әйткәндә, «сугыша белми былбыл»... Юлчыларның гамьсезлеге аркасында очраклы төстә һәлак булган сандугач балалары «сугыша белгән былбыл һәм җырлый белгән бөркет»кә, яки Данкога охшаш Мусалар сурәтендә түгел, ә көндәлек тормышта кылган гамәлләребезнең яхшысын-яманын билгеләп торучы матурлык фәрештәсе, әхлакый яхшылык символы рәвешендә күзаллана. Шунысына игътибар итегез: тайгада учак ягучылар сандугач балаларын вәхшиләрчә күрә торып яндырмыйлар һәм, бәхеткә каршы, саксызлыклары аркасында килеп чыккан күңелсезлек өчен һәммәсе дә вөҗдан газабы кичерәләр.

Ачынулы уйлар белән янучы мондый кешеләр (ирексездән браконьерлар) Галилейларны утка аткан инквизиторларга бернichек тә бәйләнми. Күңелдә янәшәлек ассоциациясе дә тумый. Барысы да аңлаешлы. Без атаклы «Гали белән Кәҗә» шигыреннән ниндидер сыйнфый каршылыклар эзләп азапланмыйбыз ич. Шагыйрь тарафыннан шактый анык ният белән язылган «Учак» әсәренең дә тематик чишелешен башкача интерпретацияләп маташмаска кирәктер. Универсаль подтекстлар бирелмәгән. Ике төрле уйларга нигез юк. Шигырь уяу булырга чакыра. Сандугачлар янган утта гамьсез рәхәтләнкә бирелеп җылынсак, җылы яратучы елан төсле, сөякләребезгә җылы эзләп кенә йөри башласак... Гамьсезлек утында җылынырга ярамый! Кемнеңдер михнәте бәрабәренә табылган рәхәтлектә җаныбыз йокымсыраса, сандугач балалары янудан да зуррак фаҗига булуы ихтимал. Шагыйрь әнә шул хакта искәртә.

Яшерен сөйсәң дә, сөюне
Ай күрә, кояш ала.
Ала да давылга бирә,
Давыл дәрьяга сала.

Шагыйрьнең күп кенә әсәрләрен табышмакка чыгарган тәнкыйтьче, аңлаешсызлыкка янәдән мисал китереп, тулаем шигырьгә карата тагын катгый хөкемен чыгара: «...мәгънә — ноль». Әлеге шигъри юлларда мәгънә чынлап та юкмы? Моңа ышанасы килми. Яшерен сөюнең дә тора-бара бөтен миргә «фаш булу»ын халыкчан яңгыраштa әйтеп бирә алган шагыйрьнең әлеге әсәргә салган уй-ниятен барлык нечкәлекләре, мәгънәви төсмерләре белән аңлатып бирергә теләмим. Шигырь фәнни хезмәт түгел — ахырда резюме язып булмый. Анысын һәрбер укучы үзенчә чыгара.

Нәрсә әйтергә теләде шагыйрь? Күпчелек очракта шигъри юллардан шундый сорауга җавап эзләнә. Югыйсә үзебезгә дә еш ишетергә туры килә: фикер әйтер өчен генә шигырь язмыйлар. Нәрсә әйтергә теләде? Мондый сораулар белән генә әсәрнең идея-эмоциональ тирәнлеген ачып булмый. Табигате буенча үзендә серлелек элементын яшергән нәзберек поэзияне маңгайга бәреп әйтелгән куркытулы сораулар ничектер чикли шикелле. Сораулар серлелекне үтерәләр. Маяковскийча әйткәндә, «Поэзия ул — баштанаяк! — беленмәгән якка юл алу». «Җырлады кыз чиркәү хорында...» исемле шигырендә Александр Блок нинди уй-ниятен ирештерергә теләгән? Күпме аңларга тырышма — ахырынача төшенеп булмый. Серлелеген тирән яшергән әлеге шигырьне дә мәгънәви яктан нольгә чыгарыйкмы? «Оятыма каршы, берни аңлый алмадым», дисәк, дөресрәк буладыр.

Үзебез шагыйрьләрнең «яхшы һәм төрле» булуларын телибез һәм үзебез шундый иҗатчыларны ничектер өнәмичәрәк кабул итәбез. Моны чал поэзия тарихы да раслый. Яхшы шагыйрь, гадәттә, авыррак таныла. Талантның төрлелек чиген киңәйтергә омтылуы гадәтилеккә күнеккән хөкемдарларда ризасызлык тудыра. Күзгә бәрелеп торган төрлелек, әйе, беренче чиратта сәерсенү уята. Тормышыбыз шулай корылганмы? — Ахрысы. Тукайча туры итеп әйткәндә, «Безнең татарларда... һәрбер нәрсәгә каршы тору ата-бабадан калган бер гадәттер». Шундыйрак каршы торулар поэзиядә дә күзәтелгәли. Алтмышынчы еллар уртасын гына искә төшерегез. Поэзияне төрләндерергә омтылган яшьләргә сәерсенеп караучылар булмадымы? Традицион шигырь белән ирекле шигырьне үзара каршы куярга тырышучылар да табылды. Вакыт әлеге бәхәсне үзенчә хәл итте. Гадәти тоелмаган «стандартсыз» яшьләрнең күбесе хәзер инде яхшы шагыйрьләр булып танылды. Яңарышка, авырлык белән булса да, күнегелде.

Алтмышынчы еллар уртасында күтәрелгән «гаугалы» буын шагыйрьләренең берсе Рәшит Әхмәтҗановның озаграк танылуын һәм кайберәүләр тарафыннан кыенрак кабул ителүен дә аның талантларга гына бирелә торган авыр юлдан барырга, ягъни башкаларныкына охшамаган иҗат дөньясы белән мең авазлы поэзияне үзенчә төрләндерергә омтылуыннан чыгып аңларга кирәктер. Шагыйрь поэзиядәге серлелек башлангычына чагыштырмача ныграк таяна, серлелек җирлегенә тирәнрәк үтеп керергә омтыла. Төрлеләр рәтендәге урынны, мөгаен, шушы сыйфат билгелидер. Кайбер әсәрләренең авыр аңлашылуы да серлелеккә өстенлек бирүдән киләдер.

«Серлелек»не кайчак «табышмак» белән бутыйбыз. Шагыйрьләр иҗатын тикшергәндә «табышмак өстенә табышмак», «шигъри ребус», «фикерне яшерү», «җеп очын югалту», «башваткыч» кебек гыйбарәләр мулдан сибелә, ә поэзиянең тумыштан килгән серлелеге, иҗатчының образлы фикерләү үзенчәлекләре, талантның эчке үсеш тенденцияләре, җиңел генә үтеп керә алмаслык катлаулы лирик дөньяның асылы һ. б. шундый мәсьәләләр тиешенчә күтәрелми. Шагыйрьнең бөтен нечкәлекләрен ачып салган эчке портретны профиль күләгәсен ашык-пошык буяштырып бирүче моменталистларча эшләп булмыйдыр. Кешене дәвалар өчен организмның эчке төзелешен белү зарур. Монысын яхшы беләбез. Гомумән, мәгълүм фикерне кабатлап әйткәндә, авторны тәнкыйтьләү җиңел, мәгәр бәяләү кыендыр. Һәм шушы уңайдан Гете сүзләрен искә төшерү дә урынлы булыр: «Язучыны аңлаешсызлыкта гаепләр алдыннан үзеңнең шәхси акылыңны анализларга һәм аңламауның сәбәбе шунда түгелме икәнен ачыкларга кирәк. Эңгер-меңгердә хәтта эре хәрефләр дә авырлык белән укыла».

Шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов әсәрләрендәге серлелекнең асылын ничек аңлатыйк? Иң элек Хәсән Туфанны тыңлап үтик: «Рәшитнең кайбер шигырьләрендә Гарсиа Лорка йогынтысы бардыр кебек тоела. (Мәсәлән, «Әллә инде кыр казлары кайта» шигырендә.) Ләкин Рәшит Испания чегәннәре фольклорына гына хас булган «табышмаклы», катлаулы метафораларның йомшак якларын, татар шигыренә ят иканлекләрен яхшы белә. Рәшитнең сурәтле торган үз теле бар...» «Өметләрне аклады» дип башланган фатихасында аксакал үзенең «энекәше» турында шундый сүзләр әйтеп калдыра. Өметләрне аклаган шагыйрьнең «Егет җыры» исемле җыентыгындагы атаклы каләм — яшел каралы каләм эзләрен күздән кичерик. «Туй көне җитә» шигыре урнашкан биткә Хәсән ага мондый сүзләр язып куйган: «Халык ритмы һәм Тукайлар ритмы ничек яңарып яңгырый!» Арырак китәбез. «Җан тетрәткеч шигырь бу!» Монысы — «Сөрелгән җир кап-кара...» дип башланучы шигырьгә бирелгән бәяләмә. «Тамчы монологы»н да ул үзенчә кабул иткән: «Юк, Лорка тәэсире түгел, бу үзе татар «Лорка»сы».

Лорка... Очраклыдырмы-юктырмы: Рәшит Әхмәтҗанов иҗатына кагылган аз санлы тәнкыйть мәкаләләрендә әлеге дә баягы Лорка исеме очраштыргалый. Атаклы испан шагыйренә тиңдәшлек үткәрмичә әйткәндә, алар арасында ниндидер охшашлык күренә шикелле. Күләм-дәрәҗәсен төгәл билгеләп булмый торган мондый охшашлык шагыйрьләрнең фикерләү рәвешендә, бигрәк тә метафоралар куллануда сизелә. Кайберәүләр өчен «аңлашылып җитмәүче» шагыйрьләр рәтендә торучы Гарсиа Лорканың ихлас ачылып әйткән мондый сүзләрен Рәшит Әхмәтҗанов әсәрләрендәге уй-хис яшәеше табигатенә карата да куллынып буладыр: «Теманың бөтен катлаулылыгын бик яхшы аңлаган хәлдә, мин төгәлләнгәнлеккә дәгъва итмим; мин сызыкламалар гына эшләргә — сөйләп бирмәскә, ә фикергә юнәлтергә телим».

«Татар Лоркасы» Рәшит Әхмәтҗанов әсәрләренең кайберәүләргә аңлашылып җитмәве, «фикер агышының логик эзлеклелеккә буйсынмаган» булып күренүе, кыскасы, шагыйрьнең бөтен серлелеге маңгайга бәреп тора торган төгәлләнгәнлеккә дәгъва итмәүдән, гомумән алганда, югарыда әйтелгән иҗат принцибына охшаш инануга нигезләнүле фикерләү рәвеше табигатеннән килмиме? «Үзен кабат-кабат укытырга мәҗбүр итмәүче китапны мин яхшы китаплар рәтенә куя алмыйм...» — Рәшит Әхмәтҗановның әнә шундый нәзберек зәвыгы да шагыйрьнең иҗат холкын шактый сизелерлек дәрәҗәдә чагылдыра төсле. Укылган китапны яңадан кулыңа алу, димәк, андагы тирәнрәк мәгънәви

катламнарны колачларга теләү, димәк, ачылып бетмәгән серләр ләззәтен татырга ымсыну, димәк, иҗатчы буларак, үзең дә тышлык белән чикләнмәгән «очсыз-кырыйсыз» китаплар тудырырга омтылу. Шагыйрь шуңа омтыла. «Уйлар катлау-катлау, хисләр катлау-катлау» (Сибгат Хәким).

Шагыйрьнең каралама-кульязмаларын актарам. Матур язу дәфтәрендәгечә түгел — үзе генә таныpлык урыннар шактый. Төзәтмәләр дә җитәрлек. Укыйсың — тертеләсең. Кайчак төшенеп булмый. Ашыгып язылган рецепт шикелле. Рецепт... Шагыйрь әнә шулай дәва әләшә. Һәрбер күңел дәвадан үзенчә шифа таба...

Караламалар ашыгып язылмаган. Җөмләләр кат-кат эшләнгән. Сөйләүгә авышкан урыннар, фикер агышын өзмәслек итеп, акыллы рәвештә сызылган. Шагыйрь чын шигъри тел — кыска, тыгыз, сурәтле һәм музыкаль тел белән язарга омтыла. Болай да уйланулар резюмесын кристаллаштыручы метафоралар арасыннан мөмкин кадәр җыйнагын һәм зуррак сыешлысын сайлый. Метафоралар катлаулана, эчтәлек тыгызлана. Янә Хәсән ага сүзләре хәтердә яңара: «Рәшит Испания чегәннәре фольклорына гына хас булган... катлаулы метафораларның йомшак якларын, татар шигыренә ят икәнлекләрен яхшы белә...» Йомшак якларын беләдер. Шулай да метафоралары шактый катлаулы чыга. Кайбер әсәрләрнең аңлашылып җитмәве, мөгаен, шушы «мазок» катлаулылыгыннан да киләдер. «Асылынып, тау тирбәлә талымның иңнәренә», «Дөнья, дөнья... Хәзер ике күзем — чүлләрендә ике күл була», «Сандугач килеп кунар чак җитте җир астындагы һәрбер тамырга»... Катлаулы булсалар да, минемчә, аңлаешлы метафоралар. Нишлисең, барысы да фикерләү рәвешенә бәйледер. Һәркемнең үз почеркы. Төрле шагыйрьләрне бердәй кабул итәр өчен төрле нечкәлектәге тоемга ия булу кирәк. Йөрәкләр тибешенең график сурәтләнеше, күпмедер охшашлык булса да, берсен-берсе стереотип төгәллегендә кабатламый. Һәрбер йөрәкнең биотогы үзенчә. Поэзиядәге төрлелекне әнә шундый кабатланмаулар билгели. Шагыйрьләр төрле булган кебек, шигырь сөючеләр дә төрле: алар өчен «авыр аңлаешлы» Дәрдмәнд тә, «җиңел аңлаешлы» Такташ та кадерледер.

Һәр сүз миннән бер матурлык сорый,
Мин фәкыйрьмен — алыйм кайлардан?
Ярый, килдең син: кояштан тамдың,
Шигыремә төштең айлардан...

«Һәр сүз миннән бер матурлык сорый...» Шагыйрьнең кемгәдер аңлашылып җитмәве, бәлки, сүз белән эш итә белмәүдән генә киләдер?! Тирәннән эзләнгән сәбәп, әнә шулай, өстә генә ятмыймы? Тикмәгә генә шулай әйтелмиː поэзия — иң яхшы тәртиптәге иң яхшы сүзләр. Әдәбиятта «сүз рәтен» белмәүчеләр бихисап. Буталчыклык шуннан килмиме?

Рәшит Гәрәй: «Шагыйрь озын язарга, кайбер яшь әдипләребез шикелле, кирәксә-кирәкмәсә дә, ...җөмләләр матур булсын өчен генә сүз уйнатырга яратмый».

Роберт Батуллин: «Мин Рәшитнең шигырьләрен музыкага охшатам. Мондый шигырь язу өчен бик тә нечкә тойгылы интеллектуаль йөрәк кирәк».

Равил Фәйзуллин: «Безнең... чичән телле Рәшитләребез... бар.»

Сибгат Хәким: «Аның шигырьләрендә сүзләр шулкадәр үз урыннарында, ул сүзләр йорт стеналарына иләп салынган ташлар, кирпечләр кебек, аларны икенче төшкә күчерүе читен, икенче төшкә алып куясы да килми».

Төрле вакытта (сүз берләшмичә) әйтелгән әлеге фикерләрдән катгый дөрес нәтиҗә чыгарырга җөрьәт итмәстән, Рәшит Әхмәтҗанов иҗатындагы кайбер тел буталчыкларын күздә тоткан хәлдә (алар кемдә булмый?!) һәм озын-озын шигъри мисаллар китермичә генә шуны белдерәсе килә: югарыдагы күзәтүләр шагыйрь файдасына сөйлиләр төсле.

Шулай да... Шагыйрьнең катлаулы фикерләү рәвешенә турыдан-туры бәйле булмаган, төгәлрәк әйткәндә, камилләшеп җитмәгән сыйфатларга — осталыкка кагылышлы (авыр аңлауга китерүче) җитешсезлекләргә дә күз йоммаска кирәктер. Шагыйрьдәге, шагыйрьлекне аяк терәп яклыйм, әмма «гаеп»ләрен тулаем инкарь итәргә җыенмыйм. Иҗат кимчелексез булмый. Аңлаешсыз юллар да очрыйдыр. Алар тәүге иҗат адымнарыннан ук килә бугай. Мондый юллар «матур егерме ике яшьтә» әзерләнгән беренче китабында да бардыр. Шагыйрь иҗатына хәерхаһлы булган Әдип Маликов Әлмәт каласын төзешкән ташчы егетнең беренче шигъри тәҗрибәләрен түбәндәгечә искә төшерә: «Без аңа: «Бу юлларың бик үк аңлашылмый бит»,— дигәч, ул кызарына, маңгаеннан тирләрен сөртә. «Әйе шул,— ди ул, ахырдан ризалашып,— үземә дә шулай тоела». Һәм икенче көнне инде без шигырьнең гади, отышлы вариантын укыйбыз».

Серле дөнья күкрәгендә
Кал син, энем, үз хәлеңдә.

Шагыйрь үзенең энесенә шундый киңәш биргән. «Үз язуы»н тудырган иҗатчыга, алай язма, болай яз, дип, акыл өйрәтүнең кирәге бармы? Өйрәтүчеләр, әлбәттә, очраштыра. Нәрсәдер көчләп тагарга тырышабыз. Художникның эчке дөньясын, рентген шикелле, тиешенчә яктырта алмыйбыз. Дөрес диагноз куелмый. «Коеп куйган» шагыйрь, һичшиксез, үзе булып калсын. Әмма киңәшләргә саңгырау булмаска кирәк. Күпләр тарафыннан күрсәтелгән кимчелекләрне кире кагып булмый.

«...Шигырь эчендәге логик эзлеклелеккә игътибарын киметә төште». Шагыйрь иҗатына кагылышлы мәкалә һәм чыгышларның «кимчелекләр өлешендә» Рәшит Әхмәтҗановка еш кына шундый дәгъва белдерәләр һәм кайбер «аңлаешсыз» әсәрләрнең уңышсызлыгын нәкъ менә логик эзлеклелек булмаудан күрәләр. Тормыштан сәнгатькә төгәл анализсыз күчеп булмыйдыр. Бүгенге аналитик заманда бигрәк тә. Иҗатның шундый кагыйдәсен дә онытмаска кирәк: стиль ачыклыгы фикер ачыклыгына һәм, соңгы исәптә, м а к с а т  а ч ы к л ы г ы н а китерә.

Фикер ачыклыгы... Фикер поэзиясе, гадәттә, аңлаешлы була. Абстрактлылыкка авышкан романтик образлылык исә үзеннән-үзе буталчыклы катлаулылыкка этәрә. Мондый үрнәкләр дә очрый. Ярым тоннарның азлыгы, кирәкле очракларда график төгәллеккә ирешмәү, абстракт төшенчәләрнең анык күзалламалар белән ныгытылмавы, фикернең калкурак итеп күрсәтелмәве дә әсәр үзәгендәге логика умырткасының тотрыксызлыгына һәм йөрәкләргә аңлаешлы серлелек белән бернинди уртаклыгы булмаган буталчыклыкка китерә. «Аңладыгызмы?» дип, маңгайга бәреп сорауга караганда, «Аңлата алдыммы?» дип әйтүне тормышта дөресрәк саныйлар. Мондый кагыйдә иҗатка да ярашлы.

Ә чын сүзләр безнең ирennәрдә
Ничә кабат канга буялган...

Фикерне калкытыбрак күрсәтү, әйе, әсәрне аңлаешлы иттерә. Аллы-гөлле гыйбарәләр, бормалы-сырмалы сүзләр, күзгә төтен җибәрү төсле, әсәрдәге теләсә нинди бушлыкны яшереп торалар. Кайвакыт купшылыкны нәфислектән аермыйбыз. Поэзия тасма теллелекне, бушбугазлылыкны яратмый. Шушы уңайдан бер хикәят хәтергә килә.

*Бер шагыйрь бер бай адәмнең ханәсенә барды. Байны мәдехләп шигырь әйтте. Ул бай адәм моңар бик хушнуд булды (рәхәтләнде.— З. М.) Әйтте: «Хәзердә минем кулымда акчам юк, ләкин ашлыгым бик күп, иртәгә кил, сиңа ашлыктан бер нәрсә биреп җибәрермен»,— диде. Шагыйрь иртәгесен янә байның ханәсенә килде. Бай әйтте: «Нихәл, ник килдең?» — диде. Шагыйрь әйтте: «Кичә ашлык бирермен дип вәгъдә кылган идең, аның өчен килдем»,— диде. Бай әйтте: «Гаҗәпсең, син мине сүзең белән хушнуд кылдың, мин һәм сине сүзем белән хушнуд кылдым»,— диде.*

Җанга берни дә бирмичә, укалы сүзе белән хушнуд итәргә тырышып, күзгә кибәк сибүчеләр азмы? Сүз боткасын күпме җылытсаң да, сүз боткасы булып кала. Фаразлау көче белән логика көче тигезләгән сакламыйча, хиссият стихиясенә баштанаяк бирелүчеләрне аксөяк кызлар төсле купшы киенгән бушсүзлелек ныграк эзәрлекли. Моны онытмау зарур. Көрәш поэзиясенең һәрбер сүзен солдатка тиңлиләр, һәм ул һәрвакыт солдат булып калырга тиеш.

Җиңелмә сүздә, җиңелсәң —
Җиреңне дә дауларлар.
Юкка гынамыни җирдә
Чичән булган бабаңнар.

* * *

Шагыйрь иҗатын янә күздән кичерәм. Китап исемнәрен бер-берсенә бәйлим: «Хыялларым үзем белән», «Егет җыры», «Ак канатлар», «Гомер чишмәсе», «Алмалы җәй», «Җан яктысы», «Кавышыр көн»... Егерме еллык иҗат гомерен колачлаган әлеге китапларны уртада торучы үзәк исем астында берләштереп карыйм. «Гомер чишмәсе»... Тоташ бер китап күз алдына килә. Китапларның берсендә дә авторның фотосурәте бирелмәгән. Бирелмәсен. «Яшәгәнчә язарга» омтылучы шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов портреты тоташ бер китап тәшкил иткән әсәрләрдә болай да ачык күренә. Мартирос Сарьянның төрле яшьтәге сурәтләрен берләштергән автопортрет шикелле. Әнә китаптан үнсигез яшьлек ташчы егет карап тора. Йөзеннән эчкерсезлек һәм садәлек сирпелә. Моңсу күзләрендә «сугыш еллары авырлыгын чәчләренә бәйләп сөйрәгән» Ләйсән

әбиләр, «бүреләрне җиңә алган колыннар», гомер буе әнкәсенең каршысына яланаяк йөгерүче ятим балалар, «Үстегезме, әллә үлдегезме?» дигәндәй, каңгылдашып кайтучы торналар чагыла төсле. Яшь — кече, уй — олы.

И бала, алтын яшьлегең
Бу җиргә нәрсә чәчәр?
Нәрсәләр чәчәр?.. Урмасмы
Бары тик көмеш чәчләр?

Әсәрләрнең уртак җыелмасында, әнә, икенче сурәт төсмерләнә. Таныш күзләр ничә яшьтә? Чама белән генә әйткәндә, ахры, Тукай яшен узып бара. Карашы элеккечә әчкерсез. Унсигездәге чалымнары кискен үзгәреш кичермәгән. Хисләр утыра төшкән. Элекке моңсу күзләр тирәнрәк булып күренә. Үзләре һаман очкынлы. Гамьлелеге арта төшкән шикелле.

Кырыгын узган шагыйрь... Бөтен рухи хәзинәләр ачкычы булган ихласлылыгын зирәклек белән тагын да ныгыта төшкән. Акыллылык сирпеп торган күзләре, балачакта-гыча, дөньяга самимилек белән карыйлардыр. Иөзендә чәүчәләклеккә охшаш бәргәләнү сизелми (тирән елга тавышсыз ага). Элеккечә. Шөһрәткә ымсыну чалымнары күренми. Тыйнак («Булсын бар биеклегем арыш биленнән генә...»). Үзенең хакыйкатен раслау юлында ул тормышның ачысын-төчесен татырга өлгергән. Картларныкы төсле капчыклык булмаса да, яшәеш хикмәтләрен шактый туплаган. «Яшь чагында авыр ташлар — тау астында, җиңел ташлар гына тора тау башында». Җандагы ялкын күзләрдә чагыла: «Күрмисез, минем күңелдә фидаи яшәгәнен...» Маңгае киңәеп киткәндәй тоела. Чигә чәчләре уңган. Тынгысызлык күз төпләренә аз гына талчыкканлык иннеге сылаштырган.

Алма белән кояш арасында
Дөрләргә дә безгә дөрләргә.
Гомер озын...
Ямьсезләндек бары
Матурлыкны күбрәк күргәнгә.

Матурлыкны күбрәк күргәнгә... Шагыйрь җиңел юлдан бармый. Матурлык өчен көрәшкәндә, әйе, ямьсезләнергә дә мөмкиндер. Ихлас җанның кылган кайбер яхшылыклары кайвакыт үзенә начарлык булып кайта. «Сүземә карагыз — юллар ачармын, үземә бакмагыз — үзем начармын...» Тукаебызның әлеге сүзләре матур яңгырашлы рифма өчен генә әйтелмәгән. «Эшләр шома гына бара...» Мондый канәгатьлекне «шома миле» генә белдерә аладыр. Хәер... Дөньяда бит шома яшәп, шома язганнар да җитәрлек. Күрәләтә авыр юлдан барырга омтылучы Рәшит Әхмәтҗановны без андыйлар рәтенә һич кенә дә кертә алмыйбыз. Вакытында аңа тәнкыйть тә эләкте, әмма ул үзенең юлыннан тайпылмады. Талантның шома була алмавын шагыйрь үзе дә бик яхшы төшенә. Күңеленә Чернышевскийча караш-инану язылган: «Үзеңнең әсәрләрең белән беркемдә дә ризасызлык уятмау, үзеңә карата беркемдә дә каршылык кузгатмау... Мондый кызыксыз бәхет бары тик баналь сүзләрне риторик рәвештә тарату белән шөгыльләнүче буш кешеләргә генә эләгә».

Мин, ахры, еракка —
Иөрәккә китәрмен...

Шушы авыр юлда өзлексез камилләшә баручы (шомармаучы!) Рәшит Әхмәтҗановка җиңеллек юрамыйк.

# КИҢӘШЕРГӘ КИРӘК!

Журналда татар әдәбиятының бүгенге хәле турында, поэзия, проза һәм драматургия жанрларының торышы хакында кызыклы фикер алышулар, шактый озакка сузылган сөйләшүләр алып барылды. Ә менә тәрҗемә турында җитди сөйләшү, дискуссия булганын мин хәтерләмим. Бу турыда сүз башлап җибәрергә чират җитмәдеме икән? Ачыклыйсы, бергәләп уйланасы мәсьәләләр бик күп бит.

Мәсәлән, минем үземне түбәндәгеләр уйландыра.

Тәрҗемәнең төп принцибы — адекватлык. Ә нәрсә ул адекватлык? Аңлатмалы сүзлек әйтүенчә, ул тәңгәллек, бер үк төрле булу, бер-берсеннән аерылгысыз, тиңдәш булу дигән сүз. Тәрҗемәдә моңа йөз процент ирешү мөмкинме? Минемчә, һич мөмкин түгел, чөнки автор белән тәрҗемәче ничек кенә рухи яктан фикердәш, талант ягыннан тиңдәш һәм бер үк омтылышта булмасыннар, тәрҗемәче барыбер авторның копиясе була алмый, оригиналны һичбер зыянсыз, нәкъ үзе шикелле итеп, ягъни бөтенләй тәңгәл итеп бирә алмый. Димәк сүз тулы тәңгәллек турында түгел, тулы кыйммәтлелек турында барырга тиеш, адекват терминын без шулай аңларга тиешбез. Менә шушы тулы кыйммәтлелеккә ничек, нинди юллар, методлар, алымнар белән ирешергә?

Бу турыда күптән бәхәс бара. Сүзгә-сүз, юлга-юл, җөмләгә-җөмлә тәрҗемә итү методы күпләр тарафыннан инкарь ителде, бу методка «буквализм» дигән мәсхәрәле исем дә тагылды. Соңгы вакытта кайберәүләр ирекле тәрҗемә, интерпретация методларын, компенсация алымнарын яклап чыктылар. Ә икенче берәүләр аның белән килешми, бу юл тәрҗемәдә башбаштаклыкка алып бара ди. Безнеңчә, мәсьәләне болай китереп кую дөрес үк булмастыр. Әгәр тәрҗемә иҗат, талант эше икән, анда төрле ысул, алымнар кулланылуы мөмкин. Оригиналны төгәл итеп бирүгә ирешү өчен тәрҗемәче үзе кирәк дип санаган бөтен стилистик һәм әдәби чараларны эшкә кушарга ирекле. Кирәк икән, хәрефкә-хәреф, сүзгә-сүз, җөмләгә-җөмлә методы да һәм ирекле тәрҗемә дә урын алырга хаклы. Ләкин тәрҗемәче шуны исендә тотарга тиеш: һәр әсәрнең нигезендә җөмлә, абзац түгел — сүз ята. Сүз ул — төп материал. Һәр әдип җөмлә төзү, аны синтаксик яктан конструкцияләү өчен башта иң кирәкле дип уйлаган сүз, сүзләр эзли, аларны табуда күп тир түгә, газаплана. Димәк, автор теге яки бу сүзне тикмәгә генә сайлап алмаган, һәр җөмләне уйлап, үлчәп язган. Шулай икән, тәрҗемәдә аларны ташлап китү дөрес булырмы? Безнеңчә, кайбер очракларда дөрес булыр. Чөнки оригинал телендә язылган әдәби элементларны, җөмлә, абзацларны икенче телдәге чаралар белән бер-ике сүз, кыска җөмлә белән төгәл биреп була, һәм киресенчә, оригиналдагы бер сүзне, җөмләне берничә сүз, берничә җөмлә белән, ягъни интерпретация белән аңлатырга туры килә. Әмма бу эштә бик сизгер булырга кирәк.

Безнеңчә, ирекле тәрҗемә, интерпретация, компенсация алымнары поэзия тәрҗемәсендә урын алырга хаклы, ул күптән шулай килә дә, ә прозада аңа чиксез хокук бирелергә тиеш түгел. Моның кирәге юк, прозада иркенлек оригиналга зыян китерми торган грамматик рамкалардан читкә чыгарга тиеш түгел.

Тагын бер мәсьәлә. «Литературная газета» һәм кайбер әдәби журналларда күптән инде тәрҗемәчегә подстрочник кирәкме, юкмы? дигән сорау тирәсендә бәхәс бара. Ә менә конкрет рәвештә, үз җирлегебез шартларыннан чыгып караганда, бездә татар тәрҗемәчеләренә ул кирәкме? Безнеңчә, хәзер инде аның кирәге калмады, чөнки, аллага шөкер, бездә хәзер русчаны да, татарчаны да су кебек эчә торган тәрҗемәче кадрлар җитәрлек. Подстрочникның бер вакытта да тәңгәллеккә алып килүе мөмкин түгел, аның белән файдаланучы күзен бәйләгән килеш, оригиналны күрмичә эш итә, аның нечкә кылларын таба, капшый алмый, аңа күп очракта үз хыялы белән эш итәргә туры килә. Пушкин да әйткән бит: «Подстрочный перевод никогда не может верен»,— дигән.

Моңа да бездә мисаллар җитәрлек: Гомәр ага Бәшировның «Намус»ын подстрочник аркылы тәрҗемәсе (Н. Чертова) бер басылудан ары китә алмады, ә менә Р. Фаизованың турыдан-туры тәрҗемәсе илебездә һәм чит илләрдә дистәдән артык басмада чыкты. Бу эштә гаделлек тә юк: иң авыр йөк тарткан, кара тир агызган подстрочникны әзерләүче кеше билгесез булып кала, аның исеме бер генә тәрҗемә әсәрдә дә телгә алынмый, аның зур хезмәте бәяләнми. Миңа калса, мин подстрочникны башкаручыны тәрҗемәче дип, ә аның хезмәтеннән файдаланучы тәрҗемәче дип аталган шәхесне тәрҗемәнең редакторы дип атар идем.

Ахырда шуны да әйтәсе килә. Бездә күптәннән инде бер бик ялгыш фикер яшәп килә: имеш, танылган язучы, шагыйрь бер үк вакытта талантлы тәрҗемәче дә була ала. Шул хата фикердән чыгып, аларга тәрҗемә тапшыралар, соңгылары әх тә итмәстән, эшкә тотыналар, ә суканың төрәне тирәнрәккә керә башласа, әйдә шулай да ярар әле, болай да китәр әле, дип, чи калдырып китә башлыйлар. Аларның кайберләре әле дә әзер әсәрне тәрҗемә итү иҗат түгел, пүчтәк, җиңел генә, тир түкми генә акча эшли торган кәсеп дип уйлый. Ә бит тәрҗемә ифрат авыр эш, кайчакта тәрҗемәче авторга караганда да күбрәк тир түгә, күбрәк хезмәт, күбрәк вакыт сарыф итә.

Тәрҗемәнең сыйфаты, аның тулы кыйммәтлелеге иң беренче чиратта аны башкаручының кем икәнлегенә — аның осталыгына, талантына һәм, ниһаять, намуслылыгына бәйле.

Мин бу язмада бездәге тәрҗемәләрдә еш очрый торган берничә характерлы җитешсезлек турында әйтергә теләдем. Алар шактый. Калганнары турында башкалар үз фикерләрен әйтер дип уйлыйм.

**Рәис САФАРОВ.**

# МОҢНЫ АЧАР АЧКЫЧ БАРМЫ?

Муса Җәлилнең Хәсән Туфанга язган бер хатын укыйм: «Туфан! Мине бер нәрсә бик борчый. Син бу мәсьәләне Татарстан союзы правлениесенә куеп чиш әле: ГИХЛ (Литгосиздат)ның СССР Халыклары иҗаты секторы татар әдип-шагыйрьләрен русчага тәрҗемә итеп чыгарганда очраклы рәвештә эш күрә: үз планын бер дә сезнең белән тикшерми.

Мәсәлән, Әх. Ерикәйнең шигырьләр китабы икенче мәртәбә русчага күчерелеп чыгарыла. Әйтерсең, нинди зур татар шагыйре, чиратсыз-нисез башлап аны һәм икенче мәртәбә, зур күләмдә тәрҗемә итәләр. Ә Такташ, Туфан Фәез (Әхмәт Фәйзи.— Л. Л.), Муса, Баттал, Кәрим — берсе дә чыкканы юк...»

Хаттан аңлашылганча, моннан илле ел элек тәрҗемә өлкәсендә хәл әнә шулай булган. Ә хәзер?

Дөресен генә әйткәндә, Җәлилне борчыган проблема бүгенге көндә дә хәл ителмәгән. Шул ук Такташны, Туфанны, Әхмәт Фәйзине, Фатих Кәримне генә алыйк: аларның әсәрләрен әле һаман да ил күләмендә яңгырата алганыбыз юк. Тукай һәм Дәрдмәнд турында әйтеп торырга да кирәкми — әсәрләренең русчага тәрҗемә кылынганнары әллә ни тел шартлатырлык түгел. Бәлкем, бүгенге татар шагыйрьләрен, язучыларын бөтен ил беләдер?..

Әйе, тәрҗемә — бүгенге татар әдәбиятының иң авырткан җире, мөгаен. Дөрес, республикабыздагы рус газеталарында һәм үзәк матбугатта шагыйрьләребезнең һәм язучыларыбызның әсәрләре әледән-әле күренгәләп тора. Ләкин кемнәрнең әсәрләре тәрҗемә ителә һәм ул тәрҗемәләрнең сыйфат дәрәҗәсе нинди? Менә хикмәт нәрсәдә!

«Советская Татария» һәм «Вечерняя Казань» газеталарын гына алыйк. Игътибар белән карасак, әдәби сәхифәләрдә гел бер үк авторларның әсәрләрен күрербез. Тәрҗемәчеләре дә бер үк кешеләр диярлек. «Вечерняя Казань»да еш кына бик матур кечкенә сәхифә — «Чебурашка» бирелә. Әмма монда да шул ук хәл: бер санда Шәүкәт Галиев шигырьләре булса, икенчесендә — Роберт Миңнуллин... Юк, мин әлеге хөрмәтле балалар шагыйрьләренең әсәрләре басылуга каршы түгел. Һич юк. Әмма бит әдәбиятыбызда балалар өчен язучылар бу ике шагыйрь генә түгел. Хәкимҗан Халиков, Рөстәм Мингалимов, Равил Фәйзуллин, Марсель Галиев, Мөдәррис Әгъләмов... кебек шагыйрьләрне кая куярга? Ахыр килеп, бу эш тәртипкә салынырга тиештер ләса? Күз-колак булу дигән нәрсәләр дә бар бит әле дөньяда...

Бер төр шагыйрьләр бар. Иң элек алар бер үк шигырьләре белән республикабыздагы һәм чит өлкәләрдәге район газеталарын «яулап» алалар. Аннан соң шул иҗат җимешләрен әвеш-тәвеш китереп, кая-кирәк алай русчага әйләндерәләр дә (кайчакта берәр хөрмәтле әдибебезнең кәефе яхшы чагын туры китереп, аннан хәерле юл теләгән сүз башы яздырып та алалар) төрле газета-журналларга юллыйлар. Озакламый кайбер әсәрләре басылып та чыга. Шуннан соң, «ил күләмендә танылган» шагыйрьләребез республикабыздагы газета-журнал редакцияләренә төргәк-төргәк «әсәрләр»ен китерәләр. Китереп кенә калмыйлар:

— Минем әсәрләрем фәлән журналда русча басылды. Мине тегендә беләләр, монда беләләр! Карагыз аны! — дип өркетеп-янап чыгып китәләр. Редакциядә эшләүче абзыкайлар әлеге «атаклы шагыйрьләр»нең әсәрләрен бер укып карыйлар, күзлекләрен төзәткәләп (күзлекләре булмаганнары баш кашып ала) тагын бер кат күз йөртеп чыгалар да... чиле-пешле әсәрләрне читкәрәк этәрәләр.

Кызганычка каршы, бар шундый «елгыр» шагыйрьләр. Бар. Рус укучысы шулар иҗатына карап, татар әдәбияты турында тискәре фикер йөртми дип кайсыгыз әйтә ала? Җә?

Уйланасылар бар әле...

Мин аварча сөйләшә дә, укый да белмим. Әмма Рәсүл Гамзатов иҗатын азмы-күпме беләм дип әйтә алам. Яратам, дисәм дә ялгыш булмас. Әмма дөньяда Рәсүл Гамзатов дигән шагыйрь бар икәнен миңа иң элек кем әйтте соң? Әлбәттә, рус шагыйрьләре, рус тәрҗемәчеләре: Н. Гребнев, Я. Козловский, В. Солоухин, Ю. Нейман, Ю. Мориц. «Алар аварча белмиләр, әмма безнең туган җирне, безнең культураны, безнең телне тоя беләләр»,— дип язган иде Р. Гамзатов «Литературная газета»да басылган бер мәкаләсендә.

Күрәсең, тәрҗемәче өчен телне белү бик үк мәҗбүри түгел. Телне тоя белү — иң мөһиме!

Рәсүлнең артында таулар,
Биек-биек таулар ич...
Таяныч кирәк язганда,
Минем кайда таяныч?

Сибгат ага Хәкимнең әлеге кыска, әмма гаять мәгънәле шигыренең асылын аңлый башладым шикелле...

Үз тәрҗемәчеңне табу — шагыйрь өчен зур бәхет булса, тәрҗемәче өчен дә үз шагыйреңне табу бәхеттер!

Роберт Бернсны мин Маршаксыз, Уолт Уитменны Чуковскийсыз, Поль Верленны Пастернаксыз һич кенә дә күз алдыма китерә алмыйм. Бармы соң безнең шагыйрьләрнең шундый бәхетләре?

Рәшит Әхмәтҗанов, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмов, Зиннур Насыйбуллин кебек талантлы шагыйрьләребезнең әнә шундый бәхеткә лаек булуларын телим мин, аларның әсәрләрен дә рус телендә күрәсе килә ләбаса безнең! Хәер, Зөлфәтнең шигырьләре Мәскәү шагыйре Марат Акчурин тәрҗемәсендә аерым җыентык булып, Татарстан китап нәшриятында басылып чыгып килә диләр...

Кайвакыт, тәрҗемә әсәрләрен укыганда шундый парадокска тап буласың: эчтәлек бар, форма да бар, әмма шигърият юк! Моның өчен тәрҗемәченең оста, талантлы булуы гына җитенкерәмидер күрәсең. Шушы уңайдан, Әхмәт Фәйзинең бүгенге тәрҗемәчеләр өчен өлге булып торырлык мондый фикере бар: «Теге яки бу шагыйрьнең бер генә шигырен булса да тәрҗемә итү өчен, шигырьнең эчтәлеген белүдән тыш: 1) аны язган кешенең бөтен иҗат йөзен, шәхесен, темпераментын, хыял-омтылышларын, иҗат биографиясен һәм 2) бу массаның, үз нәүбәтендә, шагыйрьнең шәхесенә һәм поэзиясенә мөнәсәбәтен яхшы белергә кирәк».

Үз «казаныбызда кайнаучы» шагыйрь-тәрҗемәчеләр Рөстәм Кутуй, Равил Бохараев, Николай Беляев, Вячеслав Баширов, Борис Сулимов, Роза Кожевникова, Эльмира Блиновалар әнә шул закончалыкны аңлап эш итсеннәр иде дигән якты теләк туа...

Яхшы шагыйрьнең әсәрләрен талант дәрәҗәсе тигез булган, яисә аннан да талантлырак булган шагыйрь яки тәрҗемәче тәрҗемә итәргә тиеш. Шул чакта гына әсәр отачак, мең мәртәбә отачак!

Моң. Бу сүзне русчага төгәл тәрҗемә итеп булмый диләр. Татар шигърияте дә, прозасы да моңнан тора. Алайса, шигъриятебезне дә, прозабызны да русчага тәрҗемә кылып булмый диган сүз түгелме соң бу?

Ләкин, «тырышкан — табар, ташка кадак кагар» ди мәкаль. Килер көнгә ышаныйк: кем дә булса моңга ачкыч ярагыр әле.

**Ләбиб ЛЕРОНОВ.**

## Редакциядән:

Без әнә шундый ике хат алдык. Чынлап та, укучыларыбыз бик өлгергән мәсьәлә күтәрәләр, үтә җитди проблемага игътибар итүне сорыйлар.

Шуңа күрә редакция бу саннан тәрҗемә турында (татарчадан русчага) сөйләшү башлап җибәрә. Бу сөйләшүдә язучылар һәм белгечләр генә түгел, киң катлау укучылар да катнашыр дип өметләнәбез. Тәрҗемә турындагы бу сөйләшүгә юнәлеш бирү өчен түбәндәге сораулар куела:

— Сезнеңчә, теге яки бу әсәрне бүтән телгә тәрҗемә итү процессында иң мөһиме нәрсә булырга тиеш: эчтәлекне тулы килеш саклаумы, милли колоритны бирүме, метафораларны төгәл тапшырумы һ. б.?

— Тәрҗемәнең уңышлы килеп чыгуын нәрсә хәл итә: тәрҗемәченең талантымы, осталыгымы, халыклар тарихын, культурасын, телен белүме һ. б.?

— Сез ничек уйлыйсыз: тәрҗемә оригиналның бөтен байлыгын биреп бетерә аламы? Тәрҗемә ителми торган (тәрҗемәгә бирелмәүче) шагыйрьләр яки әсәрләр буламы?

— Ике төрле тәрҗемә бар: оригиналдан һәм подстрочник аша. Боларга мөнәсәбәтегез ничек? Кайсын кулайрак күрәсез һәм ни өчен?

— Подстрочникларга мөнәсәбәтегез ничек? Алар нинди таләпләргә җавап бирергә тиеш? Ул таләпләр бүгенге подстрочникларыбызда үтәләме?

— Сезнеңчә, шагыйрьнең чын тәрҗемәчесе кем: подстрочник ясаучымы, әллә әсәрне шигъри калыпка кертүчеме?

— Г. Тукайның, Г. Ибраһимовның, Дәрдмәнднең, Һ. Такташның, М. Җәлилнең, Х. Туфанның русчага тәрҗемәләре турында фикерегез ничек?

— Бүгенге шагыйрьләребезнең русча чыккан китапларының тәрҗемә сыйфатлары турында нәрсә әйтә аласыз?

— Бүгенге прозаикларыбызның русча чыккан китапларының тәрҗемә сыйфатлары турында нәрсә әйтә аласыз?

— Илебездәге милли әдәбиятларны баетү, үзара якынайту чарасы буларак киләчәктә тәрҗемә эшен яхшыртуда нинди мөмкинлекләр күрәсез?

Хөрмәтле укучылар!

Сездән кызыклы җаваплар, мәкаләләр, хатлар көтәбез!

# БӨЕК ШАГЫЙРЬНЕҢ ҮЛЕМСЕЗ ӘСӘРЕ

Татар әдәбияты тарихында 1983 ел Кол Гали елы булды. Шагыйрьнең тууына — 800, әсәренең язылуына 750 ел тулу татар халкының гына түгел, чын мәгънәсендә барлык совет халкының культура бәйрәменә әверелеп, киң күләмдә билгеләп үтелде.

Урта гасырның бөек шагыйре Кол Гали халык күңелендә тагын да тирәнрәк урын алды. «Кыйссаи Йосыф» поэмасы күп гасырлы татар әдәбиятының олы юлында аерым бер маяк булып балкуын дәвам иттерә.

Кол Гали һәм аның «Кыйссаи Йосыф» поэмасы халык язмышыннан беркайчан да аерылмаган. Аны «Игорь полкы турында җыр», «Юлбарыс тиресе ябынган батыр» кебек уникаль әсәрләргә тиңләштерергә мөмкин. «Кыйссаи Йосыф»ның мәшһүрлеге шагыйрь, галим һәм мәгърифәтче Габрәхим Утыз-Имәнине дә яңа иҗат юнәлешенә этәргән. Ул, әсәрнең күп төрле күчермәләрен чагыштырып, аның яңа редакциясен төзегән. Моны, хәзерге термин белән әйткәндә, танкыйди нөсхә дип тә әйтә алабыз. Бу нөсхә «Кыйссаи Йосыф»ның Казан университеты типографиясендә 1839 елдан басыла башлаган барлык басмаларына нигез булган. Ниһаять, Г. Утыз-Имәни тексты поэманың Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән яңа басмасына да нигез итеп алынган. Әсәрне басарга әзерләүче филология фәннәре кандидаты Ф. С. Фәсиев. Махсус редакторы, профессор М. Г. Госманов. Рәссамы ТАССР-ның халык художнигы Т. Г. Хаҗиәхмәтов. Нәшрият редакторы Р. Н. Даутов.

«Кыйссаи Йосыф»ның бу басмасы шагыйрьнең тууына — 800, әсәрнең язылуына — 750 һәм аның беренче нәшер ителүенә 145 ел тулган вакытта дөнья күрде. Урта гасыр төрки поэзиясенең бөек әсәрләреннән берсе булган бу поэманың яңадан басылып чыгуы аның юбилее белән генә бәйләнмәгән. Бу басма — совет чорында эчтәлеге белән социалистик, формасы белән милли төстә чәчәк аткан татар совет культурасы һәм әдәбият белеме үсешендәге казанышларның көзгесе ул. Китап һәркемгә тәэсир итәрлек эстетик көчкә ия. Рәссамның бу нечкә, нәфис эше матбугат битләрендә дә югары бәяләнде.[1]

Шагыйрьнең моннан 750 еллар элек язылган әсәре, әйе, Г. Утыз-Имәни эшкәрткән текст нигезендә басылган. Ләкин бу элеккe басманы һич тә кабат нәшер итү генә дигән сүз түгел. Ул — Урта гасыр төрки ядкарьләрне бастырып чыгаруда тюркология фәнендә үзенә бер үзенчәлекле күренеш. Әсәрнең тексты хәзерге татар графикасы нигезендә аерым өстәмә хәрефләр алу юлы белән бирелгән. Икенче як каршы биттә, ягъни янәшәдә поэманың Ф. Фәсиев, А. Нуриева һәм Ә. Исхак тарафыннан эшләнгән хәзерге татар әдәби телендәге бирелеше китерелгән. Болардан соң әсәрнең шагыйрь Ә. Исхак башкарган юлга-юл русча тәрҗемәсе урнаштырылган. Әсәргә кереш сүз татар һәм рус телләрендә язылган. «Кыйссаи Йосыф»ның күп санлы кульязмаларының һәм матбага басмаларының тасвирламалары рус телендә эшләнгән. Ахырда бай библиографик мәгълүматлар китерелгән. Болар барысы да әсәрне басарга әзерләүче филология фәннәре кандидаты, тел галиме Ф. Фәсиев тарафыннан башкарылган.

«Кыйссаи Йосыф» кебек борынгы әдәби истәлекләрне бу рәвештә бастырып чыгару әдәбиятыбыз җәүһәрләре белән кызыксынучылар санын тагын да арттыра һәм дөнья әдәбияты укучылары арасында таралыр өчен дә зур мөмкинлек бирә. Күп милләтле совет халыкларының үткәндәге һәм хәзерге классика үрнәкләре, шулай итеп, рус теле аша бөтен дөнья әдәбияты мәйданына чыга һәм гомум кешелек культурасын баетуга зур өлеш кертә.

Белгәнебезчә, совет кешесенә кешелек җәмгыятенең күп гасырлар дәвамында тудырыла килгән прогрессив культура казанышлары белән танышу, алар белән

[1] Кара: Л. Елькович. Из вечного родника. Советская Татария. 1 марта 1984 г.; Р. Мөхәммәдиев. Рәссам күңелендә — шигърият. Социалистик Татарстан. 25 март, 1984 ел.

кораллану өчен барлык мөмкинлекләр тудырылган. Кешелек культурасы үсеше тарихында беренче булып, совет дәүләте дөнья әдәбияты классикасының 200 томлык иң яхшы үрнәкләрен бастырып чыгарды. Алар арасында дүрт дистәгә якын татар язучыларының да әсәрләре урын алган. Анда татар әдәбияты аңа нигез салган шагыйрь Кол Гали исеме белән ачыла.

СССР Фәннәр академиясе член-корреспонденты Г. Ломидзе «Литературная газета»да Кол Галигә багышланган «Сүнмәс нур» исемле мәкаләсендә болай язды: «Урта гасырның бөек шагыйре Кол Галинең гуманистик традицияләре төрки телле культураларның формалашуына гаять зур йогынты ясады. Ул болгар-татар язма поэзиясенә нигез салучы булды... Кол Гали бөек шагыйрь, фикер иясе, бөтен яктан мәгърифәтле кеше булган. Аның гүзәл «Кыйссаи Йосыф» поэмасы — дөнья әдәбиятының бөек шедеврларыннан берсе» (1984, 15 февраль).

Кол Галинең төрки әдәбиятлар тарихында тоткан югары урыны аның иҗатын алга таба тагын да киңрәк өйрәнүдә татар совет әдәбият белеме алдына яңа проблемаларны хәл итү бурычын китереп бастыра. Хәзер инде боз кузгалды. Шагыйрьне һәм аның иҗатын өйрәнү юлында зур хезмәтләр дә күренә башлады. 1979 елда Мәскәүнең «Наука» нәшриятында Н. Хисамовның «Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ы» дигән монографиясе басылып чыкты. Әлеге хезмәт матбугатта уңай бәя алды. Әсәр сюжетының ерак чыганакларын һәм шагыйрь алып килгән яңалыкларны билгеләүдә, иҗат ителгән мохитен ачыклауда һәм әсәрнең проблематикасын, аның халык авыз иҗаты белән динамик бәйләнешен күрсәтүдә Н. Хисамовның мактаулы эш башкарганлыгын әйтергә кирәк. Ниһаять, нур өстенә нур дигәндәй, «Кыйссаи Йосыф» поэмасының инде телгә алынган яңа басмасы укучыларга җиткерелде.

Әсәрне бастырырга әзерләүче Ф. Фәсиев, әлбәттә, аның төрле гасырларга караган күп санлы кульъязмаларын чагыштыру юлы белән тәнкыйди нөсхәсен төзүне, ягъни ядкарьнең телен язылган заманындагы хәленә якынайтуга ирешүне бурыч итеп алмаган, бәлки транскрипция юлы белән эш иткән — әзер тексттагы сүзләрнең нечкәлекләренә кадәр әйтелешләрен бирүне максат итеп куйган.

Поэманың яңа басмасына һәм аның транскрипциясенә нигез итеп алынган Г. Утыз-Имәни нөсхәсе турында өстәп, укучыларга берничә сүз әйтәсе килә. Г. Утыз-Имәни күп санлы оригинал шигъри һәм проза әсәрләре иҗат итү белән бергә, ул, галим һәм мәгърифәтче буларак, Көнчыгыш классикасының гарәп, фарсы, төрки телләрендәге бик күп әсәрләрен күчереп язган, яңа редакцияләрен әзерләгән, аларга аңлатмалар төзегән. XVIII йөз ахырында — XIX йөз башында Казанда киң колач алган рус ориенталистикасы тәэсирендә татарларда да Көнчыгыш классикасын өйрәнү мәктәбе барлыкка килә. Аның башында зур культура эшлеклесе И. Хәлфин тора. Ул бу эшкә күп телләрне белгән, зур тәҗрибәле галим Г. Утыз-Имәнине тарта, һәм соңрак Р. Әмирханов кебек мәгърифәт эшлеклеләре дә җәлеп ителә. Нәкъ шул вакытларда И. Хәлфин — «Дастаннар»ның, Г. Утыз-Имәни — «Кыйссаи Йосыф»ның, Р. Әмирханов «Кыйссасел-Әнбия»нең күп санлы кульъязмаларын чагыштыру нигезендә яңа редакцияләрен төзиләр, һәм алар заманы өчен югары сыйфатлы эшләнештәге әсәрләр булып басылып та чыгалар.

Ф. Фәсиев «Кыйссаи Йосыф»ның яңа басмасын Г. Утыз-Имәни редакцияләгән нөсхә буенча транскрипцияләгән һәм катлаулы, бик мәшәкатьле зур эш башкарган. Г. Утыз-Имәни искәрмәләренә таянып ихтирам белән карап, аларны күрсәтә бару белән бергә, контекстның эченә кереп, һәрбер сүзнең мәгънәсен аңларга тырышкан һәм үзе дә күп аңлатмалар биргән. Димәк, әсәрнең тексты мөмкин кадәр төгәл, фәнни нигездә эшләнгән дип әйтеп була. Борынгы һәм Урта гасыр язма ядкарьләренең телен, бигрәк тә әдәби кулланыштан төшкән, хәтта җанлы сөйләм телендә һәм аның диалектларында эзләрен бик авырлык белән табарга мөмкин булган иске-архаик сүзләрнең мәгънәләрен ачу зур күнегү, тәҗрибә таләп итә. Әлбәттә, моннан 750 еллар элек язылган әсәрдәге борынгы барлык сүзләрнең мәгънәләре ачылып беткән дип әйтергә омтылу ашыгыч фараз итү булыр иде. Мәсәлән, Г. Утыз-Имәнидә сүзнең бер төрле, Ф. Фәсиевтә икенче төрле язылу очраклары бар, әмма алар аңлатмалардан читтә калган. Янсә Г. Утыз-Имәнидә төрлечә язылып та, бер төшенчәне аңлаткан сүзләрне язылышы белән охшаш икенче сүзнең мәгънәсенә иярәп аңлату бар. Мәсәлән, ия, иясе сүзе:

> Мөлек вә дәүләт ийәси булдачи сән,
> (дәүләт һәм мөлкәт иясе булачаксың)
> (174).[1]

Монда иясе (хуҗасы) дөрес язылган. Ләкин текстта гарәп хәрефләре белән язылышта «иясе» сүзенә якын «үс-үс, ыс, -ес-эс» очрый. «Аң, хәтер, фикер, акыл» мәгънәләрендәге бу сүз күп төрки телләрдә яши. Ф. Фәсиев аларны күп урында «ия» сүзе белән бәйләп, «иясе» дип яза. Зөләйханың: «Эстәдегем Мисыр и (йә) си!» — дәйүр имди (385), — дигән юл «Теләгәнем — Мисыр хөкемдары имди», диелгән. Биредә Йосыфның Мисырда акыллы кеше, акыл

[1] Яңа басмадан китерелгән мисаллардан соң җәяләр эчендә строфа саны гына күрсәтелә.

иясе булуы хакында сүз бара. Алга таба тикшеренүче шул ук сүзләрне үз мәгънәләрендә «усы» (һушы) (848) дип яза.

Борынгы төрки сүз «укъ», «укъды»ны уку-укыды сүзе белән тәңгәл кую да аның мәгънәсен ялгыш аңлауга китерә.

Иа Йусеф, сән күзгүйә, бактыңмиди,
Күзгүдә күркең күрүб укдыңмиди (187).

Икенче юлдагы укдыңмиди сүзе татарчада «бик масайдың», русчада «не восхитился ли» дип бирелгән. Сүз масаю, горурлану хакында түгел, Йосыфның үз матурлыгын, аның кыйммәтен аңлау, бәһасен белү турында бара: укъдыңмиди — аңлаган идеңме, төшенгән идеңме! Башка урында да бу сүзнең асыл мәгънәсе читләтеп үтелгән.

Кол Гали һәрбер сүзнең мәгънәсенә тирәнтен төшенеп, аларның һәркайсын урынлы куллана белгән. Агалары Йосыфны сатарга булгач, Малик Догар килешү кәгазе язуны сорый.

Къәбаләсен вирмәгә йазар имди (220),—

дигән юл татарча: һәммәсе дә кул куярга әзер имди, русча: начали писать бумагу о сделке, дип бирелгән. Термин буларак, къәбалә тарихи яктан бик мөһим социаль мәгънәгә ия. Ул Йосыфның кол итеп сатылуы һәм аның киләчәктә дә бәйле булырга тиешлеген аңлата. Ләкин бу сүз тикшеренүдә игътибарга алынмаган һәм аңлатма да бирелмәгән.

Сере ачылмаган тагын бер сүзгә тукталасы килә. Ул — шагыйрьнең идеалы, әсәрнең идея юнәлеше һәм Йосыф образының асылы хакында сөйли торган сүз. Әгәр дә тикшеренүдә һәм әсәр текстының тәрҗемәләрендә әлеге сүз ачылмаган икән, шагыйрьнең эстетик идеалы да, әсәрдәге үзәк фикер дә, Йосыф образының иң мөһим сыйфаты да укучыга тулы килеш җиткерелмәгән диган сүз.

Йосыф — әсәрдә баш каһарман, идеаль образ. Акыл иясе. Уйлап эш йөртә. Акыллылыгы өчен дә аңа дәүләт белән идарә итү тапшырыла. Бу — геройның төп сыйфаты, аннан башка Йосыф образы тулы була алмый. Шагыйрь дә «Гакълы кямил, гыйльме — хикмәт кямил белүр» (684),— дип, Йосыфның акыллылыгына басым ясый. Яңа басма текстында ул төп сыйфат ачылмаган, бөтенләй башка сүз белән алмаштырып аңлатылган. Автор Йосыф портретын ун төрле сыйфат белән характерлый. Йосыфның үрнәк, идеаль хөкемдар булуы, әлбәттә, беренче сыйфатта ачыклана.

Әүвәл улдыр: кадде яхшы, зариф үзлү (425),— дигән юлның татарчасы: беренчедән, буе зифа, сылу үзе; русчасын: во-первых, стан стройный, сам — верх совершенства,— дип бирелгән. Шулай итеп, Йосыф образының төп сыйфаты «буе зифа, сылу үзе» сүзләренә кайтып кала.

«Кадде яхшы, буе-сыны матур» дигәннән соң, «зариф үзлү» дигән ике сүзне «зирәк акыллы» дип аңлатканда, барысы да үз урынында булыр иде.

Шәех Сөләйманда (Лөгате чыгтай вә төрки госмани, 320 б.), борынгы төрки сүзлектә (ДТС, с. 394) «үз»—«аң», «акыл» дип бирелгән. Кайчандыр Җаек елгасының түбән агымында урнашкан, соңыннан хәрабә хәленә килгән Сарайчык (Сарайчук) шәһәрлегендә табылган кувшин тышына XIV йөз һөнәрчесе Йосыф Баласагунның «Котадгу билиг»еннән алынган «укуш күрке тел ул» дигән сүзләрне «Бу үз күрке тел ул» дип төрки-татарча язган. Татарның XVI йөзгә караган «Мөнәббиһат» әсәрендә автор «Котадгу билиг»тәге «укуш күрке тел ул» сүзләрен «үзнең күрке тел булыр» дип бирә. Мәүлә Колыйдан бер мисал китерергә мөмкин:

Ул мивәнең ләззәтендин мәст улубән
Үздин китеп, иссез булып ятсам ирди.

Димәк, «үз»—«акыл», «аң» дигән сүз. Шагыйрьнең Йосыфны «зариф үзлү» дию «зирәк акыллы» дигән сүз булып чыга. Болай булса, Йосыф образының төп сыйфаты, шагыйрь язганча, үз урынында сакланган була.

Күргәнебезчә, «Кыйссаи Йосыф»ның яңа басмасы транскрипциясендәге аерым сүзләргә башкарачак килү һәм төрки телләрдәге фактлар белән чагыштыру аша аларның мәгънәләрен төрле яклап ачу мөмкинлекләре әлегә кала бирә. Шулай да поэма текстына карата галим тарафыннан эшләнгән һәм кабул ителгән транскрипцияне нигездә яхшы дип танырга кирәк. Ләкин автор аннан файдалануда даимилекне саклап бетерми. Шунлыктан, әсәр битләрендә бер үк сүзләр төрлечә язылыш алган, ә сәбәбе искәрмәдә аңлатылмаган. Мәсәлән, йимәк — ашау сүзе: йиден, йемеш (159), корд йэмеш (149). Бети — язу сүзе: бөти (397), бити (396), бети (395). Йир — җир сүзе: йир (533), йэр (403).

Калын һәм нечкә сузык авазлар арасындагы «э-е» авазын күрсәтү өчен сүз уртасында «э» хәрефен куллануны да отышлы дип булмый: мәсәлән, «кәрәк — кирәк» дип түгел, «кэрәк» дип язу; «мән» янсә «мин» дип түгел, «мэн» дип бирү. Бу хәл тюркология фәнендә кабул ителгән халыкара транскрипция принципларына да ятышып бетми. Транскрипция өчен калын «къ — гъ» хәрефләрен алу аерым сүзләрнең катлаулы язылышларын җиңеләйтергә тиеш иде, ләкин ул тиешенчә үтәлмәгән.

Сүзләрнең язылышындагы мондый төрлелек әсәрнең текстын фәнни максатта куллануны һәм мәктәп практикасында укучылар белән китап өстендә эш алып

баруны да кыенлаштыра. Фән өчен бигрәк тә борынгы һәм урта гасыр әдәби ядкарьләренең теле гыйльми яктан ачык эшләнгән транскрипция принципларына туры китереп бирелергә тиеш. «Кыйссаи Йосыф» поэмасының басылып чыгуы, димәк, татар тел һәм әдәбият белеме алдына хәл ителәсе яңа бурычлар да куя.

Болгар-татар язма поэзиясенә нигез салган, аның чишмә башында торган үлемсез «Кыйссаи Йосыф» поэмасы татар теленең үсү тарихын, яшәү эволюциясен аңлау өчен дә ышанычлы чыганаклардан санала. Бу әсәрнең телен дөрес күрсәтмичә һәм өйрәнмичә торып, татар теленең күптән көтелгән тарихи грамматикасын төзүне дә күз алдына китерүе кыен. Димәк, поэманың теле, лексикасы тарихи яссылыкта төрле яктан тирәнтен өйрәнелергә тиеш. Моның өчен иң беренче «Кыйссаи Йосыф»ның фәнни нигезгә корылган тәнкыйди нөсхәсен булдыру шарт. Күренгәнчә, бу юнәлештә инде зур эш башкарылды.

Тел галиме һәм әдәбиятчы Җ. Алмаз «Кыйссаи Йосыф»ны киң планда өйрәнүгә күп еллар вакытын бирде: ул әсәрнең борынгы саналган күп кенә күчермәләрен чагыштыру нигезендә аның тәнкыйди нөсхәсен төзеде, поэманың теленә грамматик һәм морфологик анализ ясады, сүзлеген төзеде, русчага тәрҗемә итте, хәзерге әдәби телгә күчермәсен эшләде, әсәрне тикшеренүгә багышланган зур кереш язды. Рус телендә башкарылган һәм төгәлләнгән күләмле бу хезмәт хәзерге вакытта Татарстан Берләштерелгән дәүләт музееның әдәбият бүлеге фондында саклана. «Йосыф китабы»н төрле яклап өйрәнүгә багышланган бу әзер хезмәтне Татарстан китап нәшрияты, Язучылар союзы һәм Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты күз уңында тоталар дип ышанырга кирәк.

Бу урында язучы Зәйни Шаһимаратовның да гыйльми хезмәтләрен искә алырга кирәк. Ул күп кулъязмалар нигезендә «Кыйссаи Йосыф»ның шулай ук тәнкыйди нөсхәсен төзегән иде.

Шунысын да әйтик, Ф. Фәсиев «Кыйссаи Йосыф»ны дөньяга чыгару юлында үзе дә зур мәктәп узды, күп тәҗрибә туплады, һәм ул поэманың яңа басмасын әзерләүдә авыр, мәшәкатьле, шуның белән бергә, тирән хөрмәткә ия булган эшен дәвам иттерер дигән өмет бар.

Татар тел, әдәбият белеме генә түгел, бөтен тюркология һәм совет әдәбият фәне дөнья классикасының гүзәл шедеврларыннан булган «Кыйссаи Йосыф» поэмасының хәзерге фән ирешкән казанышлар дәрәҗәсендә башкарылган югары сыйфатлы яңа басмасын көтә.

**Шакир АБИЛОВ.**

# ПРОФЕССОР ТАҺИРҖАНОВ

Габдрахман Таһир улы Таһирҗанов — Көнчыгышны өйрәнү фәненә Татарстан җире биргән күренекле шәхесләрдән. Ул фарсы теле һәм әдәбиятын, гарәп телен, урта гасыр төрки әдәбиятын тикшерү өлкәсендә онытылмаслык эшләр башкарды. Татар әдәбияты, әзербайҗан, үзбәк һәм төрекмән әдәбиятларының тарихын өйрәнгәндә аның хезмәтләре кыйммәтле таяныч булып торалар.

Татар укучылары өчен Г. Таһирҗанов Кол Гали һәм Фирдәүси поэмаларын чагыштырып тикшергән һәм «Кыйссаи Йосыф»ны өйрәнү эшен конкрет нигезгә куйган, татар әдәбиятының борынгыдан килә торган чишмәләрен ачыклаган, урта гасыр төрки әдәбиятының тарихи панорамасын яктырткан, төрки әдәбиятлар үсешендәге үзара йогынтының тарихи-диалектик алмашынышын күрсәткән киң карашлы һәм тирән мәгълүматлы галим буларак кадерле. Әзербайҗаннар исә аны Низаминың тормышы һәм иҗатына кагылышлы бәхәсле мәсьәләләргә ачыклык кертүче, Низаминың төрки шигырьләре дә булуы хакындагы гөманның фәнни нигезен ныгытучы дип якын күрәләр.

Күренекле галим үзенең туган республикасы белән һәрвакыт тыгыз элемтәдә яшәде. Җәйләрен аның Ленинградтан Казанга һәм туган районы Апаска кайтып йөрүләре ял итү һәм кунак булу өчен генә түгел, галимнәр, язучылар, рәссамнар, студентлар белән аралашу өчен дә уңайлы мөмкинлек иде. Габдрахман ага дусларын, яшьләрне Көнчыгыш әдәбиятлары тарихыннан яңа мәгълүматлар белән баета, үзе исә туган халкының сәнгате һәм фәне өлкәсендәге яңалыклар белән танышып кайта иде.

Г. Таһирҗанов 1907 елның 7 февралендә Татарстанның Апас районы Морзалар авылында туган. Башлангыч белемне үзенең атасыннан ала, җиде яше тулгач исә, аны Урта Балтай мәдрәсәсенә укырга бирәләр. Мәдрәсәнең үтә кырыс шартларында ул гарәпчә китаплар укырга, язарга һәм арифметикага өйрәнә.

1917 елның Октябрь революциясеннән соң әлеге мәдрәсә урынына совет мәктәбе ачылып, Габдрахман ике ел шунда укый. Яңа дөньяны балалар татарча «Марсельеза» һәм «Интернационал» өйрәнеп каршылыйлар. «Без аны «Тәфтиләү» көенә җырлый идек»,— дип искә ала галим үзенең ул көннәрен. Бу чорда аның яратып укыганы Каюм Насыйриның «Фәвакиһел җөләса», «Җәваһирел хикәят», «Әбүгалисина», «Кырык вәзир» китаплары һәм «Тутыйнамә», «Хайваннар турында әкиятләр һәм мәкальләр», «Таһир-Зөһрә», «Буз егет» кебек әсәрләр була.

Г. Таһирҗанов эш сөючән, тырыш гаиләдә тәрбияләнеп үсә. Аның әтисе оста мич чыгаручы, бакчачы һәм коө казучы була. Авыл кешеләренең байтагы ул чыгарган мич һәм ул казыган коеларның рәхәтен күргән. Яшь Габдрахман да малай чактан төннәрен ат көткән, көндез печән чапкан, урак урган. Тумышы һәм тәрбиясе аны гаять игелекле һәм сәләтле иткән. Эш сөючәнлек һәм нечкә акыл, тыйнаклык һәм сабырлык, кешенең хәленә керүчән яхшы күңел һәм тырышлык — Габдрахман Таһирҗанов шәхесен аерып торган сыйфатлар шулар. Ул үзендә яшьтән үк тәрбияләгән кырыс әхлак кагыйдәләренә гомер буе тугры калды. Аның тамчы да шәраб капмавы берәүләр өчен искергән гадәт саналса, икенче берәүләр өчен матур үрнәк булды.

Габдрахман Таһирҗанов университетка гадәттәгедән соңрак укырга керде. 1937 елда, Ленинград университетының көнчыгыш факультетындагы гарәп бүлегенә кергәндә, аңа инде 30 яшь тулган иде. Әмма ул университетка барыннан да элек гарәп теле һәм гарәп хәрефендәге кулъязма китап өлкәсендә әзлекле һәм аңлы рәвештә тупланган җитди белем запасы алып килде. Студент булганчы ук ул үзенең туган татар теле

өстенә күп кенә төрки телләрне үзләштереп, шул телләрдә сөйләшү генә түгел, аларның әдәби нормаларын да өйрәнеп өлгергән иде. Аның ул белемнәренә безнең уртак остазыбыз һәм иран филологиясе кафедрасының ул чактагы мөдире, СССР Фәннәр академиясенең хәбәрче әгъзасы, профессор Александр Арнольдович Фрейман югары бәя бирде. Академик Игнатий Юлианович Крачковский 1938 елда икенче курс студенты Таһирҗановтан гарәп бүлегенең бөтен университет программасы буенча имтихан ала. Ә университетны Габдрахман Таһир улы гарәп филологиясе белгече булып тәмамлады, һәм аның фәнни, укыту эшчәнлеге дә Көнчыгышны өйрәнү фәненең нигездә шушы өлкәсенә багышланды.

Габдрахман Таһир улы Көнчыгыш факультетында 40 ел укытты. Борынгы авторларның әсәрләрен яхшы белүе, кульъязмалардагы гарәп язылышының төрләрен камил үзләштерүе, педагогик таланты шәкертләренә иксез-чиксез чыганак булса, хезмәттәшләре өчен ныклы таяныч булды. Студентларның язма эшләрен Габдрахман Таһир улы аерым бер игътибар белән һәм җентекләп укый иде, бер генә сүз дә, бер генә хәреф тә аның дикъкатеннән читтә калмый иде. Ул аудитория эшләренең күп булуын ярата иде.

Кульъязма китапны бик яхшы белгәнгә, Габдрахман Таһир улы еллар буе Көнчыгыш факультеты китапханәсенең кульъязмалар фондын өйрәнүгә чумып эшләде. Күп еллык хезмәтнең нәтиҗәсе буларак, 1962 елда аның «ЛДУ китапханәсенең Көнчыгыш бүлегендәге таҗик һәм фарсы кульъязмаларының тасвирламасы. 1. Тарих, биографияләр, география» дигән зур күләмле хезмәте басылды. Бу тасвирлама илебездәге һәм чит илләрдәге фәнни даирәләргә яхшы таныш.

Габдрахман Таһирҗанов фарсы әдәбиятын тикшерүгә дә кыйммәтле өлеш кертте. Рудаки, Фирдәүси, Низами кебек бөек фарсы шагыйрьләренең һәм фарсы телендә язган Һиндстан шагыйрьләренең иҗат биографияләрен ул аерым бер ярату белән, мавыгып өйрәнде. Рудаки турындагы монографик хезмәте, бөек шагыйрьгә карата фәндә урнашып, илле елга якын бәхәссез хакыйкать саналган фикерләрне нигездән юкка чыгарды һәм бу серле шәхеснең иҗатын яңача яктыртуы белән эпохаль әһәмият казанды. Фарсы-таҗик әдәбияты белгечләре аны шулай бәялиләр дә. Галим, университет тарихында беренче булып, «Һиндстандагы таҗик һәм фарсы әдәбияты» курсын эшләде һәм студентларга лекцияләр укыды, Көнчыгыш факультетында үзе укыткан курслар өчен гарәп һәм фарсы телләре буенча әсбаплар да аныкы. Ул СССР Фәннәр Академиясе бастырып чыгарган Фирдәүси «Шахнамә»сенең тәнкыйди текстын эшләүдә актив катнашты. Фирдәүсинең тормышы һәм иҗатына, «Шаһнамә»дәге героик өлешнең тарихи нигезенә, «Йосыф вә Зөләйха» поэмасының авторлыгына һәм Фирдәүсинеке дип хисапланган сатирага кагылышлы мәкаләләре белән ул галимнәр арасында киң билгеле.

Габдрахман Таһир улы кыргыз эпосы «Манас»ның ярлу һәм үсү тарихы, болгар-татар халкының килеп чыгышы, Кол Гали һәм Котб иҗаты турындагы хезмәтләре белән совет тюркологиясенә сизелерлек өлеш кертте. Ул XIV гасыр төрек поэмасының һәм XVI йөз үзбәк дидактик поэмасының җыелма тәнкыйди текстын төзеде. Идел буе болгарлары темасы һәм татар язуының тарихы белән дә әзлекле һәм тырышып шөгыльләнде.

Габдрахман Таһирҗанов Әзербайҗан Фәннәр академиясенең Низами исемендәге әдәбият институты белән, СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты, СССР Фәннәр академиясе Көнчыгышны өйрәнү институтының Ленинград бүлеге белән тыгыз хезмәттәшлектә яшәде. Мәсәлән, әле яңа гына «Татар әдәбияты тарихы»ның I томында аның тарафыннан җентекләп эшләнгән бөтен бер бүлек басылып чыкты. Борынгы татар әдәбияты белгечләреннән берничә галим соңгы елларда Ленинград университетына килеп, аның җитәкчелегендә фарсы теле һәм әдәбияты өлкәсендә үзләренең белемнәрен күтәрделәр. Казан галимнәре һәрвакыт аның юмарт һәм квалификацияле ярдәмен күрә иде.

Габдрахман Таһир улы Казаннан мәшһүр болгар-татар шагыйре Кол Галинең 800 еллыгы бәйрәменнән канатланып кайтты. Шулай зур иҗат планнары белән дәртләнеп эшләп торганда, 1983 елның 18 декабрендә ул кинәт вафат булды. Һәрдаим яшьләр, үзенең шәкертләре арасында булып, ул шат күңелле, хәрәкәтчән, зур гыйлем иясе, саф күңелле кеше иде.

Габдрахман Таһир улы безнең хәтердә кабатланмас һәм гүзәл кеше, олы галим булып саклана. Без кырык алты ел аның белән иңгә-иң яшәдек, якты истәлеге исә мәңге яшәр.

**М. Н. БОГОЛЮБОВ,**
профессор, СССР Фәннәр академиясенең
хәбәрче әгъзасы, ЛДУның Көнчыгыш факультеты деканы.

# *Культура тормышы көндәлеге*

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

16 январьда узган ачык партия җыелышында «Татар әдәбияты классиклары юбилейларын классик мирасны пропагандалау, укучыга эстетик тәрбия бирү чаралары итеп әзерләү һәм уздыру» дигән темага зур сөйләшү булды.

Г. Тукай, Г Ибраһимов, М. Җәлил һ. б. язучыларның юбилейларын уздыруга әзерлек турында Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе урынбасары Р. Хәмид, «Казан утлары» журналының баш редакторы Р. Харис, Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясе мөдире Ф. Миңнуллин сөйләде. Фикер алышуда язучылар Ә. Еники, Г. Бәширов, Н. Дәүли, М. Хәсәнов, Б. Гыйззәт, Язучылар союзы партия оешмасы секретаре Р. Мостафин чыгыш ясап, үзләренең эшлекле тәкъдимнәрен әйттеләр.

## ФАТИХ ӘМИРХАН ЮБИЛЕЕ

13 январьда Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында татар әдәбияты классигы Фатих Әмирханның тууына 100 ел тулуга багышланган тантаналы кичә булды. Бирегә республикабызның производство коллективлары вәкилләре, партия, совет, профсоюз, комсомол оешмалары вәкилләре, әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре, культура работниклары, тугандаш республикалардан кунаклар килгән иде.

Кичәне кереш сүз белән ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары, филология фәннәре докторы М. Х. Хәсәнов ачты.

Әдипнең тормыш һәм иҗат юлы турында Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин сөйләде.

Классик әдип юбилеена багышланган бу кичәдә ТАССР Верховный Советы Президиумы Председателе Ә. Б. Баһаветдинов, КПСС өлкә комитеты секретаре Р. К. Беляев, КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире Д. Х. Зарипова, фән һәм уку йортлары бүлеге мөдире Р. И. Әдһәмов катнашты.

14 январьда Казан дәүләт педагогия институтының Актлар залында Фатих Әмирханның тууына 100 ел тулу уңаеннан фәнни конференция булды. Аны Татарстан Язучылар союзы һәм Казан дәүләт педагогия институты оештырды.

Конференцияне институтның ректоры — филология фәннәре докторы, профессор М. З. Зәкиев ачты.

Фән докторлары Ф. М. Мусин, Р. И. Нәфиков, Ф. Г. Газизуллин, Я. И. Ханбиков докладлар сөйләделәр.

Аннары дүрт секция эшләде. Секцияләрдә «Ф. Әмирханның поэтик дөньясы», «Ф. Әмирханның дөньяга карашы һәм публицистик эшчәнлеге», «Ф. Әмирхан һәм СССР халыклары әдәбияты», «Ф. Әмирханның лингвистик һәм педагогик карашлары» дигән темалар бернечә тармакка бүлеп тикшерелде. Конференциядә барлыгы кырык лап доклад һәм белдермә тыңланды.

СССР Элемтә министрлыгы, татар әдәбияты классигы Фатих Әмирханның тууына 100 ел тулуга багышлап, художестволы конверт бастырып чыгарды.

Язучы портреты төшерелгән конверт Габдулла Тукай һәм Галиәсгар Камалга багышланган почта басмалары белән бер рәттә торачак.

## ХӨРМӘТЛӘҮ КИЧӘЛӘРЕ

20 декабрьдә Казанның Актерлар йортында шагыйрь Хәсән Туфанның тууына 85 ел тулуга багышланган зур әдәби-музыкаль кичә уздырылды.

Кичәне Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин ачты. Шагыйрь С. Хәким, язучылар Г. Бәширов, Ә. Еники һәм рәссам Р. Имашев Х. Туфан турындагы истәлекләре белән уртаклаштылар, шагыйрьләр И. Юзеев, Ә. Рәшитов, Р. Миңнуллин, Р. Зәйдуллин, Г. Моратов һ. б. аңа багышланган әсәрләрен укыдылар. Соңыннан Х. Туфан әсәрләреннән концерт булды. Кичәне шагыйрь Р. Гатауллин алып барды.

3 январьда язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында башкалабызның әдәби җәмәгатьчелеге Һади Такташның тууына 85 ел тулуны билгеләп үтте.

Кичәдә шагыйрьләр С. Хәким, И. Юзеев, Р. Харис, М. Әгъләмов, Зөлфәт, прозаик Ф. Бәйрәмова классик шагыйребезгә багышланган әсәрләрен укыдылар, аның иҗаты һәм тормыш юлы турында сөйләделәр.

Һ. Такташ шигырьләрен һәм җырларын РСФСРның халык артисты А. Арсланов, Татарстанның халык артисткасы В. Гыйззәтуллина, Татарстанның атказанган артисты М. Галиев башкарды. Кичәне шагыйрь Р. Гатауллин алып барды.

# ҖӘЛИЛНЕҢ ЛИРИК ПОРТРЕТЫ

Бөтен дөньяга танылган каһарман-шагыйрь Муса Җәлилнең батырлыгы темасы республикабыз рәссамнары иҗатында — тагын да камилрәк образлы сурәтләү чаралары эзләү җирлегендә яңара бара. Шушы юнәлештәге яңарышка Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премиясе лауреаты Валерий Скобеев та үзенчәлекле өлеш кертте. «Муса Җәлилнең лирик портреты»... Рәссамның 1980 елда иҗат ителгән әлеге әсәре, бер яктан, тарихи портрет традицияләрен дәвам иттерсә, икенче яктан, «калыплашу» чиреннән котылу мөмкинлекләрен дә раслап күрсәтә.

...Якты шигырьләр белән канатланган шагыйрь, әйтерсең, киң итеп ачылган тәрәзә каршында тора. Янәшәсендә — сөекле кызы Чулпан. Үзенең калкандай күкрәге белән ул кызын гына түгел, иминлектән аерылгысыз әкияти балачак илен дә саклап тора шикелле. Ата һәм бала... Аларның кояшлы йөзенә әлегә сугыш сөреме кагылмаган...

Рәссам үзенең картинасын шагыйрьнең шигъри фикерләү алымына таянып иҗат иткән. Җәлилнең тормышын һәм иҗатын билгеләүче төп рух әсәрдә образ-детальләр аша күрсәтеп бирелгән: милли культура чыганакларына ишарәләүче борынгы Болгар архитектурасы, үткәннәр турында сөйләүче Казан Кремле манаралары, шагыйрьне үлемсезлеккә озатып калган башкалабыз силуэтлары... Мәңгелек яз сулышы белән өртелгән зәңгәр төскә автор тарафыннан зур эмоциональ мәгънә салынган. Мәрхәмәтсез сугышның канлы кылычы белән өзелгән гомер җыры — үлемсез халык хәтеренә ялганган «моңлы бер җыр» күзаллана. Гомумән, рәссам Валерий Скобеев, һәрбер детальгә тирән метафорик мәгънә салып, патриот-шагыйрь Муса Җәлилнең күпкырлы образын, кабатланмас лирик портретын тудыруга ирешкән. Әлеге портретка карауга ук күңелдә таныш шигъри сүзләр яңара:

Гомрем минем моңлы бер җыр иде,
Үлемем дә яңрар җыр булып.

**Людмила КОРОБЦОВА,**
Татарстан сынлы сәнгать
музееның фәнни хезмәткәре.

Тышлыкның дүртенче битендә: композитор Нәҗип Җиһановның «Җәлил» операсыннан күренеш.


**Рөстәм МАНСУРОВ** фотолары.

*Аек бул — заманга лаек бул!*



**СЕБЕРЕП ТҮК БОЛАРНЫ!**

Светлана ПРИВИНА рәсеме.



*Бу сәхифә «Чаян» журналы редакциясе белән берлектә әзерләнде.*

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)